ӘДӘБИЯТ

10

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

ӘДӘБИЯТ
10

Ачыйк иттифакъка юл:
Ушбудыр иң тугъры юл.

Габдулла Тукай

Әүвәл әхлак бозыла,
икенче, дин бетә,
өченчедән, ул халык үзе бетә.

Гаяз Исхакый

ӘДӘБИЯТ

(XX гасыр башы һәм 20 нче еллар
татар әдәбияты)

Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең
10 нчы сыйныфы өчен дәреслек

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан тәкъдим ителгән

Төзәтелгән дүртенче басма

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2011

УДК 373.167.1:821.512.145*10
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721
Ә26

Авторлары:
М. Х. Хәсәнов, А. Г. Әхмәдуллин,
Ф. Г. Галимуллин, И. З. Нуруллин

Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы,
профессор *А. Г. Әхмәдуллин* редакциясендә

Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Әдәбият (XX гасыр башы һәм 20 нче еллар татар
Ә26 әдәбияты) : татар телендә урта гомуми белем бирү мәкт. 10 нчы с-фы өчен д-лек / [М. Х. Хәсәнов һ.б. ; А. Г. Әхмәдуллин ред.].— Төзәт. 4 нче басма.— Казан : Татар. кит. нәшр., 2011.— 399 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-02101-2

УДК 373.167.1:821.512.145*10
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721

ISBN 978-5-298-02101-2
© Татарстан китап нәшрияты, 2011

XX ГАСЫРДА ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

ГАСЫР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

XX гасырның үзенчәлеге беренче нәүбәттә социаль тетрәнүләр, сугышлар һәм инкыйлаблардан (революцияләрдән) гыйбарәт. Ул бигрәк тә Россия составына кергән халыклар тарихында ачык чагыла. Бу чорга алар капитализм ныгый барганда, милли азатлык хәрәкәтләре көчәйгәндә аяк бастылар. Гасыр башында яңа һәм яшь сыйныф — пролетариат — азатлык көрәше мәйданына чыкты. Социализм идеяләре белән коралланган бу сыйныф күп кенә илләрдә хакимиятне үз кулына алу максатын куйды. Шул максатка ирешүдә бигрәк тә Россиядәге эшчеләр сыйныфы алдынгы булды. Аның көчле оешмалары һәм партияләре барлыкка килде.

1905—1907 елларда Беренче рус инкыйлабы булды. Анда патша хакимиятенә каршы күп партияләр, халыкның төрле катлаулары берләште, пролетариат актив катнашты. Инкыйлаб җиңелү белән тәмамланды. Әмма ул халыкларга кайбер җиңеллекләр дә китерде. Аны татар җәмгыяте мисалында да күрергә мөмкин. Мәсәлән, аңарчы бернинди матбугат иреге бирелмәгән татарларга бу яктан кайбер мөмкинлекләр ачылды. Казан, Оренбург, Мәскәү, Уфа, Петербург һ. б. шәһәрләрдә берничә дистә татарча газета-журналлар чыга башлады. Алар үз чиратында татар әдәбиятының һәм сәнгатенең кызу темплар белән үсүенә зур ярдәм итте.

1906 елда профессиональ татар театры барлыкка килде. Озакламый ул «Сәйяр», «Нур», «Ширкәт» труппалары рәвешендә, театр түгәрәкләре сыйфатында җәелеп китте. Сәхнә сәнгатенең шулай тернәкләнеп китүе әдәбиятның үзенчәлекле жанры булган драматургиянең тизлек белән үсүен булдырды.

Татар музыка һәм рәсем сәнгатьләре, башкару сәнгате мөстәкыйль үсеш мәйданына чыктылар.

Россиядә инкыйлаб хәрәкәте тынмады, ары дәвам итте. 1917 елның февралендә бөтен халык күтәрелүе нәтиҗәсендә, патша бәреп төшерелде, аның хакимияте җимерелде, илдә демократик үзгәрешләр өчен киң мөмкинлекләр ачылды. Ләкин халыкларның төп теләкләре канәгатьләндерелмәде: Беренче бөтендөнья сугышы тукталмады, халыкка милли азатлык бирелмәде, җирне крестьяннарга бүлеп бирү мәсьәләсе дә хәл ителмәде. Шулардан файдаланып, большевиклар партиясе хезмәт иясен пролетариат җитәкчелеге астына туплады һәм, 1917 елның октябрендә яңа инкыйлаб ясау нәтиҗәсендә, хакимиятне үз кулына ала алды. Шулай итеп, дөньяның алтыдан бер өлешен тәшкил иткән Советлар империясе барлыкка килде.

Беренче елларда яңа хакимият Россия кул астындагы халыкларга беркадәр җиңеллек китерде. Җир крестьяннарга бүлеп бирелде, завод-фабрикаларга хезмәт ияләре, эшчеләр хуҗа, һәр милләт тигез хокуклы дип игълан ителде. Германия белән солых төзелгәч, сугыш тәмамланды. Шулар нәтиҗәсендә Октябрьдән соң башланган гражданнар сугышында да күпчелек халык большевиклар ягында булды, җиңү яулашты.

Татар халкына үзенең күптәнге изге теләге булган мөстәкыйль дәүләтчелеген төзү мөмкинлеге ачылды. 1920 елда Татарстан автономиясе төзелде. Ләкин бирелгән вәгъдәләрнең күбесе үтәлмәде, бу мөстәкыйльлек бик тә чикләнгән булып чыкты. Автономияле дәүләткә элек-электән татарлар яшәгән җирләрнең бик кечкенә өлеше генә кертелде. Шуның аркасында татар халкының дүрттән өч өлеше Татарстаннан читтә аерылып калган булып чыкты. Шуңа да карамастан киләчәккә өмет халыкны дәртләндерде. Татар теле дәүләт теле дип игълан ителде. Яңа газета-журналлар чыга башлады, аларның географиясе киңәйде: Екатеринбург, Омск, Саратов, Әстерхан, Төмән һ.б. шәһәрләр. Театр труппалары күбәйде. 1920 елларда Казанның үзендә генә дистәгә якын труппа эшләде, башка шәһәрләрдә дә яңа труппалар оешты. Театр һәм сынлы сәнгать уку йортлары ачылды, Язучылар берлекләре оештырылды.

Кызганыч, бу иркенлекләр озын гомерле була алмады. Пролетариат исеменнән хакимлек итүче большевиклар партиясе илдә тоталитар системасын торган саен ныгыта барды. Күмәкләштерәбез, колхозлаштырабыз дип, крестьян

кулыннан җире дә, җитештерү кораллары да, ат-туары да тартып алынды, үзе ярым крепостной хәленә төшерелде. Завод-фабрикаларга эшче сүздә генә хуҗа иде. Бөтен хуҗалык тармаклары бюрократиянең — партаппаратчыларның хакимлек итүенә буйсындырылды. Дингә ышанучыларга каршы аяусыз көрәш җәелдерелде: мәчетләр һәм чиркәүләр җимерелде, милли мәктәпләр кысылды. Сүз һәм рух иреге бетерелде. Тормышның барлык тармаклары коммунистик идеология белән сугарылды.

Татарстанда газета-журналлар чыгару да соңгы чиккәчә кыскартылды. Бөтен матбугатка катгый цензура урнаштырылды. Театрлар да бер-бер артлы ябылды. Башка шәһәрләрдә, республика һәм өлкәләрдә яшәүче татарлар милли телдәге газета-журналларыннан, театрларыннан һәм һәртөрле сәнгать учакларыннан мәхрүм ителде. Һәр җирдә, шул җөмләдән милли республикаларда да, руслаштыру сәясәте башланды. 1920 елларның уртасыннан алып, бигрәк тә 1930 һәм 1950 елларның башларында зыялыларны эзәрлекләү, күпләп юк итү галәмәте котырынды. Барлык милләтләрдә халыкның акылын һәм намусын тәшкил иткән зыялылар катламы юкарды. Бу репрессияләр татар әдәбиятын зур югалтуларга дучар итте. Октябрь инкыйлабы көннәрендә үк большевизм диктатурасының асылын дөрес аңлап-төшенеп алган бер өлеш язучылар чит илләргә китеп өлгерделәр. Югалтуларның икенче дулкыны 1930 елларда, Сталин репрессияләре вакытында булды. Әдәбиятыбызның төп көчләрен тәшкил иткән язучылар кулга алындылар, нахак гаепләр тагылып төрмәләргә ябылдылар, лагерьларга сөрелделәр, юк ителделәр. Чит илләргә киткәннәре дә «халык дошманнары» дип игълан ителде, мираслары юкка чыгарылды, әсәрләрен уку тыелды. Шулай итеп, татар әдәбияты Г. Исхакыйсыз, К. Тинчурин һәм Г. Ибраһимовсыз, М. Галәү һәм Ш. Усмановсыз, Ф. Бурнаш һәм Г. Нигъмәтисез калды, дистәләгән башка талантлы язучыларын югалтты.

Советлар Союзы дип аталган империянең җитмеш елга сузылган тарихында халыкларга һәм мәдәниятләргә нык зыян китергән бик күп гамәлләрне һәм вакыйгаларны күрсәтергә мөмкин. Шулардан берсе — Сталин хакимияте уйлап тапкан һәм ил күләмендә «уңышлы итеп» тормышка ашырылган нәрсә — язуда рус графикасына күчү. Грузин, әрмәннәрдән башка барлык халыкларга бу эш көчләп тагылды,

күчү процессы тиз вакыт аралыгында тәмамланды. Бәхетсезлекнең икенчесе — 1941—1945 елларда Икенче бөтендөнья сугышы — Советлар Союзы халыклары өчен һәм матди, һәм рухи яктан имтихан тоту булды. Фашизм һәм коммунизм идеологияләренең хәлиткеч бәрелешендә ярый әле соңгысы җиңеп чыкты, ни дисәң дә, соңгысы фашизмга караганда кешелеклерәк иде. Ул Европа халыкларын коточкыч бер коллыктан коткарды. Ләкин бу җиңү илебез халыкларына бик кыйммәткә төште, күп дистәләгән миллионнарча кеше үтерелде, халык хуҗалыгына хисапсыз зыян килде. Әдәбиятсәнгать зур югалтулар кичерде: татар язучыларының байтагы сугыш кырларында ятып калды, фашист лагерьларына эләгеп юкка чыкты. Лагерьларда һәм әсирлектә булып исән-сау кайтканнары да эзәрлекләнде, ирексез җәфа чикте.

1950 елларның урталарыннан, ягъни Сталин үлгәннән соң, партия диктатурасы беркадәр йомшарды, рухи тормышта кайбер демократик үзгәрешләр күзәтелә башлады. Ләкин бу чын азатлык түгел иде әле, һәм ул озын гомерле булмады. Пролетариат диктатурасы тәртипләре яңадан әйләнеп кайтты, ил халыклары «торгынлык еллары» дип аталган чорга килеп керделәр. Бу хәл 1980 елларның урталарына кадәр дәвам итте. 1985 елдан СССРда һәм башка социалистик илләрдә яңа үзгәрешләр чоры башланды. Илдә базар мөнәсәбәтләре барлыкка килде, шәхси эшчәнлеккә һәм хосусый милекчелеккә юл ачылды. Сүз иреге килде, цензура бетерелде, рухи хөрлек туды. Советлар Союзы таркалды, милләтләрнең күпчелеге үз дәүләтчелеген булдыруга юл алды. Татарстан да мөстәкыйльлек юлына чыкты. Явыз Иван патша Казанны басып алгач югалткан дәүләтчелеген яңадан торгызу өчен көрәш башлады. Бу көрәш, аерым югалтуларга да карамастан, бүген дә дәвам итә.

Татар әдәбиятының сикәлтәле юллары

Сезгә, хөрмәтле укучылар, иҗтимагый фәннәр, тарих дәресләре буенча инде күпмедер күләмдә билгеле булган бу мәгълүматларны ни өчен тагын бер тапкыр кабатладык соң әле? Аларның матур әдәбиятка ни мөнәсәбәте бар дисезме? Бар һәм турыдан-туры. Чөнки матур әдәбият кеше турында, аның яшәеш рәвеше, рухи дөньясы турында бөтен кешелек тарихы, иҗтимагый мөнәсәбәтләр яктылыгында мәгълүмат

бирә. Илдә бара торган тарихи һәм иҗтимагый-сәяси хәлләр, кешелекне борчыган сораулар матур әдәбиятта чагылыш таба, әдәбиятның үсеш үзенчәлекләрен барлыкка китерә.

Татар әдәбияты XX гасырга барлык жанрлары формалашкан, мәгърифәтчелек реализмын уңышлы үзләштерә барган хәлдә килеп керде. Беренче рус инкыйлабыннан соң илдә туган шартлар аның тизлек белән үсеп китүенә юл ачты. Шуннан соңгы 10—15 елда татар әдәбияты һәм тематикасы, һәм сәнгатьчәлеге белән яңа үрләргә күтәрелде. Иң мөһиме: кешенең җанын, рухын, иҗтимагый омтылышларын, җәмгыять тормышындагы урынын аңлауда зур үзгәреш барлыкка килде. XIX гасырда әдәби әсәрләрдә аңлы-мәгърифәтле кеше үзәккә куела, кешенең шәхси бәхете аң-белемгә бәйләп карала иде. XX гасыр башындагы язучылар кешегә бәхетле булу өчен болар гына җитми икәнлегенә төшенделәр. Беренчедән, кешенең асыл хасиятен табу һәм күрсәтү өчен, иҗтимагый шартлар да мөһим роль уйный дип, икенчедән, кешенең яшәешендә милләтнең язмышы да зур урын тота дип, мәсьәләгә яңача карый башладылар. Гади-гадәти кеше образы әдәбиятның үзәгенә куелды. Аның борчу-шатлыклары, моң-зары, өмет-теләкләре киң чагылыш тапты. Шуның белән бергә, тормышны үзгәртеп кору, искелекләрдән котылу өчен, кеше көрәшче дә булырга тиешлеге ачык итеп куелды. Кыскасы, XX йөз башы әдәбияты кешенең яшәү фәлсәфәсен проблема итеп күтәрде. Кеше үзе өчен яшиме, ягъни аның шәхси бәхете мөһимме? Кеше әллә башкалар өчен дә яшәргә тиешме, аның халык бәхете өчен көрәшүе мөһимрәкме дигән сораулар куелды. Ләкин мәсьәләне, нигездә, соңгысы файдасына гына хәл итү Октябрь инкыйлабыннан соң барлыкка килгән совет әдәбиятында берьяклы үсеш алды. Кеше иң әүвәл көрәшче булырга тиеш, хезмәт иясе бәхете өчен көрәш — кешенең яшәеш нормасы, дип каралды. Икенче сүзләр белән әйткәндә, сыйнфый көрәш шәхес бәхете өчен көрәштән өстен куелды. Аерым сыйныф мәнфәгатьләре гомумкешелек кыйммәтләрен (миһербанлык, игелек, рухи хөрлек, кешегә хөрмәт, ата-ананы һәм баланы ярату, туган телеңне, милләтеңне сөю һ. б.) күмеп китте, артка калдырды. Нәтиҗәдә совет әдәбиятында шәхес мәнфәгате арткы планга чигерелде, аңа сан бетте. Һәр кешенең шәхси бәхеткә дә хакы барлыгы, кеше җәмгыятьтә бер шөреп кенә булмыйча, үзе бер дөнья икәнлеге әдәбияттан кысрыклап чыгарылды. Иҗтимагый хаҗәтләр белән генә

шөгыльләнгән, үз теләкләрен шуларга корбан иткән кеше образы совет әдәбиятының үзәгендә торды, кешенең бер үк вакытта кабатланмас шәхес тә булырга мөмкин икәнлеге еш кына онытылды. Бу үз чиратында әдәбиятта психологизмның роле кимүгә китерде, әзер, схематик сюжетлар өстенлеген булдырды.

Дөрес, ил тарихының аерым чорларында әдәбият мондый тарлыклардан беркадәр тайпылгалады. Шундый үзгәрешне Бөек Ватан сугышы (1941—1945) елларында күзәтергә була иде. Сугыш вакытында фронтта һәм тылда булган авыр һәм фаҗигале хәлләргә эләккән кешенең рухи халәтен сурәтләүдә, мәсәлән, яңа бизәкләр кулланылды.

Совет хакимияте елларында кеше шәхесенә карата мондый берьяклы карашның өстенлек итүенә дә карамастан, әдәбиятның аерым казанышлары булганын да кинәнеп әйтергә кирәк, ягъни ул үсешен туктатмады. Әлбәттә, бу үсеш темпын XX йөз башындагы яңарыш колачы белән чагыштырып булмый иде. Гасырның беренче чирегә әдәбият өчен аерата уңдырышлы булды. Яңа жанр төрләре һәм формалары барлыкка килде. Психологик һәм иҗтимагый роман, фантастик повесть, романтик хикәя һәм драма, гражданлык лирикасы, трагедия һ.б. жанрлар туды, булганнары тагын да үсте һәм баеды. Модернистик характердагы әсәрләр язылды. Кешене сурәтләүдә төп алымнардан берсе булган психологик анализ тирәнәйде. Әдәби тел нормалары тагын да ачыкланды.Нәкъ менә шушы чорда элек чит теллардән алынган сүзләрдән котылу, әдәби телне халык теленә, саф һәм җанлы телгә якынайту юнәлешендә җитди адымнар ясалды. Г. Тукай, Г. Исхакый, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Коләхмәтов, Г. Ибраһимов, Дәрдемәнд, М. Гафури һ.б. язучылар әсәрләре чын халыкчан, образлы тел белән язылган булулары белән аерылып тордылар.

Совет чорында әдәби тел өлкәсендәге казанышлар алга таба үстерелде. Ләкин монда югалтулар да булды. 1929 елда әдәбиятыбызга һәм мәдәниятебезгә меңнәрчә ел дәвамында хезмәт иткән гарәп графикасы латин хәрефләре белән, ә 10 елдан соң рус графикасы белән алыштырылды. Барча кимчелекләре өстенә бу хәлләр, бигрәк тә икенчесе, яңа буынны гасырлар дәвамында тупланып килгән әдәби тел байлыкларыннан аерды. Шуннан соң әдәби телне нормалаштыруда, терминологиядә руслашу китте. Тик соңгы елларда гына, һәр

өлкәдә яңарыш һәм үзгәртеп кору башлангач, әдәби телебезне табигый хәленә кайтару процессы көчәйде. Җирле сөйләм хәзинәләренә караш үзгәрде. Алар хәзер әдәби телне чупләүчеләр итеп түгел, аны баету чыганаклары буларак карала башлады.

Мондый үзгәрешләрне әдәбиятның башка өлкәләрендә дә күзәтергә була. Мәсәлән, иҗат методын аңлау, аңа мөнәсәбәт мәсьәләсендә. XX гасыр башында татар әдәбияты бик тиз арада тәнкыйди реализмны да, романтизмны да үзләштерде, шулар нигезендә язылган күренекле әсәрләр белән баеды. Совет чорында, алда әйтелгәнчә, кешене аңлау һәм аңлатуда яңа принциплар урнашты. Коммунистик идеология тәэсире астында иҗат методын да Совет хакимияте мәнфәгатьләренә буйсындырып үзгәртүгә йөз тотылды, аны сыйнфый көрәш максатларына хезмәт иттерергә тырышу көчәйде. Бу «яңартылган» методның исеме «социалистик реализм» дип аталды.

Матур әдәбиятның төп принципларыннан берсе аңарда тормыш тулысынча чагылдырылырга тиеш. Чагылдыру нәкъ тормыштагыча, ягъни яшәештә ничек булса, шул рәвешле булырга мөмкин. Шулай ук тормышны үзгәртеп-арттырып та чагылдырырга була. Әйтик, хыялый әкияттәге кебек. Икенче сүзләр белән әйткәндә, реалистик сурәтләү чаралары белән дә, шул ук вакытта фантастика ысулы белән баетылган романтика һәм символика чаралары, модернистик алымнар ярдәмендә дә булуы ихтимал.

Социалистик реализм методының кагыйдәләрендә дә тормыш дөрес һәм тулы итеп чагылдырылырга тиеш дигән таләп бар. Ләкин шул ук вакытта бу метод тормышны башлыча революцион үсештә күрсәтүне максат итеп куя. Нәкъ менә шул соңгысына таянып, партиячел догматиклар яңа иҗат методын тормышны буяп-бизәп күрсәтүгә хезмәт иттерә башладылар. Менә бер мисал. Колхозлашу крестьянның җиргә, мал-туарга электән килгән мөнәсәбәтен йомшартты, хезмәткә кызыксынуын киметте. Колхозлар, янәсе, крестьянның авыр тормышын җиңеләйтү өчен төзелде, дип расладылар догматиклар. Әлегә колхозлар ярлы, тәртип тә юктыр, әмма алар, һичшиксез, баерга тиешләр, моңа инкыйлаби үсеш ноктасыннан карарга кирәк, диделәр. Бәс, шулай икән, әдәби әсәрләр дә колхозның бүгенге хәлен киләчәктә ничек булачагыннан чыгып сурәтләргә тиеш. Ә бүгенге авырлыкларда казынып яту ул, имеш-

тер, социалистик реализмнан читкә китү була. Менә шундый «теоретик» раслаулар нигезендә совет әдәбияты тормышны бар булганынча, дөрес итеп сурәтләүдән шактый ераклашты, күпчелек әсәрләрдә совет чынбарлыгы бизәп-төзәтеп тасвирланды. Сәнгатьлелек ягыннан әйбәт эшләнгән, ә тормыш дөреслеге җәһәтеннән гарип әсәрләр язылды. Иң әйбәт дигән әсәрләрдә дә дөреслек ярым-йорты рәвеш алды. Ә дөреслек җитмәгән әдәбиятның, билгеле инде, укучыга тәэсир көче дә тиешенчә булмый, ул үз вазифасын тулы үти алмый.

Илдә 1985 елдан башланган кискен үзгәрешләр, Татарстанның мөстәкыйльлек өчен көрәше татар әдәбиятына яңа рух өрде. Кешенең рухи дөньясына игътибар бермә-бер артты, аны олылау, һәркемгә кабатланмас шәхес итеп карау алгы планга басты. Бер генә сыйныфны — пролетариатны — югары күтәреп тә, башка сыйныфларга кимсетүле караш юкка чыга бара. Гомумкешелек мәсьәләләрен пропагандалау көчәя. Милли аңны уятуга һәм көчәйтүгә, туган илгә һәм туган телгә, туган якка һәм табигатькә мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләүгә әдәбият торган саен ныграк игътибар итә. Татар әдәбияты төрле идеология таләпләреннән арына, анда тормышчан дөреслек арта бара.

Сораулар һәм биремнәр

1. XX гасырда халкыбыз узган тарихи юлны күздән кичерегез. Бу гасырның үзенчәлекләрен күрсәтегез.

2. XX йөз тарихында коммунистик идеологияне берьяклы һәм тарайтып аңлату нинди фаҗигаләргә китерде?

3. Бу гасырда Россиядә ничә инкыйлаб булды? Алар халыкка ни бирде?

4. Илдәге вакыйгалар татар әдәбияты үсешендә нинди үзгәрешләр тудырды? Кеше образын сурәтләүдә борылыш моментларын күрсәтегез.

5. Татар әдәбиятының совет елларында нинди зур югалтуларга дучар ителүен дәлилләп күрсәтегез.

6. Татар язу графикасын үзгәртүләрнең әдәби традицияләрне ничек итеп юкка чыгаруын үз сүзләрегез белән аңлатыгыз.

7. Тормыш дөреслеген сез ничек аңлыйсыз? Әдәбиятта тормыш дөреслегенә ирешү бер генә шәкелдә (формада) буламы?

8. «XX гасырда татар әдәбияты үсеш кичерде» дип әйтергә нинди дәлилләр бар? Шул турыда фикер алышыгыз.

ЯҢА ГАСЫРГА АЯК БАСКАНДА

Әдәбият-сәнгать үсешен тәэмин иткән алшартлар һәм сәбәпләр

XX гасыр башында татарлар үз хокукларын яклауга шактый актив күтәрелделәр.

1905—1907 еллар инкыйлабы күтәрелешләрендә татарларның оешкан төстә катнашуларының бер төп сәбәбе форсатны милли азатлыкка ирешү өчен файдалану була.

Россия дәүләте, XVI гасыр урталарыннан башлап, бер-бер артлы Идел, Урал буе, Урта Азия, Себер, Ерак Көнчыгыштагы җирле халыкларны буйсындырып, ул урыннарда колониаль хакимият урнаштыра. Изелгән халыклар бу хәл белән килешеп яшәргә теләмиләр, мөмкин булган саен Россия хакимиятенә каршы көрәшкә күтәреләләр. Мәсәлән, 1755 елда — Батырша, 1773—1775 елларда Пугачёв җитәкчелегендәге (аның аеруча күренекле тарафдарлары татарлар Бәхтияр Канкаев, Мәсәгут Гомәров һәм башкорт Салават Юлаев) татар, рус, башкорт һәм башка халыклар патша хакимиятен шактый куркуга салалар.

Татарлар арасында шуңа охшаш милли-азатлык өчен көрәш хәрәкәтләре, әле анда, әле монда бер көчәеп, бер сүрелеп, һаман дәвам итә. Безнең тарихта, мәсәлән, шундый аеруча дәвамлы көрәш вәисевчеләр исеме белән бәйле.

Баһаветдин Хәмзә улы Вәисев (1819—1894) XIX гасырның алтмышынчы еллары башында ислам динен сафландыру, аны һәртөрле бозулардан саклау максаты белән хәрәкәт башлап җибәрә. Аның уйлавынча, ислам дине мөфтиләр, ишаннар, муллалар тарафыннан бозылып беткән. Коръәнне төрлечә үзгәртүләргә юл куелмаска тиеш. Вәисевчеләр халыкны әнә шулай динне бозучы муллалар белән исәпләшмәскә өндиләр. Байлар һәм ярлыларга бүленмәгән гадел җәмгыять төзү аларның изге максаты була. Ләкин мондый хәрәкәт патша хакимиятен борчуга сала, шуның өчен вәисевчеләрне Себергә сөрәләр. Баһаветдин Вәисев исә 1884 елда сәламәт килеш юләрләр йортына ябыла. Ул анда ун ел буе интектерелә.

1904 елда аның улы Гайнан Вәисев Урта Азиядән Казанга кайта һәм әтисенең эшен дәвам иттерә. Ләкин 1909 елда аны да Сахалин утравына сөрәләр.

1917 елгы Февраль инкыйлабыннан соң Г. Вәисев үз хәрәкәтен большевиклар белән якынлаштыра. Ләкин бу ясалма берләшү була. Чөнки большевиклар эшчеләр сыйныфын бәхетле итүне максат итсәләр, вәисевчеләр барлык сыйныфларны да «бертуганнар» итеп күрергә телиләр. Алар Мөселман яшел гвардиясе төзиләр. Ләкин Г. Вәисев 1918 елда һәлак ителә. Җитәкчелек аның энесе Газизҗан кулына күчә. Большевиклар мөселманнардан гына торган хәрби берләшмәнең яшәвеннән куркалар, вәисевчеләр оешмасын 1921 елда тулысынча юк итәләр.

1905—1907 еллардагы халык күтәрелеше, патша идарәсе машинасын җимерүгә ирешә алмаса да, аны шактый какшатты. Шуның нәтиҗәсендә күпмедер дәрәҗәдә ирек бирелү белән үк татарлар яши торган барлык төбәкләрдә дә диярлек вакытлы матбугат барлыкка килә.

Татар телендә беренче газета 1905 елда Петербургта чыга. Җәмәгатьчелек 2 сентябрьдә «Нур» газетасын кулына ала.

Шул ук елның 29 октябрендә «Казан мөхбире» («Казан хәбәрләре»), тагын бер айдан Җаекта «Фикер» газеталары дөнья күрә. Нәкъ бер айдан Казан шәкертләре яшерен рәвештә «Әлислах» газетасын чыгара башлыйлар. Ә 1907 елның 3 октябреннән аңа да рөхсәт бирелә. 1906 елның гыйнвар-февраль айларында Казанда бер-бер артлы «Йолдыз» һәм «Азат» газеталары басыла. 1906 елның 24 маенда «Азат» ябылгач, Галиәсгар Камал шул ук елның 4 июленнән «Азат халык» исеме белән газета чыгара башлый. 1907 елның 4 гыйнварында Хөсәен Ямашев тырышлыгы белән Оренбургта «Урал» газетасы дөнья күрә.

1906 елның 18 маенда Казанда тагын бер газета — «Таң йолдызы» дөньяга чыга. Аңа Гаяз Исхакый, Фуат Туктаров, Сәгыйть Рәмиевләр җитәкчелек итә. «Йолдыз» газетасы алар арасында иң озын гомерлесе була (1906 елның 15 гыйнварыннан алып 1918 елның 30 маена кадәр 1895 саны басыла). Анда Г. Камал, Г. Тукай, Һ. Атласи, Г. Ибраһимов, З. Вәлиди, М. Гафури, Ш. Әхмәдиев, Н. Думави һ. б. үз мәкаләләрен, әсәрләрен бастыралар.

Оренбургта «Вакыт» (мөхәррире — Фатих Кәрими) 1906 елның 21 февраленнән 1918 елның 26 гыйнварына кадәр, Җаекта «Фикер» газетасы (мөхәррире — Камил Мотыйгый) 1905 елның 26 ноябреннән 1907 елның маена кадәр чыга. Аларның барысы да татар язучыларының якыннан булыш-

лыгы белән яшәп килә. Бу исә әдәбиятыбыз үсешенә уңай шартлар тудыра.

Шул ук вакытта төрле журналлар да чыга: Җаекта «Әлгасрелҗәдит», «Уклар» сатира журналы, Оренбургта «Карчыга», «Чүкеч», Әстерханда «Туп», Казанда «Яшен», «Ялт-йолт». 1908—1918 еллар арасында — ун ел буе — Оренбургта чыккан «Шура» (мөхәррире — Риза Фәхреддин), Казандагы «Аң» журналлары татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертәләр. Оренбургта чыккан «Дөнья вә мәгыйшәт[1]» (соңыннан «Дин вә мәгыйшәт»), Казандагы «Әд-дин вә әдәп»[2] журналлары, шулай ук Казанда басылган «Бәянелхак» газетасы халкыбызны дини, милли рухта тәрбияләүдә, гореф-гадәтләребезне саклау юлында аңлату һәм оештыру эшләре алып бардылар.

Шулай итеп, XX йөз башында татар вакытлы матбугаты халыкның милли, дини, сәяси аңын үстерүдә, аны бер максатка — милләткә азатлык яулап алуга туплауда бик әһәмиятле эш башкарды. Халкыбызның меңьеллык язу тарихы, китап ярату кебек асыл сыйфаты булмаса, газета-журналлар чыгаруны кыска вакыт эчендә шулкадәр киң колачлы итеп оештыру мөмкин булыр идемени?! Әлбәттә, монда шагыйрь һәм язучыларыбызның матбугат булдыруда һәм аны яшәтүдә каһарманнарча тырышлык күрсәткәннәрен билгеләп үтү дә зарур. Вакытлы матбугат үз чиратында сүз сәнгатебезнең моңача һич күрелмәгәнчә үсеп китүен тәэмин итте.

Халыкның үз исәбенә тоткан уку йортларының саны XIX йөз ахырында һәм XX йөз башында аеруча күбәя. Милли мәктәпләр, Татар укытучылар мәктәбе алдынгы карашлы яшьләргә туплану һәм бергәләп төрле юнәлешләрдә фикерләшеп эшләү өчен уңайлы үзәк булалар. 1902 елда, мәсәлән, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә Фатих Әмирхан җитәкчелегендә әдәби түгәрәк оеша, биредә өч ел буе әдәби кичәләр уздырыла, әсәрләрне күмәк укулар, алар турында фикер алышулар алып барыла.

Укытучылар мәктәбендә белем алучы татар яшьләре XIX гасырның соңгы елларында ук рус телендә спектакльләр куялар. Алар, әлбәттә, татар телендә дә уйнарга дәртсенәләр. Ләкин җирле хакимиятләр һәм мәктәп идарәсе моңа рөхсәт бирмиләр.

---

[1] *Мәгыйшәт* — тормыш.

[2] *«Әд-дин вә әдәп»* — «Дин вә әдәп».

Шулай да алдынгы яшьләр, бер урында уңышсызлыкка очрасалар, икенче урында күтәрелеп чыгалар. 1900 елда Касыйм шәһәрендә (хәзер Рязань өлкәсе) ике көн рәттән татарча спектакль уйнала.

Казанда беренче татарча спектакльне 1903 елның 30 декабрендә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе яшьләре уйный. Ул Г. Камалның «Бәхетсез егет» әсәре (беренче варианты) була. Аны бик яшерен уйныйлар, карарга да теләсә кемне кертмиләр, сер тотардай шәкертләр генә чакырыла. Ф. Әмирхан уйнаучыларга грим сала һәм тамаша вакытында суфлёрлык итә. Спектакльдә хатын-кызлар ролен егетләр башкара. Мәдрәсә мөдәррисе Галимҗан Баруди бу хәлне бары тик «эш узгач» кына ишетеп белә.

1906 елның 21 апрелендә Уфа яшьләре Г. Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш» әсәрен клубта куярга рөхсәт алалар. Моны җәмәгатьчелек алдында яшеренмичә куелган беренче татарча спектакль дип санарга мөмкин. Ике атнадан соң (5 майда) Казанда да «Шимбә» түгәрәге әгъзалары көче белән «Кызганыч бала» һәм «Гашыйк бәласе» спектакльләрен рәсми төстә рөхсәт алып куюга ирешелә. Рөхсәтне мең бәла белән заманының күренекле зыялысы Ибраһим Терегулов ала. Шул ук елның 22 декабрендә әлеге әсәрләр Яңа клубта кабат уйнала. Спектакльдә Фатих Әмирхан да катнаша. Дөрес, әлегә бу һәвәскәр артистлар спектакле була. Алар, «Яшьләр» дигән театр труппасы оештырып, алга таба бербер артлы Г. Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш», «Ике гыйшык», «Алдым-бирдем», Г. Камалның «Бәхетсез егет», Я. Вәлинең «Оят яки күз яше», Д. Таҗдаровның «Яшь хатын» һ. б. әсәрләрне сәхнәләштерәләр. Мондый спектакльләр 1910 елга кадәр, ягъни 1907 елда Оренбургта оешкан «Сәйяр» исемле артистлар төркеме Казанга бөтенләйгә күченеп килгәнгә кадәр дәвам итә. Шуннан соң инде профессиональ театр тарихы башлана. Театр сәнгатенең барлыкка килүе татар мәдәнияте тормышында бик әһәмиятле вакыйгага булып әверелә.

Сораулар һәм биремнәр

1. 1905—1907 еллардагы инкыйлабка татар халкы нинди өметләр баглый?

2. Матбугат ирегеннән татар җәмәгатьчелеге ничек файдалана?

3. Газета-журналларның күпләп чыгуы әдәбият үсешенә ничек тәэсир итә? Бигрәк тә кайсы язучылар вакытлы матбугат чыгару эшендә аеруча тырышлык күрсәтәләр?

4. Милли театрны булдыруда татар яшьләренең роле турында сөйләгез.

5. Рәсми хакимиятләр, азчылык милләтләрнең театр сәнгатен булдырмау өчен, нигә төрле киртәләр коралар?

6. Беренче татарча спектакль уйнауның әһәмияте нәрсәдә? Бу өлкәдә зур хезмәт күрсәткән шәхесләрдән кемнәрне беләсез?

7. «XX йөз башында татар матбугаты» дигән күргәзмә яки альбом әзерләгез.

8. «Татар театры: үткәне һәм бүгенгесе» дигән кичә үткәрегез. (Г. Камалның «Беренче театр» әсәрен әзерләргә тырышыгыз.) Бу кичәгә, мөмкин булса, әдәбият-сәнгать әһелләрен дә чакырыгыз.

Сүз сәнгате үсешенең яңа күтәрелеше

XX йөз башында татар әдәбиятының киңәеп үсеп китүе буш урында гына була алмас иде. Моңа XIX гасырның икенче яртысындагы сүз сәнгатендә ирешелгән казанышлар әйбәт нигез булып хезмәт итте. Бу чорда мәгърифәтчелек реализмы чын мәгънәсендә мәйдан тотты. Мәгърифәтчелек әдәбиятының төп уңай ягы шунда булды: ул кеше акылын зурлады, яшәешебезне алга таба камилләштерү өчен гыйлем-мәдәният кирәклеген исбат итте; акылга, фәнгә, гамәли эшкә таянып, татар җәмгыятен үсешкә алып барып булачагын аңлатты.

XX гасыр башында татар әдәбиятында төгәл кыйбла булдыру турында, Көнчыгышка әллә Көнбатышка йөз тотаргамы дигән мәсьәлә тирәсендә бәхәс барды. Шагыйрь Нәҗип Думави Көнчыгыш белән элемтәләрне саклауны куәтләде. «Без, татарлар, һичшиксез, «шәркыймез». Канымыз — шәрык каны. Бөтен тарихи күренешләремез, тарихи хәлләремез, тарихи моң-зарларымыз «шәркый». Әлбәттә, рухыбыз буенча без шәркый (көнчыгышныкы)». Бу яктан Н. Думави хаклы. Ләкин башка Шәрык халыкларыннан без иң төньякта яшәвебез белән аерылып торабыз. Телибезме-теләмибезме, без Көнбатышның да тәэсирен тоймый тормыйбыз. Ф. Әмирхан бу турыда болай дип искәртә: «Менә хәзер ун ел инде без Европа цивилизациясенә юнәлеш тотып яшибез».

Бу яктан Г. Тукайның карашы кызыклы. Ул 1912 елда «Кояшның көнбатыш яктан чыгуы» дигән шигырь яза. Кояш, әлбәттә, бары көнчыгыштан гына чыга, аның кире

яктан күтәрелүе заман ахырында гына булуы ихтимал, дигәннәр борынгылар. Шушы фикерне әйткәннән соң, Г. Тукай гыйлем кояшының Көнбатыш тарафыннан килүе турында әйтә, Көнчыгышны киләчәктә ни көтәдер дигән борчылуын да белдерә.

Әлеге мәсьәләне 1906 елда М. Гафури да күтәрә. Ул «Аурупа-Азия» исемле шигырендә бу ике кыйтганы (континент) бер-бере белән бәхәсләштерә. Аларның һәркайсы үзенең өстенлеген яклый. Аурупа (Европа) үзенең мәдәнилеге белән мактана. Ләкин гыйлемне кешегә файдалы гамәлләр өчен генә файдаланырга кирәк, ә хәзергә Европадан золым да килә, ди Азия. Автор гыйлем-мәдәниятнең уңай якларын кай тарафтан килүенә карамастан кабул кылырга кирәклеген хуплый.

Мәгърифәтчелек реализмы белән иҗат итүчеләр ахыр чиктә Көнбатыш казанышларына өстенлек бирделәр. Бу — аларның берьяклылыгы һәм, әйтергә кирәк, кимчелеге дә булды. Монда җәдитчелек хәрәкәтенең (иске тормышка яңалык кертергә омтылыш) тәэсире сизелде. Җәдитчелек кадимчелекне (искелекне яклау), нигездә, Көнчыгышка гына табыну дип карады.

Дөресендә мәгърифәтчелек белән җәдитчелекне күпмедер дәрәҗәдә бер юнәлештә баручы хәрәкәтләр дип карарга кирәк иде. Бу вакыттагы күпчелек каләм осталары иҗатында ул нәкъ шул рәвешчә күренде. Мәсәлән, Г. Тукайны һәм мәгърифәтче, һәм җәдитче итеп карый алабыз. Аның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» әсәре генә дә безгә шулай әйтергә мөмкинлек бирә. Үз чорындагы татар тормышын тәнкыйтьләп, ул аны заман таләпләренә туры килерлек итеп үзгәртеп кору мәсьәләләрен көн тәртибенә куя. Дөрес, без бу әсәрне тәнкыйди реализм дигән иҗат методы белән язылган дип әйтә алабыз. Ләкин тормыш бик катлаулы булган шикелле, әдәби әсәргә дә бер үлчәм белән генә якын килергә ярамыйдыр. Бер үк әсәрнең үзендә төрле иҗат юнәлешләре берләшкән булырга мөмкин.

Р е а л и з м вакыйгаларны, кешеләрне, аларның тормышын һәм яшәү рәвешен чынбарлыктагыча сурәтләү дигәнне аңлата. Ләкин реалист язучы төрлечә эш итәргә мөмкин. Мәсәлән, натуралист язучы үзе яза торган даирәне, күренешне, укучы өчен кызыклымы ул, юкмы, энәсеннән җебенә кадәр бөртекләп сурәтли. Мәгърифәтче реалист исә акылы,

белеме, һөнәрлелеге, әхлаклылыгы белән башкалардан нык аерылып торган кешенең өстенлеген күрсәтердәй нәрсәләрне сайлап алып яза. Тәнкыйди реалист җәмгыятьтәге һәм кешеләр яшәешендәге чынбарлыкның уңай якларын күрсәтүдән бигрәк төп игътибарын караңгы, тискәре күренешләрне ачып бирүгә юнәлтә һәм шуның белән болай яшәү рәвешенең алга таба яхшыга илтмәячәген сәнгать чаралары ярдәмендә исбатлый. Димәк ки, реализмның мәгърифәтчелекне һәм тәнкыйть итүне максат итеп куйган юнәлешләре табигый юлдашлар булып чыга. Алар әдәбиятта бер-берсенә комачаулык итмиләр, бәлки кулга-кул тотынышып баралар, хәтта бер-берсен тулыландыралар да.

Закир Һадиның «Җиһанша хәзрәт» повестен, мәсәлән, бу ике иҗат алымының кушылмасы итеп карарга мөмкин. Җиһаншаның шөһрәт, байлык сөючән, кире, үзсүзле, авыр холыклы кеше булып әверелүендә тәрбиянең, мохитнең тәэсире күрсәтелү белән бергә, әсәрдә шул чор җәмгыяте тәнкыйтьләнә дә. Әмма хәлне ничек үзгәртергә соң? Автор, кулыннан килгәнчә, дөресрәге, үзенең карашларыннан чыгып, моның юлларын да күрсәтә. Ул Хәсән мулла сүзләреннән аңлашыла: «Халыкның фикерләрен төзәтергә кирәк, фикерләре үзгәргәч, эшкә килгәндә эшләүчеләр булыр». Халыкны теге яки бу юнәлештә хәрәкәткә китерү өчен, башта аны шул эшнең асылын аңлаткан тәгълимат белән коралландырырга кирәк, төшенү, аңлау исә гамәли адымнар ясауга китерә. Димәк, тормышны үзгәртеп кору юлларын мәгърифәтчелек әдәбияты да билгеле күләмдә һәм үзенә хас рәвештә күрсәтми кала алмаган икән.

XX йөз башы татар әдәбияты турында сүз барганда, биредә стиль, жанр төрлелеге ягыннан да үсешнең тизләтелгән адымнар белән барганлыгына игътибар итми булмый. Мәсәлән, Европа әдәбиятларында классицизм, мәгърифәтчелек реализмы, сентиментализм һәм романтизм күренешләре озак вакытлар дәвамында әкренлек белән үсеп формалашканнар. Бездә әдәбиятның үсеше исә шактый үзенчәлекле. Урта гасырлар татар әдәбияты, нигездә, романтик рухлы булып үссә, XIX йөзнең ахырында, бигрәк тә XX гасырның башында реализм (аның мәгърифәтчелек реализмы, тәнкыйди реализм дигән юнәлешләре), романтизм (гыйсъянчылыкны да кертеп) — һәммәсе бергә хәрәкәткә килә һәм сүз сәнгатебезнең күп бизәкле булып әверелә баруына китерә. Шулай итеп,

XX йөз башы татар әдәбияты — гаять бай, катлаулы һәм бик кызыклы иҗат мәйданы ул. Монда, язучыларның иҗатына күзәтү ясаганда, бусы мәгърифәтчелек реализмы, монысы тәнкыйди реализм, болары романтизм белән язылган әсәрләр дип кистереп кенә әйтеп булмый торган күренешләр дә бар. Ягъни шушы иҗат ысулларының катнашмасы булганнары еш очрый.

Язучы үз әсәрен иҗат иткән вакытта катлаулы тормышның нинди өлкәләрен, вакыйгаларын алса, шуларны нинди уйлар, ниятләр белән сурәтләсә (яратыпмы — тәнкыйтьләпме, сокланыпмы — нәфрәтләнепме, дулкынланыпмы — салкын кан беләнме, әсәрләнепме — битарафмы, үгет-нәсыйхәт беләнме — дөрес мәгълүмат бирү теләге беләнме), әсәр дә шул омтылышка буйсына, сурәтләү чаралары да, стиле дә, сүзләр сайлавы да, хәтта җөмлә төзелеше дә әлеге бурычны тормышка ашыруга хезмәт итә. Гасыр башында каләм осталарын дулкынландырган һәм аларның иҗади омтылышларын билгеле торган хәл-әхвәлләр куердылар, кискенләштеләр, тиз-тиз алышынып тордылар, шуңа күрә язучыларыбыз иҗат гамәлендә сурәтләү ысулларының һәм чараларының да күп төрләренә мөрәҗәгать иттеләр. Әлбәттә, үзләрен кызыксындырган мәсьәләләрне чынбарлыкка якын итеп тасвирларга тырыштылар. Г. Тукай («Государственная Думага», «Безне урынсызга яманлыйлар», «Китмибез!» шигырьләре), Ф. Әмирхан («Яшьләр», «Тигезсезләр» пьесалары, «Урталыкта» романы), З. Һади («Җиһанша хәзрәт» хикәясе) һәм башка байтак авторларның әсәрләре шуны раслый.

XX йөз башында тормыш бер көй белән генә барды дип әйтеп булмый. 1904—1905 елларда Ерак Көнчыгышта японнар белән сугыш, 1905—1907 елларда халыкның патша хакимиятенә каршы көрәше, 1914 елда башланган империалистик сугыш — һәммәсе дә җәмгыятьне, кыл өстендә торткандай, киеренкелеккә дучар итте. Мондый гадәттән тыш хәлләр үз чиратында каләм осталарының иҗатына да тәэсир итми калмады. Әдәбиятта романтизм үзен нык сиздерде. Романтик әсәрдә геройларның күңел дөньяларын гадәттән тышрак, хисси рухта сурәтләү хас. Без моны С. Рәмиевнең «Таң вакыты», Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр», Дәрдемәнднең «Кораб», Ф. Бурнашның «Таһир — Зөһрә», Һ. Такташның «Газраилләр», «Күктән сөрелгәннәр» һәм башка талантлы язылган әсәрләрендә күрәбез.

Шул ук вакытта әдәбиятта тормышны өр-яңача, заманга бәрабәр сурәтләү өчен эзләнүләр алып барылды. Сурәтләү чаралары һәм ысулларының яңаларын табуны үзмаксат итеп куючыларны модернистлар (модернизм француз телендә өр-яңа дигәнне аңлата) дип атадылар. Модернизмның импрессионизм, экспрессионизм, футуризм, абстракт сәнгать һәм башка төрләре бар иде. Аларның мәгънәсе аңлашылмаган яклары булу белән бергә, чыннан да, сүз сәнгатенә яңа сулыш өрүгә китергән уңай сыйфатлары да булды. Мәсәлән, Ш. Камал хикәяләрендә һәм «Акчарлаклар» повестенда импрессионизм (французча тәэсир дигән сүздән) алымын урыны-урыны белән уңышлы гына куллана. «Акчарлаклар» — хис-тойгылар әсәре. Газизә, Гариф кебекләрнең күңелендәге хисләр белән табигать күренешләре бәйләнеше, мохитнең кеше халәтенә аваздашлыгы әсәр тукымасында оста итеп бирелә. Әдип, кеше күңелен үзе теләгән кәеф, рух чолганышында сурәтләп, укучыга көчле тәэсир ясый. Табигать халәте кеше кәефенә тәэсир итеп кенә калмый, алар бербөтен булып берләшәләр. Әлбәттә, «Акчарлаклар» тулаемы белән импрессионизм әсәре дип карала алмый. Ул,— дөресендә, реалистик повесть. Ләкин вакыт-вакыт, тәэсир итүне көчәйтү максаты белән, Ш. Камал «Диңгез көлә», «Егет елый», «Яшь күңел» кебек бүлекләрдә геройларның күңел дөньяларын бирүнең үтә нечкә мөмкинлекләрен таба. Импрессионизм йогынтысында язылган «Козгыннар оясында», «Уяну» хикәяләрендә Ш. Камал үзе сурәтләгән образларның кайберләрен тәнкыйтьли дә, XX йөз башындагы Россия чынбарлыгының караңгы якларын — эшчеләрне кешелек сыйфатларыннан мәхрүм итүче тормышны ачып сала. Бу — импрессионизмны тәнкыйди юнәлештә куллануда ул алып килгән яңалык иде.

Язучылар, әдәби әсәрдә кеше образын тудырганда, аны, гадәттә, җәмгыять вакыйгалары белән тыгыз бәйләнештә сурәтлиләр. Экспрессионизм юнәлеше белән эш итүчеләре исә кешенең шәхси эчке дөньясына, күңел кичерешләренә генә игътибар итәләр (экспрессио — француз сүзе, тәэсирлелек мәгънәсендә). Җәмгыятьтәге төрле рәхимсезлекләрнең, сугышларның матурлыкка, кешелеклелеккә дошманлыгын, аларның кеше күңелен тупасландыруга, бозуга китерүен ачык итеп күрсәтеп, укучыны сурәтләүләр белән тәэсирләндерү — экспрессионистларның төп максаты. Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, Дәрдемәнд үзләренең әсәрләрендә бу алымның

мөмкинлекләрен дә отышлы файдаландылар. Бу исә әдәбиятның төп хасиятләреннән булган сурәтлелекне үстерүгә ярдәм итте.

Реализмны аңлатканда, бездә бер ялгыш караш яшәде. Янәсе, әлеге иҗат методы ярдәмендә сыйныфлар арасындагы көрәш, кешеләрнең сыйнфый азатлык өчен бәрелешләре сурәтләнергә тиеш. Бу — шактый чикле караш. Тормыш сыйнфый көрәштән генә тормый. Аның бик күп бүтән яклары да бар. Аларның сурәтләнүе дә шул ук реализм рәвешен ала. Әмма чынбарлыкны үз рәвешендә генә түгел, читләтеп, символлар төсендә дә чагылдырырга мөмкин. Сүз алып бара торган чор әдәбиятында без моның мисалларын да очратабыз. Һ. Такташ «Газраилләр», «Күктән сөрелгәннәр» әсәрләрендә фәрештәне яхшылык, изгелек, Газраилне явызлык билгесе (символы) итеп бирә. Символлар белән сурәтләү әсәрне шактый катлауландырырга, аңлауны кыенлаштырырга да мөмкин. Шуңа күрә язучыларыбыз чынбарлыкны табигый рәвешендә төгәл сурәтләүгә өстенлек бирәләр.

Татар әдәбиятында акмеизм дигән иҗат агымының да беркадәр чагылышы булды (акмеизм — грек сүзе, нәрсәнең дә булса нык үсешкә ирешеп чәчәк атуы, югары дәрәҗәгә җитүе мәгънәсендә). Акмеизм тарафдарлары кешене табигать баласы итеп сурәтләделәр, символлар белән эш итүне өнәмәделәр. Мәхәббәт хисе белән янучы кешене гәүдәләндерү белән мавыктылар. Шуңа күрә кешене җәмгыять белән бәйләнешләрдән азат, тормыш каршылыкларыннан бәйсез итеп күрсәтергә тырыштылар.

Татар әдәбияты үз үсеше тарихында ике тапкыр зур яңарыш кичерде. Аның беренчесе XIII—XVI йөзләргә карый, икенчесе XX йөз башында булды. Иҗатта төрле агымнарның, стильләрнең бергә янәшә яшәве дә әнә шул Яңарыш чорының табигый юлдашы иде.

Әлбәттә, XX йөз башы татар әдәбиятында чынбарлыкны дөрес, реалистик сурәтләү өстенлек алды. Каләм осталары андый әсәрләрдә иҗтимагый хәл-әхвәлләрне ничек бар шулай сурәтләделәр, үткен социаль мәсьәләләрне кыю күтәрделәр, яшәешне яхшыртуның юлларын күрсәттеләр. Бу яктан Г. Коләхмәтовның иҗаты аерылып торды. Ул «Яшь гомер», «Ике фикер» әсәрләрендә хезмәт ияләрен бәхетле итү көрәштән башка була алмаганлыгын алга сөрде. Г. Тукай, Г. Исхакый, Ш. Камал, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Н. Думави, С. Рәмиев

һәм башка әдипләр әдәбиятыбызның реализм юлыннан үсеп китүенә ифрат зур өлеш керттеләр. Егерменче елларда да әле әдәби иҗатта гыйсъянчылык, футуризм, имажинизм кебек агымнар яши иде, ә утызынчы елларга җитәрәк бары тик пролетариат мәнфәгатьләрен күздә тоткан реализм белән генә язу таләп ителә башлады. Бу исә әдәбиятның бертөрлелегенә, шактый төссезләнүенә, билгеле бер кысаларга кертелүенә китерде. Талантлы язучыларыбыз шундый шартларда да сәнгатьчә уңышлы эшләнгән әсәрләр иҗат итә алдылар.

Сораулар һәм биремнәр

1. XX йөз башы татар әдәбияты нинди казанышларга таянып үсеп китә алды?

2. Ни өчен без татар әдәбияты үсеше тарихында ике Яңарыш чоры булды дибез? Сүз кайсы чорлар турында бара?

3. Бер әдәбият та башка халыкларның сүз сәнгатеннән бөтенләй аерымланган хәлдә генә үсми. XX йөз башында бүтән халыклар әдәбиятлары белән бәйләнеш мәсьәләсендә бездә нинди бәхәс бара?

4. Мәгърифәтчелек реализмы һәм тәнкыйди реализм арасында нинди уртаклыклар һәм аермалыклар бар? Әлеге методлар белән язган әдипләребезне әйтегез.

5. Бу чорда татар әдәбиятында тагын нинди иҗат алымнарының булуын әйтергә мөмкин?

6. Чынбарлыкны романтик сурәтләүне ничек аңлыйсыз?

7. Модернизмны сез ничек итеп күз алдына китерәсез? Аның нинди төрләре бар? Безнең сүз сәнгатендә аларның катнашы уңаймы, әллә тискәре күренеш булдымы?

8. Шулай да безнең әдәбиятта реализмның өстенлек алуы нинди сәбәпләр белән бәйләнгән?

9. Бары тик пролетариат мәнфәгатьләрен яклаган әдәби әсәрләр генә тудырырга тиеш булу язучыга иҗат кешесе буларак ничек тәэсир итте?

10. Чынбарлык табигый рәвешендә сурәтләнгән әсәрләрне атагыз. Шулар нигезендә тормыштагы чынбарлык һәм әдәби әсәрдә сурәтләнгән чынбарлык арасында нинди охшаш һәм аермалы яклар булуын билгеләгез.

Гаяз Исхакый
(1878—1954)

«Иң саф бер фидакарь»

Теләсә кайсы милләтне, барыннан да элек, аның күренекле кешеләре аша беләләр. Татар халкы да үзенең олы һәм катлаулы тарихында бөек шәхесләрне аз тудырмады. Аларның берсе — Мөхәммәтгаяз Гыйлаҗетдин улы Исхакый — Гаяз Исхакый. XX гасырның беренче яртысында ул татар, гомумән, төрки халыкларның киләчәге өчен эзлекле көрәш алып барган, шуны яшәвенең иң олы максаты дип санаган милләт агаларыбызның күренеклесе иде. Ул халкыбызны «өсте-башы бөтен, аш-суы иркен, йөзе-күзе күркәм, көе-җыры көчле, сүзесазы татлы, кыйланышы килешле, җайлы, йөреше-барышы тугъры иттереп»[1] күрергә теләде. Мондый изге эшкә гомереңне багышлау өчен, туган халкыңның үткәндәге фаҗигаләрен яхшы белергә, аның бүгенге хәле өчен йөрәгең сызланырга, шушы хәлдән чыгуның иң дөрес, иң туры юлларын табарга кирәк иде. Г. Исхакый шушы эшкә юл күрсәтүче күренекле сәяси эшлекле, оста оештыручы, зур әдип булды.

1878 елның 22 февралендә Чистай өязенең Яуширмә авылында бер малай дөньяга килә. Әтисе Гыйлаҗетдин мулла һәм әнисе Камәрия абыстай малайга Мөхәммәтгаяз исеме бирергә уйлап куйган булалар. Моның белән алар улларының

[1] «Ил» газетасы.— 1913.— 22 октябрь.

киләчәктә нинди кеше булып үсәсен билгеләгәндәй итәләр. Мөхәммәт тә (мактаулы, данлыклы), Гаяз да (ярсулы, ялкынлы) — аларның теләк-өметләренә туры килә торган гарәп сүзләре. Юраган юш килә дигәндәй, чыннан да, Мөхәммәтгаяз бик хәрәкәтчән, үзеннән көч ташып тора торган, фикерләре белән башкаларны да яндыра алу сәләтенә ия кеше була, гаять күп һәм нәтиҗәле эшләве белән мактау һәм дан ала.

Гаиләдә берданбер бала булганга, әти-әнисе малайга зур өмет баглыйлар. Гаяз башта әбисе Мәхфүзә остазбикә ярдәмендә язу танырга өйрәнә, авыл мәдрәсәсенә йөри. Унике яшендә аны Чистайдагы Закир ишан мәдрәсәсенә бирәләр. Ләкин биредә укыту тиешле дәрәҗәдә булмый. Өч елдан Гаяз Казандагы Күл буе мәдрәсәсенә килә (мөдәррисе — Галләм хәзрәт). Аны биредә күренекле мәгърифәтче Һади Максуди укыта. Малай бик тырышып укый, хәлфәсен «дәресне күбрәк бир» дип йөдәтә. Ниһаять, 1897 елда, унтугыз яшендә, мәдрәсәдә укуын тәмам итә, инде аның үзен Казандагы Әмирхановлар мәдрәсәсенә хәлфә итеп чакыралар. Һ. Максуди исә шушы уку йортына мөдәррис булып күчә. Гаяз хәлфә биредә, үзенең остазы Һ. Максудидан аермалы буларак, иҗек методы белән түгел, ә җәдитчә (ягъни яңача) аваз ысулы белән укыта башлый. Бу исә балаларның укырга-язарга өйрәнүен күпкә җиңеләйтә. Шуңа күрә ул укыткан балалар, язуны тиз танып, күпләрне гаҗәпкә калдыралар. Туган теле өстенә төрек, гарәп, фарсы телләрен дә яхшы белүе аңа укыту эшендә зур ярдәм итә.

Шулай да Гаяз үзенә дөньяви белемнең җитмәвен, рус телен, әдәбиятын өйрәнергә кирәклеген аңлый. 1898 елда Татар укытучылар мәктәбенә укырга керә һәм аны 1902 елда тәмамлый. Бер үк вакытта Яңа Бистәдәге мәдрәсәдә мөгаллимлек эшен дә дәвам иттерә. Татар укытучылар мәктәбе яшьләрне рус теле һәм әдәбияты укытучылары итеп әзерли. Алар яшь буынны рус мәдәнияте рухында тәрбияләргә тиеш булалар. Дөресен әйткәндә, әлеге мәктәп татарларны руслаштыруга хезмәт итүчеләрне ишәйтүгә дә өлеш кертә. Әмма Г. Исхакый үз милләтенә тугрылыклы булып кала — 1902 елда Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә эшли башлый. Ләкин бу мәдрәсәдәге искелеккә каршы кыю фикерләр әйткән яшь мөгаллим биредә озак кала алмый. Шушы кыска гына вакытта да ул үзенең шәкертләре, шулай ук яшь хәлфә Сәгыйть Рәмиев күңелендә якты эз калдыра, аларда фикер хөрлегенә омтылыш тудыра.

Г. Исхакый белемен тагын да камилләштерергә тели. Университетка керергә әзерләнә, шуның өчен яңадан Казанга кайта. Ләкин этисенең указы алыну сәбәпле, ата-анасының сүзен тыңлап, үзе теләмәсә дә, туган авылына кайтып мулла булып хезмәт итәргә керешә. Әлбәттә, бу эшчәнлек аны канәгатьләндерми. Егерме биш яшьлек егет киңлеккә омтыла. 1904 елда ул тагын Казанга килә, иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләрдә катнаша башлый, «Таң йолдызы» газетасын оештыра. (Ул 1906 елның 18 маеннан 17 ноябренә кадәр чыга. Унынчы саныннан башлап аның мөхәррире шагыйрь Сәгыйть Рәмиев була.) Бу газета татар социаль-революционерлар (эсерлар) органы була, халык мәнфәгатьләрен яклый. Мондый юнәлештәге газета, билгеле инде, патша хакимиятенә ошамый, аны ябалар. 30 октябрьдә Г. Исхакый кулга алына, тик берничә көннән аны чыгаралар. 23 декабрьдә исә тагын тоткынлык, бу юлы Чистай төрмәсенә ябып куялар. Ул шунда «Зиндан» исемле повесть-көндәлеген яза, атаклы «Зөләйха» әсәрен иҗат итә башлый. Думага сайлаулар узгач, аны 1907 елның 18 февралендә азат итәләр. Шул ук татар эсерлары тарафыннан нәшер ителгән «Тавыш» газетасында ул самодержавиегә каршы кискен мәкаләләр бастыра, инкыйлабый эшчәнлеген киңрәк җәелдерә бара. Шуның өчен 1907 елның октябрь аенда аны өченче тапкыр ирегеннән мәхрүм итәләр, Архангельск губернасының Пинега шәһәренә сөргенгә җибәрәләр. Бераз вакыт шуннан 15—16 чакрым ераклыктагы Пилягоры исемле авылда тоталар. Ләкин ул биредә озак калмый, кача. 1908 елның июлендә Петербургка килеп чыга, аннан Төркиягә үк китеп бара. 1909 елның көзендә яшертен генә Петербургка килә. Кышны Россиянең башкаласында, җәйне Финляндиядә уздыра, көз көне (1910 елда) Төркиягә кире әйләнеп килә. 1911 елда Хәбибназар Сатлыков исеменә алынган паспорт белән тагын Петербургка кайта. 1912 елның 26 гыйнварында полиция аның эзенә төшә, бу юлы аны тагын да төньяккарак озаталар. Ул Архангельск губернасының Мезень шәһәрендә яшәргә мәҗбүр ителә. «Бертуктамыйча Боз диңгезеннән җил исеп тора. Әллә нинди бер җәһәннәм авызы!» — дип яза ул моннан бер дустына. 1913 елның 4 апрелендә сөргеннән азат ителсә дә, аңа Казанда яшәргә рөхсәт бирелми. Ул яшертен рәвештә Казанга керә, «Шәрык» клубында Камил Мотыйгый катнашындагы концертны тыңлый, иҗат зыялылары белән очраша. Туган авылы Яуширмәгә кереп чыккач, Петербургка юл тота.

Шунысына игътибар итәргә кирәк: Г. Исхакый кая гына бармасын, шунда иҗтимагый тормыш җанланып китә. Бу юлы да шулай була. 1913 елның 22 октябреннән ул инде Россиянең башкаласында «Ил» газетасын чыгара башлый. Әлеге вакытлы матбугат органы тиз арада абруй казана. Анда Йосыф Акчура, Муса Бигиев, Сәгыйть Рәмиев, Мәҗит Гафури, Зәки Вәлиди, Фуат Туктаров һәм башкалар язышалар. Соңыннан бу газета Мәскәүдә чыга башлый. Патша цензоры аны сәяси яктан зарарлы дип таба һәм 1915 елның 27 мартында ябып куя. Тик Г. Исхакый бервакытта да аптырап калмый. Мәскәүдә 1915—1916 елларда «Сүз» газетасын, ул ябылгач, 1916—1917 елларда «Безнең ил» исемле газета чыгара. Боларның барысы да инкыйлаби-демократик рухлы газеталар була. Милли мәсьәләләргә нык игътибар итәләр. Г. Исхакый 1913 елга кадәр көрәшне сыйнфый нигездә алып баруны якласа, шуннан соң әкренләп көрәш гомуммилли юнәлештә булырга тиеш дигән карашны алга сөрә. Беренче мөмкинлек булу белән, 1917 елның 23 мартыннан Мәскәүдә «Ил» газетасын яңадан чыгара башлый.

Г. Исхакыйның эшчәнлеге туган телдә вакытлы матбугат оештыру белән генә чикләнми. Татар милләте мәнфәгатьләрен кайгыртырга ярдәм итәрдәй бер генә мөмкинлекне дә ул кулдан ычкындырмый. Мәсәлән, 1916 елның башында Мәскәүдә милли театрлар эшлекләләренең съезды үткәрелә. Биредә ун еллык эш тәҗрибәсе булган татар театры вәкилләренең булмавы Г. Исхакыйны борчуга сала. Татарча куелган беренче рәсми спектакльнең пьесасы авторы буларак, тиз генә әзерләнеп, ул үзе татар театрының хәле һәм бурычлары турында доклад ясый. Бу — татар сәнгате турында зурлап әйтелгән беренче чыгыш була.

Мәскәүдә яшәсә дә, Г. Исхакый Казан белән элемтәне өзми. Ул 1916 елның көзендә яшертен рәвештә Казанга килеп китә, кичектерми хәл итәсе мәсьәләләр хакында зыялылар белән сөйләшүләрдә катнаша. 1917 елгы Февраль инкыйлабы вакытында Мәскәүдә була, моңа шатлануын белдерә. Апрель аенда Г. Исхакый Мәскәү мөселман халкы комитеты рәисе итеп сайлана.

«Сәйяр» театр труппасы 1917 елның 17 (30) мартында Г. Кариев бенефисына Казанның Зур драма театры бинасында (хәзер В. Качалов исемендәге рус театры) Г. Исхакыйның «Зөләйха» әсәре буенча куелган спектакль күрсәтә. 27 мартта исә

(иске стиль белән) Г. Исхакый ачык рәвештә Казанга кайта, әлеге әсәр яңадан куела. Ф. Әмирхан сүзләре белән әйткәндә: «Иске хөкүмәт вакытында Казанда ачыктан йөри дә алмый торган «куркыныч» мөхәррирен бүген ачыктан җыелышып сәламли вә алкышлый алудан халыкның зур шатлык хис иткәнлеге аермачык күренә иде» («Кояш», 1917, 11 апрель).

1917 елның 1—11 маенда Мәскәүдә Беренче мөселман корылтаенда Г. Исхакый төп доклад белән чыга. Ул «Милли Шура» төзү мәсьәләсен нигезләп аңлата. Утыз миллионлы Россия мөселманнары бер платформа тирәсенә берләшергә тиешләр. Аларны дини, рухи, мәдәни яклар гына түгел, дөньяви мәнфәгатьләр дә якынайтырга тиеш. «Милли Шура» әлеге берлекнең үзәген тәшкил итәргә бурычлы. Шул ук елның июлендә Казанда Икенче мөселман корылтаенда Г. Исхакый Милли Мәҗлес үткәрүне оештыру бюросына сайлана. Ләкин 1917 елның октябрендә большевикларның хакимияткә килүе милли мәсьәләне хәл итүне кыенлаштыра. Мәсәлән, 1917 елның 20 ноябреннән 1918 елның 11 февраленә кадәр Уфада уздырылган Милли Мәҗлес утырышында Идел-Урал штаты төзү турында карар кылына. Гәрчә ул Россия Федерациясе эчендә булырга тиеш дип каралса да, большевиклар мондый дәүләт берләшмәсе төзүгә юл куймыйлар. Бу мәсьәләдә В. Ленин да эзлексезлек һәм, әйтергә кирәк, карарсызлык күрсәтә. Г. Исхакыйга үз алдына куйган омтылышларына ирешү юлы ябыла, 1919 елда аңа чит илгә китүдән башка чара калмый. Шул китүдән инде ул туган иленә кайта алмый. Чөнки 1917 елның октябрендәге хакимият алмашынудан соң, безнең илнең дөнья белән элемтәләре чикләнә. Г. Исхакый кебек үз халкы мәнфәгатьләре белән яшәгән шәхесләр «милләтче», «халык дошманы» дип игълан ителәләр.

Шуннан соң Г. Исхакый берара Кытайда, аннары Франциядә, Германиядә, Польшада яши. Икенче бөтендөнья сугышы колач җәя башлагач, аңа Варшавадан Төркиягә күчәргә туры килә. Чит илләрдә яшәгән утыз биш ел гомерендә ул әдәби, сәяси эшчәнлеген дәвам иттерә. «Милли юл» (1928—1930), «Яңа милли юл» (1930—1939) дигән журнал чыгара. Бу журнал (барлыгы 136 сан) Берлинда, кайбер саннары гына Варшавада басыла. Мукденда (Кытай) «Милли байрак» (1935—1945) газетасын да ул нигезли. Европага киткәндә, татарча типографиясе шунда кала. Шуңа күрә Төркиядә үз хезмәтләрен төрек телендә бастыра.

Чит илдә ул «Дулкын эчендә», «Ике ут арасында», «Җан Баевич», «Олуг Мөхәммәд» кебек пьесалар яза. «Өйгә таба», «Көз», «Локман Хәким», «Олугъ бәйрәм» кебек әсәрләре дә шул чорда иҗат ителгәннәр.

Г. Исхакый 1954 елның 22 июлендә Анкарада вафат була. Кабере — Истанбулның Әдернәкапы зиратында. Төркиягә барган милләттәшләребез аның каберенә чәчәк бәйләме салуны гадәт иттеләр. Халык бәхете өчен көрәшеп, шушы юлда гаять күп кыенлыклар күреп яшәгән олы әдибен, күренекле җәмәгать эшлеклесен милләт онытмый. Аның замандашы, күренекле галим Йосыф Акчураның менә бу сүзләре Г. Исхакыйны шактый тулы бәяли: «Ул фәкать идеал өчен тартыша торган иң саф бер фидакарь иде»[1]. Шагыйрь Сәгыйть Рәмиев белән нәшир Габдрахман Хөсәенов 1907 елда Г. Исхакыйның «Зиндан» әсәренә язылган кереш мәкаләдә болай диләр: «Гаяз әфәнде кебек сирәк бер әдипнең, Гаяз әфәнде кебек сирәк бер мөхәррирнең һәм Гаяз әфәнде кебек сирәк бер кешенең һәрвакыт бар булып торуы безнең татар халкы өчен минут саен кирәк... Яшә, халык! Яшә, Гаяз әфәнде!»

Сораулар һәм биремнәр

1. Язучы, җәмәгать эшлеклесе булып җитешкәнче, Г. Исхакый нинди тормыш юлы үтә?

2. Бу олы шәхескә хас булган төп сыйфатларны сурәтләгез.

3. Ул булган урыннарны билгеләп, хронологик таблица төзегез.

4. Г. Исхакый оештырган, эшләгән һәм язышкан газета-журналларны, алар басылып чыккан шәһәрләрне әйтегез. Ул көндәлек матбугатта нинди карашларны яклый?

5. Танылган әдип, күренекле җәмәгать эшлеклесе ни өчен сыйнфый көрәшкә караганда милли-азатлык хәрәкәтенә өстенлек бирә?

6. Г. Исхакый татар милләтен нинди итеп күрергә тели?

7. Казан шәһәре Г. Исхакый тормышында һәм эшчәнлегендә нинди әһәмияткә ия?

8. «Милли Шура»ны, «Милли Мәҗлес»не оештыруда, гомумән, мөселманнарны бер максатка туплауда Г. Исхакыйның эшчәнлеген ничек бәяләргә мөмкин?

9. Г. Исхакый ни өчен чит илгә китәргә мәҗбүр була? Аның туган илдән ерактагы эшчәнлеге турында сөйләгез.

10. Г. Исхакыйга аның замандашлары Ф. Әмирхан, Й. Акчура, С. Рәмиев һәм башкалар биргән бәяне искә төшерегез.

---

[1] «Казан мөхбире» газетасы.— 1906.— 5 ноябрь.

Гаяз Исхакыйның иҗаты

Татар әдәбиятының иң күренекле каләм әһелләреннән берсе булган Гаяз Исхакыйны халкыбызның бай тарихыннан, сүз сәнгате традицияләреннән, үз заманының әдәби мохитеннән аерып карап булмый. Ул борынгы әдәбиятыбыз һәм XIX йөз язучылары иҗаты белән яхшы таныш була. Шул ук вакытта төрек язучылары әсәрләрен укый, гарәп, фарсы, рус әдәбиятларыннан да хәбәрдар була. Яшьтән үк тормышның төрле якларын, шатлыгын-хәсрәтен, муллыгын-мохтаҗлыгын, мәрхәмәтен-усаллыгын үз җилкәсендә татыганга, язу өчен тема эзләүдә ул аптырамый. Ләкин язар сүзне табу, теманы ачыклау иҗат эшчәнлегенең әле башлангычын гына тәшкил итә. Төп хикмәт — күңелдә йөрткәннәреңне ничек итеп язуда. Җәмгыятьнең иҗтимагый, сәяси, икътисади үсеш дәрәҗәсе дә язучының сурәтләү үзенчәлекләрен билгели.

XX йөз башында татар җәмгыятендә милләтне алга җибәрү, моңа аң-белемне арттыру юлы белән ирешү җәмәгатьчелекнең төп гамьнәреннән берсе иде. Чөнки бу чорда милләтебезне алга җибәрү өчен патша хакимиятен юкка чыгару, барлык халыкларга да ирек таләп итү карашлары өлгереп җитмәгән иде әле. Шуның өчен каләм әһелләре милләт алдында торган бурычларны, күпмедер дәрәҗәдә булса да, әхлакны үстерү, яхшырту ярдәмендә хәл итү мөмкин дип исәпләделәр, мәгърифәтчелек карашларын уздырдылар. Г. Исхакыйның беренче әсәрләре — «Кәләпүшче кыз», «Бай углы» повестьлары һәм «Өч хатын белән тормыш», «Ике гыйшык» пьесалары да — мәгърифәтчелек карашлары белән сугарылган була.

Әлеге әсәрләрне күздә тотып, әдәбият галиме Җамал Вәлиди болай ди: «Боларда әле сурәтләр дә гаять юка булып, алар артында яшеренгән вәгазь иң гади күзгә күренеп тора... Милләтнең чын авыруларын карый, зур яраларын күрсәтә, күп сырланмый, фәлсәфә сатмый». Җ. Вәлиди хаклы. Г. Исхакый әсәрләренең беренчеләре сәнгатьчә эшләнеш ягыннан әллә ни камил түгел. Ул сурәтләүне мөмкин кадәр туры эздән алып бара. Шул ук вакытта җиңелчә генә юмор катнаштырып сурәтләнгән образларның тискәре сыйфатларын күрсәтә, ахыр чиктә аларның, кешелек затлылыгын җуеп, һәлакәткә килүләрен ачып бирә.

«Кәләпүшче кыз»

Бу әсәр 1898 елда Казанда языла һәм 1900 елда басылып чыга. Әсәр укучыларның игътибарын яулап ала. «Әүвәлге басылуында китабым бик тизлек илән таралып бетте. Бу көннәрдә сораучылар күптин-күп арттыгындин икенче мәртәбә бастырмакчы булдым»,— дип яза автор һәм үзенең укучылар тарафыннан телдән булсын, язма рәвештә булсын бик күп уңай бәяләр алуын әйтә. Күренекле галим һәм җәмәгать эшлеклесе Йосыф Акчура, мәсәлән, болай яза: «Татар әдәбиятыннан иң күп тәэсир белән укыган китабым «Кәләпүшче кыз» булды. Мәмләкәттән ерак идем... «Кәләпүшче кыз»ны укыган көнне шул Казанда гомер иттем һәм милләтемә чыккан иң-иң тәһликәле[1], иң ачулы бер чуанның сызлавын үз рухымда хис кыларлык гомер иттем. Хикәянең икенче басылуында гыйлавә[2] ителгән хатны укыганда, кабат чыдый алмадым... мескен татар кызының сөкүте[3], фәлякәте[4]... өчен озын-озын еградым». Әсәр 1902 елда кабат басылып чыга, бик тиз вакыт эчендә укучылар кулына таралып бетә. Хикәягә игътибарның шулай зур булуының сәбәбе нидә соң? Дөресен әйткәндә, сәнгатьчә эшләнешендә түгел. Моны Г. Исхакый үзе дә белә: «Кәләпүшче кыз» минем элеккеге әсәрләремдин булдыгындин, әлбәттә, күп йерләрендә кимчелекләре бардыр». Әсәрне укучыларны, барыннан да элек, сурәтләнгән кеше язмышлары кызыксындыра.

Кәримә белән Габдерәшит — шәһәрдәге һөнәрчеләр — кул көчләре белән көн күреп гомер итәләр. Ике балалары бар, зурысы кыз — Камәр, кечесе малай — Габделәхәт. Тик бәхетле тормыш озакка бармый, хатыны белән балаларын ятим калдырып, Габдерәшит үлеп китә. Автор, болар турында кыскача мәгълүмат биргәннән соң, хикәяләүнең төп өлешенә күчә. Әтисез калган балаларны Кәримә ничек тәрбия кылыр, аларны ничек итеп аякка бастырыр? Укучыны шушы сорауларның җавабы кызыксындыра. Тик утыз ике-утыз өч яшьлек Кәримәнең балаларда әллә ни гаме юк, ул үзе кияүгә чыгарга тели. Ике бала белән ир табу кыенрак. Шуңа күрә малайны булса да өйдән озатырга кирәк дип уйлый ул. Әзли

---

[1] *Тәһликә* — куркыныч.

[2] *Гыйлавә* — кушымта.

[3] *Сөкүте* — түбәнлеккә төшүе.

[4] *Фәлякәт* — бәла, кайгы.

торгач, җае да табыла. Фәхри исемле сәүдәгәр малайны үз карамагына алырга ризалыгын белдерә. Әмма Габдерәшит үлгәндә, малайны укытырга кушып, васыять әйткән була. Габделәхәт үзе дә укуда тырышлык күрсәтә. Малайның укудагы уңышларына сөенгән мөгаллим ярдәм кулын суза: аны үз исәбенә тагын ике ел укытырга уйлый. Бу очракта исеме дә билгеле булмаган бер зыялы мөгаллимнең шундый миһербанлылыгына укучыда рәхмәт хисләре уяна.

Кәримә кызы белән генә кала, димәк, кияү эзләү чарасына керешергә мөмкинлек ачыла. Иргә чыгу ниятен кешеләргә белдерүе була, хатыны үлеп, ике бала белән тол калган кырык-кырык биш яшьләр тирәсе Мифтах исемле берәүдән яучы килеп тә төшә. Биредә Г. Исхакый үзен оста психолог итеп күрсәтә. Унбиш яшьлек Камәр һәм аның энесе Габделәхәт, яшүсмерләргә хас булганча, әтиләренең рухына тугрылык сакламаган әниләренә рәнҗиләр. Бу хәл балаларның күңеленә тирән җәрәхәт ясый. Шунысы гаҗәп: ана ирле булу бәрабәренә үзенең балаларына битарафлык күрсәтә. Гәрчә хикәядә Камәрнең аянычлы язмышы үзәккә куелса да, укучы сурәтләнгән күңелсез хәл-әхвәлләрдә беренче чиратта аның әнисе Кәримәне гаепли. Камәр — бары тик үзеннән өлкәнрәк, шуңа күрә тәҗрибәлерәк, мәкерлерәк булган кешеләрнең корбаны гына. Мифтах, аның кызы Вәсфибану, мөгаллим кебек уңай кешеләр гәүдәләнсә дә, вакыйгаларда катнашучыларның күбесе тискәре образлар. Г. Исхакый җәмгыятебезне явызлардан арындырырга тели. Кешеләрдә әхлаклылык сыйфатларының өстенлек алуына ирешергә омтыла. Шуңа күрә тискәре образларны чиркангыч итеп гәүдәләндерергә тырыша. Үз кызын бозыклыгы бик күпләргә мәгълүм булган приказчик Вафа янына җибәрүе — Кәримәнең ана буларак җавапсызлыгы. Дөрес, автор бу образны да гел кара буяулар белән генә сурәтләми. Кәримә күпмедер дәрәҗәдә балалары турында кайгыртырга, алар язмышы өчен борчылырга сәләтле. Кызы югалгач, төннәр буе кайгырып чыгуы, намаз укуы, һичшиксез, аны кызгандыра. Татар хатыннарына хас сабырлык та бар аңарда. Мифтах күп яклары белән аның элекке иреннән кайтышрак булса да, бер баргач, ир хакын хаклап торуы бу хатынның әхлакый йөзен укучы күз алдында бераз уңай яктан ачып җибәрә. Шул ук вакытта язучы Кәримәнең балалары язмышына салкын каравын тәнкыйть итә.

Ә менә «күп кызларга бәла булган, күп хатыннарга җәфа салган» Вафа образын тудыруда автор кара буяуларны кызганмый. Авылдан килеп, Сәлимов дигән бер сәүдәгәрдә елына дүрт йөз сум хезмәт хакы алып яшәүче бу кибетче бары тик тискәре сыйфатлардан гына тора кебек. Ул — ялганчы, шапырынучы, надан булса да, үзен белдекле итеп күрсәтүче. Иң зур начарлыгы — Камәр кебек яклаучысыз калган кызларны харап итүе, аларны бозыклык юлына кертеп җибәрүе, моның өчен вөҗдан газабы кичереп мәшәкатьләнмәве. Шуны ук Бәдри дигән бәндәгә карата да әйтергә мөмкин. Яшь кызларны бозык ирләр өчен аулап йөрүче Зөһрә карчык кебекләр дә укучыда чиркангыч хис-тойгылар тудыра.

Әлбәттә, автор, начар күңелле кешеләр корбаны итеп карап, Камәрне аклау юлыннан китми. Үги атасының кызы Вәсфибануның, әхлаклы, саф кыз буларак, Камәргә каршы планда сурәтләнүе шул турыда сөйли. Вафа кебек кабахәтнең тасма теллеләнүен мәхәббәт итеп кабул күрүе — Камәрнең фаҗигасе. Әнә өч-дүрт яшькә кечерәк Вәсфибану да Вафа кебекләрнең икейөзлелеген аңлый. Камәр дә һәр елмаеп караучыга ышанып бетәргә тиеш түгел иде. Өйдәге иләмсез күңелсезлекләр белән башы миңгерәгән унбиш яшьлек Камәр кызганыч, Вафаның сүзләреннән иләс-миләс килә, үзенең күңел бушлыгына дәва тапкандай була. Бары тик хис колы гына булу, язмышы турында сүз барганда, акыл белән эш итмәү Камәрне һәлакәткә илтә.

Й. Акчура хаклы, гыйбрәтле язмышлы кешеләрнең аянычлы хәл-әхвәлләрен күрсәтү юлы белән укучыларны тәрбияләү максатыннан чыгып иҗат иткән әсәрләре арасында Г. Исхакыйның «Кәләпүшче кыз» хикәясен уку аеруча дулкынландыра. Хатын-кыз язмышы мәсьәләсен Г. Исхакый эзлекле күтәрде, аның яңадан-яңа катламнарын ачып салды. Ул шуны яхшы аңлап эш итте: илнең киләчәге матур, өметле булсын өчен, беренче нәүбәттә хатын-кыз чын-чынлап бәхетле булырга тиеш.

Сораулар һәм биремнәр

1. Г. Исхакыйның язучы булып өлгерүенә кайсы халыкларның әдәбиятлары йогынты ясый?

2. XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы язучылары үз әсәрләрендә ни өчен мәгърифәтчелек карашларын актив чагылдыралар?

3. Камәрнең фаҗигале юлга кереп китүенә гаепле кешеләрне атагыз, аларга бәя бирегез.

4. Әсәрдә Вәсфибану образының нинди вазифа үтәгәнен күрсәтегез.

5. Г. Исхакый бу әсәрне нинди максат белән язган?

6. Ничек уйлыйсыз, кешенең эш-гамәлләрен беренче чиратта акылымы, әллә хисләреме билгеләргә тиеш?

7. Йосыф Акчураның бу әсәр уңаеннан әйткәннәрен, аның фикерләрен үз сүзләрегез белән аңлатыгыз.

«Бай углы»

Дөрес башланмаган тормыш юлы, әлбәттә, яхшылыкка илтми. Бу хакыйкать Г. Исхакый әсәрләрендә еш раслана. Язучы карашынча, дини тәрбиядән, милләтнең гореф-гадәтләреннән, шул ук вакытта дөньяви белемнән мәхрүм кешенең бәхет өмет итәргә нигезе юк. Без моны «Бай углы» романында ачык күрәбез.

Фатих бай һәм Сәгыйдә бикә, яшь булуларына карамастан, шәһәрдә иң бай һәм абруйлы кешеләрдән саналалар. Әмма икесе дә укый-яза белми, надан калган. Ләкин байлыклары аларга шөһрәт өсти, белем ягының сай булуы сату-алу эшләрен җайлап алып барырга әллә ни комачауламый. Фатих бай хәтта Мәскәү сәүдәгәрләре белән эш йөртә.

Шулай да наданлык дигән затсыз нәрсә, сизелер-сизелмәс кенә җаен табып, бу гаиләгә үзенең зарарын сала тора. Сәгыйдә бикәнең бәбәй табу вакыты җитә. Өйгә кендекче әбиләр, өшкерүче карчыклар җыела. Ләкин берничә көн буена азаплануына карамастан, бала һаман да тумый. Хатынның хәле авырайганнан-авырая бара. Бер чара да калмагач, акушерны чакырырга мәҗбүр булалар. Акушер хатын, үз эшен фәнни һәм гамәли яктан бик яхшы белүе сәбәпле, Сәгыйдә бикәнең ансат кына бәбәй табуына ирешә. Шулай итеп, Г. Исхакый әсәрнең беренче битләрендә үк гыйлемнең өстенлеген раслый, төш юраудан, төрле им-том итүләрдән ары уза алмаган карчыкларны тәнкыйть итә. Сәхилә карчык кебек укый-яза белмәгән, шуңа карамастан аң-белемлеләрне өнәмәгән кешеләргә карата Г. Исхакый аяусыз. Нәкъ менә шундый кешеләр милләтебезне һәлакәткә алып бара дип исәпли ул. Вакыйгаларның үсешен сурәтләгәндә шуны күрсәтеп бирүне төп максаты итә.

Хәтерлисездер, Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасы «Дөньяда баланы бигрәк тә ата-ананың тәрбия кыла белмәве харап итә!» дигән сүзләр белән тәмамлана. Г. Исхакыйның

«Бай углы» әсәрендә дә нәкъ шулай аңлашыла. Тулаем әсәр шушы нигез фикерне раслау өчен язылган.

Баланы кеше, шәхес итеп тәрбияләү гаять зур хезмәт, тырышлык сорый. Без нинди дә булса эшне башлаганда күпмедер дәрәҗәдә ахыргы максатны күз алдына китерәбез. Өй салырга керешкәндә, аның ничә бүлмәле булырга тиешлеге, аларның ничек урнашачагы, биеклеге, киңлеге кебек нәрсәләрне якынча гына булса да чамалап куябыз. Баланы тәрбия кыла башлаганда да, ата-ана аны, балигъ булгач, нинди кеше итеп күрергә теләвен ачыкларга һәм бөтен юнәлеш бирү эше шушы ахыр нәтиҗәгә килүгә тупланырга тиеш. Шик юк, ул иң әүвәл Кеше булырга тиеш. Әлбәттә, үсә-үсә, баланың теге яки бу якка сәләте ачылып китүен исәпкә алып, булачак шәхесне тәрбияләү максатына үзгәрешләр дә кертергә мөмкин. Бу эш Фатих бай өендә ничек оештырылган соң? Дөресен әйткәндә, берничек тә оештырылмаган. Кәрим (балага шулай дип исем кушалар) рәхәттә яши. Күрәсең, ата-ана баланы юмарт, рәхимле, киң күңелле, намуслы, хөрмәтле, кадерле, газиз, асыл зат итеп күрергә тели. Гарәп теленнән алынган Кәрим исеменең дә әнә шундый әйбәт мәгънәләре бар. Ата-ана «бер генә баламыз, рәхәт үссен» дип, аның ашау-эчүен тәмле, кием-салымын затлы итүне кайгырта. Янәсе, шулай итсәң, ата-ана өстендәге бурыч үтәлә. Ләкин теләк бер, ә аңа тайпылмыйча бару — бөтенләй икенче нәрсә. Биредә баланың аңын, эчке дөньясын, кешеләр белән аралашу күнекмәләрен үзең теләгәнчә тәрбияләүдә әзлекле эш таләп ителә. Ә болар үзләре тәрбия кыла белмиләр, җитмәсә, моның никадәр һәлакәтле адым икәнен аңламыйча, балага иптәшкә аңардан шактый олырак яшьтәге Фәхри исемле бер урам малаен гаиләләренә алалар. Мәктәп-мәдрәсә күрмәгән әлеге унөч-ундүрт яшьләрдәге үксез үсмер Кәримгә нинди тәрбия бирә соң? Әлбәттә, үзе белгәнне өйрәтә. Ә аның бөтен белгәне — урлашу, тәмәке тарту, аракы эчү, башка бозыклыклар. Бала исә башта мондый ярамаган эшләргә керешергә теләми, тартыша.

«К ә р и м. Фәхри абый, син тартасыңмы?

Ф ә х р и. Ник тартмыйм, ул бик тәмле шул.

К ә р и м. Йә әле, тартып кара әле!

Ф ә х р и. Аннан тәмле нәрсә юк. Мин бер дә чәй эчмәенчә шуны гына тартыр идем. Мә, суырып карыймсың?

К ә р и м. Юк, ул авызны пешерә, кирәкми.

Ф ә х р и. Ник пешерсен... Мә, кап!

Кәрим (*ирексезләнеп кенә кабып*). Бер дә тәме юк ич!

Фәхри. Эчкә таба суыр!

Кәрим. Аннан ары авызга төтен керә шул!

Фәхри. Аны чыгарасың, аның тәме дә шунда гына шул.

Кәрим (*акыртын гына суырып чыгарып*). Тәмле түгел ич!

Фәхри. Шулай тарта-тарта тәмлеләнә ул, менә тагы тарт әле!»

Бу өзектән күренгәнчә, бала, табигый рәвештә, начар адымны атлауга карыша, тиеш булмаган гамәлдән читтә калырга тырыша. Әмма аның янында үзеннән өлкәнрәк кеше бар, бала өчен аның абруе зур. Фәхри аны кызыктыра, алай да булмаса, оялта, ничек итсә итә, үз үрнәгенә иярүенә ирешә. Ихтыяр көче бик йомшак булган бала озак тартыша алмый. Тора-бара ул хәмердән һәм тәмәкедән башка яши алмас дәрәҗәгә җитеп бозыла. Әхлаксыз хатын-кызлар белән мавыгып китә. Унсигез яше тулгач, аны өйләндереп карыйлар, шуннан соң рәтләнмәсме, тәүфыйкланмасмы дип өмет итәләр. Ләкин өйләнгәннең беренче көннәреннән үк, әллә кайларда йөреп, исерек хәлендә төн уртасында кайта башлый.

Ата-аналарының баланы дөрес юлга кертеп җибәрү мөмкинлекләре була. Алар аны бик әйбәт мәктәпкә урнаштыралар. Ул инде укырга-язарга өйрәнә, дога, намаз укырга керешә. Әмма үзләре дә надан ата-ана, Сәхилә кебек томана карчыкларның сүзе белән, Кәримне әлеге туры юлдан аералар. Автор, шул рәвешле, малайның һәлакәткә килүенең төп сәбәбе итеп белемсезлекне һәм тәрбиясезлекне күрсәтә. Бу бәхетсезлек Кәримнең бик иртә үлеме һәм этисе Фатих байның бөлүе белән тәмамлана. Язучы ата кешенең байлыгыннан мәхрүм калуының сәбәпләрен санап та бирә: гыйлемне кадерләмәве, дөнья белән кызыксынмавы, бала тәрбияләүдәге хәбәрсезлеге, байлык артыннан гына куу, исәп-хисап алып бара белмәве — менә шулар аянычы нәтиҗәгә китерә аны.

Әлбәттә, вакыйгаларны сурәтләү шушында тәгәлләнсә дә, укучы автор әйтергә теләгән нигез фикерне аңлап алган булыр иде: баланы һич тә Фатих бай, Сәгыйдә бикә кебек «тәрбия кылырга» ярамый! Г. Исхакый моның белән генә канәгатьләнми. Ул кешенең бәхетен кече яшьтән үк ни рәвешле әзерләргә кирәклеген дә күрсәтеп бирергә тели.

Кәримнең хатыны Бәдрия — Зәй суы буендагы бер авылдан. Кыям атлы тегермәнче кызы. Әдәпле, инсафлы, укырга-язарга өйрәнгән, динле, намазын укый. Чибәрлеге дә бар.

Шушы фәрештә кебек кыз азып-тузып йөрүче Кәримгә хатын була. Татар хатын-кызларына хас булганча, сабырлык күрсәтеп, Бәдрия ире төзәлмәсме дип өметләнә, аның төн урталарында кайтуын намаз укый-укый көтә. Ләкин тегесе, сәрхушләнеп кайтуы җитмәгән, Бәдрияне ямьсез сүзләр белән сүгә, хәтта аңа кул күтәрә. Кайнанасы Сәгыйдә бикә дә киленне әрләү өчен җай гына эзләп тора. Хәтта Кәримгә икенче хатын алып бирү нияте белән йөри. Фатих байның бөлүе, Кәримнең җинаять юлына басып төрмәгә эләгүе һәм шунда үлеп калуы вакыйгаларны икенче якка борып җибәрә. Бәдрия үзенең уңганлыгы, тырышлыгы белән гаиләне матди яктан тәэмин итүче булып әверелә. Улы Рифгатьне дә дөрес тәрбияли, укыта. Нәтиҗәдә Рифгать мәктәп бетергән, дин таныган, дөньяви белемгә ия булган, русча да укыган егет булып үсә. Рифгатькә унсигез яшь тулганда, тегермәнче бабасы Кыям абзый үлеп китә, аңардан Бәдрия белән оныгына утыз биш мең тәңкә акча, тегермән һәм биш йөз дисәтинә җир кала. Рифгать, икътисад гыйлемен яхшы өйрәнеп, бу байлыкны арттырганнан-арттыра бара. Бабасы Фатихның кеше кулына киткән өйләрен, кибетләрен дә үзенә кайтара. Бик чибәр, әдәпле, укымышлы кызга өйләнә.

Шул рәвешле, Г. Исхакый бер әсәр кысасында ике ир баланың — Кәрим белән Рифгатьнең — бала вакыттан алып балигъ булганчыга кадәрге тормыш юлларын күздән кичерә һәм аларның капма-каршы холык ияләре булуларының тамырларын сәнгатьчә сурәтләп бирә. Ул халкыбызны белемле, инсафлы, эш рәтен белүче, таза нигезгә корылган тормышлы итеп күрергә тели. Язучының каләмен хәрәкәткә китергән максат менә шул.

Г. Исхакый 1901 елда язган «Ике гыйшык» комедиясендә Хөршид исемле кызның «Бай углы» романын укыганлыгын әйттерә, шушы образ авызыннан әсәрнең кыскача эчтәлеген сөйләттерә. Аны тыңлап торган Каюм сөйләгәннәрдән мондый нәтиҗә ясый: «Менә шундый романнар кешенең холкына файда бирә». Моннан тагын бер тапкыр шул аңлашыла: Г. Исхакый иҗатының беренче чорында, мәгърифәтчелек тарафдары буларак, әдәбият ярдәмендә укучыларның холкын тәрбияләү бурычын куя һәм шул максатын эзлекле рәвештә үткәрә килә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Кеше чын мәгънәсендә бәхетле булсын өчен, нинди шартларның булуы кирәк?

2. Фатих байның үз гаиләсен бәхетле дип исәпләве нәрсәгә нигезләнгән? Бу гаилә тормышының әкренләп сүрелүендә төп сәбәп нидә дип уйлыйсыз?

3. Г. Исхакый әлеге гаиләнең бала тәрбияләүдәге нинди ялгышларын ачып сала?

4. Әдәбияттан белгәннәрегезгә, тормышта күргәннәрегезгә нигезләнеп, «Баланы дөрес тәрбия итмәү — үз-үзеңә хыянәт итү» дигән темага бәхәс уздырыгыз.

5. Әсәр бер-беренә капма-каршы куелган ике өлештән тора. Автор ни өчен шулай эшләгән? Сәнгать чарасы буларак, моның нинди әһәмияте бар? Сезнеңчә, әсәрнең беренче өлешеннән башка икенче сюжет була алыр идеме?

6. Сезнең фикерегез ничек: укучыга уңай әдәби образ көчлерәк тәэсир итәме, әллә тискәресеме?

7. Базар икътисады шартларында эш иткәндә, сез кайсы образны үзегезгә үрнәк итеп алыр идегез һәм ни өчен?

Беренче пьесалары

Патша хакимияте рус булмаган халыкларның, аерым алганда татарларның, мәдәни-рухи үсешен махсус рәвештә тоткарлап килә. Татарларда театр сәнгатенең шактый соң барлыкка килүе дә шуның белән аңлатыла. Зыялыларыбыз, спектакль куярга рөхсәт сорап, күп мәртәбәләр мөрәҗәгать итеп карасалар да, хакимият тискәре җавап бирә. Әле Казанда, әле Оренбургта, әле Уфада, әле башка урыннарда яшьләр спектакль куярга дәртсенәләр, ләкин аларның омтылышлары катгый кире кагыла. Г. Исхакыйның «Тартышу» драмасында да яшьләр спектакль куярга телиләр. Ләкин губернатор канцеляриясендә аларга болай дип җавап бирәләр: «Элгәре ул китаплар русчага тәрҗемә кылынырга кирәк. Аннан соң цензурага бирергә кирәк. Ул рөхсәт бирсә, бәлки, без бирербез».

Шулай да 1906 елның 21 апрелендә Уфаның зыялы яшьләре максатларына ирешәләр — Приказчиклар клубында Г. Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш» әсәре буенча эшләнгән спектакль куялар. Димәк, татар театр сәнгате шушы әсәр белән аваз бирә. «Казан мөхбире» газетасы 1906 ел 30 апрель санында, бу вакыйганы бәяләп, болай яза: «Агыйдел буенда яңа терелә башлау яисә төркичә телдә театр».

Шул ук елның 5 маенда Казанда да спектакльләр куела. Анда төрекчәдән тәрҗемә ителгән «Кызганыч бала» драмасы

һәм «Гыйшык бәласе» комедиясе сәхнәләштерелә. Дөрес, биредә дә татар яшьләре Г. Исхакыйның Уфада уйналган әсәрен сәхнәләштерергә омтылалар. Цензор «әсәрдә гаепкә алырлык берни дә юк» дисә дә, губернатор рөхсәт бирми, ниндидер татар авторын сәхнәгә менгерү аның вазифасына керми, янәсе. Уфа яшьләре исә бу вакытта Г. Исхакыйның «Ике гыйшык» әсәрен дә куярга өлгерәләр.

Казандагы «Яшьләр» труппасына татар драматургларының әсәрләрен куярга 1907 елда гына рөхсәт ителә башлый. Труппа бу мөмкинлектән бик өлгер файдалана. 1907 елның 13 гыйнварында Г. Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш» әсәре сәхнәгә куела. Аннан соң уйналган спектакльләр арасында аның «Ике гыйшык», «Алдым-бирдем», Г. Камалның «Бәхетсез егет» һәм башка әсәрләр була. Күргәнебезчә, татар театр сәнгатенең аваз бирүе Г. Исхакый исеме белән турыдан-туры бәйләнгән.

«Өч хатын белән тормыш»

Уфада да, Казанда дә әсәрне куярга рөхсәт итүләренең сәбәбе шул булса кирәк — биредә патша хакимияте өчен берниндидә куркынычлы фикер үткәрелми. Г. Исхакый үзе әйткәнчә, «бу драма — татар матбугатында хатыннар хакы өчен тартышучы беренче китап, ...күпхатынлылык мәсьәләсене тәнкыйть вә аннан көлү». Әйе, әсәрнең темасы шуннан гыйбарәт.

Казанның бер бае Кәрим Әсма исемле акыллы, сабыр, итагатьле хатыны белән әйбәт кенә гомер кичерә. Алар берберсен яратып, матур гына тормыш итәләр. Байлыгы да Аллага шөкер итәрлек. Ләкин акыллы баеса, йорт сала, ахмак баеса, күп хатын ала дигәндәй, Кәрим көннәрдән бер көнне тагын бер хәләл җефетле булырга карар кыла. Нәтиҗәдә йортка Әсмага көндәш булып Мәрьям килә. Әлбәттә, иренең яшь хатынга өйләнүе (дөресендә, бу ике хатын яшь ягыннан бер чамада, тик Мәрьям үзен егерме бердә генә дип алдый) Әсма өчен күңелле хәл түгел, ләкин бөтен тәрбиясе белән кешелекле бу хатын күңелендәге хис кайнарлыгын баса белә, көндәше белән уртак тел табарга омтыла. Тик берничә еллар бозыклык юлында булган, үз гомерендә байтак ир-атларны кулыннан үткәргән Мәрьям сүз сыймас кеше булып чыга. Яшь хатын, үзенең көндәшен юлдан алып ташлау өчен, мәкер ятьмәсе үрә.

Ләкин хатыннары өстеннән яшертен рәвештә сөяркәләр тотудан да оялмаучы Кәрим өченче тапкыр өйләнергә уйлый. Үзенә шактый бурычлы бер кешенең уналты яшьлек кызы Сорурны хатын итеп ала. Мәрьямнең барлык зәһәре инде яшь кәләшкә юнәлә. Ник дигәндә, Сорур яшьрәк тә, чибәррәк тә. Кәрим дә бөтен игътибарын кече хатынына бирә. Мәрьям Сорурны сүз белән генә җәберләп калмый, тотып кыйнарга ук керешә. Кәрим уртанчы һәм кече хатынын бергә ялгыз калдырырга курка башлый. Көннәрдән бер көнне бу ике хатын арасында бик каты җәнҗал чыга. Кәрим Мәрьямне талак кылырга мәҗбүр була.

Бәлки, шуннан соң Кәримнең тормышы тынычланып, бәхетле булып китәр дип көтәсең. Юк, автор Кәримнең бербер артлы һәлакәт юлыннан тәгәрәвен күрсәтүне дәвам итә. Ул очраклы рәвештә Сорурның үзен яратмау гына түгел, хәтта күралмавын белеп хәйран кала. «Шул чикле яратмыйм Кәримне,— дип сөйли Сорур өлкән хатын Әсмага,— ...менә шул чикле инде... Йөзен бер күрмәс өчен, әллә никадәр хезмәт итәр идем. Бер генә дә сөймим инде... Әтиләр Кәрим белән элгәредән эш итәләр иде... Кәримгә ике мең тәңкәгә йортлары залогта булган. Түли алмагач, Кәрим аларның йортын саттырырга җыена башлаган. Менә шундый кыен хәлдә калган гаиләгә: «Шул йортларын үзләренә бирәм, Сорурны бирсеннәр!» — дигән. Әти, башта ни эшләргә белмәсә дә, башкача бөтенләй фәкыйрьлеккә калырмыз дип, вәгъдә кылган. Менә мине шулай бирделәр».

Кәрим, шул рәвешле, хатын-кызлардан кан-яшь түктерә, кайсын усалланып (Әсманы), икенчесен юхаланып (Мәрьямгә), өченчесен куркытып (Сорурны) хатын итеп тотарга тели. Моннан башка да Кәримнең кыңгыр эшләре бихисап икән. Аның шундый гамәлләрен Г. Исхакый явызлык итеп бәяли. «Һәр җинаятьнең җәзасы була» дигән фикерне раслау өчен, Кәримнең соңгы көннәрен аянычлы итеп тасвирлый. Хатын-кызлар белән мавыга торгач, Кәрим икътисади эшләреннән бөтенләй читләшкән, буталып беткән. Ниһаять, ул үзе дә Сорурның әтисе хәленә төшә, банкротлыкка чыга. Доверенные Габбасның «Кибетне бастылар, счёт сорыйлар» (яптылар мәгънәсендә) диюенә ул: «Кая китте ул акчалар?» — дип сорый. Халык, ашаган белми, тураган белә, ди бит. Габбас та Кәримгә акчаларның кая киткәнен аңлатып бирә: «Кая китсен! Теге баланы яшереп калыр өчен, мең тәңкә марҗага

бирдегез, эчемлек кибетенә сигез йөз кырык сигез тәңкә түләп җибәрдегез, өй чыгымнарына дип, бикәләр өч йөз тәңкә алдырганнар... Мин сиңа әйттем ич: «Бу кадәр кыланмаска кирәк, чыгымыгыз керемегезгә җитми»,— дидем ич... Хәзер нишлик инде? Йортны, банкыга (банк) салып булса да, рәтләмичә ярамый». Шулар өстенә Мәрьям дә унике мең сум акчаны урлап киткән икән.

Г. Тукай әйткәнчә:

> Ә шулаймы? — Акча барда бар да дуст шул, бар да яр;
> Акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр!

Шуның төсле Кәримнең дә Соруры этисе йортына кайтып китә, дус-ишләре дә юкка чыга. Беренче хатыны Әсмасы гына аңа тугрылык саклый. Кечкенә генә фәкыйрь өйдә авыруга сабышып яткан ирен энҗеле калфак ише әйберләрен сатып тәрбияли. Г. Исхакыйга Әсманың игелеклелеген тасвирлаудан бигрәк Кәримнең кылганнарына үкенүен күрсәтеп бирү әһәмиятлерәк. Бу тора-бара мелодрама төсен ала. Аның үлер алдыннан Әсмага әйткән сүзләре тирән кичерешләренең нәтиҗәсе икәнен күрсәтә: «Сине урынсыз, гөнаһсыз җылатуымны ничек бәхилләтим?.. Нинди йөз белән синнән ризалык сорыйм? Эчемнең иң көйгәне шуның өчен! Аллаһы Тәгалә бу көннәрне шуның өчен күрсәткәндер. Бир, бәгырем, кулыңны үбим! Бәхиллә мин гөнаһлыны... Оятсызны бәхиллә! Җаным бул, никадәр изгелекләр кылдың, минем эчемне яндырып, шул гөнаһым белән Алла каршысына җибәрмә! Башка гөнаһларым да җитәрлек!..»

Автор гөнаһлы Кәримне җәзадан котылдыру юлыннан китми. Ул инде бу дөнья белән хушлашырга мәҗбүр, җан тәслим кыла. Аның каравы драматург изге күңелле, ак гамәлле Әсманы мондый авыр хәлдә калдыруны килешсез саный. Әсәр ахырында билетларга (хәзерге лотерея сыман) егерме биш мең сум отыш чыгып, аның матди тормышы шактый ныгып кала.

Г. Исхакый бу әсәрендә дә мәгърифәтчелек карашларын уздыра. Моның төп билгесе: надан кешеләргә (Кәрим, Мәрьям) белемлеләрнең (Әсма, Риза — Әсманың бертуган энесе) каршы куелулары һәм соңгыларының өстенлеккә ирешүләре. Бик акыллы, күп укыган, шуңа күрә кешеләрне таный белүче, хәл-әхвәлләрне дөрес бәяләүче Риза образы Кәрим кебек кара фикерлеләргә капма-каршы итеп куела. Тискәре

фикерле Кәримнең ялгышларын турыдан-туры әйтеп бирүче дә — шушы Риза. Ул, Кәримнең күзен ачарга тырышып, болай ди: «Безнең динемезчә менә шулай кеше бер хатын алырга кирәк, сәламәт булганда, хатын алмаска ярамый; өстенә башка хатын алу дөрест түгел... Сезнең өеңездә дүрт кешенең гомере әрәм булып ята... Кая рәхәт, кая тормыш? Картайгач та, яшь вакытыңыздагы сугышканнарыңызны искә төшерерсез шул инде... Бу көнчә ни сиңа рәхәт, ни апага, ни Мәрьямгә, ни Сорурга. Һәм һичбер вакыт булмаячак!»

Күп хатын белән яшәү, азгынлык һәм миһербансызлык кебек тискәре күренешләргә кискен каршы чыккан Гаяз Исхакыйны заманының татар зыялылары хуплый. «Өч хатын белән тормыш» әсәренең беренче булып татар сәхнәсенә менүе дә шуның дәлиле булып тора.

Сораулар һәм биремнәр

1. Татар театр сәнгате, барлыкка килгәндә, нинди каршылыкларга очрый?

2. Татар театры барлыкка килү Г. Исхакый исеме белән бәйле дигәндә, безниләрне күздә тотабыз?

3. «Өч хатын белән тормыш» әсәрен автор нинди максат белән язган?

4. Әсәр ни өчен тиз генә сәхнәгә күтәрелә алмый? Бу хәл әсәрнең эчтәлеге, авторның шәхесе белән генә бәйләнгәнме?

5. Кәрим хатыннарының өчесенә дә тасвирлама бирегез. Аларның төрле холык ияләре булуы автор тарафыннан ничек дәлилләнгән?

6. Тупас көчкә, акчага гына корылган гаиләдә мөнәсәбәтләр ихлас була алмый. Бу драма мисалында ул ничек раслана?

7. Әлеге әсәрнең мәгърифәтчелек рухында язылуы ниләрдә күренә? Риза образының әсәрдә ни өчен сурәтләнүен аңлатыгыз.

8. Тагын кайсы әдипләребез күпхатынлылыкны фаш итеп яздылар?

«Ике гыйшык»

«Ике гыйшык» комедиясе (1901 ел) сәнгатьчә эшләнеш ягыннан шактый камил. Авторның каләме шомара төшкәне сизелеп тора. Ул инде образларны да, мәгърифәтчеләрчә кырт кисеп, акка һәм карага гына бүлеп куймый, бәлки аларны табигый кешеләргә хас булган уңай һәм тискәре яклары белән сурәтли. Бу бигрәк тә Габделкаюм белән Хөршид образларына карый. Дөрес, образларны уңай һәм тискәреләргә

бүлүдә биредә дә катгыйлык нык кына сизелә әле. Мәсәлән, Рәхмәтулла кебек «яңа эшнең һәммәсенә каршы килә торган чын карт бай», Галимәдәй «елан йоткан, зәһәр, бик хәйләкәр, начарлыктан бер дә курыкмый торган хатын», Габделгазиздәй «фасикъ, вөҗдансыз, әхлаксыз» егет образлары бары тик тискәре сыйфатлар тупланмасы буларак күз алдына киләләр. Әсәрнең үзәгенә куелган Габделкаюм белән Хөршид образлары исә, нигездә, уңай булсалар да, күпмедер дәрәҗәдә каршылыклы итеп бирелгәннәр. Шуның белән дә аларның укучы игътибарын җәлеп итү көче арта.

Укыган кеше — әйбәт кеше, дигән фикер бу әсәрнең дә буеннан-буена үтә. Әле генә сүз барган тискәре образларның берсе дә мәгърифәткә, китапка, дөньяви белемгә мәхәббәт белән карауччылардан түгел. Габделгазиз (Газиз) әнә нәрсә ди: «Аларны (ягъни китапларны) укып торганчы, мин утын ярсам файдалы булыр». Габделкаюм белән Хөршид исә — икесе дә укыган, бер-бере белән акыллы, хисле, үтемле һәм хәтта, әйтергә мөмкин, фәлсәфи әңгәмәләр алып барырдай яшьләр. Димәк, мәгърифәтчеләр күзлегеннән караганда, Каюм белән Хөршид коеп куйган үрнәк сыйфатларга гына ия булырга тиешләр иде. Әмма язучы мондый туры сызыклар буенча гына эш итми. Ул алай эшләүнең әсәр сюжеты оештырылышын ярлыландырасын сизә.

Автор тормышның катлаулырак булуын раслау юлыннан китә. Яшьләрнең үзара мөнәсәбәте төрле шартларда сынау үтә. Биредә авторның билгеле бер чикләрдә ирекле мәхәббәткә юл кую ягында торганлыгы да сизелеп кала. Әмма, ни генә булмасын, язучы-әдип тормышка ачык күз белән карый.

Ул вакытларда күпчелек очракларда егет белән кыз өйләнешкәнче бер-берсе белән күрешеп таныша да алмаган шартларда, Каюм белән Хөршид аулак урыннарда очрашканнар, бер-берсенә мәхәббәтләрен белдергәннәр. Мәхәббәттә акыл беләнрәк эш итүче Каюм, хисләрен тыеп кала алмаучы Хөршид мөнәсәбәтләре укучыны җәлеп итә. Хөршидне сөюе хак булса да, Каюм күңелендә башка кызларга да урын табылырга мөмкин. Хөршид өчен исә Каюмга булган мәхәббәте бердәнбер. Яратышуның чынлыгын раслау өчен юлы бар — өйләнешергә кирәк. Икесе дә моны үзләре өчен, бәхет дип санар иде кебек. Дөрес, бу юлда киртә булып торучылар да юк түгел: Каюмның әтисе Рәхмәтулла белән үги әнисе Галимә. Алар Каюмга берәр бай кызын алып бирергә телиләр.

Талчокчы Габдулла кызы Хөршидне килен итү боларның ниятенә якын да килми. Шунысы кызык: өлкәннәрнең бу мәсьәләгә үз карашларын Каюмга әйтүләре була, ул инде Хөршидкә, мин сине хатынлыкка ала алмыйм дип, хат та яза. Бу исә сюжетның киеренкелеген йомшартып җибәрә. Өйләндерсәләр, Каюм башка бер кызның ире булырга да әллә ни каршы түгел. Тик шул арада аның этисе вафат була. Бөтен мал-мөлкәткә хуҗа булып калам дип йөргән үги ана Галимә, бөтенләй көтмәгәндә үлеп киткән ире Рәхмәтулладан бернинди язма васыять алырга өлгермәгәнлектән, өметен өзеп, бу йорт белән хушлашырга мәҗбүр. Инде Каюмга Хөршид белән бергә булырга киртә дә калмаган кебек. Әмма ниндидер Салих байның Рафига исемле кызыннан хат килеп төшкәч, Каюм аның белән очрашу, танышу гамәленә керешә.

Әсәрне комедия иткән нәрсә шул: әлеге Рафига дигәнебез Хөршид үзе булып чыга. Аулакта очрашып, бер-беренә ачылгач, мәхәббәтләренең чынлыгына тагын бер кат инангач, алар туй көнен билгелиләр.

Әйе, укучының яки тамашачының Каюмны бертөрле сөйләп, икенче төрле эшләүче икейөзле кеше булуда гаепли башларга да хокукы бар. Ул азып-тузып йөрүче Газизгә, үзен югары тотып, менәниләр сөйли: «Гөнаһсыз кызны бөтен рәхәтеннән мәхрүм иткәнсез... Яхшы эш эшләмәгәнсез, дустым. Мескеннең бөтен гомерен харап иткәнсез... Минемчә, шундый бер зур гөнаһ кыйлгансыз, дөньяда һич аның кебек начарлык булу ихтималы юк... Ничек вөҗданыңыз җитте шулкадәр золым кыйлырга?.. Мин, шул эшне эшләсәм, вөҗдан газабыннан үләр идем. Зур инсаниятсезлек (кешелексезлек)!»

Никадәр дөрес сүзләр! Тик менә үзе Хөршидне шундый ук кыен хәлдә калдырырга мөмкин иде бит. Рафига булып кыяфәтен үзгәртеп, аулакта очрашырга килгән Хөршидкә әнә нәрсә ди бит әле: «Сездән башка кыз берлән болай аулакта утырганым юк иде. Менә иң әүвәле таныш кызым сез. Мин алай кызлар алдап йөри торган егет түгел. Мин кызларның гыйффәтенең ни дәрәҗәдә икәнен беләм. Миннән курыкма!» Укучы Каюмның ялганын, сөйләгәненең ихлас булмавын күреп-ишетеп тора.

Хөршиднең менә бу сүзләре укучының күңелендә туган уйлар белән тәңгәл киләләр: «Син үзеңнең сөйләгән сүзләрең берлән кыйлган эшләреңне чагыштырып кара! Вөҗданың

булса, үзең дә белерсең. Шунысын да әйтим: мине болай итеп калдыруның җәзасын күрми калмассың!»

Шуннан алдарак исә Каюм үзе дә Газизгә шулайрак итеп әйткән иде: «Дөньяда яманлыклар һичберсе муафикъ җәза бирелмәенчә калмый». Димәк, ул үзе дә әлеге Газиз, «Өч хатын белән тормыш» әсәрендәге Кәримнәр эзеннән китеп бара түгелме соң? Болар, әлбәттә, Каюм образын бизәми. Аның каравы Каюм холкындагы мондый каршылыклар сюжетның катлаулырак һәм кызыклырак корылышын тәэмин итә.

«Ике гыйшык», автор тарафыннан комедия жанрына карый дип билгеләнсә дә, дүресендә аның бишенче — соңгы пәрдәсендә генә көлкеле хәл-әхвәл тудырыла. Пьесаның дүрт пәрдәсен драма, хәтта мелодрама дип атап булыр иде. Жанр үзенчәлекләренең аерымланып җитмәве гасыр башындагы драматургиябезнең әле бик үк җитлегеп бетмәвен дә күрсәтә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Сез Каюм белән Хөршидне бер-беренә ихлас гашыйклар дип саныйсызмы? Гомумән, аларга сезнең мөнәсәбәтегез нинди?

2. Каюм белән Газиз арасындагы уртак һәм аермалы якларны билгеләгез. Каюмның Газиздән өстенлеге нәрсәләрдә күренә?

3. Нинди вакыйга әсәрне комедия дип атарга мөмкинлек бирә?

4. Драма күренешенең комедиягә әверелүендә кайсы образның өлеше зур?

5. Бу әсәрдә Каюмнан тыш көлкегә калучы тагын башка образлар бармы?

6. Белемлелек әхлаклылыкның синонимы булмаган кебек, байлыкка ия булу да кешене уңай яктан бәяләү өчен җитәрлек түгел. Бу әсәрдә ул ничек ачыла? Ничек тасвирлана?

Г. Исхакый —
яңа әдәбиятка нигез салучы

Татар әдәбияты XX йөзгә шактый тәҗрибә туплап килде. Жанр төрлелеге, сәнгатьчә сурәтләү чараларының камилләшә төшүе, күтәрелгән мәсьәләләрнең тирәнәя һәм җитдиләнә баруы шулай әйтергә мөмкинлек бирә. Сүз сәнгатебез өчен гадәти булып әверелгән аң-белемлелекнең әһәмияте, мәктәп-мәдрәсәләрне үзгәртеп кору, хатын-кыз азатлыгы, әхлаклылык кебек темаларны күтәрүнең һәм сәнгатьчә хәл итүнең дәрәҗәсе үсте. Шул ук вакытта җәмгыятьтәге хәл-

әхвәлләрне тирәнрәк, фәнни казанышларга таянып сурәтләү, Көнчыгыш әдәбиятлары белән элек-электән килгән бәйләнешләрне саклаган хәлдә, Көнбатыш халыклары сүз сәнгатенә дә игътибар итү, алардагы казанышларны иҗади файдалану әдипләребез әсәрләренең җитди сыйфат үзгәрешләрен тәэмин итте. Әлбәттә, бу яңа дәвернең юл башында Г. Исхакый торды. Аның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (бетү, юкка чыгу), «Теләнче кыз», «Тормышмы бу?», «Мулла бабай», «Сөннәтче бабай» кебек роман һәм хикәяләре, «Мөгаллим», «Алдымбирдем», «Тартышу», «Кыямәт», «Җәмгыять», «Зөләйха» кебек драма һәм комедияләре, публицистикасы шул турыда сөйли. Боларда автор татар милләте язмышын яктырта, социаль тигезлек өчен көрәшнең әһәмиятен һәм кирәклеген нигезли. Иске белән яңаның тартышы әсәрләрендә гәүдәләнгән төп каршылыкны тәшкил итә. Ул аны сәнгать чаралары ярдәмендә сурәтләп бирә.

Йосыф Акчура, бу язучыбызның XX йөз башы татар әдәбияты галәмендә тоткан урынын билгеләп, мондый фикер әйткән иде: «Милләттәшләрем арасында ике чын әдип җитешә: берсе — хәссәс (сизгер), атәшле[1], милләтпәрвәр[2], идеалист һәм романтик Гаяз, икенчесе — гасаби[3], тешләүчән, милләтне чеметеп сөя торган рационалист вә реалист Фатих[4]». Г. Исхакыйның олы иҗаты бу сүзләрнең дөреслеген раслый.

«Ике йөз елдан соң инкыйраз»

Гомер барышының нинди дер бер мизгелендә кеше үз-үзенә менә бу сорауларны бирми калмыйдыр: «Мин дөрес яшимме? Үткән гомеремдә нәрсәләргә ирештем? Алар мине канәгатьләндерәме?»

Бу нигә кирәк? Җавап гади: иртәгә тагы да уңышлырак эш итү, куйган максатларыңа тизрәк, турырак юл белән җитү өчен. Авыруның сәбәбен белгән табиб та уңышлырак дәвалый бит.

1902 елда язган «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле әсәрендә егерме дүрт яшьлек Мөхәммәтгаяз тулаем халкы-

---

[1] *Атәшле* — ялкынлы.
[2] *Милләтпәрвәр* — милләтне яратучы.
[3] *Гасаби*— кызу канлы.
[4] *Фатих* — Фатих Кәрими.

быз язмышы турында уйлана. Болгарлар язмышы (ул татарларны шулай атый), аларның яшәеше, көнкүреше рәвешен кыл иләктән үткәреп җентекли һәм шактый күңелсез нәтиҗә ясый: тормышыбыз, яшәү рәвешебез болай барса, халкыбыз ике йөз елдан, ягъни 2100 еллар тирәсендә юкка чыгачак! Бу нәрсә яшь каләм әһелен тетрәндереп җибәрә, аның төн йокыларын качыра. Үзе ясаган нәтиҗә белән тулаем халкыбызны (дөресрәге, милләт гамен кайгыртып яшәүчеләрне) таныштырырга тели. Укыгыз, аңлагыз, безне алда нәрсә көтүен күрегез, әле эш узмаган, бергәләп нинди дә булса чарасын күрик һәм исән калуның, алай гына да түгел, алга китүнең дөрес юлларын табыйк!

Әсәрнең жанры хыялый-публицистик повесть дип билгеләнә ала. Чөнки биредә әсәр язылу вакытыннан соң йөз-ике йөз еллар үткәч булачак вакыйгалар тасвирлана. Булмаган нәрсәне бары тик хыял ярдәмендә генә фараз итәргә мөмкин. Менә ни өчен повестьны хыялый дип атарга була. Әсәрдә сүз болгар-татар халкының үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында бара, ягъни әсәрнең эчтәлеге иҗтимагый юнәлешле. Әдип үзенең повесте белән җәмәгатьчелеккә йогынты ясауны максат итә. Мондый әсәрләр публицистик төргә керәләр. Сәяси юнәлеш аларда аеруча нык сизелеп тора. Г. Исхакый — бездә сәнгатьле публицистикага нигез салучы әдипләрнең берсе.

Повесть төзелеше белән өч кисәктән тора: кереш, төп өлеш, хатимә (йомгаклау). Төп өлешнең үзен өч бүлектән тора дип карарга мөмкин. Һәм алар автор тарафыннан бик оста, үз алдына куйган максатына ирешүгә кулай итеп төзелгәннәр. Әйтик, иң әүвәл туй күренеше сурәтләнә. Ниндидер Фәхри байның улы Шаһимөхәммәт бай кызына өйләнә. Ике яктан туй чыгымнарына кырык мең сум акча сарыф ителә. Хәерсәдака мул бирелә, өстәлләргә ризык чамадан артык күп куела, кием-салымга бихисап байлык тотыла. Ләкин әлеге бай абзыйлар ни дип шулкадәр юмартланалар соң әле? Моңа җавап әсәрнең үзендә: «Менә абзаң ни эшли!» — дип, тел шартлаттыру өчен. Ягъни башкалар алдында байлыклары белән мактану максаты белән. Мондый акча түгүләр милләткә нинди дә булса файда китерәме? Юк! Автор моны «курчак уены» дип атый һәм әйтеп куя: «Эшләгән эшләремезнең ни өчен, ник икәнен белмәенчә кыйлануымыз болгарларның искедән калган табигатедер». Шул рәвешле, болгар халкының

бөтен тормышы «курчак уены» дип аталырга тиешлегенә ишарә итә, алга таба моның шулай икәнлеген тагын да ачыклый төшә.

Халкыбызның нинди эш-гамәлләрен автор «курчак уены» дип атый соң? Халык тормышын алга җибәрүгә ярдәм итми торган нәрсәләр турында кирәгеннән артык көч куеп шапырынуларны, әһәмиятле эш башкарабыз дип, үз-үзләрен ышандыруларны Г. Исхакый юмор-сатира ярдәмендә көлкегә ала. «Безнең болгар йортында ясту (ясигъ) намазы фарызмы, түгелме?», «Русча уку хәрәмме[1], мәкруһмы[2], мөбахмы[3]?», «Ысулы җәдитчә (яңа ысул белән) укыту ярыймы-юкмы?» — шундый мәсьәләләр тирәсендә генә бәхәс куертуларны әдип өнәми. Безгә чын тормыш белән яшәргә кирәк, ди ул. Аның өчен татар җәмгыятен алга киткән милләтләр сафына чыгару — иң әһәмиятлесе. Милләтнең алга үсешенә комачаулый торган сәбәпләрне бетерергә кирәк. Ә андый сәбәпләр бик күп. Шундый каршылыклар сыйфатында Г. Исхакый түбәндәгеләрне күрсәтә:

— дин әһелләренең алдынгы карашларны якламавы;

— мәктәп-мәдрәсәләрдә укытыла торган гыйлемнәрнең дөньяви ихтыяҗларга яраксыз булуы;

— халык мәнфәгатьләрен кайгырту сәләте булган кешеләрнең, бик фәкыйрь сыйныфтан чыгып, милләткә хезмәт итәр урында, бар көчен тамагын туйдыру, үзенең эш урынын саклар өчен сарыф итәргә мәҗбүр булуы;

— бик надан булуыбызны танымавыбыз, рус мәктәпләрендә укытыла торган фәннәрнең мәдрәсә-мәктәпләребездә урын алмавы;

— кылган эшләребезнең нигезле, эзлекле булмавы, башлаган гамәлләребезне ахырына җиткерә алмавыбыз.

Алга китешебезгә киртә булып торучы сәбәпләрне күрсәткәндә, Г. Исхакый болар белән генә дә чикләнмәгән булса кирәк. Әдәбият галиме Ибраһим Нуруллин да шулай дип исәпли. «Повестьны укыганда,— ди ул,— укучы күп нокталар белән билгеләнгән урыннарны еш очратыр. Болар цензор сызып ташлаган кисәкләрне аңлата. Моның шулай икәнен без тагын Гаязның русча язылган автобиографиясеннән

---

[1] *Хәрәм*— «тыелган», «тыюлы» мәгънәсендә.
[2] *Мәкруһ* — дин тарафыннан тыелмаса да, шелтәләнә торган нәрсә.
[3] *Мөбах* — хәләл дә, хәрәм дә түгел.

беләбез. Нинди урыннарны сызып ташлаган соң цензура? Әсәрнең кулъязмасы сакланмаганга күрә, бу сорауга төгәл җавап биреп булмый[1]. Шулай да чамаларга мөмкин. Укучы күрер: ике йөз елдан соң татар милләтенең юкка чыгуын яки чыгачагын автор шактый күп сәбәпләр белән аңлата. Әмма сәер хәл: шулар арасында милли-колониаль изү, шуның бер күренеше булган христианлаштыру кебек сәбәпләр юк. Г. Исхакыйның бу мәсьәләне белмәве һәм «Инкыйраз»да күтәрмәве мөмкин түгел. Менә ни өчен без кыскартылган урыннар, һәрхәлдә, аларның күпчелеге, һичшиксез, самодержавиенең милли-колониаль политикасы белән тегеләйме-болаймы бәйле дип әйтә алабыз. Хәер, әсәрдә сүз сөрешеннән дә моны чамаларга мөмкин»[2].

Әйе, татар халкының матди, рухи, фәнни, иҗтимагый тормышы артта калуга, әлбәттә, Казан ханлыгының 1552 елда бәйсезлеген, мөстәкыйльлеген югалтуы иң беренче сәбәп булып тора. Бары тик үзенең яшәешенә үзе хуҗа булган халык кына алга китә ала. XX йөз башына кадәр үз телендә газета-журналлар чыгарырга да рөхсәт ителмәгән, бер генә югары дөньяви уку йорты да булмаган татар халкының фән-техника өлкәсендә әллә ни казанышлары була алмавына гаҗәпләнергә кирәкме икән?

XXI гасырның соңгы унъеллыгын сурәтли башлаганчы, автор сүзне гомуми рәвештә, ягъни тулаем милләт язмышы турында алып бара. Тик болгарлар тәмам юкка чыгарга берничә ел калгач кына, әсәргә Җәгъфәр исемле аерым бер шәхес — тарихчы, язучы образы килеп керә. Аның әсәрдә урын алуы бик әһәмиятле. Беренчедән, ул сурәтләүне җанландырып җибәрә. Моңа кадәр автор исеменнән алып барылган уйланулар Җәгъфәрнең эш-хәрәкәтләрен һәм кичергәннәрен сурәтләү белән алышына. Укучыны инде Җәгъфәр һәм аның хатыны Сөембикә язмышлары кызыксындыра башлый. Бу, беренчедән, моңа кадәр өзлексез зарлану, борчылу, көрәшкә, эшкә чакырулардан торган тексттан ялыга башлаган укучыны бертөрлелектән коткара. Икенчедән, җанлы кеше буларак, болгарларның инкыйразын тулы фаҗигасе белән үз күңеленнән кичергән Җәгъфәрнең халәте укучының да бу мәсьәләләр

---

[1] Бу мәсьәләгә ачыклык кертелде. Кара: Госманов М. Гаяз Исхакый: «Ике йөз елдан соң инкыйраз һәм патша цензурасы»//Казан утлары.— 1995.— № 10.— 152—181 б.

[2] Казан утлары.— 1990.— № 1.— 87—88 б.

турында бөтен күңеле белән дулкынлануына китерә. Әлбәттә, галим һәм язучы буларак, Җәгъфәрнең башка милләтләр, аерым алганда рус зыялылары белән аралашуы русларның болгарлар бетүгә булган мөнәсәбәтен ачыкларга да ярдәм итә. Шулай итеп, Җәгъфәр образы — авторга үзе күтәргән мәсьәләләрнең зурлыгын һәм әһәмиятен тагын да көчәйтү өчен хезмәт итә торган сәнгать чарасы.

Повестьта болгарларның берәм-берәм үлеп баруы күрсәтелә. Ниһаять, болгар-татарлардан Җәгъфәр белән аның хатыны гына кала. Өмет иң соңыннан гына үлә, диләр. Җәгъфәрнең дә өмете бар. Аның Сөембикәсе йөкле. Димәк, әле үз нәселенең генә түгел, болгарларның да яшәп, тернәкләнеп китүе мөмкин дигән ышаныч яши. Тик... Сөембикә үле бала таба. Аны Туктамыш исеме кушып җирлиләр. Сөембикә үзе дә дөнья куя. Җәгъфәр җир йөзендә бердәнбер болгар кешесе булып кала. Кара-каршы сөйләшергә милләтәшләреннән мәхрүм калган Җәгъфәрнең Болгар шәһәренә барып чыгуы — табигый күренеш. Ул, бер манара башына менеп, уйга чума. Аның башыннан болгарларның язмышы уза. Ләкин шулвакыт бик көчле җил чыгып, манара ава. Җәгъфәрне таш басып үтерә. Шулай итеп, соңгы болгар да җир куенына керә. Әсәр ахырында укучыны әнә шундый фаҗига көтә. Тетрәткеч хәл! Бу инде — аерым бер кешенең генә түгел, бәлки тулы бер милләтнең юкка чыгуы. Әсәрнең соңгы битен ябып куйгач, күңелне борчу баса. Сүз үз халкың турында барганга, бу хисләр күңел үзәгенә үтә.

Г. Исхакый болгар-татарларның халык буларак җир йөзеннән юкка чыгуга таба баруына җаны-тәне белән тетрәнә. Шуңа күрә ул үзенең милләттәшләрен мондый афәттән саклану чараларын күрергә өнди.

Әсәр, 1902 елда язылып бетсә дә, цензура киртәләрен үтә-үтә, 1904 елда гына басыла. Шуннан соң ул 1990 елга кадәр дөнья күрми, беркайда да укучыларга тәкъдим ителми. Авторның кулъязмасы да сакланмаган. Шуңа күрә без аны тулаем килеш укудан мәхрүм.

Г. Исхакыйның замандашлары әсәргә югары бәя биргәннәр. Ф. Әмирхан, мәсәлән, болай дип язган: «Бу әсәрдә ялкынлы автор бөтен татар тормышын рәхимсез рәвештә тәнкыйть итә. Ул миңа бик тә көчле тәэсир ясады». Г. Тукай «Мөридләр каберстанындин бер аваз» шигырендә шулай ук Г. Исхакыйга мактау әйтә:

Дәрсе гыйбрәт вирде безә «Инкыйраз» нам бер әсәр,
Аһ буны язган кеше Инсан икәндер, белмәдем[1].

(Гыйбрәт дәресе бирде безгә «Инкыйраз» исемле бер әсәр,
Аһ моны язган кеше Кеше икәндер, белмәдем.)

Г. Исхакыйның бу әсәрендә күтәрелгән мәсьәләләр Ф. Әмирхан, Г. Тукай, М. Гафури, С. Рәмиев, Н. Думави, Ш. Камал, Г. Ибраһимов, Г. Коләхмәтов һәм башка әдип-шагыйрьләребезне дулкынландырган. Алар да үз иҗатларында татар халкын бәхетле, азат, мөстәкыйль, белемле, сәләтле итеп күрергә теләүләрен әйтеп бирделәр. «Инкыйраз»ның әһәмияте бүген аеруча үсте. Халкыбыз бәхеткә ирешү өчен көрәшә. Башка милләтләр белән тигез хокуклы булуны максат итә. Г. Исхакый әсәрләренең көче бу көрәшкә җегәр өсти, аның уңышка китерәчәгенә өмет тудыра.

Сораулар һәм биремнәр

1. Г. Исхакый иҗаты XX йөз башы татар әдәбиятына нинди яңа сыйфат үзгәрешләре алып килде?

2. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрен автор нинди максат белән язган?

3. Ни өчен әсәрне хыялый-публицистик повесть дип атыйбыз? Язучының бу рәвештә уйлануларының сәбәпләре ниләрдән гыйбарәт?

4. Милләтебезнең бетүгә таба бару куркынычын Г. Исхакый нәрсәләрдә күрә?

5. Әсәрне бастырырга рөхсәт иткән цензор аның нинди эчтәлектәге урыннарын сызган дип уйланыла?

6. Җәгъфәр образы әсәрдә нинди урын тота? Бу образның повестька килеп керүенең әһәмиятен аңлатып бирегез.

7. Г. Исхакыйның бу әсәренә аның замандашлары нинди бәя биргәннәр?

8. Мөмкин булса, Татарстандагы Болгар шәһәре тыюлыгына сәяхәт ясагыз.

9. «Милләтебезгә Г. Исхакый әсәрендә сурәтләнгән куркыныч янамасын өчен, без ниләр эшләргә тиешбез?» дигән темага сөйләшү-бәхәс уздырыгыз.

---

[1] Әлеге шигырь күп еллар буена шушы ике юллыгыннан башка гына басылып килде. Шуннан соң беренче тапкыр тулысынча бирелде: Казан утлары.— 1990.— № 1.— 87 б.

«Теләнче кыз»

Романның үзәгендә Сәгадәт исемле кызның язмышы тора. Аның тормышы ике өлешкә бүленә: балалык елларын авылда үткәрсә, соңыннан язмыш аны шәһәргә илтеп адаштыра.

Ярлы гына Шәрип картның гаиләсендә шактый соңгарып туган балага (әтисе күп еллар патша армиясендә йөргән), аның киләчәген матур итеп күрергә теләп, Сәгадәт дип исем кушалар. Ягъни бәхет дигән сүз. Язучы аны бик нәфис, матур күңелле, нечкә хисле итеп сурәтли. Сабакта да үзен сәләтле, зиһенле, тырыш итеп күрсәтә. Мулла кызы белән дуслашып китүе Сәгадәтнең дини һәм милли гореф-гадәтләр белән азыклануын тагын да арттырып җибәрә. Иген уңмаган 1897 елга кадәр аның тормышы менә шулай дәвам итә. Бу елны Сәгадәткә уналты яшь тула. Бер көе генә яшәсәләр, кызны озакламый кияүгә дә бирерләр, һәм ул, гадәти татар хатын-кызларына хас булганча, йорт-җир карап, бала-чага үстереп, җай гына яшәп китәргә дә мөмкин иде.

Ләкин әтисе кытлык елда, гаиләсе каршы торуга карамастан, Казанга күчеп килә. Ачлык елны биредә җиңелрәк уздырырга ниятли. Ләкин киресе килеп чыга. Алтмыш яшәр кешегә яңа җирдә тормыш корып җибәрү җиңел эш түгел. Шәрип агай эшкә дә урнаша алмый, авылдан килгән барлыюклы унҗиде-унсигез сум акчасы да су урынына агып бетә. Нәтиҗәдә фатирдан да куып чыгаралар, йортсыз-җирсез кешеләр куна торган бер шыксыз казарма почмагына барып сыенырга мәҗбүр булалар. Җитмәсә тагы өлкән яшьтәге атаана, авыруга дучар булып, бер-бер артлы җан тәслим кылалар. Сәгадәт үзе дә үлемнән чак котылып кала.

Хәерчеләр казармасында һәммәсе дә — татарлар. Күбесенең кышкы салкынга чыгарлык киеме дә юк. Әмма бер-берсенә нинди игътибарлы, мәрхәмәтле алар. Шәрип бабай үлем белән тартышып ятканда, аның хәлен җиңеләйтү өчен, яхшы сүзләрен, ярдәмнәрен кызганмыйлар. Үлгәч исә, үз араларыннан сиксән тиен акча җыешалар, кәфенлек юнәтәләр, аны шәригать кануннарына туры китереп җирлиләр. Сәгадәт милләттәшләренең кешелеклелегенә, ярдәмчеллекләренә таң кала, аның күңелендә бу фәкыйрьләргә карата иң җылы, самими хисләр туа.

Ә өстен катлаулар, шул ук татар булсалар да, рәхимсезләр. Бай малае Габдулла Сәгадәтне мәсхәрә кыла. Фәкыйрьләрне

моның белән шаккатыра алмыйсың. Мондый эшне алар инде күп күргәннәр, аңа гадәти нәрсә дип карыйлар. Тормыш авырлыгы, үтә мохтаҗлык күңелләрен тупасландырган, язмышка буйсыну, аңа килешеп карау — алар өчен гадәти хәл булып әверелгән. Сәгадәткә, ачлыктан котылып калу өчен, тормышның иң түбән баскычына — фәхишәлеккә бирелүдән башка юл калмый.

Әсәр XX йөз башы татар әдәбиятындагы төрле иҗат юнәлешләре тәэсирендә язылган. Биредә тәнкыйди реализм билгеләре дә шактый ачык төсмерләнгән. Шул ук вакытта сентиментализмнан һәм мәгърифәтчелектән дә азат түгел. Байлыгына аркаланып, теләгән һәрнәрсәне эшләргә мөмкин дип исәпләүче, вөҗдансыз Габдулланың укымышлы егет Мансур Аллаяров тәэсирендә күңел газаплары кичерүе һәм үзе харап иткән Сәгадәтне фәхишәләр йортыннан хатынлыкка алуы моңа мисал була ала. Дөрес, бәхетне фәкать кесәдәге акча белән генә үлчәргә күнеккән Габдулла соңыннан тагын үз асылына кайта. Атасыннан ун миллион сумлык мирас белән калган Сембер бае кызы аның өчен кулайрак булып чыга. Бу инде — романда гәүдәләндерелгән вакыйгаларның кырыс реализмга таба борылышы. Гомумән, Г. Исхакый үзенең иҗатында әдәбият фәне кануннары белән хисаплашып тормый һәм дөрес эшли. Ул иҗат методлары мәсьәләсендә иркен эш итә. Әйтергә теләгәнен үтемле итеп җиткерү өчен, сәнгать чараларының кайсыларын үзе кирәк дип саный, ул, бернинди кагыйдәләргә карамыйча, аны иркенләп куллана. «Теләнче кыз» әсәренә килгәндә, автор Сәгадәт кебек тормыш читенә кысрыкланган татар кызларын бәхетле юлга чыгару турында уйлана. Сәгадәтнең, баткаклыкта пычранып калмыйча, Петербургка югары белем курсларына укырга китүе бик үк типик булмаса да, кешенең нинди хәлдә дә өметен югалтмаска, яктыга омтылырга тиешлеген раслау ягыннан бик әһәмиятле.

«Теләнче кыз» романы бер үк вакытта мәгърифәтчелек реализмы әсәре дибез икән, бу, барыннан да элек, Мансур Аллаяров образы белән бәйләнгән. Аның исем-фамилиясе дә бик мәгънәле сайлап алынган. Мансур — җиңүче, Аллаяр — Алла яры, ягъни Аллаһы Тәгаләне үзенә иң якын күрүче. Шуңа күрә бу образ бары тик уңай сыйфатларга гына ия. Егерме ике яшьлек бу болгар егете мәдрәсәдә, аннары рус мәктәбендә укыган, төрекчә, гарәпчә, фарсыча, русча укый-яза. Язучылык белән шөгыльләнә, бик тәүфыйклы. Фәкыйрь

мулла улы булу сәбәпле, тормышын сабак укыту белән алып бара. Габдулла өчен бәхет төшенчәсе байлык белән үлчәнсә, Мансур исә «хезмәт» белән «сәгадәт»не бер үк төшенчәләр дип исәпли, ягъни үзенең хезмәте кемнәргәдер файдалы икән, ул — аның өчен чын бәхет. «Бик күп китаплар укыганга, бик күп уйланганга, ул егерме ике яшендә булса да, аның фикерләре кырык яшенә җитеп килә иде». Ул — үтә уңай, үрнәк мәгърифәтче. Мансур образы күп яктан Г. Исхакыйның үзен хәтерләтә. (Гомумән, ул үз шәхесенең төсмерләрен әсәрләрендә еш файдалана.)

Исеменнән үк аңлашылганча, «Теләнче кыз» романы татар хатын-кызы язмышы мәсьәләсен көн кадагы итеп куя. Аның кешечә яшәү мөмкинлекләре җәмгыятьтәге сыйнфый мөнәсәбәтләр белән тыгыз бәйләнгән. Сәгадәт тә, Мансур да, Габдулла да, бер үк милләт балалары булсалар да, матди хәлләре буенча төрле-төрле катламнардан. Аларның холык-фигылен, күңел дөньясын, кылган гамәлләрен менә шул матди нигез катламнары билгели дә. Димәк, әдәби әсәрләрне, аларда сурәтләнгән кеше образларын бәяләүдә сыйнфыйлык ягы белән бөтенләй исәпләшмәү күп кенә күренешләрне аңлата алмауга китерер иде. Язучы һәм фикер иясе буларак, Г. Исхакый моны яхшы аңлап эш итә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Сәгадәт образын тудыруда автор нинди сәнгать чаралары куллана?

2. Дөньяда бәхетле булыр өчен туган Сәгадәт ни өчен бик кыен хәлдә кала?

3. Г. Исхакыйның өстен катлауларга мөнәсәбәте ничек?

4. Мансур образының роман сюжетында нинди әһәмияте бар?

5. Габдулла кем ул? Аның Сәгадәткә мөнәсәбәте ни өчен үзгәреп тора?

6. Татар халкының төрле сыйныфлардан торуын, аларга хас булган үзенчәлекләрне, каршылыкларны язучы ничек итеп күрсәтә?

7. Автор хатын-кыз язмышын нинди юллар белән җиңеләйтергә тели?

8. Романда сурәтләнгәннәр белән сез тулысынча килешәсезме? Үзегез өчен сезне ышандырып бетермәгән хәл-әхвәлләрне билгеләмәдегезме? Билгеләсәгез, аларны дәлилләгез.

9. Әсәрнең сюжетын оештыруда кайсы образлар аеруча әһәмиятле?

10. Әсәрне язганда, автор нинди иҗат методларыннан файдалана?

«Тормышмы бу?»

«Тормышмы бу?» әсәре төрле яклап кызыклы. (Ул, 1909 елда язылып, 1911 елда Казанда басылган.) Беренчедән, әсәрнең шәкеле (формасы) үзенчәлекле. Ул көндәлекләр рәвешендә язылган. Көндәлектә исә, билгеле булганча, бары тик үзең өчен аеруча әһәмиятле нәрсәләрне генә теркәп куясың. Менә шуңа күрә бу рәвешчә язу укучының бәян ителгәннәргә ышанычын арттыра. Әсәрне укуның җиңеллеге дә шуннан килә. Повесть Г. Исхакый каләменең сәнгатьчә алымнарга байый баруын күрсәтә.

Хикәяләүче, бик ачынып, «Тормышмы бу?» дигән сорау куя. Димәк, кемдер тормышыннан канәгать түгел. Автор аны икенче төрле «Бер шәкертнең хатирәләре» дип тә атый. Хатирәләр, 1895 елның 28 маенда башланып, 1908 елның 3 маенда тәмамлана, ягъни унөч ел вакытны иңли. Унөч ел үсмер кеше өчен бер гомернең зур өлеше, бу вакыт эчендә яшь кеше җисми яктан гына түгел, аң-хис җәһәтеннән дә зур үсеш юлы үтә. 1899 елның 18 сентябрендә язган хатирәләрендә шәкерт үзенә 23 яшь тулганын әйтә, димәк, ул 1876 елда туган. Хатирәләрне яза башлаганда, аңа инде 19 яшь булган дигән сүз. Бу яшьтә кешенең әйләнә-тирә, җәмгыять турында шактый ачык фикере, күңелендә туган төгәл тойгылары була. Әгәр хатирәләр язылып беткәндә аңа утыз ике яшь икәнен искә алсак, бу инде аның ир уртасы булып җиткәнлеген күрсәтә. Гомеренең яртысын диярлек узган ир кеше, үзенең яшәешеннән канәгать булмыйча, башкалар белән шул турыда ачыктан-ачык сөйләшергә карар иткән икән, бу инде юкка гына түгел. Димәк, әлеге уйлар аны озак борчыганнар, ахырда кәгазьгә түгелгәннәр.

Г. Исхакый татар тормышының «иң җәрәхәтле җирләрен ача», язучы буларак, максатын ачык итеп әйтә: «Үзем хәл кыла алмаган шул мәсьәләне, бәлки, укучыларым хәл кылыр, мин җавап таба алмаган сөальгә, бәлки, алар табар дип, шул «Тормышмы бу?»ны китап итеп бастырырга уйладым».

Гадәти кеше өчен шәкертнең тормышында бер дә алай җитешмәслек як күренми. Әтисе — авылда абруйлы мулла. Тормышлары әйбәт. Казандагы Күл буе мәдрәсәсеннән җәйге ялга кайткач та, әтисе белән аштан ашка йөреп көн уздыра. Киләчәктә мулла буласы үсмер егеткә хәтта авылдагы яшьтәшләре белән уйнарга, күңел ачарга, бергәләп эшләргә дә

ярамый, чөнки алар аңа тиң түгел дип исәпләнелә. Бөтен аралашканы әтисе-әнисе дә, мулла җизнәсе, ишан хәзрәт ишеләр генә. Шәкерт мондый хәл белән килешергә теләми, аның авыл кызлары белән танышасы килә. Ләкин әлегә кадәр кеше белән аралашмаган, әйтергә кирәк, моңа әллә ни омтылмаган егет-кызлар белән гади итеп сөйләшеп тә китә белми, киресенчә, аларның килеп сүз кушуларын көтеп йөри.

Гадәттә, үз-үзенә бикләнгән кеше хыялга бай була, гамәлдә булдыра алмаганын уе белән булса да фараз итәргә ярата. Эчми, тартмый, китап кушмаган гамәлләрне кылмый торган шәкерт хәтта үзенең мондый «көфер» уйларыннан да курка, намаздан соң тәүбә кыла. Ихтыярсызлык — шәкертнең төп бәласе. Нәрсәдер эшләргә булып та шуны тайпылышсыз тормышка ашыру өчен, үзен туплый алмый. Әнә күрше кызы Сәгыйдәгә хат язарга ниятли, яза да, ләкин бирә алмый интегә, чөнки иң курыкканы — кеше теленә керү, яман сүзнең ата-анасына килеп ирешүе. Әлбәттә, бу — яхшы сыйфат. Әмма яшьлеккә хас матур итеп сөю-сөешү, табигать баласына чит-ят булмаган башка гадәти гамәлләр билгеле бер тәртипләр кысасы эчендә генә буйсынып яшәргә күнеккән шәкерткә атлап чыга алмастай киртә булып тоелалар. Аның иң кызыкканы — бер-берләре белән аралашып яшәүче авыл яшьләре. Беркем гаеп итми. Шәкертнең дә бөтен омтылганы — табигый яшәргә тырышу. Әмма аның хәлендәге кешегә бу мөмкин түгел. Димәк, әсәрнең кызыксындыру көче — анда шәкертнең күңел каршылыгы сурәтләнүендә. Үзен чолгап алган тирәлек һәм шәкерт күңелендәге ризасызлык. Шул рәвештәге эчке конфликт — «Тормышмы бу?» повестеның төп үзенчәлеге.

Әлбәттә, хәл-әхвәленең болай булуына шәкерт үзе генә гаепле түгел. Г. Исхакый аны яшәү рәвешенең колы итеп сурәтли. Эчке конфликтның икенче катламы белем алу һәм киләчәктә нинди шөгыль белән мәшгуль булу мәсьәләләренә бәйләнгән. Шәкерт мәдрәсәдә укыган еллар — җәдитчеләр белән кадимчеләрнең үзара тартышкан, якалашкан вакыт. Төрле тарихи, фәнни китаплардан азыкланган, өстәмә рәвештә русча да укыган шәкерт, әлбәттә, җәдитчеләр ягында. Ә этисе — кадимчеләр тарафдары. Бу хәл ата белән бала арасындагы аңлашылмаучылыкны арттыруга бара.

Әгәр әтисе тормыштагы урыныннан бик канәгать булса, малайның исә, киресенчә, авылда мулла булып каласы

килми. Чөнки мәхәллә кешеләре аңардан дини китаптагы кануннардан читкә тайпылмауны таләп итәчәкләр. Аның гыйлемлелеге, укымышлылыгы дини карашлар белән генә чикләнергә комачаулаячак. Вәгазьләрендә иҗади эш итәчәк. Мәдрәсәдә дә җәдитчеләрчә укытачак. Әмма белеп тора: болай эшләргә аңа беркем дә мөмкинлек бирмәячәк. Бөртекләп җыйган гыйлеменең авылда беркемгә дә кирәге булмаячак. Менә ни өчен дин әһеле булуны ул үзе өчен мөмкин булмаган эш дип исәпли.

Шундый кешеләрне очратабыз: дөрес уйлый, күңеле белән әллә ниләр эшләргә әзер, иксез-чиксез хыяллар белән яши. Тик ул үзенең ниятләрен чынбарлык итү гамәленә керешә алмый. Безнең шәкерт тә шулар исәбендә. Ник дигәндә, ул — туганнан бирле аркылыны буйга алып салмаган, үзе икърар иткәнчә, «егерме өч яшенә кадәр салам селкетмәгән бер әрәмтамак». Аның тормышы шулкадәр кызыксыз, бертөрле, 1901 елның 24 июленнән алып 1902 елның 28 июленә кадәр, ягъни елдан артык хәтта көндәлеген дә кулга алмаган. Бермәлне, күңеле кузгалганда, ул үз-үзенә болай мөрәҗәгать итә: «Уян, күңел! Үзеңнең дөньяларны җиңә торган, тауларны тишә торган, диңгезләрне корыта торган, тарихларның көпчәкләрен теләгән тарафка әйләндерә торган көчеңне, гайрәтеңне сарыф кыл да мине шул куркыныч диңгездән коткар! Уян, күңел, уян!»

Ни генә әйтмәсен, үз-үзен ничек кенә битәрләмәсен, шәкертнең яшәү рәвешендә бернинди үзгәреш-фәлән булмаячак. Барысы да элеккечә калачак. Тора-бара ул үз тормышына бөтенләй җайлашачак. Күңелен «юк-бар» нәрсәләр белән бимазаламаячак. Башкага ул сәләтле түгел. «Тормышмы бу?» дигән сорауга тыныч кына: «Тормыш бу, шулай яшәү — иң кулае»,— дип җавап бирсә, укучы һич тә гаҗәпләнмәячәк.

Г. Исхакый бу әсәре белән әнә шундый гамьсезлеккә, битарафлыкка, йокымсырауга каршы чыга. Бу яктан ул «Инкыйраз» әсәре белән нык аваздаш. Әсәрдән килеп чыккан мәгънә шул: шәхси язмышына шул дәрәҗәдә битараф булган кеше милләтнең бүгенгесе, бигрәк тә киләчәге турында кайгыртуны үз җилкәсенә күтәрә алмый.

Язучы 1910 елда «Мулла бабай» романын яза башлый, аның өч кисәген бастыра да. Әсәр үзенең юнәлеше буенча «Тормышмы бу?» романын хәтерләтә. Әлбәттә, ул тагын да киңрәк, тормыш күренешләренә, хис-кичерешләргә, җәмгы-

ятьне бәяләүләргә баерак булырга тиеш була. Төп герой монда инде исемле — Хәлим. Ул, алга таба мулла бабай, ягъни өлкән яшьтәге кеше булганчы, шактый дәвамлы вакыт эчендә сурәтләнергә тиеш дип уйланыла. Әмма укучы аның белән әле яшь чагында ук хушлаша. Әсәр язылып бетмәгән. Моннан күренгәнчә, бу тема Г. Исхакыйны нык дулкынландырган булса кирәк.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Тормышмы бу?» повесте Г. Исхакыйның башка әсәрләреннән кайсы ягы белән аерыла?

2. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повесте белән бу әсәр арасында уртаклык табып буламы?

3. Шәкерт образының күңел дөньясы сезнең өчен кайсы яклары белән кызыклы?

4. Шәкерт ни өчен мулла булырга теләми?

5. Әлеге шәкерт белән авторның үз башыннан кичергәннәр арасында нинди уртаклыклар табарга була?

6. Язучы шәкерт авызыннан «Уян, күңел, уян!» дигән чакыру ташлый. Бу өндәү аның үзенә генә юнәлгәнме?

7. Г. Исхакыйның «Мулла бабай» әсәрен укыгыз.

«Сөннәтче бабай»

Әлеге озын хикәя татар әдәбиятына һәм темасы, һәм сурәтләнгән образы белән яңалык алып килде. Язучы үз героен бик яратып, җиңелчә юмор белән, шул ук вакытта фаҗигале язмышлы итеп сурәтли.

Мөселманнарда ир баланы сөннәткә утырту йоласы — хуплана торган гамәл. Ир баланың сөннәтсез үсүе гадәттән тыш хәл булып исәпләнгән, аны «ул сөннәтсез» дип мыскыллый торган булганнар. Сөннәт — мөселманлык билгеләренең берсе, шул ук вакытта ул пакьлек, чисталык өчен дә бик әһәмиятле. Аллаһы Тәгалә кушуы буенча, иң беренче булып Ибраһим пәйгамбәр үз улы Исмәгыйльне сөннәткә утырткан. Шуннан соң бу гадәт таралып киткән һәм мөселманнар дөньясында шулай булырга тиешле йола булып әверелгән.

Сөннәт — гарәп сүзе, гадәт, йола дигән мәгънәне белдерә. Аның тагын бер мәгънәсе бар, сөннәт дип пәйгамбәребез Мөхәммәт саллалаһи галәйһиссәлам әйткән сүзләрне дә атап йөртәләр. Сөннәтләү дә — пәйгамбәребез кушкан эш. Менә

ни өчен әсәрдә сөннәтләү белән шөгыльләнүче Корбанколый абзый үз кәсебен җир йөзендәге иң кирәкле, изге, бары тик кешеләргә яхшылык кына китерә торган гамәл дип исәпли.

Тасвирлаудан күренгәнчә, бу эшне теләсә кем башкармаган. Корбанколыйга да ул унбиш буын ата-бабаларыннан калган. Гасырлар түреннән килә торган әлеге нәсел-ыруның башында ниндидер серле Сәлман Фарси булса, хәзер исә әлеге изге юлда — Корбанколый. Ләкин бу затлы нәсел Корбанколыйда өзелеп кала, ник дигәндә, аның бердәнбер улы патша хезмәтендә үлгән. Ягъни Сөннәтче бабайның вафаты гади генә түгел, ул — буыннар бәйләнешенең өзелеп юкка чыгуы дигән сүз. Инкыйраз темасы биредә дә дәвам иттерелә.

Билгеле ки, теләсә кем сөннәтче була алмый. Аның күңеле пакь, яшәү рәвеше саф, тәне һәрвакыт ару-таза булырга тиеш. Кешеләр бары тик изге җанлы затларга гына үз балаларының язмышын ышанып тапшыралар.

Хикәядәге Сөннәтче бабай әйтерсең лә шушы кәсеп өчен генә туган. Ул — аның гомер итү максаты, көн итү ысулы. Карчыгы Гөлйөзем әби дә картына сөннәтче вазифасын уңышлы башкарсын өчен генә яши кебек. Берсе өйнең тышында, икенчесе эчендә үз эшләрен шулкадәр пөхтә һәм төгәл алып баралар, аларны һич арттырмыйча изге кешеләр итеп күз алдына китерәсең. Бу эшкә үзләрен тышкы яктан гына түгел, эчтән дә әзерлиләр. «Шул көн якынлашуы сизелә башлагач та, Гөлйөзем әби керләр чайкый, өенең идәннәрен юа, самавырны тагы көзге кебек иттереп ачып куя, шул көнгә дип җәйли җыйган каймагыннан гөбе яза иде[1] ». Менә шундый ихласлы кеше тарафыннан бала тәненә ясалган яра ничек итеп тиз төзәлмәсен дә, ничек итеп аның сәламәтлегенә зыян килсен, ди?

Сөннәтче бабайның авылда, тирә-якта абруе зур. Ләкин ул үзенең урынын яхшы белә. Авыл хәзрәтеннән узып берни дә эшләми. Башта аның фатихасын, рөхсәтен, изге догасын ала, аннан соң гына, намазын укып, үзен чакырган ир балалы өйләргә китә.

Укучы күрә: Сөннәтче бабай йортындагы тормыш иң югары дәрәҗәдәге ислам дине кануннары, әхлагы белән сугарылган. Әсәрне укыганда, үзеңнең дә күңелең чистарганын, Аллаһы Тәгалә кушканча яшәргә омтылганыңны сизми дә каласың.

[1] *Гөбе яза иде* — май яза иде, май төшерә иде.

Халкыбызда «Ирне ир иткән дә хатын, җир иткән дә хатын» дигән мәкаль бар. Ул — зур тормыш тәҗрибәсенә нигезләнеп әйтелгән борынгылар сүзе. Әлеге әсәрдә моның шулай икәнлеге аеруча көчле раслана. Гомер иткән карчыгы Гөлйөзем әби белән торганда, бабайның өе һәрвакыт чиста-пөхтә, өсте-башы бөтен, аш-суы тәмле, туклыклы, тәнгә сихәт бирә. Бабай сыйда-хөрмәттә, кадердә яши. Әмма көннәрдән бер көнне әби авырып китә һәм бик тиз арада гүр иясе була. Менә шуннан соң бабай өчен газаплы көннәр башлана. Өйдәге һәрнәрсә гомер иткән карчыгын хәтерләтә, тормышының көе китә, ялгыз яшәүнең ачысы йөрәгенә төшә. Шуңа күрә, бераз вакыт үткәч, бабай икенче бер хатынга өйләнми булдыра алмый. Менә шунда ул хатын белән хатын арасындагы искиткеч аерманы күрә.

Бу икенче хатын шулкадәр таркау, эш рәтен белмәүче, шапшак булып чыга, пешергән аш-суын җирәнмичә авызга ала торган түгел. Озак та үтми, ялт итеп торган идәннәр пычракка бата, өйдән ниндидер авыр ис килә башлый. Бабай бу хәлгә бик борчыла, ләкин һаман да хатынына каты бәрелергә теләми, тора-бара яхшырмасмы дип өметләнә. Өйдән бизә барса да, сабыр итәргә тырыша. Әмма һәрнәрсәнең бер чиге була. Менә беркөнне кайтып керсә, ни күрсен: бу яңа хатын дигәнебез шүрлектәге затлы тартмада гына кадерләп саклана торган сөннәт пәкесе белән (...) бәрәңге әрчеп утыра!!! Бу хәл аңа шулкадәр начар тәэсир итә ки, Сөннәтче бабай авыруга сабыша, үлем түшәгенә егыла һәм ике көннән җан тәслим кыла. Димәк, ул бу дөньяда бары тик Сөннәтче буларак кына яши алган. Затсыз хатын тарафыннан пычратылган пәке инде бу эшкә ярамый, ни генә эшләтсәң дә, аны сафландырырга мөмкин түгел, дип исәпли ул. Шушы изге гамәле юкка чыккач, үзе дә яши алмый. Дөресрәге, аңа инде яшәүнең мәгънәсе калмый. Аңа дөньядагы бөтен затлылык беренче карчыгы белән җир астына киткәндер кебек тоела. Күңеленнән яраткан карчыгының рухы белән ахирәттә очрашачагын сизеп йөри. Шуңа күрә, хәзрәттән рөхсәт алып, карчыгының гәүдәсе күмелгән урын янәшәсендә үзенә кабер дә әзерләп куя. «Үзе казыган кабергә иртәгесен бөтен авыл җыелып күмде. Күрше карты аның өстенә дә каен утыртты. Ике каен, (карчыгы кабере өстендәгесен Сөннәтче бабай үзе утырткан), бер-берсе берлән бәрелә-бәрелә, сөйләшә-сөйләшә үсә башладылар... Бер тормыш бетте, бер тормыш башланды...»

Күргәнебезчә, Г. Исхакый бу әсәрдә, кайсы яктан гына алып карасаң да, татар әдәбиятына яңалык алып килә. Иң зур яңалык шунда: ул әле аңа кадәр беркем дә сурәтләмәгән сөннәтчелек һөнәре белән шөгыльләнүче кеше образын тудыра. Бу кәсепне үзенә гомерлек юлдаш итеп алган кешенең билгеле бер үрнәге булдырыла. Укучыда татар халкының гореф-гадәтләренә, яшәү рәвешенә хөрмәт уята. Мондый әсәрләрнең җитмеш ел буена халыктан яшерелеп тотылуы, һичшиксез, безнең әхлакый-милли тәрбиябезгә зур зыян китерде.

Сораулар һәм биремнәр

1. Сөннәтче бабай образын тудырып, язучы татар әдәбиятында нинди яңа сүз әйтте?

2. Язучы Сөннәтче бабайның күңел дөньясын ничек итеп тасвирлый? Тормышның үзендә, әдәбият-сәнгать әсәрләрендә аңа охшаш затларны һәм образларны очратканыгыз бармы? Бу образ кайсы яктан әһәмиятле?

3. Аллаһы Тәгалә кушканча яшәүне сез ничек аңлыйсыз?

4. Сөннәтче бабайның ике хатынын бер-берсе белән чагыштырып тасвирлагыз, аларга бәя бирегез. Ир-атның һәм хатын-кызның гаиләдәге урыны турында бәхәс-сөйләшү уздырыгыз.

Сәхнә теле белән

Гаяз Исхакый беренче чиратта язучымы, әллә җәмәгать эшлеклесеме? Бу сорауга кистереп җавап бирү кыен. Ләкин әдиплеген халык бәхете өчен көрәшендә үткен корал итеп кулланганын һич шикләнми әйтергә мөмкин. Моны аның драма әсәрләрендә дә яхшы күрергә була. Театр сәнгате кебек гаять тәэсирле мөнбәр ярдәмендә олы язучыбыз тамашачыларны үзе борчылган мәсьәләләр хакында уйландырырга, борчылдырырга тели. Шулай бергәләп гамьләнгән чакта гына кыен хәлебездән чыгуның отышлы ысулларын табу, иң мөһиме: шушы олы юлга бергәләшеп чыгарга әзер торучы тарафдарларны ишәйтү мөмкин булачак. Г. Исхакый, сәхнә әсәрләрендә төрле мәсьәләләр күтәргән кебек, бер үк жанрда гына язуга да ябышып ятмый. Әсәрләре арасында без драманы, комедияне, хәтта трагедияне дә күрәбез. Чөнки аларның һәммәсе чынбарлыгыбызда бар, аларны күрмәмешкә салышу

ихлас хәлебезгә хилафлык итүдән бүтән нәрсә булмас иде. Драматург яшәешебезне булганынча күрсәтеп бирә, аның өчен дөреслек — иң изге һәм беренчел нәрсә. Дөреслек дигәндә, тарихи чынбарлыкка тугрылык, хис-кичерешләр, гореф-гадәтләр, күңел дөньясы үзенчәлекләренең хилафлык ителмичә гәүдәләнүе күздә тотыла.

Кеше әйләнә-тирәгә үзе теләгәнчә йогынты ясарга омтылганы кебек, мохит тә аңа тәэсирсез калмый. Бу сүзләрнең дөреслегенә кем шикләнер икән?! Г. Исхакый «Мөгаллим» драмасында (1906—1907) шушы фикерне раслый. Казан мәдрәсәсен тәмамлаган Салих авылга укытырга килә. Яңа ысуллар кулланып, балаларны тиз вакыт эчендә укырга-язарга өйрәтә. Шәкертләрне аңлы-белемле итүне иң изге бурычы санап, шушы эшенә комачаулык итәргә ихтималы булган барлык нәрсәләрдән читләшергә тели. Кыз балалар өчен дә мәдрәсә ачарга хыяллана. Әмма авыл кызына өйләнеп, үзаллы тормыш корып җибәрүе була, әкрен-әкрен хуҗалык эшләре, юк-бар нәрсәләр белән мавыгып китүен сизми дә кала. Канатлы хыялларыннан мәхрүм булып баручы бер гадәти хәлфәгә әверелә. Газеталардагы яңалыкларга да күңеле саңгыраулана. Бары тик мәдрәсә иптәше Фазыл тәэсирендә генә йокымсыраган хәленнән арына, бу халәтеннән котылу өчен, авылны ташлап ук китә. Ләкин шунысы да бар: үз-үзеңнән качып булмый ул. Ягъни мохит тәэсиренә бирелү җиңел, аңа каршылык күрсәтү өчен ихтыяр көче кирәк. Салихта ул җитәрлек түгел. Автор андыйларны шуның өчен тәнкыйтьли дә.

«Мөгаллимә» драмасында да (1913) Г. Исхакый каләменә хас булган халыкка хезмәт итү, аны агарту эшләрен җайга салу, театр сәнгатен үстерү мәсьәләләре дәвам иттерелә. Автор биредә яшьләрнең мәхәббәт хисләренә бәйләнешле күңел дөньяларын сурәтләүне үзәккә куя. Шул нигездә гаять кызыклы образлар иҗат итә. Г. Гыйсмәти, Ш. Әхмәдиев, Г. Кәрам, Җ. Вәлидиләр әсәргә уңай бәя бирсәләр, Г. Ибраһимов исә аңа карата тәнкыйть рухында чыгыш ясый. Шунысы әһәмиятле: драма үз заманының фикер ияләрен битараф калдырмый.

Г. Исхакый мәхәббәт темасына элегрәк тә мөрәҗәгать иткән иде. «Алдым-бирдем» драмасы (1907) — шундый әсәрләрдән. (Әсәрдә комедиячел күренешләр дә байтак.) Автор яшьләр өчен мәхәббәткә нигезләнеп гаилә коруга мөмкин-

текләр булмау кебек хәлгә игътибар юнәлтә. Бу сюжетның шушы рәвешле оешуында Галия образының үзенчәлеге хәлиткеч әһәмияткә ия. Чөнки ул Ибраһим белән мәхәббәттә аңлашуда, уртак бәхетләре өчен көрәшүдә беренче адымнарны ясый. Аның кыю эш итүе салмаграк холыклы Ибраһимны да хәрәкәткә китерә. Мәхәббәт кебек изге хис канатларында бер-беренә омтылган яшьләрне берни дә туктата алмый. Аларга каршы булган көчләр ахыр чиктә чынбарлык белән килешергә мәҗбүр булалар.

Шуны ук «Тартышу» (1907—1908) драмасындагы Закир һәм аның иптәшләре хакында да әйтергә мөмкин. Ләкин биредә инде сүз иҗтимагый мөнәсәбәтләрдәге камиллекне тәэмин итүгә нигезләнгән көрәш турында бара. Җәмгыятьтәге искелеккә ябышып ятучы, яңалык җилләре алдында койма булып күтәрелергә әзер торучы көчләр яшьләрнең куәтен, белемгә, азатлыкка булган дәртләрен сындыра алмыйлар. Дөрес, тартышу яшьләрдән корбаннар да ала, әмма бу аларның ташкындай алга баруларына комачау тудыра алмый. Алар бернәрсәне ачык аңлыйлар: бердәм булып тартышканда гына, уңышка ирешергә мөмкин. Яшьләрнең хәлиткеч адымнарга барырга әзер торуын С. Рәмиев тарафыннан язылган менә бу шигъри юлларның яңгыравы ачык күрсәтеп тора:

Кирәкми, ташлыймыз иске юлны,
Кирәкми, яңа юл башлыймыз.
Яңа юл — яхшы юл, бер җәберсез
Тигез, рәхәт тора башлыймыз.

Әсәрнең бары тик 1917 елдан соң гына басыла алуы анда күтәрелгән иҗтимагый мәсьәләләрнең үткенлеге турында сөйли. Хәер, халыкның өметләре аннан соң да акланмады. Тик XX гасырның сиксәненче еллары ахырында гына милли мәнфәгатьләрне кайгырту мөмкинлеге туа башлады.

«Җәмгыять» (1909) һәм «Кыямәт» (1909) комедияләре икесе дә татар халкының аерым катлауларындагы наданлык, тискәрелек кебек җәмгыятьнең алга үсешен тоткарлый торган яклардан ачы итеп көлү максаты белән язылган. Г. Исхакый милләтебезнең мондый хәлләрдән тизлек белән чистарынуын теләгән.

Җәберләнгән Зөләйха фаҗигасе

Бездә халкыбызның авыр үткәненә бәйле рәвештә моңзар, кайгы-сагыш белән өретелгән җыр, бәет, мөнәҗәт кебек халык авыз иҗаты һәм әдәби әсәрләр бик күп. Г. Тукайның:

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән.
Милли хисләр белән ялкынланып,
Сызлып-сызлып чыга күңленнән,—

дию үзе генә дә ни тора! Бу шигъри юлларны Г. Исхакыйның «Зөләйха» драмасына (дөресрәге, фаҗигасенә!) эпиграф итеп куярга мөмкин булыр иде. Әсәрне башта автор «Җәберләнгән Зөләйха» дип атарга да уйлый.

1552 елда Казан ханлыгы Мәскәү тарафыннан басып алынганнан соң, Россия дәүләте татарларны мәсхәрәләүнең бик күп төрле явыз ысулларын куллана. Көчләп чукындыру — шуның иң мәрхәмәтсезе. Татарның рухи дөньясы, яшәү рәвеше русныкыннан бөтенләй аерыла. Шуңа күрә руслашу мөселман кешесе өчен, бу очракта татарларга,— бөтенләй мөмкин булмаган эш. Борын-борыннан мәдәниятле, белемле, шәригать йолалары буенча яшәү канына сеңгән халкыбыз мондый кешелексезлеккә нык каршы тора.

Көчләп чукындырылган, моның белән килешмәгәне өчен, тугыз ай монастырьда ябып яткырылган, иреннән, газиз балаларыннан аерып, ирексездән рус мужигына хатын ителгән, ләкин рухы белән татар хатыны булып калган, кяфер ирен үтереп, унсигез ел каторгада интеккән Зөләйханың язмышы ул — дөресендә татар халкы кичергәннәрнең бер тамчысы, бер кисәге. Руслар алдында шулкадәр нинди гаебе булган соң Зөләйханың? «Мине хак диннән чыгарырга теләделәр, көчләп алып, ирем бар өстеннән руска иргә бирделәр. Көчләп чукындырдылар. Көчләп ата-анамнан, бала-чагамнан аердылар. Мин, әлхәмделилла, барысына да чыдадым, барысына да! Мин ислам өчен... зәхмәт чиктем». Зөләйханың бу сүзләрендә конфликтның тулы эчтәлеге яңгырый.

Г. Исхакый бу хәл-әхвәлләрне язучылык хыялы белән генә тудырмаган. Ул мондый золымлыкларны тормышта үзе бик күпләп күргән. Вакыйгаларның XIX гасырның алтмышынчы елларда баруы турында автор искәрмәсенең әһәмияте зур. Урта гасырлардан ераклаша барганда да патша хакимиятенең

азчылык милләтләргә (татарлар алай бик аз да түгел бит әле) мөнәсәбәте элеккечә калган.

Тыныч кына яшәп яткан Гыймади карт гаиләсенә афәт килә. Аларны үз теләкләреннән башка чукындыралар. Картның үзенә — Василий, Зөләйхага — Марфа, аның ире Сәлимҗанга Митрофан дип ят исемнәр кушалар. Шулай иткәч, янәсе, алар рус була. Ләкин әсәрдәге дөнья күргән бер рус карты образы авызыннан әйтелгәнчә: «Көчләп урыс итеп булмый, көчләп татар итеп булмый. Болар бар да — юк эш». Руслар арасында да дөрес уйлаучылар булган, Г. Исхакый бу яктан гадел эш итә. Ләкин христиан фанатиклары мондый акыллы сүзләргә колак салмаганнар шул.

Әсәрдә конфликтның иң югары ноктасы — Зөләйханың рус өендә берьюлы ике ире: татар Сәлимҗан, рус Пётр белән очрашуы. Беренчесе бу хатын өчен газиз ир булса, икенчесе — чит-ят кавем кешесе, аны җәберләүче залим. Шушы күренештә Сәлимҗан руслар тарафыннан кыйнап үтерелә, Зөләйха үзенә дип әзерләнгән агулы суны, һич вөҗдан газабы кичермичә, Пётрга бирә. Үзен җәзалаучының үлеме аңа җиңеллек китерә. Ул моның өчен теләсә нинди мәхшәрләрне кичәргә әзер. Чөнки христиан чолганышындагы «ирекне» ул төрмә шартларыннан да авыррак дип саный. «Иректә күргән начарлыкны төрмәдә күрмәдем. Кыйналдым, мыскыл ителдем, суктырылдым. Ләкин мондагы кебек күңелемә каравыл куймадылар. Теләгәнчә намазымны укыдым. Теләгәнчә рузамны тоттым. Катышкан кеше булмады».

Без Зөләйханың ныклыгына, горур булуына, туган халкын шулай югары дәрәҗәдә сөюенә сокланмый кала алмыйбыз. Аның өчен кешеләр бары тик икегә бүленәләр: диненә, милләтенә хөрмәт белән, тигез итеп караучы — дус, кешенең иң изге хисләре белән исәпләшмәүчеләр — дошман. Бу мәсьәләдә ул үзе тудырган балага да ташлама ясамый. Улын, Зөләйха төрмәдә вакытта, поплыкка әзерләгәннәр, шул сәбәпле ул әнисенең рухыннан бик ерак тайпылган. Моны белгәч, ана Әхмәт-Захарны бала итеп танымый. Улы аңа бары тик мөселман рухлы булганда гына кадерле. Әнисе үләр алдыннан, Захарның ислам диненә кайтуы олы гаделлек булып кабул ителә, соңгы сулышларын алучы анага бу иң зур шатлык булып әверелә. «Балаларым,— ди ул,— үләм, менә сезне күреп, шатланып үләм. Мин үләрмен... Мөселман каберенә күмеләсем, анда бабаларыңыз, әбиләреңез белән бергә буласым

килә. Мине мөселман каберенә күмегез. Әхмәт! Сиңа васыятем! Мине урыс каберенә күмдермә!»

Бу кадәр җәфалар күргән Зөләйханың мәңгелек дөньяда оҗмахка керәчәге шиксез. Г. Исхакый Зөләйха язмышының бу ягын да күрсәтергә онытмаган. «Күк күкрәгән кебек була, караңгыланып китә. Пауза. Бердән яктыра. Зөләйха гөлләр белән тулган, әллә никадәр хатын-кыз, ирләр, фәрештәләр көтә торган оҗмахның уртасында күренә».

Ләкин кеше бу фани дөньяда ирекле, үзе теләгәнчә, рухына тугрылыклы булып, намуслы, шәфкатьле халәттә яшәргә тиеш. Кемнең дә булса берәүнең икенче кешене, бер халыкның бүтән милләтне үз ихтыярына буйсындырырга, аны ирексезләргә хакы юк. Кояш астында кешеләрчә яшәү өчен, мөмкинлекләр һәркемгә бертигез бирелгән.

1907 елда Чистай төрмәсендә языла башлап 1911—1912 елларда Истанбулда, аннан Петербургта тәмамланган «Зөләйха» әсәре авторның замандашлары тарафыннан югары бәяләнде. «Сәйяр» труппасы аны 1917 елның 17 мартында (иске стиль белән) сәхнәгә куя. Зөләйха образын Гөлсем Болгарская, Гыймадины Габдулла Кариев уйный. Фатих Әмирхан бу уңайдан болай дип язып чыга: «Зөләйха» — талантлы каләм, хәссас[1] рух белән язылган, урыны-урыны белән гаять тирән рухани фаҗигане караучының алдына китерә торган пьесадыр. Бу иске хөкүмәткә каршы гаять куәтле бер обвинительный акт[2] булуы белән бергә, милләтемезнең үз кодсияте[3] юлында һичбер төрле фидаилектән[4] кире тормас дәрәҗәдә куәтле малик фәрдләре[5] барлыгын күрсәтә вә бөтенлегемезне саклауда исламның нинди шәрифле[6] бер роль уйнаганлыгын исбат итә торган бер васикадыр[7]». Язучы, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе Шәһит Әхмәдиев исә «Шундый пьесаларны сәхнәдә күрерлек хөррият дөньясына ирештек микәнни?» дигән сорауны куюы белән җәмгыятьтәге яңа шартларга куануын белдерә. Шул ук елның март ахырында Казанга Г. Исхакый кайта. Аның хөрмәтенә Казан зыялылары мәҗлес үткәрәләр.

---

[1] *Хәссас* — сизгер.

[2] *Обвинительный акт* — гаепләүче документ.

[3] *Кодсияте* — изгелеге.

[4] *Фидаилектән* — корбан ителүдән.

[5] *Малик фәрдләре* — ия кешеләре.

[6] *Шәрифле* — хөрмәтле, затлы.

[7] *Васикадыр* — документтыр, әһәмиятле кәгазьдер.

Анда Ф. Әмирхан рәислек итә. Шуннан соң озак та үтми Г. Кариев җитәкчелегендә Г. Исхакыйның «Тартышу» әсәре дә сәхнәгә куела.

«Зөләйха» драмасы коммунистик идеология хакимлек иткән чорда халыкка тәкъдим итәргә куркыныч әсәр буларак бәяләнде. Ул бары тик 1993 елның башында гына сәхнәгә күтәрелә алды. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Празат Исәнбәт режиссёрлыгында куелган спектакль зур вакыйга буларак кабул ителде. Талантлы артистлар тудырган образларның тормышчанлыгы тамашачыларның күңелен кузгатты, хисләрен ташытты.

Сораулар һәм биремнәр

1. Гаяз Исхакый драма төренең нинди жанрларына мөрәҗәгать итә? Ни өчен сәхнә әсәрләре иҗат итүгә ул аеруча әһәмият бирә?

2. «Мөгаллим» драмасындагы Салих образының уңай һәм тискәре сыйфатларын күрсәтегез. Әсәрнең финалыннан сез канәгатьме?

3. Галия белән Ибраһимның («Алдым-бирдем» драмасы) үз бәхетләре өчен көрәштә кулланган ысуллары сездә нинди фикерләр уятты? Бу образларга мөнәсәбәтегез нинди?

4. «Тартышу» драмасында Закир әти-әнисе белән каршылыкка кереп дөрес эшлиме? Хәлнең болай килеп чыгуына, сезнеңчә, кем гаепле?

5. «Зөләйха» фаҗигасе нинди вакыйгага нигезләнеп язылган?

6. Гыймади карт гаиләсенең язмышын тәфсилләп сөйләп чыгыгыз.

7. «Зөләйха фаҗигасе — татар халкы кичергән фаҗига» дигән фикерне киңәйтеп аңлатып бирегез.

8. Зөләйха ни өчен төрмәдәге хәлен, көчләп, рус мужигы хатыны булып торуыннан өстенрәк күрә?

9. 1917 елга кадәрге чорда Россиядә татарларга карата алып барылган христианлаштыру сәясәтен сез ничек бәялисез?

10. «Теләсә кайсы милләт башкаларыннан зур да, кечкенә дә була алмый, һәммәсе тигез хокуклы» дигән фикерне, әлеге әсәрдән чыгып, киңәйтеп аңлатыгыз.

11. «Күпме михнәт чикте безнең халык» дигән темага инша языгыз.

12. Күренекле шәхесләрнең бу әсәргә биргән бәяләрен искә төшерегез.

13. «Зөләйха» әсәренең сәхнә тарихы турында сөйләгез.

Фатих Әмирхан
(1886—1926)

Татар әдәбиятының мактанычы һәм горурлыгы булган Г. Тукай, Г. Исхакый, Г. Камал, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ш. Камал кебек каләм ияләре арасында Фатих Әмирхан лаеклы урын тота. Ул талантлы прозаик һәм драматург, үткен телле сатирик һәм юмор остасы, нечкә зәвыклы әдәби тәнкыйтьче һәм ялкынлы публицист булып танылды.

Әдәбиятка юл

Фатих Әмирхан Тукай белән бер елда, ягъни 1886 елның 13 гыйнварында Казанның Яңа Бистәсендә Зариф мулла гаиләсендә дөньяга килгән. Фатихның әтисе яңарак карашлы муллалардан саналган. Анасы да йомшак күңелле аңлы хатын булган. Шуңа да Фатих сабый чагыннан ук руханилар тормышына хас күп кенә гореф-гадәтләрне, дини карашларны зиһененә сеңдереп үскән. «Минем тәрҗемәи хәлем» исемле язмасында бу турыда үзе дә әйтә: «Мин мулла баласы булганга, бик кечкенәдән үк муллалык дәрәҗәсенең, пәйгамбәр вә сәхабәлектән кала, иң зур дәрәҗә икәнен бик яхшы төшенә идем».

Җиде яше дә тулмаган Фатих мәхәллә мәдрәсәсендә укый башлый. Ул дин сабакларын бик тырышып өйрәнә. Сәләте, зирәклеге һәм тырышлыгы аркасында укуда һәрвакыт беренче булып бара.

1895 елда Фатихны Казанның иң зур һәм алдынгы мәдрәсәсе саналган «Мөхәммәдия»гә бирәләр. Монда да ул мәдрәсә гыйлемнәрен бик тырышып үзләштерә.

XIX гасырның икенче яртысында киң колач алган ояну хәрәкәте, яңа фикер, яңа карашлар «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә дә үтеп керә. Күзе ачылган олырак шәкертләр һәм алдынгы фикерле кайбер хәлфәләр йогынтысында яшүсмер Фатих та, мәдрәсә программасы белән генә чикләнмичә, татар телендәге китапларны һәм Көнчыгыш әдәбиятын укырга керешә.

XX гасыр башында татар дөньясындагы җәдитчелек хәрәкәте мәдрәсәләрдә дә торган саен көчәя бара. Дини-схоластик дәресләрдән канәгатьсезлек артканнан-арта. Шәкертләр төрле кичәләр үткәрә башлыйлар, әдәби түгәрәкләр оештыралар, кулъязма газета һәм журналлар чыгару эшенә керешәләр.Фатих әнә шул эшләрнең үзәгендә була. Соңрак исә ул дөнья өчен кирәкле фәннәр кертүне, яңача укытуны таләп итеп чыккан бөтен Россия татар шәкертләре хәрәкәтенең башында тора.

Шулай итеп, Фатих, шәкерт чагында ук, үзен милләткә, халыкка хезмәт итү эшенә багышларга карар итә. Моның өчен, билгеле, мәдрәсәдә алган белем генә җитәрлек булмый. Шуңа күрә ул, үзе әйтмешли, «яңадан укырга тотына». Мәдрәсәдә чакта ук хосусый укытучыга йөреп, рус телен өйрәнергә керешкән Фатих, 1904 елда Самара шәһәренә барып, дүрт ай буе русча укый. Аннары аерым укытучылар ярдәмендә гимназия программасы буенча имтиханга әзерләнә башлый.

Милләткә һәм халыкка, әлбәттә, төрле юллар белән хезмәт итәргә мөмкин. Ф. Әмирхан, мәгълүм булганча, язучылык эшен сайлый, кулына каләм ала. «Мөхәммәдия»дәге әдәби кичәләр, түгәрәкләр, кулъязма газета һәм журналлар, аерым өйләрдә куелган спектакльләрдә рольләр башкару, Көнчыгыш әдәбиятын өйрәнү, XIX гасыр татар мәгърифәтче язучыларының әсәрләрен уку, рус классик язучылары иҗаты белән таныша башлау — әнә шулар барысы бергә Ф. Әмирханны әдәбиятка китерә.

Журналист һәм публицист

Ф. Әмирханның журналистикага мөрәҗәгать итүе шәкертлек елларында ук башлана. 1905 елда «Мөхәммәдия»нең алдынгы шәкертләре яшертен рәвештә җилем басмада[1] «Әлислах» газетасын чыгара башлыйлар. Ф. Әмирхан — аның җитәкчесе һәм мөхәррире. 1906 елда исә аның журналист-

[1] *Җилем басма* — язма яки басма текстның күп санлы копиясен алу җайланмасы.

лык һәм публицистлык эшчәнлеге ныклап торып колач ала. 1906 елда Тукай катнашлыгында чыгарылган «Әлгасрелҗәдит» журналында аның «Париж коммунасы тарихы» исемле тәрҗемә мәкаләсе басыла. 1907 елда Ф. Әмирхан Мәскәүдә чыга башлаган «Тәрбиятел-этфаль»[1] дигән балалар журналында сәркатип булып эшли. Журнал битләрендә аның тәрҗемә итеп яисә ияреп язылган мәкаләләре күренә башлый.

1907 елның язында Әмирхан, ял итәргә дип, Мәскәүдән Казанга кайта. Ләкин монда ул коточкыч бәхетсезлеккә дучар була. Егерме икегә дә җитмәгән егетне паралич суга. Озак вакытлар дәвалануның да нәтиҗәсе булмый: моннан соң ул йөри алмаслык хәлдә кала. Әмма халыкка хезмәт итү идеалы белән янган егетнең рухын бу бәхетсезлек сындыра алмый. Замандашларының әйтүенә караганда, Ф. Әмирхан зарлану дигән нәрсәне белмәгән. Шат күңелле, үткен телле булган. Кешеләрне үзенә магниттай тарткан. Караваг һәм коляскага бәйләнеп яшәргә дучар булган әдипнең үлемсез әсәрләр иҗат итүен батырлык үрнәге дип карарга кирәк.

Шәкертләр хакын яклауны үзенә бурыч итеп куйган «Әлислах» газетасы 1907 елның көзендә рәсми төстә чыга башлый. Ф. Әмирхан бу газетаның, сәркатибе саналса да, чынлыкта баш мөхәррире була. Аның журналистлык һәм публицистлык эшчәнлеге әнә шул газета битләрендә киң колач ала. Һәр санда төрле темаларга багышланган мәкаләләре басыла. Ул, мәсәлән, Дәүләт думасының эшчәнлеген даими рәвештә күзәтеп бара, аның хаким сыйныфларны гына яклавын фаш итә. Дума эшенә катнашучы сул партияләрнең халык файдасына тырышуларын аңлата. Болардан тыш, Ф. Әмирхан милләтнең үз эчендәге искелек тарафдарларын рәхимсез камчылый, тар милләтчеләрне тәнкыйтьли. Әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә һәм бәяләмәләрендә халыкчанлыкны һәм реализмны яклый.

Публицистик һәм әдәби-тәнкыйть мәкаләләреннән күренгәнчә, дөньяга карашы ягыннан Ф. Әмирхан инкыйлаби-демократик фикердә тора. Моны без «Авырулар галәмендә» (1908) исемле очеркыннан да күрәбез. Санаторийда дәваланып ятканда, ул болай дип яза: «Фатирыма юнәлдем. Очраган йортларның тәрәзәләренә күзләремне сала барам: иртә 5 тән торып эшкә китәргә мәҗбүр крестьяннар, өйләренә ут та алмастан, йокларга ятканнар. Үзләренең теләсә кайвакыт

[1] *«Тәрбиятел-этфаль»* — «Балалар тәрбиясе».

торырга ихтыярлы икәнен белә торган дачниклар, сәгатьнең унике сугуына карамыйчан, гыйш-гашрәтләрендә[1] дәвам итәләр, өй эченнән гитарада уйнаган тавышлар, кокетка дамаларның чырык-чырык итеп көлүләре ишетелеп торалар.

Нинди контраст!

Бу йортта үлеп яталар, аның күршесендә бик ләззәт белән гомер сөрәләр. Уйлап-уйлап гаҗәпләнә башлыйм: бәгъзе[2] кешеләр шуның икесен дә бер диләр бит, шуларны аерып йөрткән кешеләрне миллият хисеннән мәхрүм дип сүгәләр бит; шул ике фирканең[3] берсе мәзлум[4] дисәң, ачуланалар бит; әгәр сез монда без гомер сөрсен өчен үлеп ятсагыз, җәннәттә сез дә безнең шикелле булырсыз дип юатырга тырышалар бит!»

Биредә әйтелгәннәр Тукайның «Сайфия» шигыренә гаҗәеп аваздаш:

Ул (ягъни бай. — *И. Н.*) хәзер туктар сиңа, и ач авыл, мохтаҗ авыл!

Җимрек өй каршында ич оҗмах кеби кәйфиясе[5].

Очеркта да, шигырьдә дә иҗтимагый капма-каршылыклар мәсьәләсе күтәрелә. Бер якта — җимерек өй һәм крестьяннарның ачлы-туклы тормышы; икенче якта — дача һәм байларның типтереп яшәве. Ике әсәрдә дә халыкның газаплы тормышын күреп ачыну һәм көчле нәфрәт чагыла.

Моннан тыш, Ф. Әмирхан үзенең әсәрендә милләт эчендәге социаль тормышны шома итеп кенә күрергә яратучы тар милләтчеләрне тәнкыйть утына тота, халыкны үз хәле белән килешеп яшәргә өндәүче руханиларның йөзен фаш итә.

Шул рәвешчә, Ф. Әмирхан да Г. Тукай, Г. Исхакый, М. Гафури, Г. Камал, Г. Ибраһимов, Ш. Камаллар белән бер якта торып көрәшкән язучы иде.

Ф. Әмирханның әдәби әсәрләрендә әнә шул каләмдәшләре иҗаты белән уртак яклар байтак. Ул да, мәсәлән, татарлар тормышындагы урта гасырчылык калдыкларын фаш итүгә зур игътибар бирде, аның иҗатында да хатын-кыз язмышы темасы зур урын тота. Ф. Әмирхан да тәнкыйди реализм методын кулланып язды, бу юнәлешне татар әдәбиятында нигезләүчеләрдән берсе булды. Әмма, һәрбер талантлы язучыга хас

---

[1] *Гыйш-гашрәт* — күңел ачу.
[2] *Бәгъзе* — кайбер.
[3] *Фирка* — төркем, катлау, партия.
[4] *Мәзлум* — изелгән.
[5] *Кәйфия* — күңел ачу урыны.

булганча, аны бүтәннәрдән аерып тора торган үз йөзе бар. Аның төп геройлары — яшьләр, гимназист һәм гимназисткалар, студент һәм курсисткалар, журналист, аттестатчы[1] һ. б. төр зыялылар. Бу хәл исә язучының биографиясе белән бәйле. Һәр язучы, мәгълүм булганча, үзе яхшы белгән тормыш хәлләрен файдаланып иҗат итә. Тормыш хәлләрен Ф. Әмирхан, үз сүзе белән әйтсәк, «яшь мәгыйшәт» типларын һәм күренешләрен демократик идеал югарылыгыннан торып тасвирлады.

Яңалык хакына искелеккә каршы

Ф. Әмирханның беренче күркәм хикәясе «Гарәфә кич төшемдә» 1907 елда языла һәм шул ук елда басылып чыга. Бу әсәр яшь язучы иҗатының киләчәктә нинди юнәлештә үсеп китәчәген дә сиздерә.

Яңача уйлый башлаган шәкерт, гарәфә[2] кич йокыга яткач, татар мәдәниятенең киләчәген төшендә күрә. Гает көн икән. Зиннәтле мәһабәт сарайның залына татар гимназиясе укучылары, югары уку йортларында һәм Европа мәктәпләрендә белем алучы татар студентлары, исемнәре бөтен Россиягә танылган татар профессорлары, инженерлары, язучылары, артистлары, җәмәгать эшлеклеләре һ. б. җыелган. Уку залындагы дистәләгән журнал һәм газеталарда татар галимнәре һәм сәнгать кешеләренең бөтен дөньяда танылган уңышлары турында хисапсыз мәкаләләр басылган.

Боларны күреп, безнең шәкертнең шатлыгы эченә сыймый. Ләкин шулвакыт аның колагына «Гает вакыты җитте, тор!» дигән тавыш ишетелә. Шәкерт матур хыял дөньясыннан чынбарлыкка кайтып төшә.

Язучы үзенең хыялында гәүдәләнгән тормышны татар җәмгыятенең шул вакыттагы хәленә каршы куеп күрсәтә. Хикәядән Ф. Әмирханның мәгърифәтчелек карашларын алга сөрүен чамалау кыен түгел. Ләкин бу мәгърифәтчелек XIX гасыр белән чагыштырганда инде шактый югары тора. Чөнки Фатих Әмирхан мәгърифәт чаралары ярдәмендә генә тормышны үзгәртеп була дип уйламый. Җәмгыятьне үзгәртеп кору андагы кимчелекләрне, эчке череклекне кешеләрнең аңына җиткерү белән бәйләнгән. Менә ни өчен Ф. Әмирхан

[1] *Аттестатчы* — гимназия курсы буенча имтиханга үзлегеннән әзерләнүче кеше.

[2] *Гарәфә* — дини бәйрәм алды көне.

иҗатында да сатира зур урын тота, һәм ул башлыча татарлар тормышындагы искелек калдыкларын фаш итә.

«Бәйрәмнәр» хикәясендә (1908) без, мәсәлән, сәүдәгәр Вәли белән очрашабыз. Ул — әйтерсең лә «Беренче театр»дагы Хәмзә байның игез туганы. Ул да яшьләрнең яңача киенүен, яңача фикер йөртүен, әдәби кичәләр оештыруын, театрга йөрүен яратмый. Ул да, Хәмзә бай кебек үк, үҗәтлеге аркасында улын надан һәм томана итеп калдырган. Аның яңалыкны дошман күрүе шул дәрәҗәгә җиткән ки, улының бозык урыннарга баруын театрга йөрүдән артыграк күрә.

Ф. Әмирханның тагын надан руханилардан һәм иске тип татар сәүдәгәрләреннән, иске мәдрәсәләрдән көлеп язган «Хәзрәт үгетләргә килде» (1912), «Габделбасыйр гыйшкы» (1914), «Салихҗан карый» (1916), «Сәмигулла абзый» (1916) кебек күп кенә хикәяләре бар.

Искелекне тәнкыйтьләү белән генә чикләнмичә, әдип кием киюдә яки сүз сөйләүдә яңа булып та, чынлыкта исә искелектән арынмаган кешеләрдән дә ачы көлде. «Милләт тәрәккый иттерү», «Танымаганлыктан таныштык» әсәрләре әнә шундыйлар.

«Фәтхулла хәзрәт» повесте

Ф. Әмирхан иҗатында гына түгел, бәлки Октябрь инкыйлабына кадәрге татар әдәбиятында иң яхшы сатирик повесть булып саналган бу әсәр 1908 елда языла башлап 1909—1910 елларда аерым кисәкләр булып дөнья күрә.

Повестьта 1950 елгы Казан тормышы тасвир ителгән. Бу әсәрдә дә, гарәфә кич күрелгән төштәге кебек, фән-техника һәм мәдәният ягыннан гаять алга киткән җәмгыять күз алдына килеп баса: көзгеле телефон, канат куеп очулар, автомат җайланмалар, һава корабльләре, үлгән кешене терелтү һ.б. Ул җәмгыятьтә яшәүчеләрнең мәдәният дәрәҗәсе дә югары. Алар музыканы бөтен нечкәлекләрен тоеп аңлый беләләр, сынлы сәнгать әсәрләрен сатып алалар...

Мәчет һәм башка дини оешмалар әхлак тәрбияләүгә хезмәт итә.

Үлеп, 42 ел җир астында яткан Фәтхулла мулла, терелеп, әнә шул җәмгыять шартларында яңадан яши башлый. Күренә ки, «Фәтхулла хәзрәт» — сатирик-фантастик повесть.

Иң элек бер мәсьәләне ачыклап китик. Бу әсәрне язудан Ф. Әмирханның төп максаты нәрсә? Киләчәктә татар җәмгы-

яте нинди булачагын күрсәтүме? Әллә Фәтхулла хәзрәт йөзендә иске фикерле руханиларны фаш итүме?

Мәкаләләренең берсендә язучы үзе үк бу сорауга җавап биргән иде. Бер тәнкыйтьченең бик үк акыллы язылмаган рецензиясенә җавап итеп, ул, чигүче кызга канва бизәк төшерү өчен булышлык кына иткән кебек, киләчәк тормыш күренешләре әсәрдә Фәтхулла хәзрәт образын җанландыру өчен генә кирәк дигән фикер әйтә. Төп максатым, ди Ф. Әмирхан, «мөбарәк[1] хәзрәтебезнең хәзинәи фикрия вә рухиясе дер[2]».

Әгәр без повестьның һәр эпизодын, һәр детален җентекләп тикшереп чыксак, язучының, чынлап та, хаклы булуын күрәбез.

Әсәр терелтеләчәк Фәтхулла хәзрәтнең газетада басылган биографиясе белән башланып китә. Аның улы Әхмәт, оныклары Зыя, Ләйлә һәм Нәфисә турында бер-ике сүзлек белешмә генә бирелә. Ә килене, ягъни Әхмәтнең хатыны турында, гомумән, бер сүз дә юк.

Моннан соң вакыйга артыннан вакыйга килә. Һәркайсының үзәгендә Фәтхулла хәзрәт тора. Һәркайсында аның бер сыйфаты ачыла.

Театр эпизодын алып карыйк. Фәтхулла хәзрәт, әлбәттә, театр уеннарына каршы. Гадәте буенча, ул театрга барырга җыенучы Әхмәт гаиләсен бу эштән туктатырга тырыша. Башта оялтып маташа, нәтиҗә чыкмагач, хәзрәт соңгы чараны — куркыту чарасын куллана: «Татар театрына барган кешеләр, фаразан, кяфер булалар»,— дип белдерә. Әхмәтләр, моны колакка да элмәстән, картны калдырып китәргә җыеналар. Ләкин хәзрәтнең дә театрга барасы килә, чөнки ул исән вакытта кадимчеләр театрны хатын-кызлар белән кочаклашып бию урыны дип күз алдына китерәләр иде. Фәтхулла хәзрәт тә театрга барып, берәр кыз белән кочаклашып биемәкче була.

Театрда иске заман тормышыннан алынган ике спектакль күрсәтәләр. Фәтхулла хәзрәт башта моны күреп куана. Ләкин, сәхнәдәге хәлләрнең уен гына булуын аңлагач, театрдан ихласы кайта да кочаклашып биюне көтеп утыра башлый. Икенче спектакльдә, муллалар бәхәсләшергә тотынгач, хәзрәт

[1] *Мөбарәк* — хөрмәтле (бу очракта ирония белән әйтә).
[2] *Хәзинәи фикрия вә рухия* — фикер һәм тойгылар хәзинәсе.

түзә алмый, кайда утырганын онытып, сәхнәгә атылып менә. Иске фикерле хәзрәтләр ролен башкаручы артистларны кочаклап үбә, рәхмәтләр әйтә.

Күренә ки, театр эпизоды тулысынча Фәтхулла хәзрәт образын тулыландыру өчен кертелгән. Биредә аның театрга дошманлыгы да, азгынлыгы да, икейөзлелеге дә ачыла.

Яисә китаплар музеенда булган вакыйгага күз салыйк. Гарәпчә язылган дини китапларны күреп, хәзрәт «менә инде бу гыйлем дәрьясы» дип соклана. Татар телендәге дөньяви әсәрләрне исә, җәдитләр язган дип, төкерекләрен чәчә-чәчә хурлый. Образ ачыклана, тулылана бара. Без аның Җиһанша хәзрәт, Кисекбаш, Хәмзә бай, Вәли бай кебекләр белән бер бакча җимеше булуын танып алабыз. Тукайның Кисекбашка биргән билгеләмәсе Фәтхулла хәзрәткә дә туры килә:

Бу мидә бардыр җәһаләт[1] ун вагон,
«Мин белемлек» дәгъвасы[2] — бер мең вагон;
«Иске — изге» фикре бардыр ун келәт,
«Һәр җәдит — кяфер» — егерме склад.

Димәк, Фәтхулла хәзрәтне терелтү һәм аны 42 ел алга, киләчәккә күчереп күрсәтү — биредә бер сатирик алым. Бу алымның отышлы ягы шунда: кара тап ак җәймәдә ачыграк булып күзгә ташланган шикелле, алга киткән җәмгыятьтәге күренешләр янында Фәтхулла хәзрәтнең болай да инде көлке дәрәҗәсендәге иске кыланышлары һәм карашлары тагын да искерәк, тагын да көлкерәк булып күренә.

Җыеп әйткәндә, «Фәтхулла хәзрәт» повесте, — фараз кылу, фантастик алым белән язылуына карамастан, реализм әсәре, ул гына да түгел, тәнкыйди реализмның менә дигән үрнәге. Чөнки Фәтхулла хәзрәт — типик характер, ягъни ул, аерым бер шәхес булып күз алдына килүеннән тыш, иске фикерле руханиларга хас булган төп сыйфатларны үзенә туплаган. Фәтхулла хәзрәтнең һәр сүзеннән, һәр хәрәкәтеннән XX йөз башы татар феодаль-буржуа җәмгыятенең бик күп яклары бөтен чынлыгында күз алдына килеп баса. Икенче төрле әйткәндә, бу образ типик хәлгә куеп күрсәтелгән. Әсәрнең реализмы әнә шунда.

---

[1] *Җәһаләт* — наданлык.
[2] *Дәгъва* — низаг, дау.

«Урталык» каһарманнары

«Урталыкта» исемле романына кадәр үк Ф. Әмирхан вак буржуаз зыялылар образын тудыруга омтылыш ясады. Бу яктан аның «Картайдым» дигән хикәясе (1909) кызыклы.

Хикәянең герое Мостафа үзенең 29 еллык гомерендә дөньяга карашы һәм омтылышы ягыннан берничә баскыч үткән. Башта ул зур шәкертләргә дәрес бирүче мөдәррис булырга хыялланган. Үсә төшкәч, тышкы тәэсирләр нәтиҗәсендә дин галиме булырга әзерләнә башлаган. Бераз вакыттан соң уку һәм яңа кешеләр белән аралашу аның планнарын тагын үзгәрткән. Ул, русча укып, дөньяви фәннәр өйрәнеп, халыкны агарту белән шөгыльләнергә карар иткән. Бу теләгенә инде ирешеп тә килә: университетта укый. Әмма Мостафа үзен бәхетсез дип саный, чөнки ул үзенең бөтен тырышуларын бушка киткән дип уйлый. Хәзер ул үзен кирәксез һәм артык кеше итеп хис кыла. Күрәсең, ул халыкны бәхетле итеп булуга ышанмый башлаган, шул ук вакытта бәхетле киләчәккә ничек бару юлын да белми. Кыскасы, Мостафа искедән аерылган, ә яңага килеп җитмәгән: ике арада тора.

«Урталыкта» романында (1912) Ф. Әмирхан икенче бер героена — Хәсән Арслановка — җентекләбрәк туктала, аның үз-үзен тотышын һәм эчке дөньясын һәрьяклап күрсәтергә тырыша.

Әсәрдә без Хәсәннең, өлгергәнлек аттестатына имтихан тоту өчен, аерым укытучыдан дәрес алып йөргән вакыты белән танышабыз. Язучы Хәсәннең өч сыйфатын күрсәтүгә аеруча игътибар итә.

Иң элек Хәсән иренчәк, ялкау. Аның эше — уку, аттестатка әзерләнү. Ләкин аның иң яратмаган эше дә шул. Укудан бик тиз туя, әзерләнеп җитмәве аркасында дәресләр калдыра.

Икенчесе — холкындагы йомшаклык, икенче төрле әйткәндә, эзлеклелек, даимилек һәм ныклык җитмәве. Извозчикка 15 тиен бирергә тиеш. Тегесе 25 тиен сорагач, каршы тора алмый, бирә. Концертка барасы килми, әмма, фатир хуҗасының сөйкемсез кызы чакыргач, теләмәсә дә бара. Үзенең фикере дөрес була, ләкин, әңгәмәдәше белән бәхәсләшергә кыймыйча, тегенең фикерен җөпли һ.б.

Өченчесе — эшләгән эшләренә үкенү, үз-үзен туктаусыз битәрләү, эчке дөньясында казыну. Ник 25 тиен бирде? Ник

концертка барды? Ник әңгәмәдә үзенең дөрес фикерләрен әйтә алмады? Үкенә, җаны кыйнала. Үзен кыю да, тапкыр да итеп күрсәтәсе килә. Теленә берсеннән-берсе үткен сүзләр килә. Шуларны вакытында әйтә алмаган өчен газаплана.

Хәсән холкындагы бу сыйфатларның өстенлек итүе,— һичшиксез, үзенең тормыштагы ныклы урынын таймавы, ике арада калу нәтиҗәсе. Чынлап та, Хәсән көрәшүче көчләрнең берсенә кушылган булса, билгеле бер төркемнең мәнфәгатьләрен үз мәнфәгатьләреннән өстен куйса, бу аңа ныклык өстәр иде, иренчәклеген киметер иде, эчке дөньясында казынып, үкенеп йөрүләренә вакыт калдырмас иде.

«Урталыкта» романында Ф. Әмирхан, шулай итеп, тирән мәгънәле тип тудырды, аның күп кенә сыйфатларын ачып бирде.

Ф. Әмирхан — драматург

Ф. Әмирханның шәкерт чагында өй спектакльләрендә катнашуы, рус театрына яратып йөрүе эзсез калмаган. Татар театры дөньяга килгәч, ул аңа төрлечә ярдәм күрсәтә башлый. Спектакльләр турында рецензияләр биреп бара, фельетон һәм әдәби әсәрләрендә театрны реакцион көчләрдән яклап яза. Шуның өстенә театрның репертуарын баетуга да өлеш кертә.

«Яшьләр» пьесасының (1909) сюжеты дөньяга беркадәр аек күз белән карый торган сәүдәгәр Хөсәен гаиләсе эчендәге каршылыкларга корылган. Хөсәен бай үзенең уллары Газиз белән Йосыфны, сәүдә эшенә файдасы булыр дип, беркадәр русча укыткан. Әмма егетләр, моның белән генә чикләнеп калмыйча, аттестат алып, университетка керергә карар иткәннәр. Шуның өстенә алар сеңелләре Зәйнәпнең дә күзен ачканнар, аны җанлы курчак булудан коткарып калырга омтылалар. Хөсәен исә кызын, бай малаена кияүгә биреп, бәхетле итмәкче була.

«Аталар» һәм «балалар» арасындагы каршылык кискенләшә бара. Хөсәен бай улларын укудан туктатып эшкә кушмакчы. Тегеләр буйсынмыйлар. Ипкә китерүдән өмет өзеп, Йосыф белән Зәйнәпне тәмам «юлдан яздыруыннан» куркып, ата олы улы Газизне өеннән куып чыгара.

Бу бәрелеш аерым бер гаилә эчендә туган каршылык кына түгел. Ул — бөтен татар җәмгыятендәге каршылыкларның чагылышы. Бу турыда Газиз болай ди: «Бу каршылыклар, бу

тавышлар безнең белән этиләр арасында түгел... Бу тавышлар — иске тормыш белән яңа тормыш арасында».

Иске тормышны яклаучы «картлар»ның күренекле вәкилләре — Хөсәен белән аның кияве Рәхимҗан. Әгәр кияве, кадимче буларак, ничек бар шулай калырга тиеш дип санаса, Хөсәен иске тормышны, нигезенә тимичә генә, аз-маз яңартырга кирәк дигән караштa тора. Милләтче Зыя, җәмгыятьтәге каршылыкларны кискенләштермәү тарафдары буларак, «аталар» белән «балалар»ны да, байлар белән ярлыларны да килештерергә тели.

Яңа тормыш өчен көрәшүчеләр кемнәр, һәм аларның тоткан юлы нидән гыйбарәт? Моны без төп сюжетка бәйләнеше аз булып тоелган икенче пәрдәдә күрәбез. Анда «Нәрсә эшләргә?», «Татар тормышын ничек үзгәртергә?» дигән сорау куела, һәм, нигездә, ике җавап өстенлек итә. Беренче җавапны үзенең атасы ишан белән арасын өзгән Гали әйтеп бирә. Аныңча, халык арасына керергә, аны агартырга, искене җимерү фикерен туктаусыз төшендерергә кирәк. Бу карашны инкыйлаби-демократик эчтәлекле мәгърифәтчелек дип билгеләргә мөмкин булыр иде.

Икенче җавапның эчтәлеге социал-демократик карашлы Әхмәт сүзләреннән аңлашыла. «Юк, брат (борадәр),— ди ул, Зыяга төбәп,— әгәр сез татарны чынлап алга җибәрәсегез килсә, фәкыйрь халыкка: крестьян, рабочийга сознание (хис) кертергә тырышыгыз. Фәлән байның һиммәте, фәлән байгураның шәфкате дип кәгазь буяганчы, шул фәләннәрнең ничек итеп кеше эшләгәнне ашаганлыкларын, шулар эше аркасында баеганлыкларын языгыз». Димәк, Әхмәт эшче һәм крестьяннарга инкыйлаби аң сеңдерүне алга сөрә.

Драматург үзе кайсы җавапны уртаклаша, кайсы юлны яклый соң? Ф. Әмирхан Гали фикеренә якынрак тора дип уйларга кирәк. Әсәрнең төп герое Газиз белән аның энесе Йосыфның Гали фикерендә булулары да шуны раслый. Димәк, пьесадан Гали җавабы рухындагы нәтиҗә чыга. Дөрес, бу юл катлаулы, авыр. Әнә учитель Зәкәрия, нәкъ Гали теләгәнчә, халык арасына киткән. Башта балалар укыткан, аннары крестьяннарның күзен ача башлаган. Ләкин теләгенә ирешә алмаган: аны, әләк язып, авылдан кудыртканнар.

Димәк, мәгърифәтчелек эшчәнлеге белән генә дә мәсьәләне хәл итеп булмый икән әле. Инде Әхмәт җавабы, Әхмәт программасы кала. Пьесадан объектив рәвештә әнә шул

программага якын килә торган фикер чыга. Автор тормыш барышын үгет-нәсыйхәт белән генә, халыкның мәгърифәтен арттырып кына үзгәртеп булмавын искәртә.

Ф. Әмирханның «Тигезсезләр» исемле икенче пьесасы (1914) мәсьәләне җитдирәк куя. Ул инде бербөтен, аны арттыра да, киметә дә алмыйсың. Персонажлар, аларның үзара мөнәсәбәтләре, эчке кичерешләре, үзенең әсәре белән автор әйтергә теләгән фикер тыгыз сюжетка сеңеп беткән.

Пьесада нинди тигезсезлек турында сүз бара соң? Анда сыйнфый тигезсезлек мәсьәләсе куелмый. Анда һәркайчан, һәркайда була торган гомумкешелек өчен әһәмиятле мәсьәлә күтәрелгән. Беренчедән, бертуган Рөкыя белән Сәлимә арасындагы тигезсезлек.

Менә Рөкыя образы. Иркә кыз бу. Бераз иренчәк тә ул. Вакыты белән чытлыклана белә. Әнә шул кимчелекләренә карамастан, әсәрдә ул — иң якты шәхес. Матур, саф, дәртле, сәләтле, туры сүзле. Беркатлылык белән кушылган аек акыл да, романтик ашкынлык та бар аңарда. Иң әһәмиятлесе, аның характерына бөтенлек хас. Хәзергә әле аның бу сыйфатына кимчелек килмәгән. Чөнки аны чолгап алган тирәлек мәдәниятле гаилә һәм гимназия белән генә чикләнә. Үз чоры чынбарлыгының кешене ямьсезли һәм гарипләндерә торган күренешләре аңа әле кагылмаган.

Менә Рөкыя дә уку һәм гаилә белән генә чикләнмәгән киң тормышка беренче адымнарын атлый, аның да баш өстендә болытлар куера, һәм кыз чынбарлык белән каршылыкка керә башлый. Ул, мәсәлән, үзенә тиң булырдай олы карашлы һәм нык характерлы кеше эзли. Әмма аңа таныш егетләрнең барысы да — төссез-чырайсыз, кечкенә, вак кешеләр. Менә ни өчен аның игътибары 35 яшьлек Сөләйманга юнәлә. Ләкин бу мәхәббәт аңа бәхет китерерме?

Рөкыя рәссам булырга хыяллана. Ә абыйсы Гомәрнең аны юрист итәсе килә. Кызның хыялы тормышка ашмаячак, билгеле. Моны без Рөкыянең бертуган апасы Сәлимә язмышыннан күрәбез. Сәлимә укырга тели иде, ләкин абыйсы киңәшен тотып кибеттә кассир булды. Рөкыя юридик мәктәп тәмамлап, адвокат булыр дип уйлыйк. Ләкин, ялган сөйли белмәве, туры сүзле булуы аркасында, ул бер эш артыннан икенчесен оттырачак. Шуңа күрә я җайлашырга, яисә инде бүтән эшкә тотынырга мәҗбүр булачак, тагын уңышсызлыкка очраячак. Бер чара калачак: күңеле теләмәгән кешегә кияүгә чыгу.

Әнә бит апасы бер егетне ярата, икенчесенә чыгарга җыена. Рөкыя дә, пьесадагы Гөлчирә кебек, тук, ләкин кызыксыз тормышта яши башлар. Бу хәл белән килешергә теләмичә баш күтәрсә, язмышы һәлакәт белән тәмамланыр.

«Тигезсезләр» драмасында кеше бәхете мәсьәләсе куелган. Ләкин байлык, мал-мөлкәт туплауга гына исәп тотканда, кеше үзенең сафлыгын, кешелек матурлыгын һәм бөтенлеген саклап кала алмый, ди безгә әсәр.

* * *

Әдәби иҗатка күп көчен биргән хәлдә, Фатих Әмирхан үзенең журналистлык һәм иҗтимагый эшчәнлеген дә беркайчан киметмәде. «Әлислах» газетасы чыгудан тукталгач, ул «Ялт-йолт» исемле сатирик журналга һәм башка газета-журналларга актив язышa. 1912 елда «Кояш» газетасының җаваплы сәркатибе (чынлыкта исә аның баш мөхәррире дисәк тә ярый) булып эшли башлый.

1917 елгы Февраль инкыйлабын Ф. Әмирхан шатланып каршы алды. Күп кенә мәкалә, фельетон, памфлетлар язды. Шул чакта ук җитәкчеләр күңеленә хуш килә торган сүз сөйләп көн күрүне үзенә кәсеп иткән типны күреп алды. Һәм аны үзенең «Март каһарманы» исемле хикәясендә сурәтләде.

Октябрь инкыйлабын исә Ф. Әмирхан күңеленә якын итеп кабул итә алмады. Дөрес, Совет хакимиятенең милләтләргә үзбилгеләнү хокукы бирүе, 1920 елда Татарстан автономияле республикасы төзелү аның фикерен беркадәр үзгәртте. Хакимиятне танып, «Кызыл Армия», «Эш», «Татарстан», «Татарстан хәбәрләре» кебек газеталарга язышты. 1923—1924 елларда татар театр техникумында укытты. Ләкин бераздан яңа тәртипләрнең кимчелекләрен дә күрә башлады. Шуны аның «Шәфигулла агай» повесте (1924) раслый.

«Хәят»

Бу әсәр берничә кисәктән торачак повесть яки роман итеп уйланылган. 1911 елның уртасында Ф. Әмирхан аның беренче кисәген язып тәмам итә һәм шул ук елда бастырып чыгара. Повестьның икенче кисәген дә төгәлләү алдында торганлыгы билгеле. Әмма ул өлеше дөньяга чыкмаган һәм кульязмасының да язмышы билгеле түгел.

Повестьның безгә таныш булган беренче кисәген тәмамланган мөстәкыйль әсәр итеп карарга мөмкин. Чөнки төп образ — Хәят — билгеле бер шәхес буларак күз алдына килеп баса.

Алтын кыса эчендәге портрет

Май аеның ямьле бер көнендә Гыймадовлар йортының капка төбенә тарантаска җигелгән ат килеп туктый. Лиза исемле рус кызы үзенең дусты Хәятне дачаларына алып китәргә дип килгән. Хәят аның каршына йөгереп чыга. Шушы уңай белән язучы Хәятнең портретына беренче буяуларны сала. «Матур бу кызның озын керфекле кара күзләре алсу-ак йөзенә могҗизалы якутлар шикелле нур чәчеп торганлыктан, гүзәл башы, хәтта бөтен буе нурда йөзә шикелле күренә иде».

Хәят дачага барырга әзерләнә башлый: декольте күлмәген кия, куе кара чәчләренә кечкенә калфак кадап куя. «Бу калфак,— ди язучы,— ефәк көлтәсенә чолганган гөл чәчәге (роза) шикелле көлеп тора иде».

Күренә ки, Хәят — чибәр кыз. Әмма бу — гадәти чибәрлек кенә түгел, таңга калдыра торган матурлык, чын мәгънәсендәге гүзәллек. Әнә шул гүзәллекне укучыга җиткерү өчен кулланылган сурәтләү чараларын карыйк. Кызның кара күзләре «могҗизалы якутлар»ны хәтерләтә. Алардан ниндидер гаҗәеп нур бөркелә. Шул нур аның бөтен гәүдәсен балкытып тора. Чәче — гади чәч кенә түгел, «ефәк көлтәсе». Ал күлмәген кигәч, ул «ал фәрештә шикелле була».

Язучы башта ук Хәятне табигать белән янәшә куеп тасвирларга керешә. Вакыйга, күргәнебезчә, май урталарында башланып китә. Бу вакыт исә — җәй башы булып, табигатьнең яшәреп җиткән һәм тузан белән капланырга өлгермәгән чагы. Йомшак талгын җил «дөньяга яңару вә яшәрү исләре чәчә һәм бөтен җанлы вә җансыз нәрсәләрне үзләренә бертөрле тереклектә коендыра».

Хәят белән Лиза, тарантаска утырып, дачага таба китеп барганда, «кояш алар өстенә ак болытлар арасыннан карап, оялчан гына көлеп тора». Әйтерсең лә табигать Хәяткә ак бәхетләр вәгъдә итә. Кояшның оялчан гына көлеп торуы да очраклы бизәк булмаса кирәк. Бу уңай белән Тукайның гүзәл кыз рәсеменә багышлап язган шигыреннән түбәндәге юллар искә төшә:

И кояш! Ямьсезлегеңнән син оялырсың, беләм,
Гәр[1] чагыштырсаң йөзеңне син бу бит алмасына.

Әнә шуның шикелле, Хәятнең сихри чибәрлеге гүя кояшны да оятка калдырырлык. Хәят образы белән пейзажның үзара мөнәсәбәте алтын белән кысалап куелган гүзәл портретны хәтерләтә.

Дачага рус яшьләре — егетләр, кызлар җыелган. Студент һәм офицерлар, гимназистлар. Хәят,— букеттагы иң матур чәчәк кебек, игътибар үзәгендә. Кызлар эчтән генә көнләшәләр, ә егетләр Хәяткә соклану катыш мәхәббәт белән карыйлар. Лизаның Казан университетында укый торган абыйсы Михаил исә кызга чын-чынлап гашыйк була.

Менә Михаил, үзенең хисләрен белдерер өчен, Хәятне бакчаның аулаграк урынына алып бара. «Таррак кына, кызыл ком белән түшәлгән бу юлның як-якларына озын һәм эре агачлар тезелеп, батып бара торган кояшның кызгылт нур тамчыларын челтәрләндереп төшерәләр, чит-читкә утыртылган резедалар көчле исләре белән юл өстендәге бөтен һаваны аңкыталар, яфраклар арасына яшеренгән кошчыклар адәмнәр аңламый торган җырларын көйлиләр дә бөтен бу юл, бу кызыл тамчылы нур һәм бу резедаларның тормышларына бер серлелек бирәләр иде».

Биредә инде пейзаж гүзәл рәсем тирәсендәге нәфис кыса гына да булып калмый. Ул Хәятнең эчке хәлен аңлата, шуны тоярга булыша торган сурәтләү чарасы булып хезмәт итә. Чыннан да, сизгер Хәят Михаилның аңа нәрсә әйтергә җыенганын чамалый. Яшь кызның үз йөрәгендә дә Михаилга карата ниндидер тойгы уянып килә. Югарыда китерелгән табигать сурәте нәкъ менә кызның эчке дулкынлануы белән янәшә куелган. Дөресрәге, язучы табигатьне Хәят күзе белән, беренче мәхәббәте кабына башлаган кыз күзе белән карап сурәтли.

Хәятнең чибәрлеге курчак матурлыгы кебек салкын, тышкы матурлык кына түгел. Чем-кара күзеннән сирпелә торган нур аның йөзен, бөтен гәүдәсен балкыта. Ягъни кызның эчке матурлыгы тышкы матурлыгына кушыла. Гаять саф ул, искиткеч сизгер, тупаслыкны аз гына да кичерә алмый. Кирәк икән, кыю һәм батыр була. Горурлык та бар аңарда.

---

[1] *Гәр* — әгәр.

Ике тормыш арасында

«Татар кызы» (1909) нәсерендәге татар кызын унбиш яшендә дүрт стена эченә кертеп биклиләр. Хәят, унбишне тутырып, уналтыга чыккан һәм аның хәле, күренә ки, татар кызы язмышыннан бик нык аерыла. Хәяткә яшьләр (дөрес, рус егетләре) белән аралашу рөхсәт ителә. Аны театрга йөрүдән, хәтта, декольте күлмәк киеп, бию кичәләренә барудан да тыймыйлар.

Кайдан килгән безнең Хәяткә мондый иркенлек? Татар кызының, Хәят кебек, шундый азатлыкта үсүе табигый хәлме?

Ф. Әмирхан, чигенеш ясап, Хәятнең үткәне турында әнә шул сорауларга җавап булырлык белешмәләр бирә.

Гыймадовлар килеп төпләнгән шәһәрдә татарлар күп түгел. Хәятнең атасы Борһан абзый рус сәүдәгәрләре белән эш йөрткәнгә һәм йорты «рус урамында» булганга күрә, Хәят рус балалары белән бергә уйнап үскән.

Лизаның әтисе — гаскәри кеше. Борһан абзый исә, сәүдәгәр буларак, армия өчен кайбер әйберләр җитештереп бирә. Шул нигездә ике гаилә аралаша башлый. Өстәвенә Мясниковларның өйләре Гыймадовлардан ерак түгел. Хәят еш кына Лизаларда була. Аларның тормыш рәвешләрен, караш һәм гадәтләрен күңеленә сеңдерә. Мясников киңәше һәм үз атасының рөхсәте белән Хәят 5—6 ай буе русча да укыган.

Әнә шул рәвешчә Хәят татар кызларының бик күпләренә эләкми торган шартларга куелган.

Киләчәк Хәяткә бәхет кенә китерер кебек. Беренчедән, аның бәхет турындагы хыялы артык зур түгел: әхлаклы, зыялы һәм төскә ярыйсы берәр егетне сөеп кияүгә чыгу һәм матур тормыш, мәгънәле тормышта яшәү. Икенчедән, бу максатка ирешү кыен булмаска тиеш. Чөнки Хәятнең теләсә нинди татар егете таләпләренә җавап бирерлек чибәрлеге, сафлыгы, аек акылы, тәрбиясе һәм укымышы бар. Ата да үҗәт кеше түгел.

Ләкин бәхет сагында бер көч тора. Гыймадовлар гаиләсендә дә абруе һәм көче зур аның. «Борһан абзый,— диелә повестьта,— гади бер татар купецы вә гади бер татар бае тормышы белән тора торган кеше иде. Шуңар күрә аның йортындагы һәр кеше, үз теләге вә үз тойгыларына буйсынудан бигрәк, борынгыдан эшләнеп килгән кагыйдәләргә буйсыныр-

га вә шулар билгеләп куйган юлдан чыкмый барырга тиеш иде».

Җиде яшендә Хәятне Мәлихә абыстайга укырга биргәннәр. Билгеле инде, үзе дә ярым надан абыстай, гаять кыенлык белән кызга язу таныткач, җиде ел буе дин сабагы өйрәткән. Абыстайның сөйләгәннәре һәм дин-шәригать китапларында язылганнар Хәятнең беркатлы саф күңеленә бик тирән кереп калган. Ул аларны шик астына алмаган, аларга һич карусыз буйсынырга кирәк дип инанган.

Шулай итеп, Хәят ике төрле яшәү рәвеше эчендә үсә. Берберсенә капма-каршы булган ике тормыш, ике төрле караш, ике төрле кагыйдәләр. Хәят әнә шул ике яшәү рәвешенең икесенең дә тәэсирен тоеп үскән. Күңеле, йөрәге белән ул беренчесенә тартыла, акылы исә аны икенчесенә бәйләп куйган.

Билгеле бер вакытка кадәр Хәятнең капма-каршы ике тормышта яши алуы табигый. «Мөселман тормышы» тик үзләрендәгечә генә, «рус тормышы» Мясниковлардагыча гына булырга тиеш дип уйлый ул. Театр, концерт, кичәләр аңа, йоклар алдыннан, икешәр сәгать төрле догалар укып ятуга комачауламый.

Ләкин Хәятнең үсмерлек чоры бетеп, җиткән кыз булу дәвере башланып килә. Иртәме-соңмы ул ике төрле яшәешне бер-берсенә тулысынча кушып булмаганны, икесенең берсен сайларга кирәклекне аңлаячак. Михаилга карата уянган беренче тойгы әнә шул күчешнең, шул үзгәрешнең башы була.

Күңел газаплары эчендә

Яңадан Мясниковлар дачасына кайтыйк. Хәят белән Михаил бер эскәмиягә барып утыралар. Егет үзенең мәхәббәтен белдерергә көч табалмыйча газаплана. Менә ул Казанда чакта Хәятне сагынуын әйтә дә йөзен кызның йөзенә якынайта. Шул мизгелдә кызның күңелендә ниндидер хис, кабынып, аның бөтен барлыгына тарала.

Бераздан Михаил Хәятнең игътибарын ботакта сайраучы кошчык тавышына юнәлтә: «Ул сезнең өчен сайрый һәм сезнең матурлыгыгызны мактап сайрый». Ниһаять, Михаил, барлык көчен җыеп: «Хәят, мин сезне сөям»,— дип әйтеп ташлый. Хәят исә, беразга тынсыз калгач, пышылдап кына: «Сез бик мәхәббәтле»,— ди дә, йөзен каплап, йөгереп китә.

Хәят бәхетле, бик тә бәхетле. Сөйкемле студент аны ярата. Үзенең күңелендә дә беренче саф мәхәббәт чаткысы кабына. Шул чаткы күңелен яктыртып, дөньяны тагын да ямьләндереп җибәрә. Бу вакыт Хәят, «татар тормышы»н бөтенләй онытып, «рус тормышы» эчендә яши.

Ләкин күп тә үтми, Хәят үз «күңелендә куркугарак охшый торган бер китеклек» сизә, «бу бик күңелле һәм бераз оялткычрак эшнең бер чите җимерелеп» төшкәндәй була. Сизгер яшь күңел ул китеклекне тойса да, акыл хәзергә моның сәбәбен аңлый алмый әле.

Төнге сәгать өчләрдә Мясниковларның аты Хәятне өйләренә китереп куя. Михаил хушлашканда: «Мин җавап көтәм»,— дип пышылдый.

Таң атып килә, бакчада, бөтен һаваны яңгыратып, сандугач сайрый. Михаил әйткәнчә, ул Хәят өчен сайрый, Хәяткә күңелле киләчәк вәгъдә итә кебек. Дачада күңеленә килгән китеклек онытыла. Бөтен барлыгы «ниндидер бер рәхәт онытылуга» чума, «аллы-гөлле нурга чолганган бәхет, яшь канга аралашып, иң вак тамырларга кадәр» үтеп керә.

Кызның уйлары яңадан дачада булган вакыйгаларга борылып кайта. Почта уены уйнаганда, егетләр Хәяткә берсеннән-берсе матуррак хатлар язганнар. Михаил хаты барысыныкыннан да аерылып тора. Ирләр кулына охшатып, кызлар тарафыннан язылган бер хатта гына «мөселман кызы булуыгызны онытмагыз» диелгән иде.

Кинәт теге китеклек тойгысы яңадан уяна һәм кызның эчен пошыра башлый.

Аннары Хәят көзге каршына килеп баса. Үз чибәрлеген күреп соклану тагын әлеге шыксыз тойгыны оныттыра. «Уйда бары шулкадәр күп бәхет вәгъдә иткән шикелле күренә торган үз матурлыгын сизү тойгысы вә шуннан килгән шатлык калды»,— ди язучы.

Әнә шул шатлык тойгысы белән Хәят юрган астына чума. Арыган тән оеп китә, күзләр йомыла. Шулвакыт Михаил сурәте Хәятнең колагына иелә дә, ап-ачык итеп, «мин көтәм» дип куя. Кыз, айнып китеп, үзенең Михаилга мөнәсәбәте хакында уйлый башлый. Егет аны, әлбәттә, сөя. «Сөя инде, сөя. Мин аны сөямме? Мин... Михаилны?» Кинәт аның күңеленә уй килә: «Михаил — урыс малае бит!» Менә шунда Хәят «Михаил белән үзе арасында үтеп булмый торган чокыр барлыгын» сизеп ала. Дачада күңеленә килгән китеклекнең

сәбәбе кинәт ачылып китә. «Йөрәкне хәзер генә җылытып торган сөекле Михаил сурәте» югала да, аның урынына «кяфер» кеше сурәте килеп баса.

Хәятнең, дачадан кайткач, башыннан һәм йөрәгеннән үткән уй һәм хисләр өермәсендә, беренче карашка, билгеле бер тәртип һәм эзлеклелек юк кебек. Ләкин җентекләбрәк карасак, бу каршылыклы, катлаулы һәм сикерешле уй-тойгыларның бер-берсенә тыгыз бәйләнүен, билгеле бер эздән агып баруын күрербез. Бер тойгы туа да, икенчесен уятып, үзе юкка чыга. Беренче тойгы тагын уяна, инде яңа эчтәлек белән уяна. Яисә бер тойгы икегә аерыла, капма-каршы ике тойгы бәрелешә, өченчесе туа һ. б.

Карап торышка тәртипсез күренгән катлаулы, каршылыклы уй-тойгылар тезмәсен бер процесс итеп тасвирлауны психологик анализ дип атыйлар. Ф. Әмирхан бу алымны «Хәят» повестенда аеруча уңышлы файдаланды һәм шуның ярдәмендә тышкы тәэсирләрнең, тирәлекнең кеше аңын, аның холык-фигылен ничек үзгәртүен күрсәтә алды.

Чынлап та, шушы йокысыз төннән соң Хәят алыштырып куйгандай була. Рус дөньясы белән үзе арасында упкын ятканын, язмышының «мөселман дөньясы» белән аерылгысыз икәнен төшенә. Моңарчы ул ике тормышның икесендә дә тыныч күңел белән яши ала иде. Хәзер инде, «кяфер» булганы өчен, Михаилны үзенең йөрәгеннән йолкып атарга мәҗбүр була һәм «рус тормышы»нда үзен Лизалар кебек тота алмаячагын аңлап ала. Дөрес, бу тормыш белән Хәят араны өзеп бетерми. Ләкин мәхәббәт тойгыларына ирек бирмичә, җиңелчә генә аралашуны үзе өченныклы кагыйдә итеп куя. Иске татар җәмгыятенең шәригать белән ныгытылган кануннары аның яшәү рәвешен әнә шулай чикли.

Искелекнең көче зур әле

Әсәрнең икенче яртысында аңа икенче бер гаилә, икенче бер тирәлек һәм, димәк, яңа типлар килеп керә. Бу — шәһәрнең иң зур татар бае, фабрикант Рәхимовлар. Алар Гыймадовларга караганда байлык һәм мәдәниятлелек ягыннан күп өстен. Кызлары Рөкыя белән Әминә чагыштырмача хөр шартларда үскән Хәяттән дә аерылып торалар. Мәсәлән, төрле укытучылар, кайсы өйләрендә торып, кайсы килеп йөреп, аларга төрле фәннәр һәм француз теле укытканнар. Бу кыз-

лар күптән инде татарлар янында йөзләрен капламыйлар. Рөкыя Николай Иваныч исемле студентны ярата. Әминә исә Степанов дигән артистка гашыйк. Әмма Рәхимовлар да балаларына дин сабаклары укыталар, татар тормышы кагыйдәләрен шулай ук нык саклыйлар. Аларда да руслар белән гаилә кору катгый тыела. «Степанов кебекләрне,— ди Әминә,— читтән торып кына сөяргә ярый». «Сөй, сөймә — барыбер, туганым, алар безгә, без аларга буласы түгел бит инде».

Рәхимовлар гаиләсе белән театрга баргач, тагын бер егет Хәятнең күңеленә керә язып кала. Бусы инде «мөселман» егет — Мәскәү университеты студенты Гали Арсланов. Ул театрда Хәяткә бер күрүдә гашыйк була. Студентның Хәяткә иркәләп каравы, «зәңгәрсу хәтфә күзләре» кызда яхшы тәэсир калдыра, кызның күңелендә рәхәт бер тойгы уята.

Гали Арсланов, Николай Иванычтан кирәкле белешмәләрне алгач, Рәхимовлар гаиләсенә үтеп керү уена килә. Аның төп теләге, билгеле инде,— Хәят белән танышу. Николай Иваныч студентның визит карточкасын Рәхимә абыстайга китереп биргәч, мондый сөйләшү була:

«— Ул мөселманмыни?— дип сорады.

Николай Иваныч:

— Әйе!— дип җавап биргәч, салкын вә кыска гына тавыш белән:

— Мөмкин түгел дип әйтегез,— диде».

Ник татар кызына татар егете белән танышырга ярамый?! Бу каршылыкның мәгънәсен аңлау кыен түгел. Яңалыкны кабул итү ягыннан алгарак киткән Рәхимовлар, әлбәттә, кызларының татар егетләре белән аралашуына юл куялар. Ләкин бу егетләрне иң элек ата белән ана иләктән үткәрергә тиеш. Кем баласы ул, байлыгы, дәрәҗәсе нинди? Югыйсә кызның хәерче студентка гашыйк булуы яисә берәр актёрга ияреп китүе мөмкин. Кызның ата-анасы аны байлыгы белән үзләренә тиң һәм үзләре сайлаган кешегә бирәчәк. Байлыкка табынган гаиләләрдә әхлак кагыйдәләре шуны таләп итә. Биредә инде без, урта гасыр кадимчелегенең калдыкларыннан тыш, исәп-хисапның да көчен күрәбез.

Әминә каршылык күрсәтмәкче була: «Мөселман булса, нәрсә булган соң инде, әни? Безне ашамас бит»,— ди. Рәхимә абыстай кырт кисә: «Син мине өйрәтергә яшьрәк әле».

Хәят алдында бу көчнең абруе тагын да зуррак. «Чынлап та, мөселман булгач, танышып булмый шул инде»,— дип

уйлый ул һәм Гали Арслановның сөйкемле сурәтен күңеленнән чыгарып ташларга ашыга.

Хәятнең Рәхимовлар гаиләсе белән аралашуы, билгеле, эзсез калмый. Әминә белән Рөкыягә ияреп, ул татарлардан йөзен яшерми башлый. Рус имласы, арифметика гамәлләре һәм француз телен өйрәнергә керешә. Ләкин болар гына Хәятнең күңел бушлыгын тутыра алмый.

Башта Хәят йөрәгенә кереп утыра язган Михаилны куып җибәрде. Аннары Гали Арслановны читкә тибәрде. Күңел тагын буш. Анда әч пошу, ачы сагыш хакимлек итә. Ф. Әмирхан, кызның бу хәлен тасвирлаганда, тагын пейзажга мөрәҗәгать итә. Әмма табигать хәзер үзенең якты буяулары белән түгел, бәлки ямьсез яклары белән күз алдына килеп баса: «Җил бик ачы тавыш белән сызгыра, бик калын тавыш белән үкерә, әле ыжгырынып, бүре улаган тавышлар чыгара, әле җен алмаштырган бала шикелле елый да тагы үкерә, тагы сызгыра башлый иде...»

Хыял һәм чынбарлык

Күңел бушлыгыннан моңсуланып йөргән көннәрнең берсендә Газизә абыстай Хәяткә бер фоторәсем китереп бирә. Г. шәһәрендә яшәүче Салих Фатихов исемле яшь бай рәсеме була бу. Егетнең Хәятне үзенә сораганын әнисе әйтмәсә дә, кыз, эшнең нәрсәдә икәнен сизенеп, рәсемне дикъкать белән тикшерә башлый. Егет ямьсез түгел. Европача киенгән. Кәләпүше генә бераз арттарак тора.

Күңел бушлыгын тутыру теләге көчле булганга, баштарак Хәяттә рәсем иясенә карата уңай тойгы өстенлек итә. Ул аны үзе күрергә теләгән мәдәниятле егет итеп күз алдына китерергә тырыша, хыялында аны иң элек калын тавыш белән сөйләтеп карый, ошамагач, баритонга күчерә. Салихның йорты да Рәхимовларныкы шикелле булып күз алдына килеп баса. Үзе һәрвакыт ак якадан гына йөри, театр-концертларда да еш була, имеш. Хыял күзе белән карагач, тагын да матурлана төшә. Кәләпүш, алгарак шуышып, үз урынына утыргандай була.

Ләкин күңел почмагында ниндидер шик бар. Озакламый акыл эшкә керешә. «Туганым»ы Әминә килеп чыккач, Салихка кияүгә бару-бармау мәсьәләсен үлчәүгә салып карый башлыйлар. Әминә, төпле бер карарга килгәндәй, бай егетнең

тәкъдимен кабул итәргә киңәш бирә. Әмма сизгер Хәят әлеге китергән дәлилләренә Әминәнең үзенең дә ышанып җитмәвен сиземли.

Һаман икеләнү. Һаман эчке көрәш. Риза булырга куша торган көч: «Барыбер, кайчан булса да бармый хәл юк»,— ди. Каршы як исә: «...холкын, табигатен белмәгән, күрмәгән һәм танымаган, ул сине сөяме, син аны сөя аласыңмы икәнен белмәгән кешегә гомерлеккә хатын булу куркыныч»,— ди.

Бер мәлгә соңгы карар җиңә. Хәят әнисенә «үзе белән белешмичә, бер сүз дә әйтә алмыйм» дияргә ниятли. Беразга күңеле тынычлангандай була. Ләкин бу озакка бармый. Хәят үзенең табигый һәм дөрес карарыннан да ваз кичә. Ни өчен? Бу урында Ф. Әмирханның кеше күңелен белүенә һәм психологик анализ остасы булуына тагын сокланмый мөмкин түгел. «Чөнки,— ди язучы,— ...аңар яучылагач кына, кияүгә бару өчен генә танышу оят төсле, мәгънәсез шикелле тоела башлады... Белешкәч тә, сөйләшергә сүз дә табылмас, җай да табылмас та, товар карашкан төсле бер-берсен карашырлар да... икесе ике якка китәрләр шикелле булды». Саф һәм горур Хәят, кешенең кешелеген кимсетә торган хурлыклы алыш-биреш уенына катнашуга караганда, күзен йомып, никах кочагына ташлануны артыграк күрә. Һәм карар кабул ителә: Хәят Салихка барырга риза. Күңелдә бетеп җитмәгән шикне тарату өчен, хыялга мөрәҗәгать итү чарасы гына кала. Хәят, Салихның начар кеше булып чыгу ихтималын читкә атып, матур, яхшы, тәүфыйклы итеп күрергә тырыша.

«Тын бакча. Ай күтәрелеп килә. Агач күләгәләре һаман кыскара бара, «әнә шул күләгәләр арасында плащка (ридага) төренгән, башына зур читле кара эшләпә кигән Салих килә!» Ул тәрәзә аркылы керер... Кергәч, билгеле инде, Хәятнең матурлыгын мактап, баритон тавыш белән җырлар».

Без моңарчы да Хәятнең хыялга бирелүчән кыз икәнен күргән идек. Сурәтләр ярдәмендә фикерләвенә дә игътибар иткән идек. Бу хәл, әлбәттә, беркадәр аның табигатеннән дә килә. Ләкин бу очракта Хәятнең хыялга бирелүе татар хатын-кызларының җәмгыятьтәге хәленә, аларның хокуксызлыгына да бәйләнгән. Чынлап та, Хәят фикергә һәм тойгыга хөрлек бирә торган «рус тормышы»н йөрәге белән якын итә. Әмма аңа ул тормыш кагыйдәләре буенча яшәү тыелган. Бер генә чара кала: әнә шундый дөньяда, шундый тормышта хыял көче белән генә булса да яшәп карау.

Булачак кияве Салихны хыялыннан матур кыяфәтле итеп үткәргәч, Хәят мендәренә каплана да: «Илаһи, мәхәббәт бир!» — дип куя.

«Бу теләк кызлык вакытының иң ахыргы вә шуның белән бергә иң куәтле теләге иде». Ф. Әмирханның «Хәят» повесте әнә шул сүзләр белән тәмамлана.

Әсәрнең реализмы

«Хәят» повестенда иң элек Хәятнең «Татар кызы» нәсерендәге татар кызына охшамаган яклары күзгә ташланды. Рус телен үз ана теле кебек үк яхшы белү, рус егетләре һәм кызлары белән аралашу, театр һәм кичәләргә йөрү аз кызларның гына өлешенә туры килә иде. Димәк, Хәят киң таралган һәм тормышта күп очрый торган тип түгел.

Хәят хәтта үз даирәсе кызларыннан — Лизалардан, Әминә һәм Рөкыяләрдән дә беркадәр аерылып тора. Беренчедән, ул чибәрләрнең чибәре генә түгел. Ул ниндидер гадәттән тыш, сихри бер гүзәллеккә ия. Икенчедән, аңа күңел сафлыгы һәм характер бөтенлеге хас. Ике тормыш тәэсирендә үсү аркасында уй-тойгылары каршылыклы булса да, кыз үзе дөрес дип тапкан идеалга һәрвакыт турылыклы булып калырга көч таба.

Хәят турында болай дип әйтә алабыз: татар хатын-кызлары өчен бик үк типик булмаган шартларга куелган бик үк типик булмаган татар кызы. Хәят образын тудырганда, Ф. Әмирхан азмы-күпме романтизм алымнарын кулланган. Хәятнең эчке һәм тышкы матурлыгын гадәттән тыш калкытып бирү, мәхәббәт тойгыларын һәм табигать буяуларын тиешеннән артык куерту,— һичшиксез, романтизм сыйфатлары. Хәятнең хыялга бирелүчәнлеге, үзен әйләндереп алган ямьсез чынбарлыктан качарга омтылып, үзе тудырган хыял дөньясына китүе турында да шуны ук әйтергә мөмкин.

Ләкин моңа карап кына без «Хәят» повестен романтизм кысасына гына кертеп куя алмыйбыз. Чөнки Хәят иҗтимагый мөнәсәбәтләрдән бәйсез итеп күрсәтелми. Аның караш һәм характеры нәкъ менә үз мохите — феодаль-буржуаз тәртипләр йогынтысында формалашкан. Икенче төрле әйткәндә, реализмның төп таләбе — кешене иҗтимагый тирәлек белән тыгыз бәйләнештә, шул тирәлек җимеше итеп тасвирлау та-

ләбе әсәрдә тормышка ашырылган. Әсәрдә реализм алымнары өстенлек ала, реализм методы хәлиткеч роль уйный. Романтик башлангыч исә биредә һич тә реализм белән каршылыкка керми. Киресенчә, романтизм алымнарына мөрәҗәгать итү повестьның реализмын тагын да баета һәм тирәнәйтә төшә. Димәк, Хәятне беркадәр идеаллаштыру, бу образга билгеле күләмдә романтизм буяулары өстәү аның типик хәлгә куелганлыгын тагын да ачыграк итеп, калкытыбрак күрсәтә. «Хәят» повестендагы реализм — җирдән чак кына югары күтәрелгән, ләкин аннан аерылып китмәгән реализм ул.

«Хәят» повесте бүген дә үзенең әһәмиятен югалтмаган. Язучылар, повестьны җентекләп өйрәнеп, әдәби осталыкларын үстерү өчен, аннан күп нәрсә алалар. Укучылар исә, «Хәят» повестен укып, иң элек XX йөз башы татар җәмгыятенең күп кенә яклары белән танышалар. Моннан тыш, «Хәят» повесте кеше күңелен, кеше психологиясен аңларга өйрәтә, укучыда матурлык, гүзәллек тойгысы тәрбияли.

* * *

Без югарыда карап үткән әсәрләрендә генә түгел, гомумән, Фатих Әмирхан милли-әхлакый тәрбияне үзгәртүгә, яңартуга зур игътибар биргән һәм бөтен иҗатын шуңа багышлаган. Әмма ләкин кайбер әсәрләрен укыганнан соң, дини-милли тәрбияне бөтенләй инкарь итү, Көнбатыш һәм рус әдәбиятын, алар мәдәниятен үзебезгә өлге итеп алып, аларча яшәү рәвешенә генә өстенлек бирергә тырышу авторның төп максаты булмаганмы дигән шөбһәле фикер дә туарга мөмкин кебек. Ләкин Ф. Әмирханны күңел биреп укыган кеше андый нәтиҗәгә килмәс. Ул искелекне яклаучы руханиларга, искергән йола-гадәтләргә кискен каршы чыга, үтергеч көлү белән мыскыллый. Чөнки үзенең туган халкын өзелеп ярата канга күрә, аның киләчәге, аң үсеше турында борчыла, дөнья халыклары арасында лаеклы урын алуын тели. Шушы юлда торган киртәләрне алып ташларга тели.

Фатих Әмирхан аңлаган: бер генә халыкның да мәдәнияте үз кабыгына гына бикләнеп үсә алмый. Ефәк кебек нәфис кара чәченә кечкенә калфак кадаган Хәяткә декольте күлмәк килешеп торган кебек, күрше халыклардан килгән рухи һәм матди казанышлар, татар тормышына сеңеп, үзләштерелеп, халыкка тагын да алга китәргә куәт, көч бирергә тиеш. Ул

үзе соңгы сулышына кадәр милләткә хезмәт итте, патша хөкүмәте гыйфрит кебек татар халкын басып торган көннәрдә арган-талганнар күңелендә өмет уты кабызды.

Сораулар һәм биремнәр

1. Ф. Әмирханның биографиясе һәм иҗаты арасындагы бәйләнешне күрсәтеп, дәлилләр китерегез.

2. Ф. Әмирханның инкыйлаби-демократик карашлы язучы булуы нәрсәдә күренә?

3. Ф. Әмирхан иҗатында сатираның зур урын тотуын нәрсә белән аңлатырга мөмкин?

4. Ни өчен Ф. Әмирхан «урталык» темасына игътибар итте? Бу теманы яктыртуның әһәмияте нәрсәдә?

5. «Яшьләр» пьесасындагы Зәйнәп һәм Фәхерниса образларының нинди әдәби вазифа үтәүләрен аңлатыгыз.

6. «Хәят» повестенда пейзаж» дигән темага доклад әзерләгез.

7. Хәят портретын повестьтагы бүтән персонажларның портретлары белән чагыштырып, аның үзенчәлекле якларын күрсәтегез.

8. Ни өчен повестьта Гали Арслановка бер бүлек багышланган? Бу бүлек әсәрнең композицион төзеклеген бозмыймы?

9. Салих Фатихов фоторәсемен алганнан соң, Хәятнең уй-кичерешләр тезмәсен җентекләп күзәтеп чыгыгыз. Шуңа нигезләнеп, психологик анализга аңлатма бирегез.

10. Шәхес һәм аны әйләндереп алган тирәлек мәсьәләсе «Хәят» повестенда ничек хәл ителгән?

11. «Хәят» повестенда романтизм алымнары куллануның әһәмияте нәрсәдә?

Шәриф Камал
(1884—1942)

«Акчарлаклар»
(*1914*)

Бу әсәр белән сез, укучылар, 8 нче сыйныфта беркадәр танышкан идегез инде. Әсәрнең «Егет елый» исемле бүлеген укып өйрәндегез, повесть турында, аның авторы хакында гомуми мәгълүмат алдыгыз. Повестьның төп идеясен, ягъни вакыйгалар үсешеннән һәм образлар системасыннан килеп чыга торган төп фикерен ачыкладыгыз.

Инде повесть белән тагын да тулырак танышыйк, аның татар әдәбияты тарихында тоткан урынын билгелик.

Эшче халык рухын аңларга тырышып

XX гасырга аяк басканда, татар тормышында яңа сыйныф үзенә урын даулый башлады. Бу — эшчеләр сыйныфы. Капиталистик мөнәсәбәтләр киңәя, завод-фабрикалар саны арта һәм сәнәгать (промышленность) көчәя барган саен, җәмгыятьтә эшчеләр катламы үсә. Аның үз яшәү рәвеше оеша, үзенең мәнфәгатьләре, иҗтимагый идеаллары формалаша. Җәмгыять тормышында инде татар эшчесе дә актив катнаша, аның мәнфәгатен яклаучылар, аны кайгыртучылар барлыкка килә, сәяси әдәбият туа. Матур әдәбиятта да бу сыйныф тормышы чагыла башлый. Инкыйлаби рухлы шигърият барлыкка килә, прозада һәм драматургиядә эшчеләр образларын үзәккә куйган әсәрләр языла. Аерым әдипләр бу теманы яктыртуга

ныклап керешәләр. Алар арасында Шәриф Камал күренекле урын били.

Эшчеләр тормышын, аларның да вакытлы (сезонлы) эшчеләр көнкүрешен яктыртуны Ш. Камал үзенең беренче әсәрләрендә үк үзәккә куя. Бу тема аның үз тормышы, ягъни биографиясе белән дә аваздаш.

Мулла гаиләсендә туып тәрбияләнгән егет бик яшьли үз көнен үзе күрә башлый. Аның яшьлек елларындагы тормышында ике юнәлешне күрергә мөмкин. Берсе — белемгә омтылу, үзебездәге төрле мәдрәсәләрдә, Рига, Истанбул, Каһирә уку йортларында белем алу, укытучы булып эшләү, газета-журналларда хезмәттәшлек итү. Икенчесе — шахталарда, балык промыселларында, тимер юл төзелешләрендә эшләү, ягъни төрле һөнәр эшчесе булып көн итү. Ә болар, ягъни тормышта үзе күреп-белгәннәр, үзе кичергәннәр, Ш. Камалга зыялылар хәятеннән дә, эшчеләр тормышыннан да үз әсәрләренә мул азык табарга ярдәм итә.

Язучы беренче хикәяләрендә үк инде хезмәт иясенең рухи дөньясын тасвирлый. Ләкин баштарак әле ул бу дөньяда яктыны аз күрә, кара яклар белән күбрәк мавыга. Мәсәлән, 1909 елда басылып чыккан «Уяну» исемле беренче хикәясендә үзәк образның сурәтләнүен күзаллап карыйк. Тегермән эшчесе Муса аракы эчүгә бирелеп киткән. Хатыны Гафифә аның бу эшенә разый түгел: «Эчмә, я булмаса мине аер...» — ди. Хатынының мондый сүзләренә Мусаның җен ачулары чыга, ерткыч хәленә килә, аны җәберли, кыйнап ташлый. Көннәрдән бер көнне аның табигатендәге бу вәхшилек, шәфкатьсезлек фаҗигагә алып килә, Гафифәне һәлакәткә китерә.

«Козгыннар оясында» исемле хикәядә дә (1910) эшче халыкның тискәре сыйфатлары күбрәк тасвирлана. Авыр хезмәт һәм күңелсез тормыш аркасында шахтёрлар тәмам тупасланганнар, миһербанлык, кешелеклелек кебек затлы сыйфатлар аларның бик азына гына хас. Аларның эштән буш вакыттагы шөгыльләре — аракы эчү, акчалы уйнау, бер-берсен үчекләп ирештерү. Эчпошыргыч яшәү шартлары шахтёрларны җыен юк-бардан кызык табу, күңел ачу белән мавыгуга этәрә. Артыкка киткәч, уеннан уймак чыга, диләр бит. Алар хәтта үзара ятатышып, бер-берсен ихтирам итешеп яшәгән Госман карт белән хатыны Мәрьямнең арасын бозуга китергән һәм хатынның фаҗигале үлеменә сәбәп булган «шаяру», «кызык ясау» уйлап табуга барып җитәләр.

Язучының кайбер башка хикәяләрендә дә эшче кеше еш кына ямьсез, тупас яклары белән күренә.

Ләкин тормышны күбрәк белә һәм ныграк аңлый барган саен, язучы хезмәт иясенең рухи дөньясында якты якларны да ачыграк күрә. «Сукбай» хикәясендә (1910) җир азлыктан авылын ташлап заводка эшкә киткән кеше гаиләсен югалту кайгысыннан сыкрана. «Ата» исемле хикәянең (1910) каһарманы, малае тугач, үзенең эти кеше булуына ихлас күңелдән, балаларча сөенә, шундый зур сөенеч бүләк иткән хатынын назлый, малаеның зур булып үсеп аңар алмашка киләчәген һәм тәрбияче булачагын уйлап рухлана. «Бәхет эзләгәндә» хикәясендә (1911) эш эзләп йөрүче, күңелләре сынык ике дус: «Без үзебезнең иптәшләр, эшчеләр янына барабыз... Алар хәзер, мөгаен, казармага җыелганнар, ашый-эчәләр, кайсыберләре җырлап та җибәрәләр булыр...» — дип юана, эшчеләрнең ярдәменә өметләнә. Һәм, чыннан да, туган якларыннан әллә кайларга килеп адашкан бу мескеннәргә якташлары ярдәм кулы суза.

Югарыда исемнәре аталган һәм тагын башка хикәяләрендә Ш. Камал кеше рухының нечкә күчешләрен, психологик кичерешләрне оста сурәтли. Кешенең үкенү, соклану, явызлану, аптырау, шатлану, кайгыру, үрсәләнү, елау моментларын төгәл гәүдәләндерерлек ситуацияләр таба, шуңа кулай җөмләләр һәм сүзләр, сурәтләүләр куллана.

Эшчеләр тормышын сәнгатьле итеп сурәтләү, кеше рухының байлыгын тәэсирле чагылдыру ягыннан «Акчарлаклар» әсәре үзенә бер урын тота.

«Канатсыз акчарлаклар»

Язучы повестьның исемен шулай — «Канатсыз акчарлаклар» дип тә куя алыр иде. Чөнки монда сүз диңгез кошлары турында барудан да бигрәк бер урыннан икенче урынга акчалы эш эзләп йөрүче кешеләр турында бара. Укучы аны шулай аңлый да. Язучы кулланган исемдә дә маңгайга бәреп әйтүсез генә шул мәгънә төшенчәсе бар. Бу кешеләрнең язмышын ачу-ачыклауда диңгез кошлары — акчарлакларның роле бик зур. Укучы күңеленә ныграк, сәнгатьлерәк тәэсир итү өчен, автор әсәр барышында акчарлаклар белән кешеләр арасында гел янәшәлек (параллельлек) уздырып бара, вакыйгалар агышында акчарлаклар образына кат-кат мөрәҗәгать итә.

Кешеләрнең рухи хәлләре, хыял-өметләре, ышанычлары һәм эш-гамәлләре шулар ярдәмендә төгәл чагылдырыла.

Кемнәр соң ул — «канатсыз акчарлаклар»? Язучы аларны ни өчен шулай кошларга охшата?

Үзенең төзелеше, корылышы (архитектоникасы) белән «Акчарлаклар» артык катлаулы әсәр түгел. Анда әллә ни искитәрлек кискен вакыйгалар да юк дәрәҗәсендә (давылда неводны коткарып калуны искә алмаганда). Сюжет сызыгы да тармакланып-тармакланып яисә борылмалы-борылмалы булып үсми. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне дә бик киеренке яки хәлиткеч дип әйтеп булмый. Вакыт ягыннан да озынга сузылган вакыйгалар тасвирланмый: март ахырларыннан апрель азагына кадәрге бер айны үз эченә ала.

Ә шулай да бу җыйнак повесть ни өчен укучы күңеленә бу кадәр нык тәэсир итә, тойгылар байлыгы тудыра, хәтердә уелып кала соң?

Моның сәбәбен бер-ике сүз белән аңлатырга була: әсәрнең сәнгатьчәлек дәрәҗәсе шактый камил. Ә ул нәрсәләрдән хасил була?

Без матур әдәбиятның үзәгендә кеше образы тора, аның эчке дөньясы, кешеләргә һәм вакыйгаларга мөнәсәбәте, шулардан туган уй-хисләре төп урынны били дип әйтәбез. Тормышчан сюжетка корылган бу повестьта да шулай: үзәктә кешеләр язмышы, аларның рухи дөньясы тора. Шулар бик тормышчан, табигый һәм ышандырырлык итеп сурәтләнгән.

Сюжеты бик гади. Гариф һәм Муса исемле ике егет күбрәк акча эшләү нияте белән балык промыселына килә. Монда алар, үзләре кебек үк сезонлы эшчеләр белән аралашып, бер ай чамасы яшиләр, эшлиләр. Ләкин күбрәк акча эшләү ниятләрен тормышка ашыра алмыйча, яңа эш урыны эзләп китеп баралар.

Салмак аккан су кебек тыныч кына барган вакыйгалар ике урында буталып-кайнарланып ала. Берсе — давыл вакытында ычкынган ятьмәне коткару күренеше («Егет елый» бүлеге). Икенчесе — пасха бәйрәме көнне исерешеп, ямьсезләнешеп алу хәлләре («Әйт шуны» исемле бүлек). Бу бүлекләрдә аерым каһарманнарның рухи халәтләре тулырак һәм тизрәк ачылып, аларның тормыш юллары укучы өчен яктырып, язмышлары ачыкланып китә.

Үзәк геройлар

«Егет елый» исемле бүлекнең төп каһарманы — Гариф. Аңарчы без аның эш эзләп йөргәнен, иптәшләре арасында укымышлырак булуы белән аерылып торуын, чибәр һәм көчле икәнен белгән идек инде. Ләкин күңелдә сораулар да туган иде. Нинди гаиләдән чыккан ул? Шундый укымышлы, мулла малае була торып, ни өчен ул сукбайлар рәтенә төшкән? Шушы бүлектә әлеге сорауларга да җаваплар табыла. Шулай ук аның батыр-кыю, хәтта тәвәккәл дә булуы, нечкә күңелле, итагатьле һәм хисчән икәнлеге дә ачыла. Ул,— чыннан да, мәхдүм, ягъни мулла улы. Әтисе, әхлак бозып, указын алдырган, инде үлгән, туганнары һәм әнисе бик авырлык белән тормыш кичерәләр. Болар барысы, күрәсең, егетне акча эзләп ил гизәргә мәҗбүр иткән.

Әлбәттә, Гарифның вакыйгалар үзәгендә торуы бу бүлектәге хәлләр белән генә чикләнми. «Әйт шуны» бүлегендә без егетне бөтенләй башка ситуациядә күрәбез. Әнә ул сугышучыларны аралый. Тәмам исергән Сафа аның битенә савыт белән бәргәч, үзе дә кызып китә, тегене тәпәләп ташлый. Исереп кыйнашуны хупламаса да, укучы Гарифның бу эшен гаепләми, хәтта аны беркадәр яклый да. Чөнки монда Гарифның бер гаебе дә юк, ул бары тик зуррак фаҗигане булдырмый кала, Фёдорны аралап ала. Ягъни ул — нахакка рәнҗетелүче. Дөрес, үзе дә бөтенләй үк аек түгел, соңыннан Газизә белән сөйләшкәндә шул ачык күренә. Ләкин иптәшләре арасында зыялылыгы белән аерылып торган егет бу очракта да акылын җуймый, якалашуны туктата, исерек мәҗлесне ташлап чыгып китә.

Автор, Гариф белән Газизә арасында бәйләнеш җепләре сузып, образга булган игътибарны киметми тартып тора. Яшьләр арасындагы мөнәсәбәт — әсәрдәге иң якты сызыклардан берсе. Ул хәтта икенче бер сызыкны күләгәдәрәк тә калдыра. Әйтик, вакытлы эшчеләрнең акча эшләргә омтылышын чагылдырган сызыкны алыйк. Промыселга җыелу, чаннарны балык тозларга әзерләү, беренче невод салу, давыл вакытында неводны коткару, беркадәр балык тотып тозларга салу, эшне бетереп китеп бару — шул сызыкны тәшкил иткән буыннар. Ләкин укучының игътибары иң беренче чиратта Гариф — Газизә мөнәсәбәтләренең кая барып чыгуы белән кызыксынуга юнәлә.

Әнә Гариф беренче мәртәбә Газизәне күрә, аңа «чибәр генә» дигән бәясен бирә. Аннары аның якыннанрак танышуы, аралашуы, кызның саф күңелле, кешеләргә игътибарлы, ата-анасына хөрмәтле булуын белүе, үзе дә сизмәстән, аны ярата башлавы... Соңгы күренештә — аңлашу һәм вәгъдәләр бирешеп аерылышу. Боларның һәммәсендә Гарифның рухи дөньясы, эчке кичерешләре тулы ачыла.

Менә шушы сызыкка бәйле төстә (аны «мәхәббәт сызыгы» дип атарга мөмкин) повестьта тагын бер персонаж ныклап ачыла. Бу — Шәрәфи карт белән Сәгыйдә карчыкның бердәнбер кызы Газизә.

Кызның рухи дөньясын ачуга автор шулай ук нык игътибар бирә, аңар аерым бүлекләр багышлый. «Чуар оеклар» бүлегендә ул Газизә белән әнисенең монда кайдан килүләре, гаиләнең кайгы кичерүе (Газизәнең абыйсы үлгән), күченеп килү мәшәкатьләре һ. б. белән таныштыра. Шунда Шәрәфи картның кимчелеге мәгълүм була: төрле халык арасында йөреп, ул бераз хәмер хирыслыгына бирелгән, шуның белән гаиләнең матди хәленә дә зыян китерә. Шулай да бүлекнең үзәгендә Газизә тора, аның менәзе[1] ачыла башлый. Кызның оялчанлыгы, әтисе алдында тел яшерүе, күңелендәге кайбер теләкләрен (читеккә караганда чуар оеклар белән шиблитларны өстен күрүен) әнисенә генә белдерүе, ягъни тыйнаклыгы чагыла.

Татар кызларына хас булган мондый сыйфатлар башкалар тарафыннан тәкъдир ителә, тирән хөрмәтләнә. Баштарак кызның Гариф белән мөнәсәбәтләрен күпертеп сөйләргә теләгәннәр дә тора-бара телләрен тешләргә тиеш булалар. Чөнки кыз артык саф һәм эчкерсез. Ә сафлык, кешелеклелек — эшчеләр арасын ныгытып, беркетеп торучы көчләрнең берсе, ул шактый уңышлы гәүдәләндерелгән.

Газизәне ни өчен төп образлардан берсе итеп саныйбыз? Чөнки кызның матур һәм чиста рухы башка әдәби персонажларга караганда чагыштырмача тулырак ачылган. Бу яктан да ул Гариф дәрәҗәсенә якынлаша. Кызның психологик йөзен тулырак тасвирлау өчен, повестьта өч махсус бүлек бирелгән: «Чуар оеклар», «Яшь күңел», «Йокла, бәбкәм» бүлекләре. Калган кайбер бүлекләрдә дә кызның күркәм сыйфатлары тегеләйме-болаймы чагылып, укучы күңеленә

---

[1] *Менәзе* — холкы, характеры.

сеңдереп барыла. Соңгы «Мин сине көтәрмен!» бүлегендә ул бигрәк тә ачык итеп, башкаларның да аңа уңай мөнәсәбәте сизелерлек итеп бирелә:

«...Егет-җилән Газизәгә әдәпсезлек күрсәтми иделәр. Газизәнең сөйкемле һәм җитди чыраенда, садәлек катыш чын кыланышында, кешенең күңелен үзенә тарту белән бергә, аны бертөрле хөрмәт иттерә торган бер хасият бар иде: мондагы татар егетләре үзләре сизмичә аны эчтән хөрмәтле тоталар, аңардан әдәп саклыйлар. Әлхасыйль[1], иң дөресе — һәммәсе диярлек эчтән аны сөя иделәр. Шунлыктан аны хөрмәтсез итәргә, оялтырга берсенең дә күңеле бармый иде. Бервакытта Гариф белән буташтырып сөйләнгән гайбәтләр дә инде онытылды. Кемнең дә күңеле Газизәне пычранган итеп күрәсе килми һәм аны дөресләми иде».

Кешеләрне нәрсә якынайта?

Әлбәттә, промыселга вакытлы эшкә килгән кешеләр чын мәгънәсендә коллектив булып оешып бетә алмыйлар. Коллектив дип, без уртак максатлар, уртак хезмәт эшчәнлеге җирлегендә озак вакытларга оешкан кешеләр төркемен күздә тотабыз. Монда исә сүз кечкенә авыллардан да, шәһәрләрдән дә җыелган кешеләр, бик аз вакытка бергә эшләгән, куллары төрле эш белсә дә, эшче буларак әле түбән баскычта торган кешеләр турында сүз бара. Чыннан да, әнә сезонлы эшкә килгән Фёдор — фабрикантлар нәселеннән, Хөснетдин — кечкенә солдат, Гариф — укымышлы мәхдүм, Шәрәфи карт — балык тозлаучы һөнәрен үзләштергән эшче һ. б.

Шулай да боларда инде эшче сыйныфка, аерым бер коллективка хас сыйфатлар бөреләнеп, формалашып килә. Дөрес, ул шома гына бармый. Вакытлы рәвештә бергә туры килгән кешеләргә хас булган таркаулык та, эчеп-исереп сугышу да, эшне бетереп акча бүлгәндәге үпкәләшүләр дә бар монда. Әмма күмәклеккә омтылу да шактый көчле. Авыр һәм хәлиткеч мизгелләрдә кешеләр бер-берсенә тартылалар, үзара теләктәшлек эзлиләр. Барысы бер булып гомуми мәнфәгатьләрне якларга әзер торалар. Мәсәлән, давыл вакытында неводның ычкынган очын алырга дип, үлем авызына кереп киткән иптәшләре өчен алар каторга китәргә дә риза: «Беләсезме, тегеләр нәрсә ди...— дип хәбәр итә Николай

[1] *Әлхасыйль* — кыскасы, бер сүз белән әйткәндә.

иптәшләре турында. — Әгәр көймә кайтмаса, әнә теге ике господинны буып суга ташламакчы булалар». Промыселдан таралганда да, эшчеләр парлап-парлап китәләр, киләсе елга тагын бергә җыелырга планнар коралар. Вак-төяк кытыршылыклар, тормыш мәшәкатьләре аркылы эшчеләрдә берберсенә хөрмәт, кешелекле мөнәсәбәт, түземлелек, башкаларның фикеренә колак салу кебек сыйфатлар ныгый. Кыскасы, эшче сыйныфның уңай сыйфатлары барлыкка килә. Коллективны, бердәмлекне булдыра торган шундый сыйфатларның бер өлеше Шәрәфи карт гаиләсенә, бигрәк тә Газизәгә мөнәсәбәттә ачык чагыла.

Повестьта күмәк хезмәткә тартылу процессы нечкә һәм оста итеп милли хисләр белән, аерым милләткә мөнәсәбәт белән үрелеп бирелә. Татар милләтенең күркәм гореф-гадәтләрен олылау, изге санау бигрәк тә Сәгыйдә карчык, Газизә, Шәрәфи карт, Гариф образлары ярдәмендә үткәрелә. Эшчәнлек, күндәмлек, инсафлык, тәртиплелек белән башка милләтләрнең дә хөрмәтен казанып була. Николай татарча яхшы белә, татарларны үз итә. Промысел хуҗасы татарларга: «Ә, князьләр икән... Яхшы халык... Яратам мин аларны, эшчән булалар», — дип бәя бирә. Болар укучы күңелендә үз милләте вәкилләре өчен, татарның уңай яклары өчен горурлану хисләре тәрбияли («князь» дип, элек татарларны атауның төбендә алардан көлү төсмере дә булган).

Шулай итеп, гомумкешелек сыйфатларын тәшкил иткән гаделлек, миһербанлык, сафлык, олы җанлылык, кече күңеллелек, ярдәмчеллек кебек сыйфатлар әсәрдә эшче сыйныфның күркәм яклары белән тыгыз аралаштырылып бирелә. Хезмәт сөю, иптәшлек, тырыш һәм гадел хезмәт ярдәмендә байлык тупларга омтылу кешеләрне үзара якынайта, берләштерә, бер төркемгә җыя. Кыскасы, җәмгыятьтә киләчәге зур булган эшче сыйныфның яралуы һәм тууындагы беренче манзаралар күз алдына килеп баса.

Повестьның кайбер сәнгатьчә үзенчәлекләре

8 нче сыйныфта без повестьның сәнгатьчә эшләнешендәге төп үзенчәлекләреннән берсе итеп каһарманнарның эчке дөньясын тулы ачып бирүне күрсәткән идек. Рухи кичерешләрне автор тәэсирле итеп, төгәл сүзләр һәм образлар ярдәмендә чагылдыра. Образлылыкны көчәйтү, сүз белән ясалган

сурәтнең тәэсир көчен арттыру максаты белән, ул җанлы (акчарлаклар, тараканнар, кырмыскалар һ.б.) һәм җансыз (ай, диңгез, давыл, җил, яфраклар һ.б.) табигатькә иркен мөрәҗәгать итә. Алар я кешенең эчке кичерешләренә капма-каршы куелалар, яисә кешеләр белән алар арасында охшашлык күрсәтелә, янәшәлек уздырыла.

8 нче сыйныфта күзәткән параллель сурәтләү алымын искә төшерик. Балык тоту әле башланмаган, өметләр зурдан, күңелләр күтәренке. Эшчеләрдәге бу халәтне үтемле итеп бирү өчен, автор акчарлакларның түбәндәге образын тудыра: «Сыек кына томан белән өртүле диңгез өстендә очынып йөргән акчарлакларның гыйгылдап көлгән шикелле үткен һәм күңелне кытыкландыра торган тавышлары диңгез өстендә асылынып торган әллә нинди тылсымлы сарайлардан ишетелгән шатлык шаркылдауларына охшый иделәр».

Балык тоту башлана. Әмма эш әллә ни шәптән түгел: балык бик әләкми, эшчеләрнең өметләре җимерелә бара. Монысында да кешеләрнең рухи хәлләре акчарлаклар образы ярдәмендә бирелә: «Кырыйга якынлаша торган невод өстендә, көмешле йомычкалар төсле, ак балыклар бертуктамый ялт та йолт сикереп маташалар, гүя үзләренең тоз эчендә һәлак буласыларын белеп, кырыйга чыгарга теләми, неводтан ычкынырга тырышалар... Очы-кырые күренми җәелеп яткан матур диңгез өстендә әллә нихәтле акчарлаклар, өермәгә эләккән яфраклар төсле, буталып очыналар һәм акылдан шашкан кешечә эчләре катып көлгән яисә үчегеп ярсыган шикелле гыйгылдап йөрәкләрне кытыкландыралар. Әллә алар шушы сәләмә кешеләрнең дә, аларның үзләре кебек оча алмауларыннан һәм тамаклары өчен борыннары белән җиргә абынып тырмалуларыннан көләләр, әллә болар балыкны бетерәләр дип көнләшә һәм үчегеп елыйлар...»

Балык сезоны тәмам. Ләкин тотылган балык аз. Шуңа да эшчеләргә акча көткәннән күпкә ким тия. Күңелләр төшенке, яңадан эш эзләргә, ил буйлап гизәргә туры киләчәк. Кешеләрнең сүрән рухи халәтен акчарлакларның үз-үзләрен тотышы ачык чагылдыра: «Газизә байтак вакыт, ишек янына сөялгән көе, китеп баручылар артыннан карап торды. Кояш та иңгән я иңмәгән! Ул якны инде болыт каплаган иде... Диңгез өстендә сирәк-саяк акчарлаклар күренгәли; алар, ак канатларын селтәп-селтәп бер югары, бер түбән очып, тоньк һәм эчпошыргыч тавыш белән елаганга да,

көлгәнгә дә охшашлы гыйгылдап-гыйгылдап кычкырыналар...»

Язучы вакытлы эшчеләрнең күңелләре сынык, төшенке булуын кат-кат искәртеп тора. Ни өчен сынык күңелле соң алар? Әсәрне укыгач, без бу сорауга да җавап табабыз. Кешеләр төрле сәбәпләр, күбрәк мохтаҗлык аркасында туганүскән җирләреннән аерылганнар, чит-ят җирләрдә акчалы эш эзләп, ягъни бәхет эзләп йөрергә мәҗбүр ителгәннәр. Вакыйгалардан күренгәнчә, аларның бәхетне табуга өметләре бик кечкенә. Менә ни өчен сурәттә авыр тойгы тудыручы сүзләр һәм тәгъбирләр шактый еш кулланылган. Мәсәлән, «елау» сүзе төрле ситуацияләр уңае белән, кеше күңеленең төрле вакытын чагылдырган кулланылышта файдаланыла. Әнә баракта «киң күкрәкле, юлбарыстай көчле һәм матур егет чикмән астында әкрен генә елый». Салкын, шыксыз барак почмагында да «бернәрсә елый». Кумык Мәһдинең думбра кыяфәтле «чогыр»ы «хәлсез бала елаган кебек» әкрен генә тавыш чыгара. Кыйналган һәм рәнҗетелгән Фёдор «кычкырып ук елый». Акчарлаклар әле «үчегеп елыйлар», әле «әчпошыргыч тавыш белән, елаганга охшашлы тавыш белән кычкырыналар». Гарифның әнисе я шыпырт кына, я ярсып елый. «Елап торган буш һәм күңелсез фатир» Сәгыйдәнең үлгән улын гүяки каршы ала. Туган йортларыннан киткәндә, карчык «әче өзелеп, үксеп-үксеп елый». Соңгы күренештә «канатсыз акчарлакларны», сөйгәне Гарифны озаткач, Газизә дә «мендәренә капланып әкрен генә үксеп-үксеп елый». Сагыш, кешеләрне тулаем биләп алган сагыш аңкый мондый юллардан. Туган ил сагышы, ата-ананы сагыну хисе, иртәгәге көннең билгесезлегеннән, тормышның авырлыгыннан барлыкка килгән әч пошу, сүрәнлек.

Ләкин болар повестьның якты рухын, тулаем күтәренке сулышын баса алмый. Әсәрнең ахыры да оптимистик рухта бетә. Моны түбәндәге җөмләләр ачык чагылдыра: «Безнең тачкачылар балыкны бик күп тотып та, кырыгар сум акча эшләү хыялларына инде бит сыптырган иделәр. Балыкның барлыгы өч чанда гына булып, алар да тулы түгел иделәр. Ләкин балыкның аз булуы аларны өметсезләндермәде. Җәй башының көләч кояшы, матур яшел хәтфәгә бөркәнгән серле таулар аларга әле бик күп нәрсә ышандыра, мең төрле вәгъдәләр бирә иделәр».

Шулай кешене өмет яшәтә, өмет йөртә. Шул өмет персонажларга көч өсти, киләчәккә ышаныч тудыра. Матурлыкны, яктылыкны, алда әйтелгәнчә, Гариф — Газизә сызыгы да, кешеләрдәге, бигрәк тә Шәрәфи карт гаиләсендәге миһербанлык, эчкерсезлек, ярдәмчеллек тә барлыкка китерә. Шуңа күрә «Акчарлаклар» повесте XX йөз башы татар әдәбиятындагы иң күренекле, кешеләр рухын дөрес итеп, хезмәт иясенең тормышын табигый хәлендә тасвирлаган иң гүзәл әсәрләрнең берсе буларак танылды.

Сораулар һәм биремнәр

1. Повестьта сурәтләнгән вакыйгаларны икегә аерып, аларның үсешен күзәтегез. «Балык тоту тарихы» һәм «Газизә белән Гарифның саф хисләре» дигән темаларга ике мөстәкыйль сюжет төзегез.

2. Үзәк каһарманнарга характеристика бирегез.

3. Сафа, Солдат, Шәрәфи карт, Сәгыйдә карчык образларын сурәтләгез. Аларга нинди сыйфатлар хас?

4. Промысел тормышында нинди уңай яклар бар? Ә авырлыклар нидән гыйбарәт?

5. Гариф җитәкләгән артельне коллектив дип әйтеп буламы? Аның нинди уңай һәм кимчелекле яклары бар? Бу артельдә эшче сыйныфка хас булган сыйфатларның нинди яралгыларын күрәсез?

6. Түбәндәге җөмләне үз сүзләрегез белән, үзегез аңлаганча сөйләп бирегез: «Мин сине көтәрмен» дигән җөмлә аның колак янында әллә нинди югары һәм эч өзгеч ноталардан җырланып бара, аның җанын ләззәт белән катыш юксыну ачыта, сызлата иде...»

7. «Акчарлаклар» повестенда хезмәт кешесенең уңай сыйфатлары» дигән темага инша языгыз.

* * *

Образ — әдәби әсәрдә кешенең эчке һәм тышкы бербөтен сурәте. Табигать күренешләре, җәнлек-кошлар, иҗтимагый күренеш-вакыйгалар да образ-сурәт төсен алырга мөмкин. Аерым әсәрләрдә, бигрәк тә лирикада, кешенең кайбер кичереш-халәте дә образ була ала.

Икенче сүзләр белән әйткәндә, образ төшенчәсе күбрәк кеше образы мәгънәсендә кулланылса да, шулай ук образ-кичереш, образ-күренеш, образ-предмет, образ-пейзаж һ.б. мәгънәләрдә дә кулланылышта йөри.

«Акчарлаклар» повестенда, мәсәлән, Гариф образы, Газизә, Солдат, Шәрәфи карт һ.б. кешеләр образлары бар. Шул

ук вакытта диңгез образы, акчарлаклар образы, давыл, көймә, барак образлары да үзенчәлекле итеп сурәтләнгән. Гариф образы дигәндә, без куркусыз, көчле, чибәр һәм ярыйсы ук укымышлы, оялчан-тыйнак, тирән кичерешле, нечкә күңелле, намуслы егетне күз алдына китерәбез. Яки акчарлаклар образы дигәч, туктаусыз хәрәкәттәге, балык эзләп очып йөрүче диңгез кошлары төркемен күз алдына китерәбез.

Акчарлаклар образын кертүнең әсәрдә икенче сәнгатьчә йөкләмәсе дә бар. Бу образ ярдәмендә вакытлы эшчеләрнең хәле — балык тотуга кадәрге, балык тоту вакытында, сезон тәмамлангач булган иҗтимагый хәлләре дә, эчке кичерешләре дә гомумиләштерелгән сәнгатьчә гәүдәләнеш таба. Менә шунда инде бу образ символик мәгънә ала.

Нәрсә ул символ? С и м в о л — нинди дә булса күренешне яки предметны аңлатучы шартлы сүз яки билге. (Ул «шартлы билге» дигән грек сүзеннән алынган.) Мәсәлән, ипи-тоз — кунакчыллык, чишмә сафлык символы булып әверелгән. Гербыбыздагы канатлы барс — Татарстан символы.

Акчарлакларны бу әсәрдә сезонлы эшчеләрнең символик образы дип әйтергә мөмкин.

ТАТАР ПРОЗАСЫ ИРЕШКӘН УҢЫШЛАР

1901—1917 елларда, шигърият белән беррәттән, чәчмә һәм драма әсәрләре дә моңача күрелмәгән тизлек белән үсте. Татар прозасы XIX йөздә үк халык тормышында аеруча мөһим булган мәсьәләләрне күтәрде. XX гасыр башында проза алдына укучылар белән әнә шул җитди әйберләр турында сөйләшүне сәнгатьлелек ягыннан тагын да югарырак дәрәҗәдә алып бару бурычы килеп басты.

Зарурилык тиешле талантларны да тудыра, диләр иде. Дөрес ул. Бу чор шигърияте күгендә Г. Тукай исемле гаять зур йолдыз кабынган кебек, проза өлкәсендә дә Г. Исхакый исеме балкып пәйда булды. Әдәбият галиме И. Нуруллин язганча, «XX йөз башы татар әдәбияты Г. Исхакыйның «Инкыйраз»ыннан чыкты дип әйтә алабыз. Бу чор әдәбияты белән азмы-күпме таныш булган укучы үзе дә күрер: Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов һ.б. классикларыбызның шигырь һәм хикәяләрендә, повесть-пьесаларында, мәкалә һәм фельетоннарында күтәрелгән һәм сәнгатьчә хәл ителгән тема һәм мәсьәләләрнең барысы да «Инкыйраз»да бар». Шул ук вакытта әлеге темаларны укучының аңына гына түгел, йөрәгенә дә үткәзеп әйтү куәтенә ия булган әдипләребез сәнгатьлелекнең яңадан-яңа, төрледән-төрле рәвешләрен, шәкелләрен[1] табып иҗат иттеләр.

Менә бер үзенчәлекле мисал. Татарстан җире эреле-ваклы елгаларга бай булса да, анда очсыз-кырыйсыз диңгезләр юк. Ә XX йөз башы каләм осталары пейзаж шигъриятендә диңгез күренешләрен шактый еш кулландылар. Бу вакытта җәмгыятьтәге вакыйгаларның тигезле-тигезсез алмашынып, бер күтәрелеп, бер басылып торуы, күрәсең, аларга диңгездә барган гаять катлаулы күренешне хәтерләткәндер.

Котырынган дулкыннар эчендә калган кораб образын яшәү белән үлем арасында чайкалган татар милләте белән чагыштырып сурәтләү дә очраклы күренеш түгел иде. Г. Коләхмәтовның «Уалган мол» исемле (1906) тәрҗемә нәсерендәге диңгез дулкыннары образы, гомумән, романтик рух белән өртелгән булса, Дәрдемәнднең «Кораб» шигырендә (1908) туган халкыбызның язмышы турында борчылу гаме өстенлек

---

[1] *Шәкел* — форма.

итә. Г. Ибраһимов «Диңгездә»[1] хикәясендә (1911) кешенең, су стихиясе белән очрашканда (гомумән, табигать хәтеренә юлыкканда), эчке кичерешләрен гәүдәләндерүгә игътибар бирә.

Әдип кызыклы күзәтү ясый: диңгез чагыштырмача тыныч чакта, кешеләр үзләренең төрле дин вәкилләре икәнлеген ассызыклап күрсәтәләр. Мөселман Нуретдин карт биш вакыт намазын укый, марҗалар чукыналар. Ләкин дулкыннар көймәне менә-менә су төбенә җибәрердәй булып котырынганда, алар һәммәсе чарасыз кеше булып кала: яшәүдән өмет өзеп, үлем иркенә бирелеп, палубага сузылып ята. Аларның табигатьтән өстен куәтләрдән (Аллаһы Тәгаләдән) ярдәм сорап ялварудан башка әмәлләре юк. Автор кешенең теләсә нинди шартларда да үз көченә ышанырга тиешлеген куәтли. Әгәр көймә белән идарә итүчеләр, бигрәк тә койрыкта утыручы, осталык һәм елгырлык күрсәтмәсәләр, физик көчкә ия булмасалар, алар да, башкалар кебек, тәкъдир кушкандыр дип риза булып, идәнгә сузылып ятсалар, диңгез дулкыннары йомычкадай чайкалган бу көймәне күптән төпкә батырган булыр иде. Көймәдәгеләр хикәяләүче егетнең шушындый хәл-әхвәлдә дә тыныч халәт саклавына сокланалар. Әйе, ул гел борчылып кына утырмый, бәлки котылу чарасына керешә, «төн буе көймәчеләргә булышып чыга».

Язмышка буйсыну һәм аңа каршы тору гамәлләре: Г. Ибраһимов боларның беренчесенең афәтен Габдулла хаҗи исемле кеше тарыган хәлне сурәтләү юлы белән бик аянычлы итеп ача. Хаҗдан кайтканда, ул утырган кораб туктап кала. Имеш, аны зур балык туктаткан, корбан алмыйча, әсирлектән азат итмәячәк. Барысы бергә җыелып, шобага тоталар һәм балыкка азык булу тиешлеге Габдулла хаҗи өлешенә чыга. Тәкъдиргә буйсынып, ул, Юныс пәйгамбәр кебек[2], диңгез ихтыяры белән ризалаша.

Бирeдә башкаларның иминлеге өчен үзен корбан иткән Юныс пәйгамбәр, Габдулла хаҗиларны үрнәк итеп китерү очраклы түгел. «Кайсы юллар, нинди упкын тарта безне җан сорап?!» (Дәрдемәнд) дип борчылу,— әлбәттә, кешенең

---

[1] «Диңгездә» — сүз Хәзәр (Каспий) диңгезе турында бара.

[2] Юныс пәйгамбәрне Зәлуха атлы балык йотса да, Ходай Тәгалә рәхмәте белән ул исән кала, кырык көннән соң ярга чыгарыла.

уңай сыйфаты. Ләкин шул упкын өстендәге юллар хәтәренә каршы үзеңнең акыл һәм җисми көчеңне куя һәм туплый белү тагын да әһәмиятле. «Диңгездә» әсәренең хикәяләүчесенә — куркыныч мизгелләрдә үзен кыю итеп күрсәтә белгән кешегә — җир мохитенә әйләнеп кайту шатлык китерми. Ихтимал, ул табигатьтә дә, җәмгыятьтә дә давыллы, зилзиләле хәл-әхвәлне ярата төшәдер, үзенең эчке көчен гадәттән тыш вакытларда гына эшкә туплыйдыр. Шулай булган тәкъдирдә XX йөз башында аның җаны теләгән шау-шулы вакыйгаларга кытлык булмады. Ул, шушы көрәшләрдә катнашып, дәртенә дәрман таба ала иде. Менә шундый үз-үзеннән, тирә-юненнән, җәмгыятьтәге хәлләрдән канәгать булмаган, әмма әле үзенең шул омтылышларына туры килмәгән якларны үзгәртү гамәленә керешмәгән геройларны сурәтләүгә бу чор прозасында еш юлыгырга мөмкин иде.

Әдәбиятның бурычы кешеләрнең эчке дөньяларын хәлиткеч бәрелешләргә әзерләүдән гыйбарәт булды. Диңгез гарасаты образы, укучыны шомландырып, аның гамен җәмгыятьтәге вакыйгаларга юнәлдерү өчен, отышлы кулланылды. Г. Ибраһимовның «Хәят дулкыннары» (1914) романының беренче кисәге (ул «Безнең көннәр» дип атала) диңгез шаулавын сурәтләү белән башлана. «Диңгез түбәндә кемгәдер ачу белән үкеренә. Аның куәтле дулкыннары, тау-тау булып, биек, ташлы, текә ярларга һөҗүм итәләр. Күңелгә шом килә: гүя менә-менә тагы бер-ике тапкыр ыргып атылачаклар да дөньяны каплап китәчәкләр».

Ш. Камал исә «Акчарлаклар»да (1914) диңгез күренешен тагын бер максатта — кешенең эчке дөньясына тәэсир итеп, аның күңел түрендәге кичерешләренә бәрабәр итеп бирүдә сәнгатьчә көчле чара буларак файдалана.

Әйе, татар халкын вакыт дулкыннарында чайкалган кораб белән чагыштырсак, ачы язмыш аны, һич ялгыштырмыйча, әкренләп бетүгә, үз йөзен югалтуга алып килә иде. Г. Исхакый кебек олуг язучы һәм куәтле фикер иясенең, «Ике йөз елдан соң инкыйраз[1]» әсәрен (1902) язып, шушы афәт турында җәмәгатьчелекне кисәтүе очраклылык булмады. Татарларның юкка чыгу, бетү мөмкинлеге рәсми хакимиятләр тарафыннан махсус тудырылды.

---

[1] *Инкыйраз* — бетү, юкка чыгу.

Бу очракта Россиядәге азчылык милләтләрне икенче, өченче сортлы кешеләр дип карап, аларны урыслаштырып, империянең бөтенлеген булдыру, гомерен озынайту сәясәте күздә тотыла. Татар, казах, үзбәк, төрекмән, якут, чуваш, мари, удмурт һәм башка халыкларның мәгарифен, мәдәниятен үстерүгә ярдәм итмәү генә түгел, киресенчә, тоткарлык ясау иң гадәти хәлгә әверелде. Менә ни өчен З. Һади, Г. Исхакый, М. Гафури, Ш. Камал, Ф. Әмирхан кебек әдипләр иң әүвәл милләтне агарту, аң-белемле итү һәм шул юл белән үз-үзен саклап калуның гамәленә керешергә өндәп яздылар.

Буш хыяллар белән гомерен әрәм итүче Габделбасыйр кебекләрне тәнкыйтьләп «Габделбасыйр гыйшкы» (1914), Ф. Әмирхан милләтне тәрәккый иттерүнең[1] юлын «Гарәфә кич төшемдә» (1907), «Фәтхулла хәзрәт» (1910) әсәрләрендә бик ачык итеп күрсәтте. Татар җәмгыяте нинди юнәлештә үсәргә тиеш? Әхмәт, Зыя, Ләйлә, Нәфисәләр яши торган җәмгыять мохите — Ф. Әмирхан һәм аның кебек башка әдипләрнең хыялы. Биредә татар милләте дөньядагы башка милләтләр белән бер дәрәҗәдә көн күрә, кимсетелүләр, кысулар юк. Үз дәрәҗәсен белеп, илһамланып иҗат итеп, ул әнә нинди югары фәнни-техник үсешкә ирешкән, матди яктан тәэмин ителгән. Икътисадның нык үсүе мәдәниятнең чәчәк атуына һәм белемлелек матди байлыкның артуына китергән. Нәкъ менә шундый алшартлар югары әхлаклылыкның да нигезен тәшкил итәләр.

Бу чор әдәбиятында гади кешегә, аның алдында торган авырлыкларны күрсәтүгә игътибар артты. М. Гафуриның «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек» (1902), «Ярлылар, яки Өйдәш хатын» (1907) әсәрләре тормышның иң түбән баскычындагы авыл һәм шәһәр ярлыларының хәленә укучының карашын юнәлтте. Шулай итеп, әдәбиятта «кечкенә кеше»не үзәккә куеп, олы итеп, аның эчке дөньясын кабарынкы пыяла аша караган сыман зурайтып бирүне күпчелек язучылар үзләренең иң әһәмиятле бурычларыннан саный башладылар. С. Рәмиевнең «Нәҗметдин агай бәйрәме» (1909), Г. Ибраһимовның «Карт ялчы» (1912), Ш. Камалның «Уяну» (1910) хикәяләре — һәммәсе шул гади кешеләрнең

[1] *Тәрәккый иттерү* — үстерү.

фаҗигасе турында. Аларны укып чыккач, ул вакытта да хезмәт кешесенең язмышы гаять авыр булуын күрү йөрәкне әрнетә.

Ш. Камал «Акчарлаклар» повестенда хезмәт кешеләренең күңел дөньяларындагы матурлыкны күрсәтү белән бергә, аларның очны-очка ялгарлык та матди нигез таба алмауларының сәбәбен дә ачып сала. Ул да булса — эшчеләрне яллаучыларның комсызлыгы, хезмәт иясләренә тиярен йомып калулары, үз кесәләрен калынайтулары. Кечкенә генә балык тоту артеле хуҗасыннан алып патшасына кадәр барысы да — гади халыкның хәләл көченнән үзләренә алтын ясаучылар. Гариф кебекләрне беркем дә ялкаулыкта гаепләмәс. Башкалар куркып калганда да котырынган диңгезгә кереп ятьмә салучы егетнең эшләп алганы такы-токы тамак туйдырудан артмый. Шулай булгач, Гариф, Газизә кебек образларны Ш. Камал тормыш тарафыннан җәберләнгән гади кешеләр итеп сурәтләргә дә мөмкин иде. Ләкин язучы яшьләрдә күңел матурлыгын, яшьлек кайнарлыгын күрә һәм, иң әһәмиятлесе, укучыга да сурәтләп бирә. Татарның яшәүгә, яктыга омтылуын расларга тели. Шул рәвешле, Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романы (1912) кебек романтик әсәрләр янына «Акчарлаклар» да өстәлә.

Әйе, романтизм бу еллар шигъриятендә генә түгел, прозасында да үзен шактый көчле сиздерде. Аерма шунда: шигъриятгәге романтизм яшәп килүче тәртипләргә кискен каршы чыгу рәвешен алса, прозада ул сөю-сөелүнең гүзәллеген ачуга («Акчарлаклар»), нәфис күңелле яшьләрнең рәхимсез чынбарлык тарафыннан җәберсетелүен («Яшь йөрәкләр») күрсәтүгә өстенлек бирде. Садри Җәләлнең «Дим буенда» повестенда (1914) Рөстәм, Фәридә кебек геройларның нечкә күңел кыллары аеруча нык тартылган мизгелләрен сурәтләү безнең әдәбиятта психологизмның тирәнәя баруына дәлил иде. Болар бәхетсез мәхәббәт темасына багышланган әсәрләр буларак та бер оя тәшкил итәләр.

1914 елда башланган империалистик сугыш кешеләр күңелендә аерылу, елау-сыктау, һәлак булулар белән бәйләнешле кичерешләр туугa сәбәп булды. М. Гафуриның «Солдат хатыны Хәмидә» (1915), К. Тинчуринның «Хәкимҗан агай» (1916) хикәяләрендә сугышның гади кешеләргә китергән афәте, чынбарлыкта булганча, тетрәндергеч итеп сурәтләнде.

Нәҗип Думавиның «Агач аяк» хикәясе исә (1916) бу яктан укучыда аеруча күңелсез хисләр калдыра. Ундүртенче елның урак ахырларында Шакир исемле крестьянны, йөкле хатыны белән өч баласы булуга карамастан, сугышка озаталар. Ул аннан агач аяк белән кайтканда, ике кызы үлгән, олы кызының күзләре сукырайган була. Өйдә фәкыйрьлек, ризык кытлыгы соңгы чиккә җиткән. Сәламәтлеге буенча үзе дә ярым-йорты гына булган бу атаның гаилә тормышын рәтли алачагына өмет юк.

XX йөз башындагы рус-япон сугышы, шуннан соң, ун ел үткәч, империалистик илләрнең үзара сугышып китүләре, илнең үз эчендәге инкыйлаби хәрәкәтләр — барысы да гади халыкны йончытты, тәмам хәлсезләндерде. Боларның һәммәсе 1917 елның февралендә халыкның өстендә афәт чыганагы булып утырган патша хакимиятенең тәхеттән ваз кичүенә китерде. Җәмгыятьтәге мондый кискен үзгәрешләр, күргәнебезчә, сүз сәнгате үсешендә һәм тема, һәм сәнгатьчә сурәтләү чаралары, һәм иҗат ысуллары мәсьәләләренә дә нык тәэсир итте. Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал һәм башка әдипләребез — һәрберсе үз иҗат йөзен булдырган, тормышның төрле өлкәләрен үзенә генә хас булганча сурәтләгән каләм осталары — XX йөз башы татар чәчмә әдәбиятының үсешенә зур өлеш керттеләр.

Сораулар һәм биремнәр

1. XX йөз башы татар әдәбияты алдында нинди бурычлар тора?

2. Ни өчен бу вакытта татар язучылары диңгез образына еш мөрәҗәгать итәләр? Диңгезнең романтик образы аларга нинди фикерләр һәм уй-теләкләрен әйтергә ярдәм итә?

3. Табигать ярсуы һәм кеше. Алар арасында нинди бәйләнеш бар? Кешеләрнең бер үк шартларда үзләрен төрлечә тотуының сәбәпләре нидә дип уйлыйсыз?

4. Кеше үз язмышын үзе хәл итәргә тиеш дигән сүз бар. Сез моны ничек аңлыйсыз? Язмышка буйсынуны һәм буйсынмауны ничегрәк күз алдына китерәсез?

5. Бу чор прозасында әле ныклы көрәшче образлары юк дәрәҗәсендә. Бу нилектән килә?

6. XX йөз башы әдәбиятында татар язмышын диңгездә чайкалучы кораб белән чагыштырулар булды. Ни өчен?

7. Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәренең XX йөз башы әдәбиятыбыз үсешенә ясаган тәэсирен аңлатыгыз.

8. Язучыларыбыз татар милләтенең язмышын ничек итеп күрергә телиләр?

9. Бу вакытта прозада гади кешегә игътибар арта. Моның нинди әһәмияте бар?

10. 1914 елда башланган империалистик сугыш чорының нинди күренешләре язучыларны аеруча борчыды? Бу нилектән килә иде?

11. XX йөз башы татар язучыларыннан кемнең һәм кайсы әсәре сезне аеруча җәлеп итте? Шул әсәр турында «Кеше үз заманының вәкиле» дигән темага сөйләшү уздырыгыз яки инша языгыз.

ШИГЪРИЯТ

ЯҢАРЫШ НУРЛАРЫ

Тарихта шундый чорлар була — аларда вакыйгалар шулкадәр тыгыз төенләнә, гасырлар буена салмак кына аккан вакытларда хәл ителмәгән нәрсәләр чагыштырмача тиз арада чишелеш таба. XX гасыр башы турында да әнә шулай фикер йөртергә мөмкин. Бу шул чордагы татар шигърияте үсешенә бигрәк тә нык кагыла. Кол Галидән алып Габдулла Тукайга кадәр булган сигез гасырлык зур бер дәвер аралыгында татар шигърияте, һичсүзсез, зур үсеш юлы үтте. Исемнәрен телгә алуга ук күңелдә хөрмәт уята торган Кол Гали, Котб, Хисам Кятиб, Харәзми, Мәхмүд Болгари, Сәйф Сараи, Кылыч бине Сайяди, Мөхәммәдьяр, Колшәриф, Өмми Кәмал, Мәүла Колый, Габдерәхим Утыз Имәни, Габделҗәббар Кандалый, Шәмседдин Зәки, Әбелмәних Каргалый, Мифтахеддин Акмулла — чыннан да, үз чорларының гына түгел, тулаем татар шигъриятенең үсешен тәэмин иткән талантлы шәхесләр.

Матди тормышта яисә рухи дөньяда булсын, бернәрсә дә буш урында барлыкка килми. Әгәр дә урта гасырлардагы һәм XIX йөздәге әдәбиятыбыз шулай төрле яклап билгеле дәрәҗәдә үсеш алмаган булса, XX йөз башындагы сүз сәнгате бик тиз вакыт эчендә генә алга китә алмас иде. Дөрес, һәр чор әдәбиятының үз элгәрләре белән бәйләнеше булу табигый. Ләкин шул ук вакытта аларның һәрберсенең үз йөзе, иҗади сыйфатлары бар. Урта гасырлар әдәбияты әсәрләре (хәтта XIX йөзне дә кертеп) күбрәк үгет-нәсыйхәт белән сугарылган, милли-дини эчтәлекле, дастан сыйфатларын җуймаган. Аларның кайберләрендә кеше язмыш колы буларак гәүдәләнә. Теге яки бу образ туганда ук каһарман булып дөньяга килә, аны язмыш үзе батыр, кыю, вакыйгаларны әйдәп баручы итеп мәйданга чыгара (мәсәлән, Йосыф һәм Хөсрәү образлары). Нигездә, геройлар хаким катлаулардан алып сурәтләнә. XIX йөзнең соңгы чирегендә исә әдип-шагыйрьләр мәгъри-

фәтчелек идеясен алгы планга чыгардылар. Җәмгыятьтәге гаделсезлекне әхлак төзәтү аркылы уңай якка хәл итәргә мөмкин дип карауга өстенлек бирелде. Гражданлык идеяләре үтә башлангыч хәлдә иде әле.

XX йөз башында әдәбиятның, шул исәптән шигъриятнең үсеп китүе, әлбәттә, илдәге халык азатлыгы хәрәкәтенең уңай йогынтысы нәтиҗәсендә дә булды. Шул елларда азмы-күпме матбугат һәм иҗат иреге яулану каләм әһелләре күңелен канатландырып җибәрде. Һичшиксез, бу эштә аерым талантларның шәхси сыйфатлары да зур әһәмияткә ия иде. Зарурилык олы талантларны тудырды. Аларның иң күренеклеләре Г. Тукай, М. Гафури, С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Н. Думави, Ш. Бабич, С. Сүнчәләй иде. Иҗат мөмкинлекләре артуны алар бик тиз сизеп алдылар һәм аны файдалана белделәр. Бу турыда шатлык-куанычларын белдереп язып та чыктылар.

Китте хәсрәт, әләмнәр,
Иркенләнде каләмнәр.

(Г. Тукай. «Хөррият хакында». 1905)

Мәзлүмнәргә якты, нурлы көннәр килде,—
Азатлык кояшы тугды имди.

(Г. Тукай. «Дустларга бер сүз». 1905)

Әй каләм! Шатлык белән караңны түк!
Тәбрик итеп милләтемә язам мәктүб:
Һәр җәһәттән хөрриятләр ачылганга,
Бу көндә хәсрәтемнән шатлыгым күп.

(М. Гафури. «Шатлык шигыре». 1905)

Шагыйрьләр әйтерсең лә инкыйлабның шигъри көндәлеген язып баралар. Бер генә вакыйга да аларның игътибарыннан читтә калмый. Һәрбер әсәрнең нинди дә булса чынбарлыктагы җирлеге бар. «Шатлык шигыре»нең нинди шартларда язылуын, мәсәлән, М. Гафури болай аңлата: «Октябрь җитте[1]... Революция дулкыны Казанга килеп бәрелде... «17 октябрь Манифесты»[2] чыкты. Моның бөтен кешегә тәэсире булган кебек, миңа да бик нык тәэсир итте. Һәр җирдә,

[1] Сүз 1905 елның октябре турында бара.

[2] 1905 елның 17 октябрендә шәхес иреге, сүз, җыелышлар иреге вәгъдә ителгән Манифест (реакция елларында ул ирекләр юкка чыгарыла).

шулар җөмләсеннән мәдрәсәдә[1] митинглар булды. Мин шул көннең тәэсире белән бер шигырь («Милләтемә шатлык») язып ташладым. Бу шигырьне Йосыф Акчура һәм башкалар укып ятраттылар һәм тиздән чыга башлаячак «Казан мөхбире» газетасында басарга вәгъдә бирделәр...»

Бу чор шигърияте ндә хатын-кызлардан талантлы каләм әһелләренең пәйда булуы аеруча кызыклы күренеш иде. Милли азатлык, һәр милләтнең тигез хокуклары өчен көрәш дулкынында татар хатын-кызларының да шигъри аваз бирүе табигый дип саналырга тиеш. Алар бу яктан Россиядә изелеп яшәүче Көнчыгыш халыкларына үрнәк булып тордылар. Газизә Сәмитова, мәсәлән, аларның күренеклеләреннән иде. Россия шартларында яшәүче лирик геройның күңеле шулкадәр китек, зарлы, табигатьнең иң гүзәл тавышлы кошы булган сандугач сайравы да аңа бетмәс газаплар алып килә:

Сайрама, сандугач, каршымда,
Сайрасана авыл башында.
Сандугач сайраса — күңлем тула,
Хәсрәтләрем авыр башымда,—

дип язды ул. Күрәбез, хатын-кыз каләме шигърияткә эчке кичерешләрнең тирәнлеген, нәфислеген өсти, тормыш кырыслыгын лирик төсмерләрдә ачу юнәлешен барлыкка китерә.

Мәһруй Мозаффария исә хатын-кызларыбызның, гаилә диварларыннан чыгып, киңрәк мәйданда хәрәкәт итүләрен күрергә теләде:

Һәр тугрыда ким түгелбез ирләрдән без,
Гыйлем алсак, иң галимнәренә тиңбез.
Бу милләтнең там яртысы[2] без булгачдин,
Карап карыйк иранлардин[3] ничек ким без?

(«Мәшһүр хатыннар»)

Бу шигырьне уку С. Рәмиевкә илһам бирә һәм аны «Юк, үлмим! Торам әле» дигән лирик чәчмә әсәр язарга рухландыра. «Ихтыярсыз җанландым. Яңадан торасым килә баш-

---

[1] Бу вакытта М. Гафури Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый.
[2] *Там яртысы* — нәкъ яртысы.
[3] *Иранлардин* — ирләрдән.

лады, кул селтәгән өмидләрем яңадан кайттылар. Мин тагы бик зур өмидләргә чумдым. Рәхмәт сезгә, хатыннар, мине тергездегез!» — дип яза ул.

Заһидә Бурнашева да (Гыйффәт[1] туташ) кызларның җәмгыятьтә үзләренә лаеклы урын алырга тиешлегенә нык ышана («Әниемә хат», «Сәбат[2]», «Өмиткә», «Эзлим» шигырьләре). Шул ук вакытта лирик кичерешләргә бай әсәрләр дә яза.

Иделгә охшатам мин күңелемне,
Чынында әллә аңар тиң түгелме?!
Аның төсле үк җәелгән ул еракка,
Сузылган ничә меӊ чакрым озакка.

Шулай гайрәт белән кайный да шаулый,
Бәрә дулкыннарын, һич армый-талмый.
Шулай ук ял итә ул кайчагында,
Көрәшмәс, ярышмас төсле тагын да.

(«Идел өстендә»)

З. Бурнашеваның шагыйрә булырга омтылуы якыннары тарафыннан хупланмый. Шуңа күрә ул үзенең шигырьләрен «Гыйффәт туташ» тәхәллүсе[3] астында бастырырга мәҗбүр була.

Зәйнәп Сәгыйдә, Мәфтуха Вәлидия һәм башкалар да уңышлы гына каләм тибрәтәләр. М. Вәлидия, мәсәлән, 1915 елда Казанда «Күңел бизәкләре» исемле шигырь мәҗмугасы чыгара. Китапның кереш сүзендә болай ди: «Безнең хатын-кыз галәмендә боңа кадәр шигырь мәҗмугасы тәртип иткән (язган, төзегән) ханым күрелмәдекендән булса да, бер-ике генә булдыгындан, үзебезнең арада да бер шигырь мәҗмугасы булсын вә без дә матбугаттан бөтенләй үк мәхрүм булып тормыйк нияте илә, ошбу беренче мәҗмугамны язып, мөхтәрәмә ханым вә туташларыбызның дикъкате нәзарларына[4] куям». Мәхбүбҗамал Акчурина исә бу елларда хикәяче, публицист булып таныла.

Шул рәвешле, XX йөз башында татар хатын-кызлары да матур әдәбиятыбыз сәхифәләренә үзенчәлекле бизәкләр өстә-

---

[1] *Гыйффәт* — саф, пакь, намуслы.
[2] *Сәбат* — нык тору, чигенмәү.
[3] *Тәхәллүс* — псевдоним.
[4] *Дикъкате нәзарларына* — игътибарына, каравына.

деләр, үзләре мөһим дип санаган мәсьәләләрне кыю күтәрделәр.

Шулай итеп, шигърияткә тормыш күренешләре һәм мәсьәләләре үзеннән-үзе килеп керә, әсәрләрдә публицистик рух (җәмгыятьтә барган вакыйгаларга аваздашлык) арта. Шагыйрьләр чынбарлык белән бәйләнешле уй-тойгыларын, кичерешләрен ачыграк итеп үткәрә башлыйлар (дөрес, әле дидактик, риторик әсәрләр дә иҗат ителә тора, ягъни тегене эшләмә, моны эшләмә, яхшы бул, дип өндәү, уңайны үрнәк алырга кушып тасвирлау).

Гражданлык белән мәгърифәтчелекнең бергә табигый үрелүе XX йөз башы татар шигъриятенең бер үзенчәлеге булды. Ул үзенә төшкән бурычны — сүз сәнгате ярдәмендә укучыларның милли һәм гражданлык аңнарын үстерү, икесенең бергәләп тәэсир итүе нәтиҗәсендә, аларны актив көрәшкә уятуны — уңышлы үтәде.

Эчтәлектәге үзгәрешләр сурәтләү чараларының да яңаларын тудырды. Инкыйлаб күренешләрен образлы гәүдәләндерү өчен, яңа символик сурәтләр файдаланылды. Инкыйлабны дулкынланган океан, диңгез белән тиңләштерү шигърияттә дә урын алды.

Дулкынланды океаннар бу көннәрдә,
Болгандылар күңелләр һәм бу көйләрдә;
Талпынадыр мәмләкәтнең кораблары,—
Сизенмәсәң, батып китәр бөтенләй дә.

(Н. Думави. «Революция заманы». 1906)

Русиянең көймәсеннән чыгып ярык,
Белмәенчә үзен үзе кыйлды гарык...

*(М. Гафури. «1906 елдан
1907 елга васыять». 1906)*

Диңгез якасында торып, без сусамыйк,—
Хөрриятнең диңгезләре ташый имди.

(Г. Тукай. «Дустларга бер сүз». 1905)

Йөзәм, диңгез ачу берлән
Бәрә дулкыннарын, кайный.
Сизәм көч, шул сизү берлән
Ишәм, һич кулларым талмый.

Ява яңгыр, ява кар, боз,
Чигенмим, һич исем китми.
Көләм, дим: «Әй явыз тормыш,
Чигенмим бит, көчең җитми!»

(Гыйффәт туташ. «Матлабка[1] таба». 1915)

Тормышта инкыйлаб нәтиҗәсендә барлыкка килгән үзгәрешләрне озын төн үтүгә, таң атуга, шәфәкъ аллануга, кояш чыгуга тиңләү дә еш булды.

Караңгы бары бетеп таңнар атар,
Ни сәбәпле безнең халык гафил ятар?
Һәрничек гафил яту ярамас дип,
Шигырь язды Габделмәҗид ибне татар[2].

(М. Гафури. «Алмашыну». 1905)

Тырышыйк, и хас вә гам[3],
Һәр көн үзгәрә заман;
Җитәр, йокламыйк һаман,—
Таңнар атты, бәдәвам[4].

(Г. Тукай. «Иттифак[5] хакында». 1905)

Без Бишенче елны бер көн уяндык таң белән,
Эшкә дәгъвәт итте[6] безне кемдер изге нам белән.
Эшкә ябышыр чак җитте, ямьсез озын төн үткәнен
Күз ачып белдек без, үлчәп күктәге Чулпан белән.

(Г. Тукай. «Аң». 1912)

С. Рәмиев исә инкыйлабны «Таң вакыты» дип атады. Икенче бер шигырендә кешеләрне, азатлык алу өчен, тырышлык күрсәтергә өндәде:

Таң атадыр, иптәшләр!
Эшләргә хәзерләнегез!
Бездән куәтле эшләр
Тели хәзер илебез...

(С. Рәмиев. «Таң ата, эшлик, туганнар». 1906)

---

[1] *Матлаб* — максат, тоткан юл.
[2] *Ибне татар* — татар улы.
[3] *Хас вә гам* — барыгыз да, барлык халык.
[4] *Бәдәвам* — өзлексез.
[5] *Иттифак* — берләшү.
[6] *Дәгъвәт итте* — чакырды, өндәде.

Таң ату (инкыйлаб) вакытында шагыйрьнең бурычы — халыкны уяту. Мәчет манарасыннан азан әйтеп, гавамны намазга чакырган мәзин кебек, шагыйрь дә шундый ук өндәүче булырга тиеш. С. Сүнчәләй «Азан» шигырендә шагыйрьнең бурычын шулай аңлавын күрсәтте:

Мен манараң өстенә, хәсрәтле җырчы, әйт азан!
Моң белән яңрат, уят тизрәк татарлар дөньясын!
Үтте төн, бетте: кояш чыгышында инде атты таң;
Җитте йоклау! Һәммәсе торсын да тизрәк уйласын!

Аның герое таң атуын тагын да тизләтергә тели:

Бер очкын-чаткы юк алда.
Һаман иске суыклык, тын.
Торам кычкырганым хәлдә:
— И таң, тиз ат! Кояш чыксын!

Күргәнебезчә, шагыйрьләр үгет-нәсыйхәт бирәләр, шул ук вакытта халыкны хәрәкәт итәргә, гамәлгә өндиләр. Моның матур үрнәген М. Гафури бирде:

Йә татар! Вакыт йитте кузгалырга,
Мәгариф шәмгыданын[1] кулга алырга;
Тәфәккерсез, гафил булып[2] карап ятмый,
Вакыт йитте гыйлем, һөнәр кулланырга!

(«Өндәү». 1905)

Бу вакыттагы шигъриятгә ватанпәрвәрлек, ягъни туган җирне, илне ярату мәүзугы[3] да еш күтәрелде. Г. Тукайның «Туган җиремә», «Китмибез!» (1907) шигырьләре укучыларга аеруча билгеле. Башка авторларыбызның да бу турыда матур-матур әсәрләре бар. Күренекле татар шагыйре үзенең туган халкына мөнәсәбәтен менә болай әйтеп бирде:

Аппак алтын җырларымны
Җырламыйм данлык өчен,
Җырлаем алтын илем,
Үз туган халкым өчен.

(Ш. Бабич. «Халкым өчен». 1914)

---

[1] *Шәмгыдан* — шәмдәл.
[2] *Тәфәккерсез, гафил булып* — уйсыз-фикерсез.
[3] *Мәүзугы* — темасы.

Россия изелеп яшәгән халыкларга ватан була алмый. Ш. Бабич «Хөррият бүләге» шигырендә (1917) моны ачык итеп әйтеп бирде:

Өч йөз ел аh ордың, Ватан дип,
Җан кыйдың, кан койдың, Ватан дип,
Шулай да ертылды намусың,
Сүгелдең: «Былчырак татар!» — дип.

Ш. Бабич та 1917 елгы вакыйгалар халыкка иркенлекләр китерер, ил татар өчен чын мәгънәсендә ватан булып әверелер дип ышанды:

Ябылды капусы сәкарьнең[1],
Ачылды җәннәте Ватанның,
Чәчелде хуш hава, хөр hава...
Бу инде көткәне татарның!..

Боларның hәммәсе шигърияттә азатлык хисләре белән илhамланган романтик герой тууга китерде. Бу геройның күңел дөньясы, җәмгыятьтә бара торган вакыйгаларга карап, үзгәреп торды. 1905—1906 елларда, ягъни инкыйлаб үзенең иң югары дәрәҗәсенә җиткәндә, ул — алга омтылышлы, үз-үзенә, халкына ышаныч белән караучы. Без моның мисалларын әле генә күреп үттек. Инде, инкыйлаб җиңелә барып, кара көчләр өскә калка башлагач, әлеге кешеләрнең күңелендә төшенкелек авазлары сызланды. Г. Тукайның лирик герое: «Минем гомерем караңгы төн. Кояшым hәм аем тугъмас»,— дип әрни («Күңел йолдызы». 1909). «Өмид» шигырендә (1908) ул әле киләчәкнең матуррак булырына ышана иде:

Юк, кояшым, мин беләм: син батмагансың мәңгегә;
Син дә, вөждан, бер торырсың: ятмагансың мәңгегә.

М. Гафуриның лирик герое да шуңа аваздаш уй-хисләр кичерә:

Сине кыса, вата хурлыклы тормыш,
Тирә-якны җылан берлән тутырмыш!
Тамыр җәй! Яфрак яр! Курыкма, тиз үс,
Бетәрмен димә, әй дус, булма мәэюс![2]

(«Алдагы өмид». 1909)

---

[1] *Сәкарь* — тәмуг.
[2] *Мәэюс* — өметсез.

С. Рәмиевнең лирик герое киләчәккә ышанычлы карый:

Һәм, караңгы көн бетеп бер,
Мәңге якты ай туар!
Тугмый калмас, бер туар ул,
Идеалым күренер әле!

(«Дөньяга». 1909)

Игътибар итегез, әгәр башка шагыйрьләрнең геройлары кояш чыгуын көтсәләр, С. Рәмиев герое «якты ай туар» ди. Бу шуның белән бәйле: С. Рәмиев — үтә романтик шагыйрь. Ә романтиклар шигърияте күбрәк айдан табалар. Әнә шул рәвешле һәр шагыйрьнең үз йөзе, үз өслүбе[1] барлыкка килә. Г. Тукай сатирик юнәлешне үз итсә, М. Гафури сәяси лирикага йөз тота.

Шигъриятнең халыкка якыная төшүе, әсәрләрдә кешелеклелек хисләре артуы, тәнкыйть юнәлешенең көчәюе бу еллар әдәбиятының иң төп билгесе иде. Болар арасында Г. Тукай белән М. Гафури аеруча аерылып тордылар. «Сәрләүхәсез[2]», «Эштән чыгарылган татар кызына», «Алтынга каршы», «Яхшы хәбәрләр», «Яратырга ярый», «Сайфия», «Көзге җилләр», «Золым» (Г. Тукай), «Электрик фонарена хитаб[3]», «Базарга чыктым!», «Татар хатыны», «Бай һәм хезмәтче», «Байлар алдында», «Кызганам», «Хәерче», «Ярлы», «Ярлы бабай» (М. Гафури) кебек шигырьләр чын мәгънәсендә халык гаме белән сугарылганнар. Шунысы кыйммәтле: шагыйрьләр бу әсәрләрдә кеше күңеленең түрендә яткан хис-кичерешләргә игътибар иттеләр, лирик геройларның авыр шартларны тирән кичерүләрен тасвирлауга өстенлек бирделәр. Тормышка тугрылык күпчелек каләм әһелләре өчен төп канун иде. Г. Тукайның:

Караны яз кара дип һәм
Игътираф[4] ит акны ак,—

дигән сүзләре күпчелек шагыйрьләр өчен уртак иде («И каләм!..»).

Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә,
Мәгълүмдер ки, курку берлән өркү харам.

(Г. Тукай. «Бер татар шагыйренең сүзләре»)

---

[1] *Өслүб* — стиль.
[2] *Сәрләүхәсез* — исемсез.
[3] *Хитаб* — эндәшү, мөрәҗәгать.
[4] *Игътираф* — тану.

Әйе, каләм әһелләренә мондый ныклык, кыюлык ул вакытта аеруча кирәк иде.

Бу еллар шигърияттендә романтизм да үзен нык сиздерде. Моны С. Рәмиев, Дәрдемәнд кебек үтә романтик шагыйрьләрдә генә түгел, башка сүз сәнгате осталары иҗатында да күрергә мөмкин иде. С. Рәмиев 1909 елда, А. Пушкинның «Пәйгамбәр» әсәренә ияреп, шул исемдәге шигырь иҗат итте. Бу шигырьнең әһәмияте шунда: шагыйрь татар әдәбиятына хас гыйсъянчы (баш күтәрүче) романтик образын тудырды. Бу геройга хисләрнең артык кайнарлыгы, шул сәбәпле аның һәммә нәрсәне инкяр итү юлына басуы хас иде. Аның:

Бизәм шунда тәмам чын-чын күңелдән
Бу дөньяның бөтен җир һәм күгеннән,—

диюе моны раслап тора. Ялгызак горурлык — романтик геройның төп билгесе. Ул үзен гавамга каршы куя, шул ук вакытта изүчеләрдән дә, изүгә каршылык күрсәтмичә яшәүчеләрдән дә читләшә. Гаять бай хыял, матурлыкка ашкынган күңел һәм үзен чолгап алган шыксыз, үтә түбән тормыш. Менә шушы ике каршылык романтик герой күңелендә өермә, хис давылы тудыра, шулар аның эш-хәрәкәтләрен билгели. Г. Тукайның «...гә (Ядкяр)» шигырендә (1908) романтик шагыйрь образы аеруча ачык итеп сурәтләнгән.

Итмә үз тормышны; тап башка җиһан, башка хәят;
Дөньяның буш шау-шуы шагыйрьгә чит, шагыйрьгә ят.
Бел: килешмидер сиңа бу вак мәгыйшәт, вак тормыш;
Чөнки мәңгегә очалмас, йортта күп асралса кош.

Әйе, Г. Тукай да романтик шагыйрь дип саналырга хаклы. «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре», «Татар яшьләре», «Даһигә» кебек шигырьләре безгә шулай әйтергә мөмкинлек бирә. М. Гафуриның «Бәхет эзләү» әсәрендә дә романтик герой тудырылды. С. Сүнчәләй, Ш. Бабичларны да һәм реалист, һәм романтик шагыйрь дип атый алабыз.

Күкләр очармын!
Йолдыз үбәрмен!
Диңгез кичәрмен,
Теләсә нишләрмен!
Мин — ирек ханы,
Кошы-солтаны!

Ш. Бабичның «Дөньяга» (1915) шигыренең бу героен гыйсъянчы дип карамыйча булмый.

С. Сүнчәләйнең «Дога» (1911) исемле тәрҗемә әсәрендәге лирик герой, Аллаһы Тәгаләгә ялвара-ялвара, халыкка мәрхәмәтле булуын сорый:

И Ходаем, бир халыкка якты көн!
Рәхмәтең берлә сыйла аның эшен!

Нык нигезлә халыкларның хөрлеген,
Чәч аларга тугрылыкның орлыгын.

Яктылыкка эт аларны тиз генә,
Нурлатыр аларны тугры эз генә.

Шул рәвешле, XX йөз башы татар шигърияте үз заманының мәнфәгатьләрен кайгыртты, халык гаменең чагылышы булды. Дөнья әдәбияты үсеше кануннары аның өчен дә ят булмады. Иҗатта төрле юнәлешләр, алымнар эзләү, кыю тәҗрибәләр ясау күзәтелде. Татар шигърияте һәм өлгергән мәсьәләләрне яктырту, һәм сәнгатьчә камиллек ягыннан югары үсешкә иреште. Г. Тукай исеме үзәктә торган бу еллар лаеклы рәвештә сүз сәнгатенең икенче Яңарыш чоры дип аталды.

Сораулар һәм биремнәр

1. XX йөз башында шигъриятнең тагын да тизләтелгән үсешенең нигезләре һәм сәбәпләрениләрдән гыйбарәт?

2. Урта гасырлар, XIX йөз һәм XX йөз башы шигъриятләре арасында нинди аермалы һәм уртак яклар бар?

3. Татар шагыйрьләре иҗатында нинди мәсьәләләр күтәрелә?

4. «Шигырьләр — чынбарлыктагы кайнар вакыйгаларның көндәлеге» дигән темага сөйләшү уздырыгыз.

5. Шигырьләрдә публицистик рух дип нәрсәгә әйтәбез? Шул чор шигъриятеннән мисаллар китерегез.

6. XX йөз башы шигъриятенең үзенчәлекләрен әйтегез.

7. Сурәтләү чарасы буларак, диңгезнең дулкынлануы, шәфәкъ аллану, таң ату, кояш чыгу, ай калку кебек күренешләрне тасвирлауга шагыйрьләр нинди эчтәлек салдылар?

8. С. Сүнчәләй шагыйрьне мәчет манарасына менеп азан әйтүче мәзингә охшата. Шагыйрь белән мәзин арасында мондый уртаклык табу нәрсәгә нигезләнә?

9. Туган җирне, халыкны ярату турында язганда, шагыйрьләр ватанпәрвәрлек фикерләрен ни рәвешле әйтәләр, ягъни моның өчен нинди сәнгатьчә чаралар кулланалар?

10. Кара көчләрнең өстенлек алуы вакытында әсәрләрдә чагылыш тапкан уй, хис-тойгыларны тасвирлагыз.

11. Тормышка тугрылык — бу чор шагыйрьләренең тагын бер әһәмиятле сыйфаты. Әсәрләр ярдәмендә шуны дәлилләгез.

12. Гыйсъянчы геройны сез нинди сыйфатларга ия итеп күз алдына китерәсез?

13. Романтик шагыйрьгә хас сыйфатларны атагыз.

14. С. Сүнчәләй «Дога» шигырендә, бәхетле булу өчен, халыкка үтә кирәк булган нәрсәләрне атый? Шуларга ирешү өчен, җәмгыять һәм аерым кешеләр тарафыннан ниләр эшләргә кирәк иде?

Габдулла Тукай *(1886—1913)*

«Салдың безне ак юлга»

Сөекле шагыйребезнең исемен телгә алуга, аның «Исемдә калганнар» дигән язмаларында бәян ителгәннәр хәтергә килә. Шуларга менә бу мәгълүм юллар өстәлә:

Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!
Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем.

Әйе, 1886 елдан алып 1895 елга кадәр, ягъни Җаекка килгәнче, кечкенә Габдулла бик күпләр озын гомер кичереп күрмәгәннәрне башыннан үткәрә. 1886 елның 29 августында (яңа стиль белән 10 сентябрьдә) әтисе Мөхәммәтгариф үлеп китә. Бу вакыт Габдуллага (тулы исеме Габдуллаҗан) дүрт ай ярым була. Әнисе, ире үлгәч, бер елга якын Кушлавыч авылында яши, шуннан соң гына, улын алып, Өчилегә — әтисе Зиннәтулла йортына кайта. 1888 елның 22 декабрендә әнисе Мәмдүдә Сасна Пүчинкәсе мулласына кияүгә чыга. Улын вакытлыча Кушлавыч авылының Шәрифә исемле бер ярлы карчыгына калдыра. 1889 елның язында Габдулланы әнисе үз янына алдыра. Ләкин озак үтми, Габдулла әнисез дә кала — 1890 елның 18 (30) гыйнварында егерме биш яшендә әнисе дә үлеп китә. Шул ук елның февраль аенда (март булуы да мөмкин) малай тагын Өчилегә кайтарыла.

1891 елда Идел буенда бик каты корылык була, халык ач кала. Ачлык 1892 елда да дәвам итә. Бабасының өендә болай да алты бала үсә. Кечкенә генә авылның фәкыйрь мулласы өчен гаиләдә тагын бер тамак арту, күрәсең, авыр тоела. Җит-

мәсә, бала чәчәк һәм башка авырулар белән җәфалана. Габдулланы Казанга озаталар. Аны асрамага Яңа Бистә һөнәрчеләре гаиләсе ала. Мөхәммәтвәли белән Газизә малайны бик кадерләп тәрбиялиләр. Ләкин авырып китүләре сәбәпле, баланы ике елдан соң тагын Өчилегә кайтаралар. Ниһаять, 1892 елның июнендә малай Кырлай авылына — Сәгъди абзый белән Зөһрә апа гаиләсенә килеп керә. 1894—1895 еллар арасындагы кышта исә аны инде Җаекка алып китәләр. Ул анда унике ел яши. Шунда егет булып җитешә, шагыйрь буларак таныла.

Габдулланың иң беренче мөгаллимәсе — Кырлай авылы остабикәсе Маһруйбикә абыстай. Әлифбаны ул аңардан өйрәнә. Аннан соң аны Кырлайдагы хатиб һәм мөгаллим Фәтхерахман хәзрәт Гатаулла укыта. Ул Габдуллага атна саен биш тиен акча биреп бара. Өченче мөгаллиме — Җаектагы Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтулла. Ул да Габдулланы үз канаты астына алып, һәрвакыт җылы мөнәсәбәтен сиздереп тора. Моның сәбәбе бар: Габдулланың этисе Мөхәммәтгариф белән Фәтхерахман да, Мотыйгулла да Кышкар мәдрәсәсендә бергә укыганнар, дус булганнар. Шуңа күрә иртә вафат булган дусларының баласына алар әнә шулай җылылык күрсәтергә тырышканнар.

Г. Тукай 1907 елда, ашкынып, «дәртле», «моңлы», «нурлы» Казанга кайта.

Билгеле булганча, Г. Тукай 1909 елда, үзе әйткәнчә, «берничә нәширләрнең язып бирергә үтенүләре» сәбәпле, тәрҗемәи хәлен «Исемдә калганнар» дигән истәлекләрендә бәян итә. Ләкин бу әсәр шагыйрьнең Җаекка килүен сурәтләү белән генә тәмамлана. Димәк, 1895 елдан алып 1913 елга кадәр булган унике ел вакытта кичергәннәре кермәгән. Г. Тукай «Исемдә калганнар»ның дәвамын да язарга тиеш булган. Әлеге истәлекләргә язган кереш сүзендә (мөкаддимәдә) ул болай ди: «Уральскига килеп җиткәнемә кадәр кичердекем хәлләр илә аннан соң хәзер шушы сәтырларны[1] язып утырган вакытыма кадәрге башыма килгәннәрне икесен ике рисалә[2] итеп чыгарырга мәгъкуль күренде». Күрәсең, шагыйрь вәгъдә ителгән икенче рисаләне яза алмаган. Ләкин тормышының бу чоры турында берни дә язмаган дип тә әйтеп булмый. Сәяхәтнамәләре, төрле истәлекләре, хатларына нигезләнеп,

[1] *Сәтыр* — юл.

[2] *Рисалә* — китап.

аның әлеге еллардагы күргән-кичергәннәрен дә шактый ачык итеп күзалларга мөмкин.

Җаекка Габдулланы этисенең сеңелесе Газизә апасы белән аның ире Галиәсгар җизнәсе эзләтеп алдыралар. Берничә елдан, җизнәсе үлгәч, ундүрт яшьлек малай торырга «Мотыйгыя» мәдрәсәсенә күчә, ягъни үз көнен тулысынча үзе күрә башлый.

Тормышының бу вакытында аңа Мотыйгулла хәзрәт матди һәм рухи ярдәм итүче була. Үзенең яшьлек дустының улын ул бик якын итә, йортына ияләштерергә, ашау-эчү якларын, кием-салымын кайгыртырга тырыша. Мотыйгулла хәзрәтнең улы Камил язганча, «әткәй ул вакытта Уральскида имам вә ахун булып торганга күрә, кулындагы русча языла торган бөтен хезмәтләрене диярлек Габдуллага кушып, шул хезмәтләре өчен аңарга мәдрәсәдә бер дә ихтыяҗ күрмәслек дәрәҗәдә акчалар бирә иде».

Габдуллага шигырь иҗат итү серләрен беренче булып өйрәтүче дә — Мотыйгулла хәзрәт. Бу күп яклап галим кеше борынгы Көнчыгыш фәлсәфәсе һәм шигърияте, астрономия буенча да тирән мәгълүматлы кеше була. Алар еш кына бу өлкәләр буенча озак-озак сөйләшеп утыралар. Улы Камил исеменә сатып алган типографиядә дә Габдулла төп хезмәтләрне башкара. К. Мотыйгый болай яза: «Мин шул елны (1905 ел. — *Ф. Г.*) 27 ноябрьдән башлап «Фикер» исемле газета чыгара башлагач, аны шул газетага мөсәххих[1] итеп куйдым. Габдулла әфәнденең хезмәтләре миңа бик ягымлы һәм үзе дә фәукыльгадә[2] иҗтиһатлы[3] булганга күрә, мин аның жалуниясен һәр ай саен арттыра бара идем. «Фикер» газетасының иң әүвәлге номерында аның «Ник йоклыйсың, мужик?» исемле шигыре басылып чыкты. Соңра, 1906 ел башында, мин «Әлгасрелҗәдит»[4] журналы чыгара башладым. Аның да иң әүвәлге номерында Габдулла Тукаевның «Алла гыйшкына» исемле шигыре басылды. Мәзкүр[5] ел ахырында «Уклар» нам[6] һөҗү[7] журнал чыгара башладык. Аңарга да

---

[1] *Мөсәххих* — корректор.
[2] *Фәукыльгадә* — гадәттән тыш.
[3] *Иҗтиһатлы* — тырыш.
[4] *«Әлгасрелҗәдит»* — «Яңа гасыр».
[5] *Мәзкүр* — шушы, әйтелгән.
[6] *Нам* — исемле.
[7] *Һөҗү* — сатирик.

Габдулла Тукаев күп шигырьләр чыгарып бастырды. Шулай итә-итә, акрынлап Габдулла Тукаев, минем матбагамда[1] иң әүвәл наборщик булып кергән дәрәҗәсеннән... соңра бик тизлек илә ...газета-журналларның иң моктадир[2] шагыйрь вә мөхәррире дәрәҗәләренә ирешеп, бөтен эшне үз кулына алырга якынлашты».

Ләкин 1907 елның февралендә әлеге типография патша хакимиятләре тарафыннан ябыла. К. Мотыйгый эзәрлекләнә. Типография башка берәүгә сатыла, эшен барыбер озак дәвам иттерә алмый.

Шагыйрь, язучы булып үсү өчен, талантың булу өстенә, язган әйберләреңне бастыру мөмкинлеге дә кирәк. Күргәнебезчә, Төхфәтуллиннар гаиләсе (аталы-уллы Мотыйгулла белән Камил) Габдуллага үзләренең газета-журналларында уңай шартлар тудыралар.

Җаек ул вакыттагы казах ягы шәһәрләре арасында иң зурысы исәпләнә, анда утыз алты мең кеше яши, шуларның дүрт меңгә якыны татар була. Тирә-якта яшәүчеләрнең күпчелеген казахлар тәшкил итә. Габдулла кайвакытта казах далаларына чыгып керә. Мәсәлән, әле мәдрәсәдә укыган вакытта, Җаектан сиксән чакрымдагы Дәвана дигән җиргә кымыз эчеп дәваланырга бара, анда унбиш көн тора. Бу җирләрдә күлләр күп икән, Габдулла балык тота, балыкларын казах балаларына тарата. Ул вакытта казахларның ир балалары алты-җиде яшькәчә бөтенләй ялангач йөргәннәр. Габдулла бер казах хатынына сөлгесе белән тастымалын биреп калдыра. Үзе болай ди: «Зурына күлмәк, кечкенәсенә ыштан тегеп киерт».

Габдулла шулай җирле халык белән аралаша, тугандаш казахларның җырларын тыңлый, аларны язып ала. Үләңнәрне[3] нечкәләп өйрәнү ярдәмендә, төркиләрнең борынгы чорлардагы җыр сәнгатен күзалларга омтыла. «Халык әдәбияты» исемле хезмәтендә дә ул кыргыз (казахларны ул вакытта шулай дип атаганнар) җырлары турында яратып искә ала.

Казанга кайткач, Г. Тукай әдәбият мохитенә чума. Галиәсгар Камал белән бергә «Яшен», «Ялт-йолт» журналларын оештыра, Фатих Әмирхан нәширлегендә чыга торган «Әлислах» газетасында еш язышa. Башка вакытлы матбугат органнары белән дә якын элемтәдә тора. Казанда аның иҗаты тагын

---

[1] *Матбагамда*— нәшриятымда.

[2] *Моктадир* — көчле, сәләтле.

[3] *Үләңнәрне* — казах җырларын.

да активлаша. Сәнгатьчә югары дәрәҗәдә язылган күпчелек әсәрләре шушында туа. Ул вакытта Казанда яшәп иҗат итүче әдәбият әһелләре белән бик тиз аралашып, дуслашып китүе дә аның каләменең үткенләнүенә йогынты ясый.

Без Г. Тукай әсәрләрендә халык өчен кирәкле мәүзугларның күтәрелүенә, аларның кыю фикерләргә, аңа кадәр очрамаган сурәтләү чараларына бай булуына игътибар итәбез. Билгеле булганча, каләм әһеленең иҗат өслүбе аның үз шәхесе белән тыгыз бәйләнгән. Әйдәгез, Казанга кайткан шагыйрьнең замандашлары күңелендә беренче очрашудан туган тәэсирләр белән танышыйк.

Г. Камал: «Көннәрнең берендә кечкенә генә гәүдәле, өстенә «абыйсының бишмәтен кигән шикелле» кием кигән, өтек кенә бер малай редакциягә керде дә («Йолдыз» газетасы редакциясенә.— *Ф. Г.*) өстәл өстендәге газеталарны актара башлады.

Бераз утыргач:

— Безнең газета-журналлар сезгә килә торгандыр бит?— диде.

— Сезнең нинди газета?

— «Фикер», «Әлгасрелҗәдит», «Уклар».

— Сез Уральскиданмыни?

— Әйе.

— Алай булгач, ...Габдулла Тукайны да бик яхшы белә торгансыздыр?

Малай елмайды да:

— Ул Апуш мин булам,— дип әйтмәсенме?!»

С. Рәмиев: «Номер ишегемне ачып:

— Сәгыйть әфәнде Рәмиев шушында торамы?— дип, бер малай килеп керде.

Карадым: яланбаш, кара күзлектән, өстенә казакимы, җөббәме[1], иске генә бернәрсә кигән бер малай, минем «ие» дигән сүземне дә көтмичә, каршымда, өстәл кырыенда, буш торган урындыкка килеп тә утырды...

Кинәт кенә үзенә таба әйләндем дә:

— Соң сез кем буласыз?— дидем.

— Габдулла Тукаев булам,— диде.

— Соң, кергәч тә шулай дип әйтсәгез ни була! Мин сезне икенче төрлерәк каршы алган булыр идем. Әй Тукаев, Тукаев! — дип, торып, үзе берлә яңадан күрештем.

---

[1] *Җөббә* — ирләр кия торган киң җиңле озын күлмәк.

Аның төсе коңгыр[1] иде. Бәдәне зәгыйфь кенә булса да, әгъзалары бер-берсе илә бик мөнасип[2], бер күзенә ак төшкән булса да, ямьсез түгел, бәлки уртача матур, биек маңгайлы; борыны килешле вә һәрдаим тулы булып ачылып торган зур күзле иде. Казанга килгән чакларында егерме бер-егерме ике, вафаты елында егерме җиде яшьлек булса да, һаман ундүрт-унбиш яшьлек бала кебек кенә күренә иде.

Мәрхүм әйләнәбездә булган һәммә тәзаһарәт[3] хәрәкәтләрдән бик мөтәәсир була[4]. Яратмаган кешеләренә каты бәрелүдән, хәтерләрен калдырудан бер дә тартынмый иде. Тарафдарларын һәммә гаепләрдән арындырырга тырыша».

Фатих Әмирхан: «Әүвәле күрешү миндә Тукаев хакында бер билгеле тойгы калдыра алмады. Тукайны мин үзем белгән татар яшьләре типларыннан берсенә дә нисбәт бирә алмадым. Аның әллә нәрсәсе минем күзләрдән, аңлаштан өртүле калган[5] шикелле булды. Ул ...дөрес сүзле, гакыл вә мантыйктан[6] бигрәк, хискә бина итә[7] торган, тормышында садәлекне һәрнәрсәдән алда күрә торган кеше иде». Ф. Әмирхан тагын болай дип өстәп куя: «Тукай — хис белән генә тора торган кеше. Без аның белән мәхрәм[8] дуслар булып киттек»[9].

Әйе, Г. Тукай үз чорының иң талантлы, әдәбият һәм сәнгать мәйданында үзе кебек ат уйнаткан Г. Камал, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй, Г. Кариев, К. Мотыйгый һ.б. шәхесләр белән аралашып яши, алар белән фикердәш, сердәш, иҗатташ, хезмәттәш була (Гаяз Исхакый бу чорда Казанда озак яши алмый). Аларның бөек шагыйрь турында һәр язганы безгә аның шәхесен аңлауда ачкыч булып хезмәт итә.

Еш кына ул истәлекләрдә шагыйрьнең бер үк вакытта балалар кебек беркатлылыгы, самимилеге, инде сабыйлыктан күптән чыккан булса да, малайлар белән мавыгып кузна уйнавы, карусельгә утырып әйләнергә яратуы турында бәян

---

[1] *Коңгыр* — коңгырт (сүз чәч төсе турында бара).

[2] *Мөнасип* — туры килә, яраша.

[3] *Тәзаһарәт* — күренеш.

[4] *Мөтәәсир була* — тәэсирләнә.

[5] *Өртүле калган* — читтә калган, аңлашылып бетмәгән.

[6] *Мантыйк*— логика.

[7] *Бина итә* — нигезләнә.

[8] *Мәхрәм* — сердәш.

[9] Мәкалә һәм башка истәлекләрне әлеге китаптан укырга мөмкин: *Габдулла Тукай*. Сайланма әсәрләр / Төз. *Ф. Г. Галимуллин*.— Казан: Тарих, 2002.

итәләр. Моңа гаҗәпләнергә ярамый. Шагыйрь күңеле, шагыйрь йөрәге еш кына башкалар өчен үзенә күрә сер булып кала. Шагыйрьләрнең шагыйре булган Г. Тукайда бигрәк тә. Туры сүзлелеге, кемнең кем булуына карамастан сүзен кистереп әйтүе, шулар турында әсәрләрендә курыкмыйча язуы — шулай ук Г. Тукайның аерылмас сыйфаты. Күрәбез, садәлек, йомшак күңеллелек, хәтта бераз баласымаклык аңа җитди һәм үткен телле булырга, югары сәнгатьлелеккә ирешергә комачауламаган. Ягъни табигать баласы булуы аңа үз чоры каршылыкларын сизгер тоярга һәм алар турында ихлас язарга ярдәм иткән.

Замандашларының истәлекләрендә Г. Тукайның хатын-кызга мөнәсәбәте турында да еш язалар. Матурлыкны күрә һәм нечкә итеп бәяли белүче, күңеле кешеләргә карата җылы хисләр белән тулы шагыйрь, әлбәттә, хатын-кыз нәфислеген дә күргән, аның турында гүзәл итеп язган. Егерме яшьлек Г. Тукай «Гыйшык бу, йа!» шигырендә болай яза:

Бер гидае җан фидаем, гыйшкыңа пәрванаем;
Кәл, гүзәл, гарз ит җамалең: янаем, кил, янаем.

Вир серүр мәсхүреңә, бер кәррә бундин ит мөрүр;
Хаке паеңдә сәнең ауланаем, ауланаем.

Ягъни:

Җанын фида иткән фәкыйрьмен, гыйшкың күбәләгемен;
Кил, гүзәл, күрсәт матурлыгың: янаем, кил, янаем.

Сихерләнгәнне шатландыр: үтче алдымнан бер кат;
Синең аяк туфрагыңда тәгәрием, тәгәрием.

Яки менә «Татар кызларына» дигән шигырьдән өзек укып карыйк (шулай ук 1906 елда язылган):

Сөям сезнең сызылган кашыңызны,
Тузылган сачыңызны, башыңызны.

Яратам тәмле, татлы сүзеңезне,
Зөбәрҗәт төсле якты күзеңезне.

Сөям кәүсәрдән әхля[1] ирнеңезне,
Бу мактауга ризалык бирдеңезме?

---

[1] *Кәүсәрдән әхля* — кәүсәр елгасының суыннан да татлырак.

Сөям кысмыйча нечкә биленңезне,
Ничек дисә дә аз тәмсилеңезне[1].

Сөям бигрәк, хосусән[2], садреңезне[3];
Ни соң ул: шәмсеңезме[4], бәдреңезме[5]?

Сөям кочмакга[6] мәрмәр муйныңызны,
Сөям оҗмахка биңзәр[7] куйныңызны.

Күрәбез, шагыйрь үзенең сөю хисләрен нинди матур сүзләр белән әйтеп бирә алган. Әйе, гашыйк булган кеше матур була. Бу вакытта аның сөйләме дә нәзакәтлелеге, бизәклелеге һәм гадәти генә булмавы белән аерылып тора. Шагыйрьнең лирик герое да нәкъ шундый кеше булып күз алдына килеп баса. Менә тагын бер мисал:

Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк,—
Парә-парә кисмәсә гыйшык-мәхәббәт кайчысы.

Әмма ләззәтле дә соң яшьрен газап, яшьрен яну!—
Бар микән, белмим, моның миннән бүтән аңлаучысы?

(«Мәхәббәт»)

Ләкин шул ук вакытта, каләмдәшләренең язуына караганда, Г. Тукай хатын-кыз күзенә бик чалынырга яратмаган. Ни өчен? Чөнки үзен — ябык кына гәүдәле, бер күзенә ак төшкән егетне — бу гүзәл җан ияләре тиң күрмәсләр дип уйлаган. Хатын-кызның күзе иң элек ир-егетнең тышкы кыяфәтенә төшә, синең турыда килеш-килбәт буенча хөкем йөртә дип ышануы аңа шактый күңел газаплары алып килгән. 1910 елдан үпкә чире белән интегә башлавы да моңа сәбәп булган. Кыскасы, табигате белән горур егет хатын-кыз каршында кызганыч хәлдә калырга теләмәгән. Аның бу омтылышын, әлбәттә, аңларга була.

Сәламәтлеккә туймау, матди яктан шактый кысынкылыкта яшәү күңеле белән әллә кайларга ашкынган Габдуллага сәяхәт кылырга да ирек бирмәгән. Кечкенә генә үз фатиры да булмаганга күрә, ул «Болгар», «Амур» кебек кунакханәләрдә

---

[1] *Тәмсилеңезне* — чагыштыруыгызны.
[2] *Хосусән* — аерым алганда.
[3] *Садреңезне* — күкрәгегезне.
[4] *Шәмсеңезме* — кояшыгызмы.
[5] *Бәдреңезме* — тулган аегызмы.
[6] *Кочмакга* — кочарга.
[7] *Биңзәр* — охшаш.

яшәргә мәҗбүр булган. Кешенең үз почмагы булмыйча, гомере буе кайда туры килсә, шунда җан асравы — бик тә кыен хәл. Г. Тукай шушы җайсызлыкларга үч итеп, үҗәтләнеп иҗат иткән, каләмен үләренә бер тәүлек кала гына читкә куйган. Г. Тукайның, эшем бетте дип, кул кушырып утырганын беркем дә хәтерләми. Ул я яза, я уйланып утыра, я «борын очын тирләтә-тирләтә» эшләп йөри, яки каләмдәшләре һәм башка кешеләр белән бәхәсләшә. Ләкин сөйләгән һәр сүзе диярлек әдәбият, шигърият турында, борчылганы татар тормышы, аның бүгенгесе һәм киләчәге турында. Үзенең яшәү шартларын җайга салу, киләчәген тәэмин итү турында гамендә дә юк. Чөнки дөньяда яшәүнең мәгънәсен ул үзенчә аңлый:

Тормак ярый: бертуктаусыз ялганласаң,
Тугъры сүзле инсаннарга ялганмасаң,
Вөҗданыңнан шәйтан төсле тыр-тыр качып,
Үзең алдап, башкалардан алданмасаң.

*(«Дөньяда торыйммы?— дип
киңәшләшкән дустыма»)*

Туры Тукай бу шигырьдә язылганча яши алмый. Ялганлау, вөҗдансызлык чын шагыйрь эше түгел. Ә намуслы юл белән яшәп булмый икән:

И Җир шары! Нидән, белмим, хак сөйгәнгә
Мең кат синең өстеңнән дә астың яхшы.

Ләкин бу Г. Тукай якты дөньяда яшәү-яшәмәү мәсьәләсенә битараф булган дигән сүз түгел. Аның янә ике-өч ел гына булса да яшәп калу омтылышы көчле була. Әмма тузган тәнендәге әгъзалары инде аның теләгенә буйсынмый. 1913 елның 26 февралендә[1] ул Клячкин шифаханәсенә (айга 150 сум түләп) кереп ятарга мәҗбүр була. Ләкин бер айдан аз гына артык вакыт үткәч, икенче апрельдә кичке тугызынчы унбиш минутта аның йөрәге тибүдән мәңгегә туктый.

Ул көннәрдә халык шагыйре Г. Тукай рухына багышланган бик күп шигырьләр, мәкаләләр, истәлекләр языла. Шәехзадә Бабич, аларда әйтелгән төп фикерләрне җыеп, болай диде:

Әй хөрмәтле Габдулла, ярлыкасын сине Алла,
Шигырең белән рухландырып салдың безне ак юлга.

---

[1] Иске стиль белән.

Сораулар һәм биремнәр

1. Г. Тукайның түбәндәге истәлекләрен һәм юлъязмаларын (*Г. Тукай.* Әсәрләр, 5 томда) укыгыз һәм аның тормыш юлындагы шикыйгаларны билгеләгез:

1) Исемдә калганнар;
2) Кечкенә сәяхәт;
3) Мич башы кыйссасы;
4) Казанга кайтыш;
5) Мәкаләи махсуса.

2. Ничек уйлыйсыз, әти-әнисез ятим калган малайны болай өйдән өйгә, авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә йөртмәскә мөмкин булганмы?

3. Габдуллага тормыш юлында өч Газизә очрый. Аларның малайга кем тиешлекләрен ачыклагыз һәм аның язмышында әлеге хатын-кызларның нинди урын тотканлыкларын сөйләгез.

4. Малай Кырлайда төпләнеп калган булса, шагыйрь булып җитлегер идеме икән? Ничек уйлыйсыз, шагыйрь булу өчен, нинди шартлар булырга тиеш?

5. Мотыйгулла хәзрәт Габдуллага аеруча җылы мөнәсәбәт күрсәтә. Моңаниләр сәбәп була?

6. Г. Тукайның тормышында Камил Мотыйгый нинди роль уйный?

7. Шагыйрьгә төрек һәм рус әдәбиятлары, шулай ук казах халык авыз иҗаты ничек тәэсир итә?

8. Казанга кайткач, Г. Тукай күренекле әдәбият эшлеклеләре белән таныша. Шагыйрь шәхесе аларда ниндирәк тәэсир калдыра?

9. Истәлекләр белән танышкач, сез Г. Тукайны кеше буларак ничек итеп күз алдына китерәсез?

10. «Г. Тукай һәм мәхәббәт» дигән темага әңгәмә уздырыгыз.

11. «Чын талантка һәм намуслы кешегә дөньяда яшәве читен» дигән фикер белән килешәсезме? Килешсәгез дә, килешмәсәгез дә, үз фикерегезне дәлилләгез.

12. Сыйныф белән шагыйрьнең каберенә зиярәт кылыгыз.

Шагыйрьлеккә юллар такыр түгел...

Г. Тукайга иҗат итү өчен, язмыш тарафыннан бары сигез генә ел вакыт бирелгән булып чыкты. 1905 елда аеруча ялкынланып яза башлаган каләме 1913 елның апрелендә туктап калды.Ләкин зур талантларның гомер озынлыгы еш кына аның ничә ел каләм тибрәтүе белән түгел, бәлки нинди әдәби мирас калдыруы белән билгеләнә.

Г. Тукай татар шигърияте тарихында үзенә бер аерым урын тота. Ул меңьеллык бу олы юлда бик тә әһәмиятле вазифа башкарырга өлгерде: урта гасырлар һәм XIX гасыр әдәбиятлары казанышларына таянып, татар сүз сәнгате үсешенең яңа дәверенә нигез салышты: шигъриятебезне сәнгатьлелек ягыннан гаять югары дәрәҗәгә күтәреп, аның дөнья мәйданына чыгуын тәэмин итте.

Г. Тукай иҗаты — татар халкының йөз аклыгы ул. Мондый шагыйре булган милләт — зур һәм талантлы милләт, үткәне һәм бигрәк тә киләчәге булган милләт.

1905 ел. Габдуллага 19 яшь. Шушы елны аның беренче шигырьләре басыла башлый. Әлбәттә, ул моңа кадәр дә шигырьләр язган. Чөнки мондый дәрәҗәдәге иҗади шәхеснең унтугыз яшькәчә каләм тибрәтмәве мөмкин түгел. Ул язганнарын дусларының шигырь дәфтәрләренә (шәкертләрдә андый дәфтәрләр булу гадәти хәл) бүләк итеп урнаштырган, икенчеләре исә аның үз рөхсәте белән күчереп алганнар. Габдулланың дуслары истәлекләреннән моны ачык күрергә мөмкин. 1901 елда ук Г. Тукайның кызларны укытырга кирәклегенә өндәп, надан бер мөгаллимнән көлеп, шигырь язганлыгы билгеле. 1902—1903 елларда ук «Әшгар мәҗмугасы»н («Шигырь җыентыгы»н) төзегәнлеге мәгълүм. «Мотыйгия» мәдрәсәсендә «Әлгасрелҗәдит» исемле кульязма журнал чыгып килгән (1905 елдан, билгеле булганча, шундый исемдә басма журнал чыга башлый). 1904 елгы өченче санында Г. Тукайның Әхмәтсафа исемле каләм тибрәтүче шәкертне мактап язган шигыре урнаштырылган. Аның каләме, хак сүзләр язганга, милләткә файда китерә дигән фикер әйтә яшь шагыйрь. Болардан күренгәнчә, Г. Тукай яңа гасыр башыннан — 1900 еллардан ук — каләм тибрәтергә тотына. Ниһаять, 1905 елда аның унлап әсәре дөнья күрә.

Аларны укып чыккач, игътибар шуңа юнәлә: яшь авторны җәмгыятьтә бара торган вакыйгалар кызыксындыра. Бу яшьтәге егет сөю, мәхәббәт, чибәр кызлар, күңел газаплары турында гына язса да ни әйтер идең? Ләкин Г. Тукайның каләмен башка темалар, башка хәлләр хәрәкәткә китерә.

Г. Тукайның матбугатта басылган беренче әсәре булып «Гыйлемнең бакчасында күңел ачып йөрик...» дигән юл белән башланган исемсез шигыре санала. 1905 елның көзендә яңа ел башыннан (1906 елдан) «Әлгасрелҗәдит» журналы чыга башлаячагын хәбәр иткән бер брошюра нәшер ителә.

Мена шунда Г. Тукайның булачак журналны укучыларга һәм язышучыларына мөрәҗәгать хаты һәм ике шигыре дә бар. Алда телгә алынган шигырьне тулаем татар халкына мөрәҗәгать буларак та аңларга була. Анда, мәсәлән, мондый фикерләр үткәрелә:

Татарларның бөеклеге, даны сигез кат күкләргә китсен;
Мәңге, һәрвакыт бу милләтне Ходаем бәхетле итсен.

Газеталар, журналларны көннән көнгә, кат-кат күбәйтик,
Мәгариф мәйданында без, татарлар, ат уйнатыйк.

Күрәбез, иң беренче басылган шигырендә үк ул халкыбызны мәгариф, фән өлкәсендә уңышлар яулап алырга чакыра, туган милләтенә зур өметләр баглый. Татарларның даны сигез кат күкләргә күтәрелүен тели, шунда ук борынгы бабаларыбыз булган болгарлар белән горурлануын белдерә.

Әле Г. Тукай үзен шагыйрь дип исәпләми. Шигырьнең икенчесендә моңа ишарә бар:

Шигырь бабында юк бәндә маһарәт,
Фәкать бу тугърыда кыйлдым җәсарәт.

Ягъни:

Шигырь язарга миндә осталык юк,
Тик әле кыюлык итеп кенә яздым.

Ахырда болай дип өсти:

Намем Габдулла — Алла бәндәсемен,
Җәмигы колларың шәрмәндәсемен.

Ягъни:

Исемем Габдулла — Алла бәндәсемен,
Алланың барлык колларыннан иң оялчаны мин.

«Дусларга бер сүз» шигырендә дә милләтнең хәлен җиңеләйтү өчен, кулга-кул тотынышып эшләргә, көрәшергә өнди. Алга киткән башка милләтләрнең хәленнән үрнәк алып, «егъла-тора алга таба атлыйк» дип өнди. «Хөррият кочагына барып керү», аныңча, үсеш, алга китү юлыннан китәргә мөмкинлек бирәчәк. Моның өчен нәрсәләр эшләү таләп ителә? Иң әүвәл, Г. Тукайча, «мәдәният мәйданында урын алу», «тырышудан бушамау», безнең мәнфәгатьләрне кайгыртучы депутатлар сайлап, Петербургка җибәрү, башкалада «кирәкләрне сорау». Без «дөнья оҗмахына» керергә тиеш. Ләкин

бу эшне муллаларга йөкләргә ярамый («дин эшендә башчы итик без аларны»), «тапшырсак без дөньяларны абразауный егетләргә», яхшы булыр.

Ләкин ул күреп тора: азатлыкны хаким катлаулар бервакытта да үз ирекләре белән бирми. «Хөррият хакында» шигырендә моны үзе дә әйтә:

Күп яшь егетләр үлде,
Мәетләр дөнья тулды,
Намнәре бакый[1] булды
Та кыямәт тидия[2].

Шагыйрь бу әсәрендә 1905 елгы инкыйлаб ярдәмендә алынган хокукларны әле артыграк бәяли. Матбугатка беркадәр ирекләр бирелү шагыйрь өчен бик олы казаныш булып тоелган, күрәсең. Бу әсәрнең шагыйрь иҗатында тагын бер әһәмияте шунда: «Фикер» газетасында әлеге шигырьгә (1905 ел, 11 декабрь) беренче тапкыр «Габдулла Тукаев» имзасы куелган.

Шулай да 1905 елдагы вакыйгаларга карата язылган иң уңышлы әсәре «Иттифакъ хакында» исемле шигыре булса кирәк. Г. Тукай монда халыкны иң зур көч дип тануын белдерә. Халык фетнәләренең күплеген күреп, патша киңлек бирде дигән фикер уткәрелә. Ләкин бу әле эшнең башы гына, мондый мөмкинлекләрдән файдаланып калырга кирәк. Һәр көнне үзгәрә барган заманда йоклау тиеш түгел. Шагыйрь, ачынып, болай ди:

Кайчанга чаклы татар
Ушбу уйкуда ятар,
Бер-беренә ук атар,
Иттифакъсыз, бәдәвам?

Бердәнбер дөрес юл — иттифакъ, ягъни үзебезне һәм көчебезне берләштерү. Шуңа күрә шигырь берләшергә чакыру белән тәмамлана:

Ачыйк иттифакъка юл:
Ушбудыр иң тугъры юл.
Сыңар җиңнән ике кул
Чыгарыйк без, бәдәвам.

---

[1] *Бакый* — мәңгелек.

[2] *Тидия* — «дигән» мәгънәсендә.

Бу көрәш юлында эш шулкадәр күп, бер җиңнән ике кул (ягъни дүрт куллап) чыгарып тырышлык күрсәтергә кирәк.

Күрәбез, вакытлы татар матбугаты мәйданга килүгә куану һәм хөррияттә җан атып катнашырга теләү Г. Тукай каләмен иҗатка рухландыра.

Шагыйрьнең Җаек чоры иҗаты турында сүз алып барганда, аның XIX йөз ахырында һәм XX гасырның беренче унъеллыгында татар әдәбиятының игътибар үзәгендә булган мәгърифәтчелек идеяләрен дәвам иттергәнлеген күрми булмый. 1906 елда язылган «Шәкерт, яхуд Бер тәсадеф» һәм «И каләм!» шигырьләрендә шуның чагылышын күрергә мөмкин. Шул ук вакытта аларда һәм кайбер башка әсәрләрендә мәгърифәтчелекнең даими юлдашы булган үгет-нәсыйхәтчелеккә дә, ягъни дидактизмга да байтак урын бирелгән.

«Шәкерт, яхуд Бер тәсадеф» («Шәкерт, яки Бер очрашу») шигырендә лирик герой буранлы көндә мәктәпкә баручы шәкертне очрата. Малайның өстендәге киеме җылы тотарлык түгел: итеге дә, бишмәте дә тишек-тошык. Җитмәсә, ачлыктан хәле юк, утырып-утырып ял итеп алгалый. Лирик герой, аның мондый халәтен күреп, кайгыга төшә, үзәге өзгәләнә. Башкаларның хәленә керә белү — кешенең затлы сыйфаты. Ләкин аның бу балага матди ярдәм итәрлек чамасы юк. Аның бердәнбер мөмкинлеге — сәеррәк тоелса да, әлеге шәкерткә шигырь уку.

Бу — лирик геройның монологы. Шәкерт аның сүзләренә каршы берни дә әйтми. Аңлаганмы ул аларны — юкмы, килешкәнме аның әйткәннәре белән — килешмәгәнме, анысы мәгълүм түгел. Лирик герой үзенең киңәшләре белән шәкертнең авыруын дәваладым дип уйлый. Бу аның сүзне идеаллаштыруыннан, үгет-нәсыйхәтнең көченә табынуыннан килә.

> Сәнең фәкърең — дорыр фәхрең, онытма;
> Моның дик юк фаразлә кайгы йотма.

Ягъни:

> Синең ярлылыгың — синең мактанычың, онытма;
> Һәм мондый юк-бар уйлар белән кайгы йотма.

Ярлылык белән мактану, моның өчен горурлану, бу дөньядан ваз кичеп, ахирәткә барырга әзерләнү мәшәкате

белән генә яшәү — суфилар һәм дәрвишләргә хас сыйфат. Ләкин авторның әйтергә теләгәне шактый катлаулырак. Ул шәкертне (гомумән, әсәрне укучыны) горур булырга, күңел байлыгын арттыра барырга, бәхеткә ирешү максатында аң-белемне даими үстерүгә ирешергә, шуның өчен үзеңне ярлы санамаска киңәш итә. Байларга ярыйм дип, кешелек дәрәҗәңне төшерүдән сакланырга үгетләве шигырьнең ахырына таба төп сызык булып әверелә. Шулай да ярлы шәкерт кемгә сыенырга тиеш соң? «Өмет ит ризкыңи рәхман рәхимдән» («Азыгыңны Алладан өмет ит»). Төп киңәше, шулай итеп, Аллаһы Тәгаләне зурлау, аны истә тоту, аңа мәрхәмәт сорап мөрәҗәгать итәргә чакыру булып кала. Ягъни, мәгърифәтчеләргә хас булганча, белем юлында тырышлык кую кешене матурлый, бәхетле итә, муллык юлына юнәлтә. Комсызлык кебек түбән сыйфатка каршы итеп, Г. Тукай белемлелекне куя.

«И каләм!» шигырендә Г. Тукай шул ук фикерне үстерә. Каләм ярдәмендә (бу очракта белемлелек дип аңларга кирәк) туры юлга басыйк, ди. Без, әсирләр, ялкаулар, хурлыкта калганбыз. Әнә белемлелек Европаны күкләргә күтәргән, ә без җиде кат җир астына төшкән хәлдә яшибез, ди.

Күрәбез, Г. Тукай ике кыйтганы — Көнбатыш белән Көнчыгышны белемлелек, тормыштагы урыннары, үсеш дәрәҗәләре ягыннан капма-каршы куя. Милләтнең мондый хәле аның язмыш китабына теркәлгәнме әллә дип уйлана. Бу хәлдән чыгуның бердәнбер юлы — белемлелекнең кыйммәтен бәяләү, наданлыкның агу, начар нәрсә икәнен аңлату. «Караны яз кара диб һәм игътираф ит акны ак» («яз караны кара дип һәм акны ак дип таны»), ягъни каләм бары тик дөреслеккә генә тугры була ала. Аерым кешеләр күңелен генә түгел, бәлки тулаем милләтнең авыруын багарга өнди. Ягъни наданлыкны гомуммилләткә хас авыру дип атый. Алай гына да түгел, барлык мөселманнар да шушы авыруга дучар. Бәхет һәм якты киләчәгебез синнән килер дип, шагыйрь каләмгә зур өметләр белән карый.

Әйлә ярдәм безгә һәрдәм, и каләм, кыйл мәрхәмәт;
Дәфгулынсын[1] җөмлә хәсрәт, фәкъ вә хәкъ, мәскәнәт!

[1] *Дәфгулынсын* (*дәфгъ улынсын*) — бетсен, китсен.

Ягъни:

И каләм, безгә һәрдаим ярдәм һәм мәрхәмәт ит;
Хәсрәт, хурлык, мескенлекләр — мәңгегә кит!

Татар милләтенең фикерен уткенәйтү, шул нигездә аны берләштерү Г. Тукайның төп хыялларының берсенә әверелә. Моны ул төрле әсәрләрдә кайта-кайта әйтә. «Фикер» гәзитәсенә генә махсус түгел» исемле шигырендә бу теләген ачыктан-ачык белдерә:

Фикремез тәфрикы өммәт йилләрен исдермәсен,
Исдереб, тәүхиде милләт юлларын кисдермәсен.

Ягъни:

Фикеребез халыкны таркаткыч җилләр истермәсен,
Истереп, милләтнең берләшү юлын кистермәсен.

Г. Тукай иҗатының башлангыч чорында, ягъни 1907 елның урталарына кадәр, байтак шигырьләрен төрек теленә якынайтып язган. Ул үзе дә иҗатының әлеге чорын «төрекләргә тәгълит вакыты...» дип атый, ягъни «төрекләргә ияру вакыты». Моның өчен кайбер сәбәпләре дә була. Беренчедән, остазы Мотыйгулла хәзрәт, үзе Мисырда укып кайткан кеше буларак, Габдуллага гаруз (шигырь төзелеше) дәресләрендә гарәп, фарсы, төрек шигырьләре кануннарын өйрәткән. Икенчедән, 1902—1903 елларда «Мотыйгия» мәдрәсәсендә бер төрек шәкерте укый. Әлеге төрек егете шигырьләр яза, аларны дусты Габдуллага яттан укып күрсәтә. «Шул шәкерт белән торган заманнарда Габдулла әфәнде төрек романнарын бик яратып укып йөри иде»,— дип яза Г. Кариев. Әмма: «1907 сәнәнең соңгы яртысының башларында ул үзенең «Шүрәле»се белән нәкъ татар теленә әйләнеп китә. Аннан соң язган шигырьләренең бөтенләен диярлек татарча яза»,— дип билгеләп үтә шагыйрьнең замандашы нәшир Гыйльметдин Шәрәф.

1907 елда Казанга килгәч, ул биредә татар шагыйрьләренең, бигрәк тә С. Рәмиев әсәрләрен күпләп укый һәм татар сүзләренең шигырьдә матур яңгырашына соклана. Димәк, Казанга кайту Г. Тукай өчен халкыбыз теленә кайту да булган икән. «Без, татарлар, һаман да татарлар булып калдык»,— дип язды Г. Тукай, горурланып. Бу сүзләрдә ти-

рән мәгънә бар. Әйе, башка халыкларның әдәбиятларына сокланырга, алардагы үз күңелеңә аваздаш якларга кызыгып карарга мөмкин, әмма синең әдәбиятыңны да башкалар үз итсеннәр, яратсыннар дисәң, аны туган милләтеңнең сәнгатьчә фикерләү чаралары ярдәмендә үстерү зарур. Моны гамәлгә ашыруы — Г. Тукайның әдәбиятыбыз алдында күрсәткән тагын бер зур игелеге.

Сораулар һәм биремнәр

1. Г. Тукайның татар әдәбияты тарихындагы урыны нәрсәләр белән билгеләнә?

2. Шагыйрь тәүге шигырьләрендә ниләр турында яза?

3. Г. Тукай ни өчен үз әсәрләрендә, барыннан да элек, иҗтимагый тормыш мәсьәләләрен күтәрә?

4. Милләтебезнең тормышын яхшыртуның юлларын аңлауда шагыйрь карашындагы үзгәрешләр турында сөйләгез.

5. Татар халкын бәхетле юлга алып чыгуның төп шарты итеп ул нәрсәне саный?

6. Шагыйрь иҗатындагы мәгърифәтчелек юнәлеше нәрсәләрдә күренә?

7. «И каләм!» шигырендә шагыйрь каләмгә нинди өметләр баглый? Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз һәм яттан өйрәнегез.

8. Җаек чоры иҗатында Г. Тукайның төрекчелеккә өстенлек бирүен ничек аңлатып була?

9. Казанга кайткач, Г. Тукай саф татарча яза башлый. Ни өчен дип уйлыйсыз?

10. «Без, татарлар, һаман да татарлар булып калдык!» дигәндә, Г. Тукай нәрсәләрне күздә тота?

11. Түбәндәге темаларга инша языгыз:

1) Г. Тукай — халыкның үз баласы;
2) Г. Тукай һәм аның каләмдәшләре;
3) Г. Тукай — кеше һәм шагыйрь.

12. Г. Тукайның нәсел агачын (шәҗәрәсен) төзегез. (Татарстан.— 1996.— № 10.— 75—77 б.)

«Җандай күрәм мин искеләрнең җырларын»

Г. Тукай шигырьләренең үзеннән-үзе җырлап торуларына, ягъни музыкальлелегенә игътибар итми мөмкин түгел. Шәрыктә шигырьләрне көй белән уку гадәте элек-электән килә. Ләкин татар теленең шигърилеге, җыр сәнгатебезнең нык үскән булуы, ягъни борын-борыннан шигъри сүз белән көйнең аерылгысыз булып үрелүе — безнең үзебезнең дә

табигый сыйфатыбыз. «Тукай — хәтта һәрбер авазның ритмик һәм музыкаль берәмлеген сизеп, үлчәп иҗат иткән шагыйрьләрнең иң күренеклесе» (Г. Халит). Болар Г. Тукайның иң әүвәл халык авыз иҗатына, бигрәк тә җыр сәнгатенә, рух байлыгына нигезләнеп иҗат итүеннән килә. Ул болай дигән иде: «Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятыбызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр». «Мин кечкенәдән үк җырчы идем. Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем... Мәдрәсәдә мине җырчы диләр иде. Кечкенәдән күңелемә урнашкан җырулар сөймәкемнән[1] миндә туган телемезне сөю тугъды. Әгәр миңа җырулар ярдәм итмәсә, мин туган телемезне сөймәк кеби бер олуг нигъмәткә малик була алыр идеммени? Яшәсен халык әдәбияты, яшәсен туган тел!»

Г. Тукай бик тә хаклы, балада туган телгә мәхәббәт уятуда халкыбыз җырларының әһәмияте гаять зур. Баланың нинди җыр җырлап үсүе — аның киләчәген хәл итү дигән сүз. «Халык җырларының җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле бернәрсә булганы өчен дә, аларга әһәмият бирергә кирәк. Аларны югалтмаска иҗтиһад итәргә кирәк»,— дип, ул үзенең бу мәсьәләдәге төп юлын билгеләде. Ул бу эштә чын мәгънәсендә тырышлык күрсәтте. Аның, мәсәлән, «Сак-Сок» бәетен җыюга аерым игътибар иткәнлеге мәгълүм. «Мин бу «Сак-Сок» дип аталган «милли фантазиябез» хакында күп-күп кешеләрдән күп-күп истифсарларда булындым[2].

— «Сак-Сок» бәетен беләсезме? Белсәгез, язып китерсәгез иде,— дип үтендем».

Булачак шагыйрь, Җаекта мәдрәсәдә укыганда ук, халык җырларын җыюга дәртсенә. Җәйге ялга китүче шәкертләргә үз төбәкләрендәге экиятләр, җырлар һәм башка халык авыз иҗаты әсәрләрен язып алып килүләрен сорый торган булган. Шул рәвешле, аның «Җырлар дәфтәре» барлыкка килгән. Бу дәфтәр 1946 елда гына табыла, һәм ул шул ук елда бастырылып та чыгарыла. Анда утызга якын җырның сүзләре теркәлгән. Саф татар телендәге бу җырлар Г. Тукай өчен шигъри мәктәп булгандыр дип уйларга кирәк. Биредәге җырларның стиль, образлылык, төзелеш ягыннан төрле-төрле, бай

[1] *Сөймәкемнән* — сөюемнән.
[2] *Истифсарларда булындым* — сораштым.

үрнәкле булуы, чыннан да, күңеле сүз сәнгатенә тартылган кешене сокландырмый калмый. Мәсәлән:

Кимә итек — ки читек,
Атна кичләре итеп;
Кил, җаныем, ташлашмаек,
Дошманнарга үч итеп.

(«Бәшир» көе)

Өфе юлы пыяла,
Яз көнендә су ала.
Өфегә барган егетләрнең
Башы шунда югала.

(«Солдат» бәете)

Унике чана утыным
Агыйделгә сал булсын;
Елама, әткәй, бәнем өчен,
Калганнары сау булсын.

(«Солдат» бәете)

Тау буеннан килгән чакта
Табып алдым бер чыбык;
　　Латифә — сары ука,
　　Бән саргайдым сән юкка!
Әтиең, әниең бирмим дисә,
Килерсең микән чыгып?
　　Латифә — күгәрчен,
　　Бәхетең бардыр, күрәсең.

(«Латифә» көе)

Казан ерак, Казан ерак,
Казаннан Мәскәү ерак.
Кайтыр идем — илләр ерак,
Кайтмасам — яна йөрәк.

Байлар күк ат җигә диеп,
Мин дә җиктем күк бия.
Сеңлесенә сүз әйтмәгез —
Тутасына күз тия.

(«Яңа Сәфәр» көе)

Салкын чишмә, салкын су —
Эчтем бәгърем көйгәнгә.
Ерак юлны якын итеп
Килдем сине сөйгәнгә.

Аклы күлмәк кем сөймәс,
Зәңгәрлесен шул кимәс.
Хакыйкать яр булган кеше
Яр өстеннән яр сөймәс.

(«Япон» көе)

Шагыйрь соңыннан да халкыбызның җырларын, әкиятләрен, мәзәкләрен, табышмакларын өйрәнүгә, аларны әсәрләрендә файдалануга зур әһәмият бирде. Дөресрәге, ул халык авыз иҗатына таянды, аның эстетик фикерләвендә үзе өчен олы үрнәк күрде. Бу исә аңа халык тарафыннан үз итеп кабул ителерлек әсәрләр язарга мөмкинлек тудырды. Аның иҗатына чын мәгънәсендә халыкчанлык хас иде. Фольклорга мәхәббәт әсәрләренең телен халык сөйләменә якынайтты, образлылыгын көчәйтүгә китерде. Әнә шулай үзеннән-үзе җырлап торучы Г. Тукай теле белән халык теле аерылмас бербөтенне тәшкил итте.

Халык рухы шагыйрь әсәрләренең тукымасында бик табигый урын алды. Аның «Әллүки», «Тәфтиләү», «Зиләйлүк», «Туган тел» кебек җырлары шулкадәр халыклашты ки, аларны шагыйрь иҗат иткәне сизелми дә. Аларда һәркем үз күңелендәге хисләргә аваздашлык таба. «Туган тел» җыры исә соңгы елларда аеруча еш яңгырый. Күп кенә әдәби-музыкаль кичәләр, хәтта төрле җыеннар да шушы җыр яңгыравы белән тәмамлана. Ул — халкыбызның рәсми булмаган гимны.

Халкыбыз тудырган әкиятләргә нигезләнеп, яңа шигъри әкиятләр иҗат итүнең матур үрнәкләрен дә безгә Г. Тукай бирде. «Су анасы», «Кәҗә белән Сарык әкияте», «Шүрәле» әкиятләрен кем генә белми? «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» сатирик поэмасында да әкият алымнары отышлы кулланылган. Халык авыз иҗаты шагыйрьгә образлылыкка ирешүдә бик файдалы үрнәк булды.

Сораулар һәм биремнәр

1. Г. Тукайның шигъри остазлары дигәндә, без аерым шәхесләрне дә, тулаем халкыбызны да күздә тотабыз. Ни өчен?

2. Г. Тукай халык җырларының кеше тормышындагы урынын ничек билгели?

3. Шагыйрь халык авыз иҗатын ни рәвешле өйрәнә?

4. Халыктан ишеткән, сезнең өчен яңа булып тоелган җыр, бәет, табышмак, мәкальләрне аерым дәфтәргә язып барыгыз.

Шагыйрь булу җиңелме?

Чын шагыйрь булу бервакытта да җиңел булмаган. Чөнки ихлас шагыйрь тормыш дөреслеген җырларга тиеш. «Дөрес сүз күзгә кылчык булып кадала»,— ди халык. Г. Тукай да шагыйрьлеккә югары бәя бирә, аны «сәмави сүз» («күк сүзен») сөйләүче итеп күз алдына китерә. Ләкин мондый кешегә яшәве авыр булыр. Чөнки:

Явар өстеңгә бөhтаннар[1], хәсәдләр[2],
Корылыр юлыңа hәртөрле сәдләр[3].

(«Шагыйрьгә»)

Шулай да шагыйрьлек көченә ия булган кеше куркып калмаска тиеш. Шагыйрьне төрле яктан кыссалар да, «күкрәк биреп каршы» торырга тиеш.

Уңга, сулга аумыйм, hәнүз[4] алга барам,
Юлда манигъ[5] күрсәм, тибәм дә аударам;
Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә,
Мәгълүмдер ки, курку берлән өркү харам.

(«Бер татар шагыйренең сүзләре»)

Шагыйрь ышана:

Бөкре түгел, төзәлергә кабер көтмим,
Тәңрем фәйзы[6] минем күңлемгә эз салыр.

Г. Тукай әйткәнчә, шагыйрь тормыш ваклыкларыннан өстен торырга тиеш. Ник дигәндә, йортта күп-озак асралган кош оча алмый. Ваксынып китеп, алтын шылтыравы астына төшәсең икән, шагыйрьлек таҗы мәңге сиңа булмас.

Баш имә син — зур син — бу әдна җанлылар[7] дөньясына;
Падишаh син! Бик кирәксә, баш исен дөнья сиңа.

(«...гә» (Ядкяр)

Тәне картайса да, шагыйрьнең күңеле ямь-яшь, җаны көчле булып кала. Күкрәгендә шигырь уты сау булганда,

[1] *Бөhтаннар* — яла, нахак сүзләр.
[2] *Хәсәдләр* — көнчелекләр.
[3] *Сәдләр* — каршылыклар, тоткарлыклар.
[4] *Һәнүз* — hаман.
[5] *Манигъ* — тоткарлык, киртә.
[6] *Тәңре фәйзы* — Ходай рәхмәте.
[7] *Әдна җанлылар* — бик түбән җанлылар.

ул тауларны күтәрерлек куәткә ия. Күңелендә исә һәрвакыт яз гына. Ник дигәндә, аның тәненә шигырьләреннән җылы бөркелеп тора.

Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә;
«Без китәрбез, сез каласыз!» — дип җырлармын,
Җәсәдемне[1] туфрак берлә күмгәндә дә.

Г. Тукай шагыйрьлекне, аның яшәү рәвешен, күңел дөньясын, җәмгыятьтәге урынын менә шулай аңлый. Асылда, ул шушы үзе әйткәннәргә гомере буе тугрылыклы булып калды. Шигърияттне ул уен-көлке чарасы итеп түгел, бәлки кешеләрне тәрбияләү, тормышны матурлау һәм җәмгыятькә тәэсир итүнең көчле коралы буларак карый.

Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,
Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,
Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,
Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен.

(«Сәрләүхәсез[2]»)

Шагыйрьнең иҗаты әнә шул «ачы хәсрәт көен» көйләве белән халык күңелен җәлеп итте дә. Үзе яшәгән елларның бер генә хәл-әхвәленә, игътибарны җәлеп итәрлек бер генә вакыйгасына да Г. Тукай битараф калмый. Ул курыкмыйча өстен катлауларны, кеше хакын ашаучы, изүче сыйныфларны тәнкыйтьли, хакимиятләргә тел-теш тидерүдән дә тыелып тормый. Мәсәлән, ул, үз-үзенә эндәшеп, болай ди:

Яза күрмә, җитәр, артык, Тукаев, вастрок[3] бар бит;
Куярлар астырып дарга, ятып тор бер дә кузгалмай.
Язам, юк, туктамыйм мин һич, алардан бер дә кот чыкмай;
Нидәндер җаннарым бу куркулардан бер дә сызланмай.

(«Сорыкортларга»)

Ул милләтебезнең кол хәлендә яшәвенә сызланды, аның бәхетле, ирекле чагын күрергә теләде:

Кайчан соң, и фәкыйрь милләт, бәһарең[4]!
Кайчан китәр кичең, килер нәһарең[5]? —

---

[1] *Җәсәдемне* — тәнемне.
[2] *Сәрләүхәсез* — исемсез (шигырь).
[3] *Вастрок* — төрмә.
[4] *Бәһар* — яз.
[5] *Нәһар* — көндез.

дип, халкы өчен яз, якты көннәр килүен теләде, шуны җырлады.

Җөмлә фикрем кичә-көндез сезгә гаид, милләтем;
Сыйххәтеңдер сыйххәтем һәм гыйлләтеңдер гыйлләтем.

Ягъни:

Бар уем кичен-көндезен сезнең хакта, милләтем;
Саулыгың — минем саулык, авыруың — минем авыруым.

(«Милләтә»)

Ул үз бәхетен тулаем милләт иминлеге белән генә тәэмин ителә дип ышанды. Бу аның халык белән үзен аерылгысыз бербөтен итеп каравы иде. Ул татарның бетүгә хөкем ителүенә ихлас әрнеде.

Инкыйразны булдырмау аның тоткан юлларының берсенә әверелде.

Күңел берлән сөям бәхтен татарның,
Күрергә шаһлыгын, тәхтен татарның.
Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

(«Үз-үземә»)

Шагыйрь халыкларның тарихи язмышлары турында уйлана, шул исәптән татар ханнарына кайгы килүенең, Сөембикәнең елый-елый җан бирүенең сәбәпләрен эзли һәм таба:

Юк шул безләрдә берләшмәк;
Юк бергә-бергә гөрләшмәк,
Бер җан, бер тән булып,
Нечкә серне бергә серләшмәк.

(«Кичке азан»)

Г. Тукай бик дөрес күрсәткәнчә, халык үзенең бәхетен тату, дус булганда, бер максатка бердәм барганда гына таба ала. Егерме яшьлек шагыйрь, шулай итеп, гасырыбызның беренче елларында ук хакыйкатьне ачып сала, татарның таркаулыгын зур кимчелек итеп күрсәтә. Язмышка битараф караучылардан усал итеп көлә.

Дәүләт, бәхет биргән йокы,
Милек, тәхет биргән йокы,
Безгә кирәк илла йокы, —
Йокы, йокы, йокы.

(«Йокы»)

Бу шигырьне баскан «Яшен» газетасы (1908, 3 сентябрь) язганча, «әгәр дә йокы шулкадәр яхшы эш булса иде, безнең татарлар күптән алга киткән булыр иде». Шуңа күрә Г. Тукай марш рәвешендә язылган шигырендә милләтне уяныргa чакыра:

Тора татар! Тора татар!
Уйкудан тиз тора татар.
Тора! Тора, тора татар,
Баш күтәргән бар татар!

(«Тартар кошы сайрый»)

Бу,— әлбәттә, шагыйрьнең күрергә теләгәне. Татарны уятырга, урыныннан кузгатырга әле байтак нәрсә кирәк булачагын ул аңлый. Ләкин шигърият шушы эшнең башында торырга тиешлегенә аның иманы камил.

Г. Тукай Сәгыйть Рәмиевкә язган хатында (Казаннан Әстерханга, 1911, 4 март) болай дигән: «Мин поэт (шагыйрь. — *Ф. Г.)* кына түгел, мин дипломат[1], политик[2], общественный деятель[3] дә бит. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә...» Бу сүзләр аны шәхес буларак шактый ачык күзалларга ярдәм итә. Үзе әйткәнчә, «Чү, аз гына «шылт!» иттеме», инде аның турында ул я шигырь, я мәкалә белән җавап бирә. Мәсәлән, «Китмибез!» шигыренең язылу тарихы бик гыйбрәтле. Милли төбәкләрдән килгән мөселман депутатлары Дәүләт думасы утырышларында үз халыкларының авыр тормыш хәле, мәктәпләрнең мөшкеллеген әйтеп чыгышлар ясыйлар. Ләкин уң депутатлар һәм реакцион матбугат мөселманнарның бу хәлен аңларга теләмиләр, киресенчә: «Әгәр сезгә Россиядәге тәртипләр ошамаса, Төркиягә китегез»,— дип кычкыралар. Г. Тукай моңа каршы «Китмибез!» шигыре белән җавап бирә. Безнең хәлне Солтан җиренә, ягъни Төркиягә китү юлы белән яхшырту мөмкин түгел. Чөнки һәркем үз туган җирендә бәхетле тормыш төзергә тиеш. Ә безнең ата-бабаларыбыз күп гасырлардан бирле шушы җирләрдә яшәгән. Безне бу җиргә кодрәтле Тәңребез үзе бәйләгән, монда туганбыз, димәк, әҗәлебез дә биредә булырга тиеш. Безнең бөек максатыбыз — ирекле мәмләкәт (дәүләт) булдыру. Шагыйрь

---

[1] *Дипломат* — илче; бу очракта: бәхәс остасы.
[2] *Политик* — сәясәтче.
[3] *Общественный деятель* — җәмәгать эшлеклесе.

сүзне Думадагы депутатларга аларның үз телләрендә мөрәҗәгать итеп тәмамлый: «Если лучше вам, туда сами пожалте, господа!» (Ягъни «Анда яхшырак икән, үзегез шунда рәхим итегез, әфәнделәр!»)

Бу теманы шагыйрь «Олугъ юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре» дигән шигырендә дә дәвам иттерде. Билгеле булганча, 1613 елда Россиянең патшасы итеп бай бояр гаиләсенең уналты яшьлек улы сайлана. 1913 елда шушы нәселнең патшалык итә башлавына 300 ел тулу көне бик зурлап бәйрәм ителә. Г. Тукай шушы уңай белән татар халкының тарихын һәм аның язмышын күз алдыннан уздыра. Төньяктан, ягъни Россия башкаласы Мәскәү тарафыннан, болыт күренсә (бу очракта берәр хәбәр килсә дип аңларга кирәк), без өметләндек, безгә бәхет китерүче хәбәр түгелме, «мәңге михнәт, мәңге рәнҗешләр кичәр» (ягъни бетәр) дип уйладык. 1552 елдан бирле Россия кул астында узган 361 елны Г. Тукай, күргәнебезчә, әнә шулай «мәңге михнәт», «мәңге рәнҗешләр чоры» дип атый. Аның бетүенә өмет итә. Тәхеткә утыруларына 300 ел тулу бәрабәренә, бәлки, халыкка җиңеллек китерә торган, күз яшен киптерергә китерүче «Мөнафис» («Манифест») чыкмасмы дип көтә. Ләкин ул өметләр акланмый. Шагыйрь мәсьәләне кискен итеп куя:

> Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
> Без тынычта аттан артык эшлибез.
> Шул халыкныңмы хокукка хакы юк? —
> Хаклыбыз уртак ватанда шактый ук!

Әсәрнең «...халык өмидләре» дип исемләнеп тә әнә шулай «күзләре җиңеллек эзләп тилмерүче»ләрнең һаман әүвәлге хәлдә калуларын әйтү белән тәмамлануы күңел төшенкелеге тудыра. Мәдхия, ягъни мактау рәвешен алырга тиешле шигырь халык кайгысын, хәсрәтен гәүдәләндерүче, шушы хәлгә патша династиясен (нәсел-нәсәбен) гаепләүче документка әверелә. Патшаның җиңеллек китерүче әмерен көтү буш хыял гына шул. Г. Тукай моны белә, ләкин әле ул патшадан йөз чөереп бетермәгән, һаман көтә.

> Зур «Мөнафис» берлә җанлансын халык,
> Бар моңын, барлык зарын өстән салып.

Бу шигырь 1913 елның февралендә, шагыйрьнең үләренә ике ай вакыт калгач язылган. Бу аның гомеренең соңгы

сәгатьләренә кадәр туган халкы турында сызлануын күрсәтә. Г. Тукайның шәхси тормышы да, туган халкының язмышы да бертөсле булды. Татар халкының инкыйраз юлына атлаганын шагыйрь күрде. Бу һәлакәттән котылу юклыгын күрү аны хәсрәтләндерде. Ул тормышка җайлашмады, өстен катлаулар, түрәләр алдында баш имәде. Нәрсә уйлаганын һич рияланмыйча үткен итеп әйтеп бирә барды. Ул үзенең шагыйрьлек вазифасын әнә шулай намусы кушканча башкарды. 1913 елның мартында ул, гомеренә йомгак ясап, «Кыйтга» шигырендә болай дип язды:

Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,
Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым.

Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым,
Чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым.

Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч — шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.

Сораулар һәм биремнәр

1. Г. Тукай шагыйрьлекне ничек итеп күз алдына китерә?

2. Шагыйрь ни өчен кыю һәм тугры булырга тиеш?

3. «Ачы хәсрәт көен көйләү тиеш» дип, шагыйрь үзенең бурычын ничек итеп билгеле?

4. Халыкның хәле турында язганда, Г. Тукай татар милләте язмышының кайсы яклары турында аеруча борчыла?

5. «Китмибез!» шигырендә шагыйрь татар милләтенең тарихы, ул вакыттагы хәле һәм киләчәге турында ничек уйлана? Бу әсәрдә шагыйрьнең нинди шәхси сыйфатлары ачыла? Әсәрне яттан сәнгатьле итеп укыгыз.

6. «Олуг юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре» шигырендә беренче карашка патша династиясенә мактау сүзләре әйтелә кебек. Әмма әсәрдән килеп чыга торган төп фикерләр бөтенләй икенче юнәлештә. Шушы шигырь буенча «Г. Тукай һәм халык язмышы» дигән темага әңгәмә уздырыгыз.

7. Халыкның хәлен җиңеләйтерлек «Мөнафис» чыгуын көтүгә сезнең мөнәсәбәтегез ничек?

8. Шагыйрь, үзенең тормышына йомгак ясап, нинди нәтиҗәгә килә?

Тукай һәм башка әдәбиятлар

Шагыйрь булып җитлегү чорында Г. Тукайның төрки һәм башка Көнчыгыш әдәбиятларыннан үрнәк алуы, алардагы үзе кирәк дип тапкан байтак якларны иҗади кулланганлыгы турында инде сез беләсез.

Мәдрәсәдә укыган Г. Тукай, әлбәттә, иң әүвәл Көнчыгыш шигърияте белән азыклана. Фирдәүси, Хәйям, Низами, Хафиз, Физули кебек борынгы шагыйрьләрнең әсәрләрен яхшы белә. Бер үк вакытта Габделхак Хәмид, Намыйк Камал, Тәүфыйк Фикрәт, Җәлил Мамедкулизадә, Галиәкбәр Сабир һәм башка төрек, азәрбайҗан шагыйрьләре иҗатына да игътибар итә. Рус әдипләре һәм шагыйрьләре А. Пушкин, М. Лермонтов, Н. Некрасов, Л. Толстой һәм башкалар иҗатыннан да ул үзенә өлгеләр таба. Шекспир, Байрон, Шиллер, Гёте, Гейне әсәрләрен укып дулкынлана. Нәтиҗә ясап әйткәндә, Г. Тукай — Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәбиятлары тәэсирен нык тойган шагыйрь. Көнчыгыш әдәбиятында гасырлар буена килгән романтизмны Көнбатышның кырыс реализмы белән бергә үрү аның әсәрләрендә яңа сыйфат билгеләре китереп чыгара. Шагыйрьнең «Көзге җилләр» шигырен алыйк. «Җил җылый[1]» сүзтезмәсе белән тудырылган хисси чолганыш әсәрнең нигезен барлыкка китерә. Табигатьнең кеше күңеленә бәрабәр итеп, үтә нечкәртелеп сурәтләнүе — романтизм билгесе. «Җил җылый» шигырьдә кабатланып килә, димәк, хисләрне үткенләндергәннән-үткенләндерә. Халык язмышы өчен борчылу — шушы моңны, хисне китереп чыгарган төп сәбәп. Автор, хисне көчәйтү өчен, гипербола куллана: көзге җил елавы бөтен ил елавына әверелә, алай гына да түгел, Җир-ана елый. Җан алучы фәрештә Газраилнең гомуми елауга кушылуы романтизм буяуларын тагын да куертып җибәрә. Бу өзелмичә елауларның сәбәбе — ач үлемнән курку, димәк, үтә реалистик (ягъни чынбарлыктан килеп чыга торган) сәбәп. Шагыйрь, ачлык афәтенең күпчелеккә кагылганын күрсәтү өчен, «тәкбир җылый» дигән образлылыкны да китереп кертә. Корбан бәйрәменә мөселманнар бергәләп (агым булып) Аллаһы Тәгалә исеменә тәкбир әйтеп[2] баралар. Бу очракта әлеге тәкбир дә, шагыйрьчә, елау булып ишетелә. Моны бары тик Көнчыгыш шагыйре (дөресрәге, ислам дине

[1] *Җылый* — елый.
[2] *Тәкбир әйтү* — олылау.

вәкиле) генә шулай табигый итеп чагылдыра ала. Менә болар ике мәдәният уртасындагы татар әдәбиятының, яңа төсмерләр тудырып, өченче — үзенә күрә бу икенең кушылмасын тәшкил иткән — тагын да көчлерәк мәдәният барлыкка китерүен күрсәтә. Моңа тагын Көнчыгыш шигъриятенең аерылгысыз юлдашы булган газәл, мәдхия, касыйдә жанрларының Г. Тукай иҗатында гәүдәләнеше үзгәрүен дә өстәргә кирәк.

Газәл — шигырьнең мәхәббәт турында җырлау өчен кулланылып килентән төре. «Яшьләр» әсәре, мәсәлән, газәл кануннары белән язылган. Ләкин шигырь тулысы белән иҗтимагый тормыш турында уйланулар, борчуларга корылган. М. Лермонтов үзенең мондыйрак әсәрләрен «думалар» дип атаган. «Өзелгән өмит» исә — газәл һәм элегия жанрлары мөмкинлекләрен бергә кушу үрнәге. Фәлсәфә кылуга, өстен көчләрне һәм югары катлауларны мактауга хезмәт иткән касыйдәләрне дә Г. Тукай җәмгыятьтәге явызлыкларны фаш итү, публицистика максатларында файдаланган.

Башка әдәбиятлардан ул сүз сәнгатенең асылы, аның үзенчәлекләре, сурәтләү чаралары, тормышка һәм чынбарлыкка мөнәсәбәте кебек сыйфатларын өйрәнә. Боларны белү һәм үзләштерү белән бергә, татар шигъриятенең үзенчәлекләрен, эчке кануннарын сизгер тою, табигый талантын ачып армыйталмый иҗат итү, аңа тиз арада әдәбиятыбызда олы шагыйрь булып җитешергә ярдәм итә. Аның иҗаты туган халкының омтылышларына, зәвыгына тәңгәл килә. Шуңа күрә аны башка милләт вәкилләре дә яратып укый. Әлбәттә, үз халкын дулкынландыруга ирешә алмаган шагыйрь башка милләт укучыларының күңелен кузгата алмый. Г. Тукай исә XX йөз башында бездә иң күренекле сүз осталарыннан берсе булып танылды.

Бөек шагыйребез әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итүнең матур үрнәкләрен биргән күренекле шагыйрь Семён Липкин болай дип яза: «Габдулла Тукайның иҗаты белән күп еллар буе танышып киләсең һәм кинәт аның байтак кына әсәрләренең традицион Көнчыгыш строфикасы белән — ике юллы шигырь итеп язылганын яки газәл формасында булуын күрәсең... Тукай шигырендә канның җанлы тибеше сизелеп тора, ул — тормышның үзе. Шулай итеп, поэзиядә могҗиза туа: эчтәлекнең гаҗәп яңа булуы аркасында, безгә форма үзе дә инде өр-яңа булып тоела».

Казах әдипләре Мохтар Ауэзов һәм Җакан Сыздыков, үзбәк Хәмзә Хәкимзадә, Гафур Голәм, таҗик Садретдин Айни, азәрбайҗанлы Сөләйман Рөстәм, кыргыз Аали Токымбаев, төрекмән Берды Кербабаев, чуваш Педер Хузангай һәм башка каләм осталары күңелендә әдәбиятка мәхәббәт Г. Тукай әсәрләре ярдәмендә барлыкка килгән. Бу турыда алар үзләре болай дигәннәр:

«Тугандаш татар халкының бөек җырчысы Габдулла Тукайның ялкынлы, самими шигырьләре йөрәгемә тирән кереп урнаштылар. Ул барлык тугандаш республикалар шагыйрьләре өчен дә кадерле һәм газиз» (Сөләйман Рөстәм).

«Казах халкы Тукайның шигырьләрен сокланып тыңлый, яратып укый... «Шагыйрь» исемле шигырен, думбра белән көйләп, күп кенә егетләрнең яттан җырлаулары әле дә хәтеремдә саклана. Казах егете думбрасын чиртеп җырлаганда, күп кенә казах картларының: «Гаҗәеп акын... Тагын да кабат җырла әле җырыңны!.. Тамаша акын!» дигәннәрен үз колагым белән күп тапкыр ишеткәнем бар.Барлык шагыйрьләр арасында Габдулла Тукай минем үрнәк алган зур остазым булды. Элегрәк заманнарда казах-татар мәктәпләрен, уку өйләрен «Габдулла Тукай исемендәге мәктәп», «Габдулла Тукай исемендәге уку өе» дип атау гадәткә кергән иде. Мин дә «Габдулла Тукай исемендәге» мәктәпләрнең берсендә (Күкчәтау шәһәрендә) укыдым. Казах халкының бөек улы, зур фикер иясе һәм шагыйре Абай әсәрләре белән беррәттән, без Тукай шигырьләрен дә ятлый, комарланып укый идек» (Җакан Сыздыков).

«Мин ул шигырьне (сүз «Шагыйрь» әсәре турында бара) сүзен сүзгә диярлек яттан беләм. Яшәүнең үлем өстеннән тантана итүе, минем аңымны киңәйтеп, күңелемдәге иҗат тойгысын көчәйтеп, тормыштагы урынымны билгеләде» (Педер Хузангай).

«Урта Азия халыкларының, шул җөмләдән төрекмән халкының да, әдәбияты үсүендә татар әдәбиятының хезмәте күп һәм олы. Тукайны да, Ибраһимовны да мин үземнең остазларым дим» (Берды Кербабаев).

«Г. Тукайны фәкать татар халкының шагыйре дип кенә әйтү җитми. Тукай — үзбәк халкы арасында билгеле һәм танылган шагыйрь» (Гафур Голәм).

«Габдулла Тукай уйгур халкының сөеп укый торган шагыйре генә түгел, бәлки әдәбиятыбызның үсеп камилләшүенә

лаеклы өлеш кушкан мәшһүр татар шагыйредер» (Г. Сәгъдеваккасов).

Менә бу әйтелгәннәрдән күренгәнчә, Г. Тукай үзе дә күп кенә халыкларның язучылары өчен остаз булган, аның иҗаты аларга үрнәк булып хезмәт иткән.

Сораулар һәм биремнәр

1. Башка халыкларның әдәбият әһелләре Г. Тукайның шагыйрь булып җитлегүенә ничек тәэсир иткән?

2. Казах шагыйре Җакан Сыздыков һәм чуваш шагыйре Педер Хузангай Г. Тукайның «Шагыйрь» исемле әсәренә нинди бәя бирәләр? Бу шигырьне яттан сөйләгез.

3. Башка халыклар әдәбият әһелләренең Г. Тукайга мөнәсәбәтле әйтелгән фикерләренең кайсы якларына игътибар иттегез? Шуларны тәфсилләп аңлатыгыз.

Шагыйрьнең тәнкыйть һәм гыйлем өлкәсендәге эшчәнлеге

Г. Тукай иҗатының зурлыгы аның шигъри әсәрләрендә генә түгел, бәлки тәнкыйть һәм әдәбиятка, тарихка караган гыйльми хезмәтләрендә дә күренә. Ул үзенә кадәрге шагыйрьләр иҗаты белән яхшы ук таныш булган һәм аларга карата шәхси мөнәсәбәтләрен дә әйтеп барган. Мәсәлән, «Шигырьләребез» дигән мәкаләсендә (1907) Габделҗәббар Кандалый шигырьләрендәге «әдәпкә һәм әдәбиятка хилаф җирләре» булуга игътибар итсә, «Суфи Аллаһыяр вә Утыз Имәни хәзрәтләре... нәзымлырак шигырь сөйли белмешләр исә дә, тик тәсаувыф бабында (суфилыкка бәйләнешле.— *Ф. Г.*) гына сөйләгәннәр. Әгәр ул әфәнделәр дөньяга вә аның халкына да бераз илтифат итеп дөньядан киткән булсалар, хәзерге көндә исемнәре тагы да артык хәер илә зикер ителер иде» дигән нәтиҗә чыгара. Ә инде Мифтахеддин Акмулла хакында «аның шигырьләренә бик күп тәгассыб (искелек.— *Ф. Г.*) катнашкандыр, һәм дә безнең татар рухына, татар халкына бер дә тәэсире юктыр, шигырьләреннән тик казах исе, күчмә халык исе чыгып торадыр» дип куя.

Әйе, әлеге шагыйрьләргә бирелгән бу бәяләр белән килешергә һәм килешмәскә мөмкин. Әмма шунысы мөһим: Г. Тукай аларның әсәрләрен белгән генә түгел, бәлки сәнгатьчә эшләнешләре, эчтәлекләре һәм башка хасиятләре ягыннан тәфтишләп, таләпчән өйрәнгән. XX гасырның беренче ун

елында аеруча күп язган Мәҗит Гафури һәм Нәҗип Думавиларны «ике бөек шагыйрьләребез» дип атавы да аның үз чоры әдәбиятыннан яхшы хәбәрдар булганлыгын һәм каләмдәшләренең уңышына сөенеп яшәгәнлеген күрсәтә.

Шагыйрь татар әдәбиятында тәнкыйть булырга тиеш дип карады. 1907 елда ул бу турыда «Тәнкыйть — кирәкле нәрсә» дигән махсус мәкалә дә язды. Аның фикеренчә, башка хезмәт белән шөгыльләнгән кеше басылып чыккан барлык әсәрләрне дә укып бара алмаска, укыганда да, өстән-өстән генә күз йөгертеп узарга мөмкин. Шуңа күрә аның «иң яхшы һәм мәгънәле» юллардан берни дә бирми торган буш урыннарны аерып бетермәве дә ихтимал. Шуның өчен аларны әйбәтләп укып, җитешле-җитешсез якларын аңлатып баручы махсус укымышлылар — тәнкыйтьчеләр кирәк. Китаплар нур һәм мәгълүмат тарату белән бергә томаналык вә әхлаксызлык алып килергә дә мөмкиннәр. Кайбер укучылар үзләренең зәвыкларына туры килүче әсәрләрне таба алмый йөриләр. Бигрәк тә яшь кешегә «яхшы рисалә табу борчак басуы өстендә бер билгеләнгән борчакны табу кадәр читендер».

Шул ук вакытта Г. Тукай тәнкыйтьчегә зур таләпләр дә куя. «Тәнкыйть итүченең дә кем очрады, шул булуы тагы ярамыйдыр». Тәнкыйтьче булу өчен, аның ышануынча, «әлбәттә, үзләре дә әдәбият галәмендә күп ат уйнаткан тәҗрибәле вә әхлаклы адәм булуы» таләп ителә. Чөнки шәхси файданы күздә тотып, тәнкыйть итүчеләр дә күп. «Җәмәгать фикере белән уйнарга ярамый»,— дип кисәтеп тә куя бөек шагыйрь.

Күрәбез, Г. Тукай тәнкыйтьнең асылы, бурычлары, ул өлкәдә эшләүченең нинди сыйфатларга ия булырга тиешлеге турында дөрес һәм урынлы әйткән. Мәсәлән, шул чордагы барлык язучыларның һәм журналистларның иҗатына тискәре бәя биргән берәүгә Г. Тукай болай дип җавап кайтара: «Сез охшашы күрелмәгән бер бөек кеше икәнсез... Ярый, язучылар, Сезнеңчә, начар һәм яраксыз кешеләр булсыннар, ләкин Сез үзегез милләткә нәрсә эшләдегез? Милләтнең хәзергесе һәм киләчәге өчен файдалы чәчмә яки тезмә берәр нәрсәгез бармы? Күрсәтегез, бер тапкыр тикшереп карыйк та, башкаларның язганнары бөтенләй ташлансын, онытылсын... Һәр язучының үзенә бер... тоткан юлы бар; шуңар күрә аларны тәнкыйтькә ашыкмаган булсагыз да ялгыш булмас иде. Һәр язучы... каләмен чылбырлап куйса, ...кемнәр язар? Сезгә тәнкыйть итәргә нәрсә калыр?

Без: «Бу шигырь барлык кимчелекләрдән пакь»,— дип язмадык лабаса! Без культура дөньясының әлифбачысы гына әле. Айлар, еллар үтәр, әлифбадан үтеп, югары күтәрелербез».

Әнә ничек бөек шагыйрь барлык китапларны, әсәрләрне һич кенә дә бер селтәнүдә юкка чыгару ягында түгел, мондый карашта торучыларны сабыр булырга чакыра. Башкалар иҗаты хакында фикерен әйтергә алынган кешенең моңа хакы һәм әзерлеге булырга тиеш. Бары тик үзе әдәбият үсешенә каләме белән ярдәм иткән шәхес кенә төпле сүз әйтә ала. Аның шагыйрь, язучы, драматург булуы мәҗбүри түгел. Әнә В. Белинский, Н. Добролюбов рус әдәбиятында бары тик тәнкыйть хезмәтләре язу белән генә шөгыльләнгән. Димәк, сүз сәнгатенең үзенчәлеген нечкә тоеп, гадел эш итүче тәнкыйтьче генә әдәбиятның абруйлы әһеле була ала. Әсәрнең үзеннән чыгып түгел, бәлки теге яки бу язучыга шәхси мөнәсәбәт буенча тәнкыйть язучыларны Г. Тукай «Мөнтәкыйд» («Тәнкыйтьче») шигырендә дә чыбыркылады:

Җил тегермәнен күрә дә: «Аһ, суы юк!»— дип куя,
Су тегермәнен күрә дә: «Пары, буы юк!»— дип куя.

Ул тота ат койрыгын да: «Бу — озын сач!»— дип куя,
«Тик нигә башта түгел, тәнкыйтькә мохтаҗ!»— дип куя.

Һәр язучы иң әүвәл үз-үзенә, шәхси иҗатына карата тәнкыйть белән карарга тиеш. Г. Тукай шундый иҗатчы булды. 1913 елда ул «Уянгач беренче эшем» дигән мәкалә яза. Үзенең җиде ел буе иҗат иткәннәрен күздән кичерә, йомшак, җитәрлек дәрәҗәдә сәнгатьчә язылмаган дип уйлаганнарын «чүп» дип атый. Шул «чүпләрне» бүлмәсеннән чыгарып ташлый. «Бүлмәмдә,— ди ул,— «үз сөйгәнем», «үз сөйгән шигырьләрем» генә калдылар. Рухани бүлмәмне бертөрле тазартырга вакыт эзли идем вә һаман Алла юл ачар әле дип өмидләнә идем. Менә Алла юл ачты, «бүлмә» себерергә бушадым. Себереп тә чыгардым. Әй җир йөзендәге төрек баласы, галимме син, хакимме син, падишаһмы син, теләнчеме син, инде мин сине өемә кертергә оялмыйм, инде син кем булсаң да, мин сиңа такмак китабымны мәгаль ифтихар[1] һәдия итә[2] алам.

---

[1] *Мәгаль ифтихар* — мактана-мактана.
[2] *Һәдия итү* — бүләк итү.

Тиз арада, ...үзем яраткан шигырьләрдән җыеп, 400 сәхифәле[1] зурлыгында рәсемле бер мәҗмуга[2] чыгарырга карар бирдем».

Бу — үз иҗатыңа гаять җаваплы карауның гыйбрәтле мисалы. Шушы сүзләрдән күренекле шагыйрь Сибгат Хәким мондый нәтиҗә ясый: «Тукайның мәкаләсендә шагыйрьләрне уйландыра торган нәрсәләр күп. Тукай, моңа хәтле язганнарын тәнкыйть аша үткәреп, яхшыларын начарларыннан аера... Менә үз-үзеңә тәнкыйть нинди була икән.

Тукайдан өйрән дә өйрән...»

Бөек шагыйребез үзенең замандашлары Г. Исхакый, Г. Камал, М. Гафури, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй, Н. Думави, Г. Ибраһимов иҗатларына карата фикерләрен белдерә. Аларның әсәрләрендә үзен канәгатьләндергән яклар турында кинәнеп язса, кимчелекләрен, Г. Тукайга хас булганча, кылычтай үткен теле белән ярып сала. Мәсәлән, М. Гафуриның «Кызларга махсус милли шигырьләр», «Ирләргә махсус милли шигырьләр» язуын килештерми, аларны «милләткә файда урынына зарар» дип бәяли. Ләкин бары тик әдәбият мәнфәгатен кайгыртып язылган мондый тәнкыйть хезмәтләре Г. Тукайга бу каләмдәшләренең күпчелеге белән әйбәт, кайберләре белән хәтта дустанә мөнәсәбәт сакларга комачаулык итми.

Әдәбиятыбыз үсешенә чын-чынлап киртә булып торган ул вакыттагы рәсми идеологиягә һәм цензорларга карата да усал-усал сүзләр яудыра. «Цензор белән он иләүче хатын арасында аерма шул гына: берсенең иләге төбендә — эшкә ашмаганрак нәрсәләр кала, берсенекендә — иң кадерле нәрсәләр генә кала». Ягъни язучының ихлас язган, шуның өчен үзенә дә кадерле тоелган фикерләрен яки әсәрләрен цензор дигән сакчы матбугатка үткәрми, сызып ыргыта. Шуңа күрә Г. Тукай, ачынып: «Кызмагыз, мәйданга чыкса чүпләрем»,— дип әйткән дә. Күренә ки, халык шагыйренең тәнкыйть өлкәсендә дә туры сүзле, гадел, аяусыз, таләпчән булуы, бигрәк тә үз-үзенә ташламалар ясамавы аның шәхесенә карата ихтирамны тагын да үстерә.

---

[1] *Сәхифәле* — битле.
[2] *Мәҗмуга* — җыентык, китап.

Сораулар һәм биремнәр

1. Г. Тукай, шигъри әсәрләр язудан тыш, иҗатның тагын кайсы өлкәләрендә каләм тибрәткән?

2. Шагыйрь үзеннән элек иҗат иткән каләм әһелләре әсәрләренә нинди бәя бирә?

3. Г. Тукай аңлатуынча, тәнкыйть ни өчен кирәк?

4. Иҗат кешесе үзе тудырганнарга тәнкыйть белән карарга тиеш. Г. Тукай бу яктан башка каләм әһелләренә нинди үрнәк бирә?

5. Г. Тукай үз замандашлары иҗатына нинди мөнәсәбәт күрсәтә? Аның цензурага карашы нинди?

Г. Тукай турында тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият фәне

Үз чорында ук Габдулла Тукай иҗатына битараф булмаганнар. Һәр әсәре, китабы җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп иткән, аларны укыганнар, язганнары белән килешкәннәр яки бәхәсләшкәннәр, мактаганнар яки ачуланганнар.

Г. Тукайның «иң беренче тәнкыйтьчеләре», әлбәттә, рәсми хакимиятләр була. 1911 елның 26 ноябрендә, мәсәлән, матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитеты Петербургка — Баш идарәгә шикаять җибәрә. Анда Г. Тукайны кайбер әсәрләре өчен җинаять җаваплылыгына тартырга кирәклеге әйтелә. Казан чиновниклары «шагыйрьнең «Китмибез!» шигыре өчен Җәзалар турындагы Уложениенең 1034 статьясы 3 пункты, «Хөррият хакында» шигыре өчен 129 статьясының 2 пункты, «Тавыш хакында», «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр» шигырьләре өчен 129 статьяның 6 пункт буенча гаепле булуын күрсәтеп» язалар.

Ә. Сәйдәшев дигән берәү, «Фикер» газетасында (1906, 3 июль) Г. Тукайның «Алай-болай» исемле мәкаләсе басылгач, газетаны судка бирә. Газета нәшире Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин бу материалларның авторы Г. Тукай булуын яшерә һәм ялгызы гына суд каршына баса. Аны ун көнгә полиция участогына ябарга хөкем итәләр.

XX йөз башында төрле социаль катлауларның ихтыярын чагылдырган вакытлы матбугат дәрьясында нindиләре генә булмый. Һәрберсе Г. Тукайның иҗатына үз мәсләгеннән һәм мәнфәгатеннән чыгып бәя бирә. Иҗат кешесе өчен үзе ныклап инанган кыйбласы булу бик мөһим. Бары тик шул

вакытта гына, ул бер яктан икенче якка тайпылдырырга тырышучыларга бирешмичә, торкан мәсләгенә туры барырга мөмкин. Г. Тукай туган халкының алга китүен, аның киләчәге яхшырак булуын теләде. Шуларны кайгыртып язган шагыйрь үзенә бик күп теләктәшләр тапты, шул ук вакытта дошманнар да җыйды.

Тәнкыйтькә карата куела торган төп таләп — гаделлек. Бары шул сыйфатка ия булганда гына, ул үзенең бурычын үти ала. Фатих Әмирханның шагыйрь Г. Тукай иҗатын өйрәнүгә багышланган мәкаләләре әсәрләрне эстетика кануннары буенча бәяләүнең матур үрнәге булып торалар. Шагыйрьнең өченче шигырь дәфтәрен бәяләүгә багышланган «Габдулла Тукаев шигырьләре» («Әлислах», 1907, 3 декабрь) дип исемләнгән мәкаләдә ул җыентыкта иске төрек теле белән язылып, гарәпчә, фарсыча, азәрбайҗанча, тагы әллә нинди телләрдән корылган шигырьләре күплегенә эче пошуын белдерә дә, саф татарча тел белән, халык арасында яши торган хыялый хикәягә нигезләнеп иҗат ителгән «Шүрәле» поэмасына югары бәя бирә. Әдәбият сөючеләргә һәм барлык шәкертләргә мәҗмуганы дикъкать белән укып чыгарга киңәш итә. Шагыйрьнең дүртенче дәфтәренә карата язганда («Әлислах», 1908, 9 февраль) Ф. Әмирхан каләмдәшенең әсәрләрен туган телебездә иҗат итүенә сөенүен белдерә: «Бу мәҗмуга... гүзәл шигырьләр белән тутырылган»,— ди ул. «Китмибез!», «Ишек бавы», «Хөррият хакында», «Бер шәехнең мөнәҗәте», «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр», «Рәсемгә ишарә», «Бер газета идарәсе хәленнән», «Көз» исемле шигырьләрне аерып күрсәтә. Шул ук вакытта тәрҗемә итеп язылган «Охшату» һәм «Мужик йокысы» әсәрләренең бу җыентыкта урын алырга тиеш түгеллеген дә әйтә. Беренчесенең тупас теленә игътибар итсә, икенчесеннән тормышны җитәрлек белмәү күренеп торуын искәртә. «Мал юк дип зарланма, үзеңнән күр аны» дигән шигырьләрнең мәгънәләре берлә Россия җир тарихын вә сәясәтен белгән кешеләр канәгать итмәячәктер»,— дип куя. Ф. Әмирхан мәкаләне шагыйрь алдына бурыч кую белән тәмамлый: «Моннан соң Габдулла әфәндедән халис[1] татар телендә язылган озын-озын поэмалар көтәбез. Татар теленең (дикъкать итегез! төрек түгел) аз булса да алга атлавы өчен,

[1] *Халис* — чын, саф.

мотлак куәи шигърияле[1] затларыбызның тәсаннызгсыз[2] татар булып калулары лаземдер».

Шул ук вакытта Ф. Әмирхан Г. Тукайны әдәбиятның үзен ныклап белмичә генә тәнкыйть итүчеләрдән аралый. «Гафуриның теле җиңел, нәфис, ә Тукаевныкы бөтенләй мөмкин түгел» дигән берәүнең сүзләренә каршы ул Г. Тукайның саф татарча яңгыраучы шигырен мисал итеп китерә. Шул ук «тәнкыйтьченең» «Тукаевның шигырьләре муаффәкыятьсез[3] тәрҗемәләрдән гыйбарәт» диюенә карата болай ди: «Ул әфәнде рәхим итеп менә шушылар арасыннан муаффәкыятьсезлекләр күрсәтсен иде: «Шагыйрьгә», «Бишектәге бала», «Вәгазь», «Шиллердан», «Мәхбүс» һәм «Әлислах» сәхифәләрендә чыккан икътибаслары[4]».

«Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» сатирик поэмасы басылып чыккач, аңа да бәяне беренчеләрдән булып Ф. Әмирхан бирә («Әлислах», 1908, 24 ноябрь): «Тукаевның бу әсәрен һәм «Яшен»дә көлке шигырьләрен укый торгач, аңар татар галәменең иң оста юмористы диясем килә башлады».

Ә инде бөек шагыйрь вафат булгач, Ф. Әмирхан «Кояш» газетасында (1913 ел, иске стильдә 4 апрель) кайгы мәкаләсе бастыра: «Шималь[5] төрекләре бүген үзләренең иң мәшһүр, иң сөекле шагыйрьләрен күмәләр... Милләтебезнең бөтен халык җырларындагы төп аһәң, кайгы, хәсрәт, авыр моң аһәңе аның шигырьләрендә дә төп көй, әсас иде. Менә шуңар күрә аны халык бик яшьләй үз шагыйре итеп таныды; аны аңлады, ул җырлаган нәрсәләрнең үз рухындагы нәрсәләр икәнен тойды». Бу сүзләрдән Ф. Әмирханның каләмдәше Г. Тукай шәхесен һәм иҗатын никадәр хөрмәт иткәнлеге ачык күренә.

Ә менә Г. Ибраһимовка килгәндә, аның Г. Тукай иҗатына мөнәсәбәте үзенчәлеклерәк булды. 1910 елда язылган «Татар матбугаты» исемле мәкаләсендә ул болай дигән иде: «Хәзер шигырь мәйданында иң шәүкәтле һәм галибәле[6] рольне мөхтәрәм Тукаев уйный. Шул дәрәҗә ки, татар шагыйре диелүгәчә, укучы зиһенендә Тукаев мәүҗүд була[7]».

---

[1] *Мотлак куәи шигърияле* — шиксез шагыйрьлек, талантлы.
[2] *Тәсаннызгсыз* — чын-чынлап, ясалма түгел.
[3] *Муаффәкыятьсез* — эчтәлексез.
[4] *Икътибаслары* — ияреп язылган әсәрләре.
[5] *Шималь* — төньяк.
[6] *Галибәле* — җиңүле.
[7] *Мәүҗүд була* — пәйда була, барлыкка килә.

Әмма берничә елдан аның Г. Тукай иҗатына булган карашы кинәт үзгәрә. Бу хәлне Г. Ибраһимовның әдәбиятыбыз бурычларына, аның асылына булган күзаллауларының, ягъни эстетик карашларының үзгәреп торуы белән аңлатырга мөмкин. Иҗатын романтизмнан башлап, тәнкыйди реализм һәм социалистик реализм «мәктәбен» үткән әдип эстетика кануннарын аңлауда бөтенләй үк эзлекле булмады.

1913 елда ул «Татар шагыйрьләре» дигән хезмәтен яза. Ул анда шагыйрь булган кешегә билгеләмә бирә: «Шагыйрь — әгәр дә ул чын мәгънәсе илә шагыйрь булса, шөбһәсез, хиссият колы. Аның, шагыйрьлеге ягыннан караганда, салкын гакыл, коры мантыйк белән күп эше булмый». Г. Ибраһимов шагыйрьлекне шулай аңлавы сәбәпле, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәндләргә бик югары бәя бирә. Аның каравы Г. Тукайга карата ул аеруча таләпчәнлек күрсәтә. Шагыйрьнең башлангыч иҗатында татар сүзләрен аз куллануына игътибар итүе белән ул хаклы. Ләкин Г. Ибраһимов, бик кискен итеп, «Тукаев шагыйрьме, түгелме?» дигән сорау куя. Шагыйрьнең бары тик «хиссият колы»[1] гына булмавы, гомумән, аның мәхәббәт лирикасына азрак урын бирүе әдипкә ошамый. Халык мәнфәгатьләре турында язуны Г. Ибраһимов хәтта шагыйрьлеккә кимчелек китерә торган як дип карады. «Халык бөтен дөнья мөселманы өчен кайгырганда, Тукаев шуны җырлады; аннан миллияткә[2] күчкәч, аның теленнән татарлык аһлары[3] коелды... Шулай итеп, халык Тукаевта... үз күңеле эзләгәнен беркадәр таба килде. Вакыты белән Гафурины да күтәргән нәрсә шул иде... Анлар заманында шигырьдән фикер вә нәсихәт эзләгән халыкка азык булса да, хәзер әдәби кыйммәтләре калмаган».

Күрәбез, Г. Ибраһимовның Г. Тукайны хәтта шагыйрь дип тә таныйсы килми. Мондый бәягә Г. Тукайның замандашлары битараф кала алмадылар. Мәсәлән, Фәтхи Бурнаш бу фикерләргә каршы чыкты, Г. Тукайны шагыйрь буларак югары бәяләде. Г. Ибраһимовның һаман да шул «Татар шагыйрьләре» дигән хезмәтендәге карашларыннан ваз кичмәвен тәнкыйтьләде. Г. Ибраһимов аңа җавабында Г. Тукай турындагы карашы: «Моннан ун-унике ел элек ничек булса, әле дә шул көенчә калды»,— дип, үзенең бөек шагыйрьгә булган тис-

---

[1] *Хиссият колы* — хис, кичерешләргә бирелгән кеше.

[2] *Миллият* — милләт.

[3] *Татарлык аһлары* — татарлар турында кайгырту.

кәре мөнәсәбәтен тәкрарлады. Ләкин шагыйрьнең талантын Г. Ибраһимов барыбер кире кага алмады. Аннары үзе үк: «Ул халыкның эченә, җанына да төшә, хыял вә әкият дөньясына да керә»,— дияргә мәҗбүр булды.

С. Хәким бу турыда болай уйлана: «Галимҗан ашыккан, артык ашыккан... Икесе дә — зур шәхес. Араларына кермим. Тукай да, Галимҗан да усал. Тукай җавапсыз кала торган кеше түгел. Шәхси яратып бетермәүләр язганнарыннан күренеп тора... Галимҗанның Тукай турындагы мәкаләләрен халык кабул итмәде. Халык Тукайга бөтенләй икенче төрле бәя бирде... Халыкка күбрәк ышанырга кирәк икән. Халык үз улын кимсетергә ирек бирми. Дөреслек — халык ягында».

1917 еллардан алып 1990 елларга кадәрге чорда Г. Тукай иҗатын төрле вакытларда төрлечә бәяләүләр булды. Егерменче елларда, аны вак буржуа шагыйре дип атап, шагыйрь иҗатындагы халыкчанлык рухы инкарь ителде. Ул шулай утызынчы елларның урталарына кадәр дәвам итте.

Г. Тукай иҗатына электән үк гадел бәя бирүләр дә булды, әлбәттә. Әле Октябрь инкыйлабына кадәр үк Гали Рәхим «Тукаев — халык шагыйре» дигән мәкалә бастырды. Г. Сәгъди болай дип язды: «Тукай тезмәдә татарча яңа, садә әдәби тел эшләп бирде. Безне җиңел әдәби сөйләргә, саф рәвештә көйләргә өйрәтте. Анда чәчмәдә дә осталык күрәбез. Ул шигырь мәктәбе тудыра алды». Г. Исхакый да 1914 елда Г. Тукайга шәхес һәм шагыйрь буларак бик югары бәя бирде: «Тукай безнең олуг милли шагыйремез иде. Тукай — безнең мәктәп балаларымыз өчен, яшь буыныбыз өчен милли бер каһарманымыз. Тукай — безнең киләчәктә татар әдәбиятына салына торган таза бер нигеземез».

1939 елда Гали Халит «Халык шагыйре Тукай» дигән китабын бастырып чыгара. Ул Г. Тукайны халык шагыйре дип дәлилли. Моны ул шагыйрьнең «халык мәнфәгатьчесе» булуы, «халык тормышы белән бергә яшәве һәм халык поэзиясенә, халык талантына, халык рухына булган мәхәббәте» белән раслый. Г. Халитнең 1956 елда рус телендә басылып чыккан «Габдулла Тукай һәм XX йөз башында татар әдәби хәрәкәте» дигән китабы да гыйльми җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнде. Г. Тукайның тууына 100 ел тулуга багышлап чыгарылган биштомлыкның да гыйльми мөхәррире Г. Халит булды. Үзенең бу басмага язган кереш мәкаләсен ул «Халык җырчысы һәм Ватан улы» дип атады. «Чын сәнгать-

не, чын шигъриятне тудырган затлар бервакытта да үлмиләр. Халык рухын били алган сәнгать иясе үлемсез. Тукай да шундый», дигән нәтиҗә ясады ул.

1938 елда М. Җәлил Г. Тукайның Мәскәүдә рус телендә чыккан «Сайланма әсәрләр» җыентыгына кереш сүз яза (ул китапны төзүче дә М. Җәлил үзе була). Ул Г. Тукайны «бөек демократ шагыйрь» дип атый. Г. Тукай — «халыкның сөекле шагыйре һәм киләчәктә дә шулай булып калачак» ди. Гомумән, М. Җәлил бөек шагыйребезнең иҗатын барлау, туплау, өйрәнү, аның әсәрләренең берничә томнан торган академик басмасын чыгару турында кайгырта. Аның бу тәкъдимнәре 1939 елның 11 августында Татарстанның җитәкче органнарына язган хатында әйтелә. Шунда ук ул игътибарны башкалабыз Казанда Г. Тукайга һәйкәл кую, шагыйрьнең музеен ачу мәсьәләләренә дә юнәлтә.

Шагыйрьне халкыбызга якынайтуда һәм танытуда бик күп галимнәрнең һәм иҗат кешеләренең хезмәтен ихтирам белән телгә алырга кирәк. Г. Тукайга багышлап, шулай ук күп җырлар, музыкаль әсәрләр, рәсем һәм сынлы сәнгать әсәрләре иҗат ителде. Бөек шагыйребез халкыбыз рухында мәңге яшәячәк.

Сораулар һәм биремнәр

1. Г. Тукай иҗаты ни өчен үзе исән чагында да, соңыннан да әдәбият әһелләренең игътибарын даими җәлеп итә?

2. Г. Тукайга кайсы әсәрләре һәм аларда нинди фикерләр әйткәне өчен хөкемгә тарту белән яныйлар?

3. Камил Мотыйгый шагыйрьгә карата нинди игелек эшли? Гомумән, сез бу шәхес турында тагын ниләр беләсез?

4. Г. Тукайның дуслары да, аны күрәлмаучылар да була. Моның сәбәпләрен ничек аңлатырга мөмкин? Ул үзе бу турыда нәрсә ди?

5. Ф. Әмирхан дусты Г. Тукайга нинди мөнәсәбәт күрсәтә?

6. Г. Ибраһимов Г. Тукай иҗатын төрле елларда төрлечә бәяли. Моны ничек аңлатып була?

7. 1939 елда М. Җәлил халык шагыйре Г. Тукай шәхесен мәңгеләштерү, иҗатын тулырак өйрәнү буенча нинди бурычлар куя? Ул бурычларның барысы да бүген гамәлгә аштымы?

8. «Г. Тукай халык рухында мәңге яши» дигән фикерне сез ничек аңлыйсыз?

9. Г. Тукай шигырьләрен сәнгатьле уку бәйрәмен уздырыгыз.

10. Г. Тукай шәхесе белән бәйле урыннарга экскурсия оештырырга тырышыгыз.

Дәрдемәнд
(Закир Рәмиев)
(1859—1921)

Шәхес һәм язмыш

Талант иясе, гадәттә, шәхес тә була. Шәхес, диденме, димәк, ул кеше үзенә генә хас үзенчәлекләр белән аерылып тора. Талант белән дә эш шулай. Аның үз йөзе, бары тик аңарга гына хас булган сыйфатлары ачык төсмерләнергә тиеш. Кабатланса, ул шәхес тә, талант та булмый.

Гаҗәеп күренеш: XX йөз башы татар әдәбиятында шәхесләр дә, талантлар да күп. Шуларның берсе,— әлбәттә, Дәрдемәнд. Аны Габдулла Тукай белән дә бутамыйсың, Сәгыйть Рәмиев, Мәҗит Гафури белән дә. Ул — үзенә бер аерым шәхес һәм талант. Бер үк вакытта зур мал-мөлкәт иясе һәм чып-чын шагыйрь. Ике тәлинкәле үлчәүне күз алдыгызга китерегез. «Бер тәлинкәсендә — Дәрдемәнд шигырьләре. Икенче тәлинкәсендә — Дәрдемәнд — Закир Рәмиевнең алтыннары... Кайсы баса? Шигырьләре баса...» — дип язган иде С. Хәким.

Әйе, бездә бер үк вакытта миллионнарча сумлык байлыкка һәм югары дәрәҗәдә шигъри талантка ия булган бүтән каләм әһеле юк. Шунысы кыйммәт: З. Рәмиев (Дәрдемәнд) матди байлыгының да шактый өлешен милләтебезне аң-белемле, мәдәниятле итүгә тота. Шагыйрь булмыйча, бары тик татар халкына күрсәткән игелекләре өчен генә дә Закир һәм аның абыйсы Шакир Рәмиевләр рәхмәт хисләре белән тәкъдир ителергә тиешләр.

Иҗат каләменә тотыну өчен, кешене нәрсә дә булса борчырга, йөрәген туктаусыз бимазалап торырга тиеш. Һәр нәрсәсе

җитешле кеше өчен мондый сәбәп тормышында юктыр кебек. Ләкин кешенең күңелен кузгата торган нәрсәләр күп икән шул. Моны без Дәрдемәнднең әсәрләреннән яхшы күрәбез.

Җитмәсә, Закир Рәмиев үзенә тәхәллүс (псевдоним) итеп «Дәрдемәнд», ягъни хисле, моңлы кеше, Тукай әйткәнчә, хәсрәт чигүче дигән тәгъбирне ала. Бу инде Закир Рәмиевкә булган кызыксынуны, аның шәхесенең серлелеген тагын да көчәйтә сыман. (Г. Тукай да, Акмулла да аерым шигырьләрендә үзләрен «Дәрдемәнд» дип атаганнар.)

Дәрдемәнд Урал җирлегендә туып үскән, яшәгән, иҗат иткән. Ул 1859 елның 23 ноябрендә Оренбург губернасының Эстәрлетамак өязендәге Җиргән авылында туган. Хәзер бу авыл Башкортстанның Мәләвез районына керә (Мирсәй Әмир дә шушы авылда дөньяга килгән). Малайга өч яшь тулыртулмас вакытта, ягъни 1862 елның җәендә, Мөхәммәтсадыйк сәүдәгәр, гаиләсен алып, Орск өязенең Юлык авылына күчеп китә. Әниләре Хәнифә укымышлы хатын була. Рус телен һәм әдәбиятын яхшы белә. Закирны һәм аның абыйсы Шакирны башта өйдә укыталар. Аннары ике бертуган Моллакай авылындагы мәдрәсәдә белем ала. Закир 1880—1881 елларда Төркиянең Истанбул шәһәрендә яши, укытучылар яллап төрек телен, әдәбиятын өйрәнә, тугандаш халыкның мәдәнияте, вакытлы матбугаты, тарихы белән кызыксына. Ул, татар теленнән тыш, гарәп, фарсы, төрек, рус телләрен белә.

Закир яшьтән үк сәүдә, икътисад кебек шөгыльләргә күңелен әллә ни салмый. Аны күбрәк яшәешнең рухи ягы кызыксындыра. Төркиядән кайткач, ул хәтта нәшрият ачарга да талпынып ала. Ләкин әле XIX йөзнең соңгы чирегендә патша хакимияте татарларның милли басмаларын һәм матбугатын булдыру омтылышларын тыеп килә.

Рәмиев фамилиясе XX йөз башы әдәбиятында еш очрый. Закир Рәмиев, Сәгыйть Рәмиев... Шагыйрь, журналист булган бу затларның тамырлары кая барып чыга соң?

Рәмиевләрнең нәселе борынгыдан ук аксөяк тамырга барып тоташа. Ерак заманнарда аларны «служилый (йомышлы) татарлар» дип йөрткәннәр. Ләкин Казан, Әстерхан ханлыкларын Россия дәүләте басып алгач, бу өстенрәк катлау кешеләрен чукынырга мәҗбүр итәләр. Чукынмаганнарының малмөлкәтен талап алалар. Рәмиевләр диннәрен сатмыйлар, чукынмыйлар, шуның өчен түбән катлау кешеләре исәбендә калалар. Ләкин нәселдән килгән (ерак бабалары Пётр патша-

да тылмач була) гыйлемлелек, зыялылык яңа буыннарга да күчә.

Нәсел-ыруларының тамыр очы Болгарга ук барып җитә. Ерак бабаларыннан берсе — Садыйк ахун — 1770 елда Зәй суы буендагы Тайсуган авылыннан Эстәрлетамак якларына күчеп килгән. Закирның бабасы Габделкәрим ару гына тормышлы кеше була. Аның малае Мөхәммәтсадыйк (Шакир белән Закирның әтисе) һәм бабалары буенча кан кардәш туганнар Лотфулла (Сәгыйть Рәмиевнең әтисе), Габдулла (журналист Исмәгыйль Рәмиевнең әтисе) бик тырыш, берне биш итәргә сәләтле кешеләр булып чыгалар. Габделкәрим малайларына хатын булырдай кызларны да үзе сайлап димли. Мөхәммәтсадыйгына, мәсәлән, Эстәрлетамак өязенең Явыш авылындагы морзалар нәселеннән килгән Әлмөхәммәт бине Ибраһим Дашковның кызы Хәнифәне яучылый.

Мөхәммәтсадыйк Җиргән авылында тормышын әйбәт кенә көйләп җибәрә, сәүдәсе киңәйгәннән-киңәя. Ләкин алга карап эш итәргә өйрәнгән Рәмиев Орск ягында алтын юу приискалары ачарлык казылма байлыклар булуын белеп ала һәм зур ният белән Юлык исемле татар авылына барып урнаша. Яңа урында бик тиз генә сәүдә эшләрен җайга сала. Алтын прииcкасы ачу өчен, җир сорап, Петербург юлын таптый. Ниһаять, 1869 елда, бирегә күчеп килүләренә җиде ел тулганда, беренче приисканы ачуга ирешә. Тора-бара егермеләп урында шундый приискаларның хуҗасына әверелә. «Восьмой» дип аталганында, Троицк мәдрәсәсендә укыганда, Мәҗит Гафури да бер җәй вакытлыча эшләп ала.

Рәмиевләр күченеп утыргач, Юлык авылының йөзе үзгәрә. Алар иң әүвәл таштан зур иттереп үзләренә йорт-җир җиткерәләр, кибетләр ачалар. Эшләре алга киткән саен, авылга ярдәмнәрен дә арттыра баралар. 1898 елда мәһабәт итеп таш мәчет торгызалар. Авылда зур мәдрәсә ачалар, озак та үтми, русча укыта торган мәктәп салалар. Хәлфәләрне, укытучыларны үз исәпләренә тоталар. Юлык тарихындагы беренче китапханәне дә алар нигезлиләр. Бу — Рәмиевләрнең китапка зур хөрмәт белән карауларын күрсәтә. (Сүз уңаенда әйтергә кирәк: 1919 елда бу китапханәдә мөдир булып драматург Мирхәйдәр Фәйзи эшли.)

Садыйк улы Закир Орск сәүдәгәре Борнаевның Мәһүбә исемле укымышлы кызына өйләнә. Мәһүбә укыту эшен оештыруга ихласлыгын күрсәтә. Егермеләп приисканың һәр-

берсендә малайлар һәм кызларга мәдрәсә ачу белән шөгыльләнә. Каргалыдагы мөгаллимәләр мәктәбенә дә җитәкчелек иткәне мәгълүм.

Өйләнешкәч, Закир белән Мәһүбә Оренбурга күчеп киләләр. Шәһәрнең үзәк урамында алар өчен махсус йорт төзелә. Бирелә дә алар җәмәгатьчелек эшенә, мәдәни-агарту шөгыленә керешәләр. Билгеле булганча, бу шәһәрдә «Хөсәения» мәдрәсәсе эшли. Аны тотучы Гани бай Хөсәеновның әнисе Нәкыя абыстай да Юлык кызы була. Ул авылдашы Рәмиевләрне үз күрә, еш кына гаилә мәҗлесләренә чакыра. Тиздән Закир Рәмиев шулай ук «Хөсәения» мәдрәсәсенең идарәсенә кертелә. Аның җәмәгать эшчәнлеге шәһәрдә тиз бәяләнә, З. Рәмиев Оренбургтан Дәүләт думасына депутат итеп сайлана.

1905 елдагы инкыйлаби көрәш кайбер демократик мөмкинлекләргә китерә. Татар телендә газета-журналлар булдыру турында күптән хыялланып йөргән Шакир белән Закир Рәмиевләр моннан файдаланып калырга тырышалар. 1906 елда «Вакыт» газетасын (ул башта атнасына өч тапкыр, 1909 елдан көндәлек булып әверелә), 1908 елда «Шура» («Киңәш») журналын чыгара башлыйлар («Вакыт»ның мөхәррире — Фатих Кәрими, «Шура»ныкы Риза Фәхреддинов була). Алар икесе дә 1918 елда ябыла. Шулай итеп, бертуган Рәмиевләр — татар мәдәнияте тарихында якты эз калдырган, исемнәре хөрмәт белән искә алынырга тиешле шәхесләр.

Рәмиевләр нәшер иткән газета-журналларның татар вакытлы матбугатын, әдәбиятыбызны һәм иҗтимагый фикерне үстерүдә өлешләре бик зур. Дөрес, Г. Тукай «Шура» журналын, төрек теленә якын бер телдә чыгарганнары өчен, тәнкыйть тә итә. Аның язышучыларын «төрек белән татар арасында калган әдипләр» дип атый. Әйе, XX йөз башында татар әдәби теле төрекчелек белән шактый чуарланган була. Шуңа күрә бу бер «Шура» журналына гына карамый, әлбәттә.

Закир Рәмиев нindирәк кеше булган соң? Рәсми рәвештә аталарыннан калган байлыкка бертигез дәрәҗәдә хокуклы булса да, күрәсең, Закир дөнья мәшәкатьләре белән әллә ни шөгыльләнергә яратмаган. Г. Ибраһимовның туганы Мохтарның истәлекләренә караганда, приискаларның берсенә җәйлеккә эшкә урнаштыруны үтенеп баргач, Закир болай ди:

— Прииска эшләренә мин катнашмыйм, шуңа күрә урнаштыра алмыйм,— ди һәм кесәсеннән бишәр сум акча чыгарып бирә.

Зариф Бәширинең искә алуына караганда, «аның барлык юанычы үзенең китапханәсендә матур әдәбият укып, язып көнен үткәрү» була. Ул үз акчасына чыга торган газета-журналлар эшенә дә катнашмый, аларны басылып чыккач кына укый, «Шура»ның мөхәррире Р. Фәхреддиновка үз шигырьләрен биргәндә дә:

— Ярарлык итеп тапсагыз, журналга кертерсез,— дия торган булган.

З. Рәмиевнең абыйсы Шакир 1914 елда вафат була. Аны әти-әниләре янына, Юлык авылы зиратына җирлиләр. Октябрь вакыйгаларын Дәрдемәнд, шулай итеп, ялгызы каршылый. Оренбургтагы йортын калдырып, Орскига күчеп китәргә мәҗбүр була. Типографиясен, алтын приискаларын яңа хакимияткә тапшыра. Шулай да аерылырга теләмәгән бер байлыгы була аның — ул да булса, гомер буе бөртекләп җыйган бик бай шәхси китапханәсе. Тик аңа бу байлыкны кайтармыйлар, әрәм-шәрәм итеп бетерәләр, утка ягып юкка чыгаралар. Шунда бергә кулъязма мирасын да юк итәләр. Шуларга карамастан З. Рәмиев хәленнән килгәнчә җәмәгать эшләрендә катнашырга тырыша. 1921 елгы ачлыкта халыкка ярдәм итү эшен оештыруга керешә. Ләкин кинәт чирләп китә һәм 1921 елның 9 октябрендә вафат була[1]. Аны Орскидагы күренекле кешеләрне күмә торган зиратта җирлиләр. Кызганыч, утызынчы елларда бу зират урынына шәһәр салалар. Шагыйрьнең кабере өстенә утыртылган истәлек ташы яңа салынган йортлар арасында аунап йөри-йөри дә аннары тәмам юкка чыга. Шулай итеп, татар әдәбиятының классик шагыйре Дәрдемәнднең күмелгән урыны, билгесез булып, йортлар астында кала. Әмма аның рухы, әсәрләре халык күңелендә һаман яши һәм шулай яшәр дә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Рәмиевләр нәселе һәм татар халкы язмышы. Бу турыда сез нәрсәләр әйтер идегез?

2. Юлык авылы һәм Рәмиевләр. Болар турынданиләр сөйли аласыз?

3. Мәгърифәт тарату эшенә бу гаилә керткән өлеш нидән гыйбарәт?

---

[1] Р. Фәхреддиновның «Асар» исемле хезмәтенең өченче томында Дәрдемәнднең үлү датасы 10 октябрь (һиҗри белән 1340 ел, 7 сәфәр) дип күрсәтелә.

4. Закир Рәмиевне сез, шәхес буларак, нинди кеше итеп күз алдына китерәсез?

5. «Октябрь вакыйгалары һәм Дәрдемәнднең язмышы» дигән темага әңгәмә уздырыгыз.

6. Язучы Л. Хәмидуллинның «Офыктагы рәшәләр» исемле әсәрен (Казан : Татар. кит. нәшр., 1990) укыгыз һәм фикер алышыгыз.

Дәрдемәнднең иҗаты

Шагыйрь булып булмый, шагыйрь булып туалар, диләр. Бу фикердә, чыннан да, дөреслек бар. Урал табигатенең гүзәллеге, Агыйдел, Сакмар, Ор, Җаек елгаларының ашкынлыгы анда яшәгән һәркемгә бердәй шагыйранә тәэсир итәргә тиеш иде. Закирдан берничә яшькә өлкән абыйсы Шакир әнә бу күренешләр белән артык нечкәләнеп тора алмый, бәлки биредәге табигый мөмкинлекләрне гаилә байлыгын ишәйтү максатларында уңышлырак файдалану хакында уйлана. Каты куллы тынгысыз эшкуар һәм нечкә-нәфис күңелле шагыйрь җанлы зат. Аларны менә шулай бәяләргә булыр иде. Ләкин Закир һәм Шакир бу сыйфатлары белән бер-берсен тулыландыралар. Абыйсының мәгърифәтне үстерү эшенә зур чыгымнар тотуга каршы тормавында, ихтимал, энесенең дә тәэсире булмый калмагандыр дип уйларга кирәк.

Шакирның 1881 елның 16 мартында Истанбулдагы энесенә язган хатыннан күренгәнчә, аның үзенең дә алдынгы карашлы булуы сизелеп тора. Закир Истанбулдан өйгә «Тәрҗеманы хакыйкать» исемле газета җибәреп тора башлаган. Абыйсы шуны рәхәтләнеп укуларын хәбәр итә. Тагын «Һәфтә» кебек берәр журнал, яхшырак эчтәлекле газета, төрле китаплар, алдынгы карашлар сурәтләнгән романнар җибәреп торуын үтенә. Шунысы кызык: Төркиядән килүче ул газеталар да цензор аркылы узганнар, «бәгъзе җирләрен кара бояу илән буяп җибәрәләр» дип уфтана Шакир. Монда «Гаспринский газетасыннан да (сүз «Тәрҗеман» турында бара.— *Ф. Г.)* бәгъзе адәмнәр өркешеп, ерактан гына таяк илән төртеп, «газета дөнья бозылырга илтә» диешәләр... «Безем милләт өчен исеме китап улсын, газета улмасын»,— ди. Шуңа күрә ул энесенә Төркиядән башта китап бастырырдай типография җиһазлары, шрифтлар сатып алу хәстәрен күрергә куша. Әлбәттә, ул типография ачудан, эшкуар буларак, матди файда алуны күздә тота, бу турыда хатта ишарә дә бар. Ләкин шунысы

хак: Рәмиевләр икесе дә заманының алдынгы карашлы кешеләре булган, гомуми яңарыш, үсеш турында кайгырткан.

«Миллионер-алтынчы онытыла бара, шагыйрь Дәрдемәнд телдә. Карт буын да, яшь буын да белә... Ник?» дигән сорау куя С. Хәким. Чыннан да, ник? Бу сорауга бергәләп җавап эзләп карыйк.

Дәрдемәнд кулына иҗат каләмен 1881 елда Төркиядән кайткач ала. Ләкин ул язган әсәрләрен бастырырга омтылмый, аларны язмый кала алмаганга иҗат итә. Хәер, XIX гасырның соңгы чирегендә әле әдәби әсәрләрне дөньяга чыгарырлык вакытлы матбугаты да булмый. Дөрес, мондый сәләтле һәм күренекле кеше, әгәр теләсә, Казан университеты типографиясендә китапларын чыгарта алган булыр иде. Дәрдемәнд, яше кырыктан ашкач кына, 1902—1903 елларда, кайбер шигырьләрен Кырымның Бакчасарай шәһәрендә чыгарыла торган «Тәрҗеман» газетасында бастыра. «Үткән көннәр» дигән шигырен исә Р.Фәхреддинов 1903 елда басылган «Әсма, яки Гамәл вә җәза» исемле озын хикәясенә кертеп җибәрә. Әсәр хикәядә сурәтләнгән Сәлим карт образы авызыннан яңгырый.

Шулай да Дәрдемәнднең чагыштырмача актив яза башлавы 1905—1907 елларга туры килә. Нечкә күңелле кеше буларак, ул илдәге хәл-әхвәлләргә борчыла, гаделсезлекләргә җаны сыкрана. Халык хәрәкәте җәмгыятькә нинди дә булса җиңеллекләр китермәсме дип уйлый. 1905 елның 24 ноябрендә Ф. Кәримигә язган хатыннан да моны сиземләргә була. «Хода кушып та тизлектә хөррият там галәбә тапса, (ягъни хөррият тулы җиңүгәирешсә.— *Ф. Г.*) хәзерге... мәванигълардан (каршы торучы сәбәпләрдән.— *Ф. Г.*) котылыр идек». Язма сүзгә, каләм көченә ул зур өметләр баглый. «Казан мөхбире» газетасының 1906 елның 6 февраль санында басылган «Каләмгә хитаб» («Каләмгә эндәшү») шигырендә бу бик ачык күренә. Каләм — күңелдәге серләрне түкми-чәчми, яшермичә ачып салырга тиеш. Бу шигырь эчке рухы белән үткәннәргә юнәлгән. Ә үткәннәр, моңа кадәр дөньяга килеп-киткәннәр турында бәян иткәндә, күз яшьләре түгелү табигый дигән фикер үткәрә шагыйрь. Шуңа күрә, кулга каләм алуга, аннан моңлы уйлар тама. «Кара тупрак[1] тулы мәзлум нидасы[2],

---

[1] *Тупрак*— туфрак.
[2] *Мәзлум нидасы* — җәберләнгәннәр аһ-зары, авазы.

алар кемдер?.. Алар кемнәр фидасы[1]?» Әлбәттә, бу аһ-зарны аерым бер кешегә, гаиләгә, нәсел-ыруга гына мөнәсәбәтле дип, даирәне тарайтып уйларга да мөмкин. Ләкин киң итеп, тарихи тирәнлек, әйтергә кирәк, хәтта галәми колачлылык белән уйларга күнеккән Дәрдемәнд бу очракта да, «килеп кичмешләр әхвәле» дигәндә, тулаем милләтебезне, аның гасырлар түреннән килгән ачы язмышын күздә тота.

Патша Россиясенең мөселманнарга карата булган кимсетүле мөнәсәбәте, әлбәттә, аның ата-бабаларына да кагылмый калмаган. Рус булмаган халыкларны сәяси, иҗтимагый, гыйльми, мәдәни мәсьәләләрдә түбән дәрәҗәгә кую, дөресрәге, бу өлкәләрдән читләштерү төп максат булып торган. Мәсәлән, һәрвакыт мөселманнарның берләшүеннән өркеп яшәгән полиция шымчылары 1910—1912 елларда «панисламизм» дигән өрәк уйлап чыгаралар, аңа каршы көрәшү өчен, шуның үзәген «эзләп табарга» телиләр. Аларның төп игътибары, әлбәттә, Казанга юнәлә. Булмаган нәрсәне алай җиңел генә табып буламы? Аптырагач-йөдәгәч, бу үзәк Оренбургта түгелме икән дигән уйга киләләр. Монда исә күләгә иң әүвәл «Шура» журналын һәм «Вакыт» газетасын чыгаручы Закир һәм Шакир Рәмиевләргә төшә. 1911 елның 22 августында Дәрдемәнд суд тикшеренүчесенә чакырыла. Күрәбез, патша хакимияте татарның өске катлавыннан да курыккан. Шулар нәтиҗәсе буларак, З. Рәмиев рәсми рәвештә «Вакыт» газетасы нәширлегеннән чыгарга һәм алтын приискалары эше белән генә шөгыльләнүче кеше булып күренергә карар кыла.

Шунысын әйтергә кирәк: жандармнарның Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Коләхмәтов, Г. Тукай, Г. Камал, М. Гафури, Дәрдемәнд, Ф. Кәримидән панисламизм эзләүләре ялгыш иде. Бу каләм әһелләре үзләре панисламизм идеяләренә каршы чыктылар. Тик Россиядәге унсигез миллион мөселманның берләшүе «рус дәүләте өчен хәвефле» булачагыннан шөлләгән чиновникларга төймә дә дөя булып күренгән. Дөрес, ул чорда татар җәмгыятендә Габдерәшит Ибраһимов (Рәшит казый), Закир Кадыйри кебек шәхесләрнең мәкаләләрендә һәм кайбер язмаларында исламга аерым бер хөрмәт белән карауны күрергә мөмкин дә булгандыр. Әмма хакимият әһелләренең игътибары, барыннан да элек, халыкка аеруча көчле йогынты ясаучы күренекле әдәбият эшлеклеләре иҗатына юнәлгән

[1] *Фидасы* — корбаны.

иде. Иҗатында сәясәткә шактый битараф булырга тырышкан Дәрдемәнд тә шулар рәтенә кертеп каралды. Аның нәширлегендә чыккан газета-журналларның аерым саннары тыелды, нәширенә штраф салынды.

Мондый эзәрлекләүләр Дәрдемәндне үткәннәр турында тирәнрәк уйланырга, татарның ул вакыттагы хәле һәм киләчәге турында тагын да ныграк борчылырга мәҗбүр итә. Бер шигырендә әйтелгәнчә:

Кил, дустым, хафа булма — бетәр бу;
Килер бер көн — китәр хәсрәт, үтәр бу!—

ди ул.

Дәрдемәнд, гомумән, үзенең әсәрләрендә язмыш, тәкъдир турында уйланды, тарих тарафыннан бирелгән язмышның котылгысыз булуы аның җанын бимазалады.

Күп еллар буена Дәрдемәндне саф сәнгать тарафдары дип йөрттеләр. Моны раслау өчен, аның Г. Тукайга атап язган «Шагыйрьгә» (1907) дигән шигырендәге шушындый юлларга таяндылар:

Ала кошларга бакмакча,
Газизем, булма такмакчы;
Матур гөлләргә бул былбыл,
Нәзакәт сагына сакчы!

Бу ике шагыйрь арасында кечкенә генә бер аңлашылмаучанлык килеп чыгу уңае белән язылган әлеге әсәрдә Дәрдемәнд Г. Тукайның талантына зур бәя бирә, аны «шагыйрь», «яңа былбыл» дип атый, вак-төяк такмаклар язып, ала каргалар рәтенә төшүдән кисәтә, ягъни талантына бәрабәр мәүзугъларга мөрәҗәгать итәргә киңәш бирә. Шигърият кануннарыннан чыгып караганда, монда бернинди дә хилафлык юк. Г. Тукай кебек үк, Дәрдемәнднең үзенә дә матур гөлләрне генә мактап җырларга туры килмәде, бәлки яшәешнең гаять күп якларына фәлсәфи бәя бирергә кирәк булды һәм шулар турында нәфис, гүзәл итеп яза белде.

Төрки халыклар шигъриятендә хикмәтле сүз әйтү дигән төшенчә бар. Хикмәт дигәндә кыска, төгәл, шул ук вакытта халыкчан шигъри афоризм күздә тотыла. Андый хикмәт, әлбәттә, үгет-нәсыйхәттән дә азат булмаган. Мондый сәләткә ия шагыйрьләр элек-электән зур хөрмәткә ия булганнар. Акмулланың «сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән»

дигән шигъри юлы бик күпләргә таныш. Үткен фикерле булу — үзе бер мәртәбә, ә инде шуны шигырь белән әйтеп бирә белү — тагы да кыйммәтле сыйфат. Акыл үткенлегенең бервакытта да кыйммәте җуелмый. XX йөз башы кебек гаять катлаулы бер чорда да хикмәтле сүз әйтү традициясе югалмады. Дәрдемәнд тә моның матур үрнәкләрен бирде.

Җитәкләргә тырыш дөньяи дүнәнне[1]
Икенең берсе: йә сине җитәкләр.

Яки:

Мөгзе бар кубның бары да кучкар[2] түгел,
Очкан кошның барысы да шоңкар[3] түгел.
Кемнәр әйтмәс шигырьне, әйтер берүк,
Чукаңлаган[4] аксак ишәк толпар түгел.

Яки:

Югарыга ташны аткан җүләрләр
Үз аңкау[5] башларын тишеп үләрләр.
Тишек тапсаң сиңа япкан ишектә —
Үзеңнең ертык аузыңнан көләрләр.

Аның «Яз чәчәге», «Җәй үтте» һәм башка шигырьләрен дә хикмәтнең матур үрнәкләре дип карарга мөмкин.

Нечкә күңелле шагыйрь буларак, Дәрдемәнд табигать күренешләрен сурәтләргә ярата.

Ятам кай чакларда моңлап,
Һаваның тынлыгын тыңлап.
Килә өнләр, колак чынлап
Диямен:
— Ни бу? Нидәндер бу?
Җавап урынында — гөрли су,
Тирәнлек тирбәнә, шаулый!..

Яки:

Гөрләгән сулар башында,
Тыңлагыз, шунда үтәр —

[1] *Дөньяи дүнән* — дөнья дигән яшь ат (тай).
[2] *Кучкар* — печтерелмәгән сарык тәкәсе.
[3] *Шоңкар* — лачын, ау кошы.
[4] *Чукаңлаган* — чатанлаган.
[5] *Аңкау* — аңгыра, миңгерәү.

Йөрсә сыктап таң-сәхәрләр
Моң-сагышлардан хыял.
И туган илнең һавасы,
Рәнҗемим, зинһар күтәр!
Рәнҗемим, зинһар күтәр!

Сораулар һәм биремнәр

1. «Миллионер-алтынчы онытыла бара, шагыйрь Дәрдемәнд телдә» дигән фикергә сезнең карашыгыз ничек? Үз уйларыгызны дәлилләгез.

2. Сезнеңчә ничек, Дәрдемәнд, кеше һәм шагыйрь буларак, нинди шәхес булган?

3. Иҗатының башлангыч чорында ни өчен ул әсәрләрен бастырырга ашыкмаган?

4. Илдә барган вакыйгалар белән аның иҗатының эчтәлеге арасында нинди бәйләнеш күрәсез?

5. «Каләмгә хитаб» шигырен ятлагыз һәм автор әйткән төп фикерне үз сүзләрегез белән аңлатыгыз.

6. Дәрдемәнд шагыйрьлекне ничек аңлый? «Шагыйрьгә» шигыре буенча шуны аңлатып бирергә тырышыгыз.

7. Шигърияттә хикмәтле сүз әйтү дигәндә, без нәрсәне күздә тотабыз?

«Уеңны уйдырып сал»

Дәрдемәнд — киная остасы. Аның шигырьләрен укыганда бик сизгер булырга, үткер фикерләрен тотып ала белергә кирәк. «Яз чәчәге» шигыре (1906 елның мартында язылган) беренче карашка табигать, аның матур чәчәге умырзая турында кебек. Умырзая язның башында ук чәчәк ата да башка үсемлекләрдән алда матурлыгын җуя. Шагыйрь дә әлеге дүртьюллыгында шул турыда тасвирлап бирә дип уйларга мөмкин. Ләкин шигырьнең исеме астына ул «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә мөнәсәбәтле язылуын әйтеп куйган[1]. 1906 елның башында бу уку йортында белем алучылар укыту программаларын үзгәртүне таләп итәләр, искечә укытуга ризасызлык белдереп, 82 шәкерт хәтта мәдрәсәне ташлап ук чыга. Күрәсең, Дәрдемәндкә бу әсәрен язарга шушы вакыйга этәргеч биргән.

[1] Мәдрәсәи «Мөхәммәдия» — 1882 елда Казанда ачылган мәдрәсә. Нигезләүчесе һәм мөдәррисе Галимҗан Баруди (1859—1921). Үз вакытында яхшы белем бирә торган мәдрәсәләрдән саналган. Аннан байтак күренекле шәхесләр: әдәбият, мәдәният, фән эшлеклеләре үсеп чыккан.

Шәкертлек чоры — кешенең яздай яшь, матур чагы. Аны киләчәк тормышка яхшырак әзерләнүгә файдалану мөһим. Тормыш җилләре егарлык булмасын. Умырзая (шәкерт дип аңларга кирәк) әле «исәр-исмәс... җиләс җил»дән дә бөгелеп, чәчәкләрен җиргә сипкән. Без биредә Дәрдемәнднең шәкертләр хәлен яхшы аңлавын күрәбез. Ул аларны әрләми, бәлки татар яшьләренең язмышына борчылуын «кәгазьгә түгә». «Яз чәчәге» шигыре белән бергә «Вакыт» газетасының 1906 елгы 22 март санында «Талчыбык» шигыре дә басылу очраклы түгел, аларның икесе дә бер үк мәсьәләгә багышланган. Белемгә омтылган татар шәкертен шагыйрь суга тилмергән тал чыбыгына охшата.

Кеше һәм вакыт. Кешенең вакыт түреннән кая таба баруы бик күп фикер ияләрен дулкынландырган. Иксез-чиксез тарих һәм галәм киңлегендә фикер йөртергә омтылган Дәрдемәнд тә үз алдына шушы фәлсәфи сорауны куймый кала алмаган. «Без» шигыре (1908, гыйнвар) шул турыда. Нинди озын булып тоелмасын, гасырлар да мәңгелек вакыт алдында бик кечкенә булып кала, нинди кодрәтле булса да, пәйгамбәрләр, падишаһларның да гомер чикләре бар. Хәтта илләр дә мәңгелек түгел. Шагыйрь гомерне комда калган эз белән чагыштыра. Җил иссә, ком бер урыннан икенче урынга күчә, эз җуела. Яшәеш мәңге хәрәкәттә, аның көче һәрдаим яңаны, камилрәкне тудыра алуында. «Дәрийгъ, мәхзүн күңел, без дә бетәбез!» («Үкенеч, аянычлы күңел, без дә бетәбез!») — ди Дәрдемәнд. Өметләрдән өемнәр хасил була, ләкин алар тора-тора чери, замана аңа ут төртә, нәтиҗәдә ут бөтенесен юкка чыгара.

Фәлсәфи куәсе ягыннан караганда, ихтимал, бу уйлануларда артык яңалык та юктыр, бәлки. Әмма безне шагыйрьнең шушы мәңгелек теманы үтә җыйнак, образлы, тәэсирле итеп бирә алуы сокландыра. Дәрдемәнд — татар шигъриятендә «кыскалыкта — осталык» дигән кагыйдәне исбат иткән талантлы сүз остасы. «Без» шигыреннән шул аңлашыла: шагыйрь кешегә бирелгән гомернең кыскалыгына, яшәүнең фанилыгына (тиз үтеп китүчәнлегенә) гаҗәпләнә. Аерым кеше өчен дә, шулай ук милләт өчен дә «мәэмүл чишмәи әбелхәят» (булыр дип фараз ителгән, мәңгелек яшәү бирә торган чишмә) табарга тели лирик герой. Ләкин таба алмавы аны борчуга сала, хәсрәтләндерә. «Бүзләрем мана алмадым» шигыре дә (1908, апрель) шул турыда.

Шигырьдәге лирик герой үз яшәешеннән, кылганнарыннан канәгать түгел. Бар булып саналган, ләкин кеше рәтендә абруй казана алмаган. Әнә Мәҗнүн белән Ләйлә, Фәрһад белән Ширин, сөешеп, мәхәббәт каһарманнары буларак дан алганнар, ә безнең лирик героебыз мәхәббәт утында «мең кабат янган», әмма кеше теленә менмәгән. Язмыш кемнәргәдер кавышу, кайсыларына өмет муллыгы биргән, ә бу өметнең сул кулыннан (игътибар итегез: сул кулыннан булса да) бер сынык икмәк ала алмаган. Ни өчен лирик геройга дөньясы гел кире килеп торган? Чөнки ул «илгә гашыйк» булып яшәгән. Ягъни шәхси язмышы өчен генә гамьләнсә, ихтимал, ул да кайсы яктан булса да өметләренә уңай җавап тапкан булыр иде. Әмма ил кайгысын кайгыртып йөргән кешегә күпчелек очракта каймаклы коймактан түгел, ә тукмактан өлеш чыга.

Ул үзенең ил гаме белән генә яшәвен яшереп кала алмый. Менә иртә-кич ил эченнән исүче җилләргә колак сала (ил йөрәге тибешен тыңлый), ләкин аннан килгән җил тавышы моңыннан үзенә ләззәтле көй ишетми. Аннан килгән хәбәрләр куанычлы түгел. Яшәешне үзгәртер өчен, тереклек суын, зәмзәм суын, милләт коесын еллар буе эзләсәң дә табып булмый. Инде менә гүргә керер вакыты да җиткән. Нинди үкенеч, кызганыч! «Кәфнем бүзләрен маналмадым!» — ди ул. Ягъни үзенең, милләтенең аянычлы язмышына куанычлырак үзгәреш кертә алмадым дип өзгәләнә. Лирик герой, шул рәвешле, яшәүдә якты төсләр күрми, күңел төшенкелегенә бирелә, аны моңа чынбарлык этәрә.

Күңел төшенкелеген җырлау Дәрдемәнд шигъриятенең бер үзенчәлеге кебек төс ала. Кайбер шигырьләреннән күңелдә моңсулык, ямансулык рухы кала. Ә укучының моның белән һич килешәсе килми. Югыйсә теләсә нинди караңгы дәвердә дә киләчәккә ышаныч уятырдай чаткылар кабынмый калмый бит. Ләкин аны тотып алыр өчен, бәлки, башкарак холыкфигыльгә дә ия булырга кирәктер. Юк, Дәрдемәнд иҗатында өметкә урын калдырган шигырьләр дә аз түгел.

Илдә бер дуст булмаса гәр,
Ил бөтен — дошман түгел! —

дигән икеюллык — шуның бер үрнәге.

З. Рәмиевтәй дәүләтле, абруйлы, шул ук вакытта бил бирмәс, үз дигәненчә көн күреп, үзенә бер дөнья хасил итеп

яшәгән кешене кемнәрнеңдер өнәмәве, якын итеп, үз итеп кабул итмәве аңлашыла. Бигрәк тә 1917 елгы октябрь аендагы үзгәрешләрдән соң мондый шәхесләргә җиңел булмады. Инкыйлабның шәхес иреге китермәячәген шагыйрь алдан ук күңеле белән сизде, моңа борчылды. Аңа байлыгын югалтудан бигрәк ирегеннән мәхрүм калу күп мәртәбә авыррак тәэсир итте. Әмма ул шулай да илнең тулаемы белән аңа дошман булмавын белә, үзенә кемнәрнеңдер теләктәш булуына ышана иде. Без югарыдагы юллардан Дәрдемәнднең тирән драмасын, хәтта фаҗигасен күрәбез. Сез җиденче сыйныфта өйрәнгән «Видаг», «Кораб», «Куанды ил» кебек шигырьләрдә дә аның үз илен өзелеп сөюче, туган җире язмышы турында гамьләнүче кеше булуын күреп үткән идегез инде.

Әйе, туган ил аңа кадерле, барыннан да өстен булды. Кайберәүләр, «Гөрләгән сулар башында» дип башлана торган шигырьне мисалга китереп, ихтимал, бу мәсьәләдә бәхәскә дә керерләр. Чөнки шагыйрь анда мондый сорау куя:

Ни газизрәк — бу ватанмы?

Әмма шунда ук җавап та бирә:

Аh, туган каүмем газиз!
Ул мөкатдәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр!..

Күрәбез, ватан белән туган кавем (нәсел, ары китеп —халык, милләт) капма-каршы куелган кебек. Ләкин бу беренче карашка гына. Мөкатдәс кан белән изге сөт биргән кавемнең туган йорты газиз булмыйча кала аламы?! Дәрдемәнднең бу мәсьәләдә үз фикерләрен аеруча ачык итеп белдергән дүрт юллыгы бар:

Ата-анам йорты өчен
Булса мең җаным фида;
Туган үскән җирем өчен
Соң тамчы каным фида.

Биредә туган илгә (ата-ана йортына караганда) өстенлек бирелүе күренеп тора. Әмма инкыйлаб вакытында язылган «Гөрләгән сулар башында...» шигырендә дә ул туган илгә рәнҗемәвен белдерә. Аның өчен «гөрләгән су башы» — инкыйлаб ул. Шуңа күрә «ватан» дигәнендә дә инкыйлаб иле дигән төсмер бар. Шагыйрь өчен шул нәрсә аңлашыла: андый ва-

тан — инкыйлаб ватаны, ул үзгәрергә дә, ят булып әверелергә дә, хәтта китәргә дә мөмкин икән. Әмма нинди генә шартларда да «сөт калыр» ди шагыйрь. Ягъни ана сөте — нәсел-ыру, кешене нинди генә шартларда да ят итмәүче, читкә тибәрмәүче газиз нәрсә.

Сөт калыр, ватан китәр!
Сөт калыр, ватан китәр!

Бүгенге чынбарлыктан да без Дәрдемәнднең никадәр тирәнтен фикер йөртүенә ышана алабыз.

Әйе, әкренләп ватан дигән әйбернең асылы да, чикләре дә үзгәрә тора. Әмма кешенең кан кардәшлек, милли рух ягыннан булган бердәмлеге нинди шартларда да сакланып кала. Дәрдемәнд моны бер шагыйрьдә дә очрамаганча үзенә генә хас кыскалык һәм фикер тирәнлеге белән әйтеп бирде. Күренекле әдип Ә. Еники дә шагыйрьнең бу юлларда әйткән фикерен шулайрак аңлый. «Бу сүзләрдә,— ди ул,— тирән мәгънә ята: ватан китсә дә, «изге сөт» кала. Аерым кешеләр язмышында гына түгел, бөтен бер халыклар язмышында да без моны ачык күрдек».

Ләкин бер нәселдән булган кешеләрне дә ана сөте генә берләштереп бетерә алмавын искәртә Дәрдемәнд. Туганнарны аера торган тагын бер нәрсә бар, ул да булса — байлык дәрәҗәсе.

Бертуганың чит тибәдер,
Дәүләт[1] тигез булмаса;
Ана сөтен айры имә,
Бала игез булмаса.

Бертуган балалар бер үк ана сөте белән ризыкланалар, ә менә үсә төшкәч, аларның ризыклану чыганаклары аерылырга һәм байлык кереме хәтта бертуганнар арасындагы сөт кардәшлегенә киртә булырга да мөмкин. Дәрдемәнд иҗатында, шул рәвешле, гадәти тормыш хәл-әхвәлләренә нигезләнгән фани дөнья фәлсәфәсенең матур үрнәкләрен шактый еш табарга мөмкин.

Дәрдемәнд ахыр чиктә үзенә, нәсел-нәсәбенә, милләтенә кирәкле бәхетне ил иминлегендә һәм бөтенлегендә күрергә теләде:

---

[1] *Дәүләт* — б и р е д ә: байлык, мал-мөлкәт.

Булырмы яз, исеп җилләр,
Килерме җәй, ачып гөлләр,
Җитәрме кыш, кичеп еллар,
Диямен, сез, газиз илләр.

Бу аның киләчәккә ышаныч, өмет белән каравы иде. Кешедә иң соңга кадәр яши торган нәрсә — өмет. Дәрдемәнд тә киләчәккә булган өметен үлгәнчегә кадәр өзмәде.

Алтын приискалары хуҗасы буларак, 1917 елгы хакимият алмашуның мал-мөлкәт иясенә ни китерәчәген аңлаган Дәрдемәнд үз урынының «үлекләр аймагында» икәнен таныды, тормыш туеның үзе өчен түгеллегенә төшенде. Үлем түшәгенә егылган Дәрдемәнд белән соңгы очрашуы турында Риза Фәхреддинов болай яза: «Оренбургтан Уфага сәфәремдә янына кереп видаг иттем[1]. Авырып түшәк өстендә иде. «Хәлем яхшыланадыр» дигәненә һәм дә үзенең беркадәре сөйләшәсе килүене белүемә күрә, янында беркадәр утырдым. Шулвакыт: «Хәзрәт, бу көнгә хәлләр беркадәр төзәлсә, без «Вакыт» бирлә «Шура»ны тәкрар[2] чыгарырмыз. Шул вакытта Оренбургка кайтып, әүвәлге хезмәтеңезне дәвам итүеңезне өмидләнәмез вә үтенәмез; сезнең берлә берлектә Хиҗаз[3] сәфәренә бару фикерем дә камил...» «Алла насыйп итсә, безнең тарафымыздан эш калмас»,— дип, видаг кылып чыгып киттем. Ахыргы күрешүем шушы булды».

Татар халкына байлыгы белән дә, каләме белән дә актыккы сулышына кадәр хезмәт иткән Закир Рәмиев кеше һәм иҗат остасы буларак менә шушындый шәхес иде. С. Хәким хаклы: иҗаты белән туган халкына, туган иленә шулай нык тоташкан шагыйрь онытылу түгел, еллар үткән саен, укучыларга якыная гына бара. Кешенең күңеленә үз уен «уйдырып» салу остасы булган Дәрдемәнднең иҗаты бүген яңа мәгънә һәм яңгыраш ала.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Яз чәчәге» һәм «Талчыбык» шигырьләрен нәрсә берләштерә? Бу шигырьләрне ятлагыз, сәнгатьле итеп укыгыз.

---

[1] *Видаг иттем* — хушлаштым.

[2] *Тәкрар* — кабат.

[3] *Хиҗаз* — Гарәбстанның көнбатышында Кызыл диңгез буендагы бер өлкә (башкаласы — Мәккә шәһәре).

2. Дәрдемәнд иҗатындагы күңел төшенкелеге чагылышының сәбәпләре нидә? «Без» шигыренә нигезләнеп, әлеге сорауга җавап табарга тырышыгыз.

3. «Бүзләрем мана алмадым» шигырендә шагыйрьнең гражданлык хисләрен чагылдыруының сәнгатьчә алымнарын билгеләгез.

4. 1917 елның октябрендә илдә булган вакыйгаларга Дәрдемәнднең мөнәсәбәте турында сөйләгез. Аның язмышындагы драматизмның чыганагы нәрсәдә?

5. «Ватан» төшенчәсен Дәрдемәндчә аңлау белән сез килешәсезме?

6. «Кеше һәм өмет» дигән темага сөйләшү уздырыгыз.

7. Дәрдемәнд шигырьләренең сәнгатьчә үзенчәлекләрен билгеләгез. Шигырьләрен күбрәк ятларга тырышыгыз.

* * *

Кешенең хисләрен, кичерешләрен гәүдәләндерүгә нигезләнгән шигырь, җыр, поэма лирик шигырь, лирик җыр, лирик поэма дип атала. Мондый әсәрләрдә шагыйрь сүзне, гадәттә, «мин» исеменнән алып бара. Ләкин бу әле, лирик герой белән әсәрне язучы шагыйрь бер үк затны тәшкил итә дип аңлау өчен, нигез була алмый. Дөрес, шагыйрь үз хисләрен дә гәүдәләндерергә мөмкин (М. Җәлилнең «Җырларым», Дәрдемәнднең «Видаг» шигырьләре, Г. Кутуйның «Сагыну» нәсере һ. б.). Шул ук вакытта күп кешеләр өчен уртак булган хис-тойгыларны гомумиләштереп язылган лирик әсәрләр дә була (Г. Тукайның «Туган тел», Дәрдемәнднең «Сабый» һ. б.). Ничек кенә булмасын, шагыйрь, лирик әсәр иҗат иткәндә, анда сурәтләнгән хисләрне үз йөрәге аша үткәрә. Ул аларга битараф кала алмый. Лирик геройның кичереш дәрәҗәсе төрлечәрәк булырга мөмкин, ягъни ул үзгәреп, көчәеп, кимеп, сүлпәнләнеп тә китә, шуңа күрә хис-кичереш хәрәкәте лирик әсәрнең сюжетын тәшкил итә. Лирик әсәргә, гадәттә, салмаклык, нәфислек хас. Аны лирик геройның монологы дип әйтергә дә мөмкин. Шуңа күрә лирик әсәрләр, гадәттә, салмак темп, йомшак тавыш белән укылалар. Бу исә лирик геройның табигатенә туры килә.

Әдәби әсәрдә үзенең эчке кичерешләрен, хис-тойгыларын нәфислек белән, укучының күңеленә үтеп керерлек итеп бәян итүче образны л и р и к г е р о й дип атыйлар.

Сәгыйть Рәмиев
(1880—1926)

Таң вакыты җырчысы

XX йөз башында гөрләп үсеп киткән татар әдәбиятында иң талантлы шагыйрьләрнең берсе Сәгыйть Рәмиев иде. Шактый кыска гомерендә бу иҗат әһеле шигърияттә, драматургиядә, прозада һәм публицистикада, ягъни иҗатның төрле өлкәләрендә эшчәнлек күрсәтергә өлгерде. Аның безгә калдырган әсәрләре артык күп түгел. Ләкин әдәбият-сәнгатьтә күләм иҗатның зурлыгын күрсәтмәскә мөмкин. С. Рәмиев «Таң вакыты» шигыре белән генә дә шагыйрьләребез рәтендә лаеклы урыннарның берсен алыр иде.

С. Рәмиев — үз заманының актив җәмәгать эшлеклесе, халыкның иҗтимагый аңын үстерүгә зур өлеш керткән, мәдәниятебезне чәчәк аттыру өчен ихлас янып-көеп яшәгән шәхес. Ул — әдәбиятыбызда үзенә лаеклы бәяне әле исән чагында ук алган бәхетле иҗат кешесе. Аның әсәрләрен XX йөз башы яшьләре дә үз итәләр. 1911 елда Буби мәдрәсәсе ябылгач, әллә кайдагы Әстерханда яшәүче С. Рәмиевнең фатирында полиция тентү уздыра. Чөнки Буби мәдрәсәсе шәкертләренең җыр-шигырь дәфтәрләрендә С. Рәмиевнең әсәрләре күчереп язылган була.

С. Рәмиевнең нәсел агачы Дәрдемәнд белән тоташа. Сәгыйть 1880 елның 12 февралендә Оренбург төбәгендә туган. Акман (Ибрай) авылында дөньяга килсә дә, аларның гаиләсе бер урында гына тормый, вакыт-вакыт күчеп йөрергә мәҗбүр була. Әтисе Лотфулла агач сату-алу, сал агызу эшләре белән шөгыльләнә. Шактый укымышлы кеше була.

Оренбург — татар, казах, башкорт кебек кардәш халыкларның бергәләп оешып яши торган төбәге. Бу якларда туып үскән Сәгыйть тә әлеге төрки милләтләрнең телен, җырларын, халык рухын кечкенәдән үк күңеленә сеңдереп үсә. Ул бай күңелле, нечкә хисле, төрле яклап талантлы шәхес булып җитешкән икән, димәк, тугандаш халыкларның рухи байлыклары белән кечкенәдән үк әнә шулай азыклануы моңа ярдәм иткән дигән сүз. С. Рәмиев Иләк шәһәрендә башлангыч мәктәпне тәмамлап, 1890—1902 елларда, ягъни унике ел буена Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыган вакытта, төрек, гарәп, фарсы телләрен һәм аларның әдәби үрнәкләрен нигезле өйрәнгән. Аннан өч сыйныфлы рус мәктәбен тәмамлау да булачак иҗат кешесен кирәкле белем күнекмәләре һәм гыйлем белән баеткан. Аның үзе укыган «Хөсәения» мәдрәсәсендә үк мөгаллим итеп калдырылуы күп нәрсә турында сөйли.

С. Рәмиев 1906 ел башында Казанга килә. Ул моңа кадәр үк, 1905 елгы революция көннәрендә, эсерларга якынлаша, шул даирәдәге Гаяз Исхакый йогынтысында була. Казанга килгәч, С. Рәмиевнең эсерлар тарафыннан чыгарылган демократик юнәлештәге «Таң йолдызы» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли башлавы, ә 19 июньнән аның мөхәррире итеп билгеләнүе очраклы түгел. Бу газета озын гомерле булмый, бары 65 саны дөнья күрә һәм патша хакимияте тарафыннан ябыла. С. Рәмиев үзе исә сәяси эшчәнлеге өчен бер ай төрмәдә утырып чыга. Ул «Тавыш» исемле газета оештырып карый. «Таң йолдызы»ның дәвамы рәвешендә «Таң мәҗмугасы» исемле журнал чыгару эшенә дә керешә, ләкин реакция чоры башлангач, Россиядә демократик ирекләр кысыла һәм татар телендә алдынгы фикерне таратучы вакытлы матбугатка да яшәү мөмкинлеге чикләнгәннән-чикләнә. Мондый кысулар «Бәянелхак» газетасына, «Дин вә мәгыйшәт» кебек журналга гына кагылмый, чөнки алар хөкүмәт сәясәтенә каршы килмиләр. С. Рәмиев, бөтенләй эшсез калгач, «Бәянелхак» (дөреслекне әйтеп бирү мәгънәсендә) газетасы редакциясенә эшкә керә. Г. Тукай үзенең якын дусты С. Рәмиевне моның өчен нык кына тәнкыйтьли, чөнки әлеге басманың юнәлеше ул мөхәррирлек иткән «Таң йолдызы» газетасы мәсләгеннән бик нык аерыла.

Тормыш бик катлаулы шул. Яшәү өчен журналистлык һөнәреннән башка килере булмаган кешенең «Казан мөхбире», «Бәянелхак» кебек газеталарда булса да эшкә урнашуы

гаҗәп тә түгел. Ихтимал, үзе эшли башлагач, газетаның юнәлешен аз гына булса да үзгәртеп булмасмы дигән теләге дә булгандыр. Әмма С. Рәмиев, өметләре акланмагач, 1910 елда Әстерханга китеп, андагы «Идел» газетасында сәркатип булып эшли башлый. Дөресендә, С. Рәмиев әлеге басманың мөхәррире хезмәтләрен үти.

Шунысына игътибар итәргә кирәк: кайсы гына газетада эшләмәсен, С. Рәмиев аның телен, төрек йогынтысыннан арындырып, халыкка якынайту гамәленә керешә. Бу аның иҗатында да чагыла. «Идел» газетасында күп кенә әйберләр бастыра: әдәби тәнкыйть мәкаләләре, шигырь техникасына караган хезмәтләре игътибарны җәлеп итә. «Татармы без, түгелме?» исемле мәкаләсендә барлык төрки милләтләрне берләштерү фикерен (пантюркизмны) якламавын белдерә, чөнки төрки милләтләрнең уртак яклары күп булса да, аларның бер-береннән үзгә булган нәрсәләре дә байтак. Шул сәбәпле, гомумтөркиләр өчен уртак мәсьәләләрне бергәләп хәл итә алсалар да, аларның аерым-аерым, үз көйләренә яшәүләре, үз көннәрен үзләре күрүләре әйбәтрәк. Ә менә гарәп язуыннан яңа алфавитка күчү, аның исәбенчә, татарлар өчен файдалырак булыр иде.

Шушы газетада эшләгәндә, ул Х. Ямашев, Г. Тукай вафатына багышлап мәкаләләр бастыра.

С. Рәмиев бер урыннан икенчесенә күчеп йөри, даими эше һәм тору урыны булмау сәбәпле, утыз дүрт яшенә җиткәч кенә өйләнә. Тик гаиләле булуына өч ай дигәндә, «Идел» газетасын ябалар һәм С. Рәмиевне Әстерханнан сөрәләр. Ул аннан хатынының туган җире Уфага китә. Биредә Уфа губерна земствосы тарафыннан рус телендә басыла торган «Авыл көнкүреше» журналына эшкә урнаша, дөресрәге, аны татарчага тәрҗемә итеп чыгара.

Октябрь инкыйлабыннан соң бераз Уфада яши. Гражданнар сугышы башлангач, Урал өязенең Ваһапов исемле посёлогына китәргә мәҗбүр була. Анда ревком секретаре итеп билгеләнә. Магнитка дигән төбәктә мәгариф эшләренә җитәкчелек итә. Верхний Урал шәһәрендә партия шәһәр комитетының мөселманнар секциясендә хезмәт итә, Чиләбедә чыга торган «Кызыл Урал» газетасында да эшләп ала (1921—1922), андагы педагогия техникумында татар әдәбиятын укыта. Уфага кайткач (1922 елның ахыры), Җир эшләре халык комиссариатында нәшрият эшләре җитәкчесе була.

С. Рәмиевнең сәламәтлеге начарланганнан-начарлана бара һәм ул 1926 елның 17 мартында үпкә авыруыннан вафат була.

С. Рәмиевнең Уфа зиратындагы кабер ташына менә мондый шигъри юллар язылган:

Булмас артык бер олуг эш
Илгә хезмәт итүдән;
Илгә хезмәт хөрмәтенә
Үскән җирдән китүдән.

Шагыйрь бу строфаны 1906 елның 19 июнендә үзе «Таң йолдызы» газетасының мөхәррире итеп билгеләнгәч чыгарылган санында бастырган. Шулай итеп, ул әлеге газетаның мөхәррире буларак кына түгел, гомумән, шәхес һәм шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе буларак та үз алдына куйган максатын әйтеп бирә, ул да булса, «иң олуг эш — илгә хезмәт итү». Гәрчә Г. Тукай аңа язган бер хатында аны «коеп куйган поэт» (шагыйрь) дип атаган булса да (аның бусы да бик олы мәртәбә), С. Рәмиев бер үк вакытта сәясәтче дә, җәмәгать эшлеклесе дә иде. Аның да күзе күпне күрде, колагы күпне ишетте, гомере буе туган халкы гаме белән яшәде һәм бөтен эшчәнлеген, тормышын шуңа багышлады.

Сораулар һәм биремнәр

1. С. Рәмиевнең биографиясен эзлекле итеп сөйләп бирегез. Кырык алты яшендә вафат булган шагыйрь күп тапкыр үзенең тору урынын алыштырырга мәҗбүр була. Моның сәбәбен аңлатыгыз.
2. С. Рәмиев — татар вакытлы матбугатын нигезләүчеләрнең һәм үстерүчеләрнең күренеклесе. Шушы фикерне дәлилләгез.
3. С. Рәмиевнең үзе өчен иң олы максаты нидән гыйбарәт була?
4. Журналист, мөхәррир буларак, С. Рәмиев үзе эшли торган газеталарны ничек кайгырта?
5. Г. Тукайның С. Рәмиевкә мөнәсәбәте турында сөйләгез.
6. Шагыйрьнең «Таң вакыты», «Дөньяга» шигырьләрен сәнгатьле итеп укыгыз һәм яттан өйрәнегез.

Шигъри иҗаты

С. Рәмиев кулына иҗат каләмен, шәхес буларак өлгереп, иҗтимагый-сәяси карашлары билгеле бер юнәлешкә кергәч ала. Билгеле булганча, С. Рәмиев мәдрәсә мөгаллимнәренең әзерлек дәрәҗәләреннән канәгать булмый (ул 1902—1906 еллар арасында мәдрәсәдә мөгаллимлек итә). Казанга килгәч,

беренче башлап иҗат иткән әсәре — «Хәзрәтләр сакалы» («Хәзрәтләр эше») шигырендәге төп максаты шәкертләр алдында белемле булып кыланып, дөресендә алардан да артта калган мөгаллимнәрнең эчке дөньяларын ачып бирүдән гыйбарәт. Аларның шәкерткә ник мыегың озын, кесәң ни өчен туры түгел, нигә урыс газетасы укыйсың сыман сүзләр белән бәйләнеп торуларыннан көлә. Ләкин шәкерт укыган газетадагы мәгълүматлар белән танышырга үзенең белеме җитми. Сакал йөртү генә әле кешегә акыл өстәми. Хәзрәт үзе дә: «Сакал ул — бер йон гына бит, язмага ярыймыни?» — дип әйтеп куярга мәҗбүр була. Дөрес, бу шигырь сәнгатьчә эшләнеше ягыннан йомшак. Бу очракта ул шагыйрьнең матбугатта чыккан беренче шигыре дип телгә алына. Шунысын билгеләп үтү мөһим: С. Рәмиев иҗат эшенә, нигездә, Казанга килгәч керешә һәм биредә яшәү вакытында иң талантлы әсәрләрен яза.

Шагыйрьнең иҗатында хатын-кызны олылау темасы актив. Аның мондый шигырьләрен ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Беренчеләрендә ул хатын-кызның матурлыгына, назлылыгына дан җырлый, аларны ир-егетләргә яшәү көче бирә торган зат итеп тасвирлый. Андыйларга «Син», «Ул», «Җәмилә» шигырьләрен кертеп була. Шагыйрьнең гүзәл затлар — хатын-кызларны тасвирлап язган юллары нәфислеге һәм шагыйранә илһамлылыгы белән игътибарны җәлеп итә. Биредә шагыйрьнең каләменә Көнчыгыш сүз сәнгатенең тәэсире дә сизелә. Билгеле булганча, фарсы, гарәп, төрек әдәбиятларында хатын-кызның гүзәллеген җырлауның бик ерак вакытлардан килә торган бай традициясе бар. «Ул» шигырендә бу аеруча ачык күренә:

Кашлары — ай аның, яңа туган,
Йөзе — айның тулган көннәре,
Керпекләре — нурлар, кич чәчелгән,
Ике күзе — шул кичнең күлләре.

Күргәнебезчә, гашыйк кешенең хисләре генә түгел, бәлки теле дә, сөйләгән сүзләре дә нәзберек була. Әлеге шигырьдә сүз гомумиләштерелгән хатын-кыз образы турында барса, «Җәмилә» шигырендә исә лирик геройның хисләре аерым бер затка юнәлдерелгән.

Күрдисә бер Алла синең
Бу зифа буй, гөл йөзең,

Сабыр итә алмас, корбан итми
Мәхлүкатын[1] һәм үзен.

Янасың ут дик төтенсез,
Яндырасың бәгъремне,
Әйтсәнә, син чын кешеме?
Әллә юк, җен-пәриме?

Бар кануннан башым алдым —
Багынамын тик сиңа!
Бар кызыктан кул селектем —
Табынамын тик сиңа!

Ихлас яраткан вакытта кешенең табигый кимчелеге дә матур бизәк булып тоела. Әнә бу кызның тешләрендә дә җитешсезлекләр бар икән. Ләкин «аһ, бәла ансы тагы!» дип күрсенсә дә, лирик герой сөйгән ярының көлүен бар нәрсәдән дә өстен күрә.

Г. Тукайның «Тешләре ямьсез матурга» шигыре бар. Язучы һәм әдәбият галиме Мөхәммәт Гали бу әсәр С. Рәмиевнең сөйгән кызына мөнәсәбәтле иҗат ителгән дип әйтә. Әлбәттә, бу очракта Г. Тукайның шаяру рухында язганлыгын искә алырга кирәк. Димәк, С. Рәмиевнең «Җәмилә» шигыре 1908 елның 18 июленнән иртәрәк язылган, чөнки Г. Тукайның әле әйтелгән әсәре «Әлислах» газетасында шул көндәге санында басылган.

Иҗат итү өчен, С. Рәмиевкә хатын-кызлар илһам биргән шигырьләрнең тагын берсе «Хатыннар галәме» (1907) дип атала. Шагыйрь биредә хатыннар галәменә (ягъни хатыннар дөньясына, барлык хатыннарга) мөрәҗәгать белән чыга. Ул аларның дөньяви, иҗтимагый аңнары түбән булуына борчыла, хатын-кызларны «наданлык дәрьясы» дип атый. Сездән башка татарлар рәхәтлек, бәхетнең нәрсәдә икәнен белмиләр. Сез татарларны ник якты юлга чыгармыйсыз дип өзгәләнә. Бу инде кешелеккә тормыш бирергә сәләтле хатын-кызларның иҗтимагый тормышта да зур эш башкара алуларына ышану иде. Бу — шигырь эчтәлегенә бәрабәр публицистик рух белән сугарылган. Хатын-кызларга багышланган беренче төркем шигырьләрдән нык аерыла. Биредә лирика чикле, сәяси җитдилек, рәсмилек өслүбе хакимлек итә.

[1] *Мәхлүкат* — яратылган барлык җан ияләре.

Шагыйрь, татар тормышындагы әһәмиятле вакыйгаларга багышлап, шигырь язуны гадәт итә. Үзе әйткәнчә, «Казанда, Яңа клуб залында, беренче башлап татар телендә театр уйнаган татар кызлары һәм татар егетләре хөрмәтенә» ул «Театр» (1907) дигән шигырен иҗат итә. Биредә дә шагыйрь кызларга соклануын белдермичә кала алмый.

Башлаучылар гәрчә уенны «Таң»нар[1] иде,
Тәмамлаучы күркәм итеп кызлар иде,
Белә килгән татар хәлен таулар, ташлар:
«Баш каһарман бу уенда — кызлар»,— ди иде.

Раст, кызлар, чын каһарман сез булдыгыз!
Татарларны тәгассыбтан[2] сез йолдыгыз!
Тарихның битләрендә алтын белән
Язылган «орден ифтихар»[3] сез булдыгыз!

«Басма сүз» (1916) шигыре исә, шагыйрьнең үзе язганча, «татар газеталары чыга башлаганга ун ел тулган көнгә багышлана».

Әй, яшә, хөр басма сүз! Яз,
Яз, данлыкла Тәңреңне!
Нәрсә корбан китсә дә — бир,
Урнына илт әмрене!

Күр дә, күңлем, Тәңрене бер,
Уйларын тазарт хәзер,
Инде иркен бер иман ит,
Тәңремез азат хәзер!

Шагыйрь Ходайдан кешегә бүләк ителгән уйлау сәләтенең моңа кадәр тоткынлыкта булып килүенә сызлана. Ниһаять, «бикле сүз буасы» ерылды, яктыга киң юл ярды. «Нур», «Вакыт», «Таң» («Таң йолдызы») һ. б. газеталар пәйда булды. Халык күңелендә йөргән фикерләрнең киң галәмгә чыгуын шагыйрь Тәңренең азат булуы белән тиңли.

Әдәбият фәнендә, шагыйрь буларак, Г. Тукайны реалист, С. Рәмиевне романтик дип карау ныклап урнашты. Бу аларның дөньяны күрү һәм аңлау, шәхси сыйфатлары белән дә бәйләнгән иде. Шул ук вакытта моның алар иҗатында гомумкешелек сыйфатларының да чагылышы икәнлеген хәтердән чыгарырга ярамый. С. Рәмиев, күккә протест белән чыкса да, бөтен кайгыртканы җир тормышы, халыкның михнәтле хәлен яхшырту иде. Шулай булгач, Г. Тукай һәм С. Рәмиев

---

[1] «Таң» газетасы тарафдарлары.
[2] *Тәгассыб* — искелеккә табыну.
[3] *«Орден ифтихар»* — мактау ордены.

иҗат алымнары белән бер-береннән нык кына аерылсалар да, төп максатлары — каләмне халыкка хезмәт иттерүдә аларны аерып карап булмый.

С. Рәмиев азатлык өчен көрәшкә чыккан лирик геройның психологик халәтен бирүгә игътибарлы. Бу геройның күңел дөньясының ниндилеге инкыйлаб вакыйгалары барышына бәйле иде. 1908 елда ул, мәсәлән, кеше халәтен менә болай гына гәүдәләндерә алды:

Көн — авыр, төн — бер кабер, бер
Ел тоела сәгатем.

Әрни-әрни ләгънәт әйтәм
Тискәре бу дөньяга.
Мин мәхәббәт нуры дим, ул
Аерылу шәмен яга.

(«Алданган»)

Әнә шулай реакция елларында С. Рәмиев әсәрләренә үлем, явызлык шәүләләре килеп керә. Мондый күңел төшенкелеге аңа тормышның үзеннән килә иде.

Юк чыны бернәрсәнең дә!
Чын «юк» үзе дә юк хәзер!
Беттем. Алдандым. Янамын...
Бар тормышым ут хәзер.

(«Алданган»)

Инкыйлаб елларында күңеле белән хөрлек килеренә ышанган шәхескә хәлнең элеккедән дә яманлана баруын күрү җиңел булмагандыр. Мондый мисаллардан гына чыгып, әлбәттә, С. Рәмиев рус шигъриятендә шактый урын тоткан декадентлыкка[1] бирелде дип әйтеп булмый. Күңел төшенкелеге аңарда булды, ләкин ул артык тирәнгә китмәде. Мондый кәефнең узгынчы гына икәнен шагыйрь белә иде. Чөнки тормышның гел караңгылыктан гына тормаячагын ул ачык аңлады.

Бу ямьсез көннәрем шунда
Гаҗиб бер ямь алыр төсле,
Мәхәббәт мәгъбәде[2] күңлем
Мәхәббәт тә табар төсле.

---

[1] *Декадентлык* — төшенкелеккә бирелгән шигърият.

[2] *Мәхәббәт мәгъбәде* — мәхәббәткә табыну бүлмәсе, «күңеле — мәхәббәткә табыну урыны» мәгънәсендә.

С. Рәмиевнең лирик герое, романтик шәхес буларак, хисне ярым-йорты гына кичерә алмый. Күңеле төшенке икән, «мин үләм» диярлек хәлгә төшә, күтәренке булса, «шунда тик бер чын бәхетле һәм рәхәттә утырам» дип кинәнә. Моңа әдәбият галиме Габдрахман Сәгъди дә игътибар итә: «Шагыйрь (С. Рәмиев.— *Ф. Г.*) үзендә бер-бере белән алышынып тора торган «караңгы-яктылы» ике халәт, ике төрле настроение күрсәтә. Берсе аның «мин»ен күрми яки аның сүзен ишетә алмый торган чагы — «үлгән» вакыты, икенчесе — «мин»ен күреп шатланган, күтәрелгән моменты». Гади генә әйткәндә, шагыйрь иҗатында геройларның кәефе капма-каршы булучан. Моннан аларның яки кәефләре әйбәт, яки начар дип кенә атарга мөмкин булыр иде. Мәсәлән, бер очракта ул шашкын, тәвәккәл:

Әмма соң бер эт итеп бу
Дөньяны атар идем,
Җир-суын да яндырыр һәм
Күкләрен ватар идем...

(«Дөньяга»)

Икенче бервакыт ул рухы төшкән, дөнья тарафыннан изелгән кеше булып күзаллана:

Караңгы һәм дә таңы ерак,
Уты сүнгән җәһәннәм минем төн,
Олы кайгы, олы хәсрәт
Һәм эч пошу тулы гел минем төн.

(«Минем төн»)

Дөресендә, кешенең тыныч, ләззәтле вакыты күбрәк булырга тиеш иде. Әмма мондый уртачалык романтик шәхескә хас була алмый. Романтик өчен хисләрнең шулай нык үзгәреп торучан булуы табигыйрәк.

Бер пьесаның герое Сөләйман да: «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!»— ди. Ягъни яшәү көче мәхәббәт икәнен раслый. «Алданган» шигыренең икенче бүлеге дә (дөресрәге, аны мөстәкыйль әсәр дип карарга мөмкин) мәхәббәт хисен барлыкка китерүче сөеклесенә гадәти булмаган көчле мөрәҗәгать белән тәмамлана:

«Син» генә — бар күккә патша,
«Аш» диген, күккә ашыйм!
«Син» генә — рух биргән Аллам,
«Син» яшә! Һәм «мин» яшим!

Мондый катгый төшенчәләр, хәлиткеч карарлылык һәм егәрле эндәшләр белән эш итү С. Рәмиев иҗатының үзенә хас сыйфатын тәшкил итә. Аның явыз чынбарлык белән очрашкан геройлары да тирәлеккә рәнҗү белән генә чикләнмиләр, бәлки, кайнарланып, бунт белән чыгалар, нәфрәтләрен ләгънәт, протест дәрәҗәсенә күтәрәләр. С. Рәмиев тәрҗемә әсәрләрендә дә үзенең романтик шагыйрь икәнлеген сиздерә. Мәсәлән, А. Пушкинның «Пәйгамбәр» шигырен татарчалаштырганда, пәйгамбәр образына романтик буяулар өстәде, аның индивидуализмын көчәйтә төште.

Лирик герой һәрвакыт укучы алдында үзенең эчке дөньясын ачып сала. Үз-үзен аңлавыннан, бәяләвеннән башка аның янәшәсендәге кешеләрнең уй-гамәлләрен хуплавы яки алар белән каршылыкка керүе табигый була алмый. Кешенең үз «мин»ен тануы — зур ачыш ясауга тиң ул. С. Рәмиевнең «Мин» шигыре (1907) — лирик геройның күңел төпкелләрен бик яхшы белүе нәтиҗәсе.

«Мин», аныңча, дөньяның үзәге. «Аллалар, шаһлар, кануннар, «мин» дидисәм[1], булалар бер чүп кенә»,— ди лирик герой. Шундый вакытта ул җирдә дә, күктә дә берүзе кала, шунда аңа рәхәт була. Ә инде «мин»не күрми торса, эшли алмый, барны да таба алмый. Тирә-юньдәге халык исә шат, бу гына берүзе кайгыда. Ул, «мин»е күзенә күренүгә, тагын күкнең югары түренә менә...

Әйе, С. Рәмиев хаклы: дөнья никадәр зур, гаҗәеп бай булмасын, ул аерым кеше өчен үз «мин»енә мөнәсәбәтле генә ачыла. Әлбәттә, берни уйларга тырышмыйча, гамьсез генә яшәргә, дөнья күләмендә уйлап газапланмаска да мөмкиндер. Андыйларга һәрвакыт барысы да җиткән була. Тик дөньяда үз «мин»ен тойган, җәмгыятьтә шәхси урынын табарга омтылган кешегә бервакытта да тыныч кына яшәү насыйп булмый. Нәкъ менә шундыйлар, каршылыкларны җиңә-җиңә, төрле өлкәләрнең үсешен тәэмин итәләр. Үзен хөрмәт итмәгән кешенең киләчәге булмый. Башкалар өлгесе белән генә яшәгән кеше шәхес буларак ачыла алмый. Кеше иң әүвәл үз-үзен аңларга һәм үзе алдында җаваплылык тоярга тиеш. Бу аңа тормышта адашмаска ярдәм итә. «Мин!» минемчөн[2] Алла ул»,— ди С. Рәмиевнең бер лирик герое. Әлбәттә, моны

[1] *Дидисәм* — диде исәм, дисәм.
[2] *Минемчөн* — минем өчен.

эгоизм, ягъни үз-үзеңне генә ярату белән бутарга ярамый. Үз «мин»еңне Алла урынына куюдан башка тулы канлы яшәү була алмый. Галәми күләмнәрдә фикер йөртә алган кеше вак җанлы булып калмый, ул олы хыяллардан курыкмый. Үзеңнең Аллаң үзең булу — камил, көчле рухлы, үз-үзеңә ышанучан, кешелекле, бай күңелле, тугрылыклы, игелекле булуның шарты. «Мин» турында бүтәннәрнең ни әйтүе әһәмиятле, ләкин «мин» хакында «мин»нең нинди бәя бирүе тагын да мөһимрәк. Кеше өчен аның үзеннән дә катгый хөкемдарның булганы юк. С. Рәмиевнең әлеге әсәрендәге лирик герой укучының фикер агышын әнә шундый юнәлешкә борып җибәрә. Бу исә әсәрнең югары сәнгатьчә эшләнүе белән аңлатыла.

С. Рәмиев шулай да күк кануннарын бөтенләе белән инкарь итеп бетерми. Аның лирик герое бик кыен вакытларда Илаһыга мөрәҗәгать итми булдыра алмый.

Илаһым, ал мине! Талдым,
Юлыңда берүзем калдым;
Куям кылычым кире кынга...
Газаплый тик сиңа антым...

(«Талдым»)

Романтик шагыйрьләрне тулырак аңлау өчен, аларның халыкка мөнәсәбәтен ачыклау мөһим. Романтик шагыйрь, гәрчә шушы күпчелекнең бәхетсезлеген күреп әрнесә дә, шуларны бәхетле итү гаме күңелен бимазаласа да, ул үзен «соры» халыктан өстен итеп, хәтта алардан аерылган, ялгыз җан итеп тоя. Ул ялгызлык горурлыгы дигән хискә ия була. Әлбәттә, бу соңгысы үзен өстен катлаулардан бәйсез итеп күрергә теләүдән дә килә. Шулай булмаса ул бөтен дөньяга нәфрәт белән чыга алмас иде.

Бу әйтелгәннәр С. Рәмиев иҗатына да хас булды. Менә аның «Бәйрәм» исемле шигыре. Ул С. Рәмиевнең 1909 елда язылган «Нәҗметдин агай бәйрәме» дигән хикәясе эчендә бирелгән. Бәйрәм көн. Ураза гаете. Халык шат. Бер-берсенең хәлен белешәләр, елмаешалар, көлешәләр. Ләкин, ди лирик герой, болар «чын түгел, битлек кенәдер». Кешеләр икейөзлеләнәләр, дип уйлый ул.

Нәләтләп каберемә керсәм,
Минем чын бәйрәмем шунда!—

дигән нәтиҗә ясый лирик герой.

Әйе, романтик шәхес башкалар яшәгәнчә генә яши, бүтәннәр эшләгәнчә генә эшли алмый. Аңа яшәешне үзенчә аңлавы кадерле, һәм ул аны берни бәрабәренә дә алыштыра алмый. Югыйсә бу үтә мөстәкыйльлек аңа күңел газаплары да алып килә. Әйләнә-тирәдәгеләрнең аңа булган аңлашылмаучан, хәтта сәерсенеп караулары да мондый шәхесне дөньядагы хәл-әхвәлне үзенчә аңлавыннан һәм аны үзгәртеп корырга дигән омтылышларыннан чигендерә алмый.

Әдәбият галиме Гали Халит, С. Рәмиевнең лирик героен тасвирлап, болай дип яза: «С. Рәмиев герое нәфрәтләнгән, ләгънәтләнгән дөнья белән котылгысыз конфликтка керә, әмма ул үзен һич тә язмыш колы итеп санамый, кечкенә бер җан иясе дәрәҗәсенә дә төшерми, ә үзендә һичбер явызлыкка буйсынмас демонизм рухы сизә. Ул — кызганыч түгел, ә үз идеалы, үз азатлыгы өчен көрәш юлында һәлак булудан курыкмаган актив трагик герой. Беренче романтик сыйфаты да аның менә шунда».

Романтик сыйфат С. Рәмиевнең мәхәббәт лирикасында да сизелә.

Мине утка аткан ул — син,
Мине суга салган да — син,
Утта янсам, суга батсам,
Тартып алган Аллам да — син!

(«Син»)

Биредә «Аллам» сүзе кызның романтик образын зурайту, көчәйтү өчен кулланылган. Кешене Аллага тиңләү Көнчыгыш сүз сәнгатендә борынгыдан ук килә (мәсәлән, XIV йөз азәрбайҗан шагыйре Нәсимине алырга була). С. Рәмиевнең лирик геройлары да гади җир кешеләрен Аллага бәрабәр итеп күрәләр.

«Мин!» минемчөн Алла ул.

(«Мин»)

Тартып алган Аллам да — син.

(«Син»)

С. Рәмиев каләме белән тудырылган бунтарь геройның татар әдәбиятындагы гыйсъянчы образга охшашлыгын күрми мөмкин түгел. Аның җәберсетелүе, ялгызлыгы, ләкин көрәш рухы белән сугарылуы шуны күрсәтә. Ул бу көрәштә җиңәрме-юкмы — анысы икенче эш. Ләкин аның яшәп килүче тирәлеккә каршы баш күтәрүе хак.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шагыйрьнең әдәби иҗаты, нигездә, Казанга килгәч үсеп китә. Моны ничек аңлатырсыз?

2. С. Рәмиев үз иҗатында аеруча нинди темаларны күтәрә?

3. Аның каләме хатын-кызны ничек итеп сурәтли? Хатын-кызның җәмгыятьтәге урынын шагыйрь ничек күз алдына китерә?

4. Г. Тукай һәм С. Рәмиев каләмнәренең бер-беренә охшашлыгы һәм аермалыгы нәрсәдә дип уйлыйсыз?

5. Лирик геройның күңел дөньясын бирүдә С. Рәмиев каләменә нинди үзенчәлекләр хас?

6. С. Рәмиевнең лирик герое ни өчен бунтарь холыклы? Бу нилектән килә?

7. «Үзеңнең Аллаң үзең булуны» сез ничек аңлыйсыз?

8. Лирик геройның Аллага (Илаһыга) мөнәсәбәтен билгеләгез.

Бәхет таңы кайчан атар?

1905—1907 еллардагы инкыйлабка шагыйрьләребез зур өметләр багладылар. Аны таң ату белән тиңләү шуннан килә иде. Г. Тукай «Иттифак хакында» шигырендә (1905) болай ди:

Җитәр, йокламыйк һаман,
Таңнар атты, бәдәвам.

Г. Ибраһимов та: «Хәзерге вакытны — татарның таң вакыты дип атарга мөмкин»,— ди. С. Рәмиев тә «Таң вакыты» шигырендә халыкның милли-азатлык көрәшенә күтәрелергә вакыт икәнлеген әйтте. Моны ул, үзенең иҗади стиленә тугры калып, көчле хисләр, кайнар сүзләр ярдәмендә аңлатты.

С. Рәмиев әлеге шигырьне беренче мәртәбә 1908 елның 2 гыйнварында Казанның «Шәрык клубы»нда әдәбият кичәсендә укый. Шунысы кызыклы: ул беренче тапкыр шул ук елның 16 гыйнварында рус телендә басылып чыга[1]. Татар телендә исә бер елдан соң гына, ягъни 1909 елның 25 гыйнварында «Әлислах» газетасында дөнья күрә.

Шигырьнең жанрын автор «мөсәҗҗәгъ нәсер» («рифмалы нәсер») дип билгеләгән. Нәсер, гадәттә, проза белән языла, анда кешенең тирән уйлары, кичерешләре хискә төреп бирелә. «Таң вакыты» әсәре дә лирик геройның уйлануларына корылган.

[1] Аны милләте буенча поляк, Казанда сөргенлектә яшәүче студент Альберт Пинкевич тәрҗемә итә. Бу егет татар телен бик яхшы белә. Ул С. Рәмиевнең тагын «Мин», «Син», «Ул» шигырьләрен дә рус теленә тәрҗемә итеп бастыра.

Илдә бөек кузгалышлар вакыты (таң вакыты), ләкин татар һаман да йоклый. Лирик герой башка татарлардан уйларга, үткәннәр һәм бүгенгене тәфтишләп төпченергә сәләтле булуы белән аерылып тора. Шуңа күрә аның күзенә йокы керми. Ләкин ул да урында яткан килеш кенә, ягъни актив хәрәкәткә керешмичә генә уйлый. Татарны йокыдан уяту гамәленә керешер иде, аталардан калган хаталар чабудан тарта. «Хатам тирән, тамыры ерак...» — ди лирик герой. Татар куркучан булып калган. Ә «теге, үсә, зурая, әле һаман да...» «Теге» дигәндә империянең күздә тотылганын аңлау кыен түгел. Татарның хатасы — аның хәлиткеч вакытларда бердәм булмавында, Казан ханлыгының бәйсезлеген юкка чыгаруда татарларның үзләренең дә катнашы барлыгында. Боларның тарихын колакка тукыйлар (әмма үзгәртеп, бозып тукыйлар), ләкин төбен тикшерергә кушмыйлар, ди лирик герой. Балалар, ягъни яшь буыннар моны тыңлыйлар, хуш, сөйлә, ди-ди тыңлыйлар, тик сөйләгәннәргә ышанмыйлар, юк, түгел, диләр. Әйе, Россиянең рәсми хакимияте Казан ханлыгын басып алуны, имеш, татарлар өчен файдалы булды, аларны мәдәниятле итүгә китерде, дип аклап килде. Тик ничә гасырлар үтсә дә, яңадан-яңа буыннар болай диюләргә ышанмыйлар.

Моңа кадәр «Таң вакыты» шигырен татар халкының ислам тәэсирендә артта калып килүен әрнүле бер кичереш белән тасвирлый диеп аңлатып килделәр. Болай дияргә нигез дә бар кебек. Чөнки бер строфа болай яңгырый:

Башларын ваткан татарларның
Тик шул бер алла[1]!
Бетәрләр микән татарлар, алла, ди-ди?
Әллә белерләр микән хаталарын бер алда?

Ләкин үзе төзегән кулъязма җыентыгында (ул «Сәҗгыләр» — «Рифмалаштырылган нәсерләр» дип атала) шагыйрь тексттагы «алла» сүзләрен сыза да алар урынына җәяләр эченә күп нокталар куя. Шулай итеп, укучыга әсәрдән килеп чыга торган дөрес эчтәлек турында уйланырга, төпченергә мөмкинлек бирелә. Дин, билгеле булганча, рәсми хакимиятләр белән тату, аларның гамәлләренә риза булып яшәргә куша. Азатлыгын җуйган халыкның шушылай буйсынып, куркып калуында, әлбәттә, диннең дә «хезмәте» аз түгел. Шуңа

[1] *Алла* — биредә Россия империясе күздә тотыла.

күрә автор «бөтен дөньяны бар иткән, бардыр, үзе бердер» булган Алланың «гакылларны тар итүенә» үпкә дә белдерә. Дин дөнья эшләренә катышырга кушмый. «Мөселман булсаң,— ди шагыйрь, татарларга «Габдулла» (Алла колы) дип эндәшеп,— юкны уйлама, ят, йоклавыңны дәвам ит. Чөнки көрәшкә чыгу, баш күтәрү бу дөньяда империя кануннары, ә теге дөньяда Алла ихтыяры белән кешене утка алып керә. Куркак татар өчен йокымсырау мең тапкыр файдалырак».

Бу хәлдән ничек чыгарга соң? Лирик герой татарга болай дип мөрәҗәгать итә:

Туг яңадан мәгърифәтле анадан!
Югыйсә син, әй татар,
Бел, бетәсең!— ди,— надан.
Бетмә надан, туг яңадан
Мәгърифәтле анадан!
Бул кеше, үзең тырыш, өмид итмә,
Хата ул өмид алладан!

Әлбәттә, соңгы юлны «хата ул өмид рәсми хакимияттән» дип аңларга урын кала. С. Рәмиев шигырь язылган 1907 елда барысын да үз исеме белән атый алмый иде. Әсәрдә сүз татар халкының авыр язмышы, фаҗигале тарихы турында бара, шагыйрь, милләтнең киләчәге турында кайгыртып, көрәшкә чыга. «Безнең халыкның гасырларча дәвам кыйлган йокысыннан, өстен каплаган кара төннән яңа дөньяга, якты кояшлы мәдәният галәменә чыгарга торган заманы. Сәгыйть «Таң вакыты»н үзенең шәхси тәэсиренә каратып язса да, ул, гомумән, чыккан»[1] (ягъни татар халкының хәлен гомумиләштерү булып чыккан.— *Ф. Г.*). Сәйфи Кудашның истәлегенә караганда, «Г. Ибраһимов, «Галия» мәдрәсәсендә тел-әдәбият укыта башлау белән үк, бу шигырьне бөтен классларның шәкертләренә диярлек ятлатты»[2]. Күрәбез, бу әсәргә әле басылып чыккан елларда ук нык игътибар иткәннәр, аны аңларга һәм аңлатырга тырышканнар.

Реакция елларында мәдрәсә шәкертләренең ятак бүлмәләрен еш тентегәннәр, аларның хәтта җыр-шигырь дәфтәрләрен җентекләп тикшергәннәр. Күпчелек дәфтәрләрдә С. Рәмиевнең «Таң вакыты» шигыре дә килеп чыга торган булган.

---

[1] *Ибраһимов Г.* Әсәрләр.— Казан, 1978.— 5 т.— 93 б.
[2] *Кудаш С.* Әсәрләр.— Уфа, 1978.— 2 т.— 229 б.

Рәсми хакимиятләр бу шигырь «революцион народниклар настроениесен чагылдыра» дигән мөһер сукканнар. Әгәр дә шигырь Аллага каршы язылган булса, жандармнарның аңа исләре китмәс иде. Шулай итеп, «Таң вакыты» шигыре С. Рәмиевнең иҗат йөзен билгеләүче әсәр булды.

Татар шигыренең традицион көйле интонациясеннән сөйләү интонациясенә таба борылыш ясавы да С. Рәмиев исеме белән бәйле. Дөрес, аңа кадәр моның яралгыларын Я. Емельяновта табарга мөмкин иде. Г. Тукайда да аның мисаллары бар. С. Рәмиев исә мондый шигырьләрне махсус яза. «Театр», «Минем төн», «Таң вакыты» һ. б. әсәрләр шундыйлардан. Соңыннан татар шигъриятендә бу юнәлешне Һ.Такташ уңышлы дәвам иттерде һәм бездә үз шигъри мәктәбен тудырды, сөйләү интонациясенә нигезләнгән талантлы әсәрләр бирде.

Кайчакта шагыйрьләр, бер-беренең әсәрләренә җавап итеп, яңа шигырьләр иҗат итәләр. Мондый бер-берсен «дәвам итешү» С. Рәмиев белән Г. Тукай арасында да була. С. Рәмиевнең «Алданган» шигыренә җавап итеп, Г. Тукай «Саташкан» әсәрен язды, «Уку» шигыренә исә «Йокы» шигырен каршы куйды. Бу ике шагыйрь берсе икенчесе өчен остаз булды.

С. Рәмиев Көнчыгыш, Көнбатыш һәм рус поэзияләре традицияләрен өйрәнде, иҗатында аларның өлгеләрен һәрвакыт сизеп-тоеп эш итте. Тәрҗемә өлкәсендә эшләү әдәби осталыкны камилләштерергә булышты. А. Чеховның «Ванька» хикәясен, Л. Толстойның «Тере мәет» пьесасын, М. Горькийның «Кояш чыга да бата», В. Фёдоровның (Омулевский) «Таң ата, эшлик, туганнар» һ.б. әсәрләрне татарчалаштырды. Татарча «Марсельеза»ны иҗат итүче дә С. Рәмиев булды. Ул яратып тудырган романтик гыйсъянчы геройның исә Көнчыгышта зур традициясе бар. «Таң вакыты» шигырен «романтизмның манифесты»[1] дип атау белән килешергә кирәк.

Кеше бервакытта да яшәүдән туймый. Дөньяны, тирәлекне романтик буяуларда күреп, кешеләрне өзелеп яратучы, милләтен сөюче, илаһи күңелле Сәгыйть Рәмиев бигрәк тә. Ул каты авыру кичергән көннәрендә «Сүзем һәм үзем» дигән шигырь яза. Анда шагыйрь тормышка булган мәхәббәтен ачык итеп белдерә:

---

[1] Татар әдәбияты тарихы. — Казан, 1986.— 3 т.— 524 б.

Сәгадәттән бер дә өмет кискәнем юк:
Хәят белән арам төйнен чишкәнем юк,
Касәсеннән хәятнең, раст, авыз итсәм дә,
Ләкин әле төбенә хәтле эчкәнем юк.

Әйе, гадәттә, мондый талант ияләре хәят (тормыш) рәхәтләрен «төбенә хәтле» авыз итәргә өлгерә алмый калалар. Халык гаме белән янып яшәүнең бер елы берничә елга бәрабәрдер, күрәсең. Г. Тукай, С. Рәмиев, Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәримне искә төшерик. Дөньядан бик яшьли китеп тә әдәбиятыбызга һәм халкыбызга кыска гына гомерләрендә күпме игелек кылып калдырырга өлгерделәр алар!

Сораулар һәм биремнәр

1. XX йөзнең беренче ун елын ни өчен күренекле шәхесләребез «татарның таң вакыты» дип атыйлар? С. Рәмиев мөхәррир булган газетаның «Таң йолдызы» дип аталуын ничек аңлатыр идегез?

2. «Таң вакыты» шигыренең жанры автор тарафыннан «рифмалы нәсер» дип билгеләнә. Сез моны ничек аңлыйсыз?

3. Татарның үз азатлыгы өчен көрәшкә күтәрелмәвенең сәбәбен (гәрчә тарихта андый күтәрелешләр булган) автор ничек итеп аңлата?

4. «Алла» дигәндә автор нәрсәне күз алдында тота?

5. Татарга ни өчен яңадан мәгърифәтле анадан туарга тәкъдим ителә? Моның төбендә ята торган өндәүнең мәгънәсе нидән гыйбарәт?

6. Ни өчен бу шигырьне С. Рәмиевнең иҗат йөзен билгеләүче әсәр дип атыйбыз?

7. Г. Ибраһимов бу әсәрне ничек бәяли?

8. С. Рәмиев татар шигъриятенә нинди яңалык алып килде?

9. Шагыйрьнең татар әдәбиятын башка халыкларның сүз сәнгате белән якынайту өлкәсендәге эшчәнлеге турында сөйләгез.

10. «Сүзем һәм үзем» шигырендә С. Рәмиев нинди шәхес булып гәүдәләнә?

С. Рәмиев — драматург һәм прозаик

Кайбер язучылар әдәбиятның төрле жанрларында иҗат итәләр. С. Рәмиев тә, шигъри әсәрләр белән беррәттән, пьесалар, хикәяләр, бер тәмамланмаган повесть һәм күп санлы мәкаләләр язды. С. Рәмиев шигъри иҗатында романтик булды. Әмма прозада бу каләм остасы, нигездә, реалист иде.

Романтик әсәрләр героеның гадәттәгедән башкачарак шәхес булуы табигый. Мондый әсәрләрдә гадәти, «уртача» кеше образлары төп урынны ала алмыйлар сыман. Ә менә «Нәҗметдин агай бәйрәме» исемле хикәясендә (1909) С. Рәмиев моның киресен эшләде. Аның Нәҗметдин агае гадинең дә гадие. Ул аяк киемнәре төзәтүчеләр әртилендә эшли. Бүген бәйрәм. Барлык мөселманнар да ял итәргә тиешле көн. Ләкин Нәҗметдин кебек яллы эшче яһүд милләтеннән булган хуҗаның кушканнарын үтәргә тиеш. Бүген аңа итек ямарга кушылган. Үтә ярлы бу кешенең бәйрәм көнне дә аш тәрләндерерлек мөмкинлеге юк. Элеккеге мөселман хуҗасына бәйрәм сәдакасы бирмәсме дип барып карый. Юк, тегесе хәтта өеннән дә чыкмый. Беркемгә дә керәге калмаган Нәҗметдин агайның кинәт үлеп китүе дә табигый тоела.

Автор гади һөнәрченең язмышын әнә шул рәвешле күрсәтеп бирә. Әсәрне укыган кеше тетрәнмичә калмый. Мондый әсәрнең беренче тапкыр «Бәянелхак»та,— нигездә, өстен катлаулар мәнфәгатен чагылдырган газетада — Ураза гаете көнне басылып чыгуы (1909, 3 октябрь) үзе бер гадәттән тыш хәл кебек кабул ителә. Хәер, ул елны Корбан гаете көнне (1909, 10 декабрь) автор шул ук газетада икенче бер хикәясен бастыра. Ул «Галәветдин хаҗи корбаны — Җаек Хәдичә» дип атала. Биредә дә укучы шул чор тормышының гадәти күренеше белән очраша. Дөньяда гүзәл, акыллы җан иясе булып бәхетле яшәргә бөтен хакы булган Хәдичәгә Галәветдин хаҗи кул сала, алдый, мәсхәрәли. Шуның нәтиҗәсендә тирә-юньгә аты-чабы чыккан кызның бөтен тормышы чәлпәрәмә килә.

Болар — ачы хакыйкать. Аларны С. Рәмиев тормыштагыча күрсәтә. Бу — аның өчен бердәнбер дөрес юл. Әлеге образларга карата укучыда кызгандыру хисләре тудыру өчен, автор бераз сентиментальлеккә дә бирелеп ала.

Аның язылып бетмәгән «Ул исерек түгел иде» повесте (1909) уңае белән дә шуны ук әйтергә мөмкин. Әсәрдә бер гадәти генә авыл малае Мәҗит сурәтләнә. Ләкин шул ук вакытта тәэсирләнүчәнлеге, тирә-юньдәге хәл-әхвәлләр турында тирән итеп уйланырга сәләтле булу сыйфатлары аны башкалардан аерып та тора. Шушы нәзберек бала тормыш кырыслыгы белән очраша. Көннәрдән бер көнне, син инде зур булдың дип, Мәфтуха апасы аны алдына утыртып сөйми башлый. Юк гаебен бар итеп кич саен этисе аны тал чыбыгы

белән кыйнауны гадәткә кертә, урамга чыкса, малайлар кыерсыта. Болар аның алты-җиде яшьлек башына зур кайгы булып төшә. Малай бу дөньяда яшәүдән тәмам туя һәм суга батып үләргә карар кыла. Ниятен тормышка да ашыра. Әмма су буендагы хатын-кызлар аны коткарып калалар. С. Рәмиев малай күңелендә шушы ниятнең барлыкка килүен мантыйклы рәвештә дәлилли. Укучы аның хисләрен һәм фаҗигале карарын аңлый.

Бу хәлләрдән соң инде атасының аңа булган карашы яхшыланмасмы дип өмет итәсең. Юк, бу хәл атаны тагын да чыгырыннан чыгара, миңа димәгәе, батып үлсен иде шунда дип, баланы тагын да катырак кыйнап ташлый.

Гаиләдә тавыш-гауга ярлылыктан, җитмәүчелектән килеп чыга, диләр. Ә Мәҗитнең әтисе Нигъмәтулла — авылның бай кешесе. Балаларын, гаиләсен бәхетле итәргә бөтен мөмкинлеге бар. Ләкин ул гаиләдә һәр ашны күз яше кушып ашата. Гадәттә, мондый хәл гаилә башлыгы хәмер белән мавыккан йортларда була. Нигъмәтулла бай турында моны әйтеп булмый, автор әсәрнең исемен үк «Ул исерек түгел иде» дип атаган. Аек килеш шундый кансыз булу тагы да яман. Югыйсә Нигъмәтулла бай биш вакыт намаз калдырмый, шәригатьнең намаз уку, ураза тоту, зәкят бирү кебек кануннарын тота, хаҗга бару хыялы белән яши. Тик миһербанлы, игелекле булу, кешеләрнең күңелен күреп яшәү кебек иң гадәти таләпләр аның ике ятып бер төшенә дә керми.

Мәҗит менә шундый шартларда үсә. Шулай да әтисенең рәхимсезлеге, усаллыгы аның аңын томалый алмый, ул айнык акыллы малай булып кала, яхшыны яманнан аера белергә өйрәнеп үсә. «Ул исерек түгел иде» дигән сүзләрне аның үзенә карата да кулланырга мөмкин («башыннан кичкәннәргә карамастан акылы камил калган» дигән мәгънәдә).

Башта аны атасы укытмаска да уйлый, үзе кебек сәүдә эшенә өйрәтергә ниятли. Ләкин бер таныш баеның, малайны, бер Җаек буе шәһәрендәге мәдрәсәгә биреп, муллалыкка укыт, дигән киңәше белән Мәҗитне шунда алып бара. Шулай итеп, Мәҗит ата йорты дигән тәмугтан котыла. Тик әлеге «низамлы мәдрәсә»дә аны ни көтәдер? Биредәге тәртипләр дә өйдәгедән яхшырак булырга охшап тормый. Укучы әлеге сөйкемле бала белән менә шунда аерылыша.

С. Рәмиевнең уйланмасы буенча, Мәҗит гаделсез кануннарга, тәртипләргә бунт белән каршы чыгарлык егет булып

җитешергә тиеш булгандыр. Ник дигәндә, ул 1915 елда чыккан җыентыгына «Мәҗит сүзе», «Зөбәйдә сүзләре» исемле шигырьләрен кертә, аларны «Ул исерек түгел иде» дигән хикәямнән» дип тәкъдим итә. Мәҗит, күрәсең, алга таба да тормыштан рәхәт тапмаган. Шуңа күрә ул күк кануннарына каршы чыга, аларга нәфрәтен белдерә. Димәк, автор яки әсәрен тулаем язып бетереп, аның дәвамын бастыра алмаган, яки шушы аерым шигырьләрен генә иҗат итәргә өлгергән. Шул рәвешле, әлеге әсәрнең тулаем язылып бетүе-бетмәве хәзергә билгесез булып кала. Шунысы хак: романтик рухлы Мәҗит белән С. Рәмиевнең үз тормышы арасындагы уртак яклар күзгә бәрелеп тора. Ягъни Мәҗит-Сәгыйтьнең алдагы язмышын, әсәр язылып бетмәгән очракта да, без шактый тулы күзаллый алабыз дигән сүз. Бу әсәр шагыйрь С. Рәмиевнең күңел дөньясы формалашу баскычларын шактый төгәл күзалларга мөмкинлек бирүе белән әһәмиятле.

Татар мәдрәсәләре үз заманы өчен яшь буынга шактый әйбәт әзерлек биргәннәр. Шулай да алардагы тәртипләрне, уку программаларын, укыту ысулларын камилләштерү, заманга яраклаштыру таләп ителә иде. С. Рәмиев бу мәсьәләләрне «Низамлы мәдрәсә» (1907) исемле бер пәрдәлек көлкеле сәхнә әсәрендә күтәрә. Низамлы, димәк, катгый кагыйдәләргә (дөресрәге, тәртипләргә) нигезләнеп эшләп ятучы мәдрәсә тормышы турында сүз бара.

Вакыйгалар агышыннан күренгәнчә, бу тәртипләр нәрсәләрдән гыйбарәт соң? Әсәрдәге бердәнбер уңай образ булган Садыйк хәлфә сүзләреннән түбәндәгеләр аңлашыла: «Урамга чыгарга ирек бирмисез, гыйбрәтле китаплар укырга рөхсәт итмисез, кеше төсле кешеләр белән катыштырмыйсыз, мәдрәсә эчендә дә бер күңел ачарлык уеннар уйнатмыйсыз».

Уку, белем алуга түгел, хәтта яшәр өчен дә мөмкинлекләр калмагач, шәкертләр ахыр чиктә баш күтәрәләр, капка-коймаларны ватып, урамга чыгалар. Әнә шулай биек коймалар артына яшереп киленгән тәртипләр тирә-юньгә фаш була, кешелексез тәртипләргә нигезләнгән мәдрәсә тормышы үзенең ныклы булмавын күрсәтә.

Ф. Әмирхан әлеге пьеса уңае белән менә болай яза: «Сәгыйть әфәнде Рәмиев бу әсәрнең сюжетын «Мәдрәсәи Хөсәения»дән алып язгандыр. Бик матур вә оста тасвир итәдер. Бөтен шәкертләргә, хосусән «мөхтәрәм» хәлфәләргә, бу әсәрне

укып чыгарга, өйрәнергә киңәш бирәм. Әгәр авызлары чалыш күренсә, көзгегә ачуланмасыннар».

Г. Исхакый да әсәрне хуплап чыкты (кара: Исхакый Гаяз. Әсәрләр. 6 т., Казан: Татар кит. нәшр., 2005.— 131—135 б.).

1907 елда С. Рәмиев «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!» исемле пьеса яза, һәм ул шул ук елның көзендә аерым китап булып басыла. Әсәрдә алдынгы карашлы яшьләрдән Сөләйман белән Зөбәйдә образлары бирелгән. Дүрт пәрдәлек әлеге драма нигездә татар тормышындагы иске гореф-гадәтләргә ябышып ятуны тәнкыйть итүгә багышлана. Динмөхәммәт хәзрәт кебек дин әһелләре — мөселманны күз карашы белән куркытып торган, һәр сүзне я ачуланып, я бик мәһабәт итеп сөйли белә торган куркыныч затлар хатын-кызларны кол хәлендә тотарлар иде. Аз гына башкачарак булырга тырышуны да алар үз хакимиятләренә кизәнү, аны йомшарту дип карыйлар. Драманың төп геройлары Сөләйман белән Зөбәйдә менә шушы тәртипләргә каршы баш күтәрәләр һәм кыюлыклары, мәхәббәтләренә тугрылыклары сәбәпле җиңеп чыгалар. Ләкин шунысы бар: әлеге яшьләр М. Фәйзинең «Галиябану» драмасындагы кебек авыр шартларга куелмаганнар. Галиябану белән Хәлилнең бергә булуына төп каршы килүчеләр — кызның ата-анасы, аларны «мең тәңкә» белән үз ягына аударган Исмәгыйль бай. С. Рәмиев әсәрендә исә Зөбәйдәнең атасы Садыйк бай — Бәдринең киресе. Ул «бер кияү чыкканда бирмәсәң, икенче мәртәбә кияү чыкмыйча, утырып та калалар алар» дип, кызын бер байның бозык холыклы малаена кияүгә бирергә карар кыла. Ләкин кызы Зөбәйдәнең күңеле Сөләйманда булуын белгәч, яшьләрне үз ирекләренә куя. Бу эшкә бераз киреләнеп торган хатынын да ризалата.

Әмма әсәр әлеге «өчпочмак» арасындагы мөнәсәбәтләрне күрсәтүдән генә торса, ул безгә мәгълүм шундыйрак әсәрләрне кабатлаудан әллә ни уза алмаган булыр иде. С. Рәмиев сурәтләү даирәсен шактый киң итеп ала. Бу, барыннан да элек, Сөләйман образы белән бәйле. Әлеге образда без С. Рәмиевнең үз омтылышларын, биографик сәхифәләрен дә күрәбез. Сөләйман да, С. Рәмиев кебек үк, бөтен гамен, тормышын халыкка хезмәт итүгә, аның аңын үстерүгә, җәмгыятьтәге чын һәм ялганны күрсәтеп бирүгә багышлаган. Моның өчен ул газета чыгару, аң-белем тарату юлын сайлаган. Әлеге юлда Сөләйман алдында бик күп каршылыклар

тора: өстен катлаулар, фанатик динчеләр аның абруен төшерү өчен гайбәт тараталар, типография хуҗалары исә газетасын басудан баш тарталар. Әти-әнисе дә аны үз яннарында күрергә телиләр. Әйе, әсәрдә аталар һәм балалар мөнәсәбәте искелек белән яңалык тарафдарлары буларак тасвирлана. Бу — Ф. Әмирханның «Яшьләр» әсәрен (1909) хәтерләтә. Әти-әнисенең өйгә кайтырга чакыруларына каршы Сөләйман болай ди: «Юк, кайтмыймын мин, халык арасында каламын. Мин халыкка хезмәт итәмен. Халкыма чын белән ялганны аңлатамын. Минем тормышым монда мәсгуд[1] булачак».

Шунысы әһәмиятле: Сөләйманның омтылышларын сөйгән кызы Зөбәйдә тулысынча кабул итә, аңлавын белдерә. Бу исә егеткә үз алдына куйган максаты өчен көрәшергә көч бирә. Сөләйман халыкны аңлы итеп тәрбияләү эшендә хатын-кызларга аеруча өметләр баглый. «Кызлар яшәсен! Кызлар кеше булсын! Кызлар кеше булса гына, без кеше булачакбыз!» — ди ул. Ягъни биредә хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсе үзәккә куела. Ләкин, хатын-кызлар ирләр белән тигез булсын өчен, нәрсә эшләргә кирәк соң?

Пьесадагы Зөбәйдә: «Безгә укырга кирәк, үзебезне үзебез белергә кирәк тә, үзебез дә ирләр хәтле булырга кирәк. Ирләр ни нәрсә белсәләр, без дә аны белербез! Һәм шул белгән чакта гына кеше рәтенә керербез!» — дип, хатын-кызларның якындагы бурычларын билгели.

Әлбәттә, мондый эчтәлекле әсәр ул вакыттагы хакимияткә һәм дин әһелләренә ошамый. Алар таләбе буенча, китап җыеп алына һәм яндырыла. Шулай да берничә данәсе кеше кулында кала, тарихчы һәм әдәбият галиме Г. Гобәйдуллин 1911 елда әсәрне яңадан бастырып тарата. Нәтиҗәдә С. Рәмиевнең бик әһәмиятле фикерләр үткәргән пьесасы халыкка җиткерелә һәм сакланып кала.

С. Рәмиев — XX йөз башы татар әдәбиятында сүз сәнгатебезне үстерүгә үзеннән җитди өлеш керткән шәхес. Аның үз чорындагы һәм аннан соңгы татар әдәбияты әһелләренә ясаган йогынтысы зур булды.

Сораулар һәм биремнәр

1. С. Рәмиев — шигърияттә романтик. Проза һәм драма әсәрләрендә исә реалист. Әсәрләре буенча шушы фикерне раслагыз.

---

[1] *Мәсгуд* — бәхетле.

2. «Ул исерек түгел иде» әсәренең төп герое Мәҗитнең күңел дөньясында барган каршылыклы уй-хисләр сездә нинди тәэсир калдырды?

3. Мәҗитнең этисе Нигъмәтулланың гаиләсенә мөнәсәбәттә рәхимсезлеге нидән килә дип уйлыйсыз? Бу образны сурәтләгәндә автор кулланган сатира алымнарына игътибар итегез.

4. «Низамлы мәдрәсә» комедиясендәге Садыйк хәлфә ни өчен мәдрәсә әһелләрендә яклау тапмый?

5. Комедиядәге хәзрәт, дамелла, казый образларының сурәтләнү үзенчәлегенә игътибар итегез. Автор биредә сатира буяуларын куертып җибәрмәгәнме?

6. «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!» пьесасында уңай һәм тискәре образлар арасында килеп туган капма-каршылыкның сәбәпләре нидән гыйбарәт?

7. Мәхәббәт хисләреннән тыш, Сөләйман белән Зөбәйдәне тагын нәрсә бер-беренә якынайта?

8. Хатын-кыз иреге мәсьәләсе әсәрдә ни рәвешле куела?

9. Каләм әһеле һәм җәмәгать эшлеклесе буларак, С. Рәмиевнең татар әдәбияты һәм иҗтимагый фикер үсешенә ясаган тәэсире турында сөйләгез.

Иҗат методы буларак романтизм

Әдәби әсәр язучының хыялы белән тудырыла. Ләкин хыял итү дәрәҗәсе төрлечә булырга мөмкин. Бар аның тормыштан бик ераклашканы һәм бар аның шуннан әллә ни аерылмаганы. Үзенең чынбарлыкны аңлавыннан, бәяләвеннән чыгып, кеше дөньяга шәхси карашын, мөнәсәбәтен булдыра. Болар аның эш-гамәлләрендә, кешеләр белән мөнәсәбәтендә, үз-үзен тотышында чагыла. Димәк, тормышның үзендә дә, реалистлар булган кебек, романтиклар да бар. Дөресен әйткәндә, бераз гына романтик булмаган кешене (бигрәк тә яшь чагында) очрату кыендыр.

Каләм остасы, әгәр дә ул чынбарлыкка тугры икән, боларның йогынтысын тоймый калмый. Ләкин шулай да без аерым сүз сәнгате осталарын романтизм вәкилләре дип кистереп әйтәбез. Болай дияргә нәрсә хокук бирә соң?

Гадәти тормышны булганынча сурәтләү дә кызыклы булырга мөмкин, чөнки анда да, үзегезгә мәгълүм, укучыларны җәлеп итәрлек хәл-әхвәлләр бихисап. Ләкин шундый кешеләр була, алар өчен әйләнә-тирәдәге тормыш кызыксыз, бертөрле, эчпошыргыч булып тоела. Күңеле ниндидер башкача дөньяга, бүтәнрәк мөнәсәбәтләргә омтыла. Нәтиҗәдә, хыялында гына

булса да, шул үзе теләгән шартларны барлыкка китерә. Димәк, романтизм яшәп килүче тәртипләргә, мохиттән риза булмау сәбәпле туа. Мондый алым белән язучы, гадәттә, тыныч урталыкны өнәмәскә мөмкин: аның өчен матурлык илаһи булган кебек, шуңа каршы куелган ямьсезлек тә күпереп, арттырылып кабул ителә. Романтик язучы, шагыйрь, драматург гадәтилектән ераклашу максатында әкияти, мифик алымнарга, образларга да иркен мөрәҗәгать итә, аларны әсәрләренең тукымасына уңышлы кертеп җибәрә. Мондый иҗат методы белән язылган әсәрләр хис-кичерешләргә бай була, ләззәт һәм газап, рәхмәтлелек һәм рәхимсезлек, матурлык һәм ямьсезлек кебек капма-каршылыкларның кискен бәрелешенә корыла. Моны С. Рәмиев иҗатында еш очратабыз. Аның каһарманнары җәмгыять белән генә түгел, хәтта күк кануннары белән дә каршылыкка керәләр.

Дәрдемәнд романтизмы исә бөтенләй башка төрле. Аның романтик табигатьле лирик герое — бик нәфис, нечкә күңелле, сүзне хикмәт дәрәҗәсенә җиткереп әйтүче акыл иясе. Без боларны олы шагыйрьләребез иҗатын өйрәнү барышында күреп уздык инде.

Г. Ибраһимовның романтик геройлары исә төрле-төрле. Зыя («Яшь йөрәкләр») эчтән янучы, тирәлеккә кыю тәэсир итүдән мәхрүм булса, Тимери («Карак мулла») — үзе теләгәнне умырып алырга сәләтле кеше. «Мин» образы исә («Диңгездә»),— гадәттән тыш шартларда авырлыкны җиңү өчен, үзен бер йодрыкка туплый алса да, көндәлек хәл-әхвәлләрдә көрсенүдән уза алмый торган зат.

М. Фәйзинең «Кызганыч», «Тәкъдирнең шаяруы» кебек романтик пьесаларындагы образлар — бөтенләй башка дөнья кешеләре. Аның Хәлил белән Галиябануы («Галиябану») да романтизмның матур буяулары белән өретелгәннәр.

Татар әдәбиятында романтизм урта гасырлардан килә. XX йөз башында җәмгыятьтә барган инкыйлаби, милли-азатлык хәрәкәтләренең күтәрелүе романтизмның үсеп китүе өчен җирлек булды. Бу хәл сүз сәнгатебезнең һәм эчтәлек, һәм сәнгатьчә эшләнеш җәһәтеннән тагын да югарырак дәрәҗәгә күтәрелүенә китерде.

Нәҗип Думави
(1883—1933)

Тормыш юлы

Татарстан Республикасының Аксубай районында Яңа Дума исемле авыл бар. Шул авылда Сибгатулла мулла гаиләсендә 1883 елның 19 маенда бер ир бала дөньяга килә. Аңа Нәҗип дип исем кушалар. Үсә төшкәч, малай дүрт ел буе әтисеннән сабак ала. Ул үзенең балалык һәм яшүсмер еллары турында болай яза: «Авылның мәчете янында бер мәктәп бар иде. Әти сабак тыңлата, сабак бирә иде... Бер үк вакытта «Иман шарты»ннан иҗек укый идек...

Әти мине намаз укыта башлады. Унбер яшемдә вакыт мине Кизләү[1] ишаннары мәдрәсәсенә илттеләр. Кизләүдә бер кыш укып, киләсе кышта Казанга, Габдулла Апанаев мәдрәсәсенә илттеләр. Казанда унтугыз яшемәчә укыдым. Һади Максудов гарәп сарф-нәхүен[2] татар теле белән укытты, гарәп теленә бик тиз төшендем... Иске мантыйк (логика), иске хикмәт, физикаларны иске фикерле бер хәлфәдән укыдым. Үземнән-үзем хәдис[3], тәфсирләр[4] карадым... Шулай итеп, барганымнан дүртенче елда үзем дә кечкенә генә бер хәлфә булып, укуны тәмам кыйлдым.

Шул унтугыз яшемдә беренче мәртәбә яңа китап — җәгърәфия һәм һәйәт[5] китабы кулыма төште. Шәмсетдин Күлтәси

[1] *Кизләү* — Татарстанның Нурлат районындагы авыл.
[2] *Сарф-нәхү* — морфология-синтаксис.
[3] *Хәдис* — Мөхәммәд пәйгамбәр сүзләре.
[4] *Тәфсир* — Коръәнне аңлатып язган китап.
[5] *Җәгърәфия һәм һәйәт* — география һәм астрономия.

дигән кешенең бу китабы миңа шулхәтле каты тәэсир итте... Әх, шундый китапларны кайдан кулга төшерергә? Яшь вакыттагы хәлфәм Һади Максуди өенә барып, иске «Тәрҗеман» газеталары, төрек газеталары алып кайтып укый башладым. Галиәсгар Камал белән танышып алдым. Ул Төркиядән китаплар алдыра башлады...

Татар балалары өчен ачылган рус мәктәбе бар иде, буй җиткән егет булсам да, сигез-тугыз яшьлек балалар арасына барып укырга язылдым. Бик тиз төшенеп киттем. Учительский школага керергә уй кузгалды».

Ләкин Нәҗипкә бу мәктәпкә кереп укырга насыйп булмый. Анда уку өчен әзерлеге дә җитәрлек булмый, матди мөмкинлеге дә чамалы гына. Акча, өс-баш юнәтү нияте белән казах далаларына китеп бара. Менә шуннан аның мөгаллимлек эшчәнлеге башлана. Чистайда, Кизелдә, «Буби» мәдрәсәсендә, Рязань губернасының Вәрәки авылында һәм Үзбәкстанда балалар укыта. 1911 елның башында патша жандармериясе заманы өчен алдынгы уку йорты булган «Буби» мәдрәсәсен тар-мар китерә, мөгаллимнәрен кулга ала, шәкертләрен куып тарата. Китапларны урамда өеп яндыралар. Н. Думави да башка мөгаллимнәр белән бергә кулга алына һәм Сарапул шәһәрендә тугыз айдан артык төрмәдә утырып чыга. 1917 елның октябренә кадәр ул полиция күзәтүе астында тотыла. Н. Думави 1904—1905 елгы япон һәм 1914 елгы империалистик сугышларга алына, яралана.

Н. Думави — карашлары ягыннан шактый каршылыклы шәхес. Ул шагыйрь, мөгаллим булып танылa. 1921—1925 еллар арасында үзенең туган авылында мулла була, ә 1929 елда Казанда рухы белән дингә каршы китап чыгара. Үзбәкстанда яшәгәндә «Ходасызлар» журналында да шундый эчтәлекле мәкаләләре басыла.

Нәҗип Думави 1933 елның 5 маенда илле яшендә Сәмаркандта вафат була.

Сораулар һәм биремнәр

1. Нәҗипнең белемгә омтылучы һәм укырга сәләтле малай булуын дәлилләп күрсәтегез.

2. Элекке мәдрәсәләрдә уку ничек оештырылган, нинди фәннәр укыганнар? Нәҗипнең кызыксынучан шәкерт булуы нәрсәләрдә күренә?

3. Н. Думавиның дөньяга карашындагы каршылыкларның сәбәбе нидән килә дип уйлыйсыз? Ул ни өчен әзәрлекләнгән?

Иҗатына гомуми күзәтү

Нәҗип Думави казах далаларында балалар укыткан елларда каләм тибрәтә башлый. Үзе дә казахларның халык авыз иҗаты әсәрләрен, җырларын өйрәнә. Халыкның авыр хәле, караңгылык, наданлык, алга таба хәл-әхвәлнең яхшыруына өмет булмау — Н. Думави иҗатының башлангыч чорында төп темалар. Аның әсәрләрендә еш кына милли-азатлык һәм мәгърифәтчелек идеяләре белән рухланган герой урын ала. Шагыйрь 1905 елгы инкыйлабны хуплый.

Бу яктан «Хөррият белән тәбрик» шигыре әһәмиятле. Татар халкына үз язмышын үз кулына алырга чакырып мөрәҗәгать итүе белән ул бүген дә вакытлы һәм урынлы яңгырый.

Мин яшим дип чык аланга,
Бас аякны нык, татар.
Шул «Татар» исемең барында
Курыкма, нык бул, татар.

Син арыслан, синдә куәт —
Бир тавыш — җир тетрәсен;
Син бөек, син көчле милләт,
Атла «коллык киртәсен».

Бул бәхетле, — син иркле,
Үз эшеңне бел, татар.
Мең йәшә, миллион йәшә, әй,
Әй йәш татар, хөр татар!

Иҗат кешесенең тормыш юлы аның әсәрләрендә дә чагыла. Ике сугышта катнашкан кеше буларак, Н. Думавиның «Агач аяк», «Головка» хикәяләрен, «Сугыш тәэссораты» шигырен иҗат итүе очраклылык түгел иде. Мәхбүслек[1] турындагы шигырьләре дә аның үз үткәне белән бәйләнгән. Нахакка иректән мәхрүм ителү аны бу турыда уйланырга мәҗбүр иткән. Алар «Мәхбүс (Күп еллар ятамын...)», «Мәхбүс (Дөньяда төннәр узып...)», «Мәхбүс (Төн тынык...)», «Мәхбүс дустыма» кебек шигырьләрендә гәүдәләнәләр.

Шагыйрь бик күп укый, Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәбиятлары, рус әдип-шагыйрьләре әсәрләре белән даими танышып бара. Халкыбызның үткәнен, тарихын өйрәнә. Кайчакта

[1] *Мәхбүс* — тоткын.

аңа бәхетле заман үткән йөзьеллыкларда булган кебек тоела. «Шәрык даһие» поэмасында, мәсәлән, ул шулайрак уйлана. Чыңгыз хан образының уңай сыйфатлары әлеге әсәрдә калку итеп бирелә. Н. Думавиның борынгы фикер ияләренә хөрмәт белән каравы аның 973—1058 елларда яшәгән гарәп шагыйре һәм фәлсәфәчесе Мәгарригә булган ихтирамлы мөнәсәбәтендә дә күренә. «Бер кисәк нәрсә белән...» (1912), «Ник мине сез орышасыз?..» (1912) шигырьләренең Мәгарри әйткән сүз рәвешендә бирелүе шуңа дәлил. Төрек әдәбияты да аңа якын иде. Ул аннан да иҗатына илһам алды. «Бер Вәлидәнең[1] балаларына нәсыйхәте» (1907) шигыренең ахырына «төрекчәдән» дип куйганлыгы да мәгълүм.

Шагыйрь тәүге җыентыгына (1912) беренче итеп «Әй минем шигырьләрем» дигән шигырен урнаштыра. Ул үзенең шигырьләренә «мөхтәрәмнәр»[2] дип эндәшә, аларны олылый. Чөнки бу әсәрләрдә аның күңеленә тулган хис-кичерешләре бәян ителгән. Сез, ди ул аларга, шат күңелдә аткан чәчәк түгел, чөнки «һич насыйп булмас миңа дөньяда шатланган күңел». Моннан күренгәнчә, Н. Думавига тормышта шатлану өчен сәбәпләр бик булмаган, ул хисләнергә, тирән кичерешләр белән мәшгуль булырга мәҗбүр.

Н. Думавины шагыйрь итеп танылгамы-юкмы? Г. Камал, мәсәлән, 1907 елда болай яза: «Арада (моңа кадәр шигырь язып килеп тә даими язучылар рәтендә. — *Ф. Г.*) фәкать өч кеше калды. Болардан берсенә (Нәҗип Думавига) нинди тамга (проба) сугарга хәзергә мин булдыра алмыйм. Минем каршымда Габдулла әфәнде илә Габделмәҗит әфәнделәр алга чыктылар. Хәзерге көндә шагыйрь исемен итлакъ кылырга[3] шул икесе лаектыр».

Моңа каршы Н. Думави «Йолдыз»га дигән шигырен яза:

Тотма телен, әй Г. Камал,
Думавиның, сөйләсен;
Үзе сөйгән думбрасын
Ярма, чалсын-көйләсен.

Әйе, Н. Думавиның әдәбиятыбызны үстерүгә керткән үз өлеше бар.

---

[1] *Вәлидә* — ана.
[2] *Мөхтәрәм* — хөрмәтле.
[3] *Итлакъ кылырга* — исемен бирергә.

Аның XX йөз башы татар вакытлы матбугатында еш язышуына сокланмый мөмкин түгел. Рус матбугатында да басылу мөмкинлеген таба. Н. Думавиның бөтен эшчәнлеге һәм иҗаты аның үз заманы борчулары белән янып яшәгәнлеген күрсәтә. Моны аерым шигырьләре мисалында җентеклерәк күрергә мөмкин булыр.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шагыйрь әсәрләрендә нинди темаларга мөрәҗәгать итә?

2. 1905—1907 еллардагы инкыйлабка аның мөнәсәбәте ничек?

3. «Хөррият белән тәбрик» шигырендә шагыйрь татар халкы язмышы мәсьәләсен ничек күтәрә?

4. Шагыйрьнең биографиясе һәм эшчәнлеге аның иҗатында нинди чагылыш таба?

5. Башка милләтләр әдәбиятларын өйрәнү Н. Думавиның үз иҗатына ничек тәэсир итә?

6. Шагыйрь үзенең шигырьләренә ни өчен «мөхтәрәмнәр» дип эндәшә?

7. Үзенең иҗат итәргә хокукы булуын шагыйрь ничек итеп дәлилли? Аның Г. Камалга җавап итеп язган шигыренең интонациясенә, үз карашын дәлилләү рәвешенә бәя бирегез.

8. Н. Думави XX йөз башында бик өлгер һәм нәтиҗәле язган. Шушы фикерне дәлилләп,ниләр әйтергә мөмкин?

Шигырьләрдә тормыш гамьнәре

«Яз» әсәре (1906) Н. Думавины лирик шагыйрь буларак күрергә ярдәм итә. Елның бер фасылы булган яз көненең күренешләрен шагыйрь бөртекләп тасвирлый. Ул әле авылдагы, әле шәһәрдәге язны, аннан кыр-басу күренешләрен күздән кичерә. Язның гүзәллеге лирик геройның кәефен күтәрә, аның сөйләме нәфисләнгәннән-нәфисләнә бара.

Әлбәттә, яз килүгә аеруча куанучылар — балалар. Озын кыш буе кысан өйләрдә, мәдрәсәләрдә гомер уздырганнан соң, табигать хозурлыгы, саф һава, киңлек, кояшның җылы нурлары аларны чып-чын бәхетле иткән. Мондый халәтне бала вакытта кайсыбыз гына кичереп кинәнмәгән!

Яз сулышы картларның сөякләрен җылыткан, алар да җиңеләеп киткәннәр. Шул рәвешле, шагыйрь үз чоры язының шигъри рәсемен гәүдәләндергән. Башка заман шагыйре яз күренешен, әлбәттә, бүтәнчәрәк тасвирлар иде.

Н. Думави сурәтләвенчә, балалардан кала, яз килүгә иң шатланучылар — фәкыйрьләр. Чөнки аларны кыш буе җәфа-

лаган салкыннар, кар-бураннар китә. Өс-башына рәтле киеме, ягарына утыны, җигәренә ат-чанасы булмаган ярлыга кыш мәңге узмас кебек тоела.

Шигырь язу — башка ни килсә, шуны язып кую түгел. Аның укучыны җәлеп итәрдәй фикере, төзелешендә һәм язылышында нәфислек, төгәллек булырга тиеш. Бигрәк тә лирик әсәрне шушы сыйфатлардан башка күз алдына китереп булмый. Әсәрнең иseme астына «мәгънәле назым», ягъни «мәгънәле шигырь» дип куелуы шуңа ишарә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Яз көне табигатьнең үзгәрүе кешенең үз-үзен тотышына ничек тәэсир итә?

2. XX йөз башы язы белән бүгенге язны сурәтләгәндә, шагыйрьләр кулланган тасвирларда нинди аермалар булырга мөмкин? Н. Думави үз чорына гына хас булган нинди сыйфатламаларны куллана?

3. Шагыйрьнең әсәрләрендә очраган кайсы сүзләр соңгы елларда кулланылмый башлаган иде? Аларның мәгънәләрен ачыклагыз.

* * *

«Золым» шигыре 1906 елда иҗат ителгән. Бу — Россия империясендә инкыйлаб һаман көчәя барган вакыт. Шигырьдә яшәп килүче җәмгыять тәртипләренең намуслы кешегә каршы юнәлдерелгән булуы нык тәнкыйть ителә. Рәсми сәясәтне автор золым, ягъни усаллык, явызлык дип атый. Кешене хокуктан мәхрүм итү гадәткә әйләнгән, бозыклык чигеннән чыккан.

Халыкның күзен наданлык белән томалаганнар. Гыйлемне агу дип бәяләгән җәмгыятьтә алга китеш була алмый. Өстенлеккә намуслы кешеләр түгел, бәлки азгыннар ирешкән. Золымнар дөньяны томандай каплаган. Адәм балалары, бу хәлгә борчылсалар да, берни эшли алмагач, барысына кул селтәгәннәр, башларын ахмаклыкка салганнар. Бергә-бергә эш итәсе урында, таркау хәлгә килгәннәр, дөнья мин-минлекле кешеләр белән тулган. Көчлеләр көчсезләрне таптыйлар. Хәзер инде залимнәр, битлекләрен салып ташлап, адәм канын кеше күз алдында, ачык мәйданнарда суыралар. Димәк, кешене изү гадәти хәл булып әверелгән.

Тарих кабатлана, диләр. Н. Думави сөйләгәннәр XX йөзнең туксанынчы елларындагы күп кенә хәл-әхвәлләрне хәтерләтә. Ләкин моннан туксан еллар чамасы элек булган хәлләр белән хәзергеләре арасында аерма бик зур. Хәзерге җәмгыять хәл

итәсе бурычлар күпкә катлаулырак. Якты максатка бару юлын табуга иң комачау итә торган нәрсә — кешеләрнең көннән-көн рухи ярлылана баруы. Димәк, рухи, милли, дини хисләрне яңарту, аларны гомумкешелекнең уңай сыйфатлары белән уңышлы итеп кушу — әлеге кыен хәлдән чыгуның иң дөрес юлы. Золым — кешелеккә бервакытта да бәхет китерми, явызлык бары тик явызлык кына тудыра. Н. Думави укучыларны шул хәтәр турында кисәтә.

Шигырь фикер сөреше ягыннан тәмамланмаган, аның ахырына өч нокта куелу шуны күрсәтә. Акыллы укучы аны үзе уе белән тәмамлап куя. Әсәрне уку дәвамында укучы золымның капма-каршысы булган «кешелеклелек», «яхшылык» дигән төшенчәләрне юксына башлый. Аңарда бу хәлләрне уңай якка үзгәртергә теләү омтылышы уяна. Бу инде — шагыйрьнең әсәрне язганда үз алдына куйган максатына ирешүе дигән сүз.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шагыйрь XX йөз башы җәмгыятен нинди итеп күрсәтә?

2. Өстен катлауларны тасвирлаганда, автор аларның бары тик тискәре сыйфатларына гына игътибар итә. Алар нидән гыйбарәт? Шагыйрь ни өчен бу катлауның уңай якларын күрә алмый?

3. «Акбүз атларны ишәктән дә түбән дәрәҗәгә төшергәннәр» дигән җөмләдәге мәгънәне сез ничек аңлыйсыз?

4. XX йөз башы хәл-әхвәле белән бүгенге тормыш арасында нинди уртаклыклар һәм аерымлыклар бар?

5. Кешеләрнең холкын уңай сыйфатлар белән баету өчен, нәрсәләр эшләргә кирәк дип уйлыйсыз?

6. Шигырьнең ахырына сез тагын нинди фикерләр өстәр идегез?

* * *

«Үтте, үтә...» шигыре беренче тапкыр 1906 елның 4 августында басылса да, аның берничә ай элегрәк язылган булуы ихтимал. Әсәрдә 1905 елның октябрь көннәре — инкыйлаби күтәрелешнең иң югары ноктасына җиткән вакыты һәм аннан соңгы вакыйгалар хакында сүз бара. Тик ул вакытлар «җил кебек узып китте хәзер бары». Билгеле булганча, бу инкыйлаб җиңелә, патша хакимияте, шактый какшаса да, әле аягында басып кала. Мондый хәл илдәге тормышны үзгәртеп кору нияте белән янган кешеләрне борчуга сала. Алар арасында Нәҗип Думави да бар. Ул шигырьнең беренче юлында ук сүзне «аһ-ваһ итеп, кайгы илә» башлавын әйтә.

Бу вакыйгалар турында шагыйрь хакыйкатьне язарга тели. Ләкин дөресен язу — ул хаким көчләрнең гаебен ачу дигән сүз. Алай эшләсәң, ватаныңнан ерак качарга кирәк. Чөнки «түзалмаслык йөрәк янса» да, серенне язма рәвештә сөйләсәң, һәр хәрефе саен бер камчы алачаксың. Патша, 17 октябрьдә Манифест чыгарса да, вәгъдә иткәннәрен үтәмәде. Шагыйрь нәтиҗә ясый: «Ышаныч юк икән шул һич ...га (ягъни патшага. — *Ф. Г.*). Җибәрде ничә меңнәрне каторга!» Автор «ышаныч юк икән шул һич ...га!» дигән юлны ике тапкыр кабатлый. Моның белән ул өстен катлауларның фәкыйрьләрне изү коралы булган патша хакимиятенә ышанычсыз карашын ассызыклап әйтергә омтыла.

1906 ел шартларында шагыйрь яшерен тел (аны Эзоп теле дип тә әйтәләр) белән язарга мәҗбүр. «Патшага» сүзен «...га» рәвешле язуы шуннан килә. Шигырьнең азактан икенче юлына ул тулаемы белән күпнокталар тезеп чыккан. Күрәсең, ул юлда хакимияткә каршы тагы да усалрак фикер әйтелгән булгандыр. Анда ниндирәк сүзләр булганлыгы турында фараз кылырга гына туры килә. «Башы кырган без такырга» дигәндә, сүзнең татарлар турында баруы аңлашыла. Чөнки аларны мыскыл итеп «гололобый» (такыр башлы, шәрә маңгайлы) дип йөртүләре — тарихи хакыйкать. Татарларга гына түгел, «ирек кирәк барлык халыкларга» дип әйтергә теләмәдеме икән дип уйларга гына кала.

Октябрьдәге кайнар көрәш көннәре үтә, хәзер кара көчләр басымы астында инкыйлаб сүрелә бара. Вакыт үтә, өметләр киселә... «Үтте» дип үткән заманның кире кайтмаслык булып артта калуын бирсә, «үтә» диюе белән бүгенге көннең барышын да туктатып булмавын белдерә. Аннан соң куелган күпнокталар — вакытның чиксезлегенә ишарә. «Гомерләр коштай очып узып бара»,— дип уфтана лирик герой. Шигырь әнә шундый күңелсез уй-хисләр белән сугарылган. Мондый эчтәлектәге шигырьне саф күңелле, халык мәнфәгатьләре белән яшәүче, аның бүгенге хәле, бигрәк тә киләчәге турында ихлас гамьләнүче шәхес кенә яза ала.

Сораулар һәм биремнәр

1. Лирик герой ни өчен сүзне «кайгы илә» дип башлый?

2. Хакыйкатьне сөйләгән өчен камчы тиешен белеп тә, рәсми хакимиятләргә каршы язылган бу әсәрен бастырып чыгарган Н. Думави,— сезнеңчә, нинди сыйфатларга ия кеше?

3. Вакыт һәм вакыйгалар агышы әсәрдә ничек бирелгән? Шул хәрәкәттәге кешенең карашындагы үзгәрешләрне күзәтегез.

4. Әсәрдә берничә урында күпнокталар файдаланылган. Алар үтәгән вазифаларны аңлатыгыз.

5. Соңгы строфа алдыннан буш калган юлны, әсәрнең тулаем эчтәлегеннән һәм рухыннан чыгып, үзегез уйлап языгыз.

* * *

Н. Думави — татар халкының үсешен тоткарларга омтылган кара эчле бәндәләрнең әләге белән тоткынлыкның ачысын татыган зат. Шуңа күрә «Мәхбүс дустыма» дигән шигырендәге лирик геройның уйлары һәм кичергәннәре аның үзенә дә яхшы таныш.

Төрмә. Тоткыннарның берсе пычранып, тузанланып беткән тәрәзәдән күзен алмыйча карап утыра, үзе ниндидер уйларга баткан. Якындагы иптәше аның тәрәзәгә күз төбәп утыруына гаҗәпләнә. Чөнки аннан берни дә күренми, бары тик сакчы шәүләсе генә чагылырга мөмкин. Бу кеше, шулай бер ноктага текәлеп, бәлки иректәге дусларын исенә төшергәндер? Берәрсе, миһербанлык кылып, аңа ярдәм кулын сузмасмы? Ләкин, лирик герой уйлавынча, моңа исәп тотарга өмет юк. Хәтта иректә калган иң якын күргән дустың да «бар гаеп аның үзендә» дип куяр. Иректәге кеше тоткынның хәлен аңлыймыни? «Дөньяда тормакка эстәр[1] чын кеше бит тик алар».

Лирик герой, күргәнебезчә, кешеләргә ышанычын югалткан. Аныңча, адәмнәр үз-үзләрен генә сөяләр, аларның бүтәннәрдә гаме юк. Дөньяда бары тик шәхси көчеңә генә таянырга мөмкин. Иректәге кешеләрнең бәхетенә көнләшеп карау да бар аңарда. Ләкин ул алардан мәрхәмәт өмет итүдән ерак тора.

Шулай да ул, вакытлы кыенлыкларга түзеп, тормышта үзенең хаклы булуын раслар дигән ышаныч кала.

Сораулар һәм биремнәр

1. Теленә, сөйләмне оештыру рәвешенә карап, лирик геройның нинди шәхес булуын ачыклагыз.

2. Сезнеңчә, кешедә башкаларга ышаныч бетү кайчан булырга мөмкин?

3. Сезнең тагын кайсы татар шагыйренең тоткын дустын юатып язган әсәрен укыганыгыз бар?

---

[1] *Дөньяда тормакка эстәр* — дөньяда торырга теләгән.

* * *

Кешеләргә гаять зур зыян китергән афәтләр була.Шуларның иң куркынычы — сугыш. Н. Думави «Сугыш» исемле шигырендә (1908) шул турыда уйлана. Кеше — табигатьнең бердәнбер камил акыллы җан иясе. Югыйсә сугыш кебек хәтәр нәрсә инстинкт белән эш итүче ерткыч хайваннар арасында гына булырга тиеш иде дә бит. Асылда, алай түгел. Кешелек җәмгыятендә бервакытта да сугышлар тынып тормый.

Әсәрнең беренче юлында ук шушы хәлгә нык гаҗәпләнү белдерелә: «Ни хәл бу? Капланган көррәи арыз[1] кан белән, буялган төтенгә». Гаҗәпкә каршы, сугышларның булуын аклаучылар да бар, аларча, имеш, гел тынычлык торса, адәм күп үрчи. Лирик герой мондый карашларны нәфрәт белән кире кага: сугыш булмаганга борчылу сәламәт акыллы кеше эше түгел.

Шигырь сәнгатьчә камилрәк язылган булса, аның яңгырашы тагын да киңрәк булыр иде. Шулай да мәгънәви ягы көчле булганга (ягъни кирәкле фикерләр әйтелгәнгә), Г. Тукай «Сугыш» шигырен үзе төзегән «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» китабына (1911) кертә. Шагыйрь империалистик сугыштан алган кичерешләрен «Сугыш тәэссораты» дигән әсәрендә дә (1916) гәүдәләндерә. Автор биредә ирония алымын куллана, шуның белән укучыда сугышка каршы нәфрәтнең тагын да көчәюенә ирешә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Илләр, халыклар арасындагы сугышлар — табигый булмаган хәл. Аларның килеп чыгуы нәрсә белән аңлатыла?

2. Шагыйрь сугышка нинди мөнәсәбәттә тора? Ул, үз карашларын укучыга үтемлерәк җиткерү өчен, нинди сәнгатьчә чаралар куллана?

3. Сугышка карата кешеләрнең төрле катламнары, гадәттә, төрлечә мөнәсәбәттә була: кемнәрдер сугышны инкяр итәләр, ә кемнәрдер хуплыйлар. Сәбәбе нәрсәдә?

4. «Сугыш» әсәрен Г. Тукай үзе төзегән дәреслеккә кертә. Моның белән ул үзенең сугышка булган мөнәсәбәтен белдерә. Әйтегез, Г. Тукай һәм Н. Думавины бу мәсьәләдә нәрсә берләштерә?

---

[1] *Көррәи арыз* — Җир шары.

* * *

Шагыйрь кешене һәрнәрсәдә — сүздә, гамәлдә кеше булып калырга өнди. Кеше — табигать тарафыннан барлыкка китерелгән иң бөек зат, шуңа күрә ул үзенең дәрәҗәсен, җирдәге затлы урынын яхшы белеп эш итәргә бурычлы. Бу гомумкешелеккә карый. Шуны ук аерым кешегә карата да әйтергә мөмкин. Күпләр нәкъ менә шуңа омтылалар да. Ләкин кайберәүләр тормыш баскычларыннан түбән тәгәри. Аны моңа этәргән нәрсәләр күп булырга мөмкин. Кеше үзенә генә хас сәбәпләр аркасында эчкечелек, караклык, бозыклык юлына баса. Ләкин боларның һәммәсе өчен уртак бер сыйфат бар, ул да булса — алар үз шәхесләрен хөрмәт итә белмәгәннәр, моңа әһәмият бирмәгәннәр. Иң куркынычы — алар шәхес буларак таркалганнар. Мондыйларны сәламәт яшәү рәвешенә кире кайтару, гадәттә, мөмкин булмый. Ихтыярлары сынган кешеләрне тормыш үз җаена алып китә. Н. Думави «Син — кеше!» шигырендә (1916) шушы фикерне дәвам иттерә. Укучыга мөрәҗәгать итеп, ул болай ди:

Бирмә серне, бул гали — типсен йөрәк зурлык белән!
Булма мәхзүн[1] — сынма төшенкелек белән, хурлык белән!
Син — бөек! Салган Ходай күктән сиңа үз орлыгын.
Бул — гали! Таптатма, зинһар, шул «Ходайлык» зурлыгын!..

Бу инде кешене иң югары дәрәҗәдә зурлау, олылау, аңа дан җырлау иде. Н. Думави кешене әнә шундый югары дәрәҗәдә күрергә теләде. Бу — шагыйрьнең тоткан кыйбласының затлылыгы, кешелеклелеге турында сөйли.

Сораулар һәм биремнәр

1. Кешенең җирдәге урыны нидән гыйбарәт булырга тиеш?

2. Минем холкым — минем язмышым, диләр. Язмышын үз кулына алган көчле ихтыярлы кешеләр турында сөйләгез.

3. Кеше исемен мәсхәрәләү хәленә төшкәннәргә сез нәрсә әйтер идегез?

4. Н. Думави «Син — кеше!» әсәрендә кешене нинди итеп күрергә тели?

---

[1] *Мәхзүн* — моңлы, хәсрәтле.

* * *

Шигырьләреннән күренгәнчә, Н. Думави — лирик шагыйрь. Ул үзенә хас сизгерлек белән үз чорындагы әһәмиятле мәсьәләләрне тотып ала, аларны шигырьләрендә гәүдәләндерүнең тиешле рәвешен таба. Шул ук вакытта аны сәяси лириканы үстерүгә билгеле бер өлеш керткән шагыйрь дип исәпли алабыз. Үз карашларын үтемлерәк итеп уздыру өчен, ул ирония алымына да уңышлы мөрәҗәгать итә.

Н. Думави, нигездә, халык сөйләшә торган телдә яза, ягъни ул үзенең әсәрләрен гади кешеләргә исәпләп иҗат итә. Шул ук вакытта шигырьләрендә җиңеллек, образлылык җитенкерәми, шул сәбәпле алар авыррак кабул ителәләр.

Н. Думави проза әсәрләре дә язды. Ул аларда мәдрәсә шәкертләренең язмышын, казах далаларындагы тормышны, Идел буенда яшәүчеләрнең хәл-әхвәлләрен, борынгы бабаларыбызның берсе булган болгарларга бәйле кайбер сәхифәләрне сурәтләде. Аның чәчмә әсәрләре бүгенге буын укучысы өчен танып белү әһәмиятенә ия, чөнки халкыбызның үткәндәге яшәү рәвеше аларда шактый кызыклы гәүдәләндерелгән.

Сораулар һәм биремнәр

1. Н. Думавиның шагыйрь буларак үзенчәлеге нәрсәләрдә күренә?

2. Шагыйрьнең шигъри юлларны рифмалавына игътибар итегез. Шигырь юлларындагы иҗекләр санын исәпләгез.

3. Н. Думавиның татар әдәбиятына керткән өлешен сез ничек бәялисез?

4. Н. Думавиның «Син — кеше!» дигән шигырен, сәнгатьле итеп, яттан сөйләгез.

ЯҢА УҢЫШЛАРГА ЮЛ ЯРГАНДА

XIX йөз ахырында барлыкка килгән татар драматургиясе, әдәби төр буларак, ике дистә ел эчендә формалашып җитте. Габдрахман Ильяси («Бичара кыз», 1887), Фатих Халиди («Рәдде бичара кыз», 1888), Галиәсгар Камал («Бәхетсез егет», 1898; «Өч бәдбәхет», 1900), Гаяз Исхакый («Өч хатын белән тормыш», 1900; «Ике гыйшык», 1902), Ярулла Вәли («Оят, яки күз яше», 1907) кебек язучылар яңа төрнең беренче нигез ташларын салучылар булдылар. Аларның пьесаларында ир белән хатын мөнәсәбәте, кызларны көчләп кияүгә бирү, моңар төрлечә караш, акча һәм байлыкның кешене бозуы, мәгърифәтле булуның өстенлекләре кебек мәсьәләләр куела.

1905—1907 еллардагы рус инкыйлабы һәм ул еллардан соң барлыкка килгән шартлар татар тормышына көчле йогынты ясады. Җәмәгатьчелек беркадәр сүз һәм матбугат ирегe алды. Тиз арада төрле шәһәрләрдә дистәләрчә газета-журналлар басыла башлады.

1906 елда Уфада һәм Казанда беренче ачык спектакльләр куела, һәм шуның белән татар профессиональ театры мөстәкыйль үсеш юлына чыга. «Сәйяр»[1], «Нур», «Ширкәт»[2] исемле профессиональ труппалар, Петербург, Мәскәү, Әстерхан кебек шәһәрләрдә, кантон үзәкләрендә йөзләрчә үзешчән түгәрәкләр оешып эшләп китә. Болар үз чиратында драматургиянең тиз үсеп китүе өчен мөмкинлек ачты. Чөнки бу труппалар һәм түгәрәкләргә сәхнәләштерү өчен яңадан-яңа пьесалар кирәк була. Нәтиҗәдә төрле формалар барлыкка килә (сатирик комедия, водевиль, романтик драма, тарихи драма, трагикомедия һ. б.). Иң мөһиме, драматургиянең эчтә-

[1] *Сәйяр* — күчмә, гизүче.

[2] *Ширкәт* — җәмгыять, компания.

леге нык байый, ул тормышка тагын да якыная, иҗтимагый мәсьәләләргә мөрәҗәгать итә.

Татар драматургиясе беренче адымнарын мәгърифәтчелек реализмы кысаларында ясаган иде. Моны инде сез, укучылар, 9 нчы сыйныфта белеп калдыгыз. Бу чорда мәгърифәтле каһарман образы әсәрләрнең үзәгендә тора. Белемгә омтылу, татар тормышын мәгърифәтле итәргә тырышу, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең миһербанлы һәм гадел булуына ярдәм итү — мондый каһарманнарның тормыш максатлары. Пьесаларда җаһиллек[1] һәм саранлык, мәрхәмәтсезлек, инсафсызлык фаш ителә. Күп хатынга өйләнү, гаиләдә тупаслык, акча туплауны бердәнбер омтылышка әйләндерү кебек ул елларда кайбер татар гаиләләре тормышына хас булган сыйфатлар кире кагыла. Хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсе көчле куела.

XX гасырга кергәч, татар драматургиясе инде тәнкыйди реализм принципларын үзләштерә башлый. Аның тормышчанлыгы көчәя, сәнгати дәрәҗәсе үсә. Беренче рус инкыйлабы тәэсирендә драматургиядә кешегә мөнәсәбәт һәм аның тормыштагы ролен аңлату ноктасыннан да үзгәрешләр күренә. Аерым кеше язмышы халык язмышы, милләт язмышы белән тыгыз бәйләнештә карала башлый. Әсәрләрдә төп каһарман итеп, җәмгыять тормышында торган саен активрак роль уйный барган кеше образы алына. Пьесаларда катнашучылар һөнәрләре ягыннан да төрләнә. Элек еш сурәтләнгән сәүдәгәрләр, аксөякләр, кибетчеләр, шәкертләр янына эшчеләр, асраулар, мөгаллим-мөгаллимәләр, дин әһелләре, көрәшчеләр, иҗат кешеләре образлары өстәлә.

Менә шундый драматургияне тудыру һәм үстерү юлында яңа талант ияләре үсеп чыкты.

Гаяз Исхакый драматургиясе

Гаяз Исхакый — бөтен татар әдәбиятына, сәнгатенә һәм мәдәниятенә, фикер үсешенә нык тәэсир иткән язучы һәм шәхес. Ул милли драматургиягә һәм театр сәнгатенә дә көчле йогынты ясый. Шуны гына әйтү дә җитә: 1906 елның 21 апрелендә Уфада куелган беренче рәсми спектакльдә аның «Өч хатын белән тормыш» драмасы уйнала, ягъни татар профессиональ сәхнәсе бөек шәхеснең шушы әсәре белән пәрдәсен ача.

[1] *Җаһил* — надан, белемсез.

Г. Исхакый барлыгы 15 сәхнә әсәре иҗат иткән. Аларның кайберләре турында (болар, нигездә, язучы эмиграциягә киткәнче иҗат иткән пьесалар) дәреслекнең Гаяз Исхакый иҗатына багышланган бүлегендә сүз булды инде. Пьесалар белән тәртип буенча танышып чыккач, бу драматургиядә татар тормышының күп яклары чагылганын күрәсең. Халык яшәешенең төрле өлкә-тармаклары, төрле һөнәр ияләре, аларның идеаллары, өмет-ышанычлары, кайгы-хәсрәтләре гәүдәләнә бу пьесаларда.

Г. Исхакый беренче пьесасын — «Өч хатын белән тормыш»ны язганда милли драматургиянең жанр үзенчәлекләре тәмам ачыкланып җитмәгән була әле. Беренче татар пьесаларында текстка прозадагы кебек гади сөйләп бирү, ягъни хикәяләп күрсәтү, эш-хәрәкәтне авторның үзенең аңлатып бирүе кебек тәфсилләр дә килеп керә. Мәсәлән, «Рәдде бичара кыз» драмасын искә төшерик. Чоландагы самавырдан ут чыгып, мирзаларның өйләре яну, янгын вакытында Әптемнең Хәлимәне күреп гашыйк булуы кебек күренешләр автор тарафыннан хикәядәге кебек сөйләп кенә чыгыла.

Г. Исхакыйның беренче пьесалары ук инде мондый кимчелекләрдән азат. «Өч хатын белән тормыш» пьесасында хәрәкәт драматургия кануннары буенча бара, диалоглар һәм монологлар төзек, күп очракта персонажларның менәзенә туры килә. Икенче сүзләр белән әйткәндә, каһарманнарның үз холык-гадәтләре, сөйләү рәвеше, катнашучының холкы-фигыленә туры килә торган үз-үзен тотышы, үсеш сызыгы бар.

Яшь Казан бае — «кыланчык һәм надан» (автор сүзләре) Кәрим — бер генә хатын белән торырга риза түгел. Урыс баеса, чиркәү сала, татар баеса, хатын ала, диләр бит. Беренче хатыны акыллы һәм сабыр Әсма өстенә ул Мәрьямгә өйләнә. Монысының «бозыклыкта гомерен үткәргән, калебсез[1] бер хатын» икәненнән ул әле хәбәрдар түгел. «Әпитит ашаганда килә» дигәндәй... озакламый гаиләдә өченче хатын да пәйда була. Монысы — Сорур, автор әйткәнчә, «йомшак күңелле, мәҗбүрә[2] бер хатын».

Ләкин өч хатын белән юньле, ипле тормыш кору өчен, байлык кына җитми, акыл да кирәк икән. Кәрим, — әйткәнебезчә, надан. Аның күп хатынлы булырга тырышуы да азгын-

---

[1] *Калеб* — йөрәк, күңел.

[2] *Мәҗбүрә* — (хатын булырга) мәҗбүр ителгән.

лыгыннан, гайре байлар алдында кәпрәясе килүдән туган. Хатыннарының үзара тату, үзен хөрмәт итеп яшәүләре өчен, ул берни дә эшләми һәм эшли дә алмый. Нәтиҗәдә гаиләдә озак кына вакыт бозык һәм комсыз Мәрьям баш булып тора. Күбрәк аның «тырышлыгы» белән Кәрим бөлә, ярлының да ярлысы булып кала. Үзенә яратып кияүгә чыккан Әсмадан кала башка хатыннарының мәхәббәтен ул яулап ала алмый. Бары тик Әсма гына иренә ахыргача тугрылык саклый. Хәерчегә калган авыру ирен ул кулыннан килгәнчә тәрбияли. Кәрим соңарып булса да тәүбәгә килә, кылган җәбер-золымнары, борчу-сыктаулары өчен Әсма алдында гафу үтенә, үз хаталарын танып дөньядан китә. Түземлек, сабырлык, олы җанлы һәм саф булганы өчен, Әсманы тыныч-имин картлык көтә; аңа бәхет иңә, ул лотереяда үз гомеренә җитәрлек акча ота.

Бу иң беренче пьесасында ук драматург персонажларны белемле, намуслы һәм акыллы булулары ягыннан кырт икегә бүлеп куя. Ләкин «үткен, укыган, гакыллы егет» Риза, «тугры карчык» Фәхрия кебекләр дә, «тупас һәм надан шәхес» Хәсәнетдин һәм «хатыннарны сөйдерәм, өшкерәм дип алдап йөрүче бозык» асламчы[1] хатын да вакыйгаларда икенче дәрәҗәле хезмәтне генә үтиләр. Аларны үзара көрәштерү максаты куелмый. Өч хатын арасында буталган бозык Кәримнең түбәнгә төшүе дә артык тәэсирле итеп бирелә алмаган. Күбрәк Мәрьям аркасында хатыннар арасында туып торган җәнҗал-низаглар гына драматик хәрәкәтне көчәйтәләр һәм җанландыралар.

Сәнгатьчә эшләнеше ягыннан әлегә өйрәнчек әсәр генә булса да, «Өч хатын белән тормыш» пьесасында инде авторның фикер-карашлары ачык күренеп тора. Ул бозыклыкка, гаилә коруга җиңел карауга, наданлыкка кискен каршы чыга. Байлар арасында очрый торган күп хатын алу кебек гадәтне тәнкыйтьли. Моның өчен ул Әсманың энесе Риза кебек аек карашлы кеше образын кертә. Риза автор әйтергә теләгәнне сөйли.

Сәхнә әдәбиятына хас үзенчәлекләрне Г. Исхакый тиз үзләштерә. Татар драматургиясен ул яңа образлар белән баета. Иң мөһиме, язучы татар тормышының яңадан-яңа якларына мөрәҗәгать итә, үзенә генә хас фикер яңалыгы алып килә һәм шуның белән укучыны, тамашачыны уйланырга мәҗбүр

[1] *Аслам* — файда, табыш.

итә. Дөрес, жанр бөтенлеге әлегә аңар һәр очракта да бирелеп бетми. Мәсәлән, «Өч хатын белән тормыш»ны автор үзе «драма» дип билгеләгән. Ләкин бу,— асылда, мелодрамага якын әсәр. Икенче пьесасын — «Ике гыйшык»ны — драматург «комедия» дип атый. Ләкин вакыйгаларны башыннан ахырына кадәр тотып тора торган көлкеле конфликт тудыра алмаган. Үзәктә торган каһарманнардан берсе Каюм, киресенчә,— «укыган, гакыллы, тәүфыйклы, җиңелчә генә уйлы» Казан егете. Аның үги анасыннан күргән җәбер-золымнары драматизм белән тулы, һич көлкеле түгел. Дөрес, бер урында комедиячел халәт туа: егет сөйгәне Хөршидне икенче кыз урынына кабул итеп көлкегә кала. Ләкин ул калган барлык вакыйгаларны үзенә буйсындырган үзәк күренеш түгел. Кыскасы, пьеса күбрәк мелодрама төренә тартым.

Г. Исхакый пьесаларының яңалыгы иң беренче нәүбәттә, аларның эчтәлегендә, алардагы фикер тирәнлегендә. Алар кешене яратуны, миһербанлыкны, гаделлек сөюне алга куялар.

Гадәттә, әдәби әсәрләрдә, бигрәк тә драма әсәрләрендә, явызлык, яманлык җәзасын ала, хаксызлык фаш ителә. Бу алымны Г. Исхакый яратып куллана. Әмма аның карашы монда үзенчәлеклерәк. Моны түбәндәге мисалдан ачык күрәбез. «Ике гыйшык» әсәрендә тәүфыйклы Каюм үги әнисеннән күп җәбер-золым татый, әтисе тарафыннан гөнаһсызга рәнҗетелә. Ләкин ул моңар артык каршылык күрсәтми. Киресенчә, явызлык барыбер үз җәзасын алачак дип, язмышына буйсынып яши. Менә Каюм үги анасы Галимәгә турыдан-туры әйтә:

«Әтине миннән суытыр өчен эшләгәнеңезне дә белдем. Тагы ни эшләргә теләгәнеңезне дә беләм. Ләкин берсенә дә каршы килмим. Кыла аласыңызны — кылыңыз, сезнең гаебеңезне дә беләм. Әтигә дә әйтмим. Кешегә дә әйтмим. Сез, менә шулай төрлечә кыландырып, әтинең дәүләтенә баш булып калмакчы буласыз?! Дөньяда сезнең шикелле золым берлән сәгадәт эзләгән кешеләр бу вакытка кадәр рәхәткә ирешә алмаганнар иде, белмим, сез генә ирешә алырсыз микән?!»

Егетнең бу фәлсәфәсе раска чыккан итеп күрсәтелә: малае белән тәмам үпкәләшкән һәм бар мирасын яшь хатынына калдырырга карар кылган Рәхмәтулла карт кибетендә кинәт кенә егылып үлә. Галимәгә байлык эләкми кала. Ә түземле һәм итагатьле Каюм исә зур байлыкка ия була.

1905—1907 еллардагы инкыйлаби шартлар, татар тормышындагы җанлылык һәм үзгәрешләр драматургиядә дә, шул җөмләдән Г. Исхакый пьесаларында да чагылыш таба. Аларда халыкка хезмәт итү, милли һәм иҗтимагый тигезсезлекне бетерү өчен көрәш мәсьәләләре алга чыга. «Мөгаллим» (1906—1907) һәм «Мөгаллимә» (1913), «Алдым-бирдем» (1907—1908), «Тартышу» (1908) кебек әсәрләрен Г. Исхакый саф драма рухында яза. Татар җәмгыятендә яшәп килгән кимчелекләрне «Кыямәт» (1909—1910) һәм «Җәмгыять» (1910) исемле сатирик комедияләрендә үтергеч көлү белән ачып сала. Тетрәткеч фаҗигалардән торган «Зөләйха» (1907—1912) драмасында татар милләтен юкка чыгару өчен, аны диненнән яздыру, көчләп чукындыру юлында эш алып барган патша хакимияте һәм карагруһчы рус руханиларының сәясәте һәм эш-гамәлләре тасвирлана. Пьесаларның күбесе милли драматургиябез өчен яңа булган образ-характерларга ия.

Г. Исхакый пьесалары фикерләргә бай, алар күптөрле. Шулай да алар арасында аеруча ике идея, ике караш ачык итеп, кат-кат ассызыклап бирелә. Берсе — җәмгыятьтә кеше башкаларның колына әверелмәскә, берәүләр икенчеләр исәбенә яшәмәскә тиеш дигән фикер. Моны «Алдым-бирдем» драмасында ачык күрергә мөмкин. Бу әсәрдә гаилә, асылда, саф мәхәббәткә, тигезлеккә нигезләнгәндә генә бәхетле һәм тотрыклы була ала дигән караш яклана. Инде күргәнебезчә, ул «Өч хатын белән тормыш»та да шулай куела. Кибетче егет Ибраһим белән бай кызы Галия арасындагы көчле мәхәббәт гаилә коруны искечә аңлауны җиңеп үтә. Яшьләр үз бәхетләренә ирешүдә тапкырлык һәм ныклык күрсәтәләр. Шул ук вакытта автор байлар һәм ярлылар арасындагы каршылыкның нигезен дә оста гына итеп ача. Икенче төрле әйткәндә, драмада сыйнфый тигезсезлеккә каршы чыгу сызыгы да бар. Бу бигрәк тә түбәндәге сөйләшүдә ачык чагыла:

«Ибраһим. Эш күп.

Галия. Башкалар эшләмимени?

Ибраһим. Башкаларга да күп.

Галия. Алай булгач, тагы яңаларны ник яллмыйлар?

Ибраһим. Файда кими!

Галия. Файданы Алла бирә ич.

Ибраһим. Алла бирә бирүен дә, без 12—13 әр сәгать эшләгәнгә бирә шул ул.

С а д ы й к (*көлеп, Галиягә*). Әле син шул байлыкларны үзеннән-үзе генә килгән дип беләидеңмени? Менә Ибраһимның 2 сәгать артык эшләвеннән калфагың булган; Андрейның 2 сәгать артык эшләвеннән читегең булган, бүтәннәре тагы шулай!

Г а л и я. Минем бөтен нәрсәм кеше хакымыни? Алар жалуния алмыйлармыни?

И б р а һ и м. Алсалар да, эшләре кадәр алмыйлар шул. Менә мин 12 сәгать эшлим икән, 6 сәгатьлек генәсен алам, 6 сәгатьлеге хуҗаларга кала. Бүтәннәре дә шулай.

С а д ы й к (*көлеп*). Шуларга бирелмәгән жалуниядән сиңа этиеңнәр калфаклар эшләтәләр, җиһазлар ясыйлар. Шакировлар аксак хатыннарыны кайсысын анда, кайсысын монда илтеп даруландыралар. Кырымга баралар, Кавказга баралар. Шуларның эш хакларыннан зәкят[1] бирәләр. Бәдәл[2] хаҗга җибәрәләр. Шуңардан кунак сыйлыйлар. Шуңардан үзләре ашыйлар.

Г а л и я. Мин шул Андрейлар, Ибраһим абзыйлар, Сәләх бабайлар, Василийларның жалуниясенә киенеп тораммыни?

С а д ы й к. Аларныкы гына түгел, каравылчы Сабит, көтүче Хәйриләрнең дә жалуниясенә киенәсең.

Г а л и я. Син көләсең, Садыйк абзый. Мин... Ибраһим абзый, дөресе шулаймы?

И б р а һ и м. Шулай.

Г а л и я. Алла бирмимени?

И б р а һ и м. Алла эшчеләрдән башка үзе генә бирми!

Г а л и я. Менә хәзер әле сез, Ибраһим абзый, безгә кунакка килдегез, сез безнең ашны ашамадыгыз, алай булса, без сезнең ашны ашадык.

И б р а һ и м. Ийе! Байлар һәрвакыт эшче ашын ашый, эшче акчасын тота, эшче байлыгына хатыннарын киендерә.

Г а л и я. Алай булгач, сез ник ул үзегезнең эш бәһагезне алып бетерергә тырышмыйсыз, менә бу газета әйткәнчә, тар тышмыйсыз?»

Күрәбез, мондагы сүзләрдән бер нәтиҗә килеп чыга: көрәшергә кирәк. Алга таба көрәш темасына Г. Исхакый махсус пьесасын багышлый һәм аны «Тартышу» дип атый. Тарты-

---

[1] *Зәкят* — шәригать буенча еллык табыш исәбеннән ярлыларга бирелергә тиешле хәер-сәдакасы (керемнең кырыктан бер өлеше күләмендә).

[2] *Бәдәл* — кеше өчен ялланып, хаҗ кылырга бару.

шу — көрәш мәгънәсендә. Драма җәмгыятьнең төрле катлауларыннан чыккан яшьләрнең сыйнфый көрәшкә кереп китүләре, эшчеләр партиясендә хезмәт итүләре, ягъни инкыйлаби эш алып барулары турында. Партия төрле һөнәр, төрле гаилә кешеләрен үзара берләштергән. Монда бай малае Закир да, укучы егет Насыйр да, ишан улы Сабир да, мужик баласы Галим дә, язучы Шәйхи дә, типография эшчесе Габдулла да, укымышлы кыз Шакирә дә бар. Яшьләрнең сыйнфый көрәшкә гомерләрен багышлауларын күрсәтү ягыннан бу пьеса Г. Коләхмәтовның «Яшь гомер» драмасына охшаш.

Г. Исхакый пьесасының гомуми рухын, әсәрнең алгы өлешендә бирелгән инкыйлаби җыр тексты билгели:

Кирәкми, ташлыйбыз иске юлны,
Кирәкми, яңа юл башлыйбыз.
Яңа юл — яхшы юл, бер җәберсез,

Тигез, рәхәт тора башлыйбыз.
Торыгыз, күтәрелегез, эшче кешеләр,
Каршы тор дошманга, ач кешеләр!
Яңгыра дөньяга үч авазы,
Алга, алга, алга, алга, алга!

Олуг әдип иҗатының баштагы чорында сыйнфый көрәшне әдәбиятның төп вазифаларыннан берсе дип караса да, тормыш барышы аның бу карашына «төзәтмә» кертә. Язучы милли азатлыкны сыйнфый көрәш белән генә хәл итеп булмаганлыгын тормышта үзе күрә. Шунлыктан Г. Исхакыйның драма иҗатындагы көчле яктыртылган икенче теманы «милләт язмышы, милләтне алга җибәрү өчен, ниләр эшләргә кирәк» дип билгеләп булыр иде. Ягъни шул фикерләр аларда өстенлек ала. Бу әсәрләрендә дә автор татар драматургиясе өчен яңа образлар тудыра. Алар иҗтимагый эчтәлекләре бай һәм мөһим булулары белән аерылып торалар.

«Мөгаллим» һәм «Мөгаллимә» драмаларында, исемнәреннән үк күренгәнчә, үзәккә укытучылар образлары куелган. Мөгаллимә Фатыйма халыкка, милләтенә хезмәт итү юлында үзенең шәхси бәхетен — мәхәббәтен корбан кыла («Мөгаллимә»). Ә Салих исә, тормыш һәм хезмәт юлын халыкка файда китерү уе белән башласа да, иске тормыш баткагына чума бара («Мөгаллим»). Ул надан хатыны һәм кара фикерле каенанасы йогынтысында тормыш идеалларыннан читләшә. Изге бурыч белән тар гаилә мәнфәгатьләре арасында буталып

калган Салих ахырдан үзенең хаталануын аңлый, «хуш, мине, минем кебекләрне эштән чыгарган бәдбәхет иске тормыш!» дип, «тормышның мәгънәсен эзләргә» китә.

Г. Исхакый иҗатында һәм, гомумән, татар әдәбиятында «Зөләйха» драмасы үзенә аерым бер урын тота. Монда татар халкының фаҗигале чорлары сурәтләнә. Дини һәм милли гаделсезлек, мыскыл ителү, кол хәленә төшерелү хәлләренә бай булган пьеса рухы белән, үзәк каһарманның аяныч язмышы белән трагедиягә тиң. Шуңа күрә аны еш кына «трагедия» дип тә атыйлар.

Г. Исхакый үз пьесаларында, нигездә, традицион алымнар белән эш йөртә. Аның драма һәм комедияләрендә арттыру да, беркадәр шартлылык галәмәтләре дә бар. Шулай да аларның язылу рәвеше тормышны үз төсендә сурәтләүгә, ягъни тормышны үз шәкелендә күрсәтүгә корылган. Бу яктан «Зөләйха» драмасы аерылып тора. Монда шартлылык инде шактый көчле, фантазиягә иркенлек бирелгән, романтик күтәренкелек бар. Бу сыйфатлары белән дә драма татар сәхнә әдәбиятына зур яңалык алып килде.

Яңа белән иске көрәше

Татар тормышындагы иске белән яңа арасындагы көрәшне сурәтләгәндә, Г. Исхакый төп игътибарын искене фаш итүгә һәм кире кагуга юнәлтте. Ул күпхатынлылыкны гаепләде («Өч хатын белән тормыш»), иске гадәт-йолалар колы булганда, кешенең нинди аяныч хәлләргә төшүен күрсәтте («Ике гыйшык», «Мөгаллим»). Иҗтимагый гаделсезлекне тәнкыйтьләде («Алдым-бирдем», «Тартышу»). Дини гадәт-тәртипләрне дөрес аңлап эш итмәгәндә, нинди хурлыклы нәтиҗәләр барлыкка килү ихтималын кисәтте («Кыямәт»).

Гасыр башындагы татар драматургиясендә бу тенденция, гомумән, көчле чагыла. Искелекне фаш итү темасына Г. Камал «Беренче театр» һәм «Бүләк өчен», С. Рәмиев «Низамлы мәдрәсә», Идрис Багданов «Помада мәсьәләсе», Фатих Сәйфи-Казанлы «Ямьсез тормыш», М. Фәйзи «Яшьләр алдатмыйлар», К. Тинчурин «Беренче чәчәкләр» исемле драма һәм комедияләрен багышлыйлар. Шуның белән бергә, бу пьесаларда искелеккә каршы булу, аны инкяр итү төсендә яңаның акрынлап керә баруы да күрсәтелә. Ә аерым драматурглар бу темага, ягъни яңаның үсешенә, махсус әсәрләрен багышладылар.

Фатих Әмирхан «Яшьләр» драмасында (1909) яңалыкның һөҗүмен конкрет образлар рәвешендә гәүдәләндерә. Пьесаның өстәмә исеме дә бар: «Татар тормышының алмашыну көннәрендә». Бу алмашыну көннәрен яшьләр булдырырга тырышалар. Болар — мәдрәсәдә укып чыккач, русча укый башлаган Газиз, аның шулай ук русча укучы энесе Йосыф, студент Ибраһим, институт тәмамлаган Фатыйма, укытучылар мәктәбендә укыган Әхмәт, укытучы Зәкәрия, кибетче Якуб, журналист Зыя, мәхдүм Гали кебек яшь буын вәкилләре. Дөрес, бу алмашынуның мәгънәсен һәм максатын аларның барысы да бертөсле генә аңламый. Социалистлар фикерен хуплаучы Әхмәтнең көрәш программасы бертөрле булса, «милләтче» исемен йөртүче Зыя бүтән караштa тора. Гали исә максатын өченче төрле күзаллый: берүзебез шулкадәр дошман күргән ул иске тормышка каршы бөтен көчебез белән сугыш ачабыз, ди ул, без, бәлки, татар өчен бернәрсә дә ясый алмабыз. Ләкин киләчәктә эшлисе кешеләр өчен җирлек әзерләрбез. Үзләренең бу көнгә бурычларын, шулай итеп, ул искене җимерү-ватуда күрә. Шуның белән яшьләр үзләрен яңалык көчләре итеп таныталар.

Г. Коләхмәтов «Ике фикер» һәм «Яшь гомер», Г. Исхакый «Тартышу» драмаларында искелеккә каршы чыккан яңа рухлы кешеләрне тагын да конкретрак, сәнгатьчә камилрәк һәм тормышчанрак итеп тасвирладылар. Ф. Әмирхан «Тигезсезләр» драмасында (1915) мондый каһарманнарны шулай ук үзәккә куя. Драманың төп исеме астына җәяләр эченә «Яңа кешеләр» дигән икенче исем куелган. Алда — «Яшьләр» драмасына бирелгән «татар тормышының алмашыну көннәрендә» дигән икенче исемдә — авторның әсәрдәге төп эчтәлекне шул рәвешле атаганын күргән идек. Монда да шулай. Яңа кешеләр — кемнәр алар? Аларның яңалыклары нәрсәдә? Драма шул сорауларга җавап бирә.

Пьесаның баш каһарманнары булган Рокыя һәм Сөләйман кебекләрнең рухи азатлыкка омтылулары, һәртөрле гадәт-йолаларның искеләрен җиңеп үтәргә тырышулары яңалыкның һөҗүмчән сыйфатын тәшкил итә. Гомәр кебек яңача тәрбияле татар сәүдәгәрләренең эшчәнлеге дә уңай яктан билгеләп үтелә.

Татар әдәбияты яңалыкка омтылуны һәрчак яклады, милләтнең үсешен алга сөрде. Рус тормышының уңай якларыннан үрнәк алуны, аерым алганда рус телен яхшы белүне, еш

кына тәрәккыятьнең бер шарты итеп карады. «Яшьләр»дәге каһарманнар шул яктан үзенчәлекле. Ләкин башка милләтләр белән аралашу, алардан үрнәк алу үз милләтеңне түбәнсетү исәбенә бармаска тиеш икәнен дә язучылар ачык аңлый башладылар. Моны Ф. Әмирхан икенче драмасында аеруча көчле сурәтли. Ул тасвирлаганча, үзе татар була торып та, татар милләтенең һәммә ягын хурлаучы, рус мәдәниятен генә яхшы санаучы кешеләр торган саен күбәя бара. Шундыйлардан берсе — Габдулла атлы егет — пьесада тәнкыйть ителә. Мондый кешеләрне автор үзәк герое авызыннан «Иванушка[1] — Абдулка» дип атый. «Фонвизинның Иванушкасы да бервакыт рус мәдәнияте, рус милләте тугрысында шундый түбән фикердә булган бит,— ди Сөләйман.— Аңар карап, рус мәдәнияте үсүдән, рус милләте ныгудан туктаганмыни? Без хәзер рус милләте шул вакытларда уздырган хәлне уздырамыз».

Шулай итеп, драматурглар иске белән яңа арасында кискен көрәш алып барган кеше образына зур әһәмият бирделәр. Шәхес бу көрәш кисешкән урында үзәк итеп каралды. Алар, хәлиткеч көрәштә шәхес беренче чиратта үзе ирекле булырга тиеш, дип санадылар.

Романтик драма һәм мелодрама остасы

Яңалыкны яклауда, татар драматургиясен яңа образлар һәм алымнар белән баетуда **Мирхәйдәр Фәйзи** зур уңышларга ирешә.

М. Фәйзи драматургиягә юлын русчадан файдаланып язылган «Ике Хәсән» исемле пьесасы белән башлый. «Яшьләр алдатмыйлар» (1911) — аның беренче сәхнә әсәрләре арасында сәнгатьчә эшләнеше ягыннан иң уңышлысы. Азгын булганы өчен, муллага сабак бирү вакыйгасы кызыклы итеп, җыйнак, көлкеле хәлләр ярдәмендә күрсәтелә.

«Кызганыч» дигән романтик драмасын (1913) автор мөһим мәсьәләгә багышлый. Ул — шул елларда җәмәгатьчелекнең игътибарын нык биләгән мәүзугъ[2] — халыкка хезмәт итү мәсьәләсе. Ул көчле мәхәббәт тарихын сурәтләү ярдәмендә ачыла. Мөгаллимә Гәүһәр белән укымышлы Заһид бер-берсен яраталар. Әмма аларның кушылуына Заһидның атасы Сөләй-

[1] *Иванушка* — Д. И. Фонвизинның «Недоросль» исемле мәшһүр комедиясендәге сатирик персонаж исеме.

[2] *Мәүзугъ* — тема, сюжет.

ман бай каршы төшә. Ул, улын бай кызына өйләндереп, байлыгын тагын да арттыру уе белән яна. Яшьләр ике ут арасында калалар. Аларның максаты — Сөләйманның теләгенә каршы килеп булса да өйләнешеп бәхетле булу, ягъни шәхси бәхеткә ирешү. Бу очракта Гәүһәргә балалар укыту, халыкны аң-белемле итү кебек изге хезмәттән аерылырга туры киләчәк. Чөнки Гәүһәр Сөләйман бай салдырган һәм аның карамагындагы мәктәптә эшли. Заһидка да, зур байлыкка хуҗа була калса, аны милләт файдасына тоту, ятимнәр турында кайгырту, яңа мәктәп-мәдрәсәләр ачу кебек матур теләкләреннән баш тартырга туры киләчәк. Яки олы мәхәббәтне корбан кылырга, Сөләйманның дәгъваларын канәгатьләндерергә кирәк.

Бер-берсенең бәхете мөһим булса да, барыннан да бигрәк, халыкка хезмәт итүне өстен санаган яшьләр нишлиләр соң? «Малдан да, мөгаллимәлектән дә кул селтәгәндә, без икәү кушылып мәсгуд (бәхетле) булачак идек,— ди Гәүһәр. — Бу мәсгудият бары икебезгә генә махсус булачак иде... Әмма без халык өчен үз бәхетебезне корбан итәбез».

Заһид атасының мирасына ия булсын һәм файдалы эшкә тота алсын өчен, Гәүһәр үзенә үзе кул сала. Заһид байлыкка хуҗа була. Ләкин сөйгәненең үлемен белгәч, байлыгын милләт файдасына тапшырып, үзе дә атылып үлә.

Классицизм әдәбиятында, аерым алганда француз әдәбиятында, көчле сурәтләнеп киленгән мондый хәл-әхвәлне драматург, шулай итеп, татар җирлегенә күчерә, аны романтик драма рухында хәл итә. Бу күренеш шәхси теләкләр белән иҗтимагый мәнфәгатьләр бәрелеше җирлегендә туа. Шулай дип әйтергә тагын бер сәбәп бар: чөнки М. Фәйзи бу чорда француз әдәбиятының көчле йогынтысы астында булган төрек әдәбиятын яхшы өйрәнә.

Сез, укучылар, татар әдәбиятының йөзек кашы булган «Галиябану» драмасын 8 нче сыйныфта өйрәндегез инде. Аның милли драматургия тарихында тоткан урынын, беренче музыкаль драма булуын беләсез. Фаҗигале мәхәббәт язмышын сурәтләү ярдәмендә иске гадәт-йолаларны һәм карашларны кире кагуның көчен күрдегез. Миһербанлыкка, гаделлеккә каршы булганда, акчага табыну нинди аяныч хәлләр тудырырга сәләтле икәнен аңладыгыз. Драматургиянең сәнгатьле детальләр куллануда, психологик кичерешләрне, кеше холык-фигыленең көчле һәм көчсез якларын сурәтләүдә ничек оста эш йөртүен өйрәндегез.

Югарыда әйтелгәннәр яктылыгында караганда да, «Галиябану» кешенең рухи хөрлеген яклый, аның гүзәл хискә — мәхәббәткә хакы барлыгын ачык итеп куя. Хәтта байлык һәм акча кебек зур көчләр дә бу хискә баш була алмый дигән фикер уздырыла.

«Галиябану» драмасы белән беренче мәртәбә татар крестьяннары образы сәхнәгә күтәрелә. Алар рухлары, кыяфәтләре, кылган эш-гамәлләре белән дә гүзәл, саф, кешелекле.

Хезмәт кешесен шундый яссылыкта тасвирлавын М. Фәйзи алга таба да дәвам иттерә. «Авыл бәйрәме», «Урал суы буенда», «Асылъяр», «Кызыл йолдыз» мелодрамаларында да, «Ак калфак» исемле романтик драмада да үзәк каһарманнар итеп крестьян яшьләре алына. Бу образларны автор билгеле бер дәрәҗәдә матурлап, югары күтәреп тасвирлый, ягъни аларны романтик билгеләр һәм сыйфатлар белән бизи. Рухлары саф һәм чиста булулары, кешелекле, миһербанлы, гадел һәм итагатьле булулары өстенә бу каһарманнар сәләтлеләр, бигрәк тә музыкага, моңга һәвәсләр.

«Ак калфак» романтик драмасы (1924) — бу яктан да, сәнгатьчә эшләнеше җәһәтеннән дә М. Фәйзинең иң уңышлы һәм кызыклы әсәрләреннән берсе.

Аның эчтәлеге артык катлаулы түгел. Аксөяк мирзаның иркә һәм чибәр кызы Хәмдия үз исеменә җыр чыгарылуын тели. Вәгъдәсе: җыр чыгаручы кем генә булса да, ничә яшьтә булса да, ул аңар кияүгә чыгачак. Шулай дип сүз биргәч, кыз җырны күзе төшкән Шаһтимер исемле мирза улы чыгарыр дип ышана. Ләкин җырны көтүче Бакый чыгара. Аксөяк кыз көтүчене түбән катлау дип санап өйрәнгән, шул аның канына сеңгән. Шунлыктан гади көтүче авызыннан үзенә багышланган әлеге гүзәл җырны ишеткәч, башта аңа искиткеч сәер тоела, ул хәтта һушыннан яза. Бакыйдан көнләшеп йөргән Шаһтимер шул арада, арттан килеп, егетне чәнчеп үтерә, һушына килгәч, кыз Бакыйның үлгәнен күрә, акылыннан язар хәлгә килә. Ул инде көтүченең мәхәббәтен кабул итәргә әзер, әтисеннән дә, аксөяклектән дә баш тарта, Шаһтимергә ләгънәт укый.

Күрәбез, вакыйгалар монда да мәхәббәткә бәйле өчпочмакка корылган. Бу традицион өчпочмак бик оригиналь сюжет корырга, гади хезмәт кешесен югары күтәреп сурәтләргә, тамашачы күңеленә көчле тәэсир итәрлек мөнәсәбәтләр тудырырга ярдәм иткән. «Галиябану»дагы кебек, «Ак калфак»та

да мәхәббәт язмышы аянычлы, фаҗигале булып бетә. Монда да җырны, көчле сөю хисе белән рухланып, хезмәт кешесе вәкиле иҗат итә. Ләкин инде әлеге әсәрдә сыйнфый тигезсезлек мәхәббәт ярдәмендә тагын да кискенрәк кире кагыла. Хәмдиянең үз сыйныфыннан баш тартуы тигезсезлекне инкяр итүнең иң югары ноктасы булып тора. Төп фикерләр түбәндәгеләр: кешенең сыйнфый чыгышы аның шәхес буларак дәрәҗәсен, кыйммәтен билгеләми; гади хезмәт кешесенең хисләре аксөякләрнең нәзберек хисләреннән өстен торуы мөмкин; табигатькә якынрак торган кешенең хисләре көчлерәк тә, сафрак та. «Хәмдия» җыры белән көчәйтелгән романтик рух мәхәббәтне югары күтәрергә, матурларга, үз сыйныфы кануннарына каршы чыгарлык ныклыкка ия булган мирза кызының романтик образын тудырырга ярдәм иткән.

«Асылъяр», «Ак калфак», «Кызыл йолдыз» пьесалары белән М. Фәйзи Октябрь борылышыннан соң җәмгыятьтә туган үзгәрешләр рухын чагылдыра. Сыйнфый тигезсезлекнең кеше шәхесен кимсетеп газапка юлыктыруын, шәхес ирегенә ирешү юлындагы көрәш авырлыкларын сурәтли. Кешенең олылыгын билгеләүче төп сыйфат сыйнфый чыгыш түгел, ә гаделлек, хезмәт сөю, миһербанлык кешене кеше итә дигән фикер уздыра.

Алмашка кемнәр килә?

XX гасырның унынчы елларында татар драматургиясенә бер төркем яшь көчләр килде. Г. Камал, Г. Исхакый, Ф. Халиди, Г. Коләхмәтов, Я. Вәли, И. Багданов һ. б. драматурглар исемлеге тагын да артты.

Фатих Сәйфи-Казанлы — татар әдәбиятына күп кенә проза әсәрләре, тәнкыйть мәкаләләре биргән язучы. Шулай да аның драматургиягә керткән өлеше күбрәк һәм җитдирәк. Бу каләм әһеленең беренче иҗат чорында язылган «Ямьсез тормыш» драмасы (1915) сәнгатьчә эшләнеше ягыннан аерылып тора. Автор монда татар әдәбиятында күптәннән килгән, драматургия өчен дә традицион булган теманы күтәрә. Бу — хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсе. Автор яратып сурәтләгән каһарманнар хатын-кызның табигый хәлен — ирләр белән тигез хокукын булдыру өчен иске тормышка каршы көрәш алып баралар. «Азатлыкны ярату адәмнәрнең табигый сыйфаты бит, азатлык кемгә дә сөйкемле!» — персонаж авызын-

нан әйттерелгән бу сүзләр драманың да төп фикере булып тора.

Бу чорда милли драматургиябезнең күренекле вәкиле **Кәрим Тинчурин** иҗаты башланып китте. Татар тормышының кара якларын, яшьләрнең белемгә, яңалыкка омтылуларын сурәтләп, ул бер-бер артлы «Беренче чәчәкләр», «Җилкуарлар», «Соңгы сәлам» кебек драмаларын һәм «Назлы кияү» исемле комедиясен яза. К. Тинчурин алга таба үзен бигрәк тә комедия остасы итеп танытты. Аның бу үзенчәлеге беренче комедиясендә үк чагыла. «Назлы кияү» (1916) — татар драматургиясендәге иң көлкеле әсәрләрнең берсе. Укыган, мәгърифәтле кыз алырга дип, Казанга еректан килгән байбәтчә[1] Рәшит теләгенә ирешә алмый, тәмам бөлеп кайтып китә. Монда аның үзенең җебегәнлеге-пешмәгәнлеге дә, туганнарының томаналыгы да, барыннан да бигрәк, Казан тормышында чәчәк аткан алдакчылык, бозыклык, намуссызлык, комсызлык сәбәпче.

Фәтхи Бурнаш әдәбиятка һәм театр сәнгатенә 1914 елны язылган «Язмыш» драмасы белән килеп керә. Ул Габдулла Кариев тарафыннан сәхнәгә куела. Аннан соңгы ике елда «Сукбай» драмасы, «Саташкан кыз» романтик драмасы языла. Боларда шәхес язмышы мәсьәләсе үзәктә тора. Заманның өлгергән сораулары: хатын-кыз азатлыгы, мәгърифәт кирәклеге, Беренче бөтендөнья сугышына каршы булу һәм башка шуның кебек мәсьәләләр бу пьесаларны актуаль итә. Димәк, яшь драматург халык тормышы белән нык кызыксынып яшәгән һәм иҗат иткән.

Бу драматурглар — татар сәхнәсен яңадан-яңа әсәрләр белән аеруча баеткан каләм әһелләре. Дөрес, аларның иҗаты туры сызык буенча гына үсмәде. Совет чорында иҗат эшчәнлеге дөрес эстетик принципларга гына нигезләнә алмады. Шулай да, гомумән алганда, бу шәхесләр татар драматургиясен бик нык үстергән, аның сәнгатьчә казанышларын баеткан авторлар булдылар.

Бу елларда драматургия тагын Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» дип аталган сатирик комедиясе, Г. Кариевның «Артист» исемле водевиле, Фазыл Туйкинның «Ватан каһарманнары», Гали Хәйдәрнең «Сөембикә» исемле тарихи драмалары һәм башка пьесалар белән байый.

---

[1] *Байбәтчә* — бай кешенең буйга җиткән улы.

XX йөз башындагы татар драматургиясе турында йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: сүз сәнгатенең зур бер тармагы буларак, ул тәмам формалашып җитте. Психологик драма, сатирик комедия, мелодрама төрләрендә яңа уңышларга ирешелде. Тарихи драма, социаль-психологик драма, романтик драма, музыкаль драма кебек, водевиль, трагикомедия төрләре туды. Татар милли драматургиясе, театр сәнгате төрки халыклар гаиләсендә алдынгыларның берсе булып танылды.

Сораулар һәм биремнәр

1. XX йөз башында актив иҗат иткән драматургларны атагыз.

2. Бу еллар драматургиясендә нинди үзгәрешләр күрәсез? Жанр төрләрендә һәм формаларында, образлар системасында, кешенең дөньядагы ролен аңлауда нинди яңалыклар бар?

3. Бу чордагы драмаларда сурәтләнгән каһарманнар акчага табыну мәсьәләсендә нинди мөнәсәбәттә торалар? Социаль тигезсезлеккә ничек карыйлар? Халык мәнфәгатьләре белән шәхси ихтыяҗлар бәрелешендә геройлар кайсы якны сайлыйлар?

4. Г. Исхакыйның драма һәм комедияләрен хронологик тәртиптә дәфтәрегезгә язып куегыз. Аларда күтәрелгән мәсьәләләрне санап чыгыгыз.

5. Г. Исхакый сурәтләгән драматик характерларның төп сыйфатлары итеп нәрсәләрне күрсәтергә була?

6. «Зөләйха» һәм «Тигезсезләр» драмаларында милләт язмышы мәсьәләләренең куелышын һәм чишелешен сөйләп бирегез.

7. М. Фәйзи иҗатында мәхәббәт язмышы ничек сурәтләнә? «Кызганыч», «Галиябану», «Ак калфак» әсәрләре мисалында аңлатыгыз.

8. 1910 елларда драматургиягә килгән яшь көчләрне атагыз, аларның төп әсәрләрен әйтегез. Алда бу авторлар язган тагын нинди пьесаларны беләсез?

9. «XX йөз башы драматургиясенең үзенчәлекле яклары» дигән темага доклад әзерләгез.

Галиәсгар Камал
(1879—1933)

Татар язучылары арасында күпьяклы талантлар бар. Бу җәһәттән Галиәсгар Камал бигрәк тә аерылып тора. Ул — драма әсәрләре, хикәя һәм шигырьләр авторы да, журналист һәм тәрҗемәче дә, театр эшлеклесе һәм рәссам да. Аңа 1926 елда, татар профессиональ театрының егерме еллыгында, рәсми төстә «Татар халык драматургы» исеме бирелә, һәм ул «татар драма әдәбиятының зур хезмәтчесе, атасы һәм татар артистларының якын ярдәмчесе» дип бәяләнә. Бүген татар сәхнә сәнгатенең әйдәп баручысы булган Татар дәүләт академия театры Галиәсгар Камал исемен йөртә.

Әдәби иҗатка килүе

Галиәсгар Галиәкбәр улы Камалетдинов 1879 елның 6 гыйнварында Казан шәһәрендә һөнәрче-мехчы гаиләсендә дөньяга килә. Татарга элек-электән хас булган күркәм сыйфат — белемгә омтылу — Галиәкбәр агай өчен дә ят булмаган. Тормыш итүе шактый авыр булса да, ул балаларын укыткан. Галиәсгар Камал соңыннан үзенең 1900 елга кадәр башта «Госмания» һәм «Халидия», аннан «Мөхәммәдия»[1] мәдрәсәләрендә һәм аның янындагы русчага өйрәнү сыйныфында укуы турында яза. Уку өчен ул, яз һәм җәй көннәрендә ялланып, Әстерхан, Мәкәрҗә (Түбән Новгород) һәм Буа ярмин-

[1] *«Госмания», «Халидия», «Мөхәммәдия»* — Казандагы күренекле мәдрәсәләр.

кәләрендә акча эшли. 1900 елда «Мөхәммәдия»не уңышлы тәмамлый.

Әдәбият һәм театр сәнгате белән Галиәсгар бик иртә кызыксына башлый. Олыгая төшкәч, ул болай дип искә ала:

«Минем язучылык, үземчә, кызык кына башланды.

...базарда ел саен Рождество, Масленица, Пасха бәйрәмнәре вакытларында, балаганнар корып, театр уйныйлар иде. Мин кызыгып карап тора торган театр «Курчак кәмите» иде. Анда кәмитнең бер почмагындагы тишектән карап торырга куркыныч та, күңелле дә: бик озын борынлы бер курчак чыга иде дә әллә нинди икенче бер «кыз» курчак белән бии, аның артыннан бер төрек чыга да аны кыйнап үтерә, аның артыннан яшел кәләпүшле татар чыга да аны да кыйнап үтерә иде. Бу эшкә, ни өчендер, минем бик ачу килә, соңыннан бутишник чыгып, ямьсез озын борынлы курчакны акыртып-бакыртып часка[1] алып киткәч кенә бераз кәеф килә иде. Шулай да никадәр ачу килсә дә, көн саен ул курчакны барып карамый калмый идем. Соңыннан (...) иптәш малайлар белән ул «озынборын»нан ачуны аладыр идек. Каткан бәрәңгеләрдән юнып — курчаклар, өйгән карларны казып «кәмит» ясап, «озынборын»ны туйганчы кыйната идек».

Болары булачак язучыны сәхнә сәнгате белән тәүге тапкыр таныштырсалар, мәдрәсәдә укыла торган дини һәм дөньяви әсәрләр, «Рисаләи Газизә», Каюм Насыйри китаплары әдәбиятны кабул итә һәм аңлый белүенә ярдәм итәләр. Ул бигрәк тә пьесаларны яратып укый. «Ильясов китабын[2] ничә кат укыганымны белмим, әмма «Рәдде бичара кыз»ны 40—50 тапкыр укыганмындыр»,— дип искә ала ул. Татарча, төрекчә һәм рус телендә басылган сәхнә әсәрләрен күп уку аның үзен дә пьеса язып карарга дәртләндерә: 1898 елда «Бәхетсез егет» исемле беренче әсәрен язып бастыра. Озак та үтми, төрекчәсеннән файдаланып, «Кызганыч бала» драмасы, аннары «Өч бәдбәхет» пьесасы языла. Болардан яшь егетнең күңеле үсә, иҗатка дәрте арта. Әти-әнисе һәм туганнары мулла булырга үгетләүләренә дә карамастан, Галиәсгар Камал милләткә хезмәт итүнең башка юлын сайлый.

---

[1] *Час* — часть (полиция бүлекчәсе).

[2] Габдрахман Ильясиның «Бичара кыз» драмасы.

Милләтне кайгыртып

Г. Камаллар буыны үсеп җиткәндә әле, татар телендә әдәбият чагыштырмача аз басыла, әсәрләр, гадәттә, кулдан язып таратылалар. Ә китапка ихтыяҗ зур. Башка халыклар арасында белемлелеге белән аерылып торган татарлар һәр яңа китапны, һәр яңа әсәрне көтеп ала. Һәм менә шул ихтыяҗны тоеп, Г. Камал китап бастырып тарату эшенә керешә. Аның «Мәгариф көтебханәсе» исемле китап кибетендә матур әдәбият әсәрләре дә, табигать һәм иҗтимагый фәннәргә караган хезмәтләр дә табып була. Яшь эшмәкәр мәдрәсә шәкертләре арасында «Дөнья күренеше» («Манзаратель-галәм»), «Телескоп» исемле кулъязма газеталар күбәйтеп тарата.

1905 елдан башлап Г. Камал ныклап торып журналистлык эшенә бирелә. Башта «Казан мөхбире» исемле газетада эшли, аннары «Азат» исемле газетага күчә, аның чын җитәкчесенә әверелә. Ул ябылгач, үзе «Азат халык» дигән исем астында газета чыгара башлый. Ләкин бу соңгысы да озак чыкмый: милли һәм социалистик эчтәлекле мәкаләләр, иҗтимагый тәртипләргә каршы рухтагы башка материалларны күпләп бастырганы өчен, 15 саныннан соң туктатыла. Г. Камал хөкемгә тартыла, аның мөхәррирлек хокукы алына.

Югарыда аталган басмаларда, шулай ук «Йолдыз» газетасында эшләгәндә, Г. Камал татар тормышының төрле якларын яктырткан мәкаләләр язып бастыра. Аның журналистлык осталыгы бигрәк тә Г. Тукай белән бергәләп чыгарган «Яшен» исемле сатирик журналда күренә. Мондагы материалларның күпчелеге бу ике язучы каләме белән язылган. Шулай ук журналдагы рәсемнәрнең дә күп өлешен Г. Камал үзе ясаган. Шулай итеп, «Яшен»дәге, ул ябылгач эшләгән «Ялт-йолт» журналындагы рәсемнәре белән Г. Камал үзен оста карикатурачы итеп тә таныта. Шунысын да аерып күрсәтергә кирәк: Г. Камал эшләгән барлык басмалар, бигрәк тә «Азат» һәм «Азат халык» газеталары, «Яшен» журналы гади халык тормышына, милләт язмышына аерата игътибарлы. Алар көн үзәгендәге мәсьәләләрне чагылдырырга омтылалар.

Г. Камал иҗатының күптармаклы булуы тагын бер яңа өлкәдә — театр сәнгатендә тулы ачыла. Г. Исхакый, Г. Коләхмәтов кебек алдынгы карашлы яшьләр белән бергә ул да татарның профессиональ театрын оештыру уе белән янып

йөри. 1905—1907 елгы инкыйлаби шартларда бу хыялны чынга ашыру өчен мөмкинлекләр туа. Дөрес, ул эш җиңел бирелми. Бер яктан, татарның күзе ачылуга һәрвакыт каршы булган рус карагруһчылары, икенче яктан, татар җәмәгатьчелегенең үз эчендә яшәп килгән кара көчләр белән ныклап көрәшергә кирәк була. Бу көрәш кыза, көчәя һәм ахыр чиктә җиңү белән тәмамлана. XIX гасыр ахырында ук мәдрәсәләрдә, аерым фатирларда, аулак өйләрдә күренә башлаган театр хәрәкәте якты дөньяга чыга: 1906 елның 21 апрелендә Уфада һәм шул ук елның 5 маенда, аннары 22 декабрендә Казанда рәсми төстә спектакльләр уйнала.

Драматургия остасы

Г. Камал бу хәрәкәтнең үзәгендә кайный. Иң беренче, үзенең пьесалары белән. Вакыт-вакыт артист һәм режиссёр буларак та, спектакльләрне бизәүче, ягъни сәхнәне җиһазлаучы булып та. Шулай да театр сәнгатендә аның роле иң әүвәл драматург буларак бәяләнә. Г. Камал пьесаларының әһәмиятен билгеләп, Г. Тукай аны «татарның Островские» дип атый.

Г. Камал пьесаларында үз заманының мөһим мәсьәләләре алдынгы кешеләрне борчыган уй-сораулар чагылышын таба.

Ул беренче пьесаларын язганда, татар драматургиясе әле баш калкытып кына килә. Габдрахман Ильяси, Фатих Халиди, Гаяз Исхакый язган сәхнә әсәрләре эчтәлекләре белән татар әдәбиятында элек-электән килгән темаларны дәвам иттерәләр. Болар — бала тәрбиясе, ата-ана һәм балалар мөгамәләсе, аң-белемле һәм намуслы-итагатьле булу, кешегә ихтирамлы караш һәм миһербанлы мөнәсәбәт һ. б. Шулай ук бу авторлар жанр үзенчәлекләрен үзләштерүгә дә күп көч куялар. Пьесаның нигезенә салынган вакыйгаларны һәм эчтәлекне кискен итүдә, характерларны тулы сурәтләүдә аларның әһәмияте зур.

Г. Камал да беренче пьесалары белән шул рухны дәвам иттерә. Аның 1898 елда язылып, 1900 елда басылган «Бәхетсез егет» драмасында үзәккә тәрбия һәм әхлак төзәтү мәсьәләләре куела. Кәрим бай белән Җәмиләнең бердәнбер уллары Закир юлдан яза: хәмер эчә, ничәшәр көн өенә кайтмый, ахырда, Гайни исемле азгын кызга ияреп, Уфага китеп бара. Моны ул үзе кызны яратуы, аңар өйләнергә теләве белән аңлата,

лəкин Гайни аны алдый, акчасы беткəнен белгəч, яныннан куа. Закир җинаять юлына баса: əтисенең танышы Сəгыйть Сабитов өен басып чыга, Гайнинең хыянəтен белгəч, кызны атып үтерə. Начар юлга кереп китүенə һəм кеше үтерүенə Закир бик үкенə. «Синең болай булуыңа сəбəп бер фахишəнең сүзенə ышанып йөрүең,— дип уфтана ул.— ...шул өч көнлек ләззəткə алданып, бөтен гомерең буенча хурлыкка төш инде». Соң чиктə, үзен тотасыларын белеп, Закир атылып үлə. Шулай итеп, бай гаилəдə тəрбиялəнгəн, үзен дə, ата-анасын да бəхетсез иткəн Закир язмышында автор зур фаҗига күрə. Бу фаҗиганең нигезендə үз эшлəрендə җавапсыз, аларга вакытында бəя бирə белмəгəн яшь егетнең хаталанулары ята.

1907 елда автор бу драмасын яңартып яза. Ул инде сəнгатьчə эшлəнеше белəн дə, фикер сөреше ягыннан да яхшыртылган. Беренче вариантта бу хəллəргə Закир үзе генə гаепле булып күренсə, монысында инде фаҗигадə ата-анасы, аларның тəрбия итə белмəүлəре дə гаепле дигəн фикер уздырыла. Дөрес, язучы Закирны акламый, аның хаталанулары өчен үзе җаваплы булуын ассызыклап əйтə. «Барысы да үз гөнаһым шомлыгы,— ди егет, үлəр алдыннан.— Əгəр өемдə генə ятсам, начар эшлəргə катышмаган булсам, ата-анам биргəн үгет-нəсыйхəтлəрен тотсам, мондый бəлалəргə дучар булмаган булыр идем». Шулай да аның мондый адымнарының башын автор гаилəдə, ата-ана тəрбиясендə, аң-белем җитмəүдə, наданлыкта күрə. Юкка гына драматург соңгы пəрдəне алдынгы карашлы Сəгыйть Сабитов сүзлəре белəн япмый: «Дөньяда баланы бигрəк ата-ананың тəрбия кыла белмəве харап итə!!!»— ди ул. Ə тəрбия итə белү өчен, үзең аң-белемле, зыялы булу кирəк. Бу яктан Кəрим бай — бик кара кеше. Яңача укытуга да каршы ул, халыкка ярдəм итүне дə кирəксенми. Боларны белгəч, аның Закирны кайда һəм ничек укытканын чамаларга була инде. Шул рəвешле, əсəрнең соңгы вариантында бала тəрбиясе, кешенең үз эшлəре өчен үзе җаваплы булу мəсьəлəлəре тирəнрəк һəм тормышчанрак төстə тасвирлана. Вакыйгаларны болай коруда драматургия кануннарын эшкə тулырак җигү омтылышы да булышкан. Чыннан да, кешенең үз хатасы аркасында җəзалануын күрсəтү бик тəэсирле. Шуның белəн бергə, аның мондый хаталануының нигезендə тагын башка сəбəплəр дə ятуын белү тормышчанлыкны көчəйтə, тамашачыга ныграк тəэсир итə.

«Бәхетсез егет»тә күтәргән мәсьәләләрне Г. Камал алдагы пьесаларында махсус тема итеп ала. Мәсәлән, гаиләдә хатын-кызның кол хәлендә яшәвен, аның тормышы кызыксыз булуын, мәхәббәткә омтылуын, ләкин еш кына, бозык күңелле кешеләр кулына эләгеп, фаҗигагә юлыгуын ул «Уйнаш» драмасында (1910) сурәтли. Яхшы күңелле, намуслы, эшчән кешенең көнчелек корбанына әверелүен, эчкечелеккә бирелүен һәм гаилә бәхетеннән дә, хезмәт урыныннан да мәхрүм калуын «Дәҗҗал» исемле драмада (1912) тасвирлый.

Көлке көлә килә...

Мондый әхлакый мәсьәләләргә драматург бигрәк тә комедияләрен багышлый, бу мәсьәләләрне көлү аша, сатира ярдәмендә хәл итә. Аның иң яхшы әсәрләре дә комедия жанрына карый. Белгечләр андый иҗатчыларны «комедиограф» дип атыйлар. Г. Камал — бездәге иң күренекле комедиографлардан берсе.

Язучы үзенең әсәрләренә материалны халык тормышыннан ала. Җәмәгатьчелекне борчыган фикерләр аны да бимазалый, уйландыра. Көн тәртибенә баскан мәсьәләләрне ничек хәл итәргә? Ничек хәл иткәндә, ул файдалырак булачак дигән сораулар аңа да тынгылык бирми. Әсәрләрен дә ул шул эшләрдә булышу теләге белән иҗат итә. Аларда тормышның алга барышына ярдәм итәрдәй каһарманнарны үрнәк төстә сурәтләп күрсәтергә тырыша. Ә инде халык язмышына, кешеләрнең кайгы-хәсрәтенә битараф булганнарны фаш итә. Үзе өчен генә кайгыртып, башкаларга төкереп караучылардан, бүтәннәр исәбенә үзенә яхшы тормыш корырга ният иткәннәрдән мыскыллап көлә, аларны тәнкыйтьли.

Г. Камал каләме өчен соңгысы аеруча үзгәлекле. Комедияләре белән ул үз чорында яшәп килгән иске гадәт-йолаларны, мещанлыкның тискәре якларын фаш итә. Һәртөрле яңалыкны аңламаган һәм аңларга теләмәгән, байлык артыннан куып, кешелек сыйфатларын җуйган кешеләрне көлү объекты итеп ала. Мәсәлән, татар театры барлыкка килүне кайбер кешеләр хупламаган. Алар арасында ислам дине кануннарын бик тар аңлаганнар да булган. Имеш, сәхнәдә уйнау, бигрәк тә хатын-кызларның йөзләре ачык килеш күп санлы кеше алдына чыгып басулары — зур гөнаһ!

«Бәхетсез егет»нең 1898 елгы язмасында ук Г. Камал бу мәсьәләгә карашын ачык итеп белдергән иде. Ул моны алдынгы карашлы Әхмәттән әйттерә. «Дөньяда чагында бернәрсә исәпләмичә йөрибез дә, әмма ахирәткә баргач ниләр булыр?» дигән сорауга егет театрның файдасы турындагы сүзләр белән җавап бирә:

«...анда никадәр гыйбрәтләр бар: начар юлда йөргән кешеләр ниндәй эшләргә очраганын һәм дөньяда ниндәй хурлыкларга төшкәннәрен күз алдында күрсәтәләр. Кешеләр гыйбрәт күзе белән карасалар, ихлас күңелләре берлән тыңласалар, андай начарлыктан сакланырлар, дөньяда шундай начарлыклардан саклансалар, ахирәттә бәхетле булырлар һәм зур дәрәҗәләргә ирешерләр. (...) Әллә аны, үлемне искә төшерү, үлемнән курку дигәч тә, мич артына кереп качу дип беләсезме? Үлем өчен азык хәзерләү дигән сүз ул! Үлем өчен азык хәзерләү начар эшләрдән саклану, яхшы эшләрне эшләү берлән була. Инде театрга барсаң, начар эшләр эшләгән кешеләр ничек булганын күз алдына китереп күрсәтәләр. Бу гыйбрәт түгелме? Һәм үлемне искә төшерү түгелме?»

«Беренче театр» комедиясендә (1908) Г. Камал менә шул хәлләрне, ягъни сәхнә сәнгате туып кына килгәндә аны кемнең ничек кабул итүен тасвирлый. Берәүләр театрга баруны, анда уйнап күрсәтелгән гыйбрәтле хәлләрне карарга омтыла. Икенчеләр исә бу эшне гөнаһ, ярамаган, бозык эшкә саный. Аларның шундый капма-каршы карашлары арасында калганнарга да җиңел түгел.

...Иске фикерле Хәмзә карт шәһәрдә театр куярга теләүләрен белгәч, үз ишләре белән аны булдырмас өчен тырышып йөри. Әнә ул шуның өчен бөтен башлыкларны йөреп чыккан, губернаторга кадәр барып җиткән. Ләкин «динне мәсхәрә кылмакчы» булганнарны бу эштән туктатып калып булмый. Ә баксаң, шул арада аның үз өй эчендәгеләр барысы да театрга киткәннәр икән! Шулай итеп, карт көлке дә, кызганыч та, ягъни трагикомик хәлдә кала. Бу вакыйгада картның кияве Вәли белән килене Факиһә алдынгы карашлы кешеләр булып, Хәмзә карт исә иске фикерле диндар булып тасвирлана. Картның үз балалары Гафифә белән Хәбибрахман, гәрчә аталарыннан уттан курыккан кебек курыксалар да, үгеткә, ялваруга түзә алмыйлар: беренчесе иренә, икенчесе хатынына буйсынып, спектакль карарга китәләр. Нәтиҗәдә бу хәлне

көтмәгән Хәмзә карт, кире алып кайтырга дип, ярсып яшьләр артыннан ташлана.

Язучының замандашлары әсәргә югары бәя бирәләр. Шул җөмләдән, Ф. Әмирхан түбәндәгеләрне язган: «Галиәсгар әфәнде бу әсәрне хосусый бер гаиләнең мәгыйшәтеннән (тормышыннан) алып язган булса да, урта буржуазный классның (сыйныфның) психологиясен бик яхшы төшенгәнлегеннән, комедиянең каһарманнарына бик оста сурәттә гомумият бирә вә, шулай итеп, бу кыска комедиясен гомуми, ярым «мөтәрәкъкый» (алга киткән, үсеш алган) купецларыбызның мәгыйшәт вә дингә нәзарларының (карашларының) бер бик тугры көзгесе итеп чыгарадыр. Комедиянең баш каһарманы Хәмзә бай,— җәннәт ачкычын үз кулына тотып, анынча йөрмәгән кешеләрнең берсен дә анда кертмәскә мөтәкәффил (берәр хәлнең үтәлешен тәэмин итәр өчен вәгъдә бирүче) булган мөттәкый (динче, тәкъва) — үзенең бик көлке хосусиятләре белән комедиядә бик ачык тасвир ителәдер. Моның тәрбиясе нәтиҗәсе булган балаларының хосусиятләре дә бик көлке сурәттә күрсәтелә».

Г. Камал татар җәмгыятендә урын алган кимчелекләрне берәм-берәм сәхнәгә чыгарып күрсәтә тора. Ул бигрәк тә буржуаз-аксөякләр тормышында киң таралган җитешсезлекләрдән белеп һәм оста көлә. Чөнки бу тормышта аларның үрчүе өчен, җирлекнең җитәрлек булуын күрә ул. Байлык бар, әмма аннан акыллы файдалана белүчеләр аз. Мещаннар арасында наданнар, ялкаулар, хөсетлеләр буа буарлык. Аларның бар шөгыле — матур киенеп кунакка йөрү, кунак җыю; бар хыялы — башкалардан өстен булу, белем ягыннан түгел, ә байлык туплауда өстенрәк, дәрәҗәлерәк булу. Андыйлар өчен бернинди изге хисләр дә, ата-ана һәм балалык мөнәсәбәтләре дә, олыларны олы итү, кечеләргә һәм көчсезләргә миһербанлы булу да юк.

Шундый сыйфатларны туплаган Хәмидә образы «Бүләк өчен» комедиясендәге (1909) вакыйгаларның үзәгенә куелган. Бу хатын, малаен өйләндергәндә үзенә тиешлене һәм яхшыны күбрәк эләктереп калу өчен, ялган юлына баса. Улы Габдуллаҗанга ошамасын белә торып, ямьсез һәм акылга таман кызны киленлеккә алырга тели, аны төрлечә мактый. Монда аңа шунысы кулай: искедән калган гадәт буенча, яшьләрне кавыштырганда, аларның алдан бер-берсен күреп белүе шарт түгел. Егет белән кыз бер-берсен белмәсә яхшырак та санала.

Киләчәктә бер гаилә булып яшәячәк кешеләрнең язмышын ата-ана гына хәл итә. Бу очракта Хәмидә хәл итмәкче була, чөнки ире Әхмәтҗан да булачак киленне белми. Аны булачак кода-кодагыйларның бик бай булулары, димәк, туйга чыгымнарның да артык күп булачагы гына пошындыра.

Иренең дә, улының да ай-ваена карамыйча, үз дигәнен эшләр дәрәҗәгә килеп җиткәч кенә, бер аңлашылмаучылык аркасында, Хәмидәнең чын нияте ачыла. Бирнәлек бүләккә асыл күлмәклек өмет иткән Хәмидә яучы карчык авызыннан «җон күлмәклек» дигәнне ишеткәч, ачуы кабынып китеп, кызның чын сыйфатларын тезә башлый. Бераздан хата ачыла ачылуын: булачак кодагый «җон» дип ялгышлык белән генә әйткән икән, шуны хәбәр итү өчен, асравын йөгерткән. Шуны белгәч, Хәмидә яңадан элекке ялганына кайтмакчы була булуын да... ләкин инде эш узган. «Син, үзеңә асыл бирнәләр килсен өчен, минем башымны колга, тилиграм баганасы, белмим, тагын әллә нәрсә шикелле озын, ямьсез, шадра, кыек авызлы, кәкре аяклы бер кызга бәйләмәкче булган икәнсең. Юк инде, хәзер торып тор, ул эшләр бик тиз генә эләкмәс!» — ди Габдуллаҗан. «Мине дә күп акча тотудан коткардың», — дип, Әхмәтҗан да сөенә. Нәфесен тыя алмаган Хәмидә, туй мәһәрен, хәер-сәдакаларны күбрәк эләктерү нияте белән генә йөргән яучы карчык Мәхүп адәм мәсхәрәсе булып калалар.

Шәһәрдә нинди серләр бар?

Галиәсгар Камал үзен татарлар арасында яшәп килгән тискәре гадәт-йолаларның, кимчелекләрнең гомерлек дошманы итеп саный. Аларның кайберләрен ул «Бәхетсез егет»тә үк искәртеп узган булса, әсәрнең икенче язылышында «Беренче театр», «Бүләк өчен» комедияләрендә, «Уйнаш» драмасында (1910) инде көйдергеч тәнкыйть астына ала. «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясендә (1911) мондый кимчелекләрнең һәм җитешсезлекләрнең ул тулы бер тасвирламасын тудыра.

Пьеса 5 пәрдәдән тора. Һәр пәрдә вакыйгаларның кайда баруына карап исемләнгән: «Җәмгыяте хәйриядә», «Ресторанда», «Клубта», «Базар чатында», «Әдәбият кичәсендә җәнҗал». Димәк, зур шәһәрнең кеше күп җыела торган урыннары, алардагы тормыш хәлләре һәр тарафтан киң итеп күрсәтелгән.

Һәр пәрдәнең үз персонажлары, үз «каһарманнары» бар. Алар, кагыйдә буларак, башка пәрдәдә күренмиләр (бу яктан беренче ике пәрдә генә аерылып тора). Вакыйгалар арасында да тышкы бәйләнеш юк. «Җәмгыяте хәйриядә» булган вакыйгалар, әйтик, «Базар чатында» барганнары белән бәйләнмәгән. «Клубта»гы күренешләр һәм персонажлар белән «Әдәбият кичәсендә җәнҗал» пәрдәсендәге хәл-әхвәлләр арасында да бәйләнеш юк. Әмма аларның күпчелегенә уртак булган сыйфатлар һәм билгеләр бар. Болар — наданлык, кирелек, бозыклык, икейөзлелек, җаһиллек, һәртөрле яңалыкка дошман булу һ. б., ягъни татар җәмгыятенең алга үсешен, тәрәккыятен тоткарлап торган кимчелекләр. Шулар җирлегендә үзара охшаш хәлләр туа: җәнҗал, күзгә карап алдашу, намуссызлык, тәртипсезлек, юк-бар белән вакыт уздыру һ. б. Менә шул уртаклыклар пьесаны бербөтен итә. Шәһәр тормышының тискәре якларыннан гына төзелгән эпик тасвирлама барлыкка килә.

Үзләрендә тискәре сыйфатларны җыйган образлар арасында берничәсе чын тип дәрәҗәсенә җиткереп эшләнгән. Алар башкалардан нык аерылып торалар. Бигрәк тә шкафчы Әхмәтҗан образы. Бу — наданлыгы белән дә, һәр яңалыкка дошманлыгы һәм әрсезлеге белән дә җиренә җиткереп эшләнгән тип. Һәр узган-барган артыннан «өреп» калуы дисеңме, оятсызланып, яшь кенә кызга бәйләнүеме, алдашуы һәм гайбәт сөйләве дисеңме, шул арада эт һәм күсе куып йөрүләреме — барысы да бу кешенең бозык рухи дөньясын һәм акылы сайлыгын күрсәтеп тора. Дин тәртипләре турында, зур сәясәт хакында һаваланып сөйләүләре белән аның үз-үзен тотышы, эш-гамәлләре арасында зур аерма бар. Бу аерма образның сатирик эчтәлеген тагын да тулыландыра. Язучы искелекнең бер билгесе булып әверелгән, «көфер почмагы» дигән исем белән дан алган иҗтимагый күренешне шушы образда һәм пәрдәдә туплап биргән. Себер бае әйткән: «шәһәрегезнең шәп кешеләре эт булып өреп калу белән генә канәгатьләнмиләр, мәче булып, күсе дә тоталар икән!» — дигән сүзләре шкафчыны да, аның иярченнәрен дә дөрес тасвирлый. Бу образларда тискәре сыйфатлар арттырып бирелсә дә, кешеләрнең үз-үзләрен тотышында чынлык юкка чыкмый. Чөнки монда тормышчан җирлек көчле, автор шуңа ирешкән.

Комедиянең төзелешендә, ягъни вакыйгалар һәм күренешләр, пәрдәләр арасындагы бәйләнешне тәэмин итүдә

Себер бае образы да билгеле бер роль уйный. Бу шәһәргә ерактан өйләнергә дип килгән, мәгърифәтле кеше ул. Шуңа күрә аның һәртөрле җәмәгать урыннары, алардагы тәртип белән танышып йөрүе дә аңлашыла һәм аклана. Чит-ят күзгә шәһәр тормышындагы уңае да, гаеп-кыегы да ачык күренә. Һәр җирдә хөкем сөрүче наданлык һәм җәнҗал, билгеле инде, аны тәмам аптыраштa калдыра. Аның соңгы сүзләре, шәһәрдәге тәртипсезлекләргә автор бәясе булып яңгырый: «Җәмгыятегездә — җәнҗал, ресторанда — җәнҗал, клубыгызда — җәнҗал, базарыгызда — җәнҗал, әдәбият кичәгездә дә — җәнҗал! Булмас ахры, өйләнмим мин! Хуш, сау булыгыз!» Шуның белән пәрдә ябыла.

Г. Камалның замандашлары бу әсәргә дә югары бәя бирәләр. Аерым алганда, Г. Тукай түбәндәгеләрне язып чыга:

«Былтыр Галиәсгар Камал безнең шәһәрнең серләрен чит шәһәрләргә сөйләде дә куйды. Электә чит шәһәрдә йөргәндә, синең яныңа киләләр дә:

— Казан ничек? Халкы ничек? Андагы «Шәрык клубы» ничек? Фәлән ничек?— дип йөдәтеп бетерәләр иде. Әлбәттә, эчләреннән Казан вә аның мөтәгалликатына (кешеләренә) бик мактаулы җавап көтәләр иде.

— Бирмәсәң — оят бәдбәхеткә, бирсәң — кыен.

Ул акчаны тапкан бит ошбу муен, дигән шикелле, Казан вә казанлылар тугрысында ялганлап, сүз белән сүи истигъмаль (урынсыз куллану) итәсе килми иде. Ялганламасаң, аларның хөсне заннарын (яхшы уйда булуларын) бозу була иде. Менә хәзер аларга «Безнең шәһәрнең серләре» — укысыннар да белсеннәр, кемнәр барын күрсеннәр».

Иҗтимагый һәм милли тигезлек өчен көрәшкәндә

Акча колы булып яшәгән җәмгыятьнең күп кенә кимчелекләрен һәм черек якларын күреп-белеп көн иткән Г. Камал 1917 елгы инкыйлабны үзенчә рухланып каршы ала. Бу инкыйлаб, 1905—1907 елгысы, татар халкына биреп бетермәгәннәрне бирер, социаль һәм милли азатлык китерер дип, чын күңелдән ышана ул.

Күз алдына китерик: менә Казан шәһәре. Тормыш инкыйлаби үзгәрешләргә бай, аларның кайберсен тиз генә аңлап-төшенеп бетеп тә булмый. Казанга ак чехлар якынлаша,

кайдадыр кемнәрдер баш күтәргән, иске тормышны кире кайтарырга маташа. Кайный Казан. Бередә мондый көннәрдә һәр эш-гамәл генә түгел, һәр тугры сүз дә зур әһәмияткә ия. Менә шуңа күрә дә инкыйлаб тарафдарлары матбугатка, театр сәнгатенә, җанлы агитациягә нык игътибар бирәләр. Дистәләгән яңа газета-журналлар оештырып, анда эшкә танылган сүз осталарын — язучыларны һәм журналистларны, галимнәрне тарталар. Җанлы агитациянең төрле төрләренә мөрәҗәгать итәләр. Мондый эшләрдән Г. Камал читтә кала алмый, билгеле.

...Әнә урамнар буйлап автомобиль килә. Аның як-яклары, алды-арты шигарьләр[1] һәм рәсем-сурәтләр белән бизәлгән. Менә ул кешеләр җыйналган чатка килеп туктый. Автомобиль өстенә мәһабәт гәүдәле, мыеклы берәү сикереп менә, кулларын селкеп, халыкка сөйли башлый. Бераздан шигырьгә күчә:

Хәзер кадер малга юк,
Буржуага сан да юк,
Суга сусаган да юк,
Һәркем тигез, бәдәвам...

Җыелган халык ораторны тиз танып ала. «Сөйлә, Галиәсгар! Әйдә, әйт дошманнарга кирәген!» дигән хуплау авазлары яңгырый.

Әйе, бу кеше — Галиәсгар Камал. Инкыйлабтан соң чыга башлаган «Эш» һәм «Кызыл Армия» газеталары редакцияләрендә төннәрен куныл эшләвенә, бу басмаларда сан саен диярлек төрле шигырьләр һәм мәкаләләр бастырып чыгаруына канәгатьләнеп бетмичә, язучы түзмәгән, декламацияләре белән, җанлы сүзе белән халыкның күңелен җилкендерү өчен, урамнарга чыгып киткән...

Бу елларда Г. Камал, асылда, шагыйрь буларак күп эшли: йөзгә якын шигырь, пародия һәм эпиграммалар иҗат итә. Өндәү рухында язылган шул шигырьләре, сатирик куплетлары белән ул хезмәт ияләрен яңалык дошманнарына каршы көрәшкә рухландыруны, контрреволюцияне фаш итүне максаты итеп куя. Озакламый драматургиягә дә әйләнеп кайта. Пьесаларында, иске тормышны тәнкыйть итү белән беррәттән, тематикасын яңартырга, яңа җәмгыять төзүчеләр образларын алга чыгарып сурәтләргә омтыла. 1921 елда язылган «Хафизә-

[1] *Шигарь* — лозунг, өндәмә.

ләм, иркәм» әсәрендә, шуннан соң иҗат ителгән «Өч тормыш», «Күзсез мастерлар», «Ахырзаман» кебек драма һәм комедияләрендә әле кичә генә изелеп яшәгән, хокуксыз булган кешеләрне бүген инде үзләрен тормыш хуҗасы дип хис итүчеләр рәвешендә күрсәтергә тырыша. Ләкин чынлыкта аларның хуҗа булудан бик ерак торулары сәбәпле, ягъни теләгәнен тулы итеп күрсәтү өчен, яңа шартларда җирлекнең булмавы нәтиҗәсендә, драматург бу пьесаларында сәнгатьчә дөреслеккә тулысынча ирешә алмый. Шуңа күрә дә бу елларда Г. Камал элек иҗат иткән, татар драматургиясенең алтын хәзинәсендә ныклы урын алган әсәрләре дәрәҗәсендәге сәнгатьчә югарылыкка күтәрелеп җитми. Шактый ясалма халәтләрдә хәрәкәт итәргә тиеш булган персонажлар тормышчанлык һәм ышандыру көче ягыннан да, үзгәлекле тип булу җәһәтеннән дә Октябрь борылышына кадәрге әсәрләрдәге образлардан күпкә калышалар.

Шуңа күрә дә без «Галиәсгар Камал мирасы» дигәндә, иң әүвәл аның «Беренче театр», «Безнең шәһәрнең серләре», «Банкрот» комедияләрен, «Бәхетсез егет» драмасын күз алдында тотабыз. Аларны классик үрнәк әсәрләр дип атыйбыз. Әлбәттә, Г. Камалның башка иҗат җәүһәрләрен дә (ә ул барлыгы утыздан артык пьеса һәм инсценировкалар, шигырьләр, мәкаләләр, бәяләмәләр язган, тәрҗемәләр ясаган) югары бәялибез. Татар әдәбияты хәзинәсенә зур өлеш кертүе, армыйталмый җәмәгать эше алып баруы белән Г. Камал халыкның мәхәббәтенә лаек булды, олы абруй казанды. 1923 елда аңа «Хезмәт батыры» дигән мактаулы исем бирелде.

Г. Камал Казанда 1933 елның 8 июнендә йөрәк параличыннан кинәт үлеп китә, каләмдәшләре һәм күп санлы укучылары аны хөрмәтләп соңгы юлга озаталар.

Сораулар һәм биремнәр

1. Тормыш юлындагы төп вакыйгаларга тукталып, Г. Камалның кыскача биографиясен сөйләгез.

2. Язучының беренче әсәрләрендә үзәккә куелган мәсьәләләр нидән гыйбарәт? Ни өчен бу әсәрләрне мәгърифәтчелек әдәбиятына кертеп карыйбыз?

3. Ни өчен «Галиәсгар Камал — комедия остасы» дип әйтәбез? Дәлилләгез.

4. 6 нчы сыйныфта өйрәнгәннәрне дә искә төшереп, «Беренче театр» комедиясенә анализ ясагыз. Әсәрнең конфликтын билгеләгез, образларына характеристика бирегез.

5. Совет хакимиятенең беренче елларында ни өчен Г. Камал кыска әсәрләр — төрле декламацияләр һәм шигырьләр язуга күчә?

6. Г. Камалның Октябрь инкыйлабына кадәр язган пьесалары белән соңгы чорда иҗат иткән сәхнә әсәрләрен чагыштырыгыз. Алар арасында нинди аерма бар? Аңарчы классик әсәрләр язган драматургның соңгы пьесалары шул ук дәрәҗәдәме? Моның сәбәпләрен нәрсәдә күрәсез?

7. Галиәсгар Камал иҗатының әһәмияте турында сөйләгез.

8. Өйдә «Безнең шәһәрнең серләре» исемле комедияне укып, әсәрдәге сатирик типларның берәрсе турында инша әзерләп килегез.

«Банкрот»
(*1911*)

«Банкрот» әсәре реалистик драматургия тарихында күренекле урын тота. Язылуы белән үк сәхнәгә күтәрелгән бу комедия бүген дә театрларда яратып уйнала, тамашачыны тәрбияли. Акча бәрабәренә намусларын саткан кешеләрдән көлүе белән әсәр бүгенге көнгә дә аваздаш.

Комсызлык корбаны

Әсәрнең нигезенә вакытлы матбугатның «көндәлек вакыйгалар бүлеге»ндә, яки, икенче төрле әйткәндә, «җинаятьләр хроникасы» бүлегендә генә урын алырлык вакыйга салынган. Комедиянең баш каһарманы Сираҗетдин Туктагаевка аны оештыру фикере, чыннан да, газетада бер сәүдәгәрнең ничек талануы турындагы хәбәрне укыгач килә. «Үземезчә газеталар чыкмаса, мин әле ул фикерне кайдан уйлап чыгара алыр идем»,— ди ул. Һәм менә Сираҗетдин, бурычка алган товарларының бәясен киметеп түләү максаты белән банкротлыкка чыгу өчен, шактый хәтәр хәйләсен эшкә җигә. Янәсе, Мәскәү сәүдәгәрләренә түләргә дип, ул читек куныччларына 49 мең акча урап кия (чынлыкта акча урынына кәгазьләр чорный). Юлда вагонда аны «талыйлар», һәм ул «акылдан яза». Моннан соң ул «җүләр» ролен шулкадәр оста уйный ки, бераү дә, шул җөмләдән Мәскәүдән килгән доверенныйлар да, аның акча урлатуына шикләнмиләр. Сираҗетдиннең «җүләр»леген тикшереп карау өчен чакыртылган табиб-доктор ярдәмендә бу алдакчы үзенең акылдан язуына доверенныйларны тәмам ышандыра. Нәтиҗәдә ул 120 мең

сум бурычының 10 процентын гына түләү бәхетенә ирешә һәм шул ук докторның «тылсымы» ярдәмендә яңадан «үз акылына кайта». Боларны доктор, әлбәттә инде, зур гына акча алу бәрабәренә эшли. Нәтиҗәдә шушы оста үткәрелгән аферасы ярдәмендә Сираҗетдин 108 мең сум табыш ала.

Акчага һәм байлыкка омтылу кешегә элек-электән хас. Ләкин бу омтылыш саф һәм чиста булырга, хак юлда торырга тиеш. Ислам дине мондый омтылышның изге һәм хыянәтсез булуына бик нык әһәмият биргән. Сәүдәгәр кеше байлыкка гадел юл белән генә ирешү өстенә, килгән еллык табышларыннан зәкят бирергә, ягъни кырыктан бер өлешен фәкыйрьләр, ярлылар, авырулар файдасына хәер итәргә тиеш. Ә инде алдашуга, хыянәткә нигезләнеп байлык тупларга омтылу кире кагыла, гөнаһ санала. Г. Камал да түбән җанлы кешеләрнең мөселманлыкка да, әхлак нормаларына да сыешмаган шундый омтылуын фаш итә һәм тәнкыйтьли. Ваклыкның, үз-үзен генә яратуның кешене нинди түбәнлекләргә төшерү ихтималлыгын күрсәтә.

Сираҗетдин Туктагаев — «тыштан бик изге күренә торган сәүдәгәр» дип тәкъдим итә автор баш каһарманны. Чыннан да, ул тыштан шактый гына итагатьле, динле, инсафлы булып күренә. Ә чынлыкта гел үзе өчен генә кайгыртучы, акча дигәндә оятын җуйган комагай, икейөзле аферист. Дөрес, шәхес буларак аның игътибар итәрлек сыйфатлары да юк түгел. Мәсәлән, ул — бик максатчан, эшчән кеше. «Әле мин белгәндә генә Сираҗи кышкы суыкта бер кат юка бишмәт белән калтырап туңып йөри торган бер кибетче малай иде,— дип сөйли Нәгыймә карчык.— Аз арада гына нинди баеды да китте». Димәк, аның сәүдә эшенә сәләте бар. Шулай ук аны тапкыр түгел дип тә әйтеп булмый: әнә ничек оста оештыра ул алдашуны. Ә аның артистлыгы! «Җүләр» кеше булып ничек оста уйный ул! Үзен чолгап алган сәүдәгәрләрнең дә, доктор кебек «зыялы»ларның да холык-фигылен яхшы аңлый ул, аларның кимчелекләреннән бик белеп файдалана.

Бер кешегә шундый капма-каршы сыйфатларны туплап биреп, драматург образны, бердән, җанлы һәм тормышчан итә, икенчедән, аның сатирик көчен арттыра. «Җүләр»гә сабышкан кешенең кыланышлары болай да көлке тудыра, билгеле. Ләкин бу очракта бу кыланулар бик җитди төс ала, чөнки максат бик зурдан — 108 мең тәңкәне кулга төшерү! Шуңа күрә дә Сираҗетдиннең «җүләрләнүе» сатирик көлү

уята. Әгәр дә Сиражетдиннең максаты изгедә, мәсәлән, ярлымескеннәргә ярдәм итүдә булса, эш башкача булыр иде. Андый очракта укучы һәм тамашачы мондый хәтәр юлга баскан кешенең бу кыланышларын хупламаса да, беркадәр хәерхаһлык белән көлер иде. Юк шул, максат бик тар, бик шәхсән. Моны Сиражетдиннең «сәламәтләнгәч», ягъни алдашуларын тәгәлләгәч әйткән сүзләре ачып сала. «Эш пеште! — дип куана ул.— Бер минут эчендә йөз дә сигез мең сум файда! Хатынны җибәрәм, яшь хатын алам, йорт салам, афтамабил алам! Типтерәм дөньясында!» Үз корсагын гына кайгыртып яшәгән мондый кешенең маймыл кебек кыланышларыннан бары тик мыскыллап көлергә генә мөмкин. Сиражетдин — комсызлык корбаны, түбән җанлы, эче һәм тышы этлек белән тулы аның. Бу образ ярдәмендә драматург җәмгыятьнең явыз чиренә әйләнә барган комсызлыктан, сәүдәгәрләр даирәсендә киң җәелгән кимчелекләрдән ачы көлә.

Алдакчының даирәсе

Баш персонажның көлкеле якларын тулырак күрсәтүгә аның әйләнә-тирәсендәге кешеләр ярдәм итә. Икенче төрле итеп әйткәндә, автор Сиражетдинне шундый кешеләр белән уратып алган ки, алар мондый зур аферистның тууына һәм яшәвенә ышандыра торган мохит барлыкка китерәләр. Шул ук вакытта аларның һәрберсенең үз йөзе, үз дөньясы бар.

Менә Гөлҗиһан — Сиражетдиннең хатыны. Тар фикерле, иренең күзенә генә карап тора. Бар теләге — дошманнарының йөрәге янарлык итеп яшәү. Им-томчы карчыклар, гайбәтче хатыннар — аның аралашкан даирәсе, дуслары һәм ахирәтләре. Ә башкалар көнләшерлек итеп яшәүне ул кунакка йөрүдә, мәҗлес җыюда күрә. Асрауларның зарлануларына караганда, ул — тәкәббер, холыксыз, эш рәте белмәүче, саран һәм ялкау хатын. Аның кайгы-хәсрәтләре бик вак нәрсәләр тирәсендә әйләнә: әнә бламажилары әзерләнмәгән, кемнәрдер аның турында начар сөйләгән, кайсыдыр аның баласы булмый дигән һ. б. Инде зур кайгы килгәч, аны, иренең акылдан язуыннан да бигрәк, 49 мең акчаны югалтып, ярлыланып калу борчый. Әгәр дә байлыкларына зыян килмәгән булса, ул бер дә артыгын пошынмас, «җүләр» иреннән дә тиз котылыр иде. Кыскасы, бу образ ярдәмендә язучы аксөякләр даирәсендә, тар дөньяда бикләнеп ятуга дучар ителгән хатын-

кызның көлке дә, кызганыч та булган хәлен тасвирлый. Әйе, аны бераз кызганасың да. Әнә ул, мескен: «Кунакка барам, кунак чакырам, мәҗлес уздырам! Янсын дошманнарның йөрәге!» — дип шапырына. Тиздән үзен Сираҗетдиннең куып чыгарасын башына да китерми.

Сираҗетдин белән Гөлҗиһан вакыйгаларда баштан ахырга кадәр катнашсалар, башка персонажлар чагыштырмача аз, кайберләре ара-тирә генә күренеп алалар. Шулай булуга да карамастан алар укучының һәм тамашачының хәтерендә уелып калалар. Мондыйларны ярдәмче персонажлар дип, ә тагын да азрак катнашканнарын яки күренеп кенә киткәннәрен эпизодик персонажлар дип атыйлар.

Шундыйлардан менә Нәгыймә — им-томчы карчык. Бер караганда, ул Г. Камал пьесалары өчен инде яңа образ да түгел. Андый типтагы карчыклар «Бәхетсез егет» (Мәгъри), «Өч бәдбәхет» (Мөгълифә), «Бүләк өчен» (Мәхүпҗамал) пьесаларында да бар. Әлбәттә, алар бер үк сыйфатлы персонаж түгел: берсе усал һәм астыртын булса, икенчесе хәйләкәр, өченчесе тупас, ягъни һәркайсының үз холык-фигыле. Шулай да бу карчыкларның барысына да хас уртак сыйфатлар — байлыктан көнләшү һәм байлар, бигрәк тә бай-бичәләр янында йөреп хәер-сәдакадан, яучылыктан, им-том өчен килә торган акчаны күбрәк эләктереп калырга омтылу. Нәгыймә карчык та шундый. Дөрес, ул күзгә керә торган әрсез түгел, күбрәк хәйлә белән эш йөртә. Изге, итагатьле булып кылану артында алдакчы, бер генә әйбергә — акчага табынучы кеше яшеренгән.

Эпизодик образлардан Гарифә белән Мәликә истә калалар. Алар бер күренештә генә катнашалар. Бу күренеш әлеге гайбәтче хатыннарның җанлы һәм тормышчан гәпләшүләреннән гыйбарәт. Болар — Гөлҗиһанның кунаклары. Шул кыска гына вакыт эчендә дә алар шәһәр мещаннары катлавы тормышын тулы итеп күз алдына бастыралар.

Ярдәмче персонажлар арасында доктор образына шактый җитди йөкләмә салынган. Сираҗетдиннең хәйләсе уңышлы барып чыгуын тәэмин итүдә ул төп урынны тота. Башкалардагы чир — акча ярату — аңар да йоккан. 500 сум бәрабәренә ул да алдашуга бара. 10—15 сумга бер сыер сатып алырга мөмкин булган замана өчен бу — зур акча. Аферистлыкта ул Сираҗетдингә тиң. Хәл-әхвәлдән котылуның нинди җайлы юлын таба ул: авыруны терелткән булып, тагын 500 не кул-

га төшерә, иң мөһиме, яхшы доктор дигән шөһрәт тарату мөмкинлегеннән дә файдалана.

Комедиядәге башка ярдәмче һәм эпизодик персонажлар да үзләренә хас сыйфатлары белән күренеп калалар. Вакыйганың табигый оешуында, үсүендә һәм чишелешендә, тормышчанлык һәм чынлык иллюзиясе тудыруда, иң мөһиме, Сираҗетдиннең тулы, чын йөзен ачышуда аларның һәрберсе мәгълүм бер роль уйный.

Комедиянең сәнгатьчә эшләнеше

«Банкрот» комедиясе сәнгатьчә эшләнеше белән дә Г. Камалның башка әсәрләре арасында аерылып тора. Иң беренче, аның конфликты анык һәм җыйнак. Бөтенесе бер вакыйга тирәсендә бара, өстәмә вакыйгалар юк. Сираҗетдин үзе оештырган алдашуда җиңеп чыгармы, юкмы? Шул сорау укучы һәм тамашачыны гел искәртеп тора. Киртәләр аз түгел: Сираҗетдин «талануына» һәм «җүләрләнүенә» якыннарын ышандыра алырмы? Мәскәү доверенныйлары ташлама ясарлармы? Доктор 500 сумга «чиртерме»?.. Сираҗетдиннең шушы киртәләр белән көрәше конфликтның нигезен тәшкил итә. Бу конфликт җирлегендә көлкеле хәлләр тудырырга, персонажларны сатирик яссылыкта күрсәтергә мөмкинлек бар. Драматург моннан бик оста һәм тулы файдаланган.

Конфликтның аныклыгы белән сюжет төзеклеге үзара нык бәйләнгән. Сюжетның экспозиция өлешендә укучы һәм тамашачы төп «каһарманнар» белән таныша, баш каһарманның асыл теләген белә. Энесенең таланганын һәм акылдан язганын Җамали хәбәр итә. Бу урын төенләнеш булса, алга таба вакыйгалар чишелешкә таба үстерелә. Ул бик хәрәкәтчән, уку өчен дә, сәхнәдә карау өчен дә кызыклы һәм җанлы. Сираҗетдиннең 108 мең сумны отуы белән конфликт чишелә, вакыйга тәмамлана. Композиция бик түгәрәк, урынсыз детальләр дә, артык күренеш һәм персонажлар да юк. Вакыйгалар Сираҗетдин, аннары Гөлҗиһан сәхнәгә керү белән башлана, элек Гөлҗиһан, ахырдан Сираҗетдин сәхнәдән чыгып китү белән тәмамлана. Димәк, бу яктан да билгеле бер эзлеклелек саклана.

Сюжет төзелеше ягыннан «Банкрот»ны «Безнең шәһәрнең серләре» белән чагыштырып карарга мөмкин. Бу соңгысында кайбер пәрдәләрнең урыннарын алыштырырга мөмкин, аннан

әсәргә зыян килми. Мәсәлән, 4 нче пәрдәне 3 нче итеп тә, 1 нче яки 2 нче итеп тә куярга була. 3 нче, 5 нче пәрдәне дә шулай. Мондый урын алыштырулардан әллә ни үзгәрми. Ә «Банкрот»та мондый алыштырулар мөмкин түгел.

Вакыйгаларны җанлы һәм көлкеле итү өчен, драматург аерым мизгелләрдән, тел үзенчәлекләреннән бик оста файдаланган. Сираҗетдиннең асыл ниятен тамашачыга белдереп бару өчен, автор «читкә әйтелгән реплика» дигән сәхнә алымыннан иркен файдалана. Персонаж әйләнә-тирәсендәгеләрнең теләк-омтылышлары белән үз хәле арасындагы аерманы һәрвакыт шәрехләп бара. Менә мисал. Абыйлары һәм Гөлҗиһан Сираҗетдинне юләрләр йортына тапшыру турында киңәшәләр:

«Җ а м а л и. Менә инде Мәскәү давиринныйлары гына килеп килешеп китсеннәр, аннан соң сумашушныйга менгерсәк менгерербез.

С и р а җ е т д и н (*үзалдына*). Тотарсыз капчыгыгызны! Алар килеп киткәч, ничек йөрергә икәнлеген мин үзем дә бик яхшы белермен».

Яисә менә, мәсәлән, Гөлҗиһан ирен юлга җыя, аңар кирәк ярагын хәстәрли. «Бер мендәр, көрпә, адиял куйдым,— дип санап китә ул.— Комганны менә бу капчыкка тыктым. Өч пар күлмәк, ике сөлге, өч тастымал, бер пар аякчу, намазлык, кечке күлмәк. Һәммәсен дә куйдым». Чәйнек, чынаяк та куйдым дип, алга таба саный ул: «Бер пычак, балкашык, тоз — һәммәсен дә куйдым. Юлга ашарга уникe кәтлит, ике алма бәлеше, бер табак сумса, бер тавык гөбәдиясе, ике чебеш хәзерләдем. Менә алары бу кәрзинкәдә булыр. Чәй-шикәрләр дә шунда. Бер савыт белән варинья да куйдым». Әйтерсең лә кеше айлап юл йөрергә чыга. Казан белән Мәскәү арасында поезд ул вакытта никадәр акрын йөрсә дә, бер тәүлектән әллә ни артык йөрмәгәндер инде югыйсә.

Яки менә көлке тудыруның мондый рәвеше. Сәхнәгә килеп кенә кергән Камали абыйсы Җамали белән Гөлҗиһан әйткән керделе-чыктылы такылдаулардан берни дә аңламый тора:

«К а м а л и (*ишектән кереп*). Абый, абый!

Җ а м а л и. Ах җүләр, җүләр! Читек балтырында кырык тугыз мең!

К а м а л и. Нәрсә дисең?

Җ а м а л и. Кырык тугыз мең!

Г ө л җ и һ а н. Ах! Читек балтыры!

Камали. Нинди читек балтыры? Нинди кырык тугыз мең?

Җамали. Сираҗинең читек балтыры!.. Сираҗинең кырык тугыз мең сумы!..

Камали. Читек балтыры ни эшләгән?

Җамали. Талаганнар.

Камали. Читек балтырынмы?

Җамали. Кырык тугыз мең сумын!

Камали. Ни дисең?

Җамали. Менә тилиграм...»

Тискәре персонажларның бозык, тупас һәм надан булуларын аларның сөйләм телендә чагылдыруга Г. Камал нык игътибар бирә. Мәсәлән, Сираҗетдин биру дими, сузу, тамызу, төртү ди: «Докторлары нинди кеше икән?Аңа бер биш йөзлекне сузмый туры килмәс»; «Акча төрткәч доктор эреде»; «Бу — доктор түгел, шайтан икән! Яңадан бер биш йөзлекне тамызмый туры килмәс»,— дип сөйли ул. Шул рәвешле сүзләре белән Сираҗетдин үзенең чын йөзен ача. Әнә ул, хатынны аерам, кәеф-сафа корам, дими (чөнки болар әдәби тел сүзләре), сөреп чыгарам, типтерәм дигән гади сөйләм гыйбарәләре белән алмаштыра.

Сираҗетдин үзенең наданлыгын белемле булып күренергә тырышуы белән яшермәкче итә. Ул алынма сүзләрне бозык әйтүендә дә ачык чагыла: «Хәзерге заманнарда акчаны үзең белән йөртү апасны бит, пираватбелән генә җибәрергә кирәк иде»,— ди (...); «Ничава, дим, Алла кушмаган эш булмас, дим, ето, дидем, судба, дидем. Судбада язылмаса, бернәрсә дә булмас, дидем» һ. б.

Шулай итеп, жанр мөмкинлекләреннән, көлкеле хәл-әхвәлләрдән, сатирик персонаждан, тел-сурәтләү чараларыннан оста файдаланып, Г. Камал татар драматургиясенең алтын фондында урын алган комедия иҗат итә. Аның бу һәм башка пьесалары бездә тәнкыйди реализм әдәбиятының югары баскычта булуын раслый.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Банкрот» комедиясенең кыскача эчтәлеген сөйләгез.

2. Әсәрдәге персонажларга характеристика бирегез. Искелекне, наданлыкны тулырак чагылдыру ягыннан, сез аларның кайсыларын аерып күрсәтер идегез?

3. Ярдәмче персонажларны, эпизодик образларны аерып атагыз, һәр персонаждагы үзенчәлекле сыйфатны табып күрсәтегез.

4. Комедиядәге конфликт нидән гыйбарәт?

5. «Сираҗетдин ота, ләкин кеше буларак оттыра» дигән гыйбарәне төшендереп бирегез.

6. Әсәрнең бигрәк тә кайсы урыннарын һәм ни өчен көлкеле дип таптыгыз?

7. Комедиянең сәнгатьчә эшләнешендәге үзенчәлекләрне күрсәтегез.

8. Әсәрнең теле халыкчан булуныниләрдә күрәсез?

9. «Сираҗетдин — комсызлык корбаны» дигән темага инша языгыз.

* * *

С а т и р а — «җыен юк-бар» дигән мәгънәне белдерүче латин сүзеннән ясалган термин. Ул — көлүнең бер төре; усал һәм ачы итеп көлүне аңлата. Тискәре, гарип күренешләрне, кешеләрдәге яман гадәтләрне фаш итү алардан үтергеч көлү ярдәмендә эшләнә. Чынбарлыкны сәнгатьле чагылдыруның үзенчәлекле бер төре. Әгәр дә юмор еш кына гафу итү, мәрхәмәтлелек сыйфатларына да ия булса, канәгать елмаю уятса, сатира, киресенчә, үткерлеге, мәрхәмәтсезлеге белән аерылып тора. Ул көлә торган эш-хәлне чынбарлыкка үткәрмәү, кабул итмәү рухы белән сугарылган була.

«Банкрот» комедиясендә, нигездә, сатирик конфликт ята, ягъни Сираҗетдиннең үз файдасы өчен алып барган көрәше автор тарафыннан мыскыл катыш көлеп күрсәтелә. Сатирик образ үз асылыннан бик нык арттырылган, күпертелгән булуы белән аерыла, анда гипербола һәм гротеск төсмерләре, бизәкләре зур роль уйный. Чыннан да, Сираҗетдиннең үзен юләрләрчә тотуында, акылдан язган булып кылануында гына да күпме арттыру бар.

Гафур Коләхмәтов
(1881—1918)

Үзе ышанганнарны, үзе инанганнарны каләме белән генә түгел, ә кулына корал тотып та яклаган язучылар бар. Инглиз шагыйре Байрон, венгр Шандор Петёфи, чех Юлиус Фучик, татар Муса Җәлил — шундыйлардан. Югары идеалы өчен үлемнең күзенә туры карый алган мондый шәхесләр рәтенә Гафур Коләхмәтовны да кертергә кирәк. 37 яшьлек кыска гына гомерендә ул язучы һәм көрәшче буларак өлгереп җитә. Бу язучы дөньяви карашлары һәм гамәли эшчәнлеге белән дә, әдәби иҗаты белән дә тарихыбызда сизелерлек эз калдырды.

Тормыш юлы

1881 елның 5 маенда Пенза шәһәрендәге сабын, шәм, хушбуй һәм бизәнү-ясану әйберләре заводы хуҗасы Юныс Коләхмәтов һәм аның хатыны Газизә гаиләсендә бишенче бала дөньяга килә. Аңа Габделгафур дип исем кушалар. Озакламый Юныс агайлар бөлә, гаиләгә фәкыйрьлек килә. Гаилә башлыгы төрле җирләрдә ялланып эшли: бер хуторда идарәче (управляющий), икенчесендә бакчачы була, аннары Казанга килеп, сабын заводларының берсенә мастер булып урнаша. Аңарчы мәдрәсәдә укыган Гафур 1898 елда Казандагы Татар укытучылар мәктәбенә имтиханнарын уңышлы тапшыра һәм мәктәпкә казна исәбенә укырга кабул ителә.

Шушы чорда бу мәктәптә татар мәдәниятенең киләчәген тәшкил итәчәк яшьләр күп укый: Гаяз Исхакый, Хөсәен Ямашев, Галимҗан Сәйфетдинов, Габделкаюм Коләхмәтов һ. б.

Аларны үз милләтен мөстәкыйль итеп, хезмәт иясен азат һәм бәхетле итеп күрү теләге берләштерә. Мондый ирекләрне патша хакимияте бирмәячәге ачык иде. Социализм тәгълиматчылары исә күңелләрне җәлеп итәрдәй шигарьләр белән чыктылар. Барлык милләтләрнең тигезлеген тәэмин итү вәгъдәсе шуларның иң көтелгәне иде (дөрес, хакимиятне кулларына алгач, большевиклар үз сүзләрендә тормадылар). Менә шуның өчен бу яшьләр социализм идеяләренә тартылалар, яшерен төстә инкыйлаби әдәбият укыйлар, социал-демократик түгәрәк оештыралар. Мәктәптә укуының соңгы елында инде Гафур сыйнфый көрәш һәм кешелекне азатлыкка чыгару мәсьәләләрендә ныклы бер карашка килә. Моны түбәндәге мисал раслый. 1902 елның башларында булган бер сөйләшүдә Гафур Коләхмәтов география укытучысына укучылар алдында: «Без, социалистлар, сезнең өркетүләрегездән бер дә курыкмыйбыз!» — дип җавап бирә.

Гадел социализм карашларын пропагандалау Г. Коләхмәтовның яшәү максатына әверелә, һәм ул бар гомерен шуңа багышлый. Публицистик мәкаләләрендә һәм гыйльми хезмәтләрендә дә, әдәби әсәрләрендә дә, гамәли эшчәнлеге белән дә ул сыйнфый тигезсезлеккә каршы чыга, кешеләр тигез булырга тиеш, дөньяның хуҗасы — хезмәт иясе, дип раслый.

Укытучылар мәктәбен «яхшы» һәм «бик яхшы» билгеләренә тәмамлагач, Гафур Коләхмәтов Казандагы өч сыйныфлы Пороховой рус-татар училищесына укытучы һәм мөдир итеп билгеләнә. Монда ул 1912 елга кадәр укыта. Эшчеләр белән даими аралашып яшәү аны пролетариат идеологиясенә тагын да якынайта. Ул марксистик әдәбиятны өйрәнә, инкыйлаби эчтәлекле мәкаләләр һәм прокламацияләр яза. Үз инануларын Г. Коләхмәтов махсус әдәбият ярдәмендә тарату белән генә чикләнми. Кирәк вакытта идеяләренә тугрылыгын эшгамәле белән дә раслый. Ә моның өчен мөмкинлек 1905 елның көзендә Казандагы инкыйлаби вакыйгалар барышында туа. 19 октябрьдә шәһәр Думасы янында күп мең кешеле митинг булып, чыгыш ясаучылар халыкны көрәшкә күтәрелергә чакыралар. Сугышчан дружиналар оештырыла, халык шәһәрнең хуҗасына әйләнә. Әмма бу озак бармый: 21 октябрьдә хөкүмәт гаскәрләре һөҗүм башлый. Сугышчан дружиналар управа бинасына бикләнеп каршылык күрсәтәләр.

Алар арасында Г. Коләхмәтов та була. Кулына корал тотып, карагруһчыларга һәм патша гаскәрләренә каршы сугыша. Баш күтәрүчеләр белән бергә ул да кулга алына, айга якын төрмәдә утырып чыга. Моннан соң инде ул гел жандармерия күзәтүе астында яши, ләкин көрәштә катнашуын туктатмый. Эшчеләр арасында Россия большевикларының «Искра» һәм шулай ук сыйнфый көрәшне яклаучы татарча «Урал» газеталарын тарата, аларда басылган мәкаләләрнең эчтәлеген аңлата. Аның язганнары «Азат» һәм «Азат халык», «Урал» газеталарында басыла.

1912 елдан Г. Коләхмәтов — Казандагы «Касыймия» мәдрәсәсе каршындагы рус теле сыйныфында укытучы һәм мөдир. Әмма бу елларда аның электән килә торган үпкә авыруы көчәеп китә. Ул ике мәртәбә Кырымга һәм Кавказга барып дәваланып кайта. Ахырда, 1916 елның азагында, хезмәтеннән бөтенләй чыга һәм хәзерге Мордва Республикасының Торбеево районы Юнә авылына китә. Авылда да Г. Коләхмәтов иҗтимагый эшчәнлеген дәвам иттерергә тырыша. Мәсәлән, аны Пенза губернасыннан Уфадагы Милли Мәҗлескә депутат итеп сайлыйлар. Аңар шундый зур ышанычны юкка гына күрсәтмәгәннәр, билгеле.

Авыру үзенекен итә: 1918 елның 1 апрелендә Гафур Коләхмәтов үпкә авыруыннан вафат була. Аның җәсәде Юнә авылы зиратына күмелә.

Азатлык фикерләрен яклап

Кешеләр бер-берсенә кол булмаска, тигез булырга тиешләр.Бу фикер кешелек җәмгыятен элек-электән кызыксындырып килгән. Ул күпчелек тәгълиматларда, шул җөмләдән дини тәгълиматларда да, ачык итеп куела. Социализм тәгълиматының да нигезендә шул ята. Монда инде тигезлек идеясе сыйнфый җирлеккә утыртылган. Марксизм исә күптәнге кешелек хыялын аерым бер сыйныф — пролетариат ноктасыннан торып хәл итүне алга сөрә, ягъни кешеләргә тигезлекне иң алдынгы сыйныф булган пролетариат кына яулап алырга сәләтле, дип куя.

Г. Коләхмәтов — иманы нык кеше. Үзе инанган идеяләргә ул гомере буена тугрылыклы. Һәм аларга бүтәннәрне дә ышандыру өчен, ул көчен дә, сәләтен дә кызганмый. Азатлык фикерләрен халык арасында тарату өчен, Г. Коләхмәтов иң әүвәл

публицистлык куәтен эшкә җигә. Ә бу эш тәрҗемәдән башлана: 1904 елда «Һәр хезмәтче (эшче) ни нәрсә белергә һәм ни нәрсә исендә тотарга тиешле?» дигән хезмәтне русчадан татарчага тәрҗемә итә. Бер елдан соң илдә социалистик җәмгыять һәм демократик республика төзү юнәлешендә эшчеләрнең бурычларын аңлаткан прокламацияне, «Ахыргы заман» дигән брошюраны татарчалаштыра, алар берничәшәр йөз данә басылалар, алдынгы зыялылар һәм эшчеләр арасында таратылалар. Аннан соң инде үзе дә прокламацияләр, мәкаләләр яза, аларны тарата, газеталарда бастыра. Бу мәкаләләрендә социал-демократик фикерләр уздыра, татар җәмәгатьчелеген өлгергән мәсьәләләргә, мәсәлән, хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсенә игътибар итәргә өнди. Кешелек җәмгыятенең тууын һәм үсешен материалистик нигезләрдә аңлатып, берничә кисәктән торган «Тарих сәхифәләре» дигән хезмәт яза. Бу хезмәтнең «Тарихтан әүвәл адәм балалары», «Әүвәлге мәмләкәтләрнең урыннары һәм халык», «Мисыр» исемле кисәкләре китаплар булып басылалар. Укытучы буларак та ул аерым фәннәр буенча хезмәтләр һәм методик кулланмалар язып бастыра («Ысулы тәгълим хисап» һ. б.).

Әдәби иҗаты

Публицистика һәм фән өлкәсендәге, инкыйлаби эшчәнлегендәге кебек үк, әдәби иҗатында да Г. Коләхмәтов азатлык һәм тигезлек фикерләрен алга сөрә.

Монда, беренче тәҗрибәсе итеп, «Уалган мол» нәсерен (1906) күрсәтергә кирәк. Ул — русчадан тәрҗемә. «Разрушенный мол» балладасында аллегорик образлар ярдәмендә азатлыкка каршы торучы явызлыкның күмәк көч тарафыннан җиңелүе сурәтләнә. Диңгездә дулкыннар башта ирекле булганнар. Ләкин явыз тиран, аларның хөрлегеннән көнләшеп, юлларына зур корылма — мол ясаткан. Әлеге эшне башта көлеп кенә күзәткән дулкыннар тора-бара молның үз ирекләрен чикләүнең ни икәнен аңлап алганнар, хөрлекләренең дошманы икәненә төшенгәннәр һәм, аннан котылу өчен, көрәшкә күтәрелгәннәр. Алар санап бетергесез күп мәртәбәләр һөҗүмгә ташланганнар, корбаннар биреп, кире чигенгәннәр. Ләкин бертуктаусыз һөҗүм итү барыбер үзенең нәтиҗәсен биргән: мол җимерелгән, дулкыннар янә хөрлек алганнар. Нәсернең мәгънәсе тирән. Ул кешеләрне патша Россиясендәге

тормыштан риза булмаска, аны үзгәртергә чакыра. «Үлгәннәргә дан! Терекләргә ирек!» — дип, дулкыннар азатлык өчен көрәшкә өндиләр. Әсәрнең азагы символик мәгънәне бигрәк тә ачык чагылдыра: «Бу хикәяне уйлап шаккатып тордым. Шатланып тәгәрәп йөри торган дулкыннарга мин хозурланып карадым...

Өстемдә якты күк, астымда киң диңгез. Бу диңгезнең дулкыннары май аендагы кояш илә уйнап тәгәрәп йөриләр...

Еракдыйн шәһәрдәге халыкның кызганыч тавышлары ишетелә... Кара төтен күренә... Аяктагы чылбырлар бәрелүе ишетелә...

И кызганыч тавышлар, кызганыч тавышлар!..

. . . .

Колагыма ерактагы давылның тавышы ишетелгән кеби була...

И кызганыч бәндәләр, кызганыч бәндәләр!..»

Ә шулай да кеше кайчан үзен тулысынча азат һәм хөр дип саный ала? Бу фәлсәфи сорауга Г. Коләхмәтов 1906 елда «Ике фикер» исемле драмасында җавап бирә. Җавапны эзләү, асылда, Давыт образы ярдәмендә эшләнә. Моның өчен драматург бик тә тапкыр эш иткән: Давытның хакыйкатьне эзләп бәргәләнүен аның фикерләре көрәше рәвешендә бирә, ә ул фикерләрне кеше кыяфәтенә кертә. Ягъни Давыт фикерләрен персонажлаштыра, аллегорик образлар тудыра. Кызыл һәм Кара фикер дип аталган менә шул ике персонаж, үз хуҗалары булган Давытны тулысынча яулап алу өчен, үзара тартышалар. Көрәш Кызыл фикернең җиңүе, Кара фикернең җиңелүе белән тәмамлана.

Кеше җәмгыятьтә яши, ул иҗтимагый мөнәсәбәтләрне үзендә чагылдыра. Давыт — зыялылык ягыннан бай һәм эзләнүчән шәхес. Шуңа күрә аның кеше турында, аның җирдәге урыны, яшәвенең мәгънәсе хакында, үзенең әйләнәтирәсе, ягъни мохите мәсьәләсендәге уйланулары бик табигый.

Кара фикер Давытны «бәндә», «кол» дип атый. Аны үзе өчен генә кайгыртып яшәргә өнди, тыныч һәм рәхәт, тук тормыш белән кызыктырырга тырыша. Кызыл фикер, киресенчә, җиңел, рәхәт тормыш вәгъдә итми, үзе артыннан барганда аның юлы авыр һәм газаплы булачагын кабат-кабат искәртеп тора. Ләкин нәкъ менә шул юлда ул яшәвенең мәгъ-

нәсен табачак, аның гомере бай булачак, кешеләргә бәхет һәм азатлык яулап алуда катнашуы белән ул үзен бәхетле санаячак. Әнә бит Кызыл фикер Давытка «адәм», чын мәгънәсендә «кеше» дип дәшә. Шунысы да мөһим: кешене үзенә сүзсез буйсындырырга омтылган Кара фикердән аермалы буларак, Кызыл фикер Давытны үзенчә фикер йөртергә өйрәтә, мөстәкыйль һәм хөр булырга өнди.

Кызыл һәм Кара фикерләр — кеше рухы өчен көрәшүче ике көчнең чагылышы. Алар вәгъдә иткән тормыш әле киләчәктә булачак: идеалдагы якты тормыш та (Кызыл фикерчә), рәхәт-тук тормыш та (Кара фикерчә) — әлегә фараз гына. Хәер, гамьсез һәм тук тормышның кайбер чалымнары моңарчы Давыт яшәгән мохиттә күренә иде. Егетнең әүвәлге дуслары шул тормыштан, яшәүнең шул рәвешеннән канәгатьләр. Беренче карашка, чыннан да, монда барысы да яхшы кебек. Мәдәният ягыннан бераз алга китеш бар. Яшьләр рус һәм Европа мәдәниятенең йогынтысын тоялар. Бөтенесе дә вакытлы рәхәтлеккә һәм буш күңел ачуларга корылган. Әмма Давыт инде болай яшәүнең кеше табигате өчен зарарлы булуын аңлый башлый, чөнки үзләрен зыялыга санаучы бу яшьләр миллионнарча хезмәт кешеләренең, ачлар һәм ялангачларның газаплы тормышын белмиләр, белүне дә кирәксенмиләр.

Тора-бара Давыт кешенең җәмгыятьтә тоткан урыны, яшәүнең эчтәлеге һәм максаты турында күп уйлану, фикерләр көрәше аша бары тик Кызыл фикер күрсәткән юл гына чын хакыйкатькә ирештерәчәк икәненә төшенә. Моңар ул җирдәге иң камил җан иясе булган кешенең фәлсәфи һәм реаль асылын, төп яшәү максатын һәм рухи мәгънәсен аңлау ярдәмендә килә. Реаль мохитне кире кагып, Кызыл фикер аның алдына инкыйлаби эчтәлекле тормыш идеалын куя. Ул егетне фикердә дә, эштә дә хөрлеккә өйрәтә. Бу исә шәхеснең рухи коллыктан котылуының башы булып тора. Шулай да бу гына җитми әле. Кызыл фикер халыкка ышанырга, аның белән һәрчак бергә булырга, аның язмышын уртаклашырга чакыра: «Гавам[1] үзенә чын һәм рәхәт тормыш тудырыр өчен алга бара... Адәм, син берәүгә дә сукыр килеш ышанма. Үзең уйла, үзең аңлап тап та гавам белән бергә хакыйкатьне

---

[1] *Гавам* — масса, халык.

эзләргә барырсың... Шул юл белән барганда гына, син дөньяда үзеңә рәхәт табарсың!»

Мәгърифәтчеләр дә уку һәм белем ярдәмендә җирдә тигезлек хөкем сөргән, гаделлеккә корылган җәмгыять төзүне максат иткәннәр. Ләкин бу гына җитми, дип куя мәсьәләне драматург. «Әйе, укыгач күпне беләсең икән,—диде Давыт.— Ләкин күзем ачылган саен, фикерем киңәйгән саен, шатлык, тынычлыклар урынына башым төрле кайгылар, хәсрәтләр белән тула бара. Шул хәсрәтләр, шул кайгылар белән йөрәгем янган саен, үземнең яшәвемдә бер ләззәт табам, тормышымда бер ямь сизгән кебек булам. Шулай... Җанлы багана булып яшәүгә караганда, кайгы-хәсрәтле ут эчендә яшәү мең өлеш артык! Югыйсә дөньяга туунын мәгънәсе дә булмас иде!» Бу — фәлсәфи йомгак, ул «кеше үзенең дөньяда торуын бары тик актив төстә эш-хәрәкәт итеп, көрәшеп кенә аклый ала» дигән тәгълиматны чагылдыра.

Давытның көрәшче булырга әзерлек юлын җентекле сурәтләү аркылы автор хезмәт иясенең азатлыкка омтылышын күрсәтә. Көрәшче психологиясенең эчке көчләрен аңлатып бирә. Персонажның бу юлы тагын да ышанычлырак булсын өчен, Давытның төш күрү күренешен кертә. Төштә халык массаларының үзләрен изүчеләргә каршы сугышы күренә.

Шулай ук Галия исемле аңлы, укымышлы кызның Давытның карашларын уртаклашуын, аларның уртак тел табуларын, ахырда көрәш юлына бергәләп аяк басуларын сурәтләү дә мәгънәле. Шуның белән азатлык фикерләренең акрынлык белән булса да җәелә баруы күрсәтелә.

Әсәр аллегорик сурәтләүгә корылган булса да, анда тормышчанлык көчле. Яшьләрнең күңел ачулары, мәзәк хәлләр сөйләшүләре кебек гадәти күренешләр драманың тормышчан җирлеген арттыра. Катлаулы мәсьәләләрне чишүгә багышланган һәм фәлсәфи мәгънәләр белән эш йөртүгә корылган булса да, «Ике фикер»нең теле гади һәм халыкчан, җанлы һәм үтемле.

Әйтергә теләгән төп фикере белән дә, образлар системасындагы үзенчәлекләре белән дә «Ике фикер» драмасы татар әдәбиятына зур яңалык алып килде.

Татар җәмәгатьчелеген борчып торган мәсьәләләрне чагылдыруын Г. Коләхмәтов үзенең икенче сәхнә әсәре булган «Яшь гомер» драмасында да дәвам иттерә. Ул 1908 елда

басылып чыга. Матбугат битләрендә аның хакында күп санлы мәкаләләр һәм бәяләмәләр басыла.

Драматург буларак, Г. Коләхмәтовның тагын ике әсәр язганлыгы мәгълүм. «Әбүҗәһел» дип аталган драмасының бары тик кечкенә өлеше генә безгә килеп җиткән. Әсәрдә сүз Мөхәммәт пәйгамбәрнең ислам динен таратудагы эшчәнлегенә җаны-тәне белән каршы көрәшкән Әбүҗәһел турында бара. 1908 елда язылган бу әсәр 1910 елда типографиядә инде өч пәрдәсе басарга әзерләнеп беткәч кире кагыла. Моны дин әһелләре таләп итәләр. Алар драма ислам дине канун-нарына каршы чыга, дип карыйлар. Әйе, социализм тәгълиматының дини инануларга каршы көрәшүен халык беркайчан да хупламады.

Язылганлыгы турында хәбәрләр булып та, бүгенгәчә кульязмасы табылмаган «Кем гаепле?» пьесасы Г. Коләхмәтовның драматургия өлкәсендәге иҗаты киң колачлы булуы турында сөйли.

Болардан тыш, Г. Коләхмәтов — берничә хикәя авторы. «Ник уйгандым?!» исемле сатирик хикәясе аның иҗатында аерым бер урын тота. Иң әүвәл сатираны үзенчәлекле файдалануы белән. Әсәрдә тук-рәхәт яшәүче бер бозык зат сурәтләнә. Ул төшендә үзенең кылган гөнаһлары өчен тәмугка, аннары могҗиза аркасында җәннәткә ирешүен күрә, хур кызлары белән ләззәтләнгәндә генә уянып китеп, ул боларның төш кенә икәнен белеп үкенә: аның җәннәттә каласы килә. Ул дөньялыкта никадәр күп гөнаһ кылган, алар аның хәтерендә яңаралар.

Күрәбез, бу кешенең яшәү рәвеше кешелек кануннарына да, дини өйрәтүләргә дә сыешмый. Хәер, ул аны үзе дә аңлый: әнә бит аның бу дөньяга кайтасы килми, үлгәч үзенең җәннәткә эләкмәячәген, җәһәннәм кисәве булачагын белеп кайгыра...

Шулай итеп, иҗат гомере нибары 10 елга гына сузылган Г. Коләхмәтов төп көчен һәм вакытын хезмәт иясен азат итү өчен көрәшкә, татарча инкыйлаби эчтәлекле, ягъни сәяси әдәбият тудыруга сарыф итүе өстенә, 4 драма, 2—3 хикәя яза, күп санлы әсәрләр һәм хезмәтләр тәрҗемә итә, публицистик мәкаләләр һәм рецензияләр бастыра. Иң мөһиме — язучы әсәрләренең идея-сәнгать дәрәҗәсенең югары булуында, аларның үз чоры һәм үзеннән соңгы татар әдәбиятына һәм сәнгатенә ясаган уңай тәэсирендә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Язучы биографиясендәге төп моментларга тукталып, аның тормыш һәм иҗат юлын сөйләп бирегез.

2. Г. Коләхмәтовны ни өчен «көрәшче язучы» дип атап була?

3. Г. Коләхмәтовның публицистик эшчәнлеге турында сөйләгез. Аның публицистикасында төп темалар нидән гыйбарәт?

4. Г. Коләхмәтовның әдәби иҗатына күзәтү ясагыз.

5. «Ике фикер» драмасын өйдә укып килегез. Кара һәм Кызыл фикерләргә автор биргән характеристиканы үзара чагыштырыгыз. Давыт белән Галияне үзара нәрсә якынайта?

6. «Давытның көрәшкә килү юлы» дигән темага фикер алышыгыз һәм инша языгыз.

«Яшь гомер»

(*1908*)

Тартышу нидән гыйбарәт?

«Яшь гомер» — ифрат үзенчәлекле драма. Аның үзенчәлеге иң әүвәл ике катлы әсәр булуында, берьюлы ике теманы колачлавында күренә. Авторның тоткан кыйбласы һәм әсәрнең төп асылы — азатлык фикерләренең халык арасына үтеп керү хәрәкәтен күрсәтү, гаделлек өчен көрәш карашларын тарату. Моның зарурлыгын ул татар җәмгыятендә яшәп килгән искелекләрдән, тормыштагы җитешсезлекләрдән котылуда күрә, ләкин патша цензурасы шартларында моны күрсәтүне ачыктан-ачык эшли алмый.

Беренче карашка, пьесада вакыйгалар Зөләйханы үзенеке итү теләгеннән чыгып алып барылган көрәш рәвешендә оешкан. Кызга бай малае Мостафа өйләнерме, әллә иптәшләре ярдәмендә аны Гали коткарырмы? Дөресен әйткәндә, Мостафа кыз өчен көрәш алып бармый. Моның өчен аның байлыгы эшкә җигелгән. Байлыкка кызыккан әтисе Зөләйханы аңа бирергә хәл иткән инде. Кызны коткарырга теләп, көрәшне Гали алып бара. Ләкин монда егетнең мөмкинлекләре бик чикле. Аның кулында төп көч булырлык капитал юк. Шуңа күрә дә аның көрәше сүз белән үгетләүгә, кызга алдынгы фикерләрне сөйләп аңлатуга, шуның белән аны качып китәргә әйдәүгә кайтып кала. Тартышу, аңлашыла ки, Мостафа файдасына, ягъни капитал ягына хәл ителә.

Бу — пьесаның бер катламы. Аның артында тагын икенче каты бар. Монысы революционерларның патша хакимиятенә каршы кылган эшләрен күрсәтүдән гыйбарәт. Бу көрәшнең ахыр нәтиҗәсе укучыга мәгълүм булмый кала, ләкин аның ничек баруы, авырлыгы һәм килешмәүчән сыйфаты шактый үтемле итеп тасвирлана. Вәли һәм Гали халык арасында агарту эшләре алып баралар, аларга Йосыф та булыша. Аларның бу эшләре әсәрдә бик үк ачык күренми: кайдадыр митинг уздыралар, ниндидер тыелган хезмәтләрне тәрҗемә итәләр... Аларның эшләре хәвефле: төрмәгә эләгүең бар. Һәм ул шулай була да: Гали кулга алына, 6 ай төрмәдә утырып чыга. Бу көрәшнең сәбәпләре ачык, ул әсәрдә каткат әйтелә: хезмәт иясе төрлечә изелә, кеше азат түгел, байлар ярлылар исәбенә яшиләр, хатын-кыз хокуксыз, завод-фабрикалар ябыла, эшсезләр арта, татарлар мәдәният ягыннан артта һ. б.

Г. Коләхмәтовның осталыгы да шунда: ул бу ике сызыкны бик табигый төстә бергә берләштергән һәм укучыны-тамашачыны кызыксындырып торырлык вакыйга тудырган. Драмадагы бу үзенчәлеккә, әле әсәр басылып чыккач ук, бәяләмә язган (1908 ел, 19 май) Фатих Әмирхан да игътибар иткән. «Монда автор әсәренең күбрәк өлешен азатлык хәрәкәтендә катнашкан татар яшьләре тормышына багышласа да,— дип яза ул,— иске тормышның да кайбер җимешләрен күрсәтергә өлгерәдер».

Кайсы мөһимрәк?

Вакыйгаларда катнашу дәрәҗәсе буенча әсәрнең баш каһарманы итеп Галине санарга кирәк. Дөрес, икенче һәм соңгы пәрдәдә ул күренми, аның турында сүз генә булып ала. Ләкин персонажларны барлык пәрдәләрдә дә катнаштыруны автор максат итмәгән. Әнә бит катнашучылар исемлегендә беренче итеп Мостафаны атый. Ләкин Мостафа үзәк каһарман түгел, вакыйгаларда хәлиткеч роль дә уйнамый, икенче һәм бишенче пәрдәдә генә күренә.

Хикмәт, әлбәттә, барлык күренешләрдә дә катнашу-катнашмауда түгел. Иң мөһиме, Гали — иң тулы ачылган образлардан берсе. Драматизмның көчен дә аның борчылуэзләнүләре һәм Зөләйханың аяныч хәле билгели. Галинең психологик кичерешләрендә без пролетар революция бары-

шындагы «авырткан урынны» да күрәбез. Ул да булса, бөтен хезмәт иясен сыйнфый яктан азат итү өчен барган көрәш вакытында аерым шәхесләрнең теләк-омтылышларына битарафлык күрсәтеп, алар белән исәпләшмәү. Ягъни революциянең гомуми бурычлары артында аерым шәхес мәнфәгатьләренең күмелеп калуы. Менә шул мәсьәлә «Яшь гомер»дә сәнгатьле чагылыш таба.

Гали Зөләйханы ярата. Башта ул үзен кызга «гыйшык тотмыйм, әмма сөям... шул гына» дип юата. (Күрәсең, егет өчен сөю белән гыйшык тоту арасында аерма бар. Сөюне ул кызгануга тиң бер хис дип аңлый, ахрысы.) Вәли аны шелтәли: «130 миллион Русия кешеләре, шакшы җанияләре кеби, былчыракта коенып торган вакытта, халыкка хезмәт итәм дип, Зөләйханы коткара, имеш!» — дип аптырый. Аның өчен төп максат — барлык кешене бәхетле итү. Ләкин бит Гали дә моңа каршы түгел. Ул да — үзен азатлык көрәшенә багышлаган кеше. Шуның белән бергә, чын зыялы һәм инсафлы зат буларак, конкрет шушы очракта ул аерым шәхес язмышына да битараф кала алмый. Бик күп кызганыч хәлдәге кызлар арасыннан, ичмасам, Зөләйханы гына булса да коткарасым килә, ди ул. Ягъни бу очракта үзе яраткан кызның бәхетле булуы аның өчен барлык изелгәннәрне азатлыкка чыгару шикелле үк мөһим. Шуның белән ул Вәлидән күңел байлыгы белән аерылып тора, һәм шул хәл аңарда эчке кичерешләр тудыра да.

Икенче бер очракта да Галинең үзгәрәк рухлы булуы чагыла. Өченче пәрдәдә шундый күренеш бар. Өч иптәш сөйләшеп утырганда, урамнан каравыл кычкырган тавыш ишетелә. Менә шуңар аларның мөнәсәбәте бик үзенчәлекле. Участокта утырганда кандаланы «җан иясе бит» дип үтерергә кызганган Йосыф урамдагы кыйнашка канәгатьләнү белдерә, «сал берне!» дип дәрт биреп тора. Моның өчен, күрәсең, нигез дә бар. «Халыкны кыйнаганда яхшы идеме? Сал берне»,— дип хуплый Йосыф, һәрвакыт сабыр һәм төпле Вәли исә бу хәлне «менә кызык!» дип бәяли. Ә инсафлы Гали өчен бу алай түгел. «Кешене каны чәчрәп чыкканчы кыйнасыннар да, кызык булсын, имеш»,— дип рәнҗи ул. Әгәр дә кыйналучы йөзендә Йосыф сыйнфый дошманын гына күрсә, Гали өчен ул — иң элек, кеше, начар булса да, кеше! Һәм аңа кешечә мөнәсәбәт тә булырга тиеш!

Яңа мәгыйшәт каһарманнары

Яңа мәгыйшәтнең (тормышның) каһарманнары итеп Ф. Әмирхан Галине, Вәли һәм Йосыфны күрсәтә. Боларга хас уртак сыйфат — азатлык көрәшенә бирелгәнлек. Шул ук вакытта «...зыялы вә кадердә үскән яшь белән дөньяның һәртөрле михнәтләрен башларыннан уздырган эшчеләр арасында бик зур аерма да бар», ди атаклы язучы. Олы максаты белән шәхси теләк-омтылышлары арасында бәргәләнгән Галинең эчке кичерешләре турында алда сүз булды инде. Бу яктан Вәли — бербөтен характер. Аның бөтен эш-хәрәкәте азатлык көрәшенә буйсындырылган. Ул укучы хәтеренә иң беренче шул ягы белән тыныч һәм сабыр холыклы, акыллы кеше булып кереп кала. Иптәшләре турында кайгыртучан, ярдәмчел булуы да аңарга карата җылы хисләр уята. Гали төрмәгә эләккәч, аның карчык анасы бу кайгыны күтәрә алмый, авырып урынга егыла. Шул вакытта аны тәрбияләү, үлгәч җирләү кебек мәшәкатьләрнең барысын да Вәли үз җилкәсенә ала.

Йосыф та ярдәмчел, иптәшләре өчен барысын да эшләргә әзер тора. Шуның белән бергә, аңа бунтарьлык сыйфаты да хас. Ул бераз хәмер эчәргә дә ярата, авызына шайтан суы керсә бәйләнеп тә ала, уендагысын һич курыкмый сөйли. Әмма никадәр исерек булса да, сөйләгәннәрендә аның «төтене» туры чыга. Эшченең, хезмәт кешесенең дөньядагы урыны, байлар белән эшчеләр арасындагы каршылык, байларның еш кына гаделсезлекләре турында сөйләнүләрендә пролетар идеологияне үз итүе ярылып ята.

Шулай итеп, бу өч образ ярдәмендә драматург зур сәяси көч булып оешып килүче эшчеләр сыйныфын гәүдәләндерә. Аның киләчәге зур булуына, яңа тормышның шушы көч белән бәйле икәнлегенә иманы камил. Эшче сыйныф әле беренче адымнарын гына атлый, ул әлегә кимчелекләрдән дә азат түгел. Аның идеологлары арасындагылар, Гали кебек, рухи чайкалулар кичерәләр, төп көче буласылары, Йосыф кебек, вакытларын һәм көчләрен әлегә юк-барга сарыф итәләр. Бу көчнең кайбер йомшак яклары да чагылып уза: үч алуга артык бирелгәнлек, гомуми эш өчен кайгыртуны гына алга сөреп, аерым шәхескә игътибар җитмәү һ. б. Драматург боларын да күргән. Шулай да киләчәк шушы сәяси көч белән бәйле, дип ышана ул.

Искелек корбаны

Драмада игътибар үзәгендә торган образлардан берсе— Зөләйха. Укучыны һәм тамашачыны иң әүвәл бу кызның кызганыч һәм фаҗигале язмышы җәлеп итә. Әсәрнең соңгы сүзләре дә аныкы: «Уф Алла! Бу ир белән гомеремне ничек үткәрермен!» Әлбәттә инде, газап эчендә үткәрер, изелер, матурлыгын да, кешелеген дә җуяр. Ихтимал, үзенең юньсезлекләренә риза булып тормаганы өчен, Мостафа аны талак кылып аерып җибәрер...

Зөләйха — фикерле кыз, дип бәяли аны Гали. Дөрес, фикерле булуы камил үк түгел, ди. Ни өчен? Чөнки Гали аңар күпме сөйләсә, аңлатса да, ул аның белән әтисе арасында адашып йөрүдән туктамый. «Әткәйләр һәм мулла бертөрле сөйлиләр, Гали икенче төрле сөйли,— ди Зөләйха үзе дә.— Әткәйләрнең сүзене аңлыйм, әмма Галинең сүзләрене ни сәбәптәндер аңлап бетерә алмыйм... Аңлап бетерә алмасам да рәхәтләнеп китәм. Чөнки ул шулкадәр матур һәм ләззәтле итеп сөйли, шулкадәр башымдагы фикеремне ача, аннан аерылсам, дөньяның бөтен кабахәтене күрә башлыйм. И Алла, кайсы мине хак юлга өнди: әткәйләрме, Галиме икән?..»

Зөләйханың бу хәлен аңларга була. Чөнки ул — искелек традицияләрендә тәрбияләнгән кыз. Ата-ана сүзеннән чыкмау аның канына сеңгән. Галинең хатын-кыз азатлыгы, хатын-кызның гаилә коруда, мәхәббәт мәсьәләләрендә ирләр белән тигезлеге турындагы сүзләре аның өчен бөтенләй дә яңа. Шулай да Зөләйха күп икеләнү-шикләнүләрдән соң Гали ягына басар иде, аның тәкъдимен кабул итәр иде. (Болай уйларга кызның менәзе мөмкинлек бирә, чөнки инде Мостафаның хатыны булганнан соң, без аның кайбер мәсьәләләрдә үз сүзендә нык тора алуын күрәбез.) Ләкин байлык басымы астында, ягъни акчага кызыгып, кызның әтисе үз хатынына катгый таләп куя: «Әгәр Зөләйха мин теләп бирә торган бай егеткә бармыйча, Гали белән качса, ул вакытта син гаепле булырсың. Шуның өчен сине һәммә балаларың белән өемнән куып талак итәрмен». Менә шул соңгысы кызны хәлиткеч адым ясаудан тыя. «Үзем рәхәттә торырмын дип, анамны актык көннәрендә утка салыйммы?»— дип сорый ул, һәм үзе үк җавап та бирә: «Ни булса да булыр, анамны бәладән коткарып, үземне утка салам». Менә шул миһербанлыгы,

якыннары өчен үзен кызганмавы Зөләйхага карата күңелдә ихтирамны тагын да арттыра.

Әлбәттә, мәсьәлә алай бик җиңелдән түгел, аны ансат кына, берьяклы итеп кистереп куеп булмый. Бу уңай белән Йосыф әйткән сүзләрдә дә дөреслек юк түгел: «Зөләйха әрәм булса ярый. Әмма анасы әрәм булса ярамый, имеш,— дип каударлана ул.— Соң, Зөләйха дөньяга үз рәхәтене күрми, кеше рәхәте өчен генә килгәнмени?!»

Зөләйха күңеленә Гали чәчкән яңалык орлыклары бөтенләй дә шытым бирми дип әйтеп булмый. Кызның менәзе ныгый, шәхес буларак ул үсә. Моны без бишенче пәрдәдә күрәбез. Бер очракны Зөләйха үзе сөйләп бирә. Мостафа аны ялангач көе фотога төшермәкче була, кыйный, ләкин теләгенә ирешә алмый — хатын чишенми. Татар хатыны өчен анадан тума ялангач көе рәсемгә төшү — үлем белән бер. Икенче очрак инде тамашачы күз алдында үтә. Мостафа хатынын сөяркәсе янына алып бармакчы, шуның белән иптәшләре алдында мактанмакчы була: менә без хатынны ничек кулда тотабыз, янәсе! Әмма ныклы каршылыкка очрый. Үзен хатын-кыз буларак та, шәхес буларак та кимсетүче бу түбәнлеккә Зөләйха риза булмый. Бернинди куркытулар да, үгетләүләр дә ярдәм итми. Шунда без Зөләйханың шәхес буларак үскәнлеген, авыр тормыш шартларында да кеше булып кала алырлык ныклыгын күрәбез. Ул инде иске тормыш тозагыннан ычкынып чыгар өчен өлгереп килә.

Тагын кайбер үзенчәлекләр

Пьеса тема һәм образлар ноктасыннан караганда әдәбиятка яңалык алып килде. Иске тормышның яраксызлыгы, сыйнфый азатлык, хатын-кыз азатлыгы темалары, эшче-революционерлар образлары, көрәшче-зыялы образы... Социализм тәгълиматының кайбер гадел өйрәтмәләрен гади тормыш күренешләре һәм җанлы образлар системасы ярдәмендә, җиңел, аңлаешлы итеп җиткерә алуы белән драма җитди сүз әйтте.

Шуның белән бергә, патша цензурасы шартларында бу алдынгы фикерләрне укучыга һәм тамашачыга җиткерү өчен, драматург кайбер читләтеп әйтүләргә, хәйләләргә дә барырга әзер. Шулар аркасында сәнгать ягыннан караганда әсәрдә аерым кимчелекләр дә бар. Мәсәлән, композицион төзелештә

бөтенлек җитеп бетми, өзек-өзек эшләнгән күренешләр һәм артык персонажлар урын алган һ. б. Әйтик, Зөләйха өчен көрәш сызыгы ягыннан килеп караганда, әсәрнең икенче пәрдәсе артык. Монда полиция участогы бүлмәсе күрсәтелә. Дөрес, патша хакимиятенә каршы көрәшнең кирәклеген дәлилләү ноктасыннан ул бик тә әһәмиятле. Бигрәк тә Йосыф һәм рус егете арасында булган сөйләшүдә сыйнфый көрәшнең зарурилыгы мәсьәләсе ачык аңлашыла. Бакчадагы күренештә үк пролетар бунтарьлык карашлары белән күренеп калган Йосыф монда инде азатлык фикерләрен шактый тирән үзләштергән кеше буларак ачыла.

Рус егете һәм рус кызы, пыялачы һәм кайраучы кебек образларга карата да шуларны ук әйтеп була. Гали — Зөләйха сызыгына мөнәсәбәтләре булмаса да, алар шактый җитди идея йөкләмәсе үтиләр. Рус егете һәм рус кызы сөйләшүеннән татарлар арасындагы аерым кимчелекле гадәтләрне, пыялачы һәм кайраучы диалогыннан илдәге иҗтимагый мохитне, эшчеләрнең авыр хәлен белеп каласың.

Драманың бишенче пәрдәсе үзенә бер аерым урын били. Зөләйха — Гали — Мостафа «өчпочмагы» инде оешып бетте, һәм кызның кемгә булуы мәсьәләсе хәл ителде. Беренче пәрдәдә үк инде үзенең бозыклыгы белән күренгән Мостафаның әшәкелеген монда тагын бер кат раслау кирәк идеме? Әллә бу пәрдә тагын да башка өстәмә йөкләмәләр үтиме? Бу сорауларга «кирәк» һәм «үти» дип җавап бирәбез. Драматургның тагын да бер максаты — хатын-кыз темасын сыйнфый көрәш яссылыгында хәл итү. Илдә хезмәт иясе тулаем кол хәлендә булганда, хатын-кыз да тулысынча азат була алмый. Бу фикерне автор теоретик планда, Вәли һәм Гали диалогында бик аңлаешлы итеп үткәргән иде инде. Ләкин шуны тормышчан күренешләрдә раслап та куярга кирәк. Соңгы пәрдә шуның өчен кертелгән. Гали сөйләгәннәрнең дөреслеге, Зөләйха үзенең беркатлылыгы белән «бәлкем, болар миңа кагылмас, мин бәхетле булырмын» дип өметләнгәннәрнең хаталыгы җанлы вакыйгаларда күрсәтелә. Укучы Галинең аерым кеше бәхете өчен тырышып йөрүләрен тагын бер кат бәяли. Шулай ук, инде алда әйтелгәнчә, Зөләйханың шәхес буларак үсүе дә бу пәрдәдә төгәлрәк күрсәтелә.

Драманың үзенчәлекләре турында сөйләгәндә, аның пролетар язучы М. Горький әсәрләре йогынтысында иҗат ителүен әйтеп үтәргә кирәк. Моны автор үзе үк пьесаның

керешендә искәртә. Аерым алганда, Йосыфның бакчадагы сүзләре белән Горькийның «Мещаннар» драмасындагы эшче Нил сүзләре арасында зур охшашлык бар. «Эшләүче кеше генә һәрнәрсәгә хуҗа!» — ди Нил. Йосыф участокта очраткан Рус егетнең шулай ук Горькийның аерым әсәрләрендәге, мәсәлән, «Тормыш төбендә» пьесасындагы персонажларга охшашлыгын да күрергә мөмкин.

Г. Коләхмәтовның тулы килеш безгә килеп ирешкән ике пьесасы стильләре һәм язылу үзенчәлеге ягыннан аерылалар. «Ике фикер» — фәлсәфи рухтагы шартлы-романтик драма, символик образларга һәм хәл-әхвәлләргә ия. Бу чын тормышчанлык билгеләре көчле булган «Яшь гомер»дә дә сизелә. Хәтта әсәрнең исеме дә символик мәгънәгә ия. Бердән, азатлык хәрәкәтенең яшьлегенә, тәҗрибәсезлегенә ишарә ителә. Язучы монда гомерләрен хезмәт иясе өчен файдалы эшкә һәм көрәшкә багышлаган кешеләрнең яшьлеге, инкыйлаби берләшмәләрнең беренче адымнары турында сүз алып бара. Бу — бик мөһим, мәгънәле деталь. Икенчедән, пьесаның атамасы яшьлеген газап эчендә үткәрергә мәҗбүр ителгән татар кызларының бәхетсез язмышын әйтеп тора. (Монда Зөләйханы гына түгел, беренче пәрдәдәге бакчада күренеп калган татар хатыны һәм татар кызы образларын да истә тотарга кирәк.) Кешегә гомер бер генә бирелгән кебек, аның яшьлеге дә бер генә килә. Аны ничек уздыру кешенең үзеннән дә, иҗтимагый сәбәпләрдән дә, мохиттән дә тора.

Ике драма арасында моннан тыш та уртаклыклар бар. Аларның иң мөһиме — бер үк мәсьәләләр хакында гамьләнү дәвам иттерелә. Мәсәлән, зыялыларның азатлык көрәшенә килүе һәм сыйныфлар көрәшендәге урыны Давыт һәм Гали образлары ярдәмендә тәмамланган төс ала. Яшьлекне халык файдасына багышлау турында да шуны ук әйтергә мөмкин. «Яшь гомер шулай ук буш үтәргә тиешмени?» — дип сорый «Ике фикер»дәге Галия. «Яшь гомер» драмасы үзенең образлар системасы һәм сюжет төзелеше белән шул сорауга тагын бер кат җавап бирә.

* * *

Пьесаның төп билгеләмәсе — сәхнәдә уйнау өчен язылган әсәр булуында. Дөрес, уку өчен генә язылган пьесалар да була. Шулай да пьеса атамасы белән берләштерелеп йөртелә торган драма, комедия, трагедия жанрларындагы әсәрләр

иң әүвәл сәхнәдә тулы гәүдәләнәләр, аларның идея-эстетик үзенчәлекләре спектакль уйналганда ачыла.

Һәр пьесаның үзенә генә хас төзелеше һәм стилистик үзенчәлекләре бар. Аларны без, гомумиләштереп, художестволы (сәнгатьчә) эшләнеш дип атыйбыз. Пьесаның сәнгатьчә эшләнешенә үзенчәлекләр хас, махсус алымнар һәм чаралар кулланыла. Мәсәлән, драматурглар, эчтәлекнең тәэсирле булуына ирешү өчен, художестволы детальләрдән киң файдаланалар. Мисал өчен, «Яшь гомер»дә күрше хатынының Гали янына адрес яздырырга керүен алырга мөмкин. Бу деталь ярдәмендә Галинең укымышлы, ачык күңелле, кешегә ярдәмчел булуы күрсәтелә. Халыкның русча укымышы начар булуына да ишарә бар. Яисә участок бүлмәсендә кибәккә (кандалага) Йосыфның мөнәсәбәте, тоткыннарның тәмәкесез интегүләре һ. б. детальләр дә сәнгатьлелек дәрәҗәсенә күтәреләләр.

Пьесаның сәнгатьчә эшләнешендә ремаркалар да зур роль уйный. Аларны автор күрсәтмәләре дип тә әйтеп була. Чөнки персонажларның кара-каршы сөйләшүеннән (диалогтан) торган төп текстка автор вакыйгаларда катнашучыларның үз-үзләрен тотышларын һәм хәрәкәтләрен, сөйләү рәвешләрен, уен бара торган урынны һәм вакытны һ. б. ны аңлата торган үз сүзләрен кертеп бара.

Пьесада афиша да мөһим роль уйный. Пьесаның алдында бирелгән катнашучылар исемлеген афиша дип атыйлар. Бу исемлек еш кына төп каһарманнарны атаудан башлана, аларның яше, җенесе, киенү үзенчәлекләре, аерым очракта холык үзенчәлекләре дә әйтелә.

Пьесада паузаларның да билгеле бер роле бар. Паузалар, сәхнәгә куйганда искә алу өчен, режиссёрга һәм актёрларга күрсәтмә булып торалар, персонажларның эш-гамәлендә күчешне, кичереш дәрәҗәсен күрсәтәләр, аерым күренеш-вакыйгаларның характерын билгелиләр.

Реплика — пьесада катнашучыларның бер-берсенә эндәшүләре, җавап бирүләре, бара торган вакыйгаларга мөнәсәбәтләрен белдерүләре. Икенче төрле әйткәндә, реплика — персонажның аерым сүзе яки кыска гына җөмләсе.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Яшь гомер» драмасының кыскача эчтәлеген үз сүзләрегез белән сөйләгез.

2. Драманың сюжет үстерелешен күзәтегез, төенләнешен һәм кульминацион ноктасын билгеләгез. Монда экспозициягә һәм вакыйгалар үстерелешенә нәрсәләр керә, чишелеш кайда?

3. Гали һәм Зөләйха мөнәсәбәтенә турыдан-туры карамый торган пәрдә, күренеш, персонаж һәм репликаларны аерып күрсәтегез. Алар әсәрдә нинди роль уйный?

4. Гали, Вәли һәм Йосыф образларына характеристика бирегез. Аларның яңалыгы нәрсәдә?

5. «"Яшь гомер" драмасында хатын-кыз темасы» дигән исем астында доклад әзерләгез.

6. Ф. Әмирханның бу драмага язган рецензиясен укыгыз. Андагы фикерләр белән сез килешәсезме?

7. Драмада сәнгатьчә детальләрне табыгыз, паузаларны күрсәтегез. Алар нәрсәгә хезмәт итә? Афишаның, ремаркаларның ролен мисаллар белән аңлатыгыз. Диалогларга, монологларга мисаллар китерегез. Аеруча мәгънәле репликаларны табыгыз, аларга салынган мәгънәви максатны аңлатыгыз. Нәрсә ул реплика?

8. «Гали — ике ут арасында» дигән темага инша языгыз.

XX ЙӨЗ БАШЫНДА БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Милләтнең балалар әдәбияты үсешенә карап, аның сүз сәнгатенең нинди дәрәҗәдә булуы хакында фикер йөртергә мөмкин. Татар әдәбиятында балалар өчен махсус әсәрләр иҗат итү XX йөз башында аеруча җанланды. Г. Тукайның шул заманда «Яңа кыйраәт» («Яңа уку китабы») һәм «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дигән дәреслек-хрестоматияләре басылып чыгу башка иҗатчылар өчен дә әйбәт үрнәк булды. Алар балаларга сүз сәнгате ярдәмендә белем һәм тәрбия бирүдә бик кирәкле җыентыклар булдылар.

Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, М. Гафури, С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Н. Думави, Н. Исәнбәт һәм башкалар балалар әдәбиятын үстерүгә зур тырышлык куялар. Балалар өчен махсус шигырь язуның матур үрнәген М. Гафури бирде. «Укучы кызга» шигырен (1906) ул үгет-нәсыйхәт бирү рәвешендә болайрак башлап җибәрә:

Йорт эче матурлана һәм нурлана сезнең белән,
И татар кызы, бүгеннән соң укы, бел, яз, өйрән.

Аның «Ата-ана» шигыре (1906) баланың иң кадерле кешеләренә самими мөнәсәбәтен хис-кичереш ярдәмендә җиткерүе белән укучыга көчле тәэсир ясый:

Сөямен чын күңел берлән үземнең әткәм-әнкәмне,—
Алар олуг, алар матур, алар дөньяда иң ямьле.

Балалар шигъриятенең үсешендә, әлбәттә, Г.Тукайның өлеше аеруча зур. Ул балалар өчен иҗат тәҗрибәсе туплагач кына яза башлый. «Ата илә бала» шигырен (1908) әлеге юлдагы беренче тәҗрибәсе дип исәпләргә мөмкин. «Сабыйга» (1909), «Эш беткәч уйнарга ярый» (1909), «Эш» (1909), «Эшкә өндәү» (1911) әсәрләре дә балаларга үгет-нәсыйхәт бирү рәвешендә язылган. Шагыйрь балаларны юк-барга ышанмаска, хезмәт сөяргә, үз алдыңа куелган максатка ирешмичә күңел ачу, җиңел тормыш белән мавыкмаска өнди. «Бәхетле бала» әсәрендә (1909) кешедә кече яшьтән үк булырга тиешле уңай сыйфатларны мактый. «Кышкы кич»тә дә (1909) шул ук фикер ята.

Г. Тукай үзенең нәни дуслары күңелендә миһербанлылык сыйфатлары тәрбияләнүен тели. «Бала белән Күбәләк»,

«Гали белән Кәҗә», «Шаян песи», «Кызыклы шәкерт» әсәрләре (1910) табигать, аның җанияләре белән аралашу вакытында балалар күңеленең яңа хисләр һәм уйлар белән баюын күрсәтеп бирүе белән кыйммәтле.

«Таз» исемле әсәрдә (1908) вакыйга бер авыл малае авызыннан сөйләнә. Таз — татар халык авыз иҗатында үзенең тапкырлыгы, һөнәрлелеге, уңган-булганлыгы белән еш очрый торган образ. Г. Тукай аның балалар дөньясындагы гәүдәләнешен бик оста, табигый итеп тасвирлый. «Су анасы» әсәре исә (1908) югары сәнгатьчә эшләнеше һәм гыйбрәтле фикере белән балалар күңелен яулады. Аның «Шүрәле» (1907), «Кәҗә белән Сарык хикәясе» (1909), «Япон хикәясе» (1909) кебек әсәрләре дә балалар күңелендә үз урынын алдылар. Г. Тукай, күргәнебезчә, балалар өчен язганда, үгет-нәсыйхәттән әкренләп сәнгатьчә сурәтләүгә күчә барды, шуның нәтиҗәсендә балалар әдәбиятын үстерүгә куәт өстәп җибәрде. Халык авыз иҗаты белән табигый бәйләнеш әсәрләренең үзенә җәлеп итү көчен арттырды. Авторы мәгълүм булган әкиятләр язуны да Г. Тукай үстереп җибәрде. Бу аның әдәбиятыбызга алып килгән тагын бер зур яңалыгы булды.

Дәрдемәнд тә балалар өчен әсәрләр язуны үзе өчен изге бурыч итеп санады. Ул иҗатының бу юнәлешен «Балалар, әйдә мәктәпкә!» шигыре (1908) белән башлады.

Балалар, әйдә мәктәпкә,
Әтәч кычкырды күптән!
Тезелегез, кил, рәткә,
Карады кояш та күктән!

«Сабый» исемле чәчмә шигырендә (1909) лирик герой балага карап соклана. «Бәллү» шигырендә дә шул ук хисләр:

Кил, гөлкәем,
Сөмбелкәем,
Йоклаек икәү!

Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәллү-бәү!

Балалар өчен язуда М. Гафури стиле дә үзгәрә. Ул табигать күренешләрен сурәтләүне үзәккә куя, шуны мәгърифәтчелек рухы белән сугара. Уку, белем алу балалар өчен иң изге эш буларак бәяләнә:

Уку белән бик тиз үтәр бу озын кыш,
Уйнап-көлеп бушка йөрмә, балам, тырыш.

Тырышуың аркасында кеше булсаң,
Милләтеңә күрсәтерсең шаять бер эш.

(«Кыш фасылы», 1907)

Зыя Ярмәки бу елларда балалар өчен матур-матур шигырьләр яза. «Ак каен» шигыре (1913) хәтта җыр булып та әверелде.

Нәҗип Думави балаларның күңел дөньясына шактый уңышлы, үтеп керә. 1911 елда, мәсәлән, ул, нәни дусларына багышлап «Балалар! Сезне мин ничек яратам», «Йомшак кына кар ява» дип башланган шигырьләрен, «Балалар сүзе», «Авыл балаларының яңгыр теләве», «Яңгыр соңында», «Ятим бала», «Мәктәп», «Беренче кар» кебек әсәрләрен иҗат итә. Шагыйрь балалар өчен китаплар чыгара.

Бу вакытта балалар шигъриятен үстерүгә шулай ук Сәгыйть Сүнчәләй, Нәкый Исәнбәт һәм башка шагыйрьләребез дә өлеш керттеләр.

Балалар өчен чәчмә әсәрләр дә иҗат ителде. Дәрдемәнд балаларга кечкенә күләмле хикәяләр язды. Алар, җыйнак булсалар да, балалар күңеленә яхшылык, игелеклелек орлыклары салу ягыннан бик олы вазифа үтиләр. «Ике туган», «Гали», «Бер хәзинә», «Нури белән Зәйнәп», «Басуда үскән күлмәк» әсәрләре бу җәһәттән аеруча әһәмиятле. Беренче карашка, гади генә булган нәрсәләрдән олы мәгънә китереп чыгару кебек, Дәрдемәнд каләменә хас хасият аларда да аермачык күренә.

Г. Ибраһимовның «Карт ялчы» хикәясендәге (1911) Сәфәр исемле малайның ярдәмчесез яшәүче ялгыз Шаһи картка булган мәрхәмәтле карашы да укучыларны битараф калдырмый. «Яз башы» хикәясендәге (1911) Салих — кыш буе мәдрәсәдә яткан малай — табигать уянып килгән бер мәлдә күңеленә килгән тирән кичерешләре белән кызыклы. Шуңа охшаш хәлне Шәһит Әхмәдиевнең «Ай алдады» хикәясендә дә (1913) күрергә мөмкин. Күк күкрәп, яшен яшьнәгән төндә урманда ялгызы калган малайның кичергәннәре үз-үзебезне җен-пәриләр белән куркытып яшәүнең кайчакта аянычлы нәтиҗәләргә китерүенә мисал була ала.

Сирәк булса да, Г. Исхакый да балалар өчен әсәрләр язды. Сез 7 сыйныфта аның «Кәҗүл читек» хикәясе белән таныштыгыз.

Ф. Әмирхан «Ул үксез бала шул», «Корбан» (1913), «Нәҗип» (1914) хикәяләрендә балаларның төрле халәтләрен сурәтли.

Фәхрелислам Агиев, Гали Рәхим, Гали Рәфикый, Нәҗип Думави, Садри Җәләл, Рәхим Баязит һ.б. балалар өчен әйбәт чәчмә әсәрләр иҗат иттеләр.

XX йөз башында Мәскәүдә «Тәрбиятел-әтфаль» (җаваплы сәркатибе Ф. Әмирхан), Казанда нәниләр өчен «Ак юл» (мөхәррире Ф. Агиев) журналларының чыгуы да татар балалар әдәбиятын үстерүгә зур этәргеч бирә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Милләтнең балалар әдәбияты булуының әһәмияте турында сөйләгез.

2. Г. Тукай балалар әдәбиятына нинди таләпләр куя, аның балалар әдәбиятын үстерүгә керткән өлеше турында сөйләгез.

3. Ничек уйлыйсыз: турыдан-туры үгет-нәсыйхәт бирү сәнгатьлелеккә ирешүгә ярдәм итәме, әллә киресенчәме? Г. Тукай иҗатыннан балаларга киңәш бирү рәвешендә язылган әсәрләрне табыгыз.

4. Г. Тукайның балалар өчен язган әсәрләрендәге тема төрлелеген күрсәтегез. Аларның һәрберсендәге сәнгатьчә эшләнеш үзенчәлекләренә игътибар итегез.

5. М. Гафури балалар өчен язган әсәрләрендә нинди мәсьәләләр күтәрә?

6. М. Гафури балаларның төп эше итеп укуны саный. Шулай дип әйтү дөресме?

7. Дәрдемәнднең балаларны яратучы шәхес булуын әсәрләре буенча дәлилләп буламы?

8. Балаларга чәчмә әсәрләр иҗат итүдә аеруча нәтиҗәле эшләгән каләм әһелләрен атагыз. Аларның әсәрләре турында сөйләшегез.

9. Ф. Әмирхан үз әсәрләрендә балаларның күңел дөньясын ачуга игътибар бирә. Моны сез аның әсәрләре буенча ничек итеп дәлилләр идегез?

10. Г. Тукайның «Исемдә калганнар» әсәре кайсы яклары белән әһәмиятле?

11. XX йөз башында балалар өчен нинди журналлар чыга? Хәзерге көндә балалар өчен нинди газета һәм журналлар бар?

ИҖТИМАГЫЙ ФИКЕР ҮСЕШЕ ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

Татар вакытлы матбугатының нинди авырлыклар белән тууы мәгълүм. «Ана телендә гәзитә чыгару өмиде — татар язучыларының күңелләрендә бик күп заманнар тик бер матур хыял гына булып асрап киленде. Бу турыдагы һәммә кузгалышлар, иске патшачылык идарәсенең каты кысуы аркасында, бер-бер артлы югала бардылар»,— дип язды Г. Ибраһимов. Әйе, олы язучыбыз хаклы. XIX гасыр буе, йөз ел дәвамында, татар вакытлы матбугатын булдыру өчен көрәш бара. Россия идарәчеләре бервакытта да, бер халыкка да сорап кына һичнәрсә бирмиләр. Кирәкле нәрсәләрне аннан бары тик көрәшеп кенә алып була. 1905 елгы инкыйлаби вакыйгалар нәтиҗәсендә татарлар күпләп яшәгән һәр төбәктә: Петербургта, Казанда, Оренбургта, Җаекта, Уфада, Хаҗитарханда (Әстерханда), Мәскәүдә, Самарада, Троицкида һәм башка урыннарда вакытлы матбугат барлыкка килә. Алар эшендә шагыйрь, әдип, драматургларыбыз, галимнәребез, дин әһелләребез һәм башка зыялыларыбыз бик якыннан катнаша. Бу эшнең әйдәп баручылары сафында ахун Г. Баязитов, башка дин әһелләре Муса Бигиев, Риза Фәхреддинов, Габдулла Апанаев, иҗади зыялыларыбыз Галиәсгар Камал, Камил Мотыйгый, Габдулла Тукай, Гафур Коләхмәтов, сәяси эшлекле Хөсәен Ямашев һәм башка бик күпләрне күрәбез.

Газеталарның һәммәсе дә диярлек, үзләренең төп юнәлешләреннән чыгып, татар халкының аяныч хәле, диннең, телнең, матди тормышның кысылуы, халыкның күпчелеген тәшкил иткән хезмәт ияләренең аеруча аянычлы хәле турында борчылып язалар. Әлбәттә, газеталарның үзәгендә публицистика (җәмгыятьтәге күренешләргә, хәл итәсе мәсьәләләргә укучыларның игътибарын җәлеп итүне күздә тотып язылган мәкаләләр, очерклар) тора.

«Казан мөхбире» газетасы бу яктан нык аерыла. Анда бик әзерлекле, үткен каләмле авторлар языша. М. Гафури 1907 елның 1 гыйнварында «1906 елның 1907 елга васыяте», ә 198 нче санында «1907 елның җавабы» дигән шигырьләрен бастыра. Публицистик шигырьнең иң әйбәт үрнәкләреннән саналырга хаклы әсәрләрне үз битләренә урнаштыруы әлеге газетаның кыюлыгы, сәяси йөзенең ачыклыгы, ягъни рәсми хакимияткә каршы булуын күрсәтә иде. М. Укмасыйның «Аяныч фәкыйрь» исемле шигыре дә шушы җәридәдә (газе-

тада) басылды. Г. Коләхмәтов та «Уалган мол» исемле тәрҗемә әсәрен укучыларга «Казан мөхбире» ярдәмендә җиткерде. Биредә әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм спектакльләргә бәяләмәләр дә еш урын ала. Бу җәһәттән Г. Кәрам (Габдрахман Рәхмәтуллин) мәкаләләре аерылып торалар.

Г. Апанаев чыгарып килгән «Азат» газетасы да бу яктан калышмый. Моны Г. Коләхмәтов һәм Х. Ямашевның үткен-үткен мәкаләләре күрсәтеп тора. Г. Коләхмәтов, халык тормышының үтә әһәмиятле якларын эләктереп алып, укучыларның күңелен кузгатырдай итеп яза. «Хатыннар мәсьәләсе», «Государственная думага пассив бойкот ясау», «Эш юктан» кебек мәкаләләре бигрәк тә игътибарга лаек. Автор Дәүләт думасына битарафлык күрсәтергә өнди, гаять авыр хезмәттә изелүче хатын-кызлар һәм балалар тормышы турында борчылуын белдерә, башка халыкларны басып алу сәясәтен алып баручы патша хакимиятенә дә өлеш чыгара.

Шулай ук М. Гафури, Г. Камал, Н. Думави, М. Укмасый «Азат» газетасы битләрен үзләрен һәм халыкны борчыган мәсьәләләрне үткенләндерү өчен оста файдаланалар. Мөхетдин Корбангалиев тә (соңыннан күренекле тел галиме) «Хөррияте шәхсия[1] ни нәрсә, һәм ул ни өчен кирәк?» дигән мәкалә бастыра. Анда кеше бәхетенең асылын ача, бәхетнең хөрлектән, чын иректән башка була алмавын дәлилли.

«Таң йолдызы» (мөхәррире С. Рәмиев) газетасының тоткан юлы үзенә бертөрле иде. Халык телендә язуы аның тагын бер үзенчәлеге булды. Моңа хәтта цензор да игътибар итә. Гади теле белән ул халыкка үз язганнарын тизрәк җиткерә дип борчылу белдерә, аның укучыларга ясаган көчле тәэсиреннән курка. Бу газетада Г. Исхакый күп язышты. Ул язмаларында татар милләтен азат, башкалар белән тигез хокуклы, дәүләтле итеп күрергә теләвен ассызыклап килде. «Ил», «Сүз», «Безнең ил» газеталарында да аның кайнарланып язган мәкаләләре күп басыла.

«Урал» газетасы исә (1907 елның гыйнварыннан чыга) җәмгыятьнең сыйныфларга бүленгәнлеген күрсәтүгә игътибар бирә. Аның битләрендә хезмәт ияләре өстен катлауларның хакимлеген көч куллану юлы белән тартып алырга, барлык җитештерү чараларына, икътисадка һәм сәясәткә хуҗа булырга тиеш дигән караш якланды. Бу газетаның башында Х. Ямашев торды.

---

[1] *Хөррияте шәхсия* — шәхси ирек.

«Йолдыз»ның баш мөхәррире Һади Максуди газетаны хакимиятнең ачуын бик кабартмаслык итеп алып барырга тырыша. Ул, татар җанлы кеше буларак, милләт мәнфәгатьләрен кайгыртучы язмаларны оста итеп урнаштыру юлларын таба. Мәсәлән, күренекле инкыйлабчы Х. Ямашев вафат булгач, 1912 елның 15 апрель санында Г. Тукайның «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» шигыре һәм Г. Камалның «Җеназа мәрасиме» исемле мәкаләсен урнаштыра. Аларда олы кайгы белдерелә. Шул ук вакытта әлеге битт̆ә Х. Ямашев шәхесенә бик үк уңай караштa тормаган берәүнең кечкенә генә бер язмасы бирелә. Шулай итеп, бер үк вакытта Х. Ямашевның шәхесенә зур бәя бирелә, аңа хәерхаһ булмаганнар барлыгы да күрсәтелә.

«Вакыт» газетасы да (Оренбургта чыга) талантлы каләм әһелләрен үз тирәсенә туплый, аларны иҗади үстерүгә әһәмият бирә. 1910—1916 еллар арасында Ш. Камал да биредә үзенең әсәрләрен һәм публицистик рухтагы мәкаләләрен дөньяга чыгара. Әлеге газетаның мөхәррире Фатих Кәрими 1912—1913 елларда Истанбулда тора, аннан хәбәрләр һәм төрле язмалар җибәрә. «Истанбул мәктүпләре» — шуларның иң күренеклеләреннән. «Вакыт» мөселманнар арасында фәнни фикерләр, мәгърифәт таратуны, туган телне камилләштерүне һәм баетуны, язуны уңайлы итүне, әдәбиятны үстерү турында кайгыртуны үзенең мөкатдәс бурычы дип саный.

Татар яшьләре, аерым алганда, шәкертләр тарафыннан чыгарылган «Әлислах» газетасы шулай ук көннең иң кайнар вакыйгаларына бик тиз генә җавап бирүче басма буларак танылa. Анда Ф. Әмирхан аеруча зур тырышлык куя.

Күрәбез: XX йөз башы публицистларының җәмгыятьтәге, аерым алганда татар милләте тормышындагы, барлык мәсьәләләргә күзләре җиткән, һәм алар, җәмәгатьчелекнең игътибарын юнәлтү өчен, бөтен талантларын һәм көчләрен салып иҗат иткәннәр. Әйе, милләт мәнфәгатьләрен ярым-йорты гына эшләп кайгыртып булмый. Моның өчен Г. Исхакый, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев һәм башкалар кебек саулыксәламәтлекне биреп, гомереңне тулаем шушы максатка багышлап кына кайбер нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин.

Сораулар һәм биремнәр

1. Ничек уйлыйсыз: милли телдә вакытлы матбугат булуның әһәмияте нәрсәдә? Аны булдыру өчен, кемнәр тырышлык куйган?

2. Бер гасыр буе сорап та алып булмаган мөмкинлек (сүз газета-журналлар чыгару турында бара) 1905 елда ни өчен шактый җиңел барлыкка килә ала?

3. Бездә нинди исемдә газета-журналлар чыга? Анда кемнәр эшли, кайсыларын даими укып барасыз?

4. Газеталарның татар җәмгыяте тормышында тоткан урыны турында сөйләгез.

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Әдәбият үсеше үз чиратында тәнкыйтьне дә барлыкка китерә. XX йөз башында татар әдәби тәнкыйтенең аваз бирүе очраклылык түгел иде. Иҗтимагый фикернең җанлануы, әдәбиятның төрле жанрлары үсеше, вакытлы матбугат барлыкка килү — һәммәсе дә тәнкыйть фикере мәйданга чыгуга юл ачты, матур әдәбиятның асыл хасиятләрен аңлатуга ихтыяҗ барлыкка китерде. Шуның нәтиҗәсе буларак XX йөзнең беренче ун елында сүз сәнгатебезнең бу тармагында сизелерлек җанлану башланды.

Тәнкыйтьчеләр алдына һәрвакыт бик әһәмиятле бурычлар куела. Бу киң колачлы һәм җаваплы хезмәтне башкаручылар билгеле бер сыйфатларга ия булырга тиеш. Г. Тукай: «Тәнкыйтьче булыр өчен, әлбәттә, үзләре дә әдәбият гамәлендә күп ат уйнаткан тәҗрибәле һәм әхлаклы кеше булуы таләп ителә». С. Рәмиев: «Кешенең... тик эше хакында гына, чын күңел белән карап, фикер сөйләүче йә язучы кеше дип беләм». Җ. Вәлиди: «Нечкә сизем, үткен хис вә тугры зәвыклы булырга тиеш». Күренекле каләм әһелләре тәнкыйтьчене менә шундый кеше итеп күз алдына китергәннәр.

Алар шул ук вакытта әдәбиятның тормышыбыз «көзгесе» булырга тиешлегеннән чыгып эш иткәннәр. Ягъни сүз сәнгате әсәрендә, Г. Тукай әйтмешли, халык үз хәлен күрергә, көлерлек булса — көлергә, еларлык булса еларга тиеш. Шуннан соң инде кимчелекләрне төзәтү гамәленә керешергә була. Ягъни әдәбият-сәнгать тормышны камилләштерү чараларыннан берсе буларак та карала. Шушы җәһәттән чыгып, Г. Тукай Г. Камалның «Безнең шәһәрнең серләре», М. Гафуриның «Хәмитнең хәяте» әсәрләрен уңай бәяләде. Ф. Әмирхан да Г. Камалның «Беренче театр» әсәренең ярым «мөтәрәккый»[1]

---

[1] *Ярым мөтәрәккый* — ярты-йорты гына мәдәниятле, ярты-йорты гына белүче.

купецларыбызның мәгыйшәт вә дингә нәзарларының[1] бик тугры көзгесе итеп чыгаруны хуплый. Шул ук Ф. Әмирхан Г. Тукайның «Мужик йокысы» әсәрен, мәгънәне искечә аңлатканы өчен, ягъни авыл кешесенең авыр тормышында мужикның үзен генә гаепләве сәбәпле, шагыйрьнең җыентыкларына керергә тиеш түгел дип язып чыкты.

Г. Рәфикый исә каләм әһелләренә икенчерәк бурычлар куя: «Сез кешенең йөрәген үтәли күрергә: һәркайсыгыз бер психолог булырга, ә язган нәрсәләрегез кешенең эчен-тышын бердәй ачык күрсәтә торган якты көзгеләр кеби булырга тиеш». Болай дип әйтү әдәбият алдында торган бурычларны тиешенчә аңлауга тагын да якынрак килү иде, чөнки биредә сүз сурәтләнәсе кеше образының «йөрәген үтәли күрү», ягъни аның күңел дөньясын ачу турында бара. Г. Исхакый, Ш. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, М. Гафури һ.б. әдипләребез кешенең психологиясен ачып бирү юнәлешен үстереп җибәрү белән әдәбиятыбызга яңа сулыш өрделәр. М. Мәрҗани (Мәхмүт Галәү), Җ. Вәлидинең әдип Ш. Камал иҗатындагы кешенең эчке дөньясын ачу хасиятләренә игътибар итүләренең нигезе бар иде. Язучы, фотога төшергән кебек (Г. Камал каләмдәше Г. Коләхмәтовның «Яшь гомер» драмасына да шундыйрак таләп куйган иде), тормышның вагын-төяген әсәренә кертеп тутыра алмый, бәлки, М. Мәрҗани аңлавынча, чынбарлыкның «авыру җирләрен җәмгыять әгъзаларының рухи халәтләрендә чагылдыра». Г. Исхакыйның «Тормышмы бу?», Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә», Ш. Камалның «Уяну», «Сулган гөл», Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрләре моның үрнәкләре булып торалар. Димәк, әдәбиятның кеше күңелен сурәтләүгә йөз тотуында тәнкыйтьнең дә билгеле күләмдә өлеше бар.

Г. Ибраһимовның бу мәсьәләләргә карашы аерылып торды. Ул проза әсәрләренең тормыш белән якын булырга тиешлеген якласа да, шагыйрь «бу җирдәге вак, гади тормыш илә канәгатьләнә алмый» дип язды. Шуңа күрә ул «халык ни уйлый, ни хис кыла» темасын гына язган Г. Тукайны шагыйрь дип санамау ягында. Аның каравы «гакыл вә зиһеннән түгел, бәлки адәмнең рухыннан, күңеленнән, хыял вә хисеннән» шигырь тудырганнары өчен, С. Рәмиев белән Дәрдемәндне чын шагыйрьләр дип исәпли. Дөрес, бу соңгылары

[1] *Нәзар* — караш.

да алай тормыштан бөтенләй үк аерылып язмадылар. Биредә сүз Г. Ибраһимовның матурлыкны аңлау мәсьәләсендә югары өслүпкә, ягъни романтизмга, өстенлек бирүе турында бара. Р. Фәхреддинов, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Сәгъди исә Г. Тукай шигъриятенең халыкчанлыгын хуплап чыктылар. Г. Ибраһимов та бөек шагыйребез иҗатының бу ягын бәяләмичә булдыра алмады. Җамал Вәлиди сүзләре Г. Тукай иҗаты тирәсендә барган бәхәстә аеруча дәлилле булды: «Ул халык илә бергә, халык өчен халык йөрәгеннән сөйли иде». Шунысы кызык: Г. Тукай үзе әдәби тәнкыйтькә нигез салуда бик әһәмиятле эш башкарды, татар әдәбияты үсешенең эстетик кануннарын билгеләүдә шул ук Г. Тукай иҗаты тәнкыйтьчеләребез өчен ышанычлы җирлек тә булды.

Күргәнебезчә, 1905—1917 еллар арасында әдәби тәнкыйть һәвәскәрлектән мөстәкыйль иҗат өлкәсенә әверелде. Биредә, әлбәттә, Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәбиятларындагы казанышлар да йогынты ясамый калмады. Тәнкыйтьнең фәнни карашларга, татар милли әдәбиятына һәм чынбарлыкка таянып барлыкка килүе сүз сәнгатебез үсешенә зур этәргеч бирде.

Сораулар һәм биремнәр

1. XX йөз башында татар әдәби тәнкыйте барлыкка килүенең алшартларын күрсәтегез.

2. Тәнкыйтьчегә нинди таләпләр куела?

3. «Әдәбият — тормыш көзгесе» дигәндә, сез сүз сәнгатенең җәмгыятьтәге урынын ничек аңлыйсыз?

4. Тәнкыйть өлкәсендә хезмәт иткән шәхесләрнең бу өлкәдәге карашларын аңлатыгыз.

5. Г. Тукай иҗатына мөнәсәбәтле фикер каршылыкларын сез ничек итеп күз алдына китерәсез?

СОВЕТ ХАКИМИЯТЕ ЧОРЫНА КЕРГӘНДӘ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Инкыйлаблар тәэсирендә

1914 елның җәендә башланып киткән Беренче бөтендөнья сугышы Россияне тәмам бөлгенлеккә төшерде. Авырлыкның зурысы крестьянга, үз кул көче белән яшәүчеләр җилкәсенә төште. Мылтык тотып үлемгә барган солдатларның да төп өлеше авыл кешеләре һәм эшчеләр иде. Күпләгән хуҗалыклар эшче кулсыз, мал-туарсыз калды, гарип-гораба күбәйде, илдә ачлык галәмәте көчәйде.

Патша хакимиятенең тышкы һәм эчке сәясәтеннән ризасызлык үскәннән-үсә барды. Төрле фиркаләр, шул җөмләдән эшчеләр һәм крестьяннар партияләре, бу хәлдән чыгу юлларын эзләделәр. 1917 елның февралендә Россиядә инкыйлаб булды, патша үзенең тәхетеннән ваз кичәргә мәҗбүр ителде. Илдә хакимият Вакытлы хөкүмәт кулына күчте. Төрле урыннарда эшче-крестьян һәм солдат депутатларының советлары төзелә башлады.

Вакытлы хөкүмәт ил алдында торган мөһим бурычларны ашыгыч хәл итә алмады. Бөлдергеч һәм мәгънәсез сугыш һаман дәвам итте. Крестьяннарга вәгъдә ителгән җир бирелмәде. Халыкның ризасызлыгы кимемәде, ә һаман артты.

Бу хәлдән эшчеләр партиясе файдаланды. 1917 елның 7 ноябрендә (яңа стиль белән) хакимият эшче-крестьян һәм солдат депутатлары советлары кулына күчте. Бу күчеш «социалистик революция» дип аталды.

Тарих шуны күрсәтә: хакимиятне бер генә сыйныф һәм бер генә партия дә үз теләге белән, ансат кына бирергә теләми. Шуңа күрә инкыйлаб күп вакытта мәҗбүр итү, корал куллану, кан түгү, юк итү юлы белән бара. Бу яктан Октябрь инкыйлабы аеруча дәһшәтлесе һәм кансызы булды. Ул югары сыйныфлардан үч алу, аларны юк итү рухында узды.

Хакимияткә килгәч тә, инкыйлабның беренче елларында большевиклар хөкүмәте халык өмет иткәннәрне үтәү юлында кайбер җитди адымнар ясады: Россия империалистик сугыштан чыгарга солых төзеде, җир крестьяннарга бүлеп бирелде. Хуҗалыкны идарә итүнең яңа ысуллары барлыкка килде. Тулы азатлык һәм ирек вәгъдә ителде. Аерым милләтләргә, чикләнгән күләмдә булса да, мөстәкыйльлек бирү башланды.

Менә шундый шартларда татар әдәбиятында җәмгыятьтәге үзгәрешләрне чагылдыруга игътибар артты. Бу чорда аның өчен бигрәк тә **иҗтимагый тигезлек** һәм **милли азатлык** темалары әһәмиятле булды.

Бу хәл аңлашыла да иде. Чөнки дәүләтчелеген җуйган татар халкы ничәмә гасырлар колониаль буйсыну хәлендә яшәде. Төрлечә кимсетү-кыерсытуларга карамастан, ул барыбер чыдам һәм түзем ватанпәрвәр булып калды, милләт буларак үзен саклап, милли азатлыгын, дәүләтчелеген кире кайтару өмете белән яшәп килде. Ә 1917 елгы инкыйлаб татар халкының бу өметенә саф сулыш өрде. Бу хәл татар әдәбиятында да уңай яктан чагылыш тапты.

Инкыйлаб һәм татар язучылары

Татар язучыларының зур күпчелеге илдә инкыйлаби үзгәрешләр булуга уңай карады. Инкыйлаб әдәбиятның җанлануына китерде. Февраль инкыйлабы алдыннан күп кенә әдипләр инкыйлаби эчтәлекле газеталар оештырдылар, милли һәм сыйнфый азатлыкны яклап, халык арасында аңлату эшләрен җәелдерделәр. Мәсәлән, Мәҗит Гафури «Кызыл байрак», Сәгыйть Сүнчәләй «Ихтилал[1] шигырьләре» дип аталган җыентыклар чыгардылар. Бу шигырьләрдә, хезмәт кешеләренең бер максатка берләшүенә соклану белән бергә, көч кулланууны хуплау, кызыл төсне мактау кебек хасиятләр дә урын алды.

Кара син алга!
Күрәмсең анда
Кызыл байракны,
Буялган канга.

Көчле эшчеләр
Күтәргән аны,
Буялган аңа
Шәһитләр[2] каны,—

дип язды Мәҗит Гафури «Кызыл байрак» шигырендә. «Патшаның тәхете җимерелүе», «бар явызларның төрмәгә керүе» М. Гафурины куандыра. Аның бу вакытта иҗат иткән «Хөррият иртәсе», «Азатлык хөрмәтенә», «Курыкмагыз!» шигырьләрендә, шатлык хисләре белән бергә, азатлык көрәше каһарманнары белән горурлану да ачык чагыла. Аныңча, мондый

---

[1] *Ихтилал (ихтиляль)* — баш күтәрү, фетнә.
[2] *Шәһит* — корбан булган көрәшче.

каһарман — эшче-җиңүче, дошманнарны кырып-себерүче. Шунысы кызганыч: мондый төсмерләр, ягъни дошманны ватып-сытуга, аннан үч алуга, кан коюга өндәү Октябрь инкыйлабыннан соң, бигрәк тә гражданнар сугышы елларында, әдәбиятта төп юнәлеш булды һәм берьяклы үсеш алды.

Октябрь борылышының төп көчләрен һәм киләчәген төрле язучы төрлечә аңлады һәм күзаллады. Берәүләр пролетариат диктатурасын берсүзсез кабул итте, аңа хезмәт итә башлады. Болар — күпчелек, һәм алар арасында Г. Ибраһимов, М. Гафури, Г. Камал, Ш. Камал кебек талант ияләре бар иде. Аларга бераздан Ф. Бурнаш, К. Тинчурин, Һ. Такташ, Ш. Усманов, К. Нәҗми кебек яшь көчләр кушылды.

Октябрь үзгәрешләрен кабул итеп, гражданнар сугышы елларында аны яклап чыккан язучылар арасында **Галиәсгар Камал (1879—1933)** да бар. Ул «Эш» һәм «Кызыл Армия» кебек беренче татар совет газеталарының уңышлы чыгып килүен тәэмин иткән каләм әһелләренең берсе булып китә. Танылган драматург бу чорда поэзия жанрына күчә, кыска шигырьләр, эпиграммалар, шигъри куплетлар һәм пародияләр иҗат итеп, аларны газеталарның һәр санында диярлек бастыра барды. Бу вакытлардагы эшчәнлеген язучы үзе: «Гражданнар сугышының кызган чоры. Деникин, Колчак һәм башка ак бандалар яшь Совет иленә төрле яктан һөҗүм итәләр. Шуңа күрә дә мин, кыска әсәрләр (шигырьләр) язып, көннең кадагына сугып барырга тиеш идем. Ул вакытларда мин, икешәр көн өйгә кайтмыйча, редакциядә кунып эшли идем»,— дип искә төшерә.

Г. Камал иске җәмгыятьне «төн» дип атап, яңа җәмгыятьне «таң» белән чагыштырды:

Рәхәтләндерә йөрәкне ирек җилләре,
Нинди нурлы безнең ирек илләре;
Турайды эшченең бөгелгән билләре,
Ни өчен бу сәгадәт моннан йөз ел элек килмәде!

(«Таң», 1918)

Үгетләү һәм өндәүләрдән торган кыска әсәрләре һәм сатирик шигырьләре белән әдип советларга каршы көчләрдән көлде. Бу шигырьләрендә ул дини эчтәлекле борынгы әсәрләрнең стилен һәм тасвирлау чараларын файдаланды. Моңа мисал итеп, аның «Яңа тәкый гаҗәп», «Бәдәвам китабы», «Бакырган китабы» кебек шигырьләрен һәм пародияләрен

күрсәтергә була. Г. Камал фельетоннар да яза, кичәләрдә һәм кызыл сугышчылар арасында сатирик әсәрләрен укый.

Элегрәк Г. Коләхмәтов һәм Г. Исхакый әсәрләрендә күренә генә башлаган каһарман — инкыйлабта актив катнашучы кеше образы — бу елларда әдәбиятта торган саен күбрәк урын алды. Мондый образны иҗат итүгә омтылыш бигрәк тә яшь язучыларда көчле иде. Мәсәлән, шундыйлардан берсе **Мәхмүд Максуд** (1900—1962) инкыйлабларны эчке әзерлексез каршы ала. Октябрьдән соң аның сыйнфый аңы зур үзгәреш кичерә. Инкыйлабның максатын хуплый. Шул аның әсәрләрендә дә чагыла. Шигырьләрендә романтик пафос көчле, тема яңа. Шул ук вакытта аларда абстракт өндәүләр, чакырулар шактый урын алган, җимерү-кыру, сыту-изү шигарьләре (лозунглары) кирәгеннән артык күп. Ә конкретлык, шигъри образлылык җитми. Образлы тәэсир итү ягыннан М. Максудның нәсерләре уңышлырак.

Үзенчәлекле жанр буларак, татар әдәбиятында нәсер электән яшәп килгән. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Дәрдемәнд, С. Рәмиев аның матур үрнәкләрен биргәннәр. М. Максуд әүвәлге казанышларны үзләштереп, аларны сәяси көрәш максатында эшкә җикте. «Изге көрәшкә», «Сагынам, сөям сине, Туган илем», «Елама, Рәшидә, елама!» һ. б. нәсерләрендә автор лирик буяулар, эчке кичерешләр төрлелеге һәм үткен чагыштырулар белән эш итә. Аның ярсулы хисләре публицистик фикерләре белән үрелә. Әкият алымнарын һәм хыялый чагыштыруларны ул гади, реаль тормыш күренешләре белән аралаштыра. Аларда азатлык көрәшенең мәгънәсен аңлый баручы кеше образы эчке бер җылылык һәм күтәренкелек белән тасвирлана. Бу еллар әдәбиятында еш очраган стилистик алымны — антитезаны[1] — М. Максуд та яратып куллана. Мәсәлән, «Минем кануннарым» (1920) исемле нәсердә лирик каһарман, хезмәт ияләре өчен уртак омтылышны һәм максатны чагылдырып, болай ди:

«Җир йөзендә хөкем сөргән кыргыйлык кануннары миңа дошман иде — мин аларны җимердем.

Бөтен кара көчләр котырынып өстемә килгәннәр иде — һәммәсен җиңдем.

Моннан соң да матур дөньяның канга буялуын теләмим — һәм ул буялмас.

---

[1] *Антитеза* — капма-каршы куеп тасвирлау.

Моннан соң да бай табигатьтә бер телем икмәк өчен гыйффәт[1] сатулар булуын теләмим — һәм ул булмас.

Матур дөньяда тик рәхәт кенә, бәхет кенә булуын телим — һәм ул булыр».

Гражданнар сугышы елларында татар әдәбиятында, шигърияттән кала, драматургия актив жанрларның берсе булды. Бу елларда **Кәрим Тинчурин** (1887—1938) аеруча дәртләнеп иҗат итте. Комедияләрендә («Сәяси сакал», «Йосыф—Зөләйха» һ. б.) ул мал-мөлкәтле катлам вәкилләреннән, һәртөрле сорыкортлардан оста көлә, өлгергән мәсьәләләрне күтәргән мәкаләләр белән чыга, хикәяләр дә иҗат итә. К. Тинчурин, режиссёр һәм артист буларак, Г. Кариевтан соң театр эшләрендә җитәкчелекне үз кулына ала, театр сәнгатен яңа нигезләргә кую эшенә әһәмиятле өлеш кертә.

Яшь көчләрдән **Шамил Усманов** (1898—1937) үзенең беренче пьесалары белән әдәбиятка шушы елларда килеп керде. Аның «Канлы көннәрдә» һәм «Беренче адым» драмалары илнең төрле почмакларында уйналалар, бигрәк тә солдатлар һәм эшче-крестьян тамашачысы арасында уңыш казаналар. Беренче татар бригадасы комиссары Ш. Усманов бу әсәрләрендә үзе күргән, чынбарлыкта булган вакыйгаларны чагылдыра. Шулар аша инкыйлабның кеше акылына һәм рухына ясаган тәэсире ачыла. Каһарманнардагы халык азатлыгы өчен көрәшкә бирелгәнлек сыйфаты аеруча калку итеп һәм бизәп күрсәтелә.

Пролетар инкыйлабына килү шулай да барлык язучылар өчен дә бертөсле һәм ансат кына булмый. Шуны **Шәехзадә Бабич** (1895—1919) мисалында күрергә мөмкин. Гражданнар сугышы елларындагы мәрхәмәтсез кан кою аны аптырашта калдыра. Шагыйрь үз күңелен рәнҗеткән бу хәлдән котылуның төрле юлларын эзли, бәргәләнә. Берара советларга каршы көрәшүче башкорт солдатларына барып кушыла, алар өчен газета чыгара. Аннары, бер төркем башкорт солдатлары белән берлектә, советлар ягына чыга. Моны патшага, аның явыз тәртипләренә каршы булуы белән нигезләп аңлата:

Большевиклар әйтә: бу дөньяда
Ярлы халык хөкеме йөрсен, дип;
Ярлы эшчеләрнең хас дошманы —
Буржуйларның тамры корсын, дип!

---

[1] *Гыйффәт* — б и р е д ә: «намус» мәгънәсендә.

Дутов, Колчак әйтә: эш башына
Алтын таҗлы патша менсен, ди;
Патша, менеп, һаман, Николайдай,
Ярлыларның канын имсен, ди.

(«Без ник кызылларга кушылдык», 1919)

Ике арада бәргәләнгән шагыйрь 1919 елның мартында фаҗигале рәвештә һәлак булды.

Бөтен иҗаты кешене ярату, хөрмәт итү рухы белән сугарылган **Мирхәйдәр Фәйзи** (1891—1928) шулай ук аптырашта кала. Берара ул «хакимлек аклар кулында булса да, кызылларда булса да — барыбер» дип фикер йөртә. Ләкин озакламый, кан кою һәм мәҗбүр итүләргә карамастан, хаклык хезмәт иясен яклаучылар ягында дигән фикергә килә. Каләмен Совет хакимиятен яклауга хезмәт иттерә башлый. «Асылъяр», «Ак калфак» кебек пьесаларында көчле мәхәббәтне сурәтләү ярдәмендә сыйнфый тигезсезлекне инкяр иткән драматург, «Кызыл йолдыз» драмасын язып, ачыктан-ачык пролетар карашны яклау позициясенә баса.

Танылган әдип **Фатих Әмирхан** (1886—1926) Октябрь инкыйлабын хуплап каршылый. Әмма озак та үтми, ул хуҗалык һәм мәдәният өлкәсендә совет һәм партия оешмалары үткәрә торган сәясәтнең кешегә каршы булган якларын тиз күреп ала, тәнкыйтьләп чыгышлар ясый. Мондый инкыйлабның юлы дөрес булуына шик-шөбһә белдерә. Аерым шәхесләрдән культ ясауны, гасырлар буе урнашкан гореф-гадәтләргә каршы чыгуны кискен тәнкыйтьләп, ул «Шәфигулла агай» исемле сатирик повестен яза.

Гаяз Исхакый (1878—1954) исә Октябрь инкыйлабын бөтенләй кабул итмәде. Мәгънәсез кан кою, байларны кыерсытып ярлы хәленә төшерергә тырышу гамәлләре, күп санлы корбаннар сораган вакыйгалар аны тетрәндерде. Бер сыйныфны — эшчеләрне генә өстен куеп, аларның мәнфәгатьләрен генә изге санап, башка сыйныфларны, бигрәк тә крестьяннарны кимсетү-түбәнсетү бөтен иҗатын хаклык, кешелеклелек рухына багышлаган әдип өчен ят иде. Нәтиҗәдә ул большевиклар хакимиятен кире какты, аннары чит илгә чыгып китәргә мәҗбүр булды. Соңгы көннәренә кадәр ул советларга, аларның вак милләтләргә, крестьяннарга каршы алып барган дошманлык сәясәтенә каршы көрәште, шәхес ирекен яклап, сәнгатьчә дәрәҗәдәге әсәрләр язды, аларда халкыбыз мәнфәгатьләрен яклады.

Мәхәббәт һәм бурыч каһарманнары

Татар язучыларының байтагы шәхес азатлыгын социаль тигезлек белән бәйләп карады, моны тәэмин итү сыйнфый көрәш ярдәмендә генә мөмкин дип исәпләде.

Татар әдәбиятында элек-электән килгән «Кеше хөр булырга тиеш!» дигән шигарьне **Фәтхи Бурнаш** (1898—1942) үзенең беренче әсәрләрендә үк күтәреп чыккан иде. Аны ул «Таһир — Зөһрә» дип исемләгән шигъри трагедиясендә бигрәк тә ачык итеп куйды.

Батыр егет Таһир белән гүзәл кыз Зөһрә арасындагы көчле мәхәббәт тарихы күп кенә Көнчыгыш язучыларын илһамландырды. XV гасыр шагыйре Сайяди «Бабахан дастаны»нда бу тарихны шигъри юлларда сөйләп бирә. XIX йөз ахырында әлеге сюжет Әхмәт Уразаев-Курмашины да дәртләндерә, һәм аның «Таһир—Зөһрә» әсәрен татар укучылары бик яратып укыйлар. Ф. Бурнаш бу фаҗигале сюжетны сәхнә әсәре язуга файдалана, заманча рух сала. 1917 елда язылган әлеге трагедия, 1918 елның башында Габдулла Кариев тарафыннан сәхнәләштерелеп, зур уңыш казана.

...Таһир белән Зөһрә арасындагы гүзәл, яшерен мәхәббәт турында мәкерле Гарәп кызның атасына җиткерә. Хан, үз кызының шөһрәтен саклап калу өчен, ниләр генә эшләми: егетне, сандыкка салып, суга агызалар, төрмәгә ябалар. Таһирның бердәнбер «гаебе» — кара нәселдән, ягъни чыгышы белән түбән катлаудан булуында. Шуңа күрә, янәсе, кызга тиң түгел. Нәтиҗәдә егет җәзалап үтерелә. Сөйгәнен югалту кайгысыннан Зөһрә үз-үзенә кул сала. Кызны үзенеке итәр өчен төрле әшәкелекләр кылган Гарәп тә үзен үтерә.

Вакыйгалар барышында егет ханнарга баш бирмәс каһарманга әверелә бара. Ул көрәшен ханның сүзенә буйсынмау белән башлый, соңыннан исә хан хакимиятенә, сарайларга каршы турыдан-туры баш күтәрү, аларны кире кагу белән тәмамлый.

Канлы куллар! Әйдә, абруйсызлар,
Менә инсан — корбан итегез,
Ләкин табылыр миннән көчлерәкләр,
Тар-мар килер алтын тәхетегез.—

ди Таһир ханга.

Иң мөһиме, Таһир,— ватанпәрвәр буларак, туган илен чит ил баскынчыларыннан саклаучы. Аның йөрәгендә, Зөһрәсенә булган олы тойгыга үрелеп, илен ярату хисе урын ала. Шу-

ның белән эчтәлек тә нык үзгәреш кичерә, Таһир — яңа тип. Сайяди дастанында да, Курмаши поэмасында да Таһир бары тик мәхәббәт каһарманы итеп кенә бирелгән.

Трагедиядә дини әдәбияттан килә торган образлар да бар. Мәсәлән, Хозыр Ильяс. Ул хаксызга төрмәдә утыручы Таһирны ирекка чыгара, аның Ватан сакчылары янына, сугыш кырына юнәлүенә фатиха бирә. Бу образ Ф. Бурнашның шул ук елны язылган «Дулкыннар арасында» поэмасында да күренеп китә. Монда да ул поэма каһарманын үз көченә ышанырга өнди, кешенең табигать көчләреннән өстен булуын әйтә:

Зурланмасын диңгез зурлык белән,
Мактанмасын дулкын көч белән,
Шаярмасын упкын инсан белән,—
Алар көче аңа чүп кенә.

Ләкин шул ук вакытта ул егетне Тәңрегә буйсынырга чакыра, илаһилыкка өнди:

Таян да син, егет, күкрәгеңә,
Сал да күңелең бөек Тәңреңә,
Юлында бул, курыкма берсеннән дә,
Карышма тик Аның әмеренә!..

Кешенең рухи хөрлеген Ф. Бурнаш алга таба турыдантуры иҗтимагый тигезлек белән бәйләп карый башлый. Ягъни һәр кеше җирдә бүтәннәр белән тигез яшәргә һәм үз мәнфәгатьләрен кайгыртырга хокуклы булса да, җәмгыять югары һәм түбән катлауларга бүленгәнлектән, бигрәк тә түбән катлау вәкилләренә бирелгән хокуклар чикле, дип борчыла язучы. Җәмгыятьне үзгәртергә, димәк, югары сыйныфларның хокукын чикләргә кирәк, аныңча.

Бу фикерләрен автор шул ук 1917 елда язган икенче бер сәхнә әсәрендә — «Яшь йөрәкләр» комедиясендә — тагын да ачыграк итеп чагылдыра. Авыл яшьләре Хәйретдин белән Сәрбиҗамал арасына бай улы Галимҗан килеп керә. Егетнең солдатта булуыннан файдаланып, ул кызны урлап китә, аны мәҗбүри үзенеке итмәкче була. Сәрбиҗамалны сугыштан кайтып килүче сөйгән егете Хәйретдин белән аның дусты Сәйфулла коткаралар, бай балаларының арт сабакларын укыталар.

«Галиябану» драмасын иҗат иткәннән соң бер ел үткәч тә язылган бу әсәр кайбер яклары белән М. Фәйзи пьесасына охшый. Шул ук «өчпочмак»: крестьян яшьләре бер-берсен яраталар, алар арасына бай егет керә. Авыл яшьләренең гореф-гадәтләре, кичке уен, аулак өй һәм башка этнографик

күренешләрнең мул сурәтләнүе, музыка-җыр яңгырашы ике пьесаны үзара якынайта. Хәлиткеч мизгелдә утлы корал эшкә җигелә. Ләкин Исмәгыйль кулындагы корал каһарманның гомерен өзсә («Галиябану»да), ярлы Хәйретдин кулындагы корал байбәтчәне акылга утыртырга ярдәм итә («Яшь йөрәкләр»дә). Бердәй ситуацияне хәл итүдәге мондый кискен үзгәлекне илдәге сәяси хәл тәэмин итте. Замана кысалары белән санлашмыйча, мәхәббәттә, гаделлек өчен көрәштә ярлы катлау яшьләренең җиңеп чыгуы раслану Россиядәге гомуми хәл-әхвәл белән бәйле иде. Ил күләмендә инкыйлаб тарафдарларының өстенлек алуы яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләрне әдәбиятта чагылдыруга да тәэсир итте.

Сыйнфый тигезсезлеккә каршы булуын әсәрләрендә яклаган яшь язучы (ә бу вакытта аңа нибары 19 яшь!) гамәли эшчәнлеге белән дә яңа җәмгыятьне ныгытуга өлеш кертергә тырышты. Октябрь борылышыннан соң башланып киткән гражданнар сугышы чорында Ф. Бурнаш тәмам большевиклашып бетә. Аны 1918 елның апрелендә Сембердә (соңыннан Ульяновск) чыга башлаган «Көн» газетасының мөхәррире итеп билгелиләр. Ул искиткеч өлгерлек белән хезмәт иясен яклаган, байларны һәм инкыйлабка каршы кешеләрне тәнкыйтьләгән публицистик мәкаләләр, шигырьләр һәм хикәяләр язып бастыра, пьесалар иҗат итә. Советларга каршы баш күтәргән чех гаскәрләре Сембергә кергәч, аны төрмәгә ябалар. Ф. Бурнаш өч айдан соң, төрмәдән качып, кызыллар ягына чыга һәм газетаны яңадан аякка бастыра, романтик шигырьләре, поэмалары белән танылып китә. «Гөлчәчәк» поэмасында шагыйрь иске тормышның авыр һәм фаҗигале күренешләрен, «Сахра каны» әсәрендә көрәшнең зур батырлар тудыруын тасвирлый. «Таң алдында», «Икеләнмә», «Чәчәктән һәйкәл» кебек поэмаларында ул халык азатлыгы өчен барган көрәшнең изге һәм зарури булуын күрсәтә. Мондый әсәрләрнең үзәгендә шәхси теләк-өметләрен инкыйлаби көрәш файдасына корбан кылган яшьләр образлары тора. Еш кына яшь егет, сөйгәненең җибәрәсе килмәвенә дә карамастан, хезмәт иясен азат итү өчен, көрәшнең аеруча зарурилыгын аңлап, сугыш кырларына китә. Аның үзенең дә сөйгәненнән аерыласы килми, күңеле теткәләнә, ләкин... барырга кирәк! Шәхси теләкләр белән иҗтимагый мәнфәгатьләрнең мондый бәрелешендә яшь каһарман өстен чыга, көрәштә аңа мәхәббәте көч бирә. Чөнки ул — кыерсытылганнар, изелгәннәр, җәберләнгәннәр ягында, аларны яклаучы кеше! Гаделлек тарафдары!

Ф. Бурнашның әсәрләре тирән кичерешләргә, сурәтләүләргә бай, алар җанлы, җыйнак, йөгерек тел белән язылганнар. Алар арасында бигрәк тә «Ак каен» поэмасы (1919) шигъри тасвирлауларга бай булуы белән аерылып тора. Анда яшь сугышчы образы сурәтләнгән. Шагыйрь үз авылларын һәм шунда яшәүче сөйгәнен дошман кулыннан азат итү өчен ашкынып кайткан егетнең соңгы һөҗүм алдыннан булган кичерешләрен тасвирлый. Авыл азат ителә, әмма егетнең сөйгән кызы һәлак була. Газаплы кичерешләре вакытында егетне ак каен юата, хәсрәтен уртаклаша. Шул рәвешчә, шигъри образ — каен образы туа, ул сафлыкны, тугрылыкны олылаучы, көрәшнең зарурлыгын раслаучы символик образ дәрәҗәсендә сурәтләнә:

Егет елый сагынып Гөлҗамалын,
Тоткан хәсрәт тулы башкаен,
Җилфердәтеп яшел яфракларын,
Юатмакчы була карт каен:
«Кайгырма, юк. Сиңа юл бер генә:
Үткен кылыч синең билеңдә...»

Йөрәк ярасыннан кан саркып торган сугышчы егет көрәш юлыннан алга атлый.

Җилфердәтеп яшел яфракларын
Уйный иртән җилдә ак каен,
Бара егет алга — киң Уралга,
Уйлап өзлеп сөйгән җанкаен.

* * *

Шулай итеп, Октябрь инкыйлабы татар язучыларын төрле якка таратып ташлады. Пролетариат диктатурасы, аннары тоталитар режим шартларында әдәби тормышыбыз Гаяз Исхакый кебек талантлардан башка гына дәвам итте. Ләкин, илдәге әдәби хәрәкәткә турыдан-туры тәэсир итә алмаса да, Г. Исхакый татар әдәбияты үсешенә соңыннан килеп кушылачак гаҗәеп зур иҗади мирас тудырды.

Ә язучыларның күпчелеге исә, инкыйлабның кайдадыр ерак офыктан кызыктырып торган шигарьләренә ияреп, яшь Совет илен якларга тотынды. Совет хакимиятенең сыйнфый азатлык, солых, җирне крестьянга бирү, шәхси хөрлек кебек вәгъдәләре аларга беренче елларда, чыннан да, тормышка ашар сыман булып күренде. Ләкин соңрак инде алар партия-совет идеологиясенең коточкыч басымы астына килеп керделәр һәм аңлап та, аңламыйча да сталинизм режимын якларга кереш-

теләр, дөресрәге, шуңа мәҗбүр ителделәр. Бу язучылар инкыйлаб вакытында ук киң җәелә барган кан кою, көч кулланып буйсындыру, күпчелек мәнфәгатьләре өчен дип, азчылыкның теләк-омтылышларын аяк астына салып таптау кебек афәтләрне күреп бетерә алмадылар, күрсәләр дә, аларны дөрес бәяләү мөмкинлегеннән мәхрүм булдылар. «Совет әдәбияты», «социалистик реализм методы әдәбияты» дип исемләнгән мираста шул чор рухын чагылдырган әсәрләр күпчелекне тәшкил итте. Аларда гомумкешелек кыйммәтләре — гаделлек, рәхимлелек, кече күңеллелек, миһербанлык, тугрылык, һәркемгә шәхес итеп карау кебек төшенчәләргә өстенлек бирелә алмады, киресенчә, мондый затлы сыйфатлар рәсми сәяси карашлар күләгәсе аша гына шәйләнделәр, ягъни шуларга туры килгән очракта гына әсәрдә гәүдәләнү хокукы алдылар.

Сораулар һәм биремнәр

1. Илдә инкыйлаблар булуга бер яки ике партияне генә җаваплы санап буламы? Мәсәлән, Октябрь инкыйлабы өчен В. Ленин җитәкләгән большевиклар партиясен генә җаваплы санау дөресме? Инкыйлабларны, асылда, нинди сәбәпләр китереп чыгарды?

2. Октябрь инкыйлабы чорында татар язучылары ничә төркемгә бүленде? Бу бүленештә нинди сыйфатлар төп билге булды?

3. Кемнәр кайсы юлны сайлады? Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Ибраһимов, Ш. Бабич, М. Фәйзи һәм башкаларның Октябрь инкыйлабына мөнәсәбәтен сөйләгез.

4. Инкыйлаб һәм гражданнар сугышы елларында татар әдәбиятында бигрәк тә нинди жанрлар активлашкан? Моның сәбәпләрен күрсәтегез.

5. Инкыйлабтан соң иҗатлары башланып, колачланып киткән яшь көчләрне атагыз. М. Максудның бу еллардагы иҗатының үзенчәлекләрен билгеләгез.

6. Ф. Бурнашның шул чордагы иҗаты турында сөйләгез. «Таһир—Зөһрә» һәм «Яшь йөрәкләр» пьесаларының үзәк каһарманнарына хас төп хасиятләр нәрсәләрдән гыйбарәт?

7. Инкыйлаб көрәшчесенең әдәби образында аеруча еш сурәтләнгән сыйфат-үзенчәлекләрне атагыз.

8. Бу еллардагы әдәби каһарман шәхси теләкләр (мәхәббәте, үз гаиләсе, әти-әнисе һәм якыннары, үзе өчен кайгырту) һәм иҗтимагый мәнфәгатьләр (хезмәт иясен азат итү, туган илне саклау) конфликты эчендә ачыла. Мондый каһарман күбрәк кайсы якны сайлый, ни өчен? Аның сайлаганы һәр очракта да дөрес булып чыгамы? Шулар турында сыйныфта сөйләшү уздырыгыз.

9. «Россиядәге инкыйлаблар һәм татар әдәбияты» дигән темага доклад әзерләгез.

Галимҗан Ибраһимов
(1887—1938)

Галимҗан Ибраһимов — бөек шагыйрьләр Г. Тукай һәм Дәрдемәнд, олуг әдипләр Г. Исхакый һәм Ф. Әмирхан, мәшһүр драматурглар Г. Камал һәм М. Фәйзи белән бергә XX гасырның беренче чирегендә татар әдәбияты үсешенә аеруча зур өлеш керткән язучы. Әдип иҗат эшчәнлегенең төп тармакларын санап кына чыгу да аның олы образын күз алдына китереп бастырыр.

Халкыбызның милли аңы, иҗтимагый үсеше һәм милли азатлык хәрәкәте тарихында тирән эз калдырган фикер иясе, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе; татар әдәбиятының классигы, милли әдәбиятта реализмга нигез салучыларның берсе, татар мәдәнияте үсешенә зур өлеш керткән талантлы сүз остасы; күренекле тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече, шактый еллар татар әдәби-мәдәни хәрәкәтен оештыручы һәм әйдәп баручыларның берсе, яшь талантларга остаз, татар милли матбугатында онытылмаслык урын алган ялкынлы публицист һәм журналист; тирән эрудицияле, киң колачлы галим-филолог, тарихчы, ориенталист; ниһаять, мәгариф өлкәсендәге гыйльми хезмәтләре һәм нәтиҗәле гамәли эшчәнлеге белән күпләрне сокландырган педагог. Боларның һәркайсы — махсус талант һәм хәзерлек, иҗат көчен тулысынча шуңарга гына сарыф итүне сорый торган өлкә. Галимҗан Ибраһимов таланты менә шуларның барысын да колачлый, иҗаты шул тармакларның бөтенесен дә җыйный алган. Ул әлеге өлкәләрнең һәркайсында яңа сүз әйтеп кенә калмый, аларның күбесендә юл яручы, әйдәп баручы, нигез салучы. Таланты,

иҗаты һәм фәнни эшчәнлегенең характеры белән ул — энциклопедияче.

Г. Ибраһимов туган халкының Россия күләмендә җәелгән инкыйлаби-азатлык хәрәкәте аша милли һәм социаль азатлыкка, яңа тормышка омтылышын, шуның өчен көрәшен, шул максатка ирешү юлындагы өметләрен, алдану-фаҗигаләрен үзенең җәмәгать эшчәнлегендә, әдәби һәм фәнни иҗатында, әсәрләрендә гаять тулы һәм тирән, бөтен катлаулылыгы һәм каршылыклары белән чагылдырды.

Тормыш баскычлары

Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов 1887 елның 12 мартында Уфа губернасының Эстәрлетамак өязе (хәзерге Башкортстан Республикасы, Авыргазы районы) Солтанморат авылында туган.

Әтисе Гыйрфан озак еллар мәдрәсәдә укый, аннары Троицк шәһәрендә укытучылык итә. Соңыннан Солтанморатка кайтып, мулла була. Картайгач, муллалыгын ташлап, игенчелек белән шөгыльләнә. Ул укымышлы, заманының алдынгы карашлы кешесе булган. Әнисе Хәсәнә ханым Троицк шәһәрендә туып үскән, әйбәт белем һәм тәрбия алган, мөгаллимә булырга әзерләнгән.

Булачак язучының сабый чагы туган авылында, әти-әнисе йортында уза. Җәен Галимҗанның көннәре башлыча табигать кочагында үтә. Ул урман-болыннарга җиләккә йөри, балык тотарга ярата. Ә төннәрен малайлар белән яланга яисә урманга ат сакларга бару аның иң яраткан шөгыльләреннән берсе була. Ул яшьтән үк кыр эшләрендә катнаша башлый.

Г. Ибраһимовта табигатькә мәхәббәт бик иртә уяна. Сабый чакта күңеленә сеңеп калган туган җир табигатенең тәэсире язучыны гомере буена илһамландырып, иҗат хыялын азыкландырып тора.

Галимҗанның иң беренче укытучысы әнисе була. Аннары ул ике кыш буе Солтанмораттан 5—6 чакрым ераклыктагы Кешәкне мәдрәсәсенә йөри. Шул ук вакытта земство мәктәбендә башлангыч рус сыйныфында да укый.

1898 елның көзендә Гыйрфан мулла олы улы Шакирҗан белән Галимҗанны, шәһәр мәдрәсәсенә бирү өчен, Оренбургка алып китә. Абыйсын «Хөсәения»гә, ә Галимҗанны Вәли мулла мәдрәсәсенә урнаштыра.

XIX гасыр ахырында татар мәдрәсәләре нык үскән, татарлар яшәгән җирләрдә киң таралган булып, күбесенчә җәдитчә укытуга күчсәләр дә, эчтәлеге ягыннан аларның барысы да бер дәрәҗәдә түгел иде. Алар арасында искелек белән сугарылган кадим мәдрәсәләр дә аз булмый. Г. Ибраһимов укырга тиешле Вәли мулла мәдрәсәсе әнә шундыйлардан санала. Табигый талантлы, эзләнүчән табигатьле яшь Галимҗан бу мәдрәсәнең асылын тиз аңлый һәм укуының икенче елында ук аны үзгәртеп кору өчен «баш күтәрә».

1905 ел инкыйлабы тәэсире белән Оренбург шәкертләре татар мәдрәсәсендә фән нигезләрен укытуны көчәйтүне, укыту-тәрбия ысулларын үзгәртүне һәм шәкертләрнең тормыш шартларын яхшыртуны таләп итеп чыгалар. Шәкертләр хәрәкәте бастырыла, башлап йөрүчеләре (алар арасында Ибраһимов та) мәдрәсәдән куыла.

1906 елның көзендә Галимҗан Ибраһимов Уфага килә һәм «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә. Татар мәгърифәте тарихында күренекле урын алган бу җәдит мәдрәсәсенең әле ачылган гына чагы була. Укуының беренче елында Ибраһимов аңа керүенә бик канәгать булса да, заманының алдынгы идеяләре белән таныша, азыклана барган яшь егетне торабара әлеге уку йорты да канәгатьләндерми башлый. Укыту ысулларына каршы чыга һәм нәтиҗәдә аны да ташларга мәҗбүр була. «Галия»дән киткәннән соң, Г. Ибраһимов казах далаларында, Әстерхан нугайлары арасында укытучылык итә, Уралда Миасс заводында эшчеләр арасында яши.

1909 елның ахырында ул Казанга килә. Аның теләге — университетка керү. Ләкин ул вакытта инде ислахчы шәкертләр хәрәкәтендә актив катнашучы булып танылган, хакимият органнары каршында сәяси яктан ышанычсыз саналган татар егетенә югары уку йортларының ишекләре ябык була. М. Горький шикелле, Ибраһимовка университетны тормышның үзендә үтәргә туры килә. Ул үзлегеннән күп укый, фән нигезләрен, тарих һәм философияне өйрәнә, дөнья әдәбияты классикларының әсәрләре белән таныша.

Әмма аны һаман да югары уку йортларының берәрсенә кереп белем алу теләге ташламый. Шуны тормышка ашыру нияте белән ул 1912 елның ахырында Киевка китә. Анда университетка ирекле тыңлаучы булып керә, мөселман студентларының яшерен оешмасында катнаша. Патша хакимияте белән аның беренче бәрелеше нәкъ шунда була: 1913 елның

17 апрелендә ул кулга алына, июнь уртасында төрмәдән чыгарылгач (1917 елның Февраль инкыйлабына чаклы), охранка күзәтүе астында яши.

1913 елның көзеннән Г. Ибраһимов Казанда. Ул — яңа чыга башлаган «Аң» журналының җаваплы сәркатибе. Аның нияте бу журналны иҗтимагый-сәяси мөнбәр итү, журнал тирәсенә алдынгы иҗат көчләрен туплау була. Ләкин бераздан, уй-планнарын гамәлгә ашыру мөмкин түгеллеге ачыклангач, журналны ташлап китә.

1914 елның февралендә Г. Ибраһимов яңадан Киевта. Жандармерия агентлары аның бу килүенең сәбәбен «ниндидер партия йомышы белән бәйле булса кирәк» дип аңлаталар. Киевтан ул Одессага, аннан Кара диңгез аша Сухумига килә. Анда 1905 ел инкыйлабына багышланган зур әсәрен — «Безнең көннәр» романын иҗат итә.

Аннан соң туган якларына — Солтанморатка кайта, ә 1915 елның көзендә Уфага килеп, «Галия» мәдрәсәсенә мөгаллим булып урнаша. Бу мәдрәсәнең эшчәнлеген, уку-укыту ысулларын үзгәртү турындагы шәкерт чагында тормышка ашмаган хыял-теләкләрен хәзер ул мөгаллим буларак гамәлгә ашырырга керешә.

Мәдрәсәдә эшләү чорында Г. Ибраһимовның педагогик сыйфатлары ачык чагылды. Ул, укыту-тәрбиядә вәгазь тукуга һәм иҗек-хәреф ятлаучылыкка каршы чыгып, шәкертнең аңлы фикер эшчәнлегенә, иҗат көченә таянып эш итә. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрен үрнәк булырлык дәрәҗәгә куя. «Галия» мәдрәсәсендә аннан белем алган кешеләрнең барысы да аның яхшы педагог, акыллы методист һәм оста тәрбияче булуын раслый.

Г. Ибраһимов мәдрәсәдә татар әдәбиятын өйрәтү белән генә чикләнеп калмый, шәкертләргә дөнья әдәбиятыннан да киң мәгълүмат бирә, аларда сәнгатькә мәхәббәт тәрбияли, әдәби иҗат асылына өйрәтә. Ш. Бабич, С. Кудаш, Х. Туфан, С. Сүнчәләй, Б. Ишемгулов, Г. Нигъмәти, С. Габәши кебек күренекле татар, башкорт шагыйрьләре һәм әдипләре, казах әдәбиятына нигез салучы Б. Майлин, адыгей язучысы Т. Керашев һ. б. беренче иҗат сабагын шушы мәдрәсәдә Г. Ибраһимовтан алалар.

Әдип шунда эшләү чорында күп кенә гыйльми-педагог һәм методик хезмәтләр дә яза. Аның бу өлкәдәге беренче хезмәтләре 1911 елда ук басылып чыга. Алар янына тагын

«Татар имлясы», «Яңа әдәбият» (1914), «Әдәбият дәресләре» (1916, икенче басмасы 1918 елда «Әдәбият кануннары» исеме белән чыга), «Татар телен ничек укытырга?» һ. б. китаплары өстәлә. Бу хезмәтләр, татар теле һәм әдәбиятын укыту методикасы башлангычы булу белән беррәттән, тел белеменә һәм әдәбият теориясенә дә нигез салалар. Алар Совет чорында да кат-кат басылалар, озак еллар мәктәпләрдә дәреслек-кулланма булып хезмәт итәләр.

1917 елгы Февраль инкыйлабын Г. Ибраһимов, «Галия» мәдрәсәсе мөгаллиме буларак, ялга кайткан җирендә, туган авылы Солтанморатта каршылый. Патша төшерелү хәбәрен ишетү белән, ул Уфага китә һәм, укытучылык эшен ташлап, тулысынча революцион көрәш дөньясына чума.

Г. Ибраһимов ул чакта эсерлар партиясе әгъзасы була. Аның да сул канатында тора. Февраль инкыйлабыннан соң, 1917 елның 30 мартында Уфада «Ирек» исемле газета чыгара башлый.

Бу газета революцион-демократик идеяләрне пропагандалый. Киң халык массаларына ирек, крестьяннарга җир, изелгән милләтләр өчен милли азатлык таләп итә. Беренче саннарыннан ук «Бетсен сугыш» шигарен күтәреп чыга, һаман дәвам иткән империалистик сугышка каршы көрәш җәелдерә. Газетада, Г. Ибраһимов белән бергә, язучы Ф. Сәйфи, шагыйрьләр М. Гафури, С. Кудаш, С. Сүнчәләй һәм башка язучылар, журналистлар актив катнашалар.

1917 елның сентябрендә «Ирек», «Солдат теләге» (мөселман солдатлары органы) газетасы белән берләшеп, алар урынына «Безнең юл» исемле газета чыга башлый. Аның мөхәррире шулай ук Г. Ибраһимов була. Матбугатта эшләүдән тыш, Г. Ибраһимов татар-башкорт эшчеләре, солдатлар, укучы яшьләр, мәдрәсә шәкертләре арасында инкыйлаби аңлату эшләре алып бара, демонстрацияләрдә, митингларда актив катнаша. Аның эшчәнлеге татар һәм башкорт халыкларының социаль һәм милли үзаңын үстерүгә хезмәт итә.

Г. Ибраһимов 1917 елның маенда Мәскәүдә үткәрелгән беренче һәм июль аенда Казанда булып узган икенче Бөтенроссия мөселман җыелышларында катнаша. Төрки-татар халыкларының мәшһүр җәмәгать эшлеклеләре, сәясәтчеләре, язучылары катнашында үткәрелгән ул җыелышларның максаты Февраль инкыйлабыннан соң барлыкка килгән иҗтимагый-сәяси шартларда Россиядә яшәүче мөселман халыклары-

ның киләчәк үсеш юлларын билгеләү, аларның милли-дәүләт төзелеше мәсьәләләрен хәл итү була. Казандагы җыелышта Ибраһимов беренче тапкыр М. Вахитов белән очраша. Татар халкының бу ике көрәшчесе арасында дуслык һәм хезмәттәшлек шуннан башланып китә.

Октябрь борылышына кадәрге чорда Г. Ибраһимов әнә шундый бай һәм катлаулы иҗтимагый-сәяси үсеш юлы үтә.

Язучының 1917 елга кадәрге әдәби иҗаты

Г. Ибраһимов әдәбият мәйданына XX йөз башында — татар халкы Россиядәге инкыйлаби-азатлык хәрәкәтенә ныклап кушылган, патша хакимиятенә каршы милли азатлык өчен кискен көрәшкә күтәрелгән чорда килде. Ул вакытта татар телендә вакытлы матбугат, милли театр һәм сәнгатьнең башка төрләрен үстерү өчен, кайбер мөмкинлекләр яулап алына башлаган иде. Нәкъ шул чорда татар әдәби теле формалашып өлгерде. Милли әдәбиятның ныклап үсеше, анда тәнкыйди реализмның, прогрессив романтизмның һәм төрле әдәби жанрларның формалашу, аякка басу процессы бара иде.

Г. Ибраһимов үзенең беренче хикәяләрендә үк җәмгыять үсеше өчен мөһим мәсьәләләр күтәрергә, татар дөньясының гаделсезлегенә, иске тәртипләргә каршы чыгучы шәхесләрнең образларын тудырырга омтыла. Зәки шәкерт («Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясе, 1907) мәдрәсәдәге иске укыту ысулларына, кадимчелеккә каршы чыга. «Татар хатыны ниләр күрми» хикәясендә (1910) Гөлбану хатын-кызларның хокуксызлыгына каршы күтәрелә.

Әдипнең 1917 елга кадәрге әдәби иҗатын, нигездә, икегә бүлеп карарга кирәк. Беренчесе 1907—1912 елларны эченә ала. Бу чорда язучы үзенең иҗат принциплары буенча башлыча романтик юнәлештә үсте. Аның иҗатына иске тормышны кире кагу, романтик рәвештә гаделсезлеккә каршы чыгу, ирек теләү хас. Әдипнең ул елларда язган хикәяләрендә («Яз башы», «Диңгездә», «Сөю-сәгадәт», «Уты сүнгән җәһәннәм» һ. б.) реаль тормыш белән килешмәүче шәхес образлары бирелә. Әмма язучының каһарманнары ул тормышны, социаль-сәяси тәртипләрне үзгәртеп кору юлларын чынбарлыкның үзеннән эзләмиләр әле. Реаль тормышка алар романтик хыял дөньясын, матурлык һәм мәхәббәт культын каршы куялар. Сәнгатьчә эшләнеше ягыннан Ибраһимовның бу әсәрләре

сурәтләү чараларының байлыгы, психологик тирәнлек, табигать күренешләрен сурәтләү осталыгы белән аерылып торалар. Әдип көчле характерлы образлар тудырырга омтыла, аларның татар халкының социаль-сәяси хәленнән, тарихи язмышыннан ризасызлыгын күрсәтә. Аның геройлары колониаль тормышның тар кысаларыннан котылырга, милли азатлыкка, рухи иреккә омтылалар.

«Яшисе, мең, миллион ел яшисе килә. Ләкин моңарчы булган кызганыч тән яшәве белән түгел, башка бер яшәү белән, матур, изге, бөек яшәү белән яшисе килә»,— ди «Диңгездә» хикәясенең каһарманы.

Романтик геройның рухи дөньясын сурәтләү аркылы Ибраһимов кеше кичерешләренең җанлы хәрәкәтен, хисләр көрәшен күрсәтте. Татар прозасын лирик психологизм, яңа сурәтләү алымнары һәм көчле характерлар белән баетты.

«Яшь йөрәкләр» романы

1912 елның маенда Г. Ибраһимов үзенең тәүге зур әсәрен — «Яшь йөрәкләр» романын язып тәмамлый һәм 1913 ел башында бастырып та чыгара. Бу роман тиз вакыт эчендә милли әдәбиятта күренекле урын ала. Матбугатта чыккан мәкаләләрдә татар әдәбиятының киләчәген аның авторы белән бәйләп карый башлыйлар.

«XX гасыр башларынача без борынгыча яшәдек. Хәзер татар уянды. Яшәү юлында яңалыклар эзли башлады. Безнең хәятнең хәзерге көннәре — искелек җимерелеп, яңалык мәйдан ала башлаган бер дәвер. Бу дәвердә картраклар борынгы уйны, борынгы хәлләрне сакларга, яшьләр аны ватарга, җимерергә, яңа рәвешчә яшәргә тырышалар. Ике арада көрәш бара, бу көрәш бишенче елдан соң аеруча куәт алды.

«Яшь йөрәкләр» — роман. Анда искелек белән яңалыкның көрәшү дәверендәге хәлләр төрле каһарманнар аркылы тасвир ителгәннәр. Бар искелек каһарманнары: Җәләш мулла, Гәрәй мирза һәм аларның хатыннары; бар яңалык каһарманнары: Сабир, Зыя, Госман, Сәлим, Камилә һәм башкалар»,— дип яза Г. Ибраһимов «Әдәбият кануннары» китабында (1918).

Әмма әсәрнең мәгънәсен аталар белән балалар арасындагы каршылыкка гына кайтарып калдыру аның идея-эстетик кыйммәтен тарайту булыр иде. Романда, гомумән, татар халкының хәле, милләт язмышы, аның киләчәге мәсьәләсе күтә-

релгән. Ул татарның патша хакимияте алып барган колониаль сәясәте шартларында яшәвеннән тирән ризасызлык, милли азатлыкка омтылыш рухы белән сугарылган. Боларның һәммәсе шәхес иреге таләбе аша гәүдәләнгән.

Әсәрнең үзәгендә Зыя образы тора. Язучының уңай идеалы шушы образда гәүдәләнгән, романдагы башка әдәби каһарманнар аңа мөнәсәбәттә бирелгән, барлык вакыйгалар аның тирәсенә тупланып сурәтләнгән.

Зыяның төп хасияте — музыкаль сәләт иясе булуында. Бу сыйфат аның сабый чагында ук беленә һәм үсә барган рухи ихтыяҗларының эчтәлеген, юнәлешен билгели. Аңа татар көйләрен ишетү, кубыз яки гармун уйнау — яшәү өчен зарури булган мөһим шартларның берсе. Ләкин геройның рухи ихтыяҗлары ул яшәгән тормыш белән каршылыкка керә. Аның музыкага булган ихтыяҗларын, омтылышларын канәгатьләндерү өчен шартлар юк. Алар аның өендә дә, мәдрәсәдә дә, гомумән, татар дөньясында юк.

Зыяның рухи ихтыяҗларына, идеалларына каршы килә торган төп көч әсәрдә башта аның әтисе Җәләш мулла образында гәүдәләнә. Җәләш — авыл мулласы, искелекне яклаучы гаилә башлыгы. Аның характерындагы төп сыйфат — шөһрәт сөюе. Җәләшнең нәсел-нәсәбе бик мәшһүр булган. Әмма аның үзендә ата-бабаларындагы зурлык та, абруй да юк. Бары тик аларның күләгәсе генә бар. Нәкъ менә шул аңа тынгылык бирми.

Ул башта зур шәһәрнең беренче мәхәлләсенә мөдәррис булу турында хыялланган. Ләкин тормыш шартларының комачаулавы аркасындамы, башка сәбәптәнме, моңа ирешә алмаган. Бары тик авыл мулласы гына булып калган. Аның шөһрәт сөючән табигате бу хәле белән, әлбәттә, килешә алмый. Ул хәзер үзе ирешә алмаган максатка уллары ирешер, дип өметләнә. «Чөнки барыбер алар Җәләшнең угыллары, барыбер Җәләшкә угыллары аша зурлык килә».

Ләкин әсәрдән күренгәнчә, XX гасыр башында татар тормышы инде нык үзгәргән. Җәләшнең карашлары улларының карашына туры килми, аның идеаллары хәзер Зыя һәм Сабир кебек яшьләргә идеал була алмый. «Заман вә табигать тәэсиреннәндерме, атаның әмәле белән балаларның гамәле кара-каршы килеп бәрелештеләр»,— дип яза әдип.

Җәләш мулла менәзенең этәргеч көче — аның шөһрәт сөюе, мин-минлеге. Ә Зыя образының эйдәүче сыйфаты нәрсәдә соң?

Аның максаты, яшәү идеалы — туган халкына хезмәт итү, аны газаплы тормыштан коткару, азатлыкка чыгару. Ул үзе, музыка җанлы шәхес булганлыктан, халыкны азатлыкка чыгаручы, бәхетле итүче төп көчне дә музыкада күрә. Зыя уенча, музыка халыкның аяныч хәлен аның үзенә аңлатып бирәчәк, аңарда якты киләчәк өчен көрәш утын кабызачак. Ул шуңа күрә музыкаль хисләрен туган халкына җиткерү, күңелендәге музыканы халык күңеленә салу һәм шуның аркылы аның язмышын җиңеләйтү турында баш вата. Ләкин Зыя күңелендәге музыкаль ялкынны, изге теләкләрне халыкка җиткерә алмый.

«Ул, үзенең кулларының йөрәге чаклы музыкаль булып яратылмавына, скрипканың карышкалавына җаны әрнеп, берничә мәртәбә атып бәргәләсә дә», һичнәрсә эшли алмый. Чөнки аңа музыкаль тәрбия бирелмәгән, татар дөньясында аның өчен шартлар юк.

Зыя образында табигый талант белән иҗтимагый хәләт һәм гаилә тәрбиясе арасындагы тәңгәлсезлек, каршылык чагылган. Г. Ибраһимов Зыя шикелле рухи тормыш өчен яратылган шәхесләргә татар дөньясында хәтта беренчел шартлар юклыгын күрсәтә. Романны укыгач, урынлы сорау туа: үзенең рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерергә омтылган шәхес гаепле­ме яисә моның өчен тиешле шартларны тәэмин итмәгән тормыш гаделсез корылганмы?

Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларның бөтен асылы соңгысын раслый. Әнә аның иң калку гәүдәләнеше:

«— Менә тормыш! Менә хөррияте шәхсия! Яшәргә уйлыйсың, бәхет эзлисең! Бар да әрәмгә! Бар да юкка!.. Имеш, музыка хәрәм! Җыр хәрәм! Матурлык гөнаһ! Матурлык белән тәләззез[1] хәрәм!

Матурлык алдында сәҗдә итү көферлек! Соң, Илаһым, алай булгач, безгә ник мондый җан бирдең? Ник безне туң йөрәк, тупас күңел итеп яратмадың?.. Син безне хәят өчен яратмагансың, син безне туган көнебездән алып авыр трагедия эченә ташлагансың!.. Безгә хәят кирәк, безгә ирек кирәк... Бу теләкләрнең барысын да син үзең биргәнсең. Ләкин мохит моңа каршы бара. Тормыш безне кыса, безнең пакь вә гали теләкләребезгә, мәгъсум тойгыларыбызга гөнаһ дип карый...»

---

[1] *Тәләззез* — ләззәтләнү, тәм табу.

Монда татар дөньясы хакында сүз бара. Бу юллар Россия империясенең татар халкын шундый аяныч хәлгә китергән милли-колониаль системасына ләгънәт булып яңгырыйлар. Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларны тиешле эзлеклелектә ахырына кадәр дәвам иттерсәң, татар тормышын, аның Россия империясендәге социаль-сәяси хәлен тамырдан үзгәртеп кору кирәк дигән нәтиҗә килеп чыга. Зыя образына йөкләнгән идея-эстетик мәгънә әнә шуннан гыйбарәт.

Әмма авторның уңай каһарманы Зыя мондый зур эшкә әзерме соң? Һич юк. Чөнки Зыя — сүлпән шәхес. Ул җанлы иҗтимагый эшчәнлеккә сәләтсез, татар дөньясындагы гаделсезлекне күреп газап чигүче генә. Аның ихтыяр көче дә, романтик идеалларының реаль тормышта социаль-сәяси таянычы да юк, язмышы аяныч.

Зыяның язмышы аның мәхәббәт фаҗигасе белән бергә үрелеп сурәтләнгән. Уңай каһарманның хыялый булуы, гамәли эшкә сәләтсезлеге аның мәхәббәтендә дә чагыла.

Аның яшәеш мохите тар. Сабый чакта ук аңа «мужик» малайлары һәм кызлары белән аралашырга рөхсәт ителми. Ул әнисе куенында гына үсә, авылда торса да, андагы тормышны белми, аның кешеләре белән аралашмый. Зыя сабый чактан ук бергә уйнап үскән бердәнбер бала Гәрәй мирза кызы Мәрьям була.

Мәрьям — нечкә күңелле, кайнар йөрәкле, хыял белән яшәүче бер туташ. Әтисе аны, «аздырудан куркып», гимназиягә дә бирмәгән. Ул «Гәрәй мирза хәрәмендә», әнисе кочагында, «Әлфе ләйлә вә ләйлә» әкиятләрен, мәхәббәт романнарын укып кына үскән, аның хыялын шулар азыкландырган.

Яшьтән үк Мәрьямгә авыл кызларыннан өстенлеген әйтеп, «Мәрьям туташ» дип тукып торганнар. Туташ, авылда үссә дә, авыл тормышын белми, белергә дә теләми. Ул шул тормыш эчендә, әмма аның «матдилегеннән», «тупаслыгыннан» әллә никадәр югары тора.

Зыяның Мәрьямгә булган мәхәббәтендә шәхес азатлыгы, рухи ирек идеяләре гәүдәләнгән. Ләкин романтик мәхәббәт чынбарлык кануннары белән килеп бәрелешә. Зыяның солдатка алынуы аның язмышын хәл итә.

Зыя образында шәхес белән яшәеш арасындагы каршылыкның бертөрле чишелеше бирелсә, Сабир образында ул башкача хәл ителгән. Зыя шикелле үк, Сабир да Җәләшнең карашлары белән риза түгел. Ул да әтисе күрсәткән юлдан

барырга теләми, аның идеалларын кабул итми. Сабир да татар дөньясының иске тормыш нигезләренә каршы чыга. Бу яктан ул Зыя белән бергә бара. Ләкин идеал мәсьәләсендә Зыядан аерыла. Ул халык язмышы турында борчылмый, аны газаплы тормыштан коткару хакында уйланмый. Аңа шәхси иминлек кирәк. Шәхес белән чынбарлык арасындагы каршылыкны ул башкача хәл кыла: шәһәрне ташлап, ерак бер авылга, «мужик арасына» яшәргә китә. Шәһәр ыгы-зыгысыннан туйган Сабир рухи тынычлыкны җиргә һәм үз аты белән сабанына хуҗа булуда таба. Ул шунда, үзенә оя корып, тыныч яшәргә омтыла. Асылда, ул татар авылында XX гасыр башында барлыкка килгән яңа катлауны чагылдыра.

Әсәрдәге геройларга үз мөнәсәбәте мәсьәләсенә килгәндә, авторның мәхәббәте, һичшиксез, Зыя ягында. Чөнки анда, романтик рәвештә генә булса да, гуманлы идеал, шуңа омтылыш бар. Аңарда татар халкының иҗтимагый-сәяси хәле хакында борчылу, тирән уйлану, аны азатлыкка илтүнең юлларын эзләү бар. Язучы бу образны яратып иҗат итә, аңа әсәрнең эчендә киң урын бирә. Шуңа күрә романтик каһарман һәлак булып, Җәләшләр урынына Сабирларның утырып калуыннан чыгып, язучының уңай идеаллары Сабир образында гәүдәләнгән, дип карарга ярамый.

Романның кайбер үзенчәлекләре

«Яшь йөрәкләр» — Г. Ибраһимовның иҗат методы, нигездә, романтизм принципларында торган хәлдә, реалистик сурәтләү алымнары белән баюын күрсәткән әсәр. Язучының «Диңгездә», «Сөю-сәгадәт», «Уты сүнгән җәһәннәм» хикәяләрендә чагылган романтизмы монда дәвам итсә дә, җитди үзгәрешләргә дучар була. Бу үзгәрешләр иҗат методында гаять әһәмиятле булган характер мәсьәләсендә, образларны иҗат итүдә кулланылган сәнгатьчәлек алымнарында ачык чагыла.

Ул хикәяләрдә романтик шәхеснең эчке кичерешләре, рухи дөньясы озын бер монолог аркылы ачыла иде. Геройларның эчке кичерешләрен ачуда, аларның рухи дөньясын сурәтләүдә «Яшь йөрәкләр»дә дә эчке монологның роле зур. Әмма романда геройларның чын тормышына, үзара мөнәсәбәтләренә дә зур урын бирелгән, аларның характер сыйфатлары табигыйлеккә якын вакыйгалар аша ачылган.

Бу хәл язучыны образлар иҗат итүдә яңа алымнар эзләүгә китергән, «Яшь йөрәкләр»дә баштагы хикәяләрдә очрамаган

портрет һәм һәртөрле психологик анализ алымнары барлыкка килә. Әсәрдә геройлар яшәгән мохитне, социаль шартларны сурәтләүгә шактый зур урын бирелә. Язучы, төп образларны иҗат иткәндә, типик һәм шәхси сыйфатларның берлегенә ирешергә тырыша. Кыскасы, «Яшь йөрәкләр» романында романтизм иҗат методы өстенлек итсә дә, ул реализмга хас сурәтләү чаралары белән нык аралаша.

«Яшь йөрәкләр» — жанры ягыннан психологик роман. Анда иҗтимагый әһәмиятле мәсьәлә геройларның тирән, психологик кичерешләре аша сурәтләнгән. Әдипнең роман жанрына мөрәҗәгать итүе, бердән, XX гасыр башында матур әдәбият алдында торган бурычларның артуы белән аңлатылса, икенчедән, моңа Ибраһимовның әдәби осталыгы үсүе дә сәбәп булды. Язучының сурәтләү чараларына килгәндә исә, әсәрдә иң зур урынны геройлар һәм алар катнашкан вакыйгалар хакында авторның үз сөйләме алып тора.

Ул — объектив хикәя кылу. Ибраһимов геройларының үткән тормышын аларның үзләре искә төшерүе, хәтердән үткәрүләре аша түгел, бәлки, чигенеш ясап, авторның хикәя кылуы юлы белән бирә.

Образлар иҗат итүдә, әсәрдә еш очраган чараларның берсе — геройларның уйларын һәм тойгыларын тасвирлау юлы белән сурәтләү алымы. Бу алым әсәрдә рухи дөньясы азмыкүпме күрсәтелгән һәрбер образны иҗат итүдә кулланылган. Ул, гадәттә, геройларның сөйләм характеристикасы, хәрәкәтне сурәтләү, аңлатма бирү һәм башка төрле әдәби алымнар белән аралашып бара. Шушы алым белән язучының образга мөнәсәбәте дә күрсәтелә.

Сәнгатьлелек чарасы буларак портретның роле зур. Геройларның психологик портретын, аларның тышкы кыяфәтен рухи дөньясына тыгыз бәйләп сурәтләүдә Ибраһимов Л. Толстой традицияләрен дәвам иттерә. Портретта геройның рухи халәтенең аерым бер вакыттагы анык чагылышы түгел, ә холык-фигыленең даими төп сыйфаты әйтелә. Ул, гадәттә, портретның әһәмиятле бер деталендә чагыла. Ибраһимов кешенең күз карашына аеруча игътибар бирә. Җәләш, Сабир, Зыя һәм Мәрьям характерларының сыйфаты, мәсәлән, аларның күз карашларында гәүдәләнә.

Образлар иҗат иткәндә, Г. Ибраһимов каһарманнарның холык-фигыльләрен үзләреннән ачтыру алымын киң куллана. Ул монда аларның үз сөйләменнән оста файдалана. Бу —

татар прозасында аңа кадәр М. Акъегет, З. Бигиев, Г. Исхакый әсәрләрендә кулланылган алым. Сөйләм характеристикасы әсәрдә эш һәм хәрәкәтләр белән турыдан-туры бәйләнгән образларны иҗат итүдә урынлы кулланыла, ә рухи дөнья белән яшәүче геройларның характерын ачуда ул чагыштырмача сирәк очрый.

Геройларның эчке дөньясын, аларның психологик кичерешләрен ачуда эчке монологның — күңел монологының роле зур. Бу әдәби алым романда, барыннан да бигрәк, Зыя белән Мәрьям образларын иҗат итүдә кулланыла. Бу табигый да, чөнки алар — хис кешеләре, рухи кичерешләр белән яши торган шәхесләр. Шуның өстенә алар — әсәрнең идея-эстетик мәгънәсен гәүдәләндергән үзәк образлар да. Аларның уйлары һәм тойгылары аша еш кына авторның үзенең уңай идеаллары әйтелә.

Г. Ибраһимов геройлары, аеруча авыр хәлләргә калган, җитди сынаулар алдына куелган вакытта, күңел монологына мөрәҗәгать итүчән булалар. Андый чакта аларның психологиясе, эчке дөньясы гадәттәгегә караганда тулырак, тирәнрәк ачыла. Ә тискәре образларны характерлау өчен, әдип күңел монологын сирәк куллана. Фәхри образын иҗат итүдә ул, мәсәлән, бөтенләй юк. Аның эчке дөньясы күрсәтелми. Бу геройны рухи тормыштан мәхрүм итүдә үк авторның аны тәнкыйтьләве, кире кагуы сизелә.

Әсәрдә геройларның характерларын, эчке дөньясын ачуда уңышлы кулланылган чараларның тагын берсе — төш. Г. Ибраһимов аны геройларның билгеле бер психологик хәлен тирәнрәк күрсәтү өчен файдалана. Алар кешенең тормышында яңа гына булып үткән бер вакыйганы, шул вакыйганың герой психологиясенә ясаган тәэсирен аңлаталар. Төшләр еш кына геройларның зур сынау, хәлиткеч вакыйга алдыннан булган эчке кичерешләрен күрсәтәләр. Мондый очракта алар геройның рухи дөньясын ачып кына калмыйлар, алдагы вакыйгаларның нинди юнәлештә булачагын да хәбәр итәләр.

Әсәр Мәрьямнең төш күрүе белән башланып китә. Анда романда сурәтләнәчәк вакыйгаларга алдан ук ишарә ясала. Бу алымны А. С. Пушкин әсәрләрендә («Евгений Онегин»да Татьяна, «Борис Годунов»та Григорий төшләре) очратырга мөмкин. Аеруча, «Капитан кызы» романының башында ук, Гринёвның буран көнне күргән төшеннән Гринёв белән Пугачёв арасында нинди мөнәсәбәт урнашачагын алдан ук сизәсең.

Л. Н. Толстойның «Анна Каренина»сында Аннаның беренче төшендә дә шулай ук героиняның язмышына ишарә ясала. «Яшь йөрәкләр»дәге Мәрьям төше дә шундый вазифаны үти.

Ниһаять, геройларның эчке дөньясын ачуда пейзажның роле зур. Г. Ибраһимов «Яшь йөрәкләр»дә табигать күренешләренең гүзәл тасвирларын бирде. Алар авторга геройларның күңелендә теге яки бу халәтне тудыруга хезмәт итә. Әсәрдә пейзаж геройларның эчке кичерешләренә янәшә яки капма-каршы куеп сурәтләнә. Һәр ике очракта да ул аларның эчке дөньясын тирәнрәк ачарга ярдәм итә.

Г. Ибраһимов әсәрләрендә табигать тасвирлары баш геройларның язмышына һәм әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларга язучы тарафыннан бирелгән әхлакый-фәлсәфи шәрехләү рәвешендә дә килергә мөмкин. Мәсәлән, «Яшь йөрәкләр»нең эпилогындагы пейзаж. Биредә табигать күренешләре Зыяның туганнары һәм дусларының эчке кичерешләре, авторның үз фәлсәфи уйланулары белән аралаштырып сурәтләнгән. Ул Зыя кебек сәләтле шәхесләрне һәлакәткә дучар иткән тормыштан ризасызлыкны чагылдыра. Бу пейзажда шул чорның социаль тәртипләренә читләтелгән протест яңгырый.

Язучы бу романы белән татар әдәбиятында психологик анализ чараларының күп кенә төрләренә (күңел монологы, төшләр, монолог-хат, психологик портрет, лирик пейзаж һ. б.) тулы хокук бирде. «Яшь йөрәкләр» милли әдәбиятта романтизмның күп кенә уңай сыйфатларын урнаштырды. Ул татар прозасының, дидактизмнан һәм примитивлыктан арына барып, прогрессив романтизм элементларын үзләштергән хәлдә, чын реализмга юл алуын раслады. Г. Ибраһимов тәнкыйди реализм дип аталган иҗат методын романтизмның сурәтләү чаралары белән баетты.

Романтизм дип аталган әдәби-эстетик күренеш татар әдәбиятында 1905 ел инкыйлабы нәтиҗәсендә барлыкка килгән гомумдемократик күтәрелеш, социаль һәм милли азатлык хәрәкәте шартларында формалашты. Ул дөнья классикларының иҗат алымнары белән нык сугарылган романтизмның да, реализмның да күп кенә сыйфатларын бергә җыйган күренеш буларак туды.

«Яшь йөрәкләр» романы татар прозасының эстетик тәэсир итү көче артуына, сурәтләү чараларының баюына һәм камилләшүенә ярдәм итте. Ибраһимовның бу чор иҗатында чагылган прогрессив романтизм һәм реализм элементлары язучы-

ның киләчәктә реализм юлыннан үсүенә ныклы җирлек хәзерләделәр.

Г. Ибраһимов әдәби иҗатында икенче күтәрелеш чоры 1912 ел ахырларыннан башлана. Бу чорда язучының, сәяси карашлары үсешенә бәйле рәвештә, иҗатында да җитди үзгәрешләр, яңа сыйфатлар барлыкка килә. Алар реалистик элементларның ныгуы, тирәнәюе белән бәйләнгән.

Монда Киев вакыйгаларының роле зур була. Язучы хәзер үзенең әсәрләрендә социаль мәсьәләләрне күтәрә башлый, «тормыш төбендә» яшәүчеләрнең образларын сурәтләүгә борылыш ясый. «Карт ялчы», «Көтүчеләр» хикәяләре — шуның ачык мисаллары.

Ул әсәрләрдә иҗтимагый азатлык, түбән катлау кешеләре өчен бәхетле тормыш мәсьәләсе куела, хезмәт халкын социаль гаделлеккә алып чыгу юллары эзләнелә. Г. Ибраһимов хезмәт иясе исеменнән кешелек дөньясының бөек галимнәренә, олуг философларына һәм рәссамнарына мондый сорау белән мөрәҗәгать итә: «Сезнең юлыгыз хата түгелме? Сез үзегезгә тапшырылган көтүнең җәфалануы өчен, үзегезнең мәсьул[1] икәнлегегезне игътираф[2] итеп, адәм балаларына башка юллар эзләргә, башка көтүчеләр, башка илчеләр табарга чакырмыйсызмы?»

Социаль һәм милли азатлык өчен көрәш юлына баскан каһарманнар образын Г. Ибраһимов «Безнең көннәр» романында бирде. Бу әсәрне язучы иҗатындагы икенче этапның югары ноктасы дип санарга кирәк. Аның басыла башлап та патша хакимияте тарафыннан тыелуы, конфискацияләнүе юкка гына түгел иде. Чөнки ул 1905 ел инкыйлабын, патша Россиясенең колониаль системасына каршы татарларның көрәшен күрсәтүгә багышлана. Ә яңа инкыйлаби күтәрелеш елларында патша хакимияте өчен бу хәтәр нәрсә иде.

«Безнең көннәр» романы бары тик 1917 ел инкыйлабыннан соң гына дөнья күрә алды. Әдип аның 1920 елда бернинди үзгәрешсез, 1914 елда ничек язылган булса, шул хәлендә басылып чыгуына басым ясап әйтте.

Г. Ибраһимовның шушы чорда иҗат ителгән тагын ике әсәрен күрсәтеп үтәргә кирәк. Алар — «Табигать балалары» һәм «Мәрхүмнең дәфтәреннән» хикәяләре.

---

[1] *Мәсьул* — җавап кеше.
[2] *Игътираф* — тану.

«Табигать балалары»нда крестьян егете Хафиз болында печән өмәсендә авылның иң атаклы печән чабучысын җиңеп чыга һәм нәтиҗәдә аның чибәр кызын — үзенең сөйгәнен алу бәхетенә ирешә. Шушы гади генә сюжет язучыга табигать кочагында чыныгып үскән хезмәт баһадирларының рухи дөньясын тирән итеп, бөтен матурлыгы белән күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Беренче карауда гади генә булып күренгән җир улларының искиткеч бай рухи дөньясы, саф әхлак йөзе укучыда көчле тәэсир калдыра. «Табигать балалары» туган җиргә мәхәббәт тәрбияли, хезмәт кешесенә дан җырлый, яшәү шатлыгын раслый. Ул — Г. Ибраһимов иҗатында еректан ялтырап торган, беркайчан да тутыкмас мәрҗәннәрнең берсе.

Ә «Мәрхүмнең дәфтәреннән» хикәясендә әдәбият һәм сәнгатьнең иҗтимагый роле мәсьәләсе куела. Аны язучының ул чордагы идея-эстетик программасы дип санарга мөмкин.

Әдәби тәнкыйть һәм публицистик эшчәнлеге

Г. Ибраһимов XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте һәм публицистикасы үсешенә дә зур өлеш кертте.

1917 елгы инкыйлабка кадәрге чорда ук инде татар әдәби тәнкыйте мөстәкыйль тармак булып формалашып җиткән, аның Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Җ. Вәлиди, Г. Газиз, Г. Кәрам шикелле күренекле вәкилләре бар иде. Г. Ибраһимов алар белән бергә татар әдәби тәнкыйтенең нигез принципларын билгеләде. Бу җаваплы эшне башкарганда, ул гомумкешелек әдәби-эстетик принципларына таянды.

Әдәбият һәм сәнгатьнең асылы һәм үзенчәлеге, аларның тормышка мөнәсәбәте, үсеш этаплары, талант һәм аның җәмгыять тормышы белән бәйләнеше, язучының дөньяга карашы, реализм һәм халыкчанлык, типиклык, милли әдәбиятның Көнбатыш һәм Көнчыгыш әдәбиятларына мөнәсәбәте һ. б. мәсьәләләр аның әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә, хезмәтләрендә киң чагылыш тапкан. Ибраһимовның әдәби тәнкыйть һәм публицистик эшчәнлегендә татар әдәбиятының барышына, әдәби жанрларның үсешенә, аерым язучыларның әдәби агымдагы урынына, татар матбугатына, милли театрга, әдәби телгә, милли тарихка бәйләнешле мәсьәләләр дә зур урын алып тора.

Аның «Борынгы ислам мәдәнияте» исемле китабы, «Без татарбыз», «Рус, төрек вә татар тарихыннан», «Милли та-

рих» исемле мәкаләләре күренекле мәгърифәтче һәм галим Ш. Мәрҗани турындагы хезмәтләре, Г. Тукай, Дәрдемәнд, С. Рәмиевләр иҗатына багышланган «Татар шагыйрьләре» китабы XX йөз башы тәнкыйтенең кыйммәтле сәхифәләрен тәшкил итәләр. Ул әдәбият теориясе һәм эстетика мәсьәләләренә мөрәҗәгать итте. Татар әдәби хәрәкәтенә еллык күзәтүләр ясауны гамәлгә кертте һәм инкыйлабка кадәр үк башланган бу эшне егерменче елларның беренче яртысында да дәвам иттерде.

Әдипнең 1914—1916 еллардагы әсәрләре һәм тәнкыйть мәкаләләре патша хакимиятенә каршы көрәш рухы белән сугарылган.

Г. Ибраһимов колониаль изелү шартларында яшәгән милләтләрнең мәдәният багланышларына зур әһәмият бирә. Аның украин, казах һәм башка халыкларның әдәбиятлары турындагы мәкаләләре шуны раслый. Бөек украин шагыйре Т. Г. Шевченконың йөзьеллык юбилее уңае белән Киевта язган «Каһарман шагыйрь» исемле мәкаләсе аеруча игътибарга лаек. Анда татар язучысының украин шагыйренә кайнар мәхәббәте һәм хөрмәте, аның каһарманлыгына соклану, милли азатлык өчен көрәштә халыклар дуслыгы идеяләре гәүдәләнгән. Г. Ибраһимов Тарас Шевченконы украин халкының милли азатлык каһарманы дип саный, аның иҗатында чагылган азатлык мотивларының татар халкы өчен дә уртак булуын әйтә. «Ул — хөррият каһарманы,— дип яза автор.—Болардан бигрәк ул мәхкүм[1] бер халыкның киң, якты бер дөньяга чыгу юлындагы тарихи идеалының тәмсалы мөҗәссәме[2]. Ул — малорус халкының бөтен иҗтимагый әмәлләренең символы... Мин шагыйрь-каһарманның урынында, халкының язмышында, милли кайгыларында безгә куәтле бер якынлык күрәм».

Патша хөкүмәтенең Шевченко юбилеен үткәрүне тыйган булуын да искә алсак, бу мәкаләнең әһәмияте тагын да ныграк аңлашылыр. Нәкъ шундый вакытта татар матбугатында бөек украин шагыйре турында ялкынлы, инкыйлаби рухлы мәкаләнең басылуы милли азатлык өчен көрәш максатларына хезмәт итте.

---

[1] *Мәхкүм* — хөкем ителгән.

[2] *Тәмсалы мөҗәссәме* — гәүдәләнгән үрнәге.

Г. Ибраһимов, татар әдәбиятын дөнья әдәбиятының аерылгысыз өлеше, дип саный, аны дөнья классикларының әдәби-эстетик казанышлары белән баетырга чакыра. «Безгә... фәкать үз кабыгыбызга бикләнеп калырга мөмкин түгел,— дип язды ул 1915 елда.— Безгә гакыл вә фикеребезне гомум бәни адәм офыгына таба юнәлдерергә... бөтендөнья әдәбиятының тарихи агымнары белән дә танышырга лазем[1] булачак».

Г. Ибраһимов дөнья әдәбияты байлыгын Көнбатыш белән генә чикләми. Бу орбитага ул Көнчыгыш классик поэзиясен һәм философиясен дә кертә: «Киләчәк көнебезнең яктыруы өчен, Гареп мәдәнияте белән файдалануыбыз никадәрле лазем булса, шул нисбәттә үк, безгә Шәрыкнең үткәне белән дә танышырга, Шәрык даһиларының хикмәт вә шигырьләре белән дә азыкланырга тиештер. Гомер, Данте, Шекспир кебек Гареп классиклары илә янәшә утыртып, алларына бердәй тезләнергә фарыз булган Шәрык даһиларын хәтергә ала башларга вакыттыр дип уйлыйм. Мәдрәсә көрсиләренә[2], аннан бөтен татар йөрәгенә «Илиада»лар, «Илаһи комедия»ләр белән бергә үк гарәпнең Мәгарри, Фирдәүсинең «Шаһнамә»ләре, Сәгъди белән Фозулинең «Гөлстан» вә «Ләйлә — Мәҗнүн»нәре кереп утырырга... тиешледер».

Әдипнең ул чордагы әдәби тәнкыйть мәкаләләре — 1917 ел инкыйлабына кадәрге татар тәнкыйте һәм эстетик фикер үсешенең югары ноктасы.

Совет хакимияте урнашкач

Г. Ибраһимовның Совет чорындагы иҗтимагый эшчәнлеге 1917 елгы Октябрь борылышыннан соң 20 ноябрьдә Уфада җыелган «Милләт мәҗлесе» утырышларында катнашудан башлана. Анда татар халкының милли дәүләт төзелеше мәсьәләсе тикшерелә. Г. Ибраһимов һәм аның тарафдарлары территориаль автономия идеясен яклап чыгалар.

Г. Ибраһимов Учредительное собраниегә сайлаулар кампаниясендә дә актив катнаша. Бу сайлаулар 1917 елның ноябрендә, Октябрь борылышыннан соң, әмма партияләрнең аңа кадәр үк төзелгән исемлекләре буенча үткәрелә. Г. Ибраһимов учредилкага делегат булып Уфа губернасында яшәүче татар

[1] *Лазем* — тиеш, кирәк, зарур.
[2] *Көрси* — кафедра.

эшчеләре, крестьяннары һәм солдатлары өчен махсус төзелгән исемлек буенча сайлана.

Әдипнең шуннан соңгы иҗтимагый эшчәнлеге Петроград һәм Мәскәү шәһәрләре белән бәйләнгән. Ул Петроградка 1918 елның 5 гыйнварында килә. Бу нәкъ Учредительное собрание ачылган көн була.

Әдип большевиклар, сул эсерлар һәм башка сул делегатлар белән учредилканы ташлап чыга. Шуннан соң 6 гыйнварда Совет хөкүмәтенең декреты белән Учредительное собрание таратыла.

1918 елның 10 гыйнварында эшче-крестьян һәм солдат депутатлары советларының III Бөтенроссия съезды җыела. Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитеты карары нигезендә анда, учредилканы ташлап чыккан большевик һәм башка сул делегатлар белән бергә, Г. Ибраһимов та катнаша. Анда ул Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитеты әгъзасы итеп сайлана.

1918 елның азагында Совет хөкүмәте Милләтләр халык комиссариаты каршында Үзәк мөселман комиссариаты төзи. Аның рәисе итеп Мулланур Вахитов, ә урынбасарларыннан берсе итеп Г. Ибраһимов раслана. Г. Ибраһимов — Үзәк мөселман комиссариаты каршында татар телендә чыга башлаган «Чулпан» газетасының оештыручысы һәм мөхәррире. 1918 елның мартында әдип, Совет хөкүмәте һәм Үзәк мөселман комиссариаты белән бергә, Мәскәүгә күчә. Советларның 14 мартта җыелган гадәттән тыш IV Бөтенроссия съездында Брест солых договорын раслауда катнаша.

Г. Ибраһимов,— М. Вахитов белән бергә, Татар-башкорт республикасын төзү мәсьәләсен көн тәртибенә куючыларның, аның положениесен әзерләүчеләрнең берсе. Ул документ матбугатта 1918 елның 22 мартында игълан ителә.

Бу положение игълан ителүнең икенче көнендә үк Г. Ибраһимов, аның төп маддәләрен аңлатып, «Чулпан» газетасында махсус мәкалә язып чыга, аның татар, башкорт халыкларының теләк-омтылышларын чагылдыруын күрсәтә. Әдип Татар-башкорт республикасы турындагы бу рәсми документны халык арасында пропагандалап кына калмый, аны эшкә ашыру юлындагы күп кенә оештыру чаралары үткәрүдә дә актив катнаша. Ул — Татар-башкорт республикасын төзү съездын җыю мәсьәләсе буенча Мәскәүдә Милләтләр халык комиссариаты һәм Татар-башкорт комиссариаты (ул вакытта

Үзәк мөселман комиссариатының исеме шулай дип үзгәртелгән була) тарафыннан үткәрелгән киңәшмәне оештыручыларның берсе. Ләкин Татар-башкорт республикасын төзү планы, аннан элегрәк, 1917 елның ноябрендә Уфада «Милләт мәҗлесе»ндә С. Максуди, Г. Исхакый, Й. Акчуралар тырышлыгы белән кабул ителгән «Идел-Урал штаты» проекты кебек үк, Совет хөкүмәте тарафыннан тормышка ашырылмый калды.

Үзәк мөселман комиссариатында җаваплы эшләр белән мәшгуль булуына да карамастан, Г. Ибраһимов халык белән элемтәсен югалтмый. Ул ашыгыч йомышлар белән еш кына төбәкләргә бара, анда төрле чаралар үткәрә. 1918 елның май ахырында, мәсәлән, Казанда Бөтенроссия мөселман укытучыларының III корылтаен уздыруда катнаша, 1918 елның җәендә, М. Вахитов Казанга гражданнар сугышы кызган җиргә киткәч, Г. Ибраһимов Мөселман комиссариатының җитәкчесе булып кала. Кыен шартларда ул аның өзлексез эшләвен тәэмин итә. 1918 елның октябрь урталарында әдип Казанга кайта.

1919 елның язында, Колчак гаскәрләре көнчыгыштан ябырылып килгән чакта, Г. Ибраһимов аклар тылына китә. Бик күп шәһәр һәм авылларны үтеп, Урал һәм Көнбатыш Себерне йөреп чыга, Колчак хакимлегендәге кешеләрнең хәле белән таныша, аларның Колчакка һәм Кызыл Армиягә мөнәсәбәтен өйрәнә. Анда күргән-белгәннәре әдипнең киләчәктә сәяси позициясен билгеләүдә мөһим роль уйнады, иҗаты өчен бай материал бирде. Бу сәфәре тәмамлангач, Г. Ибраһимов Казанга кайта һәм, кайбер кыска вакытлы китеп торуларын искә алмаганда, даими рәвештә 1927 елга кадәр биредә яши.

1920 елның 26 сентябрендә Г. Ибраһимов Казанда Татарстан АССР Советларының I оештыру съездында катнаша, анда Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты әгъзасы булып сайлана. 1920 елның декабрендә ул, рәсми рәвештә эсерлар партиясеннән чыгып, большевиклар партиясенә керә.

Г. Ибраһимов — Татарстан матбугатын оештыручыларның берсе. «Эшче», «Кызыл Армия», «Кызыл яшьләр» газеталарының башлангыч адымнары аның исеме белән бәйләнгән. Татарстан республикасы төзелгәннән соң, Казанда чыга башлаган педагогик һәм әдәби журналлар да турыдан-туры аның катнашы белән барлыкка киләләр. Г. Ибраһимов — «Безнең

юл» һәм «Мәгариф» журналларын оештыручы, аларның мөхәррирләреннән берсе.

Ул милли мәгариф эшен юлга салуда да зур эш башкара.

Аның 1924 елның февралендә Мәскәүдә үткәрелгән Татар-башкорт мәгариф эшчеләре съездындагы эшчәнлеге мөһим. Ул анда милли мәктәпләрнең үсеше, аларда укыту-тәрбия эшләрен яхшырту, программа һәм дәреслекләр төзү һ.б. мәсьәләләрне тикшерүдә катнаша.

1925 елның башында Г. Ибраһимов Татарстан хөкүмәте карары белән ТАССР Мәгариф халык комиссариаты каршындагы гыйльми үзәк рәисе һәм комиссариатның коллегия әгъзасы итеп раслана. Анда ул 1927 елга кадәр, каты авырып Кырымга күчеп киткәнче эшли. Бу әһәмиятле дәүләт органы эшендәге иң бай, иң нәтиҗәле чор нәкъ менә ул җитәкләгән елларга туры килә. Г. Ибраһимовның зур галим, фәнни-тикшеренү, мәгариф һәм мәдәният эшләрен оста оештыручы булуы да тулысынча нәкъ әнә шунда күренде.

Гыйльми үзәк Татарстан мәктәпләре өчен программалар төзү, дәреслек һәм кулланмалар бастырып чыгару эшен юлга сала; татар телен гыйльми-әдәби эшкәртү чараларын үткәрә. Шулай ук туган якны өйрәнү, татарлар арасында иҗтимагый фикер үсеше һәм инкыйлаби хәрәкәт тарихын тикшерү, әдәби мирасны җыю һәм бастырып чыгаруда зур эш башкара.

Г. Ибраһимов инкыйлаби хәрәкәт, мәгариф һәм әдәбият тарихы буенча гыйльми хезмәтләр яза һәм фәнни-тикшеренү эшендә зур сәләт күрсәтә. Аның 1925 елны Казанда татар һәм рус телләрендә басылып чыккан «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре», «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» (1924) исемле хезмәтләре, К. Насыйри, Ш. Мәрҗани турындагы һәм татар әдәбияты тарихына караган башка мәкаләләре зур әһәмияткә ия.

Ибраһимовның әдәби тәнкыйть мирасының да шактый өлеше Совет чорына туры килә. Ул гражданнар сугышы тәмамланган көннән алып егерменче еллар ахырына кадәр әдәби хәрәкәтнең башында тора, гомеренең соңгы ун елында җанлы әдәби процесстан аерылгач та, тәнкыйть каләмен кулдан төшерми, аерым мәкаләләрендә, каләмдәшләренә һәм дусларына, укучыларга язган хатларында әдәбият үсешенең актуаль мәсьәләләрен яктырта.

Егерменче елларда Г. Ибраһимов, язучы, фән һәм мәдәният эшлеклесе буларак, бер Татарстанда гына түгел, бөтен

ил күләмендә танылa. Аны күп кенә гыйльми җәмгыятьләр мактаулы яки хакыйкый әгъза итеп сайлыйлар. 1928 елда ул Бөтенроссия Сәнгать фәннәре академиясенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлана.

1932 елда Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитеты аңа «Хезмәт батыры» исеме бирә. Башкарма комитетның ул турыдагы карарында болай диелгән: «Татар хезмәт ияләренең социаль-мәдәният өлкәсендәге бик күренекле һәм аеруча файдалы хезмәтләрегезне — татар матур әдәбиятының классик әсәрләрен тудыру, татарлар арасында сыйнфый көрәш һәм инкыйлаби хәрәкәтне өйрәнү буенча хезмәтләрегезне, шулай ук актив җәмәгать эшчәнлегегезне искә алып, Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитеты президиумы Сезгә «Хезмәт батыры» дигән исем бирә».

Каты авыру сәбәпле, Г. Ибраһимов соңгы ун ел гомерен Кырымда үткәрде. Татарстан хөкүмәте анда язучыга яшәү һәм дәвалану өчен кирәкле шартларны тудырырга тырышты.

Әдип Ялтада да иҗат эшен туктатмады. «Татар хатыны ниләр күрми» повестен яңадан язды, «Безнең көннәр» романының яңа вариантын иҗат итте, тарихка һәм әдәбиятка багышланган хезмәтләрен тәмамлау өстендә эшләде.

1933 елның көзендә Г. Ибраһимов Казанга кайтып китә. Татарстан хөкүмәте чакыруы буенча, ул республика колхозчы-ударникларының II съездында кунак булып катнаша. Завод һәм колхозларда була, эшчеләр һәм крестьяннар, әдәбият, сәнгать әһелләре белән очраша. Ялтага кайткач, ул «Хәят дулкыннары» трилогиясенең икенче һәм өченче кисәкләрен язуын дәвам итә, «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» тарихының икенче кисәген һәм «Әдәбият кануннары» китабын тәмамлау өстендә эшли.

Кызганыч, әдип иҗат планнарын тормышка ашыра алмады. Ул тоталитар режимның, Сталин репрессияләренең корбаны булды. 1937 елның августында Г. Ибраһимов Ялтада кулга алына, Казанга кайтарыла. Авыру язучы төрмә газапларын кичерә алмый, 1938 елның 21 гыйнварында Казанда Пләтән төрмәсендә вафат була.

Мәшһүр әдипнең тормышы әнә шулай фаҗигале рәвештә өзелә.

Язучының Совет чорындагы әдәби иҗаты

Г. Ибраһимов, 1917 елгы Февраль, Октябрь инкыйлаблары, аларның дәвамы булган гражданнар сугышы вакыйгаларында катнашуы нәтиҗәсендә, татар халкы азатлыкка, бәхетле тормышка иҗтимагый инкыйлаб, сыйнфый көрәш аркылы ирешәчәк, дигән фикергә килә. Егерменче еллар башында иҗат иткән әсәрләрендә ул уңай герой итеп шул көрәшләрдә актив катнашучылар образын сурәтли. Ә Гаяз Исхакый бу чорда халыкның азатлыкка ирешүен милли бердәмлектә күрә, сыйнфый көрәшнең чикле булуын, җәмгыятьтә аерым катлауларны капма-каршы куюын дәлилли. Кызганыч, Г. Ибраһимов моны инкяр итте.

Әдипнең Совет чорында язган беренче әсәре «Яңа кешеләр» драмасы булды. Анда гражданнар сугышы — язучының Колчак тылында үзе күргән вакыйгалар сурәтләнә. Пьесаның үзәгендә кызыл командир Батырхан һәм авыл укытучысы Камәр образлары тора.

Язучының бу юнәлештәге идея-эстетик эзләнүләре «Кызыл чәчәкләр» хикәясендә (1922) дәвам иттерелә. Бу әсәрдә Агыйдел буена урнашкан татар авылларының берсендә туып үскән биш егетнең 1917 елгы инкыйлабларда, гражданнар сугышында катнашулары, соңыннан фаҗигале язмышлары сурәтләнә.

Совет чорында әдип татар прозасын киң пландагы җәүһәрләр белән генә түгел, кечерәк күләмле әсәрләр белән дә баетты. 1922 елда язылган «Алмачуар» хикәясе — шуның ачык мисалы. Бу әсәрдә Г. Ибраһимов ат яратучы крестьян малае Закирның күркәм образын иҗат итте, аның үзенчәлекле характерын, бай эчке дөньясын, кичерешләрен күрсәтте.

«Алмачуар» — XX йөз башы татар авылы тормышын, аның гүзәл табигатен, хезмәтчел кешеләрен, гореф-гадәтләрен, өметхыялларын чагылдыручы классик әсәр. Авыл кешесенең җир белән бергә яшәү һәм хезмәт символы булган атка сабый бала мәхәббәте аркылы язучы туган җиргә, аның табигатенә һәм кешеләренә, андагы яшәешкә дан җырлый, яшь буынны патриотизм рухында тәрбияли.

Совет чорында Г. Ибраһимовның иҗат методы, характерлар иҗат итү принциплары реалистик нигездә үсә. Алар арасында аеруча әһәмиятлесе — геройларның эш-хәрәкәтләре яшәеш кануннары белән бәйләнештә бирелүе. Шуның белән бергә,

язучының иҗат практикасында романтизм традицияләре дә саклана һәм үсә бара. Болар, мәсәлән, гадәттән тыш халәтләргә игътибар итүдә, геройларны гадәттәгедән күп калку итеп күрсәтүгә омтылышта, стиль чараларының хисси-лирик буяулар белән нык сугарылган булуында күренә.

Алар чынбарлыкны сурәтләүнең реалистик принциплары белән бергә кушылалар.

«Казакъ кызы» романы

Г. Ибраһимовның киң колачлы талант иясе булуы әдәби иҗатында ачык чагылды. Ул татар дөньясы белән генә чикләнеп калмады, башка халыклар тормышына да үтеп керде. 1924 елда Мәскәүдә басылып чыккан «Казакъ кызы» романы — әнә шуның ачык мисалы.

Бу әсәр, 1923 елның көзендә тәгәлләнгән булса да, языла башлау тарихы әле революциягә кадәрге чорга ук карый. Г. Ибраһимов аны 1909 елның җәендә Уралда Миасс заводы посёлогында яшәгән чагында яза башлап, 1911 елда Казанда тәмамлый. Ләкин роман, шул ук елда Оренбургтагы «Вакыт» нәшрияты тарафыннан басарга кабул ителсә дә, дөньяга чыга алмый. Кульъязма типографиягә бирелгәч, тентүләр вакытында жандармерия тарафыннан конфискацияләнә. 1912—1913 елларда Г. Ибраһимов аны кулында калган караламасы буенча яңадан язып чыга. Ләкин әсәр тагы бәлагә тарый: шул елның язында Киевта язучы кулга алынган чакта, китаплары һәм барлык кульъязмалары белән бергә, ул яңадан охранкага эләгә.

«Безнең көннәр» романы шикелле үк, бу әсәрне бастырып чыгару әдипкә бары тик 1917 елдан соң гына насыйп булды.

Г. Ибраһимов бу әсәрендә казакъ кызы язмышы мисалында инкыйлабларга кадәрге казакъ тормышын сурәтләүне максат итеп куя. Анда сурәтләнгән вакыйгалар, романда китерелгән кайбер тарихи мәгълүматлардан аңлашылганча, XIX гасыр ахыры — XX гасыр башындагы чорга карый.

Ул вакытта инде Казакъстанның Россиягә буйсындырылуы тәмамланган була. Гәрчә дала тормышында патриархаль-феодаль мөнәсәбәтләр әле сакланып килсә дә, анда инде капиталистик мөнәсәбәтләр дә үтеп керә башлый. Әсәрдә казакъ кызының язмышы әнә шул социаль-сәяси үзгәрешләргә ты-

гыз бәйләнештә сурәтләнгән. Әдип тугандаш халыкның мөһим бер иҗтимагый үсеш баскычындагы катлаулы тормыш панорамасын тудыра.

«Казакъ кызы» романының каһарманы Карлыгач-Сылу әле яшь ярымлык чакта ук күрше ыругның ай ярымлык ир баласына ярәшелеп, аның өчен 100 баш терлек, 400 алтын, ике сандык асыл зат калым алып куелган була. Кызның әтисе Сарсымбай моны сарман һәм кара-айгыр ыруглары арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгыту, казакъча әйткәндә, җир берлеген кан белән беркетү өчен шулай эшли. Горур кызының, киләчәктә үз иреге өчен, ата-бабадан калган гадәтләргә каршы баш күтәрәчәге һәм шуның нәтиҗәсендә бер әтисе ыруына гына түгел, бөтен кавем-нәселенә күп мәшәкатьләр, кыенлыклар тудырачагы, билгеле, аның башына да килми.

Карлыгач-Сылу, бай кызы булганлыктан, мул тормышта үсә, дала киңлекләрендә уйный-көлә, әнисе кочагында назлана, яраткан әтисе кулында иркәләнә. Ниһаять, дала кызы үсеп буйга җитә, сахраның матуры булып җитешә.

Г. Ибраһимов Карлыгач-Сылу образында табигый гүзәллекне генә түгел, хатын-кызның рухи азатлыкка омтылышын да күрсәтә. Аны кош исеме белән Карлыгач-Сылу дип атау — үзе үк әнә шуңа ишарә. Язучы кош кебек хөр табигатьле горур сылу образында казакъ кызларының барысында да, хәтта бер аларда гына булмыйча, гомумән, мөселман хатын-кызы табигатендә тирән яшеренгән рухи азатлыкка омтылыш хисләрен чагылдыра.

Карлыгач-Сылуның омтылышлары, табигый булып, барыннан да элек, аның мәхәббәтендә чагыла. Ә мәхәббәт чаткысы анда тәүге тапкыр зур туйларның берсендә, яшь егетләр белән кызлар ачыктан-ачык җыелып утырган җирдә кабына.

Казакъ кызының йөрәгендә кабынган мәхәббәт хисләренә ирек бирергә, яраткан егетенең тышкы матурлыгын күреп белергә генә түгел, холкын сынап карарга да мөмкинлеге бар. Әсәрдә мондый сынауның үзгәлекле бер төре сурәтләнә. (Сарсымбай авылының икенче бер җәйләүгә күчүе вакытында, ат өстендә уйнаклап барган Карлыгач-Сылуның Арысланбай белән очрашу эпизодын искә төшерик.)

Мондый шартларда үскән иркә кыз, әлбәттә, элекке гадәт буенча әзерләнеп куелган язмыш белән генә килешә алмый. Казакъ гадәте буенча байлыкка сатылган бик күп кызларның

гыйбрәтле хәлен ул көн саен күреп тора. Г. Ибраһимов әсәрдә, Карлыгач-Сылу мәхәббәтенә капма-каршы итеп, гаилә тормышыннан бәхет тапмаган, фаҗигале язмышка дучар ителгән казакъ хатын-кызларының тулы бер галереясын бирә.

Шундыйларның берсе аның үз өендә үк. Ул — Карлыгач-Сылуның әтисе Сарсымбайның тукалы (яшь хатыны).

Тукал — шулай ук казакъ йортындагы гадәтнең корбаны. Ул башта Сарсымбайның туган энесенә әйттерелгән булган. Ләкин егет сугышта үлгәч, калымга алынган мал кире китмәсен дип, әтиләре аны Сарсымбайга биргәннәр. Әмма олы бичә өстенә килен булып төшкән җирдә аңа гаилә кояшы елмаймаган. Сарсымбай өендә ул үзенә бәхет тә, рәхәт тә, рухи тынычлык та тапмаган. Яшь хатын — байның хезмәтчесе хәлендә, йорт эшләренең бөтенесе аның җилкәсендә.

Тукал үзенең мондый хәлен, әлбәттә, авыр кичерә. Ләкин нишләмәк кирәк? Бу бит бер аның башына гына төшкән бәхетсезлек түгел. Мондый хәл — казакъ йортының тимер кануны. Ялгыз башы аның бу тәртипләрне җимерерлек көче юк. Ул бары тик еллар буена эчендә сакланган, йөрәгенә кара кан булып сауган авыр хәсрәтен караңгы төндә шундый ук фаҗигале язмышка дучар ителгән икенче бер карчыкка, үкси-үкси сөйләп, эчен генә бушата ала.

Ләкин казакъ йортында яшь хатын җилкәсенә төшкән кыенлыклар никадәр зур һәм дәвамлы булмасын, алар барыбер аның хатын-кызлык горурлыгын сындыра алмыйлар. Бу горурлык аны байбичә белән гомер буе эчке каршылыкта яшәтә яки, байның йөрәгенә ачкыч эзләп, багучыга илтә, һич тә булмаса, казакъ арасында балалар укытып йөргән татар молдакәсе кочагына ташланырга мәҗбүр итә.

Г. Ибраһимов тарафыннан иҗат ителгән хатын-кыз образларының һәрберсендә мөселман хатын-кызы язмышының кайсы да булса бер ягы чагыла. Мәсәлән, Карлыгач-Сылуның яшьлек дусты Чулпан образын алыйк. Язучы бу образда казакъ хатынының кыз чагындагы хәле белән килен булып төшкәч башланган авыр тормышы арасындагы зур аерманы күрсәтә.

Чулпан белән очрашканнан соң, Карлыгач-Сылу үзенә дә гореф-гадәтләр корбаны булу куркынычы бик якын торганлыгын тагын да ачыграк аңлый. Нәкъ әнә шуннан соң инде ул һичбер икеләнүсез-нисез туган җәйләвеннән үзенең сөйгән егете белән качып китә. Сылу кыз бу адымы белән рәхимсез

тормыш тәртипләренә, казакъ илендә яшәп килгән иске гадәтләргә, ярәшеп куелган егет ыругының кодалык намусына ачыктан-ачык чакыру ташлый. Әсәрдән күренгәнчә, Карлыгач-Сылу ахыргача үзенең мәхәббәтенә тугрылыклы булып кала. Горур табигате аны сөйгән ире һәм этисе артыннан сөргенгә китүдән дә куркытмый.

Г. Ибраһимов бу образда мөселман хатын-кызларының үзләренең хокукы өчен көрәш үрнәген күрсәтте. Ә казакъ кызының соңгы адымын ирләре артыннан Себергә киткән декабрист хатыннарының батырлыгына тиңләргә мөмкин. Татар әдәбиятында Г. Ибраһимовка кадәр мөселман хатын-кызының мондый кыю образын биргән әсәр юк иде әле.

Күчмә тормышта яшәүче казакъ ыругларының иминлеге җир-су белән бәйләнгән. Шуңа күрә төрле ыруглар арасында яхшы җирләр өчен бертуктаусыз тартыш-көрәш бара. Бу көрәш кайбер вакытларда, пыскып яткан учак шикелле, эчтән генә көйри, ә кайчакларда дөрләп кабына һәм ялкынланып яна. Бу бигрәк тә хакимияткә сайлаулар вакытында шулай.

Мәгълүм булганча, Казакъстанның Россия тарафыннан басып алынуыннан соң, 1868 елда идарә тәртипләренең яңа системасы кертелә. Аның нигезендә моннан ары казакъ тормышы белән абруйлы аксакаллар түгел, бәлки бер территориядә яшәүче йорт хуҗалары тарафыннан сайланып куелган авылнайлар, биләр һәм булыслар идарә итәләр. Ә бу урыннарга сайлауларда хәлиткеч рольне кешенең байлыгы, малы, дәрәҗәсе уйный. Элеккечә кан-ыруглык нигезе җимерелеп, сайлауларның территориаль принципта үткәрелүе төрле катлам-ыруг талашларын китереп чыгара.

Әсәрдә сайлауларга әзерлек вакытында төрле катлам арасында җәелгән кискен көрәш сурәтләнгән. Астыртын рәвештә патша диндарлары кулы уйнаган бу көрәшләрдән бер генә ыруг та читтә кала алмый. Бу талашлар, ызгышлар төрле ыругларның үзара мөнәсәбәтләреннән башлап, ир белән хатын арасындагы гаилә мөнәсәбәтләренә, кыз белән егет мәхәббәтенә кадәр үтеп керәләр һәм аларны үзләренең мәнфәгатьләренә буйсындыралар, еш кына корбан итәләр. Ил агасы Байтүрә хатыны Рөкыя байбичә авызыннан әйтелгән: «Кирәксә — мал бирәбез, кирәксә — кыз бирәбез, кирәксә — җир аударабыз, мәгәр үз теләгебезне кылабыз»,— дигән сүзләр бу көрәшләр вакытындагы хәлне бик төгәл характерлый.

Карлыгач-Сылу мәхәббәте дә әнә шул көрәшләргә корбан ителергә тиеш була. Чөнки аны күрше ыруг егете Калтай белән ярештереп кую Байтүрәләр партиясенә каршы Карлыгач әтисе Сарсымбай партиясенең куәтен арттыру өчен эшләнгән була. Шуңа күрә Карлыгачның сарманнар белән кара-айгырлар арасындагы килешүне аяк астына салып таптап, өченче бер ыруг егетенә китеп баруы нәкъ сайлаулар алдыннан гына озак еллар тупланып килгән көчләр бүленешен бозу куркынычын тудыра.

Кызның булачак кияве Калтай, әле теге вакытта ук, гадәт буенча кыз куенына керергә дип килеп тә, Карлыгач-Сылуның кискен каршылыгына очрагач: «Яхшы атадан туган ул яман сылу белән безнең кара-айгыр йорты ничек исәпләшергә белер!» — дип китеп барган иде. Бу аның турыдан-туры партия талашлары, сайлаулар вакытында үч алу белән янавы иде. Хәзер ул әнә шул ниятен тормышка ашыра: Сарсымбай партиясеннән үч алуның төрле чараларын күрә.

Сарсымбай партиясе белән көрәшүче партия башында Байтүрә тора. Ул — заманда бик күп партия талашларын оештырган кеше, зур тәҗрибә иясе, оста ызгышчы. Бу карт, патша диндарлары белән берлектә, күп еллар казакъ халкын талап, җәберләп килгән.

Ниһаять, казакъ халкының бик күп күз яшьләрен түктергән бу кеше үзе дә үлем түшәгенә ауган. Бу Сарсымбай партиясенең алда торган сайлауларда җиңеп чыгу өметен арттыра. Шуңа күрә алар, Карлыгач-Сылуның сөйгән егете белән качып китүе нәтиҗәсендә, Сарсымбай партиясенең үз эчендә туган каршылыкларны бетерүнең ашыгыч чараларын күрәләр: кара-айгыр ыругының олы кешеләре белән сөйләшү-килешү өчен, Сарсымбай йортыннан бер-бер артлы илчеләр җибәрелә. Мөнәсәбәтләрне җайлаштыру эшенә Биремҗан аксакал үзе керешә. Кыз өчен алынган калым кире кайтарып бирелә. Нәтиҗәдә таркалыш булмый кала.

Казакъ илендәге зур байларның берсе Сарсымбай сайлау алды көрәшләрендә үз кавеменең дә, шулай ук каршы якның да реаль көчләре-мөмкинлекләре хакында аек хисап белән фикер йөртә. Ул сайлаулар вакытында тотачак уй-фигылен алдан ук күзаллап куя: «Бер минутта алдагы көрәшнең бөтен күренешләре күз алдына килде. Бер якта Байтүрә, Якуп, Яңгырбай; аңа каршы Сарсымбай, Арыслан, кияве Калтай ыруы, тагын әллә ничаклы ярдәмчеләр! Дошманда мал күп,

акча күп, түрә дә астыртын аларны яклый; мәгәр сарман ыруы, кирәксә, акча да бераз түгәр, халыкның Байтүрәгә ачуыннан да файдаланыр».

Халык фикеренә килгәндә, аның, билгеле, тегесенә дә, монысына да ачуы бар. Ләкин Сарсымбай биредә, халык дигәннән, казакъның өстен катлавын күздә тота. Ә казакъ байларында Байтүрәләргә, Якупларга, чыннан да, ачу зур. Чөнки алар казакъ җирен талауны патша диндарлары ярдәмендә үз кулларына алганнар, сарманнар белән кара-айгырларга киңәергә ирек бирмиләр. Байтүрә белән Якупларга карата булган нәфрәт аркылы казакъ арасында патша хакимиятенең колониаль сәясәтеннән ризасызлык чагылган.

Бу уңайдан әсәрдә сурәтләнгән Биремҗан образының идея-эстетик йөкләмәсе гаять әһәмиятле. Автор аны аеруча бер җылылык белән иҗат итә.

Биремҗан — Байтүрәләр тарафыннан оештырылган талашлар, һәртөрле ызгышлар корбаны булган ил карты. Ул, башта уртача мөлкәтле кеше булса да, соңыннан бөлгән, бетеренгән. Күрәсең, менә шуңа күрә ул казакъның түбән катлавына әсәрдәге персонажларның һәркайсына караганда да якынрак тора. Аның әйткәннәре казакъ иленең йөрәк тавышы булып яңгырый.

Биремҗан авызыннан ак патшага каршы сөйләнгән сүзләрне еш ишетергә мөмкин. Ул патша яраннарын, казакъ байлары, Байтүрәләр, Якуплар шикелле түрәләр белән берлектә, казакъ җирен талаулары өчен сүгә. Ул патша хакимиятенең колониаль сәясәте бер казакъларга гына түгел, башка халыклар өчен дә зур бәла булып төшкәнлеген йөрәге белән сизеп тора. Аның казакълар арасыннан иң беренчеләрдән булып дала җиренә куып китерелгән украиннар хәлен уртаклашуын, аларга ярдәм кулын сузуын автор юкка гына сурәтләми. Моның белән ул патша хакимиятенең колониаль сәясәтенә каршы төрле милләт халыклары арасында үзара аңлашу һәм теләктәшлек тууына басым ясый.

Әсәрдә моңа кадәр пыскып яткан кавем талашларының ил агасы Байтүрә үлгәч дөрләп кабынуы һәм ялкынланып януы күрсәтелә. Бу көрәш сайлауларда Сарсымбайның җиңүе белән тәмамлана, ләкин мәсьәлә моның белән хәл ителми. Сылу кыз мәхәббәтенең кемнәр мәнфәгатьләренә килеп тоташкан булуы нәкъ әнә шунда күренә дә инде. Карлыгачның элеккеге кияве, теге вакытта Сарсымбай йортына мәгъ-

нәле рәвештә янап киткән Калтай, үзенең үчен ала. Калтай, Якуп һәм Яңгырбайларның, патша әһелләренең уртак тырышлыгы белән сайлау нәтиҗәләре юкка чыгарыла, Сарсымбай казакъ җиренә түрә булып утырам дигәндә, ак патшага каршы кешеләр белән катнашы бар дип, аның өстеннән Калтай һәм башка кешеләр ягыннан жалу (жалоба) бирелеп, илдән сөрелә. Аның белән бергә Карлыгач-Сылуның яраткан ире Арысланбайны да ят илгә алып китәләр.

Горур табигатьле Карлыгач-Сылу белән дала илендә хөкем сөргән тәртипләр арасындагы каршылык әнә шулай хәл ителеп төгәлләнә. Ә моның белән Г. Ибраһимов саф мәхәббәт, хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсенең аерым шәхесләрнең баш күтәрүе белән генә хәл ителә алмаганлыгын, казакъ илендәге колониаль тәртипләрне нигездән үзгәртеп кору юлы белән генә чишеп булачагын раслый. Шулай итеп, ул хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсен социаль һәм милли азатлык мәсьәләсенә китереп бәйли.

Әсәрдә тормышчан каршылыкларның чагылышы

Дала тормышындагы каршылыклар беренче карашка төрле ыруглар арасындагы көрәшләрдән: кабилә, кавем талашларыннан гына гыйбарәт кебек тоелса да, чынлыкта алай түгел. Әсәрнең эченәрәк кереп, анда сурәтләнгән тормыш белән тирәнрәк танышкач, төрле кавем көрәшләренә тартылган, аның иң драматик минутларында бердәм, бербөтен кебек тоелган ыругларның һәрберсендә эчке каршылыклар булуы аңлашыла. Алар социаль каршылыклардан гыйбарәт.

Сарман ыруының «меңләгән җылкылары, яхшы нәсел төпләре, исәпсез куйлары» — һәммәсе дә Карлыгач-Сылуның әтисе Сарсымбай кулында. Бер якта — исәпсез-хисапсыз маллары белән бергә дистәләрчә ялчылары һәм хезмәтчеләре булган Сарсымбай. Икенче якта — авылның ярлылары һәм гидайлары, йортсыз-җирсез, мал-туарсыз кешеләре.

Әсәрнең темасы сыйдырган кысаларда бу ике тормышны бөтен тулылыгы белән сурәтләү мөмкин булмаса да, Сарсымбай җәйләвендәге кычкырып торган социаль тигезсезлекне күрсәтүгә язучы зур игътибар бирә. Аерым алганда, тормышкөн итү күренешләре ул тигезсезлекне гаять калку итеп күз алдына китереп бастыралар. Мисал өчен, автор тарафын-

нан бик оста тасвирланган казакъ йортының кичке аш мәҗлесен алыйк. Әсәрдә Сарсымбай табыны болай сурәтләнә: «Һәркем үзенең дәрәҗәсенә карап, кайсылар ишек төбендә баскан, кайсы чүгәләгән, өлкәннәре киез өстенә урнашканнар.

Иң түрдә, хәтфә палас өстендә, аякларын бөкләп, зур симез гәүдәсе белән Сарсымбай утыра. Аның бер ягында ука бүрекле кунак егет Арысланбай, аннан түбән Җылкычы ата, аның янәшәсендә авылның фәкыйрь карты Иржан баба, байның икенче ягында хуҗаның сәүдә эшләре белән йөри торган Куйбагар атлы егет, аңардан түбәнрәк шул җәйләүдәге ир уртасы фәкыйрьрәк казакълар, тезелеп, бөтен мәҗлесне түгәрәк бер табын ясыйлар. Башкалар бу мәҗлескә кермиләр, читтә көтеп торалар».

Ә көтеп торучылар турында автор болай дип өсти: «Ишек тирәсендәге халык ач күзләрен парланып торган майлы итләргә текәделәр».

Бу күренештән табын артында утыручы һәрбер кешенең үз урынына карап ыруг тормышындагы ролен билгеләү кыен түгел. Ишек төбендә торган, күзләрен майлы иткә текәгән ач халыкның ыруг эшләрен хәл итүдә ни дәрәҗәдә катнашы барлыгы яхшы аңлашылса кирәк.

«Казакъ кызы» романында Сарсымбай, Байтүрә, Якуп кебек байлар һәм түрәләр белән беррәттән, ялчылар һәм хезмәтчеләр, ил гизеп йөрүче гидайлар образларының тулы бер галереясы бирелгән. Аларның бер ишләре, мәсәлән, Җолкынбай, дивана Кимпер үзләренең хәсрәт тавышларын бөтен далага ишеттерергә теләгәндәй аваз салалар, ул тормыштан үзләренең ризасызлыгын белдерәләр, хәрәкәт итәләр. Ә икенчеләре тормышларыннан кычкырып зарланмыйлар, тавышсыз-тынсыз гына эчтән сыза бирәләр. Ә андыйлар казакъ җәйләвендә адым саен. Бу кешеләрне авыр тормыш шулкадәр изгән ки, аларның, үз хокукларын яклап, байга сүз әйтергә батырчылыгы да җитми.

Г. Ибраһимов акчасыз һәм малсыз кеше өчен тормыш бер дала җирендә генә түгел, илнең башка урыннарында да авыр һәм михнәтле булуына ишарә ясый. Әсәрдә сурәтләнгән казакъ егетләренең берсе — Җолкынбай, мәсәлән, казакъ байларының балаларыннан һәм киленнәреннән кыйналудан туеп, унсигез яшьләрендә даланы ташлап китеп караган, чит җирләрдә йөргән. Кайдадыр мал багучы булып торган,

казакъ баенда йорт караучы булып эшләгән, калада заводта йөк ташучы хезмәтен үтәгән. Ләкин кая гына барса да, «кара сакалы артыннан калмаган», ул бер җирдә бәхет тә, тук тормыш та тапмаган. Соңыннан барыбер далага әйләнеп кайткан, Сарсымбайга килеп ялланган. Менә анда инде, өч ел хезмәт итүенә карамастан, бай тиешле эш хакын түләми, вәгъдәсен үтәми. Шуның аркасында яшь егет өч ел буена күзе төшкән тол хатынга өйләнә алмый йөри.

Бу образлар мисалында ачык күренгәнчә, XIX гасыр ахырларында казакъ тормышында социаль каршылыклар шактый нык үскән була. Ә алар бөтен даланы каплап алган кабилә талашлары, кавем көрәшләре белән тагын да тирәнәйтелә һәм катлауландырыла. Чөнки казакъ байлары арасында яхшы җирләр өчен бертуктаусыз дәвам иткән ызгышларның бөтен авырлыгы ахыр чиктә барыбер шул ярлы халык өстенә төшә. Ул ялчы һәм хезмәтчеләр йөрәгенә авыр таш булып ята. Бу көрәшләрдә соңгылары шул ызгышларның, сатып алуларның корбаны ителәләр.

Әнә шундый корбаннарның берсе — Байтүрә йортында ялчы хезмәтен үтәүче Азымбай карт. «Ябык, чандыр гәүдәле, эчке хәйләкәр күзле, җиңел кузгалышлы» бу карт, дала иленең аяклы хәбәрчесе буларак, үз гомерендә кабилә талашлары борылмаларын күп кичергән. Соңыннан ул үзе дә әнә шул борылмаларның берсенә кереп бата. Азымбайны аның байлык сөючән, мал яратучан табигате шулай итә. Байтүрәнең дәрья булып, болыт булып җәйләүләрне баскан исәпсез малы картның күңелен менә ничек кыздыра: «Ай Ходаем, ау, шуның йөздән берсен миңа бирсәң, синең кай җирең җимереләчәк иде?!»

Иш-дәрәҗә өчен талашларда Азымбай кайсы яктан зур сөяк эләксә, шул якка күчеп йөри, «Байтүрәнең сөяген кимереп, илне талыйсың» дип, Якты-Күл җәйләвендә дивана Кимпер тарафыннан тотып кыйналгач, ул күңеле белән сарманнар ягына тартыла. Ә Байтүрә җеназасында мәрхүмнең үзе кигән яхшы туны белән көпесе эләккәч, аның күңелендә яңадан шөбһә туа.

Байның искесенә канәгать булып күңеле хушланган Азымбай, Карлыгач-Сылу Арысланбай белән качып киткәч, Яңгырбай кушуы буенча, каршы як ыругның берлеген таркату өчен тегендә дә, монда да чабып, күп ат тирләтә. Ләкин йөри торгач, ул үзе дә Сарсымбай яклылар тозагына килеп эләгә.

Ә Сарсымбай ялчысы Җолкынбай байлар арасында түрәлек өчен барган талашларга аек карый, чөнки аның күңел күзе байлык, хосусый милек нәфесе белән сукыраймаган. Ул башта, Яңгырбай вәгъдәсенә алданып, сарманнарның серләрен каршы якка хәбәр итәргә дип юлга чыккан булса да, соңыннан, аңына килеп:

«— Боларның Сарсымбае да, Яңгырбае да бары бер эт түгелме? Бу талашларда найманнар җиңсә, ни файда да, сарманнар җиңелсә, ни зарар?.. Ни дип мин Кызыл-Ком серләрен Якты-Күлгә ташып йөрим?!» — дип кире борылып кайта.

Бу сүзләрдә халыкның байлар арасындагы талашларга мөнәсәбәте ачык чагылган. Җолкынбайлар һәм Күчәрбайлар өчен бу талашларда Якуплар-Яңгырбайлар җиңәме яки Сарсымбай өстен чыгамы — барыбер. Чөнки түрә булып утыручы байның исеме алмашынудан гына үзләренең тормыш хәле үзгәрмәячәген алар яхшы аңлыйлар.

Ләкин партия көрәшләренең тимер мантыйгы аларның мондый битарафлыклары белән хисаплашып тормый, астыртын ызгышлар ятьмәсенә барыбер үзләрен тартып ала. Мондый вакытларда байлар ялчылары һәм хезмәтчеләре белән дә, хәтта кешелек намусы белән дә хисаплашып тормыйлар. Г. Ибраһимов шул ук Җолкынбайдан үч алу күренешен түбәндәгечә тасвирлый: «Кулларын артка каерып бәйләгәннәр, нечкә иске бишмәте телгәләнгән, якалары суелып төшкән, кан катыш балчыкка пычранган коточкыч йөзе һәм зур гәүдәсе белән Җолкынбай ята. Чәчле егет һаман кыйный, ялчы кулын чишәргә, газаплы тәнен яшерергә маташа, ләкин булдыра алмый, һаман акыра».

Талаш-ызгышлар ялкыны Сарсымбай канын шулкадәр кыздырган ки, ул ялчы өстенә ташланган гаепнең расмы, түгелме икәнен дә тикшереп тормый, Якуплар-Яңгырбайларга булган бөтен ачуын бергә туплап, аның өстенә ябырыла. Ә соңыннан, Җолкынбайның нахакка кыйналганлыгы беленгәч, бай үзенең хатасы өчен, имеш, җавап бирә: аңа өч ел эшләгән хезмәт хакын түләргә риза була.

Менә нинди тәртипләр хөкем сөрә дала җирендә.

Мондый кыргый тәртипләрне, тормышның ачы җимешен ярлы халык бик яшьтән татый. Бай кызы Карлыгач-Сылу белән бай малае Арысланбайлар далада ат өстендә уйнап, күңел ачып, кәеф-сафа кылып йөрсәләр, ярлы Кәрим малае,

байның төпчек кызының чытлыклануы аркасында, байбичә камчысын ашый. Хәтта үз балаларын мал, алтын бәрабәренә яшьтән үк сатып куйган Сарсымбай һәм байбичә Алтынчәчләр өчен башка кешеләрнең балалары, бигрәк тә ялчы һәм хезмәтче малайлары, кәҗә бәтиенә дә тормый.

Далада, бер яктан, меңнәрчә җылкылары, яхшы нәселле төяләре, исәпсез куйлары булган Сарсымбайларның, Якуп-Яңгырбайларның кәеф-сафа корган тавышлары яңгыраса, икенче яктан, Җолкынбайларның, социаль тигезсезлекнең аяклы кыңгыравы булган дивана Кимперләр һәм ач-ялангач балаларның әрнүле йөрәк сыкравы ишетелеп тора. Карлыгач-Сылуның мәхәббәте әнә шундый каршылыклы фонда яфрак яра. Авторның моны шулай эшләве очраклы түгел. Моның белән Г. Ибраһимов хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсенең әнә шул социал изелүдән коткарган вакытта гына хәл ителә алачагын раслый.

«Казакъ кызы» — татар прозасының гүзәл үрнәкләреннән берсе. Ул — шулай ук егерменче елларда төрки әдәбиятлары үсешенә татар язучысы керткән җитди өлеш тә. Бу романда Г. Ибраһимов иҗтимагый теманы көнкүреш мәсьәләләре белән тыгыз сурәтләү остасы булып күз алдына килеп баса. Аның югары романтик рух белән сугарылган реализмы казакъ тормышының эчке, яшерен тенденцияләрен сурәтләүдә, дала халкының үсеп барган иҗтимагый аңын күрсәтүдә чагылды. Рәссамның үткен каләме халык тормышының эченә үтеп керә, аның тирән катламнарын күтәрә, җәмгыятьнең социаль яраларын ачып бирә алды. Г. Ибраһимов, төрки язучылардан беренче буларак, гаиләдәге һәм иҗтимагый изүгә каршы күтәрелгән казакъ кызының гүзәл образын бирде. Моның белән ул хатын-кыз азатлыгы темасын эшкәртүгә бик зур өлеш кертте.

Г. Ибраһимовның иҗат тәҗрибәсеннән М. Ауэзов, С. Муканов, А. Кадыйри, А. Токомбаев кебек зур язучылар файдаландылар. Күренекле төрекмән язучысы Бирде Кербабаев болай дип язды:

«Минем беренче әсәрләрем төрекмән хатын-кызларының азатлыгы темасына багышландылар. Икърар итә алам һәм моны шатланып әшлим: минем әсәрләрем Галимҗанның зур йогынтысы белән иҗат ителде. Ул, совет язучыларының беренчесе булып, гаилә һәм җәмәгать изүенә каршы баш күтәргән мөселман хатын-кызы образын иҗат итте.

...Мин аның «Казакъ кызы» романын сокланып укыдым һәм Казакъстанның сарык һәм ат көтүләре таралган киң далаларын күз алдыма китерә алдым. Мин кабиләләр арасындагы ызгышларны, хакимлек өчен көрәшне күрдем. Болар барысы революциягә кадәрге Төрекмәнстандагы чынбарлык белән җанлы образлар аркылы якыннан бәйләнгән иде».

Бу әсәрдә Ибраһимовның әдәби осталыгы һәрьяктан: сюжет һәм композиция төзүдә, геройларның эчке дөньясын тирән ачып бирүдә, көнкүреш сурәтләренең мул һәм төгәл булуында, пейзаж күренешләренең зәвыклыгында да, теленең матурлыгында, көчле һәм колоритлы булуында да күренде. Романны иҗат иткәндә, автор үзенең шәхси иҗат тәҗрибәсен генә түгел, дөнья әдәбиятының казанышларын да, шулай ук казакъ фольклорын да киң файдалана.

Г. Ибраһимовның Совет чоры әдәби иҗатына кыскача күзәтүне аның тагын ике зур әсәрен искә алу белән тәмамлыйк. Аларның берсе — 1928 елда басылып чыккан «Тирән тамырлар» романы. Ул 1917 ел инкыйлабыннан соң авылдагы социаль үзгәрешләрне сурәтли. Әсәр башыннан ахырына кадәр сыйнфый көрәш рухы белән сугарылган. Ул Совет чорында язучы иҗатының, партия таләпләре кысаларында, нинди юнәлештә дәвам итүен күрсәтүе ягыннан аеруча характерлы.

Икенчесе — «Татар хатыны ниләр күрми» повестеның яңа редакциясе. Бу әсәрдә татар хатынының язмышы инкыйлабка кадәрге чордагы татар авылы тормышы, татар халкының гореф-гадәтләре, традицияләре, гаилә мөнәсәбәтләре, крестьян хезмәте, авылның бай табигате панорамасында сурәтләнә. Бу әсәр бер татар әдәбиятына гына түгел, гомумән, төрки халыкларының әдәбиятларына уңай йогынты ясады.

* * *

Галимҗан Ибраһимов үткән юл — татар халкының XX гасыр башларыннан алып утызынчы елларга кадәр булган катлаулы һәм каршылыклы үсеш юлы ул. Әдипнең тормышы һәм иҗаты халыкның социаль һәм милли азатлык көрәше тарихы, яңа тормыш төзүгә омтылышы белән тыгыз бәйләнгән.

Г. Ибраһимов зур талант иясе иде. Ул бездә яңа милли әдәбият нигезләрен салучыларның берсе булды һәм татар

сүз сәнгатенә зур сыйфат үзгәрешләре алып килде. Милли прозаның идея тематикасын, социаль колачын киңәйтте, аңа киң сулыш бирде, лиризм, музыкальлек һәм романтик рух белән сугарды, реалистик сурәтләү чаралары белән баетты.

Г. Ибраһимов — киң колачлы язучы. Аның бу сыйфаты әдәби-гыйльми иҗатында һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлегендә бик ачык күренә. Г. Ибраһимов иҗаты бер Татарстанда гына түгел, башка халыклар арасында да мәхәббәт казанды. Аның әсәрләре рус, украин, азәрбайҗан, башкорт, казах, кыргыз, таҗик, төрекмән, үзбәк, чуваш һ. б. телләргә тәрҗемә ителделәр. Аларны бик күп милләт кешеләре укыйлар, яраталар.

Г. Ибраһимов таланты, иҗаты киң җәмәгатьчелек, күренекле язучылар, сәнгать әһелләре тарафыннан югары бәя алды. Күренекле француз язучысы Луи Арагон татар әдәбиятында роман жанрының үсүен аның исеме белән бәйләп карады.

Г. Ибраһимов иҗаты төрки әдәбиятлары үсешенә көчле йогынты ясады. Башкорт халык шагыйре С. Кудаш, мәсәлән, аны үзенең остазы дип атады. Башкорт әдәбиятының өлкән буын вәкилләренең күбесе әдәбиятка турыдан-туры Ибраһимовтан сабак укып яки аның әсәрләреннән өйрәнеп килгәнлекләрен әйтте.

«Галимҗан Ибраһимовны казахлар үз язучылары итеп исәплиләр,— диде язучы-академик С. Муканов.— Безнең халык тормышын шулай яратып язган өчен, казахлар Г. Ибраһимовка һәрвакыт хөрмәт белән карарлар».

«Зур татар прозаигы, романчы Г. Ибраһимовның әсәрләре республикабыздагы киң катлау укучылар арасында зур уңыш казанды. Күпләр хәтта аны азәрбайҗан язучысы итеп саныйлар иде»,— дип язды атаклы азәрбайҗан әдибе Мәһди Хөсәен.

Бөтенроссия Сәнгать фәннәре академиясе президенты профессор П. С. Коган Г. Ибраһимов үзе исән чакта ук: «Ул — әһәмияте үз иле чикләреннән еракларга китә торган рәссамнарның берсе. Ул кешелек дөньясының иң яхшы шагыйрьләре рәтенә горур атлап керә ала»,— дигән иде.

Бу сүзләрне тарих раслады. Ул, чыннан да, үз чорының олы шагыйрьләре сафына басты һәм үзенең исемен мәңгеләштерде.

Сораулар һәм биремнәр

1. Г. Ибраһимов эшчәнлегенең төп тармакларын санап чыгыгыз.

2. Г. Ибраһимовның эстетик карашлары һәм әдәби иҗаты формалашуга дөнья әдәбиятының йогынтысы нидән гыйбарәт?

3. Язучының Совет чоры иҗатына кыскача күзәтү ясагыз.

4. Г. Ибраһимовның тормышы һәм иҗат юлы турында сөйләгез.

5. Г. Ибраһимов әсәрләре буенча эшләнгән нинди сәхнә әсәрләрен беләсез? Аларның режиссёры, төп рольләрне башкаручы актёрлары кемнәр?

6. Г. Ибраһимов образын гәүдәләндергән әдәби әсәрләр һәм сәнгать әсәрләре белән танышып, үзара фикер алышыгыз.

7. Түбәндәге темаларга докладлар, рефератлар әзерләгез:

а) Г. Ибраһимовны зур тормышка әзерләгән социаль шартлар.

ә) Г. Ибраһимовның иҗтимагый эшчәнлеге.

б) Язучы иҗатында табигать («Яз башы», «Алмачуар», «Кызыл чәчәкләр» әсәрләре мисалында).

8. Миниатюр иншалар языгыз:

а) Г. Ибраһимов — журналист.

ә) Язучы үткән юл.

б) Г. Ибраһимов иҗатында пейзаж.

Һади Такташ
(1901—1931)

Шундый шәхесләр була: аларга язмыш үзләре хезмәт иткән өлкәдә беренче булу вазифасын йөкли. Икенче төрле әйткәндә, әйдәп баручы була. Шуңа күрә андыйлар бик тиз вакыт эчендә баш әйләндергеч биеклекләргә ирешәләр, үз-үзләрен аямыйча янып эшлиләр, иҗат итәләр, җәмгыятьтә олы абруй казаналар. Һ. Такташ кыска гына гомерендә бай рухи мирас калдырган шундый шәхесләрнең күренеклесе иде.

Җирдә нибары утыз ел яшәп, үз артыннан кешеләргә галәмәт бай мирас калдыру өчен (күләм белән генә түгел, бәлки, сәнгатьлелекнең югары дәрәҗәсе белән), чыннан да, гадәти генә кеше булу җитми торгандыр. Халкыбызның күренекле шагыйре булачак әлеге малай гап-гади генә гаиләдә туа. Тамбов губернасының Спас өязендәге (хәзерге Мордва Республикасының Торбеево районы) Сыркыды авылында XX гасырның беренче көнендә туган бу малайга Мөхәммәтҗан дип исем кушалар. Әмма тора торгач, әлеге исемне ошатып бетермичә, мулла чакырып, аны Мөхәммәтһадига алыштыралар. Хәйрулла абый белән Шәмсениса апаның өченче баласы була ул. Авыл кешеләре исемне кыскартып әйтүгә һәвәс була бит, малайны, «Мөхәммәт»ен онытып, «Һади» дип кенә йөртә башлыйлар.

Әнисе болай сөйли: «Һади тугыз айда тәпи йөрде, ике-ике яшь ярымнарда чиста итеп сөйли белә башлады. Басынкы, еламый, кайда ятса — шунда йоклый... Бала вакытында яраткан эшләреннән берсе каз бәбкәләрен карау иде». Ул бик шаян малай була. Күршеләрендәге Мөхәммәтҗан (Мокамай)

белән һәрвакыт бергә уйныйлар. Мокамай эшкә, Һади телгә оста иде, дип сөйлиләр авылдашлары. (Соңыннан, дустына багышлап, шагыйрь «Мокамай» әсәрен яза.) Һадиларның өйләре янында бер күл бар. Аны Сәпүш күле дип атаганнар. Такташның бабасы Сәйфетдин исеменнән шундый атама ясаганнар. Һади шул күлдән чуртан тотарга ярата. Парча инешендә су коена, Лангыш урманында җиләк-җимешләр җыя. Һәр авыл малае кебек үк, ул да ат ярата. Кара байталларның сыртына баса да бар көченә юырттыра. Дусларының истәлегенә караганда, әкият сөйләргә, җырга барысыннан да оста була.Кызганыч, хәзерге вакытта шагыйрь туып үскән йорт юкка чыккан.

Һадиның әти-әнисе икесе дә укый-яза белгән. Шуңа күрә ул бик тиз хәреф танырга өйрәнә. Берничә ел авыл мәктәбендә укый. Ата-ана бу сәләтле малайның төплерәк белем алуын тели. Аны Сыркыдыдан утыз чакрым ераклыктагы Пешлә мәдрәсәсенә бирәләр. Хәйрулла агайның улына Пешлә мәдрәсәсен сайлавы да очраклы түгел. Аның мөдәррисе Сабир мулла фән-белемгә, яңалыкка омтылучан кеше була, шуңа күрә укытучылыкка белемле мөгаллимнәрне генә ала. Дин сабагы укыту белән бергә, балаларга дөньяви гыйлемнәр дә укытыла.

Һади 1913 елда шушында беренче тапкыр Г. Тукай шигырьләрен тыңлый. Бу — шигъри даһиебызның вафат булган елы. Әйтерсең лә Һади бөек шагыйрьдән иҗат юлына кереп китү өчен фатиха ала. Шунда ук Сәгыйть Рәмиев шигырьләре белән дә таныша, аның «Таң вакыты» әсәрен бик яратып яттан сөйли. «Сәгыйтьнең шигырьләре,— ди Һади,— сөйләр өчен яхшы, җиңел, уңайлы. Шуңа күрәдерме, мәктәптә вакытта «Таң вакыты» кебек әйберләрне яратып сөйли идем». Бу турыда язучы Кәрим Әмири дә искә ала: «Унике-унөч яшьлек кечкенә Адюк (Һади.— *Ф. Г.*) мәктәптә чакта шигырь сөйләргә яратса, зурайгач та шулай булды. Такташ булгач та бик күпләрне үзенә каратты».

Шигырьгә булган мәхәббәт инде аңарда бервакытта да сүнми. Бохарада ерак туганнарында ялланып эшләгәндә дә ул һаман зыялыларга тартыла, сәүдә эшенә күңеле ятмый. Туган якларына кайтып, Спаста (соңрак Беднодемьяновск) кыска вакытлы укытучылар хәзерләү курсын үтеп, Сыркыды мәктәбендә укытканда да балаларда шигырь һәм җырга мәхәббәт уятырга омтыла. Беренче сыйныф балаларына «И туган тел, и матур тел» дигән шигырьне матур итеп сөй-

ләргә өйрәтүен, «Галиябану» көен җырлап күрсәтүен өлкәнрәк кешеләр авылда искә алып сөйлиләр.

1919 елда әле генә искә алынган укытучылар хәзерләү курсында аны Вольнадан (Вильнюс) бу якларга күчеп килергә мәҗбүр булган бик укымышлы белгечләр укыта. Бигрәк тә рус теле һәм әдәбияты буенча төпле белем алу мөмкинлеге була. Һ. Такташ әдәбиятның, әсәрләр иҗат итүнең гаять катлаулы, шул ук вакытта мәртәбәле эш икәнен җитди рәвештә шунда төшенә. Авыл шартларында ул үзенә чын-чынлап әдәбият белән шөгыльләнү өчен колач җитмәячәген яхшы аңлый һәм 1919 елның көзендә Оренбургка китә. Биредә «Юксыллар сүзе» газетасында җаваплы сәркатип булып эшли башлый. Татар-башкорт язучысы Афзал Таһиров җитәкчелегендәге бу газетада Һади журналистлык мәктәбе үтә. Оренбургта да курсларда укый, даими рәвештә белемен күтәрү өстендә эшли, татар һәм рус әдәбиятларын өйрәнә. Укучы яшьләр белән А. Таһировның «Эшчеләр» пьесасын сәхнәгә куюны оештыра, үзе дә роль башкара.

Ләкин 1921 елгы ачлык вакытында үзеңне саклап калу мәсьәләсе алга килеп баса. Такташ та җылырак һәм ризыклырак якка — Ташкентка китә. Монда «Белем йорты» дигән журналда җаваплы сәркатиплек хезмәтенә керешә. Эшче-дехканнар өчен ачылган уку йортында татар теле һәм әдәбияты укыта. Берара хәрби мәктәптә төрки халыклар яшьләрен язу танырга да өйрәтә. Ләкин аның үзенең ныклап белем аласы килә. Шул ният белән 1922 елның җәендә ул Мәскәүгә чыгып китә. Өч айдан артык шунда яши, төрле әдәби кичәләргә йөри, рус шагыйрьләре белән кызыксына. Әмма күңелен татар халкының мәркәзе Казан тарта. Ноябрь аенда ул Казан җиренә аяк баса һәм гомеренең соңгы көненә кадәр аннан аерыла алмый. Казан — аның тормышында аеруча әһәмиятле урын биләгән шәһәр. Ул биредә зур шагыйрь булып танылa, журналистлык эшен киң җәелдерә, гаиләле була, балалар үстерә һәм шунда вафат була.

Элек Казанда Һадиның танышлары булмый диярлек. Оренбург, Ташкент шәһәрләрендә чагында Таҗи Гыйззәт, Әсгать Мәҗит кебек артистлар белән якыннан аралашкан Һади, аларның хәзер Казанда икәнен белеп, татар театрына килә, һәм дуслар шатланып очрашалар. Әлеге иптәшләре аңа театрга суфлёр булып урнашырга һәм кунакханәдән урын алырга ярдәм итәләр. Бераздан ул «Безнең байрак» газетасына

сәркатиплек эшенә чакырыла. Аннан соң «Татарстан» газетасында әдәби хезмәткәр, «Чаян», «Азат хатын» журналларында җаваплы сәркатип булып эшли. Шулай итеп, иҗатын гомере буе газета-журналларда эшләү белән бергә үреп алып бара.

Замандашларының искә төшерүе буенча, Һ. Такташ ниндирәк кеше булып күз алдына килә соң? Малай вакытыннан ук шаян-шук, сүзгә җор, кешеләр белән аралашканда каушап калмый торган, шул ук вакытта уйчан, моңлы булганлыгын әйтәләр. Сары чәчле, зәңгәр күзле Такташның сөйкемле кыяфәте күпләрнең игътибарын җәлеп итә. Һади үзенең туганнарын, эти-әнисен бик ярата. Әнисе байтак еллар аяктан калып авырый, шул вакытта Һади аны Казанда табибларга йөртә, күтәреп, бакчага чыгарып утырта, аның белән озаклап сөйләшеп утырудан тәм таба. Әнисе дә аны ихлас якын итә. Һадие үлгәч, ана үзенең хәсрәтен менә ничек белдерә:

Син утырткан ятим каеннарга
Күз яшьләрдән сулар сибәмен.
Таң алдыннан каен яфракларын
Җылы йөзең итеп үбәмен.

Каеннарга сөйлим моңнарымны,
Аңлаган күк тып-тын торалар.
Синең кулың итеп ботакларын
Гүя миңа сузган булалар.

Һади Такташ чын мәгънәсендә югары дәрәҗәдәге әхлаклылыкны үзе өчен кагыйдә итеп ала. Хәмер эчү, тәмәке тарту кебек нәрсәләрне өнәми. Ата-анасы, туганнары турында кайгырту, балаларын өзелеп ярату — аның аерылмас сыйфатлары.

Тормыш иткәндә, кеше бик катлаулы хәлләрдә калырга мөмкин. Һ. Такташка да еш кына шундый четерекле мәсьәләләрне хәл итәргә туры килә. Менә шуларның берсе генә.

Һадиның әтисе Хәйрулла агай (1868—1943) ярлы гаиләдә туа. Патша хакимияте вакытында крестьяннарга җирне ир затыннан булганнарга гына биргәннәр. Күп балалы Хәйрулла агайга байтак җир тигән, ул хәтта урта хәллеләр исәбенә кергән. Ләкин хатыны авырып китү, балаларының читкә таралуы сәбәпле, көзге кыр эшләрен кеше яллап башкарып чыгарга да туры килгәләгән. Моны күреп, Хәйрулла агайны кеше хезмәтеннән файдалана дип гаеплиләр һәм гражданлык хокукларыннан мәхрүм итәләр. Кызы Хәнифәне шуның өчен

Казанда техникумдагы укуыннан чыгаралар. Һ. Такташ моңа бик борчыла һәм, документлар әзерләп, тиешле урыннарга, бу хатаны төзәтүләрен үтенеп, хатлар җибәрә. 1929 елда әти-әнисенә дә, кайгыртып, хат яза. «Минем язуны Советка бирдегезме? Менә шул хакта да язмадыгыз. Бит тавышсыз тору сезнең үзегез өчен дә бик яхшы түгел. Хәнифәләр, Габидуллалар өчен дә (Һ. Такташның туганнары.— *Ф. Г.*). Хәзер аны бик сизмәсәгез дә, аның начарлыгын соңга таба күрерсез... Бу мәсьәләгә җиңел карарга ярамый»,— дип яза ул. Һ. Такташның кайгыртуы бушка китми, әти-әнисенең тавыш хокуклары 1929 елның 12 ноябрендә кире кайтарыла.

Һ. Такташның әсәрләре генә түгел, хатлары, язмалары, көндәлекләре дә аның үзен һәм ул яшәгән заманны төрле яклап аңларга ярдәм итәләр.

Һ. Такташ, бик кыска вакыт эчендә авырып, 1931 елның 8 декабрендә вафат була.

Ул Казанның М. Горький исемендәге Үзәк культура паркы территориясенә урнашкан туганнар каберлегенә җирләнә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шагыйрьнең балачагын тасвирлап бирегез.

2. Ничек уйлыйсыз: Һадиның шагыйрь булып әверелүе очраклылыкмы, әллә тумыштан бирелгән сәләтме?

3. Такташның күпьяклы сәләтләргә ия булуы нәрсәләрдә күренә?

4. Егерменче еллар татар вакытлы матбугатын аякка бастыруда Һ. Такташ керткән өлеш турында сөйләгез.

5. Ата-анага, туганнарга җылы мөнәсәбәт күрсәтү — кешене матурлый торган сыйфат. Һ. Такташта без боларны нәрсәләрдә күрәбез?

6. «Такташ — яңадан-яңа буын кешеләренең күңелендә шагыйрь булып яши» дигән фикерне киңәйтеп сөйләгез.

Шагыйрь иҗатының бөтенлеге

Һади Такташның иҗатын ике чорга бүлеп карау гадәткә кергән. Вакыт ягыннан аларны 1916—1922 һәм 1922—1931 еллар дип алырга мөмкин булыр иде. Бу ике чорны әдипнең торган-яшәгән һәм иҗат иткән урыннары буенча да аерырга мөмкин. Беренче чор — Сыркыды — Оренбург — Ташкент; икенчесе — Казан, ягъни Татарстан белән бәйле.

Ләкин мондый бүленеш шартлы. Ни генә булмасын, Һ. Такташ иҗатын бербөтен итеп, әмма гел хәрәкәттә карарга кирәк. Бары шул вакытта гына гасырыбызның олы шагыйрьләреннән булган Һ. Такташ иҗаты турында бөтенлекле караш булдыра алырбыз.

Һ. Такташ әдәбиятка романтик шагыйрь буларак килде. Ул иҗатын бик иртә башлый. Матбугатта чыккан беренче шигырьләре 1916 елда басылсалар да, яшь шагыйрь аларга кадәр дә язган, әлбәттә. Чөнки бу шигырьләрдә инде аның каләменең шактый җитлеккәнлеге күренә. Билгеле булганча, язмыйча, каләм чарламыйча гына шагыйрь булып өлгереп булмый. Яшүсмернең дөньяны хыялындагыча күрүе, романтикларча кабул итүе табигый. Яшь Такташ иҗатының романтизм белән өртелүенең тагын бер сәбәбе бар. Ул С. Рәмиев шигырьләре белән мавыга, аларны яттан укый. Бу шагыйрьне үзенә өлге итеп ала. Сезгә инде мәгълүм булганча, С. Рәмиев иҗаты романтизм белән сугарылган.

Иҗатындагы романтиклык Һ. Такташның үз шәхесенә карата әйтелгән аерым фикерләрендә дә сизелә. Мәсәлән, «Син дә үл инде» шигырендә (1925) ул үзенә карата «шашкан уйлар, тилергән хисләрнең даһие» дип әйтә. Шунысын аңларга кирәк: бу — аның отышлы кулланган шаяру алымнарыннан берсе. Болай дию шагыйрь холкында һәм күңелендәге яшьләргә хас сыйфатларны җанлы итеп күз алдына бастырырга, аны шәхес буларак күзалларга мөмкинлек бирә. «Шашкан уйлар, тилергән хисләр» аңа, яшәешне җир белән чикләмичә, галәм киңлегенә чыгарга, бишегебез булган җирне иксез-чиксезлектәге бер җисем итеп карарга, кешеләр язмышының фаҗигале якларын гадәти булмаган чаралар ярдәмендә ачарга ярдәм итә.

Беренче әсәрләреннән булган «Газраилләр» (1916), «Күктән сөрелгәннәр» (1918) шигырьләренең икесендә дә галәмҗир мохитендәге фәрештә образын күрәбез. Шуңа карамастан шагыйрь җир кешеләре турында кайгырта, укучыны гади бәндәләрнең язмышы хакында уйлануга этәрә. Фәрештәләрнең һәр икесен дә кешеләр турында кайгыртучы итеп сурәтләү беренче карашка акылга сыешып бетми кебек.

Дини өйрәтүләр буенча, фәрештә — кешеләргә яхшылык, изгелек кылучы, Газраил исә — җан алучы фәрештә. Фәрештәнең изге күңелле булуы — табигый нәрсә, ә инде Газраилнең кемгәдер шәфкатьлелек итү бәрабәренә күк кануннарына

каршы чыгуы — көтелмәгән хәл. Ләкин романтик шагыйрь үзен ниндидер кагыйдәләр белән чикләми, нәкъ менә гади акыл белән уйлаганда мөмкин булмастай хәл-әхвәлләрне сурәтләргә җөрьәт итү аның өчен берни дә тормый. Җирдәге тормышны үзенчә күргән, бәяләгән романтик шагыйрь өчен күк тәртипләре дә үзгәрми торган нәрсә була алмый. Ул аларны үз карашларына, максатларына, кешеләргә ни әйтергә теләвенә карап үзгәртә, яңабаштан кора.

«Газраилләр» әсәрендә фәрештә һәм Газраил образлары дини тәгълиматта әйтелгәннәргә каршы килми, аларның берсе — игелеклелек, икенчесе явызлык билгесе (символы) итеп сурәтләнгән, ягъни әсәрне укып, кешедә әлеге мифик образларга карата караш үзгәрми, алар антиподлар, ягъни бер-берсенең капма-каршысы булып кала бирәләр.

Фәрештә моннан бик күп еллар элек күкнең (галәмнең) ерак бер түреннән бу йолдызга (җиргә дип аңларга кирәк) очып килгән. Теләге — бәхет бакчасы үстерү, рәхәтлек тәэмин итү. Ул үз алдына куйган максатына шактый якынлаша. Җир йолдызында җәннәт ясый. Ләкин яхшылыкның чиге юк, ул биредәге хәлне тагын да матуррак итеп күрергә тели. Яңадан-яңа гөлләр алып кайту өчен, галәм түренә кире очып китә. Бер чәчәктән икенчесенә кунып, ширбәт җыеп йөргән бал корты кебек, ул, йолдызлардан йолдызларга күчә-күчә, матур гөлләр туплап йөри...

Шушы игелекле сәяхәттән җиргә әйләнеп кайтса, өнсез кала... Чөнки ул калдырып киткән гөлбакчалар урынында сөякләрдән — таулар, каннардан күлләр барлыкка килгән. Кешеләр кулларына сөңгеләр тотып йөриләр, ирләр өем-өем булып үлеп яталар, тирә-як җәһәннәмдәгедәй ут белән тулган. Кыскасы, тормыш гөрләп чәчәк аткан ил — матур йолдыз «янып сүнгән», «гакылсызлар йорты булып әверелгән». Фәрештәнең баш өстеннән туплар оча. Бу афәт каян килгән, җәннәт кебек җирне кем җимергән? Фәрештә, үзен тетрәткән бу сорауга җавап таба алмыйча, тирән уйга батып, тау өстендә утыра. Талган. Канатлары җирдә ята. Әмма өмет уты сүнмәгән, маңгаенда нурлы йолдыз яна. Күзләрендәге нурланыш офыкны яктырткан, таң аттырган. Димәк, әле барысы да бетмәгән, алга таба яктылык, акыл җиңәр дигән ышаныч бар. Җилләр фәрештәгә яшертен генә (явыз көчләрнең ишетеп калуы бар!) бу илдән китәргә киңәш итәләр, чөнки монда вәхшәт, монда үлем! Монда газраилләр хакимлек итә,

димәк, яхшылык көтү мөмкин түгел. Ләкин фәрештә алга таба нишләр, мәгълүм түгел, ул уйга чумган.

Уналты яшәр егетнең шушындый шигырь яза алуына таң каласың. Ул дөнья-галәмнәр күләмендә фикер йөртә, аны кешелек язмышы гаме борчый. Бүгенгесен тарих яссылыгына куеп карый. Чын бәхетле тормыш үткәндә булган кебек тоела. Бүген, империалистик сугыш афәтләре кешеләргә газаплар алып килгән бу дәвердә, бары тик үтерү, җимерү генә бар. Бу исә — гайре табигый хәл. Чөнки җирдә газраилләр түгел, бәлки кешене сөюче, аңа игелекле булган фәрештәләр хакимлек итәргә тиеш, ди ул. Газраилләр патшалык иткән җирдә (кешеләргә бары тик үлем генә теләүче хакимият өстенлек иткәндә) иман, шәфкатьлелек, рәхимлелекнең булуы мөмкин түгел. Яшь шагыйрь, шул рәвешле, 1914 елда башланган сугышның кешелексез хакимиятләр тарафыннан оештырылуын, аның халыкка никадәр җәфалар китерүен гомумиләштереп, бик тасвирлы итеп әйткән һәм гаять оста күрсәтеп бирә алган. Шигъриятьнең бурычы төгәл вакыйгалар, шәхесләр белән эш итү булмаска да мөмкин. Сәнгатьчә чаралар ярдәмендә укучыларда теге яки бу хәл-әхвәлләргә карата билгеле бер хис-тойгылар уята ала икән, ул — үзенең вазифасын үтәгән дигән сүз. Яшь Һ. Такташ моңа ирешә алган. Әлеге шигырь сугышның вәхшәтен, караңгы якларын укучының йөрәгенә үткәзеп күрсәтеп бирә алган. Аның фәрештәсе гуманизм белән сугарылган образ булып кабул ителә.

«Күктән сөрелгәннәр» шигыре исә «Газраилләр» әсәренең дәвамы булып тоела. Укучы хәтерлидер: «Газраилләр»дәге фәрештә бездән тау өстендә уйга батып утырган хәлдә калган иде. «Күктән сөрелгәннәр»дә исә ул, бер карарга килеп, күк патшасына бара һәм аңардан җирдәге коллыкны, күз яше һәм кан түгелүен туктатуын үтенә. Менә шуның өчен күк патшасы аны «хаинә» дип атый, җиргә сөрә, салкын зинданга яба. Бөтен галәмне иңләп йөргән фәрештә өчен җир тар зиндан булып кала. Аның урыны дүрт дивар арасында, җан өшеткеч салкын. Аны тәмам онытканнар, үләр вакыты якынайган. Газраил аның да җанын алырга килгән. Фәрештә үлсә, гомумән, җирдә гаделлек турында уйлаучы, бәхет турында кайгыртучы булмаячак. Бары тик миһербансыз күк патшасы һәм аның фәрманы буенча тереклекнең җанын алып йөрүче Газраил генә калачак. Моннан да коточкыч хәлнең булуы мөмкинме?!

Менә шушы урында романтик Һ. Такташ каләме могҗиза тудыра. Канатының очларыннан кан тамып торучы, канга баткан зур күзләре уттай янган Газраил, фәрештәне — күк кызын — күреп, бермәлгә үзенең ни өчен килгәнлеген хәтереннән чыгара, «Тәңре хөкемен» онытып, корбанының аягына ташлана. Бу матурлык, сафлык, гөнаһсызлык алдында үлем фәрештәсе Газраилнең күңелендә җылылык барлыкка килә, сөю хисе уяна. Матурлык, мәхәббәт яшәүне саклап кала дигән караш бу очракта үзенең дөреслеген раслый. Ләкин соң инде, фәрештәгә ярдәм итү мөмкин түгел. Ул Газраилнең ярдәмен кабул итә алмый. Газраилнең каты тимер кулларында аның ак тәне кара ташка әверелә.

Һ. Такташ, шул рәвешле, һәрбер сүзен, аның нинди фикер һәм хисси мәгънә алып килүен тирән уйлап яза. Сылу кызның ак тәне кара ташка әверелүе табигый кабул ителә. Башкача була да алмый. Газраил килеп орынгач, тере тән җансыз калган кебек, аның кинәт кенә сыйфат үзгәреше кичерүе дә гаҗәп тоелмый.

Ләкин табигатенә хас булмаган кызгану хисенә бирелгәч, Газраил дә күк патшасы каһәренә дучар ителә, ул җиргә сөрелә. Бу урында үзеннән салкынлык бәреп торучы Газраил образына карата укучы күңелендә уңай хисләр уяна.

Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: фәрештә үзен җәберләүче көчләргә каршы чыга алмый, язмышына сүзсез генә буйсына. Газраил исә күк патшасына нәгъррә[1] ора, үзенең нәфрәтен белдерә:

Бер минутлык шәфкатемә түзалмадың;
Бар биргәнең тартып алдың да кимсеттең.
Китәм хәзер канлы үлем кырларына!
Сөйлим хаклык мәзлум[2] адәм улларына!

Күренекле язучы Мирсәй Әмир болай дигән иде: «Тәнкыйть Такташ иҗатының беренче чорын символизм рухында язылган дип, реализмнан ерак дип, шагыйрьнең кимчелекле әсәрләре итеп бәяләп килде... Киресенчә, аларда азатлыкка омтылу пафосы бөркелеп тора, алар дөньяның каршылыклары турында уйландыралар». Өлкән әдип хаклы: моның шулай икәнлеген «Газраилләр», «Күктән сөрелгәннәр» әсәрләре турында сүз барганда ачык күрдек.

---

[1] *Нәгъррә* — каты тавыш, ачы тавыш; акыру-бакыру.
[2] *Мәзлум* — рәнҗетелгән, кыерсытылган.

Фәрештә һәм Газраил кебек символик образлар белән эш итү Һ. Такташның иҗат хыялын чикләнгәнлектән азат итә, ул, автор буларак, сурәтләү чараларын куллануда ирек ала. Мондый ирек, кулланылган детальләр, символлар чынбарлыктан күпмедер ерагаюга китерсәләр дә, алар әсәрнең тулаем тормышчанлык көчен арттырырга, җәмгыятьтә хәл ителәсе мәсьәләләрне тагын да үткенрәк иттереп куярга яңа мөмкинлекләр ачалар. Менә ни өчен Һ. Такташ символлардан бервакытта да (хәтта моның өчен бик каты тәнкыйть ителсә дә) тулысынча ваз кичмәде. «Янар таулар» (1923) шигырен, гомумән, символлардан башка язып булмас иде. Җир шары үзәгендәге атомнар озак вакытлар буена басылып, кысылып яшәгәннәр. Менә алар, бөтен катламнарны үтеп, галәм киңлекләренә атылганнар. Шуның белән Һ. Такташ уянып киткән халык көченең, бигрәк тә яшь буынның, зур эшләргә, кыю адымнарга сәләтле булуын күрсәтергә омтылды. Әнә шулай галәм күләмендә эстетик фикерләү Һ. Такташ иҗатының бер уңышлы үзенчәлеген тәшкил итте.

Кеше урын һәм вакыт кисешкән ноктада яши. Галәм — бу очракта урын. Без инде аның Һ. Такташ иҗатында, сәнгать чарасы буларак, ничек сурәтләнүен күрдек. «Мәңгелек әкият» әсәрендә (1923) исә кешенең һәм аны борчыган сорауларның вакытка бәйләнешле сурәтләнүе белән очрашабыз. Монда Һ. Такташның фәлсәфәче булуы тагын да ачыла төшә. Халык фәлсәфәсе милләтнең авыз иҗаты әсәрләрендә, аерым алганда әкиятләрендә, ачык күренә. Шагыйрь дә, кешелекне мәңге уйланырга мәҗбүр иткән сорауларны ачыклау өчен, әкият алымына мөрәҗәгать итә. Әсәрнең башта чәчмә юл белән язылган булуы аны әкияткә аеруча якынайткан.

Ләкин шунысын әйтергә кирәк: «Адәм кайдан килгән, кайда китәр?» дигән сораулар бездә күптән инде язма әдәбиятта куелган һәм аңа җавап табарга омтылулар булган. Урта гасырларның атаклы шагыйрьләреннән берсе Котб, мәсәлән, «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә (1342) шушы фәлсәфи сорау тирәсендә фикер йөртә. Һ. Такташның лирик героен — «Мәңгелек әкият» әсәрендәге егетне дә — шушы ук нәрсәләр борчый. Шагыйрь биредә вакыт агышын бирүдә төрле заманда яшәгән ике егетнең бер үк мәсьәләләр хакында баш ватуларын бирү алымы ярдәмендә сиздерә. Кайчандыр бер егет мәңгелек алдына, җавап алырга өмет итеп, шушы сорауларны куйган. Ләкин мәңгелек телсез. Үткәндәге нәрсәләр, серне тирән яше-

реп, «телсез каты ташка әйләнгән». Алар җавап бирергә сәләтле түгел. Нык ихтыярлы егет мәңгелекнең тимер ишекләрен вата алмый, шул сәбәпле яшерен серләр дә ачылмый кала.

Дөньяда ике нәрсә генә — вакыт һәм тирәлек кенә (андагы җисемнәрнең торышы түгел) мәңгелек. Кеше җисми яктан мәңгелек түгел. Шуңа күрә беренче егет серне белә алмыйча үлә. Ләкин аның артыннан әлеге сораулар кала. Аларны ачыклау шөгыленә икенче егет керешә. Әнә шулай кешелек өчен әһәмиятле фикер, җисми дөньяның кеше дигән аңлы заты яшәгән вакытта, буыннардан-буыннарга тапшырылып, дәвамлы, «мәңгелек» яши. «Мәңгелек» сүзен куштырнаклар эченә алу аңлашылса кирәк, кешелекнең яшәве ахыр чиктә чын мәңгелектән (вакытның бервакытта да туктамый баруыннан) кыскарак, ул аның билгеле бер өлешен генә тәшкил итә. Җирдә тереклек яшәр шартлар бетеп, кеше юк була калса да, вакыт һичнигә карамый алга таба агышын дәвам итәчәк, аның ахыры юк һәм аны күз алдына китерү дә мөмкин түгел.

Һ. Такташның бу әсәрендәге беренче егет һәм аннан соң дөньяга килгән зәңгәр күзле егет (ул аны шулай дип атый) — фикердәшләр (искәрмик: шагыйрь үзе дә зәңгәр күзле), аларны бердәй максатлар берләштерә. Үзенең тоткан юлында гомерен дә кызганмаган беренче егетнең фидакярлеге зәңгәр күзле егетне рухландыра. Ул уңышка ирешәчәген белми, шул ук вакытта үзенең элгәренең эзләнүләрен дәвам иттермичә дә кала алмый.

Син эзләгән яшрен, зур серләрне
Мин дә эзлим, егет,—
Тыныч бул!
Син күзләгән төпсез упкыннарны
Мин дә күзлим, егет,—
Тыныч бул!

(«Мәңгелек әкият»)

Яткан таш мүкләнә, йөргән таш шомара, дигәндәй, иҗат итә-итә Һ. Такташның каләме дә чарлана, ул инде мифологияне турыдан-туры әсәрләренә эчтәлек һәм образ итеп кулланудан бигрәк аларда күтәрелгән мәсьәләләр тирәсендә уйлануларга өстенлек бирә башлый, әкренләп фәнни карашларны гәүдәләндерүгә күчә. «Кояш күктә шулай мәңге йөзәр» шигырендә (1923) ул Җир, Кояш, планеталарның хәрәкәте, аларның кайчан да булса бервакыт, инерция көче бетү аркасында,

башка хәлгә кучәчәкләрен сурәтли. Шагыйрь моны җыйнак, төгәл һәм образлы итеп әйтеп бирә:

Кояш куктә шулай мәңге йөзәр,
Көлә-көлә йөзәр, йөзәр дә...
Бер көн килер: көчле тимер канун —
Мәңгелекнең җебен өзәр дә,
Бер-берсенә бәрелеп бар йолдызлар,
Бөтен дөнья утка әйләнер,
Әйләнер дә,
Бик куп еллар үтәр,
Атомнарга атом бәйләнер.
Тагын хәят каплар кук йөзен.

Без бу шигырьдә «Мәңгелек әкият» әсәрендә башланган уйлануларның тагын да дәвам иттерелүен күрәбез. Менә ни өчен Һ. Такташ иҗатына тулаем, бөтенлекне бер җыелма рәвешендә карарга кирәк дибез. Без алга таба фикер йөртүне шул юнәлештә дәвам иттерербез дә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Һ. Такташның иҗатын нинди чорларга бүлеп карыйлар?

2. Ни өчен шагыйрь иҗатын бербөтен итеп өйрәнү отышлырак?

3. Романтик шагыйрь дигәндә, без иҗат кешесенең нинди үзенчәлекләрен күздә тотабыз?

4. Һ. Такташның романтик шагыйрь булуының сәбәпләрен ачыгыз.

5. «Газраилләр» һәм «Күктән сөрелгәннәр» әсәрләрендәге фәрештә образының сәнгатьчә эшләнешен күрсәтегез.

6. Газраил образы үзгәрештә бирелгән. Автор моның белән нәрсә әйтергә тели?

7. «Газраилләр», «Күктән сөрелгәннәр» әсәрләренең язылу җирлеген аңлатыгыз. Фәрештә, Газраил образларында шагыйрь нәрсәләрне символлаштыра?

8. Фәрештә һәм Газраил күк патшасының әмерләренә икесе ике төрле мөнәсәбәт күрсәтәләр. Бу нилектән килә?

9. Һ. Такташ ни өчен символлар куллана? Бу аңа ни өчен кирәк?

10. Һ. Такташ — фәлсәфәче шагыйрь. Шушы фикерне дәлилләгез.

Яшь егет образы

Һ. Такташ иҗатын бербөтен итеп карауга этәрүче тагын бер үзәк бар, ул да булса — аның даими лирик герое. Ул — яшь егет. Бер әсәрдән икенчесенә кучә-кучә, хакыйкать эзли.

Ярсу йөрәкле, ашкын күңелле буларак, аңа яшәп килүче кысалар тар, мәгънәсез булып кала. «Мәңгелек әкият», «Урман кызы», «Кояш күктә шулай мәңге йөзәр», «Казан» кебек әсәрләрнең үзәгеннән шушы егет үтә. Әнә шул яшь геройны сурәтләгәндә, шагыйрьнең уңышлары аеруча күренә, ныграк ачыла. Бу сөйкемле, дөньяны ул гына булдыра алганча күрә, бәяли, уйлаганын романтик күтәренкелек белән әйтеп бирә алган яшь кеше укучыларны да үзе артыннан ияртергә сәләтле. Шушы юлчы егет үзенең кабатланмас уйлары, юлда очраган маҗаралары белән укучыны да мавыктыра.

Мин бара идем ялгыз гына урман буйлап,
Ат өстендә тирән серле уйлар уйлап,—

(«Таң кызы»)

дип, ул җиңел генә игътибарны үзенә җәлеп итә.

Укучы бу егетне төрле хәл-әхвәлләрдә күрә. «Сагыну» шигырендә (1923) ул әле үзенең балалыгыннан аерылып җитмәгән. Сабый вакыты аңа «серле җәннәт» булып күренә. Биредә без бу лирик геройның чаялыгын, яшьлеген кире кайтарып бирмәгән көчләргә үзенә хас шаяртулары белән ризасызлык белдерүен күрәбез. Әлеге «көчләр» — беркемгә дә буйсынмаучы вакыт. Вакыт аяусыз. Аның үз агышы бар. Ул бер генә юнәлешкә — алга таба гына хәрәкәт итә. Шуны никадәр иртәрәк аңлый алса, кеше үзе өчен дә, җәмгыять өчен дә файдалырак яшәргә тиеш. Аның игелекле эшләре җисми гомерен узып яшәргә мөмкин. Һ. Такташның герое — әнә шундый шәхес. Ул партизан да булган, көтү дә көткән, рабфак тәмамлап, югары уку йортында да белем ала.

Кайтырмын бер килер көннәргә;
Тик көтүче булып түгел,
Ә инженер булып эшләргә!

(«Урман»)

Бу егетнең холкы бик катлаулы. «Антым» шигырендә (1920) ул ярсу, кайнар, аның һәр сүзендә көчле ихтыяры сизелә.

Һ. Такташ,— көйләүгә нигезләнгән шигырьне сөйләм стильле шигырьгә әверелдерү буенча, Я. Емельянов, С. Рәмиевләрдән килә торган башлангычны тагы да үстереп, татар шигъриятенә зур яңалык алып килгән, үзенең мәшһүр мәктәбен тудырган шагыйрь. Бу «Антым» шигырендә дә үзен нык

сиздерә. Әлеге шигырьне, бик теләсәң дә, көйләп укып булмас. Аның герое кайнарланып сөйли, әйтерсең лә трибунадан чыгыш ясый.

Герой үзен изелгәннәрне яклаучы көрәшче дип игълан итә. Әйе, мәзлумнар (изелүчеләр) мондый каһарман йөрәкле яклаучыларга мохтаҗ. Аларны каннан, вәхшәттән аралап, сәгадәт (бәхет) юлына чыгару өчен, бу хәлләрендә ярату, үз итү кирәк. Шуңа күрә дә лирик герой кулына «мәхәббәт байрагын» ала. Тик түбән катлауларның изелүе бик борынгыдан — меңнәрчә еллардан килә. Коллыкның мәңгелек бауларын өзү җиңел түгел. Шунысы ачык: Һ. Такташның романтик герое өчен мөмкин булмаган нәрсә юк. «Өзелә бер кул селтәвемнән мәңгелек баулар» дию — шуңа ишарә. Ул тылсымлы әкиятләрдә була торган егетләрне хәтерләтә. Бәхет юлына киртә булып торучыларны шагыйрь еланнар белән тиңли. Бик мәгълүм булган билге-символлар кулланып (мәсәлән, елан халык аңында явыз көч буларак гәүдәләнә), үзе әйткәннәрнең аңга гына түгел, укучының хисләренә дә тәэсир итүенә ирешә.

Күз яше һәм кан сеңгән байрак образы да Һ. Такташның символларны әсәр тукымасында тирән мәгънәле һәм сәнгатьчә үтемле итеп куллануына мисал була ала. Ләкин болар Һ. Такташны тулысы белән символист шагыйрь итеп кенә карарга мөмкинлек бирми әле. Г. Ибраһимов, мәсәлән, аны символист дип исәпләү ягында торды. Мондый нәтиҗә шагыйрьнең иҗатына бөтенлекле караш булмаудан, аның тасвирлау чараларының хасиятен аңлап бетермәүдән килә иде.

Һ. Такташ каләме бик үзенчәлекле. Үзенә кадәрге кысаларга гына сыеп бетми. Ул шуның белән кызыклы да. «Урман кызы» әсәрен (1922) игътибар белән укыган кеше аның лирик героеның күңел дөньясын ачып соклана. Яшь бер кызның рәсемен сүз ярдәмендә шулай камил тудыру шагыйрь талантының көчен күрсәтә. Матурлыкны нечкә итеп тойган егет үзе дә бай дөньясы белән ачыла. Шифалы саф һава үзен сиздермәгән кебек, күңеле белән кызны илаһилаштыручы егет образы да күзгә ташланып тормый. Ләкин ул бар. Ләйләсен көннән-көн ача барган Мәҗнүн кебек, Әминәнең асыл сыйфатлары да бары тик егет бәяләвендә генә шулай эзлекле гәүдәләнә ала. Ул аны әле су кызы итеп күрергә тели, әле фәрештәгә тиңли, әле таң кызы рәвешендә күрә. Егетнең юлчы итеп тәкъдим ителүе дә очраклы түгел. Үз-үзеннән канәгать булмаучы, эзләнүчән, якты хыялларга омтылучы

кеше, телиме-теләмиме, бары тик юлчы гына була ала. Ул — хыялы белән юлчы. Бу әсәр Һ. Такташның мәхәббәт кебек мәңгелек теманы алга таба да моңача беркем җырламаганча күтәрәчәге турында матур бер хәбәр рәвешендә кабул ителә. Юкка гына «Урман кызы» шигыре композитор Җ. Фәйзине шундый гүзәл көй язарга рухландырмаган.

Аның герое әкренләп романтик күңелле шәхестән социаль мәсьәләләр өчен борчылган кешегә әверелә бара. «Такташ үлде» шигырендә (1923) ул үзенең кискен фикерләре, иҗатта көтелмәгән борылышы белән укучыларны аеруча сискәндереп җибәрә. Зәңгәр күзле уйчан яшь егет, үзе әйткәнчә, «иске тормыш»тан йөз чөереп, көрәшчеләр арасына килә. Ул шуны образлы рәвештә «егетнең үлеме» дип атый. Дөресендә, бу аның дөньяга карашы үзгәрүен, тормыштагы урынын яңача аңлавын күрсәтә.

Шагыйрь, әсәрдәге егет образын гомумиләштереп, шигырьне «Ул үлде» дип исемли. Ләкин бу шигырь, лирик геройны сурәтләүдән бигрәк, Һ. Такташның иҗади юнәлеше һәм әсәрләренең эчтәлеге үзгәрүен күрсәтү максаты белән язылган. Шуңа күрә автор аны соңыннан «Такташ үлде» дип атый. Биредә аның лирик герое сыйфат үзгәреше кичерә. Исән-сау көенчә үзен ата-аналары өчен үлгән кеше дип игълан итүен туры мәгънәсендә аңларга кирәкми. Такташ герое өчен бу очракта ата-ана — үткәнне, искелекне гәүдәләндерүче символлар гына. Дөрес, искелек билгесе итеп ул башка символлар да ала алыр иде. Ләкин инкыйлаб белән рухланган егетнең яңа тормыш төзүдә катнашучы булуын раслау максатында, үзе өчен изге булган иң якын кешеләреннән аерымлануы барысыннан да ышанычлырак яңгырар дип уйлавына гаҗәпләнергә кирәкме икән? Кеше өчен гадәти булган ата-анасыз, малсыз, сөйгән ярсыз калган егетнең көрәшчеләр сафына килеп кушылуы төрле уйлануларга этәрә. Кеше көрәштә нәрсәне дә булса якларга тиеш, ә бу килештән әлеге егетнең изге дип санарлык бернәрсәсе дә юк кебек. Мондый кешенең көрәштә рәхимсез алымнарны үзенә корал итеп алу ихтималы укучыны борчымый калмый, билгеле.

Безнең борчылуыбыз нигезсез түгел шул. «Син дә үл инде» шигырендә (1925) лирик герой тагын да кискенрәк холыклы була бара. Ул инде яңа тормышны аңлап бетермәүчеләрнең дә яки социаль хәле буенча аны кабул итмәүчеләрнең дә «үлүен» таләп итә башлый. Ул үзенә дә, хәтта әнисенә дә ташлама

ясамый. «Сиңа булган мәхәббәте көрәш көче тарафыннан җиңелде» дип әйтергә куша ул әнисенә. Бу инде ул елларда тамыр җәйгән көрәш аскетизмы дигән нәрсәнең Һ. Такташ иҗатында чагылуы булды.

Фәлсәфәдә инкяр итүче нәрсәнең үзен дә инкяр итү дигән канун бар. Әлеге шигырьдә без моны ачык күрәбез. Әнисен инкяр иткән лирик геройның үзенә дә, бер көн килеп, улы болай диячәк икән:

— Яңа җырлар белән аренага
Яңа кешеләр килде,
Шуның өчен
Син дә үл инде...

Һәммәсен кире кагып баручы лирик герой, яшьләргә хас булган мавыгып китүе сәбәпле, бер нәрсәне оныта: үсеш табигый булырга тиеш. Ягъни һәр буын үзеннән соңгыларга яшәешне дәвам итәргә җитәрлек җисми һәм рухи көч, тереклек итүнең бик әчкә яшерелгән серләрен калдыра. Шул буыннарның бер-берсен алыштыруы ясалма рәвештә бүленсә, табигый алга барышка нык зыян килә. Әмма «кызыллык» белән авырган егет бу рәвешле алдын-артын уйларлык дәрәҗәдә түгел. «Тилергән хисләрнең даһие» буларак, ул карашын киләчәккә текәгән. Үткән белән араны өзү, икенче төрле әйткәндә, иртәгесе көннең үсеш тамырларын кисү икәнен аңлау өчен, тормыш тәҗрибәсе һәм бәйсез фикер йөртергә кирәклеген ул әле соңрак төшенер.

Бу егет һәрвакыт нәрсәне булса да инкяр итә. «Әйдә, энем!» шигырендә (1926) исә шәһәр шау-шуыннан, аның рәхимсезлегеннән авылга китеп котылырга тели ул. Шәһәрнең кешеләренә, мәдәниятенә кул селтәп, галстук белән билне буып (маймыл күзлекне аркасына куеп мәшәләнгән кебек), авыл тарафына карап юлга чыгу нияте аның ашкынулы күңелен биләп ала. Егетне шәһәрдән башка сәбәпләр дә куа кебек. Егерменче елларда җәмгыятьнең кеше хокукларын бозу юлыннан китәчәге ачык төсмерләнгән иде инде. Һ. Такташның, вариант буларак, менә болай дип язып куюы очраклылык булмагандыр:

Монда безгә:
— Мужик,
Бунтарь, диләр,
Тагын

— Буржуй!
Исмен тагарлар,
Ялгыш берәр нәрсә эшләп куйсаң,
Төрмәгә дә тотып ябарлар.

Бу герой менә шулай шагыйрьнең үзе белән бергә үсә, камилләшә, дөньяга карашы киңәя. Акылы үсә төшкән саен, аңарда бер кыйммәтле сыйфат арта бара, ул да булса — юмор хисе. Һ. Такташ иҗатында баштарак юмор чаткыларын табу җиңел түгел иде. Аның әсәрләрен аккош мамыгы төсле җиңеләйтә торган бу хасият Казанга килгәч тә бик тиз генә пәйда булмый. Моның өчен тагын ике-өч ел үтә. Гадәттә, юморның иҗатта табигый урын ала башлавы — авторның сәнгатьчә камиллеккә ирешүдә алга атлавы дигән сүз. Юмор каләм әһеленең акыл камиллеген дә күрсәтә. Һ. Такташның сәнгатьлек чараларына юмор өстәлү иҗатын тагын да ачып, үткенәйтеп, мөлаем итеп җибәрде.

Һ. Такташ иҗаты үз вакытында ук төрле бәхәсләр уятты. «Такташ бу юл белән барса, безгә кирәкми» дип әйтүгә кадәр барып җиттеләр. Аның аерым строфалары турында зур гомумиләштерүләр ясарга омтылулар булып торды. Моның бер гыйбрәтле мисалын «Үтеп барышлый» шигыре (1928) буенча да күрә алабыз. Әстерханга укучылар белән очрашуга барышлый, ул туган якларын поезд тәрәзәсеннән карап үтә. Нәтиҗәдә «Үтеп барышлый» шигыре туа. Анда бу шигырьнең безгә мәгълүм яңартылган текстыннан бераз аермалык була. Мәсәлән:

Авыр миңа хәзер,
Элек миннән курыкмый
Сәвит сүгеп йөргән абыйлар,
Хәзер инде миңа болай... әллә ничек,
Читли төшебрәк карыйлар...
Алар нәрсә уйлый хәзер? —
Кайсы аның
Алдашмыйча җавап бирәлә? —
Аю кебек алар... авыр... түземлеләр.
. . . .
Сүгенеп-нитеп булса да әле,
Үз эшләрен алып баралар,
Алар көче белән җирдән күтәрелә
Яңа авыл, яңа калалар...

Шагыйрьнең чын хәлне сиземләвенә, дөрес бәяләвенә сокланырга гына кала. Күргәнебезчә, ул элек гел гади халык

белән бергә булган; аңардан эчке серләрен яшермәгәннәр, ләкин хәзер «читли төшебрәк карыйлар». Чөнки «кызыл» шигырьләр яза башлаган шагыйрь алар өчен шиклерәк кешегә әйләнгән. Ике арада ачыктан-ачык сөйләшү була алмау сәбәпле, аларның (крестьяннарның) нәрсә уйлавын да төгәл белми ул хәзер. Крестьяннар Совет хакимиятеннән риза түгелләр, «сүгенеп-нитеп» кенә эшлиләр. Әлбәттә, мондый юллар рәсми даирәләргә ошамый. Шагыйрь, әсәрнең бу урынын үзгәртеп, менә болай язарга мәҗбүр була:

Алар башка хәзер;
Алар, тар сукмактан чыгып,
Зур юлларга табан баралар.
Алар көче белән күтәрелә
Яңа авыл, яңа калалар.

Һ. Такташ әсәрләрендә зәңгәр күзле егетне аның үз шәхесеннән аерып карап булмый. Бу герой кайвакыт ялгышты, ләкин алдашмады. Шагыйрь иҗатына бик җаваплы карады, намусы кушканча эш итте.

Һәрбер юлым, һәрбер хисем өчен
Мин үземне мәсьүл[1] санадым,—

дип язуы ихлас күңелдән иде.

Сораулар һәм биремнәр

1. Һ. Такташ әсәрләрендәге лирик герой — яшь егет образының үсеш-үзгәрешен күзәтегез.

2. Кулына «мәхәббәт байрагын» алган егетнең эш-гамәлләре сезне канәгатьләндерәме?

3. Егет образының романтик рухта булуын ничек итеп дәлилләргә мөмкин?

4. «Такташ үлде», «Син дә үл инде» шигырьләрендә яшь егет һәммә нәрсәне инкяр итә. Болай эшләве белән ул хаклымы-түгелме?

5. Егерменче елларда Һ. Такташ каләме белән идарә итү шактый көчле булган. Сез моңа игътибар иттегезме?

6. Һ. Такташны үз заманында символист шагыйрь дип атаучылар булган. Моның сәбәбен аңлатып бирегез.

7. Һ. Такташ иҗатында юморның сәнгатьлелеккә ирешүдәге урынын билгеләгез.

---

[1] *Мәсьүл* — җаваплы.

Мәхәббәт ул — үзе иске нәрсә

Һ. Такташ әдәбиятыбызга гүзәл поэмалар бирде. Шуларның да укучылар тарафыннан иң сөеп укылганы — «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы (1927).

Кеше өчен иң затлы, бөек хис — яратуның серен әле тулысынча аңлата алучы булганы юк. Ләкин шунысы ачык: кешене кеше иткән нәрсә — мәхәббәт. Аннан башка чын мәгънәсендә кешелекле, игелекле, башкаларны хөрмәт итүче, күңел нечкәлекләренә ия, назлы шәхес була алмый. Мәхәббәт — уңай хис, ә уңай хис кешене күркәм, матур итә. Ярату хисе балаларга, оныкларга күчә. Шул рәвешле, кеше гомере буе мәхәббәт белән бергә атлый. Аны картлык көннәренә кадәр саклаганнар гомерләрен мәгънәле үткәрдек дип әйтә алалар.

Кешедә мәхәббәт хисләре елның теләсә кайсы вакытында туарга мөмкин. Шулай да халык мәхәббәтнең яз белән юлдаш булуын үзенең җырларында еш искәртә. Һ. Такташ исә «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасында Зөбәйдәнең хисләре турында сөйләгәндә, күңелдә мәхәббәт хисләре кабынуның үзен язга тиңли. Мәхәббәт елның теләсә кайсы фасылын яздай матур итә.

Күңел язы шаулап үтте аның
Тәңкә карлар яуган буранда...

Бу юллар — шагыйрьнең чын сәнгатьчә табышларының берсе генә. Ә мондый табышларны Һ. Такташ әсәрләреннән бик күп очратырга була. Дөресен әйткәндә, «Мәхәббәт тәүбәсе» үзе сүз сәнгате җәүһәре дип исәпләнә ала. Һ. Такташның шагыйрьлек таланты әлеге әсәрдә аеруча тулы ачыла.

Әсәр лиро-эпик поэма жанрына керә. Димәк, анда вакыйгалар белән бергә кешенең эчке кичерешләре, хисләре бик тыгыз үрелеп бара. Зөбәйдә белән Мәхмүт бер-берсен яратышалар. Егет кызга мөнәсәбәтендә бик үк җитди түгел, аны вакытны ләззәтле уздыру өчен генә кирәк дип карый. Зөбәйдә исә Мәхмүтне ихлас ярата, шуңа күрә егет хисләренең чынлыгына шикләнми. Халык әйткәндәй, мәхәббәтнең күзе сукыр. Нәтиҗәдә егет кызны алдый. Кыз балага узгач, туачак җан иясе өчен җаваплылыктан качып, Мәхмүт Зөбәйдә янына бөтенләй килмәскә әйләнә. Бала көткән ананың күңеле болай да бик нечкә була. Ата буласы егетнең үзен ташлавы аны аеруча борчуга сала. Ләкин, бәхеткә каршы, бала тугач, егеттә үз кылганнарына үкенү хисе уяна, ул Зөбәйдәсе һәм үзенең баласы янына килә. Гаилә туа.

Мәхәббәт алдауны, хыянәтне кабул итә алмый. Аның юлдашы — сафлык, тугрылык, намуслылык. «Ирекле мәхәббәт» — кешенең татлы кичерешләреннән, аның мөкатдәс омтылышларыннан көлү ул.

Автор Зөбәйдәне бары тик уңай, егет тарафыннан кыерсытылган кыз итеп тасвирлый. Мәхмүтне исә күпмедер дәрәҗәдә тискәре сыйфатларга ия кеше буларак сурәтли. Ләкин, дөресендә, алар икесе дә бердәй гаепле, бу хәлнең килеп чыгуына бертигез җаваплы. Халкыбызга хас булган изге гореф-гадәтләрнең билгеле бер чикләрен атлап чыгу аларны шактый җайсыз хәлгә куя. Егетнең дә мондый юлга тиз төшкән кыздан, күпмедер вакытка булса да, гайрәте чигеп торуы бар. Гадәттә, җиңел холыклы кызларга егет халкы өнәмичәрәк карый торган була. Мәхмүт исә, соңыннан гына булса да, кызның холык-фигылен яхшы аңлаган, аның җитди кыз икәнен күргән. Әлбәттә, аңа карата күңелендә ярату хисе дә булган дип уйларга кирәк, шул сәбәпле ул Зөбәйдәгә ир, балага ата булырга ниятләгән. Вакыйгаларның шактый ук күңелсез тәмамлануы да мөмкин иде. Укучы, Зөбәйдәнең хәленә кергән кебек, Мәхмүтне дә яратып кала, бу гаиләнең алга таба бәхетле булырына өметләнеп, әсәр белән аерылыша.

Поэмада укучыга әллә ни сизелми торган тагын бер образ бар, ул — шагыйрьнең лирик образы. Әгәр ул булмаса, поэма болай җиңел укылмас, тәэсирләндермәс иде. Укучыны ул йөгерек теле, матур сурәтләүләре белән үзенә тартып тора, вакыйгаларга шигъри җан өрә. Башта ул мәхәббәт мәсьәләсенә шәхси мөнәсәбәтен ачыклый. Янәсе, аның Зөбәйдә белән Мәхмүт турында сүз алып барырга хакы бармы? Бар икән, чөнки лирик геройның бу мәсьәләдә иманы нык, ул ныгытып берәүне генә ярата:

«Аның» рәсмен беркем, бервакытта
Ала алмас минем күңелдән,—

ди.

Әсәр бик матур кереш өлештән башлана. Татар шигъриятендә яшьлек һәм аның табигый юлдашы мәхәббәт турында кемнең дә булса мондый да матур, җыйнак итеп әйтеп биргәне юк дияргә мөмкин.

Яшьлек,
Гомрең кыска синең,
Шундый кыска булып тоела,

Кичен чәчәк аткан була,
Ә таңында инде коела...
Мәхәббәт,
Ул үзе иске нәрсә,
Ләкин
Һәрбер йөрәк аны яңарта,
Тиле яшьлек ярты гомрен бирә
Аның хисе белән янарга...

Бу нәфис яңгыраучы юллар укучының күңелен билгеле бер дулкынга көйли, алда сүз барачак хәл-әхвәлләрне кабул итәргә әзерли. Дөресен әйткәндә, «Зөбәйдәнең рәсме» дигән беренче бүлек тә кереш дип атала ала. Биредә һәммәсе менә бу фикерне җиткерүгә хезмәт итә:

Мәхәббәт тә —
Нәфис матур чәчәк,
Ләкин
Үзе гаҗәп гомерсез,
Кайчак загс белән соңы бетә,
Ә кайчакта...
Яхшук күңелсез.

Икенче бүлектә җыйнак кына, әмма тәэсирле рәвештә Зөбәйдә белән Мәхмүт арасындагы мөнәсәбәт турында хикәят ителә. Зөбәйдәнең күңелендә мәхәббәт утлары кабыну, хисләре ташу укучыга да тәэсир итәрлек итеп бирелгән.

Аның гыйшкы көзен чәчәк атты
Эштә,
Собраниедә,
Урамда.
Күңел язы шаулап үтте аның
Тәңкә карлар яуган буранда...

Һ. Такташ яшьләр арасында булып алган тетрәндергеч хәлне әллә ни киң җәелеп тәфсилләми, акыллы кеше аңларлык итеп, кайбер ишарәләрен бирә. Ләкин Зөбәйдә белән Мәхмүт күңелендәге хисләрнең давыллы булуын сиздерү өчен, беренче карашка бу вакыйгага бөтенләй катнашы юк кебек күренгән янәшәлекләрне бирә:

Ул төнне ай күктә, эш тапмыйчы,
Эче пошып сүгенеп йөрегән,
Ул төнне Әүхәди юлга чыгып,
Кире кайткан куркып бүредән...

Шушы төнне Гыймади, эт өрсә дә,
Тәмле йокысыннан тормаган,
Шәкүр карак аның абзарыннан
Күк айгырын кереп урлаган...

Укучы күрә: бу төн ниндидер шомлы, хәерсез. Ай да холыксызлана, бүре дә котырына, караклар да үзләренең кара эшләрен башкаралар, Зөбәйдә дә алдана... Менә шулай шагыйрь укучы күңелендә әсәрнең беренче бүлегендәгегә капма-каршы кәеф, мохит тудыра. Укучыны шомлану хисе биләп ала. Бу — сюжетның төенләнеше, укучыны вакыйгалар белән кызыксындырып куюк. Алга таба болар нәрсә эшләр? Укучыны шул сорау борчый башлый. Укучы әдәби әсәр геройлары өчен борчыла башладымы, бу инде — әсәрнең уңышлы булуының ачык билгесе.

Зөбәйдә алга таба нишли? Татар хатын-кызларына хас булганча, сабырлык, тыйнаклык белән эш итә. Сөйгәненә хат яза, аны көтүен әйтә, вәгъдәсез булуына үпкә белдерә. Җавап булмагач, «зур күзләрен канлы яшьләр белән тутыра».

Кешене әнә шундый каршылыклы, күңелсез уйлар бимазалаганда, шагыйрь нигә соң әле «Хатынсыз ай» дигән бүлек китереп кертә?Бу бүлекнең исеме үк сәер кебек: ай — күк җисеме, аның хатыны буламыни? Автор урынсызга сүз уйнатмыймы? Юк, сәнгатьчә камил эшләнгән әсәрдә бу бүлекнең кирәклеге башкаларныкыннан һич тә ким түгел икән. Шагыйрь күктәге ялгыз ай белән алданган Зөбәйдәне тагын янәшә куя. Монда шагыйрьнең халык авыз иҗатына нигезләнүе әйтмәсәң дә күренеп тора. Белгәнебезчә, бездә айга багышланган җырлар бихисап.

Иртә торып тышка чыксам,
Айга карап туймыймын;
Айга карап, бергә булган
Минутларны уйлыймын,—

дигәне шуларның берсе генә. Күк йөзендәге ай һәрвакыт кешенең игътибар үзәгендә. Сагышланганда — ай да сагышлы, шатланганда, ай да шатлана кебек тоела аңа. Лирик герой да, Зөбәйдәнең күңел дөньясына бәрабәр итеп, болай ди:

Ә ай күктә һаман сүгнеп йөри,
Җил йоклады исә төн белән;
Айның хатыны да юк,
Ай ялгыз ул,
Төн үткәрсен соң ул кем белән?..

«Зөбәйдә һәм ай» бүлегендә Зөбәйдә үзе дә нәкъ шушындыйрак халәттә:

Ай да ялгыз,
Безнең Зөбәйдә дә...
Ул тын гына
Айга карап килеп утырды.

Мәхмүт — наборщик, ягъни хәреф җыючы эшче. Ләкин гадәти генә эшче булмаска тиеш, чөнки ул җыелышларда доклад сөйли, театрга йөри. Димәк, сәясәттән, сәнгатьтән читтә тормый торган кеше. Шул ук вакытта ул яңа тормышта әхлакның нигезе «ирекле сөю» булырга тиеш дип уйлый. Күрәбез, «ирекле сөю» нәтиҗәсендә дә бала туарга мөмкин. Монда инде кешенең үз баласына мөнәсәбәте турында сүз бара. Икәвең бергә яратышып дөньяга китерелгән бала өчен җаваплылыкны ананың яисә атаның гына алуы табигый булмый. Бала уртак, аның турында кайгырту икесенең дә гаме булырга тиеш. Халкыбызның күп гасырлардан килгән яшәү рәвеше шуны таләп итә. Шулай түгел икән, андый кешеләрне бервакытта да хупламаганнар. Әнә җил дә мондый гаделсезлекне күреп дулый, буран тузгыта. Шагыйрь җилнең урыныннан кузгалуын сурәтли, Зөбәйдә күңелендәге кичерешләр давылын ачып сала.

Шагыйрь шушы урында табигатьнең сөйкемле җан иясе песиләр белән кешеләр арасында охшашлык уздыра. Песи песи инде, балаларын ташлау алар өчен гадәти нәрсә, әмма кешеләр — акыл ияләре. Алар хайваннардан акыл белән эш итүләре ягыннан аерылып торалар. Ләкин чынлыкта кешеләр тагы да рәхимсезрәк икән. Шулай да шагыйрь бу очракта Мәхмүткә булган ышанычын киметми.

А, юк!
Аның күңле күрми түзалмас!

Чыннан да:

Ишек ачылып берәү әкрен генә
Зөбәйдәгә таба атлады,
— Зөбәйдә, син кичер мине!— диде,
Үзе Зөбәйдәнең
Күкрәгенә килеп ташланды...

Шул рәвешле, Һ. Такташ яшьләр арасында булырга мөмкин төрле катлаулы хәлләрне бер үк вакытта ләззәт бирер-

дәй һәм гыйбрәт алырдай итеп сурәтләп биргән. Сәнгатьчә камиллек, ихлас хисләр гәүдәләнеше әсәрнең яшәү көчен тәэмин итә, ул бүгенге укучыны да тирән дулкынландыра.

Сораулар һәм биремнәр

1. Нәрсә ул мәхәббәт? «Мәхәббәт — кешене кеше иткән» дигәндә, без бу фикергә нинди мәгънә салабыз?

2. Кеше күңелендә мәхәббәт хисе кабынсын өчен, нинди шартларның булуы кирәк?

3. Һ. Такташ әсәрне «Мәхәббәт тәүбәсе» дип атаган. «Тәүбә» сүзенең мәгънәсен ачыклагыз. Бу сүз әсәрдә кайсы образ белән бәйләнгән?

4. Сезнең Мәхмүт омтылган «ирекле сөю»гә мөнәсәбәтегез ничек?

5. Зөбәйдә һәм Мәхмүт образлары холкындагы уңай һәм кимчелекле яклар нәрсәләрдән гыйбарәт?

6. Халык тарафыннан меңнәрчә еллар дәвамында тудырылган әдәп, әхлак кануннары безнең тормышта нинди урын тота? Алар белән исәпләшмәү нинди нәтиҗәләргә китерә?

7. Шагыйрьнең лирик образының уйлары, күңел дөньясы әсәр төзелешенең камиллеген тәэмин итүдә нинди әһәмияткә ия?

8. Сәнгать чаралары буларак, ай, җил, песи малае кебек образларның әсәр тукымасындагы бурычларын аңлатып бирегез.

9. Поэманың сюжет элементларын табыгыз.

10. Һ. Такташның сурәтләү чараларында халык авыз иҗатының табигый файдаланылуына мисаллар табыгыз.

11. Әсәрнең үзегезгә нык ошаган урыннарын яки тулысынча, сәнгатьле итеп, яттан сөйләргә өйрәнегез.

Матурлык ничек югала?

Гаиләле булу, ир белән хатын мөнәсәбәтләре, аларның бала тудыру, үстерү, тәрбияләү өлкәсендәге бурычларына караган гореф-гадәтләр һәр халыкта бик күптәннән барлыкка килгән. Яшәү рәвешенең нигезен тәшкил итүләре сәбәпле, алар канунлашканнар, мәҗбүри үтәлергә тиешле нәрсәләр буларак кабул ителгәннәр. Ислам дине гаилә тормышының бик күп очракларына үзенең үтәлергә тиешле таләпләрен куя, аларны үтәү ир белән хатын, өлкәннәр белән яшьләр, төрле җенес вәкилләре арасындагы мөнәсәбәтләрнең әхлаклы, намуслы, саф, гадел булуын тәэмин итә. 1917 елда, хакимият алмашынудан соң, кызганычка каршы, «яңа тормыш» төзү тарафдарлары кабул ителгән яшәү рәвешен тулысынча инкяр итү,

гаилә кебек гаять нәзберек өлкәдә дә һәммәсен «тамырыннан үзгәртеп кору» юлына бастылар. Һ. Такташ та бу хәлгә игътибарсыз кала алмады. «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы турында сүз барганда, без моны күреп үттек инде. «Югалган матурлык» драмасы күтәрелгән мәсьәләләре ягыннан «Мәхәббәт тәүбәсе»нә аваздаш. Драманың башта шулай ук «Мәхәббәт тәүбәсе» дип аталуы ук моңа дәлил булып тора.

Әлеге әсәр үзәгенә дә гаиләдә ир белән хатынның берберенә мөнәсәбәтләре, бала тәрбияләүдәге вазифалары кебек мәсьәләләр куелган. Әсәрнең эчтәлеге аның бер герое Газиз тарафыннан әйтелгән: «Ике зур теләккә омтылган йөрәкләр, гаилә төзи алмыйлар»,— дигән фикерен раслауга кайтып кала. Әлеге «зур теләккә омтылган йөрәкләр» кемнәр соң алар?

Сүз заводта эшләүче 27 яшьлек инженер Газиз, университетта укучы 21 яшьлек Галия турында бара. Алар да җыелышларда, төрле җәмәгать эшләрендә танышканнар. Башта алар арасында гап-гади иптәшлек мөнәсәбәтләре генә. Газизне киң күңелле, йомшак табигатьле, игелекле егет итеп күрәбез. Кызга яратуын әйтергә җөрьәт итеп бетермәүче оялчан да. Аларның бергә булуы ихлас яратуга нигезләнгән.

Әсәрдә туган каршылыклар Галия образы белән бәйле. Ул ире Газизгә болай ди: «Синең каныңда аккан җиңелмәслек ирлек көчең мине синең алда хатын итеп кенә калдырудан куркам... Синең белән гакыл көчемдә иптәш икәнлегемне югалтырмын төсле». Күргәнебезчә, Галия иң әүвәл табигый рәвештә үзен хатын-кыз итеп сизә, ләкин бер үк вакытта бары тик ир хатыны гына булып калудан да курка. Шушы ике якны бергә үреп алып баруны ул күз алдына китереп бетерми, ягъни бары тик җәмәгать эшлеклесе генә булуның тулы бәхет тәэмин итмәвен аңлаудан ерак тора. Дөрес, бу эчке каршылыклар белән бара. Кайчакта аңарда хатын-кызлык ягы өстенлек ала. Менә ул үзенең иренә ана булачагын хәбәр итә: «Минем күкрәктә ике тормыш, ике йөрәк тибә башлады. Сез, ирләр, хатыннарда аналык хисләре уянган минутларны белмисез...» Аның сабыйга ихлас ана булачагына шикләнмисең. Әмма Газиз белән Галия, ир белән хатын гаиләсе урынына, Зөбәрҗәт исемле бер персонаж әйткәнчә, «иптәшлек тормышы» төзиләр. Болай бер дә начар нәрсә түгел кебек. Ләкин аның асылы гайре табигый яшәү рәвеше булып чыга.

Галия баласына йомшак күңелле ана була алмый. Күкрәк сөте күрмәгәннән, яхшы тәрбияләнмәгәннән баласы үлем хә-

лендә яткан көнне бу «ана», өйдән иртүк чыгып китеп, төнге унбердә генә кайтып керә. Бәлки, бер аптекадан икенчесенә дару эзләп йөргәндер? Юк! Сәбәбе шулкадәр ахмак: «Партсобраниедән правление җыелышына китеп соңгардым»,— ди ул ирено. Гадәти ана, кайтып керү белән, тиз генә киемен алыштырып, кулларын юып алыр һәм баласы янына ташланыр иде. Ә Галия нишли? Яшәү рәвеше турында фәлсәфә сатып утыра! Ире Газиз дә баланың һәлакәтенә тыныч карый. Галиясе исә тагын да «алгарак» китә, икенче баласын тудырып та тормый, аборт ясата. Һ. Такташның менә бу юлларын искә төшерик:

Ярый әле сезнең песи малайлары
Ни булса да тере туалар,
Ә кешеләрнең күбесе,
Бала табудан куркып,
Корсакта чакта ук буалар.

Яңа тормыш төзү өчен көрәшүче Галия — шундыйларның берсе. Ул хатын-кыз буларак кына түгел, хәтта кешегә хас эчке һәм тышкы матурлыгын югалта, кешелеген җуя. Һ. Такташ Галия кебекләрне аяусыз тәнкыйть итте.

Әсәр 1929 елда Татар академия театрында уйнала. Ләкин Галия кебек «алдынгы» кешенең бу рәвешле сурәтләнүе кайбер тәнкыйтьчеләргә ошамый. Авторны «татар әдәбиятында чит идеология» таратуда гаеплиләр. Әсәр сәхнәдән төшерелә. Драма бары тик 1956 елда гына басылып чыга һәм яңадан сәхнәдә куела. Спектакль инде уңай бәя ала.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы һәм «Югалган матурлык» драмалары арасындагы аваздаш якларны билгеләгез.

2. Галиянең егеткә үзе тәкъдим ясавы сездә нинди уйлар тудырды?

3. Галиянең күңелендә ике омтылыш бәрелешә: ана булыргамы, әллә җәмәгать эшлеклесеме? Сез ничек уйлыйсыз: ул кем булырга тиеш?

4. Галиядәге хатын-кызга хас сыйфатларны күрсәтегез.

5. Хатын-кызга тулы бәхетле булу өчен, нинди шартларның үтәлүе кирәк дип уйлыйсыз?

6. Ана булу өчен, хатын-кызда нинди сыйфатлар булырга тиеш?

7. Газиз урынында булсагыз, сез нәрсә эшләр идегез?

8. «Мәхәббәт тәүбәсе» әсәрендәге Зөбәйдә баласына нинди мөнәсәбәт күрсәтте икән? Шул турыда уйланыгыз.

9. «Гаиләдә ирнең һәм хатынның тоткан урыны» дигән темага сөйләшү уздырыгыз.

Киләчәккә хатлар барып җитә...

«Киләчәккә хатлар» (1931) — Һ. Такташның иң соңгы әсәрләреннән берсе. Ун хаттан торырга тиеш дип уйланылган бу әсәр тәмамланмаган, дөресен әйткәндә, өченче хаты да фикере тәгәлләнмичә өзелеп калган. Һәр каләм әһеле бүгенге һәм киләчәк укучылары өчен яза. Һ. Такташ исә әсәрен киләр буыннарга төбәп иҗат итә. Ләкин бу — бер әдәби алым гына. Аның бу поэмасына утызынчы еллар укучылары битараф калгандыр дип уйларга ярамый. Әйтәсе фикерен хат рәвешенә кертү шагыйрьгә укучылары белән диалог алып барырга уңайлы булып чыккан, бу хәл аңа әсәрләренең формасын төрләндерергә ярдәм иткән. Хатны шигъри юл белән язу татарларда элек-электән килгән. Һадиның әнисе дә улына хатларны шигырь белән язган. Хат алымы белән әсәрләр иҗат итүдә Һ. Такташ бездә беренче адым ясаучы түгел. Әле XIV гасыр уртасында Харәзми «Мәхәббәтнамә» («Мәхәббәт хатлары») исемле поэма язган. XIX йөз шагыйре Г. Кандалыйның «Сахибҗамал» әсәре дә — шуның бер матур мисалы. Аннан соң да шуңа охшаш әсәрләрне очратырга мөмкин.

Әлбәттә, төп яңалык биредә Һ. Такташ тарафыннан әсәр эченә салынган эчтәлектә. Бу яктан ул үзенә кадәрге авторларның берсен дә кабатламый.

«Киләчәккә хатлар»ны XX гасырның утызынчы елларында безнең илдә барган хәл-әхвәлләрне аянычлы каршылыклары белән талантлы итеп сурәтләп биргән әсәр буларак бәялибез. Шагыйрь үзе яшәгән утызынчы еллар башындагы тормышны бик яхшы белә, аның гомуми юнәлешен нечкә тәшенә, кешеләрнең күңелендәниләр барын сизгер тоя. Шул ук вакытта ул җәмгыятьтә барган үзгәрешләрне хуплый. Шагыйрь шул еллардагы сыйнфый көрәш, бер-берең арасыннан дошман эзләү, хәтта бик якын танышларыңа да шикләнеп карау халәтен сурәтләүдә дә чынбарлыкка тугрылыклы булып кала.

Безнең хисләр сездә кабатланмас,
Сез ул хисләр белән янмассыз,—
Безнең бөек чорның каршылыклы
Кешеләрен аңлый алмассыз,—

дигән юллар алга таба сүз барачак вакыйгаларга кереш булып яңгырый. Ул үз чорын «бөек» дип атый. Әйе, утызынчы еллар кешеләренең күп гасырлардан килгән яшәү рәвешләрен, гореф-гадәтләрен, хуҗалык итү тәртипләрен үзгәртеп кору

елларын «бөек» дип атарга мөмкинме дигән сорау кую яки шик белдерү ул вакытта, әлбәттә, тыела иде. Аның каравы шагыйрь шул «бөек» үзгәрешләрнең кеше күңелендә күпме каршылыклар тудырганлыгын дөрес итеп күрсәтү мөмкинлекләрен тапкан. Бусы — поэманың иң әһәмиятле ягы.

Бу җәһәттән Мохтар карт образы һәм аның фаҗигасе күпләрне битараф калдырмый. Моңа кадәр Мохтар картны комедиячел образ итеп аңлатып килделәр, аның кылганнарыннан көлделәр. Баксаң, без үзебезнең асыл тамырларыбызны кисүдән кызык табып көлеп йөргәнбез икән. Дөресендә, Мохтар карт — фаҗигале герой. Ул барлык крестьяннарга хас булган гадәт-сыйфатларны үзенә җыйган. Бу сыйфатлар түбәндәгеләр: җирне ярату, аңа хуҗа булу хисе, яшәешенең бөтен өлкәләрендә төп терәге булган атны үзенең җаны-тәненең бер өлеше итеп карау. Әмма Мохтар картны атын колхозга бирергә мәҗбүр итәләр. Аты күмәк хуҗалык абзарында булса да, ул аны әле һаман үзенеке дип исәпли. Җаен туры китереп, өстәмә ризыгын да бирә, аны карап, тәрбияләп торырга тырыша. Аты үлеп киткәч, тәмам кайгыга сабыша. Боларның һәммәсе табигый, нәкъ шулай булырга тиеш тә. Чөнки крестьянны бүтәнчә күз алдына китереп булмый. Киресенчә булганда, тормышчанлыкка зур хилафлык булыр иде.

Һ. Такташ монда бик кискен борылыш ясый: атның инде күмәк хуҗалыкныкы икәнен исенә төшергәч, Мохтар карт хәтта шатланып та куя. Янәсе, колхоз атының берсе үлсә, әле әнә ничәсе кала! Биредә шагыйрьнең күзәтүчәнлегендәге намуслылыгын билгеләмичә булмый. Колхозлашу, моны көчләү юлы белән эшләү крестьяннан иң асыл сыйфатны — хуҗа булу хисен юкка чыгарды, шул ук вакытта күмәк милеккә битарафлык тәрбияләде.

«Киләчәккә хатлар» әсәре, безнең бер тарихи чорның шигъри документы буларак, үз әһәмиятен югалтмый. Ул безгә утызынчы еллар вакыйгаларын дөрес аңларга ярдәм итә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Поэманы хат рәвешендә язуны, әдәби алым буларак, сез ничек бәялисез?

2. «Киләчәккә хатлар» әсәренең иң әһәмиятле ягын күрсәтегез.

3. Утызынчы елларны ни өчен кеше психологиясендә зур каршылыклар китереп чыгарган вакыт, дибез?

4. Мохтар картны, юмор кушып сурәтләнсә дә, фаҗигале образ, дип атадык. Комедия белән фаҗига арасында нинди бәйләнеш бар?

5. «Киләчәккә хатлар» әсәре бүгенге буын кешеләренә нәрсә бирә?

* * *

Ш и г ы р ь т ө з е л е ш е. Матур әдәбият әсәрләре барлык халыкларда да диярлек төп өч төрдә языла: чәчмә, капма-каршы сөйләшү (драма әсәрләре) һәм шигъри. Бу төрки халыклар, аерым алганда татар әдәбиятында да шулай. Бездә шигырьнең бик борынгыдан ук килүе күзәтелә. Төрки сүзлек төзегән Мәхмүд Кашгарый (XI йөз) мисал итеп китергән хисси сөйләм үрнәкләре безне бүген дә дулкынландыра. Халкыбыз, моңга һәвәс булган кебек, бәет, җыр чыгаруга да маһирлыгын күрсәткән. Әлбәттә, шигырь үзенең төзелеше, оештырылышы ягыннан әүвәлгедән үзгәреш кичерә барган.

Шигырь диюгә, нык тәртип белән берсенең астына икенчесе урнашкан ике, өч, дүрт, биш һәм аннан да күбрәк юлларның тезелеп торулары күз алдына килә. Шуңа күрә шигъри юлларны т е з е м (гарәпчә — мисраг) дип йөртәләр дә. Кайчак «шигъри әсәр» диясе урынга «тезем белән язылган әсәр» диюне ишетергә туры килә.

Ике яки аннан да күбрәк юллардан строфа оеша. С т р о ф а — теземнәр оясы — шигырьнең иң беренче күзгә ташланучы билгесе. Ләкин шигырьне шигырь иткән нәрсә бу гына түгел әле. Шигырь — ритмлы сөйләм. Ә ритм нәрсәнеңдер билгеле бер вакыт эчендә кабатлануын белдерә. Ритмсыз музыка булмаган кебек, шигырьне дә аннан башка күз алдына китерү кыен.

Икенче кыйммәт нәрсә — күңел диган,
Күңле бозык адәмнән түңел[1] диган;
Бозыкка җир өстеннән асты артык,
Булмаса күңел таза — күмел диган!

(Акмулла. «Дамелла Шиһабеддин хәзрәт...»)

Әссәламегаләйкем, Шәмсекамәр,
Без исән-сау, башкача юк яңа хәбәр;
Уңайлы вакытыңыз булырмы икән,
Бүген кич сезнең якка барсак әгәр?

(Ш. Бабич. «Шәмсекамәргә»)

---

[1] *Түңел* — йөз чөерү (бору).

Акмулла строфасындагы дүрт тезем дә унберәр иҗектән тора. Димәк, бу шигырь унберле үлчәм белән язылган. Ш. Бабич әсәреннән алынган строфаның икенче теземе — унике, беренче, өченче һәм дүртенчеләре исә унберәр иҗектән. Шулай булгач, ул — унбер-уникеле үлчәмле шигырь. Телисеңме, теләмисеңме һәр теземнән соң күпмедер арада тыныш ясап алу таләп ителә, бу исә билгеле бер ритм тудыра. Ләкин әле эш моның белән генә бетми, тезэмнәрнең уртасында да, сөйләм кануннарына туры китереп, билгеле бер иҗекләрдән соң тыныш ясап алмыйча булмый:

Газиз Йосыф	тәмам унбер
Йагъкуб сәүче	уйлукында (тезләрендә)
Уйуркән (йоклаганда) бер	гаҗәб дүш (төш)
Тәэвилини (юралышын)	атасындан

йәшәр ирде,
уйур ирде (йоклар иде),
Йосыф күрде,
сурар имде.

Игътибар итегез: һәр тезэмдә дә дүрт иҗектән соң (өченче тезэмдәге урта буыннан башкаларында) мәҗбүри рәвештә тукталып алабыз. Шулай итмәсәң, мәгънә бутала. Тезэмнәрне билгеле бер сандагы иҗектән соң багана булып телеп төшкән аралыкны ц е з у р а дип атыйлар. Цезура шигъри ритмны барлыкка китерүдә гаять әһәмияткә ия. Бу шигырьнең тезэмнәре күп иҗекле, шуңа күрә анда ике цезура бар. Тезэмнәрдә иҗекләр саны азрак икән, бер генә цезура була.

Салма, Тәңре, безне тагын
Син газапка, кайгыга,
Үтте гомеребез болай да
Канлы хәсрәт-кайгыда.

(Һ. Такташ. «Җир уллары трагедиясе»)

Әлбәттә, барлык шигырьләрдә дә цезура булу мәҗбүри түгел.

Кырга ак кардан
Юрган ябылган;
Җир язга чаклы
Уйкуга талган.

(Г. Тукай. «Җир йокысы»)

Цезура өстәмә рәвештә ритмлылыкны көчәйтүгә хезмәт итә.

Шигырьнең тотрыклы билгеләреннән берсе — аның строфалардан торуы. Берничә тезмәне бер строфага уртак фикер, интонация бәйли. Аерым шигъри әсәр, гадәттә, үлчәм ягыннан бердәй строфалардан төзелә. Мәсәлән, шигырь яки поэманың беренче строфасын шагыйрь дүрт тезмәдән, һәр тезмәсен тугыз-ун иҗектән тора торган итеп яза башлый икән, ул аның башка строфаларын да шул үлчәмдә дәвам иттерә.

Строфаны бербөтенгә туплаучы бик әһәмиятле чара булып рифма хезмәт итә. **Рифма** — шигырь юллары (тезмәләре) ахырында аваздаш, охшаш яңгырашлы сүзләр килүеннән гыйбарәт. Дөрес, рифмасыз строфалар да була, аларны **ак шигырь** дип йөртәләр. Ак шигырь драматик поэзиядә, хистән бигрәк фикергә өстенлек бирелгән әсәрләргә хас.

Син телсез, син сүзсез...
Ярсып-ярсып нәрсә сөйлисең син,
Белмим...
Ләкин сине тыңлаганда гына
Ин-иң ачык булып
Аңлашыла миңа бөтен кайгым,
Бөтен шатлыкларым.
Үземнең дә телем ачылып китә,
Фикерләрем төгәл җөмләләргә
Тезелә.
Менә бит син нинди,
Телсез, сүзсез
Музыка.

(Ә. Давыдов. «Музыка»)

Ике генә тезмәдән торган строфа **бәет** дип атала.

Башлыйк әле сүзне Карәхмәт илә,
Яд итәрләр, кем белә, рәхмәт илә.

(Г. Тукай. «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш»)

Газәл, касыйдә, кыйтга, мәснәви кебек шигъри әсәрләр бәет өслүбе белән языла. Тик алар бер-берсеннән эчтәлекләре, тезмәләрнең саны һәм рифмалашу тәртибе белән аерылалар.

Газәл — мәхәббәтне җырлауга корылган лирик шигырь, гашыйк җыры. Ул өчтән алып унике бәеттән, ягъни алты —

егерме дүрт тезмәдән торырга мөмкин. Беренче һәм икенче тезмәләр үзара рифмалашалар, аннан соңгы һәр бәетнең соңгы сүзе шушы беренче бәет рифмасы белән аваздаш була.

Бер тамаша: бу гашыйклык берлә күңел азмасын,
Агыр икән, хәсрәте чук — дошманыңа язмасын.

Бу гашыйклык тоткан икән, нинди түзем исә дә,
Бән түзәрлек дисә дә [кем], үлчәшергә базмасын.

Ул Зөләйха түзмәде лә, бер өмиден өзмәде,
Бер тоташ им эзләде лә, бетереп мал-казнасын...[1]

(Г. Кандалый. «Бер тамаша: бу гашыйклык...»)

Дөрес, газәлләрнең иҗтимагый эчтәлекле булганнары да бар. Мәсәлән, Г. Тукайның «Көзге җилләр», «Өзелгән өмид», «Сайфия», «Үтенеч», Дәрдемәнднең «Бүзләрем маналмадым» кебек әсәрләре. Кол Шәриф газәлләре дә моңа мисал була ала.

К а с ы й д ә — мактауга корылган лирик шигырь. Аның ярдәмендә автор аерым бер шәхесне яки күренекле вакыйганы бик күпертеп мактый. Мондый шигырьләрдә, гадәттә, шагыйрьләр, шул макталган шәхескә яки вакыйгага мөнәсәбәтле рәвештә, үзләренең максатларын, омтылышларын, теләкләрен дә әйтеп биргәннәр. Аларда рифмалашу газәлдәге кебек, ләкин бәетләр саны шактый күп була (уникедән алып йөзләрчә). Касыйдә үзенең рухы буенча м ә д х и я (мактау шигыре) белән аваздаш. Алар арасында аерма шунда: мәдхия үзен нинди дә булса кысалар, кагыйдәләр белән чикләми, ирекле языла.

К ы й т г а — кыска лирик шигырь. Ул фәлсәфи яки үгет-нәсыйхәт фикерләре белән сугарылган була (икедән алып ун бәеткә кадәр күләмдә).

— Фәлсәфәдән туйдык инде, сатма, ташла фәлсәфәң;
Фәлсәфә чәйнәр заман узган, хәзер эшләр заман.
— Сез туйгач та, туймаганнар ач көйгә торырмыни?
«Фәлсәфә сатма!» — дигән сүз — фәлсәфә түгелмени?

(Ш. Бабич. «Кыйтга»)

---

[1] Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында сурәтләнгән Мисыр патшасы, Йосыфны сатып алу өчен, бөтен байлыгын сарыф итә; Зөләйха да шушы гүзәл егет өчен бик күп чыгымнар тота, тәмам хәерче булып кала.

М ә с н ә в и — тезмәләре бердәй үлчәмле фәлсәфи-дидактик, романтик, героик әсәр. Һәр бәетнең ике тезмәсе дә үзара мөстәкыйль рифмалаша.

Бу жанрлар безгә Көнчыгыш (гарәп, фарсы, төрек) әдәбиятыннан кергән. Хәзерге шагыйрьләр аларны сирәк очракта гына кулланалар.

Бүгенге шигырьдә нинди дә булса төгәл чикләүләр юк. Хәзерге шагыйрьләр икеюллыкларны да, өч, дүрт һәм башка күләмдәге строфаларны да яратып кулланалар. Ш. Мөдәррис, М. Хөсәен сонетлар (ундүрт юлдан торган катлаулы строфа) да яздылар. Х. Туфанның ятраткан строфасы биш тезмәле. Ул бик табигый рәвештә беренче тезмәне бишенче итеп тулаемы белән кабатлап куярга ярата.

Татар шигыре силлабик (иҗек саны тигез булуга нигезләнгән) шигыренә керә, ягъни анда шигырь юлларында иҗек санының тигез булуы бик әһәмиятле урын тота. (Чагыштыру өчен: грек (антик) шигырендә озын һәм кыска иҗекләрнең билгеле бер тәртиптә урнашуы, русларда басымлы иҗекләрнең аерым эзлеклелектә килүе (тоник шигырь) төп нигез булып тора.)

Күргәнебезчә, шигырь төзелеше күп яктан теге яки бу телнең үзенчәлекләренә, аның аһәңе шул милләтнең рухи дөньясына, авазлар яңгырау сыйфатларына бик нык бәйләнгән. Шигъри сурәтлелек, авазлар һәм сүзләр яңгырашының хасиятләре татар шигъриятенең үзенчәлекле йөзен билгели. «Татар теле — бөек шагыйрьләр теле!» дип әйтүе белән төрек язучысы Назыйм Хикмәт хаклы.

ЕГЕРМЕНЧЕ ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Татар халкы Россиянең бик күп урыннарына таралып яши. Бу егерменче еллар әдәби хәрәкәтендә дә ачык күренә. Татар язучылары бу елларда, Казаннан тыш, Мәскәүдә, Уфа, Оренбург, Самара, Екатеринбург һәм башка шәһәрләрдә дә яшиләр һәм иҗат итәләр.

Бик күп урыннарда татар телендә вакытлы матбугат барлыкка килә, аларның эшендә каләм әһелләре зур дәрт белән катнашалар.

1921 елны Татарстанда татар теленең дәүләт теле дип игълан ителүе дә матбугатның уңышлы оешып китүенә, язучыларның илһамланып иҗат итүләренә бер сәбәп була. Алар төрле әдәби күмәклекләргә берләшә башлыйлар. «Завод» (1923), «Часовой», «Октябрь» (1924) кебек әдәби күмәкләр барлыкка килә. Бигрәк тә «Октябрь» күмәге үзенең язучыларга йогынтысын киңәйтергә омтыла. Максатыбыз, диләр октябрьчеләр, «социализм өчен хезмәт итү һәм буржуазия, мещанлык, динчелек идеологиясенә каршы көрәшү». Моннан күренгәнчә, алар әдәбиятны идеологик максатларда файдалануны үз эшчәнлекләренә нигез итеп салганнар. Аның төп оештыручылары Фәтхи Бурнаш, Шамил Усманов, Кави Нәҗми, Фәхри Әсгать, Гадел Кутуй булган. Әмма сәяси бурычлар белән мондый мавыгу кайбер каләм әһелләрен канәгатьләндермәгән. 1924 елда Г. Кутуй һәм Г. Толымбай җитәкчелегендәге бер төркем язучылар, бу күмәктән аерылып чыгып, «Сулф» («Сул фронт») дигән берләшмә хасил итәләр. Болары исә футуризм[1] дигән иҗат юнәлешенә йөз тоталар. Ләкин татар әдәбиятының ерак гасырлардан килгән традицияләрендә тәрбияләнгән татар укучысы өчен футуристларның әсәрләре ят булып тоела.

1923—1924 елларда имажинистлар[2] да әдәби хәрәкәтне үзләренчә иялтеп алып китәргә теләделәр. Ләкин алар да әдәби иҗатның халыкка аңлаешсыз формаларына мөрәҗәгать иттеләр, шуның белән үзләрен укучылардан читләштерделәр.

---

[1] *Футуризм* — әдәбиятта күптәннән килгән сурәтләү алымнарыннан баш тартып, яңача, катлаулы формада язу тарафдарлары. Бүгенге укучыларга караганда безне киләчәк буыннар яхшырак аңлар дигән өмет белән эш итүчеләр.

[2] *Имажинизм* — образлы сурәтләүгә артык игътибар итеп, мәгънә аныклыгына зыян китереп язучылар.

Шигырьдә ритмик төзелеш бетәргә тиеш дип карау шуның бер чагылышы булды. «Иске шигърият,— диде К. Нәҗми шул чорда,— үзенең чикләнгән кануннары, музыкасы, вәзеннәре[1], кафияләре[2] вә башка хасиятләре белән үзе тудырган иске җәмгыять, иске тормыш белән бергә бетәргә тиешле». Әмма, күргәнебезчә, бу агымнар үзләре әдәбият мәйданыннан читкә китәргә мәҗбүр булдылар.

Әлеге елларның язучыларын рәсми оешмалар ясалма рәвештә өч төркемгә аерып йөрттеләр: пролетар язучылар (чыгышлары буенча эшчеләр), крестьян язучылар (авылның ярлы катлавыннан үскәннәр) һәм юлаучылар (арурак тормышлы гаиләләрдән, зыялылар арасыннан чыгучылар). Бу хәл хәтта 1917 елга кадәр үк зур язучылар булып танылган каләм осталарын да үгисетеп карауга китерде һәм, әлбәттә, әдәбиятыбызның алга китешенә хезмәт итмәде. Әнә шулай Дәрдемәнд (Закир Рәмиев), Ф. Әмирхан, Г. Камал — либераль-буржуа язучылары, Г. Тукай, М. Гафури, Г. Ибраһимов, Ш. Камал вак буржуа язучылары «булдылар».

Язучыларны сәяси карашлары, идеологиягә тугрылыгы буенча гына үз итү сүз сәнгатебездә һәм эчтәлек, һәм форма ягыннан бертөрлелек хакимлек итүгә китерәчәге бәхәссез иде. Хәтта Г. Ибраһимов та «Татар әдәбияты җәмгыяте» дигән оешма төзергә тәкъдим иткәндә (1927 ел), бу берләшмәгә «гыйльми-әдәби эшләрендә марксизм принциплары» буенча эш иткән татар әдәбиятчылары керәләр дип, бүтән каләм әһелләрен читтә калдыруны хуплады. Ләкин шунысы әһәмиятле: Г. Ибраһимов бу оешмага Татарстаннан читтәге төбәкләрдә иҗат итүчеләрне дә бергә тупларга тәкъдим итте. Тик күренекле язучы-галимнең бу хыялы тормышка ашмый калды, чөнки Совет хакимияте Татарстаннан тыш төбәкләрдә яшәүче татар әдипләренең күмәкләшеп эш алып баруын хупламады. Шуңа күрә аларның күбесе (Һ. Такташ, Ш. Камал, Ә. Фәйзи, Н. Исәнбәт һ. б.) Казанга килергә, кайберләре (М. Гафури, С. Кудаш һ. б.) башка милләтләрнең язучылар оешмаларында торырга мәҗбүр булды. Россия пролетар язучылар ассоциациясенең Мәскәүдәге, Екатеринбургтагы, Уфадагы, Самарадагы татар секцияләре дә утызынчы елларда бетерелде. Бу безнең әдәбиятыбызның яшәү, таралу чикләрен тарайтуга юнәлдерелгән сәясәтнең бер чагылышы иде.

---

[1] *Вәзен* — шигырьдә иҗек саны; ритм.

[2] *Кафия* — рифма.

1928 елның язында Казанда ТАПП (Татарстан пролетар язучылар ассоциациясе) оештырыла. Исеменнән күренгәнчә, ул шулай ук чыгышы белән пролетар язучыларны гына берләштерә. Ләкин аңа мөстәкыйль эш итәргә мөмкинчелек булмый, әдәби хәрәкәттә ул РАПП (Россия пролетар язучылар ассоциациясе) җитәкчеләре күрсәтмәләрен үтәүдән ерак китә алмый. ТАПП чыгарган «Атака» журналы, мәсәлән, әдәби булудан бигрәк, сәяси матбугат органын хәтерләтә. Чөнки ул нигдидер үз йөзе булмаган интернациональ әдәбият булдыру, милли үзенчәлекләргә, әдәбияттагы уңлык (коммунистларча булмаган) күренешләренә каршы көрәш алып баруны төп максат итә. Әлеге журнал ул елларда ялганга нигезләнеп әвәләнгән «солтангалиевчеләрнең» тамырын корытуга аеруча өлеш кертә. Һ. Такташ та, «көрәш булмаган җирдә әдәбиятның кирәге юк» дип, сәнгатьнең бурычын сәясәткә бәйләп карый.

1929 елның сентябрь ае ахырында РАППның пленумында ТАПП җитәкчеләреннән берсе Гомәр Галинең хисап чыгышын тыңлыйлар. Шул җыелышның кабул иткән карары бик гыйбрәтле. «Революциягә чаклы,— диелә анда,— татар әдәбиятының төп йөзе буржуазия әдәбияты булмыйча мөмкин түгел иде». Моннан әдәби әсәрләргә бары тик сыйнфый яктан гына бәя бирелүе бик яхшы күренә. Октябрь борылышына кадәрге әдәбиятыбызга мондый мөһер сугылу үз мирасыбызны кире кагып, татар әдәбиятын меңьеллык тамырларыннан аерып кую дигән сүз иде.

Бу карарда сәнгатьчә осталык мәсьәләләренә карата сүз әйтергә онытылса да, идеология ягына нык игътибар ителгән. «Сәнгатьтә һәм әдәбиятта,— диелә анда,— буржуаз идеологиясе белән килешүчәнлеккә һәм бу өлкәдә партия сызыгыннан читкә тайпылуга яки аны бозуга каршы чиксез каты көрәш алып барырга». Монда инде каләм әһеленә як-якка борылырга да урын юк, ул ирекле эш йөртүдән тулысынча мәхрүм ителгән булып чыга. Шул рәвешле, элек-электән рухи аралашып яшәгән Көнчыгыш, аерым алганда төрек сүз сәнгатьләре белән арадашлык итү ярамый торган эш дип санала, аларның ишеге безнең өчен ябылып куела. Бу хәл әдәбиятыбызда гаять зур югалтуларга китерә.

Алай гына да түгел, ТАППның үз эчендә дә язучыларның бер-беренә сынау күзе белән карарга тиешлеге әйтелә, «ТАПП һәм башка татар секцияләре үзләренең составларын чистартырга тиеш» дигән боерык бирелә. Мондый шартларда

кулга каләм алып иҗат итү, язучылар сафында тору, әлбәттә, кешедән үзе бер зур батырлык сорый иде. Әсәрләреңә карап түгел, бәлки социаль чыгышың буенча дуска яки дошманга аеру, күңел теләгәнне, җаныңны борчыганны яза алмау шартларында каләм белән эш итү җиңел буламы соң?!

Сораулар һәм биремнәр

1. Егерменче елларда татарча вакытлы матбугат җанлануын һәм аның географиясе киңәюен сез ничек аңлатыр идегез?

2. Язучылар ни өчен төрле күмәклекләргә берләшергә телиләр? Нинди дә булса иҗат оешмасына кермичә генә иҗат итеп буламы?

3. «Октябрь» күмәге ни өчен икегә аерыла?

4. Нәрсә ул футуризм, имажинизм? Аларның барлыкка килүенә аерым кешеләр сәбәпчеме, әллә зарурилыкмы?

5. Язучыларны пролетар, крестьян һәм юлаучыларга бүлү дөрес булганмы?

6. «Татар әдәбияты җәмгыяте»н төзергә тәкъдим иткән Г. Ибраһимовның дөрес һәм хаталы карашларын аерып күрсәтегез. Бу җәмгыять ни өчен Татарстанда да, аннан читтәге төбәкләрдә дә төзелми кала?

7. РАПП һәм ТАППларның әдәбият өлкәсендә алып барган сәясәтен ачыклагыз.

8. Безне әдәби мирастан, күп гасырлардан бирле аралашып килгән Көнчыгыш әдәбиятыннан читләштерергә омтылуның сәбәпләрен сез нидәрдә күрәсез?

9. Язучының каләме белән идарә итәргә омтылуның аянычлы ягы нәрсәләрдә күренә?

* * *

Егерменче еллар безнең халык тормышының аеруча катлаулы, фәкыйрь, билгесезлек чоры булды. Икътисади нигез җимерелеп, яңа шартларда җитештерү җайга салынмаган, гражданнар сугышы, ниһаять, бетүгә карамастан, большевиклар сыйнфый көрәшне дәвам иттерәләр. Бу хәл халыкка бетмәс-төкәнмәс авырлык, фаҗига алып килә.

Әдәбият әһелләре дә бик кыен хәлдә яши. Шуңа карамастан алар иҗат итә, китаплар, җыентыклар бастыра. Аларның күңелләрендә киләчәкнең яхшырак булырына ышаныч кимеми. Шул өмет аларны яшәтә, каләмнәренә көч бирә.

Инкыйлаб һәм аннан соңгы болгавыр елларда әдәбиятта яшьләрдән байтак яңа исемнәр пәйда булды. Алар, тормышны үзгәртеп кору хәрәкәте белән рухланып, шигъри әсәрләр язуда шактый гына активлык күрсәтеп алдылар. Ләкин бу еллар

безнең әдәбиятка югалтулар да алып килде: Шамун Фидаи, Ибраһим Йосфый, Даут Гобәйди — аклар кулыннан, Шәехзадә Бабич кызыллар тарафыннан рәхимсез рәвештә үтерелделәр. Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, Ф. Әсгать, авырулары көчәю сәбәпле, иҗатларын сүлпәнәйттеләр, һәм өчесе дә 1926 елда вафат булды. 1928 елда М. Фәйзи дә дөньядан китте.

Инкыйлаб башланган вакытта барлыкка килгән олы өметләрнең акланмавы кулларына иҗат каләме алган байтак кешеләрнең күңелен төшерде. Дөрес, чын талант теләсә нинди шартларда да сүнеп калмый. М. Гафури, Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ш. Камал, Ф. Бурнаш, Н. Исәнбәт, К. Әмири, С. Сүнчәләй, С. Кудаш, М. Галәү, Ш. Усманов, чит илгә китәргә мәҗбүр булган Гаяз Исхакый, Фуат Туктаров һәм халыкта танылган Риза Фәхреддинов, Һади Атласи, Муса Бигиев иҗатларын дәвам иттерделәр.

Егерменче еллар әдәбиятыбызга кыю һәм талантлы яшь каләм көчләрен бирде. Алар арасында иң әүвәл Һ. Такташ, Х. Туфан, М. Җәлил, М. Максуд, К. Нәҗми, Ә. Фәйзи, Г. Кутуй, Ф. Кәрим, Ә. Исхак, Ш. Маннур, С. Баттал, Б. Рәхмәт һәм башкалар күздә тотыла. Әдәбият белеме һәм тәнкыйте өлкәсендә Габдрахман Сәгъди, Җамал Вәлиди, Галимҗан Нигъмәти, Гали Рәхим нәтиҗәле эшли.

Бу ун елда әдәбиятта нинди темалар үзәктә тора соң? Шулардан: инкыйлаб һәм гражданнар сугышы; сугыштан соңгы чордагы сыйнфый көрәш; эшчеләр тормышы; эшчеләр һәм крестьяннар психологиясендә, яшәү рәвешләрендә барлыкка килгән үзгәрешләр; диннең һәм дин әһелләренең абруен төшерү; рус мәдәниятенә һәм рус яшәү рәвешенә ихтирам тәрбияләү; чит илләрне, бигрәк тә төрек, гарәп, фарсы дөньясын, ягъни Көнчыгышны безгә дошман итеп күрсәтү; юлбашчыларны, аларның сәясәтен мактау кебек темалар. Күрәбез, сүз сәнгате кебек, кешегә гаять көчле тәэсир итү коралы, нигездә, бер максатка — 1917 елга кадәрге барлык нәрсәне инкяр итеп, шуннан соңгы «уңышларны» алсу-кызыл бизәкләргә төреп сурәтләүгә хезмәт итә.

Егерменче еллар башында әдәбиятта гыйсъянчы (бөтен нәрсәне инкяр итүче) герой актив булды. Мондый герой безнең сүз сәнгатебездә шушы чорда гына туды дию дөрес булмас, аның традицияләре шактый еракка китә. Ләкин егерменче елларның беренче яртысында милли әдәбият җирлегендә гыйсъянчы образының активлашуы күзгә ныграк чалына. Бу

романтик герой, инкыйлаб вакыйгаларына зуррак өмет баглап, элеккегене кире кагу юлына басты. Һ. Такташның «Гыйсъян» шигыре (1923) — бу яктан караганда аеруча дәһшәтлесе, куе буяулар белән сурәтләнгәне. Аның гыйсъянчы герое инкяр итүче генә түгел, үзе әйтүенчә, усал, явыз да. Үзләренең бәхете өчен илен корбан итүчеләргә ул нәфрәт белән карый. Бу ил исерек, ди ул, аның кешеләре дә тиләләр. Шәп атка атланып килүче яңа гасырны (инкыйлабтан соңгы чорны герой шулай дип атый) исерек хәлдә каршылау оят, ди ул.

Һ. Такташның гыйсъянчы герое яһүдләрнең «Тәүрат»ын да, русларның «Инҗил»ен дә «себереп түгә», бер уңайдан «Коръән»не утка якканлыгын әйтә. Димәк, әлеге гыйсъянчы җирдәге тәртипләргә генә түгел, дини һәм рухи кануннарга да берьюлы каршы чыга. Мондый гаять олы колачлы инкяр итүче образы татар әдәбиятында иң беренче Һ. Такташ тарафыннан тудырылды. «Җир уллары трагедиясе»ндәге Кабил образы да нәкъ менә шундый герой иде.

М. Җәлил, Н. Исәнбәт, К. Нәҗми дә үз әсәрләрендә гыйсъянчы-көрәшче образын сурәтләделәр.

Ләкин шигърият бары тик көрәшче образын тудырудан гына тормый. Шигырь дидеңме, анда гүзәл, нәфис уйларны, хис-тойгыларны гәүдәләндергән җылы сүзтезмәләр пәйда була. Инкыйлаб, гражданнар сугышы, сыйнфый көрәш җырын гына җырлаган шигърият, ниһаять, бер көн килеп, кеше күңеленә якынаятөшәргә тиеш иде. Бу шулай булды да. Егерменче еллар уртасында, җәмгыять чагыштырмача тотрыклырак була барган саен, шагыйрьләр лирик әсәрләр язуга да игътибар итә башладылар. Шулай да лириканы көрәш белән бергә үреп бару омтылышы байтак сакланып килде.

Дуслар, кабат-кабат сүгәрсез дә
Нечкәләнгән лирик җырларны.
Ләкин минем йөрәк тибеп сорый
Лирикада көрәш җырлауны.

(Д. Фәтхи. «Салкын күбәләкләр»)

Бу турыда, җыйнак һәм үтемле итеп, Х. Туфан да әйтте:

Иң ахыргы, соңгы сулышны да
Көрәш учагына өрербез,
Йөрәкләрнең соң кат тибүен дә
Тәзү кадагына бирербез!

(«Аягүрә үлеп булыр микән?»)

Ә. Фәйзи дә, күңел кичерешләрен, табигать күренешләрен сурәтләгәндә, сәясәттән тиз генә азат булып бетә алмый.

Карале син, кара! Кызарып бара...
Кояш чыга, иртә, күңелле...
Әле иртә, алда — «бөек көндез»,
Каршылыйбыз, сөенеп, бүгенне.

Мондый мисалларны ул вакытта иҗат иткән байтак шагыйрьләрдән табарга мөмкин булыр иде. Бу Ә. Фәйзи әйткән «бөек көндез»нең, ягъни яңача корылган тормышның кешеләр өчен бәхет алып киләчәгенә ихлас ышанудан туган рух күтәренкелеге белән аңлатылды.

Лирика белән сәясәт мөнәсәбәте турында егерменче елларның кайнар йөрәкле шагыйрьләреннән берсе Г. Кутуй да уйланмый калмаган. С. Есенинның фаҗигале үлеме уңае белән, ул болай дип яза: «Есенин, теләсә дә, революционер була алмас иде. Чөнки аның тормышы лирикага сатылган. Ул аңардан аерыла алмый». Күргәнебезчә, бу вакытта Есенинча үтә нечкә, интим хис-кичерешләр белән өртелгән лириканы әллә ни кирәксенмәделәр. Андый шигъриятне «күңел төбендә казынучы мещанлык» дип атадылар. Безнең шигъриятнең нинди эстетик каршылыклар, бәхәсләр эчендә үсүе моннан ачык күренә.

Чын шигърият яшьлек хисләреннән, сөю, сагыну, соклану тойгыларыннан мәхрүм була алмый. Яшь каләмнәр моңа аеруча сизгер була. Шәйхи Маннур да 1928 елда кеше өчен гадәти хис-тойгыларны гәүдәләндергән «Сагыну җыры» шигырен бастыра. Лирик герой, гади генә итеп, үз күңелендәгеләрне әйтеп бирә:

Бөдрә урманнарга кәккүк килер,
Кәккүк җырлар,
Кәккүк моңаер.
Ялгыз кәккүк кебек ялгыз башым
Кемгә сыкрар, кемгә елмаер?

Һәр таң саен Идел ярына килеп,
Сагыну җырын җырлап үтәм мин.
Һәр таң белән Идел комнарыннан
Эзләреңне эзләп китәм мин.

Баласыз каз нинди уйчан йөри,
Башын түбән салып моң гына.
Сагыну җырын,
Татлы сагыну җырын
Сагынганда җырлыйм тын гына.

Биредә инде автор сәясәткә керми, кешенең күңел дөньясын җай гына сурәтләп бирә. «Рәхмәт, бик матур шигырь. Киләчәктә дә шулай уңышлы иҗат итегез»,— ди аңа тел галиме Гыйбад Алпаров. Шул заманның атаклы җырчысы Ситдыйк Айдаров бу шигырьнең берничә строфасын халык көенә җырлый башлый. Шуннан канатланган Ш. Маннур «Соңгы уйлар» шигырен бастыра.

Ләкин «Безнең юл» журналы әлеге әсәрләрне «үлеп бара торган капитализмның соңгы шыңшынуы» дип бәяли. «Ш. Маннурның бу шигыре, пессимизм үрнәге буларак, каты тәнкыйть утына тотылсын»,— дип язып чыга. Һәм утка тоталар да аны. Бер тәнкыйтьче «иптәш» аеруча тырыша, яшь шагыйрьне «буржуа сыбызгысы», «кулак сандугачы», «чыкылтап торган чит элемент» дип атый. Әйе, сөю, назлану, матурлыкны күрә, бәяли белү буржуаз калдык, безгә чит күренеш дип исәпләнгән ул елларда Ш. Маннурдай шагыйрьләрнең әсәрләре колакка ятрак тоелгандыр шул.

Шигъри әсәрләр, әлбәттә, төрле-төрле була. Кайберләре сәясәткә багышлана, икенчеләрендә акыл, фикер өстенлек итә, өченчеләрендә хис-тойгы үзәк урынны ала. Аларның һәркайсы — олы акыл «җимеше», иҗат нәтиҗәсе. Һәрберсе дә яшәргә хокуклы. Шигъриятнең хасиятен исәпкә алып эш итмәгәндә, теге яки бу каләм әһеле иҗатын дөрес бәяләмәскә мөмкин. Һ. Такташ, С. Кудаш, Ә. Фәйзи һәм башка күп кенә шагыйрьләр өчен кешегә хас булган хисләрнең берсе дә ят булмадылар. С. Кудашның «Туган җир» (1925), «Кына чәчкәсе» (1927) шигырьләре лирик әсәрләрнең матур үрнәге булды.

Җырлый-җырлый көн дә каршылыйсың,
Тәрәзә ачып, көннең иртәсен,
Кына чәчкәләре арасыннан
Күзләреңне кемгә сирпәсең?
Әйтче, кызый, кемгә җырлыйсың?

Кына чәчкәсенең кызылыдай,
Ал бөркелә матур йөзеңә.
Гөлләр үтәсеннән дәрт елмайтып,
Нинди ут ул яна күзеңдә?
Әйтче, кызый, кемне күзлисең?

(«Кына чәчкәсе»)

Шигърияттен, нигездә, сәясәткә генә багышлаган М. Гафури да кешенең табигый халәтен җырлаган «Яз» (1925),

«Диңгез янында» (1929) кебек шигырьләр иҗат итте. Гуманист табигатьле М. Гафури, инкыйлабтан соң тугыз ел үткәч тә, халыкның тормышы һаман авыр булуын үз «мине» кичерешләре ярдәмендә йөрәккә үткәзергә тырышты:

Таңын һаман күрә алмыйм төнемнең,
Читен һаман күрә алмыйм диңгеземнең.
Нигә янам?.. Нигә мин шат түгелмен?..
Нигә соң яктысы аз көндеземнең?..

Шигъриятьтә фикер аныклыгы, хисләр тирәнлегенең җиңеп чыгуы, һичсүзсез, сүз сәнгатебез үсешенең дөрес юнәлештә булуын күрсәтә.

Егерменче еллар шигъриятенә романтизм да ят түгел иде. Гәрчә ул вакытта романтизмга карашлар төрлечә булса да, шигырьнең сәнгатьлелеген тәэмин итүдә аның укучы күңелен җәлеп итүчән хасиятләре уңышлы кулланылу мисалларын да очратырга мөмкин. Әлбәттә, бу юнәлешне Һ. Такташ җитәкләде. Аның «Җир уллары трагедиясе» мондый әсәрләрнең иң уңышлыларыннан берсе дияргә була.

Бу чорда поэма жанры активлашты. Х. Туфанның «Башлана башлады», «Ике чор арасында» (1927), «Бибиевләр» (1932), Һ. Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» (1927), М. Гафуриның «Эшче» (1928) әсәрләре поэзиянең үсешен тәэмин иттеләр. М. Гафури әлеге поэмасының беренче вариантын 1920 елда ук язган иде. Аның төп герое — эшче, төрле заводларда, шахталарда эшләп, тормышын бөтәйтә алмагач, авылына кайтып китә. 1928 елда язганында исә эшченең язмышы үзгәрә: ул сыйнфый көрәштә катнашып һәлак була. Әдәбият белгечләре әсәрнең беренче вариантын — тәнкыйди реализм, икенчесен социалистик реализм ысулы белән язылган дип бәяләделәр.

Реализмны тәнкыйди һәм социалистик дигән төрләргә бүлү сүз сәнгатен сәясәтләштерүдән килеп чыкты. Дөресендә, чынбарлыкны әдәбиятта чагылдыруның ике ысулы бар: хыял белән иркен эш итеп, нигездә, рухи тормышны күтәренке өслүбтә (стильдә) гәүдәләндерү (романтизм) һәм тормыштагыга якынайтып сурәтләү (реализм). Ләкин егерменче елларда «реализмның яңа шартларны сурәтләргә мөмкинлек бирердәй башкача ысулын табарга» дигән бурыч куелды, һәм шул юнәлештә эзләнүләр алып барылды. М. Гафуриның «Эшче» поэмасының икенче варианты әдәбият галимнәре тарафыннан нәкъ әнә шул яңача сурәтләүнең уңышлы бер үрнәге итеп каралды.

Хезмәт белән рухланган эшчеләрне калку итеп күрсәтү ягыннан Ш. Маннурның «Колчеданлы таулар өстендә» поэмасы (1929) үз чорында бер яңалык булып кабул ителде. Х. Туфан үз заманын фәлсәфи-лирик уйланулар ярдәмендә ачты. М. Гафури исә эшченең социаль хәлен чынбарлыктагыча күрсәтүне максат итте. Һ. Такташ татар поэмасының бөтенләй яңа рәвешлесен — лирик юмор белән сугарылган үрнәген бирде. Боларның барысында лирика белән эпос рухы һәм чалымнары бергә кушылды. Тик моны һәрбер шагыйрь үзенчә эшләде.

Сораулар һәм биремнәр

1. Егерменче еллар иҗат итү өчен катлаулы һәм авыр чор булды, диюебезне ничек дәлилләрсез?

2. Әдәбият тормыш белән нык бәйләнештә генә үсә ала. Егерменче еллар сүз сәнгатенә карата моны ничек әйтерсез?

3. Кем ул гыйсъянчы герой? Егерменче елларның беренче яртысында аның аеруча күп сурәтләнүе нәрсә белән аңлатыла?

4. Бу вакытта күп шагыйрьләр әдәбиятны ни өчен көрәш белән бәйлиләр?

5. Ш. Маннурның лирик шигырьләре ни өчен каты тәнкыйтькә очрый? Сезнең уегызча, аңа карата әйтелгән фикерләр урынлымы?

6. Иҗат ысуллары булган романтизм һәм реализм турында сөйләгез.

7. Һ. Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы мисалында лирик юморның сәнгатьлелекне тәэмин итүдәге әһәмиятен күрсәтеп бирегез.

* * *

Егерменче елларда чәчмә әсәрләр иҗат итү өлкәсендә дә эзләнүләр барды. Шулай да монда шигърияттәге кебек форма мәсьәләләрендә бер яктан икенче якка ташланулар кимрәк булды. Каләм әһелләре чынбарлыктагыча сурәтләү стилен төп кыйбла итеп алдылар. Тел, стиль мәсьәләләрендә инкыйлабка кадәрге прозабызның ирешкән уңышлары күпчелек язучыларыбыз өчен нигез булып хезмәт итте.

Ләкин инкыйлаб әдәбиятны да капма-каршы ике сафка аерды. Гаяз Исхакый, Фуат Туктаров, Муса Бигиев, Һади Атласи бөтенләй инкяр ителделәр, аларны «ак әдәбият» вәкилләре дип атау гадәткә керде. Гали Рәхимнең «Идел» исемле зур хикәясе дә (1922) шулар рәтендә каралды. Г. Ибраһимов та аны «черек буржуа рухлы» әсәр дип атады. Янәсе, ул үз халкын «канаты сынган акчарлакка» тиңләде.

«Идел»нең төп герое чынбарлыкны булганынча күрә. Ул болай уйлана: «Әнә аргы якта олуг Татарстан җәелеп ята. Шунда тирес оясы төсле искергән саламга күмелгән авылларда, кечкенә генә өйләрдә хисапсыз күп бәхетсез кешеләр гомер кичерәләр. Бәхетсез халыкның бәхетсез балалары! Аларны бернисез сугышларга илтеп тураталар. Алар, сарык көтүе төсле, ләм-мим димичә, кем өчендер шунда барып, төз җирне түмгәк итәләр...»

Г. Рәхимнең үз герое авызыннан мондый күңел төшенкелегеннән гыйбарәт булган монологны бирүе очраклы түгел иде. Әсәр 1922 елда, ягъни безнең халык өчен аеруча авыр бер вакытта язылган. 1921 елгы ачлык Идел буенда яшәүчеләр өчен зур афәт була, татар халкына ул аеруча зур югалтулар китерә. Шул вакытта кулына иҗат каләме алган кешенең, бигрәк тә милләтебезнең ерак тарихын бик яхшы белүче Г. Рәхимнең «бәхетсез халыкның бәхетсез балалары!» дип язарга хакы бар иде, әлбәттә.

К. Нәҗминең «Тукран даласы» хикәясе, Ф. Әмирханның «Тәгъзия» нәсере, М. Гафуриның «Кеше ашаучылар» поэмалары шул ачлык елының җанны өшетерлек күренешләрен тасвирлауга багышландылар. Бу теманы яктырткан әсәрләр арасында фаҗигане аеруча тирән итеп күрсәткәне Г. Ибраһимовның «Адәмнәр» повесте (1923) булды. Яңа гына Совет хакимияте яклыларны кызыл чәчәкләргә тиңләп (сүз «Кызыл чәчәкләр» повесте (1922) турында бара) язган Г. Ибраһимовның мондый әдәби әсәр тәкъдим итүе үзе бер гыйбрәтле хәл иде. Демократиягә юнәлеш тоткан илдә, хакимиятне үз кулларына алып, гражданнар сугышы китереп чыгарган большевиклар бу турыда нәрсә дә булса язуны өнәмәделәр. Язылган очракта да, аларча, бу бәхетсезлекләрнең сәбәпчесе итеп кулакларны күрсәтергә кирәк иде. Г. Ибраһимов исә, бернинди сәяси күрсәтмәләрне искә алмыйча, хәлне ничек булса, шулай сурәтли.

Язучы фаҗиганең тирәнлеген бигрәк тә Гәрәй карт гаиләсе мисалында күрсәтә. Хатынының, балаларының бер-бер артлы дөнья куюлары хәсрәтен кичергән Гәрәйнең соңгы чиктә вәхшилеккә баруы психологик яктан гаять тирән анализланган.

Ш. Усманов Г. Ибраһимовның бу әсәрен 1924 елда ук тәнкыйтьләп чыкты. Аның төп кимчелеген ул «Советлар хөкүмәтенең ачлык белән көрәшү юлында зур фидакярлекләр

күрсәтүен» ачмауда күрде. Чыннан да, Совет хакимияте ни өчен, ач үлемнән коткарып калырлык кына булса да, Идел буе халкына ярдәм оештыра алмаган? Җавап гади: большевиклар бөтен илне хәерче хәленә төшерделәр. Моның сәбәпләре күп иде. Бердән, халыкны үзара сугыштыру нәтиҗәсендә, илдә азык-төлек җитештерү азайды. Икенчедән, игенченең ашлыкны мул җитештерүгә омтылышы кимеде, чөнки икмәкнең бар булганын кырып-себереп алып чыгып киттеләр. Өченчедән, Брест солыхы нигезендә Россиянең Германиягә бик күп ашлык озатырга тиеш булуы да үзенең йогынтысын ясамый калмады. Һәм башка шундыйлар. Ягъни, Ш. Усманов таләп иткәнчә эшләгәндә, язучы менә шушыларны ачлыкның төп сәбәпләре итеп күрсәтергә тиеш иде. Ә Г. Ибраһимов аның сәбәпләрен санап күрсәтеп тормый, бәлки ачлыкның аянычлы күренешләрен тасвирлый. Әсәр 1990 елга кадәр кабат басылмады, һәм әдәбиятка багышланган фәнни хезмәтләрдә ул, Г. Ибраһимовны натурализмга бирелүдә шелтәләү өчен, бер сәбәп булып килде.

Ф. Әмирхан 1921 елның 8 октябрендә язган көндәлегендә ачлыкның сәбәпләрен шактый дөрес ача. «Менә соңгы чирек гасыр эчендә генә инде бу ачлык Русиядә өченче мәртәбә. Боларның һәр өчесендә ачлыктан иң каты ярдәмчесез калган, аннан каты җәфа чиккән халык — Волга һәм Кама буйлары тирәсендәрәк утырган татар халкы булды. Деспотизм дәверендә ачлыктан иң күп җәфа чиккән татар халкының инде революциядән соңгы әүвәлге ачлыкта да ярдәмчесез калуы, бу яктан социальный революциянең без татарларның хәлен үзгәртә алмавы безнең икътисади яктан иң зәгыйфь халык икәнебезне күрсәтә... Партияле иптәшләр... миңа «әүвәлге еллардагы ачлыклар» мәүзугына язарга заказ биргәннәр иде. Аларча, партиясез бер мөхәррир каләме белән: «Бу елгы ачлык — бары самодержавиедән калган мирас, бу турыда хәзерге властьның һич гөнаһы юк. Ачлыктан шәһәр урамнарында үлә торган крестьянның әхвәленнән бераз хәбәрдар булган өлеше юкка гына Сәетгалиев — Борһан Мансуровлар (большевиклар партиясенең Татарстандагы җитәкчеләре.— *Ф. Г.*) партиясен ләгънәтләп үлә»,— дип язылып калырга кирәк иде. Мин алай дип яза алмадым. Чөнки мәркәзнең (Мәскәүнең дип аңларга кирәк.— *Ф. Г.*) менгезүе белән мәркәздә (хакимияттә.— *Ф. Г.*) торган Сәетгалиев — Мансуровлар агымының бу ачлыкны

татар гонсыры[1] башына китерүдә бик зур рольләре барлыгы, мәркәз алдында тәлинкә тоту наменә аларның татар крестьяннарыннан хәтта мәркәздә тәгаен ителгән[2] микъдардан артык иген көчләп тартып алуларын, җирле большевикларның татар авылларына развёрстканы гаять тарифгиранә[3] салып, бөтен крестьян хуҗалыкларын аяктан екканлыкларын, әүвәлге татар кечкенә чиновник һәм татар полиция унтерлары тибының бары иләк ягы белән әйләндерелеп, кызыл буяуга буяганнарыннан гыйбарәт булган Сәетгалиев—Мансуров фиркасенең бу эштә бер дә шөбһәсез кабахәт бер гамилләр[4] икәнлекләрен мин яхшы беләидем».

Шул рәвешле, Ф. Әмирхан, 1920 елда Татарстан Республикасы төзелүгә шатлануын белдерсә дә, аның җитәкчеләренең халык мәнфәгатьләрен түгел, бәлки үз урыннарын саклап калу турында гына кайгыртуларын аңлагач, Совет хакимиятенә дә, коммунистлар фиркасенә дә ышанмый башлый. Аларның гамәлләреннән иҗаты өчен рухланырлык нәрсә тапмый. Киресенчә, 1924—1925 елларда язылган «Шәфигулла агай» исемле хикәясендә, яңа тормыш төзибез дип, коры куык очыручыларны ирония белән сурәтли. Әлбәттә, мондый юнәлештәге әсәр Совет хакимияте елларында дөнья күрә алмады. Ул бары тик 1991 елда гына беренче тапкыр укучыларга барып ирешә һәм безнең Ф. Әмирхан иҗаты турындагы карашларыбызны тулыландырып җибәрде. Яңа чынбарлыкка әнә шулай тәнкыйть күзе белән караучы язучыларның әсәрләре дөньяга чыга алмау гына андый язмалар булмады дип әйтергә хокук бирми әле.

Ә менә К. Нәҗми, А. Шамов, М. Максуд, Ф. Әсгать, Ш. Усмановның әсәрләре кан коюлы сугыш елларының әдәби елъязмасы булу ягыннан гыйбрәтле. Алар стильләре, сурәтләнгән тормыш материалы, сәхифәләре белән бертөрле генә булмадылар. Чынбарлыкны эстетик тасвирлауда татар әдәбиятында борынгыдан килгән лиризм бу еллар прозасында үзенә аерым урын дәгъвалады.

Фәхри Әсгать, Мәхмүт Максуд каләме белән тудырылган нәсерләр — шуларның матур үрнәкләре. Мондый әсәрләр

---

[1] *Гонсыры* — халкы.
[2] *Тәгаен ителгән* — билгеләнгән.
[3] *Тарифгиранә* — артык.
[4] *Гамил* — сәбәп, нигез.

сугышның афәтен тагын да йөрәккә үткәзебрәк җиткерергә ярдәм иттеләр. М. Максудның «Елама, Рәшидә, елама!» нәсере (1920) сугышта үлгән батыр егетнең монологы рәвешендә язылган.

Ф. Әсгатьнең «Бәхет» нәсерендә дә (1923) шушы тема дәвам иттерелә. Аның лирик герое бәхет турында уйлана. Ләкин ызгышлы гаиләдә бәхет булмаган шикелле, бер үк илнең кешеләре кара-каршы сугышкан җирдә дә җан рәхәте, күңел тынычлыгы калмый. Гражданнар сугышы — сугышларның иң куркынычы, афәтлесе һәм мәгънәсезе. К. Нәҗминең «Шобага» (1926), «Яр буендагы учаклар» (1928), Ш. Усмановның «Ил кызы», «Краском мәхәббәте» (1923), А. Шамовның «Днепр буенда» (1927) әсәрләрен укып, шул фикергә килергә мөмкин.

Егерменче еллар уртасында илнең үз эчендәге кешеләр арасыннан дошман эзләү башланды. Моңа этәргечне В. Ленин үзе бирде. Ул болай дип язды: «Дошман — безне һава кебек чолгап алган һәм пролетариат сафларына көчле үтеп керә торган вак буржуаз стихия». Шуннан соң «буржуаз стихия» шулкадәр киң төшенчәгә әверелде ки, әз генә үзенчә уйлый торган кеше дә, дини йолаларга һәм хисләргә тугрылык саклаучы да, матур, җитешле яшәргә омтылучы да, эшен яратып, хуҗа булып башкаручы да буржуа калдыгы итеп каралды. Менә Газиз Гобәйдуллинның тирән мәгънәле «Эчке эмигрант» хикәясе (1929) герое Искәндәрне алыйк. Бу кеше социализмның гомере кыска булуына нык ышана. Ул, бик теләсә дә, инкыйлаб вакытында Төркиягә китә алмаган, Кавказ шәһәрләренең берсендә калырга мәҗбүр булган. Ләкин күңеле белән элеккеге идеалларына тугрылыклы. Искәндәр үзен эмигрант итеп саный, эмигрантның да чит мәмләкәткә киткәне түгел, бәлки ил эчендә калганы. Уйлап карасаң, бездә аның кебек эчке эмигрантларның исәбе-хисабы булмагандыр. Шушы вакытта «вөҗданны саф килеш саклап калу өчен», әлбәттә, көчле ихтыярлы булырга кирәк иде, халкыбыз бу сынауны да үтә алды.

Мөхәммәт Гали хикәяләре исә гади кешеләрнең күңел дөньяларын үтә эчкерсез, игелекле итеп сурәтләүләре белән аерылып торды. Аның геройлары әйтерсең лә тирә-якта бара торган хәл-әхвәлләрне бөтенләй күрмиләр дә, аларга илтифат та итмиләр. Көтүче Мөхәммәтҗан бабай һәм аның ярдәмчеләре Садыйк солдат малайларының («Көтүчеләр», 1923) авыл

малларына гаҗәп миһербанлы булулары, көн саен халыкка игелек кылулары бик якты итеп сурәтләнгән. Авыл һәм кала кешеләренең күңел дөньясындагы, яшәү рәвешендәге аерманы зур төгәллек белән күрсәтеп биргән «Мин дигәнчә булмады» хикәясе (1926), ат сатып алуга мөнәсәбәтле крестьяннарның холыкларын тасвирлаган «Базарчылар» әсәре (1929) лирик прозаның матур өлгесе булды.

Шул ук вакытта А. Шамов «Рәүфә» повестенда (1926) яңа җәмгыять шартларында хатын-кыз язмышы мәсьәләсен хәл итәргә омтылыш ясады. Әсәрдә ярлы кызы Рәүфә кебекләрнең яңа хакимият тарафыннан яклау табуы, шуның нәтиҗәсендә бәхеткә ирешүләре расланса да, гаилә җимерелү нәтиҗәсендә килгән мондый «бәхетнең» дәвамлы булмаячагы да көн кебек ачык иде.

Ш. Камал «Таң атканда» романында (1926) 1917 елгы Февраль демократик революциясеннән соң большевикларның хакимиятне үз кулларына алу өчен көрәшен тасвирласа, Г. Ибраһимов «Тирән тамырлар» әсәрендә (1926) авылда ясалма рәвештә алып барылган сыйнфый көрәшнең халык өчен китергән җәфаларын ачып күрсәтте. Бу әсәрләрдә каләм осталарына хас югары сәнгатьлелек белән иҗат ителгән сәхифәләр булса да, конфликтның ясалмалылыгы, эчтәлекнең сәяси вакыйгаларны аңлатуга иллюстрация рәвешендә корылган булуы әдипләрнең үзләре ирешкән казанышларыннан чигенүләре иде. Шулай да Г. Ибраһимов егерменче елларда иҗатының иң матур сәнгать җәүһәре булган «Казакъ кызы» романын (1923) бастырып чыгарды һәм әлеге әсәре белән үзен сүз сәнгатенең олы рәссамы итеп раслады.

Шулай итеп, егерменче елларда татар әдәбияты төрле иҗади эзләнүләр алып барды, чынбарлыкны сәнгатьчә сурәтли белүдә тәҗрибә җыйды, алдагы күтәрелешләре өчен көч туплады.

Сораулар һәм биремнәр

1. Егерменче еллар прозасы үсешендәге ике төрле юнәлешне билгеләгез.

2. Г. Рәхимнең «Идел» әсәренең төп герое авызыннан татар халкына карата әйтелгән «бәхетсез халыкның бәхетсез балалары» дигән фикерне ничек аңлыйсыз? Фикерегезне дәлилләгез.

3. 1921 елгы ачлыкны татар язучылары ничек бәяләделәр? Бу афәтнең чын сәбәпләре турында Ф. Әмирхан нәрсәләр яза?

4. Ф. Әмирханның инкыйлабтан соңгы хәлләргә мөнәсәбәте «Шәфигулла агай» әсәрендә ничек чагыла?

5. Прозада нәсер иҗат иткән язучыларны һәм аларның әсәрләрен исегезгә төшерегез. Нәсер белән лирик шигырь арасында уртак һәм аермалы якларны әйтегез.

6. Гражданнар сугышы темасына язган каләм әһелләре һәм аларның әсәрләре турында сөйләгез. К. Нәҗми һәм Ш. Усмановның әсәрләрен табып укыгыз. К. Нәҗми әсәрләренең романтик рухта булуы нәрсәләрдә күренә? Ш. Усманов геройларындагы инкыйлаби аскетизм (үзеңне чикләү) билгеләрен күзәтегез.

7. Г. Гобәйдуллин һәм М. Галинең прозаик буларак үзенчәлекләрен сезниләрдә күрәсез?

8. Ни өчен Ш. Камал, Г. Ибраһимов кебек сүз сәнгате осталары «Таң атканда», «Тирән тамырлар» әсәрләрендә яңа чынбарлыкны сурәтләүдә кыенлык кичерәләр?

9. «Егерменче еллар татар әдәбиятында минем яраткан язучым һәм әсәрем» дигән темага инша языгыз.

Фатих Әмирхан

«Шәфигулла агай»
(1925)

Фатих Әмирхан — оста сатирик. Аның бу таланты Октябрь борылышына кадәр үк ачыла. «Габделбасыйр гыйшкы», «Салихҗан карый», «Сәмигулла абзый» хикәяләрендәге, ниһаять, «Фәтхулла хәзрәт» повестендагы персонажлар XX гасыр башы татар әдәбиятындагы иң калку сатирик типлардан саналалар. Язучы сатирага 1917 елгы инкыйлаблардан соң да мөрәҗәгать итә.

Бушбугаз «каһарманнар»

Туган халкының милли һәм иҗтимагый азатлыгы өчен җан атып яшәгән Ф. Әмирхан инкыйлабларга артык мөкиббән китмәгән. Дөрес, сыйнфый бәрелешләр Россия империясендә изелеп яшәүче төрле халыкларга, шул җөмләдән үз халкына да җиңеллек китермәсме дигән өмет яши аңарда. Ләкин инкыйлабларның, нигездә, көч куллану һәм кан коюлар белән барачагын да аңлый ул. Мондый кискен борылышлар кешеләрдә рухи сыкранулар гына тудырмасмы, аларга җәфалар гына китермәсме?!

Илдә Февраль инкыйлабы була, патша үз тәхетеннән ваз кичәргә мәҗбүр ителә, монархия җимерелә. Халык беркадәр иркен сулый башлый, гадел җәмгыять тәртипләре урнашуга өмет уяна, демократия беренче адымнарын атлый. Ләкин мондый болганышларда бер төр кешеләрнең хискә чумып үсенеп китәчәкләрен, андыйларның башкаларга һәм, гомумән, җәмгыятькә дә зарар салачагын тиз күреп ала әдип. Озакламый нәкъ шундый «геройлар» Ф. Әмирхан әсәрләрендә дә күренә башлый. Аларның чын йөзләре ачыла, ни өчен зарарлы булулары күрсәтелә.

Әдәбиятыбыз өчен өр-яңа булган мондый типларны әдип беренче тапкыр «Март каһарманы» дигән әсәрендә сурәтли. Ул — Гыйсмәтулла исемле, Февраль инкыйлабы булу белән, үзен «социалист» саный башлаган «төче кеше». Гыйсмәтулла хәзер инде йокысыннан да «җаным, бәгърем, рабучий туганым» дип уяна. Гәрчә вакыйгаларга бернинди катнашы булмаса да, «без, революционерлар, җанымыз-канымызны фида итеп, халыкка хөррият алып бирдек» дип күкрәк кага. Бер-

ничә яңа сүз ятлаган бу шарлатан митингларда туктаусыз чыгыш ясый, нәрсә сөйләгәнен үзе дә юньләп белештермичә, эшче-крестьянга өстенлекләр таләп итә. Чамасын белми, мәгънәсезлеген аңламый. Менә крестьянга нәрсәләр таләп итә ул:

«Ә крәстиян туганнарым, былбылларыма һәр кеше башына йөзәр дисәтинә җир бирелсен, урманы, суы шунда булсын, торырына һәр семья башына бер зур таш пулат салып бирелсен, бишәр баш ат, алтышар баш сыер, кырыгар баш сарык, йөзәр баш каз, икешәр йөз баш тавык бирелсен. Хатын-кызлары өчен һәйбәт асыл күлмәкләр булсын, тагар өчен һәрберсенә борчак зурлыгы бриллиант кашлы брошка, бөтен бармаклары саен алтын йөзек булсын, җирләрен эшләр өчен, һәр крәстиян туганга бишәр хезмәтче бирелсен. Аларга айлык вазифаны хәзинә түләсен, крәстиянкә туганнарның балаларын карар өчен азында берәр нянька, ашларын пешерер өчен повар, өйләрен матурлап тотар өчен, азында берәр асрау кыз бирелсен» һ. б.

Ә мондый өстенлекләр кем һәм нәрсә хисабына булачак? Болар турында ул уйламый, күрәсең, уйлый да белми. Аның таләпләре буенча эш йөрткәндә, крестьяннарның бик азы гына кичәге аристократ катлау дәрәҗәсенә күтәрелеп, җәмгыятьнең күпчелеге аларга хезмәт итәчәк була түгелме соң?!

Февраль революциясе китергән кайбер уңай үзгәрешләр янәшәсендә Гыйсмәтулла кебекләр «тырышлыгы» белән барлыкка килгән мәгънәсезлекләрне автор оста күрсәтеп бирә. Мәсәлән, Гыйсмәтулла тиз арада «Кәләпүш типчүче хатыннар мәркәз бюросы», «Тегәрҗеп урамы мөселман демократиясе оешмасы», «Бөтен Русия читек башы сабучылары берлеге», «Кучер һәм дворниклар союзы» кебек оешмаларның я рәисе, я рәис урынбасары булып ала, һәрберсеннән аңа акча килеп тора. Мондый оешмаларның җәмгыять өчен файдасызлыгын аларның исемнәреннән үк күрәсең. Алар бары тик Гыйсмәтулла кебек бушбугаз һәм демагог ялкауларга гына кирәк. Монда Ф. Әмирханның каләме үткер. Мәсәлән, «Базар көннәрендә йөктән чәчелеп калган печәнне җыючы мөселман малайлары мәркәз бюросы» дигән оешманың атамасында ук күпме ачы көлү, сарказм бар.

1917 елгы инкыйлаблардан соң барлыкка килгән мондый әрәмтамакларны башка язучылар да каләм очына «эләләр». Мисалга егерменче еллар татар әдәбиятының иң күренекле сатирикларыннан берсе — Кәрим Тинчуринның 1918 елда

язылган «Йосыф—Зөләйха» сатирик комедиясен китерергә мөмкин. Кулыннан бер эш тә килми торган ач-ялангач егет, эшсез һәм эшкә яраксыз Сәфәргали тормышын җайга салу өчен, бай карчыкка өйләнә. Менә шушы әрәмтамак, инкыйлаб булу белән, бик тиз әүвәлге кыяфәтен алыштыра. Үзен ачлыктан коткарган, 8 ел ашатып-эчертеп торткан хатынына ул «буржуй» дип кенә җибәрә, «җитәр, канымны күп эчтең» ди, «Алга, алга, алга!» җырын ятлап ала, «иске дөнья, яңа дөнья» дип акыл сата.

Ф. Әмирханның «Март каһарманы» хикәясе 1917 елның августында, ягъни Февраль инкыйлабыннан соң 5 ай узгач язылган, «Аң» журналының сентябрь ае санында басылып чыккан. Исеме астына «вакыйгага пародия» дип куелган. Димәк, көлке тудыру максаты белән автор хәлне күрәләтә бозып, арттырып сурәтләгән. Ә инде 1918 елда әсәрне кабат бастырганда, Ф. Әмирхан хикәя исеменә аңлатманы тулыландыра: «Язылган вакытта шарж иде, октябрь ахырында фактка әйләнде»,— дип куя. Димәк, Февраль көннәрендә борын төртеп чыккан, күренә генә башлаган кимчелекләр, Октябрь инкыйлабыннан соң киң таралып, системага әверелгәннәр. Канкоюлы революцион чынбарлыкның бу көлкеле дә, кызганыч та, аяныч та сыйфатлары алга таба формалашып җитә. Ф. Әмирхан «Шәфигулла агай» повестенда менә шуларны, тулыландырып, сәнгатьчә оста чагылдыра.

Кем ул Шәфигулла агай?

Аны Гыйсмәтуллаларның бер төре дияргә дә мөмкин. Ләкин Шәфигулла,— инкыйлаблар тудырган шәхесләрнең чагылышы буларак, әдәби яктан эрерәк тип. Ул — чор күренешләрен үзенә тагын да тулырак туплаган образ. Икенче төрле әйткәндә, Гыйсмәтулла инкыйлаби яшәештәге чүп-чарны гәүдәләндерүдә эскиз гына булса, Шәфигулла инде — яңа җәмгыять төзү елларының тулы бер сурәте.

Ә шәхес буларак нинди кеше соң ул Шәфигулла агай? Ул — бер фабрика эшчесе, авылдан килеп, моңарчы хатыны, өч-дүрт баласы белән тыныч кына яшәп яткан бер адәм. Беркатлы, белем ягы бик таман, төче холыклы, һәрнәрсәгә тиз ышанучан. Нәкъ Гыйсмәтулла кебек үк, Шәфигулла да инкыйлаб шигарьләренә табына. Һәртөрле яңа-ят сүз һәм гыйбарәләрне яратып кабул итә һәм сөйләмендә кабатлый.

Үзен «сознательный»га санап, хатынын да, балаларын да «агартырга» тырыша. «Искелеккә», кечәге тормышка каршы көрәштә һәрчак алдынгы булырга, «эшче-крәстиәнгә пример» күрсәтергә омтылып яши.

Ләкин бу ике кеше арасында зур аерма бар. Гыйсмәтулла һәрнәрсәдән иң әүвәл үзе өчен файда эзли. Бу яктан Шәфигулла шактый ук эчкерсез. Ул, нәрсәне дә булса эшләгәндә, үзенә җиңеллек тә, файда да өмет итми. Хәер, аның бердәнбер, ләкин бик көчле теләк-максаты бар, Шәфигулла агай бернигә карамый, шуңа омтыла. Ул — һәр җирдә һәм һәр эштә, үзе әйтмешли, «эшче-крәстиәнгә пример» була. Монда аны тыеп тора алмыйсың: ул кулыннан һәм көченнән килгәннең һәммәсен эшләргә әзер. Шуңа омтылып, һәрнәрсәне ихластан башкара.

Ә Гыйсмәтулла турында алай әйтеп булмый.

Шәфигулланың әлеге сыйфатлары фанатиклыгы яссылыгында бөтенләй башка төс ала. Аның төп бәласе шунда: фабриканың партия һәм профсоюз җитәкчеләре нәрсә генә әйтсәләр дә, ул барысына ышана. Нинди генә «яңалык» кузгалса да, кирәкме ул, юкмы, файдалымы, түгелме, ул башлап йөрергә әзер. Монда аның беркатлылыгы алдан йөри, сай акылы йөгерек эшли. Җае да чыгып кына тора бит. Иске гореф-гадәтләргә сугыш игълан ителү белән, Шәфигулла ничәмә еллар түрдә эленеп торган шәмаилне[1] фабрика ишегалдында җиргә салып таптый. «Яңача быт төзергә» дигән фәрман булу белән (ә бу җәмгыятьтә бар нәрсә югарыдан күрсәтү, фәрман нигезендә эшләнә!), ул 20 ел бергә яшәгән никахлы хатынын талак кыла, аның белән «советча язылышып» тора башлый. Муллалар кушкан исеменнән коткарам, яңага алыштырам дип, кече малае Вәлиулланы бөтен кеше алдына алып чыга. («Вәлиулла» исеме «Алла» исеме кушып ясалган бит!) Исем алыштыру вакыйгасы тәмам әкәмәткә әйләнә, монда язучының сатирик каләменә сокланмый мөмкин түгел.

...Үтә дә мөһим эш майтаралармыни?! Зурдан кубып, эшчеләрне җыеп, фабрика җитәкчеләре Вәлиуллага яңача исем кушу кичәсе оештыралар. Профком рәисе Рәхимовның: «Бу сознательный семья балаларын Владимир Ильич кушкан юл белән алып барырга һәм РКПның корыч сафларына тагы бер сознательный эшче тәрбияләп үстерергә сүз бирә»,— дигән

---

[1] *Шәмаил* — рам эченә язып куелган дини эчтәлектәге текст.

кереш сүзләреннән соң балага яңа исем сайлау башлана. Ниләр генә тәкъдим ителми! Шулай да тар идеология белән агулана башлаган кешеләрнең фантазиясе бер тирәдә әйләнә: я берәр юлбашчының исем-фамилиясен кирегә укып исем ясау (Ленин — Нинел, Калинин — Нинилак, Троцкий — Икстурт), яки футуристларның мәгънәсез гыйбарәләрен исем итү. Хәтта эш коралларыннан исем ясау кебек тәкъдимнәр була: Кызыл чүкеч, Кызыл өргеч, Пар казаны һ. б. Ахырда партия ячейкасы сәркатибе Михайловның бик акыллы кыяфәттә (әсәрдә әйтелгәнчә, «вәкарь белән»!) тәкъдим иткән исемгә тукталалар: «Владимир булсын, һәрбер коммунистка һәммә нәрсәдән кадерле булган исемне үз өстендә йөртсен!» Фабком рәисе бу тәкъдимнең мәгънәсен тагын да «тирәнәйтә»: «Чынлап та, татар баласына әүвәл мәртәбә кушыла торган бу исем һәр сәгатьтә, һәр минутта кадерле юлбашчыбызны искә төшереп тору белән бергә, бөтен дөнья сознательный татар эшчеләренең инде милли шавинизм һәм дин дурманнарыннан бөтенләйгә котылган икәнлекләрен күрсәтеп торачактыр... Бу эш бөтен татар эшчеләренә коммунистлык үрнәге булыр...»

Арттырылган сурәтләрдә — чынбарлык

Мондый мәгънәсезлекләр «яңа тормыш»ның башка өлкәләрендә дә урын ала бара. Әсәрдә аларның берничәсе чагылыш таба. Мәсәлән, кирәксә-кирәкмәсә, сәбәпле-сәбәпсез, төрле сәяси вакыйгалар уңае белән, аерым низагларга бәйле төстә, митинглар яки демонстрацияләр уздыру. «Сознательный» булуны үзенчә аңлап эш йөрткән, таман акыллы Шәфигулла стенасыннан алган шәмаилне, һичшиксез, фабрика ишегалдына күтәреп килә, партоешма сәркатибе һәм фабком рәисе, зурдан кубып, митинг оештыралар. Ерак Польшада бер комсомол үтерелгәч, шәһәр күләмендә демонстрация оештырыла. Шунда бит инде Шәфигулла агай төне буе демонстрантларга ияреп йөри, балаларын да азаплап бетерә, кече улына салкын тиюгә һәм аның үлеменә төп сәбәпче була.

Автор Беренче май уңае белән оештырылган демонстрацияне җентекләбрәк сурәтли. Шуның белән яңа җәмгыятьне идеологияләштерүнең никадәр көчле булуы тасвирлана. Бәйрәм барышында «Беренче майның фазыйләтләрен[1]» 12 докладчы сөйли. Ә аларда, нигездә, бер үк сүз! Моны түбәндәге

[1] *Фазыйләт* — өстенлек.

өзектән дә аңларга була: «Шәфигулла агай революция башыннан бирле Беренче май көненең фазыйләтләрен бик күп мәртәбәләр ишетеп, теләсә кай җирдә үзе сөйләрлек дәрәҗәдә күңелдән белсә дә, хатибларның[1] сүзләрен бик ихлас һәм дикъкать белән тыңлап торды: «...Бөтен эшче-крәстиән өчен изге сүзләр, мин сиңа әйтим... Бу сүзләрне мең кат ишеткән булсаң, мең дә беренчесендә тагы да ихлас белән рәк тыңларга кирәк, мин сиңа әйтим...»

Яңа идеологияне «пролетар идеология» дип тә, «социалистик» яки «коммунистик идеология» дип тә атыйлар, «совет идеологиясе» дип әйтү дә бар. Ул Совет җәмгыятендә әйдәүче идеологиягә әверелде. Һәрнәрсәне сыйнфый көрәш ноктасыннан торып бәяләү карашы барлыкка килде. Мәсәлән, гасырлар буена формалашкан һәм халыкның көндәлек яшәү рәвешенә әверелгән гореф-гадәтләргә каршы көрәш ачу да әсәрдә үтемле төстә тасвирлана. Яңа идеология иң әүвәл, гореф-гадәтләребезнең нигезендә яткан ислам дине кагыйдә-тәртипләренә һөҗүм башлады. Шәмаилләр белән сугышудан башланган эш-гамәлләр һәртөрле дини йолаларны кире кагу, үткәннәрдәге гореф-гадәтләрне мыскыл итү, хәтта ата-ана рухын мәсхәрәләү кебек ямьсез кыяфәтләр ала. Шәфигулла агайның Мөхиб әбигә сөйләгәннәрен мисалга китерик: «...Һи Мөхиб абыстай, уйласаң җыларсың; бәхетсез дә заманнарда, нисазнательни ата-ана кулларында бәхетсез җаннар булып кына үскәнбез лә: безнең яшь заманнарда бу эшләрнең исе дә булмады бит... Менә бу кызыл арысланнар хәзер, мин сиңа әйтим, сәвит бәйрәмнәрен бәйрәм итеп, изге диманстратсияләргә чыгып, бөтен буржуаларның, мин сиңа әйтим, котларын очырып, йөз аклыгы белән, мәңге бәхетле үсәләр... Уйлап-уйлап торам да исләрем китә: безнең әти бичараны беләсең инде син... Үлгән кешене сүксәң яхшы түгел, ә сүкмәсәң, мин сиңа әйтим, үзеңә авыр... Ул дурак карт самый настаяшши нисазнательни дурман иде бит: карт көнендә котырынып, ишанга кул биреп, әллә нинди дурманлы догалар укып зикер әйтәм[2] дип, әллә нинди әкәмәтләр эшләп, зикер мәҗлесенә барам дип, бәйрәм кичләрендә ишан авылына барып йөреп, эшен калдырып, бөтен хуҗалыгымызны эштән чыгарып йөрде... Безне, балаларны, шунда ишан янына алып

---

[1] *Хатиб* — оратор.

[2] *Зикер әйтү* — искә алу.

барып, аннан өшкертеп, аннан... догалыкларын күңелдән ятлатып укытып, адәм хуры итеп йөртә иде, бичара... Атабыз бичараның партәйни булмавы аркасында, адәм хуры булып йөргәнмез икән...»

Совет системасында беренче планга коллективчылык куелды, ягъни һәр эш-гамәл, һәр уй-фикер күмәкчелек ноктасыннан торып бәяләнде, коллектив, барыннан да элек, пролетариат һәм ярлы крестьян катлавы дип каралды. Бу системада аерым шәхеснең үз тормышына, теләк-омтылышларына, үз мәнфәгатьләренә урын калмады. Җәмгыять корылышында аерым кешегә «шөрепчек» вазифасы гына бүлеп бирелде. Әсәрдә әнә Вәлиуллага яңа исем кушканда да шуның чаткысы күренеп кала. «Нинел», ягъни Ленин фамилиясен киргә укудан туган исем кушарга дигән тәкъдим булгач, берәүләр әйтә куя: «Ул исем бик күбәйде инде. Безнең ячәйкәдә генә 43 балага шундый исем кушылды, балалар үзара бик саташтырылырлар». Моңа үзен Колынбайский дип атап йөртә торган «коммунистически университет шәкерте» болай дип каршы чыга: «Саташтырылсалар, бигрәк яхшы. Коммунистически обществода берәм-берәм личностьләргә игътибар булырга тиеш түгел. Личность булмый, коллектив кына була». Усал һәм үткер Ф. Әмирханның каләме! Теләсә нинди җәмгыятьнең нигезен шәхес тәшкил иткәнен, иң беренче чиратта аерым кеше мәнфәгатьләре алгы планда торырга тиешлеген, яңа җәмгыятьтә бу яктан хата фикер хөкем сөрә башлаганын ул бик дөрес тотып алган.

Әсәр исеме астына «Дустанә шарж» дип куелган. Шарж — французча «арттыру» дигән сүз. Сәнгать әсәрләренә (рәсемгә, скульптурага, әдәби әсәргә) карата ул кемне яки нәрсәне дә булса бер охшашлыгы нигезендә шаяртып яки ачы көлеп, арттырып сурәтләү өчен кулланыла. Еш кына бу арттыру карикатура төсен ала.

Әлеге әсәрдә дә шулай. Ул бигрәк тә Шәфигулла образы белән бәйле төстә оста кулланыла. Аңлашыла да, чөнки ул — үзәк персонаж. Шәфигулла агай үзенчәлекле. Ул, әйтелгәнчә, бик беркатлы, шактый надан, шактый үзсүзле, һәр җирдә һәм һәр эштә беренче һәм үрнәк булырга омтыла.

Шәфигулла характерында арттыру бик кечкенәдән башлап эре гомумиләштерелүләргә кадәр җиткерелә. Әнә ул һәрдаим төчеләнә: тавышында төчелек, елмаюында төчелек, каравы төче, сүзләре төче, көлүе төче. Менә ул малаеның исемен

алыштырырга әзерләнә: эштән зур кызыл әләм алып кайта, Вәлиулланы шуңа төреп клубка алып бара. Исем кушу күренеше гел сатирик арттырулардан тора. Башта фабком рәисе озын нотык сөйли. Аннары, күмәкләшеп, «Интернационал» җырлыйлар, бер генә дә түгел, Шәфигулла агайның үтенече буенча тагын ике тапкыр, котлаулар вакытында тагын да берничә кат җырлыйлар. «Исем кушылгач, Владимир исеме кушуның «кызыл тормыш» өчен ярдәмен тәфсилләп сөйләделәр,— дип дәвам итә автор.— Берәү, чыгып, Вәлиулла-Владимирның пионерлар сафына кабул ителгәнен сөйләп, аңар пионерлык билеты бирде... Баланың өстенә ячәйкәнең кызыл әләмен бөкрәйтеп тоттылар...» Әйе, әле теле дә ачылмаган балага — пионерлык билеты!

«Интернационал» мәсьәләсендә Шәфигулла агай, гомумән, мөкиббәнлек күрсәтә. Инде йоклаган балаларын уятып җырлату дисеңме, иртән йокыдан торуга һәм кичен йоклар алдыннан, «үзем өйдә юк көннәрдә җырланмый кала торганнар өчен булыр» дип, икешәр мәртәбә җырлату дисеңме...

Яки менә Шәфигулла агай Ленин каберен зиярәт кылырга җыена. Аның өеннән чыгып киткәндәге саубуллашу сүзләре аңында һәм дөньяга карашында иске һәм яңа төшенчәләрнең аралашып килүенә ачык бер мисал: «...Ерак сәфәрләргә китәм инде... Атагыз изге җирләрдә, изге туфракларда була инде... Владимир Илич каберләре өстендә мин сезнең өчен дип атап та «Күмү маршы» җырлармын... йөземне кабер туфракларына сурермен... Аның кабереннән изге чишмә чыкмыйча калмагандыр әле, сезгә, боерган булса, шул изге чишмәләрдән су да алып кайтырмын... Изге илләрдә үлә-нитә калсам, хәтерегездән чыгармагыз... Әледән-әле «Күмү маршы» җырлап, миңа багышлый торган булыгыз... Аналары! Син күз-колак бул, балалар көндәлек интернатсианалларын җырлый барырга онытмасыннар!..» һ. б.

Автор Шәфигулла кебекләр табына торган җәмгыятьнең һәм яңа мохитнең дә кайбер үзенчәлекләрен каһкаһәләп көлү дәрәҗәсенә җиткереп сурәтли. Монда, мәсәлән, аерым авторитетларга табыну җәмгыятьнең иң югары баскычыннан алып түбәнгә кадәр сугарылган. Барысы өчен дә Ленин, Калинин, Троцкий кебек җитәкчеләр — зур абруй. Үз чиратында партком сәркатибе Михайлов һәм профсоюз оешмасы рәисе Рәхимов сүзләре һәм күрсәтмәләре — күпләр өчен бәхәссез хакыйкать. Алар ни әйтсә дә, шуңа ышана Шәфигулла ке-

бекләр. Кыскасы, бу яңа җәмгыятьтә авторитар система формалаша. Бу системада пропагандага бик нык әһәмият бирелә. Ул кайвакыт мәгънәсезлек чигенә җиткерелә.

Шушы чорда, хакимиятнең яклавы белән, рәсми төс алып, урыслашу да башлана. Менә Шәфигулла турындагы газета материалыннан бер өзек: «Массадагы сознаниянең артуы удивительни бер темп белән бара: почти 60 яшенә достигать иткән татарин рабочи Шәфигулла эле недавно гына партияга записаться иткән булса да, религиозный дурманнарны к чёрту җибәреп, полный сознательность проявить итте: катынының бисмиллалы бумагасын кусокларга рвать итеп, рабочи публика арасына алып килеп таптады; новорождённый ребёнкысына Владимир куштырды» һ. б.

Совет вакытлы матбугатының тел-стиленнән көлү монда югары дәрәҗәдә.

Кыскасы, Ф. Әмирханның бу әсәре, дустанә шарж итеп язылса да, чынында совет шартларында тамыр җәя башлаган, урыны белән инде ныгып урнашкан кимчелекләрне аяусыз үткерлек белән тасвирлаган ачы сатира булып чыккан. Ул яңа җәмгыять шартларында шәхеснең тизлек белән рухи бөлгенлеккә төшә баруын, идеологик кысаларның кешене ничек итеп гади бер шөрепкә әйләндерүен, миңгерәүләтүен сәнгатьчә югары дәрәҗәдә сурәтли. Бу повесть совет әдәбияты тарихында иң көчле сатирик әсәрләрдән санала.

Сораулар һәм биремнәр

1. Повесть ни өчен үз вакытында басылмаган, басыла алмаган? Сәбәпләрен аңлатыгыз.

2. Шәфигулла агайны характерлагыз. Аның холкындагы кайсы яклар сезгә ошый, кайсылары тәнкыйтькә мохтаҗ?

3. Шәфигулланың якыннары турында ниләр әйтеп була?

4. Шәфигулла агай кебекләр «искелек калдыгы» дип караган, аларга каршы көрәшкән гадәт-йолаларны күрсәтегез, аларга үз мөнәсәбәтегезне сөйләгез.

5. «Арттырылган сурәтләрдә — чынбарлык» дигән сүзләрне сез ничек аңлыйсыз, үз сүзләрегез белән аңлатыгыз.

6. Әсәрдән ачы көлүгә караган мисаллар табыгыз. Көлүнең Совет җәмгыяте шартларына караганнарын аерып күрсәтегез.

7. «Шәфигулла агай — әдәбиятыбыздагы иң калку сатирик типлардан берсе» дигән темага инша әзерләгез (яки сыйныфта языгыз).

Кәрим Тинчурин
(1887—1938)

Заһидә Тинчуринаның истәлекләрендә шундый бер хатирә бар. Ул ире Кәрим Тинчуринның борчылган, нәрсәгә дә булса рәнҗегән, кәефсезләнгән вакытларында дәшми генә ишеклетүрле йөрү гадәте барын яза. Озак йөри, дип исенә төшерә ул, аннары миңа да дәшә: «Әйдә, бергәләп йөрик әле!» — ди, һәм без икәүләп тын гына йөри башлыйбыз...

Менә шушы истәлектән гаҗәеп үзенчәлекле, көтмәгәнуйламаган карарга килергә сәләтле кеше күз алдына килеп баса. Аның әсәрләрендәге үзенчәлекләрне дә аңлый-төшенә башлыйсың.

Сикәлтәле тормыш юлының башы

Кәрим Гали улы Тинчурин 1887 елның 15 сентябрендә хәзерге Пенза өлкәсенең Аккүл авылында ишле крестьян гаиләсендә туа. Күрше авыл мәдрәсәсендә башлангыч белем алганнан соң, ул 1900 елда Казанга юл тота.

13 яшьлек малай Казанда эш таба алмыйча шактый вакытлар тилмереп йөри. Ниһаять, бер ашханәгә савыт-саба юучы булып урнаша. Әмма аның зур теләге — шәкерт булу. Малай армый-талмый шул олы максатына омтыла. Бернинди эштән дә тайчанмыйча, көзгә хәтле эшли, әз-мәз акча юнәтә, атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. Монда ул 6 ел белем ала, мәдрәсәдәге фәннәр белән генә канәгатьләнмичә, тырышып үзлегеннән дә укый.

1905 елгы инкыйлаб дулкыннары татар мәдрәсәләренең дә ишеген шакый. Шәкертләр арасында яңалыкка омтылу

көчәя. Кайберәүләр алдынгы карашлы студентлар белән аралаша башлый. Андыйлар арасында Кәрим дә була. Мәдрәсәгә реформа таләп итеп, дәгъва башлаган 87 шәкерт белән бергә аны да 1906 елның февралендә укудан чыгаралар. Моннан соң К. Тинчурин төрле эшләрдә эшли: урман каравылчысы була, балалар укыта, язу эшендә көчен сынап карый. Нәтиҗәдә 1906 елда беренче әсәре булган «Моназарә» («Бәхәс») комедиясен иҗат итә. Шулай итеп, К. Тинчуринның әдәби иҗаты халыкта иҗтимагый, сәяси һәм милли азатлыкка омтылыш уянган чорда башланып китә.

Бу чорда татар сәхнә сәнгате дә барлыкка килә һәм ныгый башлый. Сәхнә дә, тормышның башка өлкәләре кебек үк, фикерләр көрәше мәйданына әверелә. Халыкка хезмәт итүне үзенең максаты иткән кайбер фидакяр зыялылар театр труппаларына берләшә башлыйлар, кара көчләргә каршы көрәш игълан итеп, хезмәт иясенең демократик хокукларын, гуманизм идеалларын яклап чыгалар.

Бу хәрәкәткә К. Тинчурин да кушыла, иҗат сәләтен театр эшенә багышлый. 1910 елда ул Габдулла Кариев җитәкчелегендәге «Сәйяр» труппасына килеп керә. Кыска гына вакыт эчендә үзен сәләтле артист итеп таныта, күп кенә спектакльләрдә төп каһарман булып уйный. Тәнкыйтьчеләр яшь актёрның киләчәге бик өметле булуын күрәләр.

Күпьяклы иҗат

Үзе уйнау белән бергә, К. Тинчурин труппаның репертуарын баетуга да күп көч куя, бер-бер артлы пьесалар яза. «Хәләл кәсеп» (1910), «Шомлы адым» (1912), «Беренче чәчәкләр» (1913), «Соңгы сәлам» (1917) исемле драмалары, «Назлы кияү» һәм «Җилкуарлар» (1916) дигән комедияләре татар драматургиясенә өметле яңа иҗатчы килүен күрсәтәләр.

К. Тинчурин тормышны тирәнтен белергә һәм әсәрләрендә халыкның уй-теләкләрен, өмет-хыялларын чагылдырырга тырыша. Аның «Беренче чәчәкләр» драмасы аеруча игътибарга лаек. Монда ул 1905—1907 еллардагы инкыйлаб дулкыннары белән хәрәкәткә килгән яшьләрне чәчәкләргә тиңли. Яктылыкка омтылган яшьләрнең беренче адымнары кара көчләрнең каршылыгына очрый, кайберәүләр, кыраудан шиңгән гөлләр кебек, реакция елларында башын сала.

Шундый фаҗигаләрнең җанлы шаһиты булган һәм халыкка хезмәт итү уе белән янып яшәгән язучы 1917 елгы

инкыйлабларны рухланып каршылый. Татар халкы өчен, милли мәдәният язмышы өчен аларның файдасы зур булуына өметләнә яшь драматург. Октябрь борылышыннан соң ул яңа театр оештыру эшендә актив катнаша. 1918 елның көзендә, Казан чехлардан азат ителгәч, «Сәйяр» труппасына җитәкче итеп билгеләнә. Бу коллектив инкыйлабның беренче көннәрендә үк үзен яңалык тарафдары итеп таныта, пролетариат язучыларының әсәрләрен халыкка күрсәтә башлый, шул исәптән М. Горький, Г. Исхакый, Г. Коләхмәтов пьесаларын һәм башка инкыйлаби эчтәлекле әсәрләрне сәхнәгә куя.

Театрда эшләүдән тыш, К. Тинчурин «Эш» исемле беренче татар газетасын чыгаруда да катнаша. Ул биредә күренекле драматург Г. Камал белән бергә эшли. Бу чорда тәҗрибәле журналист кадрларга ихтыяҗ зур була, К. Тинчурин үзенең белемен дә, осталыгын да кызганмый, яңа тормыш төзүчеләр сафында җиң сызганып хезмәт итә.

Гражданнар сугышы елларында мәдәният эшенә, театрларга милли кадрлар әзерләүгә билгеле бер дәрәҗәдә игътибар көчәеп ала. 1919 елның язына таба, Колчак Идел буйларына якынлашканда, кызыл гаскәрләргә спектакльләр күрсәтү өчен, артистлар труппалары төзелә. Кызыл Армиянең сәяси идарәсе карамагындагы Уникенче труппаның баш режиссёры итеп К. Тинчурин билгеләнә. 1920 елда ул Самара шәһәрендә ачылган театр студиясендә укытучы һәм баш режиссёр хезмәтен дә башкара. Бу студиядә соңыннан драматург булып танылган Таҗи Гыйззәт, күренекле артист Хөсәен Уразиков эшли. 1921 елда К. Тинчурин Оренбург шәһәрендә оешкан Г. Кариев исемендәге труппага җитәкчелек итә. 1922 елда Ташкентта Үзбәкстан Мәгариф комиссариаты карамагындагы гыйльми советның театр бүлегендә эшли. Аннары ул Казанга кайта. Гражданнар сугышы тынып, халык хуҗалыгын аякка бастыру эше башлангач, аерым труппаларны бер дәүләт театры итеп оештыру мәсьәләсе алга килеп баса. Бу җаваплы эш К. Тинчуринга тапшырыла. 1922 елның 8 ноябрендә хәзерге Яшь тамашачылар театры бинасында ачылган Татар дәүләт театрының баш режиссёры итеп К. Тинчурин билгеләнә. 1928—1929 еллардагы театр сезонында ул Татар дәүләт академия театрының бер төркем артистлары белән Әстерханга күченеп килә, анда татар театрында баш режиссёр булып эшли, берничә оригиналь спектакль куя. Үзенең яңа

язылган «Ил» музыкаль драмасын да ул башта шушында сәхнәләштерә. Спектакль зур уңыш казана.

Театр өлкәсендә актив эшләү белән бергә, К. Тинчурин әдәби иҗатын да даими көчәйтә бара. Ул бигрәк тә комедия жанрында уңышлы эшли. «Йосыф белән Зөләйха», «Сакла, шартламасын!», «Тутый кош» (1918), «Американ» (1924), «Җилкәнсезләр» (1926) әсәрләрен иҗат итә. Болар белән ул үзен зур комедия остасы итеп таныта, сатирик комедия юнәлешен яңа баскычка күтәрә.

Аның драмаларына да яңалык хас. Аларда психологик яктан төгәл эшләнгән персонажлар тасвирлана. М. Фәйзи һәм Ф. Бурнаш әсәрләре белән башланып киткән музыкаль драма жанрын К. Тинчурин алга таба үстерә.

«Зәңгәр шәл» (1926), «Ил» (1927), «Кандыр буе» (1931) драмаларында, «Алар өчәү иде» (1935) комедиясендә бу бигрәк тә ачык күренә. Идея эчтәлеге һәм сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан уңышлы иҗат ителгән әлеге әсәрләр К. Тинчуринның драматург буларак йөзен, иҗат үзенчәлекләрен билгелиләр.

Аның пьесаларын дусты Салих Сәйдәшевнең сокландыргыч музыкасы тагын да җанландыра, сәнгатьлелеген баета һәм тамашачыны җәлеп итә. К. Тинчурин белән С. Сәйдәшев кебек ике зур талантның бердәм иҗаты нәтиҗәсендә «Зәңгәр шәл», «Ил», «Кандыр буе» шикелле әсәрләргә язылган җырлар — татар музыкасының җәүһәрләре туа. Алар һаман да халык күңелендә яши.

К. Тинчурин матур тавышлы оста җырчы була. Ул, тыңлаучыларның йөрәкләренә үтеп керерлек көйләр тудыру өчен, композиторларга илһам бирә, яңа музыкаль әсәрләрне еш кына беренче булып үзе башкара.

Бу күпьяклы талант иясе мәдәниятебез тарихында үзенчәлекле режиссёр буларак та билгеле. Пьесаларын ул үзе сәхнәгә куя, аларда үзе дә уйный, әсәрләренең фикерен тамашачылар күңеленә бөтен тулылыгы белән, тәэсирле итеп җиткерә белә. К. Тинчурин сәләтле актёр булып танылa. Аның сәхнә образлары, ышандыру көченең табигый булуы белән, тамашачы күңелендә тирән эз калдыра.

К. Тинчурин оста педагог та була: күп кенә яшь драматургларның беренче әсәрләрен сәхнәгә куя. Алар арасында Таҗи Гыйззәт, Кәрим Әмири, Гадел Кутуй, Габдрахман Минский,

Риза Ишморат, Мирсәй Әмир һ. б. бар. Татар артистларының бөтен бер буыны аның җитәкчелегендә иҗат мәктәбе үтте.

Аның талантының тагын да бер бизәге — ул бик әйбәт хикәяче дә. Авторның «Мәрҗәннәр» исемле повесте һәм хикәяләре иң яхшы әсәрләр рәтендә саналырга хаклы. Алар характерларның җанлылыгы, үзенчәлеклеге, теленең образлы, милли үзгәлекле булуы белән аерылып торалар.

Театр өлкәсендәге зур хезмәтләре өчен К. Тинчуринга 1926 елда «Татарстанның атказанган артисты» дигән исем бирелә. 1934 елда аны Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул итәләр.

Утызынчы елларның урталарында көчәйгән культ чорындагы репрессияләр К. Тинчуринга да кагыла. Аны нахакка гаепләп кулга алалар, бернинди нигезсез «халык дошманы» исеме тагалар. Олы талантның гомере 1938 елның 14 ноябрендә Казанда Пләтән төрмәсендә өзелә. Кызганычка каршы, аның хәтта кабере дә билгесез. Сталин палачлары К. Тинчуринның язганнарын да билгесез итәргә, халык хәтереннән исемен җуярга тырыштылар.

Әмма тарихта хаклык барыбер өстен чыга. Илленче елларның ахырында Кәрим Тинчурин иҗаты халыкка яңадан кайтарылды, китаплары басыла, әсәрләре кат-кат сәхнәләрдә уйнала башлады. Г. Камал исемен йөртә торган Татар дәүләт академия театры һәр театр сезонын К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл» мелодрамасы белән ачып җибәрә. Казандагы профессиональ театр — Татар дәүләт драма һәм комедия театры — 1989 елдан аның исемен йөртә.

Сораулар һәм биремнәр

1. К. Тинчуринның тормыш юлы турында сөйләгез. Аның юлында нинди авырлыклар булуын мисаллар белән раслагыз.

2. Бу язучының нинди әсәрләрен укыганыгыз яисә сәхнәдән караганыгыз бар? Аларның бигрәк тә кайсысы сезгә ошады?

3. «Сакла, шартламасын!» комедиясен өйдә укыгыз. Андагы образларны сурәтләгез. Автор монда нинди көлдерү чараларыннан файдаланган?

4. «Кәрим Тинчурин — күпьяклы талант иясе» дигән темага сөйләшү уздырыгыз.

5. К. Тинчуринның артист, режиссёр, язучы булуын мисаллар белән раслагыз.

6. Язучы белән бер чорда иҗат иткән башка драматургларның исемнәрен атагыз, әсәрләрен искә төшерегез.

«Американ»

(1924)

Чит илдән профессор килгән...

Уку йортларының берсендә студентлар тарих түгәрәге оештыралар. Ләкин түгәрәк җанланып китә алмый: материаллар җитми. Менә беркөнне шәһәр байларының берсендә борынгы кулъязмалар, ярлыклар саклануы турындагы хәбәр ишетелә. Ләкин аларны ничек кулга төшерергә? Бай үз теләге белән бирмәячәк, чөнки кулъязмаларның бәһасен ул белә. Ярлы студентлар, билгеле инде, байны канәгатьләндерерлек акча тәкъдим итә алмыйлар. Шуннан соң Искәндәр исемле студент бер хәйлә тәкъдим итә...

Шәһәргә Америкадан татар профессоры килгән дигән хәбәр, яшен тизлеге белән таралып, ыгы-зыгы тудыра. Бигрәк тә кичә җәмәгать хадимнәре булып йөргән, бүген исә җәмгыятьтә үзләренә урын да, хезмәт тә таба алмаган кешеләр әсәрләнгәннәр. Һәркем профессор белән танышып, якынаеп, үзе өчен бер-бер файда чыгармакчы. Мусаның, мәсәлән, җиткән кызын профессорга кияүгә биреп, Америкага күчеп китәсе килә. Габдуллаҗан бай, профессорны үз кияве итә калса, Америкадан вагонлап-вагонлап мал кайтартып, сәүдәсен тагын да киңәйтер иде. Шәехмирзаның да үз хыялы: «факультет ярым бетергән»енә таянып, Америкага барып профессор булу. Советларны яратмаучы мирза Насих Николаевич та, электәге полиция полковнигы Сәлимгәрәй дә, карт зыялы Нигъмәт тә, тарихчы Сәлим дә милли профессор белән танышуны үзләре өчен мәртәбә саныйлар. Асылда, бик тар карашлы, чын тормыштан ерак торган бу кешеләр, олы кунакка якынрак елышу өчен, үзара ярышалар, ызгышып бетәләр. Бигрәк тә Габдуллаҗан белән Муса нык чәкәләшә, һәр икесе профессорны кияү итәргә хыяллана. Ә «профессор»ның төп теләге исә — кулъязмаларны кулга төшерү, форсаттан файдаланып, тәмле ашап-эчеп калу. Нәтиҗәдә ул шуңа ирешә: кызыңа өйләнәм дип, кулъязмаларны кулга төшерә дә чыгып кача.

Әсәрнең эчтәлеге менә шуннан гыйбарәт. Аны бер сюжет сызыгына салуы да кыен түгел. Студентларның план коруы белән тәмамланган беренче пәрдә экспозиция өлешеннән, ягъни булачак вакыйгалар һәм аерым персонажлар белән таныштырудан тора. Дөрес, алга таба вакыйгаларда студентлардан

икесе — Искәндәр белән Апуш катнашачак. Аның каравы алар, бигрәк тә Искәндәр, ул вакыйгаларның үзәгендә кайный, аларның ничек оешуында, хәл ителешендә төп рольне уйный.

Искәндәр — профессор, Апуш аның иптәше булып Мусалар өендә пәйда булуларын сюжет сызыгының төенләнеше дип билгеләргә мөмкин. Моннан соң вакыйгалар үстерелә, сюжет сызыгы яңадан-яңа персонажлар белән байый, яңадан-яңа көлке хәлләр туып тора. Профессорны үзенә карату, ахыр чиктә «профессор кияүле булу» өчен барган тартышның иң югары ноктасы итеп (аны кульминацион нокта диләр) Искәндәрнең Габдуллаҗан алдына таләп куюын алырга кирәк. «Я син тарихи кулъязмаларны бирәсең һәм мин синең кызың Мәйсәрәгә өйләнәм, юк икән, Дилбәрне кәләшем дип игълан итәм!» — ди профессор. Искәндәрнең кулъязмаларны эләктереп чыгып качуы — сюжет сызыгындагы соңгы буын — чишелеш була.

Көрәш нәрсә өчен бара?

Комедиянең үзенчәлекләреннән берсе шунда: вакыйгаларның үзәгендә яткан тартыш, ягъни конфликт ике юнәлештә бара. Берсе — Искәндәр белән Габдуллаҗан арасында кулъязмалар өчен барган көрәш. Икенче көрәш учагы Муса һәм аның кызы Дилбәр белән Габдуллаҗан һәм кызы Мәйсәрә арасында кабына. Монысының нигезендә профессорны кияү итеп эләктерү омтылышы ята. Һәрберсе мөстәкыйль юнәлештә барган кебек булса да, бу конфликтлар ахырдан бер яссылыкка төшеп җыела. Чөнки беренчесенең асылы икенчесенең үзәген тәшкил итә.

Бу бәрелешләрнең төп үзенчәлеге шунда: алар көлкеле халәт тууга хезмәт итәләр. Гади бер студентны «профессор» дип кабул итү, шуны аера белмәү, аның кайбер тозсыз кыланышлары (сөйләшкәндә, корсакка төртеп кую гадәте) һәм чамадан тыш арттырып ялганлаулары («мин бөтен Америка шәһәрләренең университетларында эшлим», «минем йөз дә биш автомобилем бар» h.б.) бары тик комедиядә генә мөмкин. Тагын башка даулашулар һәм көлкеле күренеш-хәлләр әсәрнең буеннан-буена бара. Мәсәлән, ач студентларның «пәрәмәч җитәрме икән?» дип борчыла-көенә тамак туйдырулары; «факультет ярым бетергән» Шәехмирза Юкабашовның (!) үзен

таныту, күрсәтү өчен һәркем белән гел бәхәскә кереп әрсезләнүе; профессор белән очрашу мәҗлесендә кем башлап сүз әйтергә тиешлеге хакында бәхәсләшү һ. б. Габдуллаҗан белән хатыны Разия арасындагы тартышу да гаять көлкеле: ирнең үз хатыны авызыннан «сиңа әйтәм», «атасы» дигән «иске» сүзләрне чыгарып ташлатып, аны зыялы итеп күрсәтәсе килә; Разияның исә, иренә исеме белән эндәшеп, гөнаһлы буласы килми. Дилбәр белән Мәйсәрә арасында кияү өчен барган яшертен көрәш тә бик оста эшләнгән. Габдуллаҗан белән Муса арасындагы тартышу да үзен гел сиздертеп тора. Һәр ике ата үз кызын дәрәҗәле профессор кәләше булырга лаеклы дип саный, ә туташларның икесенең дә кимчелекләрен һич яшерерлек түгел. Аталарның үзләрен әйбәт итеп, берсенең зур галим, икенчесенең «тәрәккый пәрвәр», зыялы итеп күрсәтәсе килүдән дә күпме көлке туа. Муса уңайны да, кимчелекне дә «миллилек» пәрдәсе белән яба. Габдуллаҗан бөркелеп торган тупаслыгын һәм наданлыгын сиздермәскә тырыша, «зыялы» булырга омтыла. Болар һәммәсе тамашачыда һәм укучыда мыскыллы елмаю, көлү хисе уята.

Комедиядә тагын бер үзенчәлекле көрәш бар. Ул беренче карашка күренми, каядыр тирәндә ята, аны чын мәгънәсендәге тигез көрәш дип тә әйтеп булмыйдыр. Бу — кайбер персонажларның Совет хакимиятенә каршы булулары. Аның чаткылары беренче пәрдәдә үк, студентлар тормышында ук күренә. Яшьләр арасында мулла малае Касыйм яңа тәртипләрдән ризасызлыгы белән аерыла. Автор, шул көннәр күзлегеннән карап, Касыймны көлке объекты итеп ала. Ә бүгенге югарылыктан торып караганда, егет дөрес фикерләр дә әйтә. «Иртә җыр, кич җыр,— дип сукрана Касыйм.— Каян чыга бу кешедә бетмәс-төкәнмәс перманентный[1] җыр... Нәрсәгә дәртләнә торганнардыр». Яки студентлар өчен ашханә ачылачак дигән яңалыкка да ул шөбһә белән карый: «Алты айдан бирле ишетәбез лә без аны»,— ди. Совет хакимияте чорындагы аерым төсмерләр, планнарны зурдан алып та, аларның үз вакытында үтәлмәве кебек кимчелекләр сизелеп кала монда.

Яңа җәмгыять шартларын кабул итмәгән яки кабул итеп бетермәгән кичәге «җәмгыять баганалары»ның күбрәк эчке теләген чагылдырган бу көрәшне чын мәгънәсендә конфликт дип тә булмый: чөнки бу «баганалар» — артык мескен, көчсез,

---

[1] *Перманентный* — даими, өзлексез.

үзләреннән көлергә генә ярарлык бәндәләр. Аларның теләк-максатлары да тормышка һич ашарлык түгел. Шәехмирза, билгеле инде, бу илдән китеп, Америкада профессорлык урынын ала алмаячак. Сәлимгәрәй, Насих Николаевич һәм Сәлимнәр дә — буш куык. Шулай да алар астан гына эш йөртергә каршы түгелләр, советлар җимерелер дә, без әүвәлге хәлебезгә кайтырбыз, дип өметләнәләр. Җае чыкканда, өркеп-куркып кына булса да зарланып (чөнки яңа хакимият аларның котын алып бетергән!), үзләренчә яңа тәртипләргә тискәре мөнәсәбәтләрен сиздереп, кечкенә генә булса да этлек ясарга әзер торалар. Нигъмәт: «Иске мунча, яңа таш, һаман шул бер балык башын чәйниләр. Тегеләй эшлибез, болай эшлибез дип мактанудан уза алмыйлар әле. Юньләп эшләгән бер эшләре юк. Мәмләкәт тоту бунт чыгару түгел икән шул»,— дип сөйләнгәндә, аның хаклыкка якын торуын бүгенге укучы-тамашачы аңлый. Шул ук Нигъмәт профессорны каршы алуга әзерләнү, банкетның программасын төзү өчен җыелыш уздырырга, «вакытлы гына бер рәис, бер сәркатип сайларга кирәк» дигәч, Насихның: «Сез, Нигъмәт әфәнде, соңгы вакытта тәмам кызыллашып киттегез. Нигә кирәк рәис! Банкет — банкет ул. Сөйләрбез, тост күтәрербез»,— диюендә дә дөреслек бар. Монда кайбер мәсьәләләргә драматургның үзенең дә иронияле мөнәсәбәте сизелеп кала. Чөнки яңа система вакытында юк кына мәсьәләне дә озын-озак җыелышларда тикшерү киң таралган иде.

Шуның белән бергә, драматург кайбер персонажларның күп кенә хыял-өметләрен, эш-гамәлләрен мыскыллап көлә. Бу мескеннәрнең «милләт өчен», «милли» дип сөйләнүләрендә дә көлкедән башка нәрсә юк. Ни өчен дигәндә, аларның миллилеге үзләре өчен генә җайлыны эзләүдән, үз кимчелекләрен каплау-яшерүгә омтылудан тора. Икенче яктан, автор башка төр фәлсәфәгә таянган кешеләрдән дә каһкаһәләп көлә:

«Насих. Профессор әфәнде, менә бу безнең солтанәтле[1], көчле рус иле төрле вак җөмһүриятләргә бүленүенә менә безнең ватанпәрвәрчеләрнең йөрәкләре бик әрни. Русның гали ханданы[2] хөкем сөргән вакытларда бөтен халыкка рәхәт иде, татарларга аеруча рәхәт иде. (...) Менә мәрхүм падиша хәзрәтләренең кучеры, ат караучысы татар булган. Менә

[1] *Солтанәт* — мәһабәтлек.
[2] *Хандан (ханәдан)* — гаилә, династия, нәсел.

бит падиша хәзрәтләре дә татарларга ничек ышанган. Менә хәзерге Совет власте, төрле халыкларга мохтариятле[1] җөмһүриятләр биреп, утарларны талап алып, халыкны узындырды. Сез уйлап карагыз, җөмһүрият төзегән булып, җыен балачаганы эш башына утырттылар. (...)

Сәлимгәрәй. Әле тагын көчләп татар телен укыталар.

Насих. Да, да, бусы инде — бик зур ахмаклык. Мин французча, инглизчә, немецча, хәтта японча да укытуны аңлыйм, ә инде татарча өйрәтүне һич башым сыйдыра алмый. Безгә, татарларга, культура кирәк, ә алар татарча укытып маташалар. Безне, яшьлектә татарча укый алмаган картларны, татарча укырга мәҗбүр итәләр. Бу мәсхәрәлек, позор, издевательство! Нигә миңа кирәк татарча уку?»

Күрәбез, Насих Николаевич кебекләрнең фикере бүгенге «бүленмәс Россия» шигарен тәкрарлаучыларның карашыннан ерак китми. Патша хакимиятенең олтан астын һәм коллыкны сагынган мондый кешеләрдән тарих та, тамашачы һәм укучы да мыскыллап көлә, әлбәттә.

Бер яктан, «миллилек» дип сәүдә итүче, икенче яктан, бөек державачыл фикерләргә табынган бу капма-каршы көчләр ничек алай берләшә алган соң? Монда нинди көч уйный? Ул — яңа шартларны, үзләрен кире каккан җәмгыятьне күралмаудан туган көч, билгеле.

Көлкене арттыручы ысул-чаралар

Пьесаның **сатирик комедия** булуын тәэмин иткән өстәмә чаралар һәм ысулларны да драматург бик белеп кулланган.

Көлүне тудырган, барлыкка китергән иң үтемле чаралардан берсе — ул эчке мәгънә белән тышкы форманың туры килмәве. Чыннан да, мондагы персонажлар, бер яктан, үзләрен башкаларга танытырга тырышалар, үзләре турында зур итеп уйлыйлар, икенче яктан, аларның үз-үзләрен тотышында, эш-гамәлләрендә көчле аерма бар. Бу аерманы автор шундый итеп ачып сала, укучы һәм тамашачы тыела алмый көлә.

Карагыз инде ул Шәехмирзаны! Адым саен «мин факультет ярымфакультет бетергән» дип мактанган бу кешенең тупас-

---

[1] *Мохтарият* — бәйсезлек.

лыгы, мин-минлеге һәм әтәчләнүе, үзен Европада беренче галим дип санап та, базарда тоз төреп сатарга гына яраклы бер китап чыгарган булуы үз ишләре арасында да мыскыллы көлү уята.

Менә шунда без К. Тинчурин кулланган тагын бер алымны күрәбез. Тискәре геройларның кимчелекләре үз ишләре тарафыннан ук фаш ителә. Ягъни искелекне генә яклаучы бу көчнең эченә корт төшкән, ул үзен үзе ашый. Тискәрене тискәре тарафыннан инкяр итүдән драматург гаять оста файдалана.

Эчтәлек белән форманың туры килмәвенә ачык мисал — Габдуллаҗан образы. Сәүдәдә зур уңышка ирешкән бу кешенең яшертен теләге — үзен зыялы, тәрбияле итеп таныттыру. «Син, Габдуллаҗан әфәнде, бер сәүдәгәр генә. Зыялылар сөйләшкәндә тыңлап торырга кирәк»,— дип, Шәехмирза әйтеп тә тора инде үзенә югыйсә. Ләкин зыялылыкка омтылышы бик көчле шул аның. Әнә бит ул хатыны белән кызын ничек тырышып «тәрбияли». Тик шунда тупаслыгы һәм тәрбиясезлеге тагын өскә бәреп чыга:

«Р а з и я. Бәйләнмә инде, сиңа әйтәм...

Г а б д у л л а җ а н. Сиңа әйтәм?! Сиңа әйтәм?! Әллә син мине авылдан базарга кәбестә төяп килгән гыйбди[1] дип уйлыйсыңмы?! Яңадан шул «сиңа әйтәмеңне» авызыңнан чыгарсаң, телеңне кадак белән тишәрмен. Гыйбди дисәң гыйбди. Мужик, надан... Бу кадәр заманны аңламаган, тәрәккыйга күнмәгән хайваннар булырсыз икән! Ат кәмитендә бит аюны да сездән яхшырак, сездән тәрәккый пәрвәррәк итеп нәзакәткә[2] өйрәтәләр. Бу кадәр аңгыра булырсыз икән. Кара аны, Разия ханым, бүген кешеләр алдына чыгасы булма! Синең өчен бөтен планнарымнан колак кагар хәлем юк. Әнә ашханәдә дөмегеп тор. Кеше итәргә, кеше арасына кертергә тырышмадым түгел инде. Алла кабул итсен. Ә син һаман үзеңнең мокытлыгыңнан аерыла алмыйсың».

Яки менә ул кызын профессорга кияүгә чыгарга үгетли. (Хәер, «үгетли» сүзе бу очракта туры килеп бетми, чөнки ул инде үзе өчен мәсьәләне хәл итеп куйган.) Бер яктан, зыялы булырга омтылыш аңа кызын мәҗбүр итмәскә куша. Икенче яктан, канына сеңгән мин-минлек, байлык өчен җан ату аны чын үзе булып сөйләшергә мәҗбүр итә. Кыска гына арада да

[1] *Гыйбди* — надан.
[2] *Нәзакәт* — нәфислек, әдәплелек.

ул үзендәге шушы капма-каршылыкны, шуны да аңламаслык наданлыгын күрсәтеп өлгерә:

«Мәйсәрә. Әем, мин аңарга чыкмыйм!

Габдуллаҗан. Сөйләп бетергәнне көт дим, юкә баш. (...) Әгәр дә насыйп булып аңарга кияүгә чыксаң, Америкага китәрсез. Ел саен берәр кат без дә барырбыз. Сез аннан, вагонлап-вагонлап, мал җибәрерсез. Без монда сатарбыз да, алтынга әйләндереп, сандыкларга тутырып, сезнең янга Америкага торырга китәрбез. Бу тупас Рачы[1] халкы арасында торуы да туйдырды инде. Төшенәсеңме, кызым, эшләрнең кая барганын? (...) Аннан соң, шуны да истә тот, кызым. Син аның аяк астында туфрак булырга тырыш. Минем өемнән чыгып киткәннән соң, тәрбияң аның кулында булачак. Кем ашын ашаганыңны һәрвакыт исеңдә тот. Яхшы булсаң, сый күрерсең, яман булсаң, ут күрерсең...

Мәйсәрә. Әем, алай ут йотарлык булгач, мин аңарга чыкмыйм.

Габдуллаҗан. Мин, кызым, тупас татар бае түгел. Әгәр дә күңелеңә ошамый икән, мин сине көчләп бирмим. Ә инде минем сүземә каршы килүең өчен, яңагыңнан утлар чыгарырмын. Мин сине утыз яшькә кадәр ашатып түремдә тотмам. Хәзер заманасы ул түгел. Гомер буе кияүгә чыкмасаң да, мин сине һичберәүгә көчләп, елатып бирмәм. Ә инде баш-баштаклыгың өчен яңагыңнан утлар чыкканны көт тә тор... Мин синең белән ике сөйләшмәм. Мин замана кешесе. Син белгән җәдидлекне мин дә беләм. Йә, ни әйтерсең, кызым?.. Дәшмисең?!

Разия. Дәшмәү — ризалык галәмәте ул, атасы.

Габдуллаҗан. Син тик тор, әрәмтамак! Дәшмәү — ризалык галәмәте, дип эш кылырга мин кадим бай түгел. Миңа үз теле белән шартлатып әйтеп бирсен. Мин аны көчләп бирергә теләмим. Инде минем планнарымны җимерә икән, үзенә үпкәләсен. Яңагын кабыргалы бозау кәтлитеннән ким ясамам. Йә, кызым!.. Мин көтәм!

Мәйсәрә. Риза.

Габдуллаҗан. Менә, бәрәкалла, кызым. Менә бу эш чын җәдид, зыялыларча булып чыкты. Үзеңә дә уңай, миңа да яхшы. Халык күзендә дә күңелле».

Шул рәвешле, персонажның үз-үзен фаш итүе кебек алымнан драматург монда бик оста файдаланган. Моңа ул татар

---

[1] *Рачы* — Россия.

теленең эчке мөмкинлекләре, сүз уйнату, сүзне аңламаганга сабышу һ. б. ярдәмендә дә ирешә. Мәсәлән, «джунгли» дигән инглиз сүзен Искәндәр «җон даласы» дигән татар сүзләреннән китереп чыгара. Ә бу милләтчеләргә бик ошый. Яки Габдуллаҗан кызына: «Теге мутный күлмәкләреңне киеп, рәтләнеп, хәзерләнеп тор»,— ди. Ягъни «модный» сүзе урынына «күз кыздыру» мәгънәсендәге рус сүзен куллана. Яисә әнә Мәйсәрә Дилбәр белән бәхәсләшә:

«Мәйсәрә. ...Эти әйтә, әгәр дә, ди, шул профессорга барсаң, ди, ни генә сорасаң да кызганмам, ди. Әбәзиян тун тектерермен, ди.

Дилбәр. Әбәзиян — маймыл була бит ул. Маймыл тиресе киеп йөрерсеңмени?

Мәйсәрә. Әбәзиян нишләп маймыл булсын ул! Мех ул,бик кыйммәтле мех. Әй мескен, шуны да белмисеңмени? Маймыл булса, кем кияр иде соң аны? Әбәү, маймыл тиресен киярргә!»

Ә «америка профессоры» исә, кайбер сорауларны юри аңламаганга сабышып, башка җаваплар бирә:

«Сәлимгәрәй. Виноват, ваше превосходительство! Бездәге бу коммунистлар, Советлар һәм вак-төяк җөмһүриятләр турысында Америка җәмәгатьчелегенең фикере ничек?

Искәндәр. Бик һәйбәт. Быел мамык, шоколад, дөге, автомобильләр бик уңды».

Ялганлау, күпертү, күрәләтә алдашу — болар барысы да персонажларның эчке бушлыгын, наданлыгын, оятсызлыгын ачуда эшкә җигелгән. Муса, мәсәлән, профессор «минем бөтен әсәрләремне укып чыккан» дип кенә канәгатьләнми, «безнең мәрхүм әткәй белән профессор хәзрәтләренең әткәсе шәрик[1] булып укыганнар... профессор хәзрәтләре ана ягыннан безгә кардәш тә була икән» дип тә күзгә төтен җибәрә.

Кыскасы, милли тарлык һәм нигилизм[2] кебек күренешләрне кертеп, наданлык, мин-минлек, зур байлыкка омтылу, кеше җилкәсендә яшәргә тырышу, хөсетлек кебек сыйфатларны тагып, драматург эшлексез «каһарманнарыннан» үткен көлә, мондый сыйфатларга ия булган кешеләрнең урыны тарих чүплегендә булуын күрсәтә.

«Американ», «Сакла, шартламасын!», «Җилкәнсезләр» кебек әсәрләре белән Кәрим Тинчурин татар драматургия-

---

[1] *Шәрик* — иптәш.

[2] *Нигилизм* — кабул ителгәннәрне тулаем кире кагу, инкяр итү.

сенең комедия төрен яңа баскычка күтәрде, сәхнәне кабатланмас яңа сатирик типлар белән баетты.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Американ» комедиясенең төп конфликтын билгеләгез.

2. «Әдәбият белеме сүзлеге»ннән файдаланып, комедиядәге сюжет үстерелешен барлыкка китергән элементларны санап-күрсәтеп чыгыгыз.

3. Әсәрдәге сатирик типларны характерлагыз. Аларның һәрберсенә нинди төп билге-сыйфатлар хас?

4. «Насих Николаевич — манкорт» дигән фикерне раслагыз.

5. «Американ» белән «Сакла, шартламасын!» комедияләрендәге сатирик типлар арасында нинди уртаклыклар һәм аерымлыклар күрәсез? Бу әсәрләрдә акчаның һәм байлыкның роле ничек күрсәтелә?

6. Бу әсәрләрдән көлке тудыру чараларына мисаллар китерегез.

7. «Кәрим Тинчурин — комедия остасы» дигән темага инша языгыз.

* * *

Комедия дип матур әдәбиятта драматургия төренең бер жанрын атыйлар. Бу атаманың нигезендә «күңел ачу», «көлке» дигән мәгънәдәге грек сүзе ята. Дөрес, көлке әсәрләр матур әдәбиятның башка төрләренә дә хас. «Шаян хикәя», «сатирик повесть», «юмористик шигырь» дип атауларны беләбез. Ләкин «комедия» дип атау бары тик сәхнә әсәрләренә карата гына кабул ителгән.

Комедиянең билгеләмәсе һәм вазифасы — иҗтимагый тормыштагы яки көнкүрештәге тискәре күренешләрдән көлү, кеше менәзендәге (характерындагы) көлкеле якларны күрсәтү.

Алдагы сыйныфларда берничә комедия өйрәнелде. Халыкчан шаянлыкка, юморга бай булган «Хуҗа Насретдин», сатира элементлары белән баетылган «Беренче театр», хәерхаһлык белән яратып, үз итеп көлүгә корылган «Бәхетле кияү» комедияләре мисалында бу жанрның төрләре күп булуы күрсәтелде. Ягъни комедия көлүнең төрле дәрәҗәләре белән эш йөртә. «Банкрот» һәм «Американ» комедияләрендә бу — сатира. Мондый әсәрләрнең сюжеты һәм конфликты мыскыллап көлү өчен җирлек бирә, сатирик персонажларның килешсез якларын фаш итү өчен мөмкинлек тудыра. Вакыйгалар кызыклы, образлар сәнгатьчә үзенчәлекле һәм кабатланмас булсын өчен, драматурглар күптөрле көлке тудыру чараларыннан файдаланалар.

ЭЧТӘЛЕК

XX гасырда татар әдәбияты

Гасыр үзенчәлекләре. *А. Әхмәдуллин* 3
Яңа гасырга аяк басканда. *Ф. Галимуллин* 11

Проза

Гаяз Исхакый. *Ф. Галимуллин* 22
Фатих Әмирхан. *И. Нуруллин* 66
Шәриф Камал. *А. Әхмәдуллин* 91
Татар прозасы ирешкән уңышлар. *Ф. Галимуллин* 103

Шигърият

Яңарыш нурлары. *Ф. Галимуллин* 110
Габдулла Тукай. *Ф. Галимуллин* 122
Дәрдемәнд. *Ф. Галимуллин* 161
Сәгыйть Рәмиев. *Ф. Галимуллин* 178
Нәҗип Думави. *Ф. Галимуллин* 202

Драматургия

Яңа уңышларга юл ярганда. *А. Әхмәдуллин* 214
Галиәсгар Камал. *А. Әхмәдуллин* 230
Гафур Коләхмәтов. *А. Әхмәдуллин* 251

XX йөз башында балалар әдәбияты. *Ф. Галимуллин* 269
Иҗтимагый фикер үсеше һәм публицистика. *Ф. Галимуллин* 273
Әдәби тәнкыйть. *Ф. Галимуллин* 276
Совет хакимияте чорына кергәндә татар әдәбияты. *А. Әхмәдуллин* 279
Галимҗан Ибраһимов. *М. Хәсәнов* 290
Һади Такташ. *Ф. Галимуллин* 327
Егерменче еллар әдәбияты. *Ф. Галимуллин* 360
Фатих Әмирхан. «Шәфигулла агай». *А. Әхмәдуллин* 376
Кәрим Тинчурин. *А. Әхмәдуллин* 385

Учебное издание

Хасанов Мансур Хасанович
Ахмадуллин Азат Гильмуллович
Галимуллин Фоат Галимуллович
Нуруллин Ибрагим Зиннатович

ЛИТЕРАТУРА

(Татарская литература начала XX века и 20-х годов)

Учебник для 10 класса
средней общеобразовательной школы
с татарским языком обучения

Издание четвёртое, исправленное

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Хәсәнов Мансур Хәсән улы
Әхмәдуллин Азат Гыйльмулла улы
Галимуллин Фоат Галимулла улы
Нуруллин Ибраһим Зиннәт улы

ӘДӘБИЯТ

(XX гасыр башы һәм 20 нче еллар татар әдәбияты)

Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең
10 нчы сыйныфы өчен дәреслек

Төзәтелгән дүртенче басма

Мөхәррире *В. Г. Гомәрова*
Бизәлеш мөхәррире *Л. Р. Вафина*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Л. И. Матвеева*
Корректорлары *Т. Н. Сәгъдуллина, А. М. Закирова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 16.09.2011. Форматы $60 \times 90^1/_{16}$.
Шартлы басма табагы 25,0 + форз. 0,25. Тиражы 10200 д. Заказ Р-1334.

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Безне адәм иткән уку,
Адәмне алга илткән уку.

Сәгыйть Рәмиев

Әдәби вә шигъри әсәрләргә
һичбер төрле тәэсир
бирмәгән адәм юк.

Галимҗан Ибраһимов

9 785298 021012